*Тази* ***Гиззат***
*(Гиззатов Тази Калимович)*

ПЬЕСЫ
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

2006

УДК 821. 512. 145-2
ББК 84 (2 Рос = Тат)-6

Г92

**Гыйззәт Т.К.**

Пьесалар: Таҗи Гыйззәт / Төз. Казбек Гыйззәтов.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.—384 б.

ISBN 5-298-03930-8

Күренекле татар драматургы Т.Гыйззәтнең бу җыентыгына, нигездә, 1939 — 1949 елларда иҗат иткән пьесалары туплап бирелде.

ISBN 5-298-03930-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2006

© Гыйззәтов К.Т., төзү, 2006

# ЯЛКЫН

**(Фәрхиназ)**

*Драма дүрт пәрдәдә, биш күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Маһитап — ярлы карчык.
Җиһанша — аның улы.
Каһәрман — аның кече улы, читтән йөреп кайткан егет, матрос.
Иргали — аларның күршеләре, мич чыгаручы.
Абруй — аның хатыны.
Фәрхиназ — аларның кызлары.
Айдар — авылның абруйлы карты.
Тимерша — аңлы кеше, суык тимерче.
Мөстәкыйм — авылның зур бае, тегермәнче.
Файзә — аның олы хатыны.
Сәетҗан — Файзәнең артыннан килгән улы.
Хәдичә — Мөстәкыймнең икенче хатыны.
Мөхсин — авыл мулласы.
Фәезхан — куштан.
Ишнияз — староста.
Камай — сотник.
Ротмистр — шәһәрдән килгән команда башлыгы.
Исправник — административ начальник.
Гөлҗамал — күрше хатын, җиңгәчи.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Маһитап карчыкларның ишегалды. Алгы планда җилкапка һәм урам. Уң якта — өй. Сулда — читән койма. Читән аша Иргалиләр өе күренә. Пәрдә ачылганда, өйдән Маһитап карчык чыга. Күз өстенә кулын куеп, күктән нидер карана.

Маһитап. Яңгырлар булыр, ахры, кояш ничек кыздыра.

Айдар керә.

Айдар. Ни югалттың, Мәһитап килен, нәрсә күзлисең?

Мәһитап. Явымнар булыр кебек, көн бик кыздыра, дим.

Айдар. Булыр, Мәһитап килен, булыр. Иртәдән бирле карлыгачлар да түбән очалар.

Мәһитап. Булсын инде, Айдар абзый, бик корыга китте бит. Бәрәңгеләр дә сусаган. Нишләп йөрисең?

Айдар. Алты яшьлек юлдан кайтса, алтмыш яшьлек күрергә килә дигәндәй, күрше авылда кызымда идем, Каһәрман кайткан икән, өйдәме?

Мәһитап. Каядыр чыгып киткән иде.

Айдар. Бик баеп кайткан, диләр.

Мәһитап. Ярый инде, бераз акчасы да бар, өс-башлары да бөтен. Барыннан да бигрәк үзе исән-сау кайткан, шуңар шатланам.

Айдар. Шулай булмый ни. Бик күп еллар читтә йөрде бит.

Мәһитап. Кызым, Фәрхиназ!

Фәрхиназ (*тәрәзәсен ачып*). Нәрсә, әби?

Мәһитап. Җиһанша абыең уянса, әйтерсең, күрше Сәйфуллага сөлек салырга керәм.

Фәрхиназ. Ярый, әби, әйтермен.

Айдар. Мич чыгаручы Иргали кызы түгелме? Сездә нишли ул?

Мәһитап. Каһәрманның киеп кайткан киемнәрен яратмыйм, Фәрхиназдан алача күлмәк-ыштан суктырам. (*Сөйләшә-сөйләшә, Айдар белән китәләр.*)

Фәрхиназ. Су буена төшәр идем,
Су басмасы тал булса.
Һич теләгем калмас иде,
Үз сөйгәнем яр булса.

Тимерша керә.

Тимерша. Хуҗалар өйдәме?

Фәрхиназ. Каһәрман абый каядыр чыгып китте. Җиһанша абый өйалдында йоклый.

Тимерша (*өйалды тактасын кагып*). Җиһанша, Җиһанша, дим!

Корсагын кашып, өйдән Җиһанша чыга, көянтә-чиләк күтәреп,
Иргали керә.

Җиһанша. Әйдә, өйгә керик, Тимерша.

Тимерша. Көпә-көндез нишләп йоклап ятасың?

Җиһанша. Төнлә убыр саклаган идек.

Тимерша. Нинди убыр?

Җиһанша. Ишетмәдеңме? Безнең авылга убыр ияләшкән.

Тимерша. Кем әйтә?

Җиһанша. Камай сотник күргән. Һәр Ходай бирмеш төнне, беренче әтәч кычкыруга, чуаш Кирәмәтеннән чыга да, тубал кадәр ут булып, безнең авылга очып килә, ди.

Тимерша. Ышанма, юк сүз ул.

Җиһанша. Нишләп юк булсын? Мал-туар арасында үләт булу юкка түгел. Авылда уйнаш итүчеләр, убырлы хатыннар бар, дип, җомга намазында хәзрәт сөйләгән.

Иргали. Үләт дигәннән, бүген Саттар Ахунның да сыеры чирләгән.

Җиһанша. Менә күрдеңме? Убыр эше инде ул.

Тимерша. Әй, калдыр әле шул юк-барларга ышануыңны. Әнә алпавыт Алкин өяздән кайткан, судта тагын безне откан, ди.

Җиһанша. Отмый ни? Ул Фәезхан нәрсә белә соң? Мине җибәрмисез бит, күптән эшен бетергән була идем.

Абруй керә.

Абруй. Ай-һай-һай! Һай-һай! Мин анда су көтәм, ә ул монда кергән дә корсагын терәгән.

Иргали. Ярый инде, Абруйкамал, дулама, үтеп барышлый гына туктадым.

Абруй (*үчекләп*). Үтеп барышлый гына, имеш, уҗым бозавы!

Тимерша. Әбәү, Абруй җиңги, нигә инде бу кадәр чиныйсың?

Абруй. Чинау гына түгел, утырып еларсың. Мин анда су көтәм, ә ул монда кергән дә эшсез Җәмәйләргә иш булган. Бар, бар! Атлавыңны бел!

Иргали. Төрткәләмә, барам лабаса. (*Көянтә күтәреп китә башлый.*)

Мәһитап карчыклар өеннән Фәрхиназ чыга.

Фәрхиназ. Тукта, эти, үзем барырмын. *(Иргалидән көянтә-чиләкләрне алып китә башлый.)*

Абруй. Барма, үзе барсын. Сиңа әйтәм түгелме? Фәрхиназ, дим! *(Фәрхиназ югала.)* Ярый, көләү карачкысы, өйгә кайтырсың әле!.. *(Иргалигә.)* Йә, нәрсәгә каттың? Әйдә, өйгә утын ваклап кертерсең. *(Төрткәләп алып китә.)*

Тимерша. Ай-яй... Хатының яхшы булса — казна, яман булса — каза, дип белеп әйткән бабайлар. Каһәрман кайтмас, ахры.

Җиһанша. Йомышың бар идемени?

Тимерша. Күрергә килгән идем.

Чыгып киткән яктан Айдар керә.

Айдар. Бу нинди оятсыз кеше булды соң?!

Җиһанша.Тагын ни булды, Айдар абзый?

Айдар. Тегермән алдына төшкән идем, Мөстәкыйм мөртәт буабызга тагын кабык салдырып ята.

Тимерша. Шулай инде, егылганны түбәләргә җиңел бит.

Айдар. Юк, Тимерша, түбәләтмәбез.

Җиһанша. Шауламагыз, үзе килә.

Мөстәкыйм керә.

Мөстәкыйм. Киңәшләр берексен.

Җиһанша. Әйдүк, Мөстәкыйм абзый, уртасында бул.

Айдар. Быел тагын судан мәхрүм итәсең икән.

Мөстәкыйм. Нигә мәхрүм булырга? Чишмә суыбыз бар, шуннан эчәрсез.

Айдар. Юк инде, бер чакрымнан ташып эчмәбез! Авылның язмышы белән уйнарга да ирек бирмәбез.

Мөстәкыйм. Тегермәнегезне приговор белән ун елга миңа бирдегезме?

Айдар. Бирсәк! Без бит сиңа мунчала салып суны сасытырга түгел, он тартырга бирдек.

Мөстәкыйм. Ун елга кадәр су минеке! Мин анда он тартаммы, мунчала саламмы — сезнең эш түгел.

Айдар. Юк, безнеке! Кайчанга кадәр сиңа баш иеп торырбыз? Бабаң, ерак басуыбызны бер кадак чәйгә сатып, җирсез калдырды. Атаң комсыз урманыбызны корытып бетерде. Син инде суыбыздан да мәхрүм итәргә җыенасыңмы?

Мөстәкыйм. Бу халык дигәннән, рәхмәт юк икән. Үткән ел, минем мунчалам булмаса, ярты авылыгыз тәпиен суза иде. Авылга эш булсын дип тырышасың-тырмашасың, алар сиңа — мә!

Айдар. Әйе. Кыш буенча авыл белән сиңа кап сугабыз. Ә син һәр ел саен яңа каралтылар сузасың.

Мөстәкыйм. Хәлегездән килсә, сез дә сузыгыз.

Айдар. Без бит авыл таламыйбыз.

Мөстәкыйм. Ярый, келәузник! Бүгенгенең иртәгәсе барын онытма!.. (*Китә.*)

Айдар. Өркетмә, өркетмә, әллә мин сиңа көртлекме?

Җиһанша. Әнә Фәезхан абзый кайтып килә, өяздәндер. Фәезхан абзый, бире кер әле, бире!

Аркасына капчык аскан Фәезхан керә, кулында таяк.

Фәезхан. Әссәламегаләйкем!

Башкалар. Вәгаләйкемәссәлам!

Фәезхан. Исән-сау гына тордыгызмы?

Җиһанша. Беркөй генә, Фәезхан агай. Үзеңдә ниләр бар?

Фәезхан. Шатланырлык хәбәрләр юк, Җиһанша. Өяздә дә такыр басуыбызны алпавыт Алкин файдасына хөкем иттеләр.

Айдар. Нишләп соң ул алай?

Фәезхан. Әлеге дә баягы, шул рибез планын гына чыгарып күрсәтә.

Айдар. Соң бит ул дөрес түгел, ул җирләрне без Әби патша заманыннан бирле чәчеп киләбез. Шуны аңлатырга иде.

Фәезхан. Аңлаттым, Айдар агай, бик нык аңлаттым. Авызына шайтан төкергән, атбакат яллаган. Барлык закун китапларын алдына ачып куйган да судияләрнең күзен дә ачырмый.

Айдар. Шулай итеп, оланнар, җирсез дә калдыкмыни?

Фәезхан. Юк, Айдар абзый, калмабыз, өяздә безнең файдага хөкем итмәгәннәр икән, губернага барырбыз. Аныкыннан да остарак атбакат белән сөйләшеп кайттым, астын өскә айкап чыгарам, ди.

Тимерша. Ай-һай, эт авызына кергән беленне алырсыз микән?

Фәезхан. Алырбыз, Тимерша! Болай бирми икән, тешен коеп алырбыз! Хәзер коллык заманы түгел. Алпавытка ирек бирмәбез. Шулай, агайлар, юллык акча бирсәгез, атбакатка акча бирсәгез, судияләргә төртерлек акча бирсәгез, бүген үк мин губернага юл тотам.

Айдар. Җибәрергә кирәк, оланнар.
Җиһанша. Әйе, әйе. Ятып калганчы, атып кал, дигән бабайлар.
Айдар. Тик акчасын кайдан табарбыз?
Җиһанша. Бозау киртәсен сатыйк.
Айдар. Әйдәгез, староста Ишниязга барып сөйләшик әле.
Җиһанша. Фәезхан агай, әллә мин дә барыйммы?
Фәезхан. Кая?
Җиһанша. Губернага, дим.
Фәезхан. Анда син нәрсәгә?
Җиһанша. Судта сиңа иптәш булырга, сөйләргә.
Фәезхан. Миңа иптәш кирәкми, Җиһанша, акча кирәк, акча! Акча булса, сүз сөйләргә мин үзем дә бик оста.
Җиһанша. Айдар абзый, Мөстәкыймне дә судка бирмикме?
Айдар. Монысының эшен бетерик әле, Җиһанша, аннан күз күрер. (*Шаулашып чыгып китәләр.*)

Фәрхиназ,судан кайтып, Иргалиләр ягына уза. Бераздан әйләнеп чыга да Маһитап карчыкларга кереп китә. Тәрәзәдән киндер су-га башлаганы күренә.
Сәетҗан керә. Фәрхиназ тәрәзәсе янына бара.

Сәетҗан. Нихәл, Фәрхиназ.
Фәрхиназ. Әбәү! Куркыттың...
Сәетҗан. Монда нишлисең?
Фәрхиназ. Күрәсең ич, киндер сугам.
Сәетҗан. Мондый матур кулмәкне кем кияр икән?
Фәрхиназ. Сәетҗан абый, тәрәзә яныннан кит әле, кеше күрсә, әллә ни уйлавы бар.
Сәетҗан. Их, Фәрхиназ, һаман мине читкә кагасың.
Фәрхиназ. Әнә кеше килә, зинһар, кит инде.
Сәетҗан. Ярый алайса, кичкә килермен, чыгарсыңмы?
Фәрхиназ. Әрсезләнеп йөрмә, чыкмам.

Мөстәкыйм керә.

Мөстәкыйм. Сәетҗан, тегермәнгә бармый нишләп монда йөрисең?
Сәетҗан. Менә Җиһанша абыйда йомышым бар иде.
Мөстәкыйм. Бар, эшеңдә бул! Сиңа әйтәләр түгелме? Алпавыт Алкиннан бүген өч йөз пот ашлык китерерләр, ике ташны да җибәрерсең, шунда кунарсың. Ашарга китерерләр.

Сәетҗан теләр-теләмәс кенә китә. Фәрхиназ тәрәзәсен яба.

Бу малай нишләп монда йөри икән?.. Әллә Фәрхиназга күзе төшкәнме?..
Абруй үтеп бара.

Абруйкамал, тукта әле. Күптәннән бирле синнән сорарга йөргән бер сүзем бар иде.
Абруй. Нинди сүз ул, Мөстәкыйм абзый?
Мөстәкыйм. Синең үги кызың Фәрхиназ холык ягыннан ничегрәк?
Абруй. Син сорама, мин әйтмим инде, Мөстәкыйм абзый. Мондый явыз кыз баланы күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде.
Мөстәкыйм. Бик усалмыни?
Абруй. Кара еланнан да зәһәррәк. Шуның өстенә үзе уңмаган, үзе булдыксыз. Аңа ир булган кеше гомеренә рәхәт күрмәс, бичара.
Мөстәкыйм. Алай икән... Туры сүзең өчен рәхмәт. Мин аны кече хатынлыкка сорарга йөри идем. Насыйп түгел икән, күрәсең.
Абруй. Мөстәкыйм абзый... Андый теләгең булгач, нигә әйтми йөрдең? Ал гына, ике куллап бирәбез.
Мөстәкыйм. Аллам сакласын, андый усал белән башка бәла тагаммы?
Абруй. Усал дип инде, ул мин әйткәнчә үк усал түгелдер. Күрше-колан белән дә бик тату тора. Минем белән генә тынышмый. Бераз гына үземдә дә гаеп бардыр инде. Әгәр дә, Мөстәкыйм абзый, аңар өйләнеп алсаң, хатынның менә дигәненә кинәнер идең. Төскә-биткә дисеңме, буйга-сынга дисеңме, бер килмәгән җире юк. Ул эшкә-солга дисәң, авылдагы бөтен кызлар чигү-чүпләм өлгеләрен аннан алалар, аннан өйрәнәләр.
Мөстәкыйм. Ул якларын ишеткәнем бар. Тик менә усаллыгы гына гайрәтемне чигерде.
Абруй. Яшь хатын булган кешегә җөбеп торырга да ярамый. Өлкән хатыннарыңның кагулары бар. Аллага тапшырыйк, Мөстәкыйм абзый, син урта бармактай яшь хатынлы бул, без бер тамактан котылыйк.
Мөстәкыйм. Атасы ни әйтер бит?

Абруй. Һи... Алла бәндәсе, минем сүздән чыкмый ул.
Мөстәкыйм. Ярый алайса, Иргалигә оеткыны салып куй. Шушы арада яучы җибәрәм, каршы алырсың.
Абруй. Ярый, ярый, Мөстәкыйм абзый, каршыلармын. (*Китә.*)

Артта тавыш ишетелә. Кулларын болгый-болгый кычкырып, Җиһанша керә.

Җиһанша. Шулай, шулай, Хөтбетдин, кабыгын алдырабыз!..
Мөстәкыйм. Кемнең кабыгын алдырасыз?
Җиһанша (*Мөстәкыймне күргәч аптырап кала*). Теге, ни... кабыгын димим. Мамыгын, дим.
Мөстәкыйм. Нәрсә мамыгын?
Җиһанша. Кәҗәнең...
Мөстәкыйм. Нинди кәҗәнең?
Җиһанша. Күрше Хөтбетдиннәрнең кәҗәсе сөт бирми башлаган, мамыгын алдырыгыз, дим.
Мөстәкыйм. Ә... Әллә син дә минем буадагы кабыкларны алдырырга йөрисеңме дип торам.
Җиһанша. Юк, юк, Алла сакласын, синең турында мин алай сөйли аламмы?
Мөстәкыйм. Әйдә әле, минем сиңа сүзем бар.
Җиһанша. Нинди сүз ул, Мөстәкыйм абзый?
Мөстәкыйм. Юлда сөйләрмен. (*Китәләр.*)

Маһитап кайтып керә. Өйдән Фәрхиназ чыга.

Фәрхиназ. Майтап әби, алачаңны сугып бетердем. Хәзер чайкарга барам.
Маһитап. Рәхмәт, кызым, бәхетең, тәүфигың күп булсын. Әниең мәрхүм генә бу көннәрне күрә алмады.

Каһәрман кайтып керә. Фәрхиназ көянтә-чиләк белән инешкә китә.

Кайда йөрдең, улым, бик озак?
Каһәрман. Әрәмәдә булдым, болында йөрдем. Тегермән алдына төшеп су кердем.
Маһитап. Ярый, улым, бик әйбәт булган. Аннан, улым, кайтканыңа ике көн, Фатыйма тутаңнарга барып күрешеп кайтсаң икән, үпкәләве бар.
Каһәрман. Юк, әни, бер атнасыз мин беркая да бармыйм әле. Мин сине сагындым...
Маһитап. Сагынсаң, алты ел буена кайтмый йөрмәс идең, сагынмагансыңдыр шул...
Каһәрман. Сагындым, әни. Тик буш кул белән кайтып күренергә гарьләндем.
Маһитап. Юләр. Ата-ана баланы мал байлыгы өчен үстерәмени?!
Каһәрман. Егет күрке дан белән, кеше күрке мал белән, диләр бит. Менә минем сезгә күрсәтерлек малым да, даным да булмады. Син, әни, минем улым начар юлда йөргән икән дип уйлый күрмә. Минем кебек мал таба алмый йөргән егетләр бик күп анда...
Маһитап. Ярый, улым, кайтып яхшы иткәнсең. Мин инде сине күрә алмый үләм дип тора идем. Аннан, улым, бу чәчеңне алдырсаң икән, әллә ничә кешедән ишеттем, урыска охшаган, диләр.
Каһәрман. Ярый, әни, алдырырмын.
Маһитап. Иртәгә бу киемнәреңне дә салырсың инде, Фәрхиназ алачаңны сугып бетерде. Бүген тегеп тә бетерәм, ди. Иллә уңган кыз да инде, Фәрхиназны әйтәм, бер генә дә кулыннан килмәгән эше юк. Кемгә генә насыйп кыз булыр инде?..
Каһәрман. Әни, минем ашыйсым килә.
Маһитап. Ярый, улым, ярый, хәзер әзерләп бирәм. Фәрхиназны әйтәм, аш-суга да бик оста... (*Кереп китә.*)

Җиһанша кайтып керә.

Җиһанша. Туганай, минем сиңа аталарча әйтә торган сүзем бар.
Каһәрман. Нинди сүз ул, абый?
Җиһанша. Син алай, кылдый-былдый буталып йөрмә, яме!
Каһәрман. Буталып? Мин нишләгән?
Җиһанша. Чит илләрдә алай да болай, бездә халыкны байлар, боярлар талыйлар икән, дип сөйләгәнсең. Килеп өстеңнән протокол язарлар, төрмәгә дә ябып куярлар.
Каһәрман. Япсалар, бик әйбәт булыр.
Җиһанша. Ничек инде ул әйбәт булыр?
Каһәрман. Миннән котылырсың. Әрәмтамак кайтты инде, дип, кешеләргә сөйләп йөргәнсең.
Җиһанша. Һи... Беткән баш!.. Сиңа аңлатып буламы? (*Өйгә кереп китә.*)

Тимерша керә.

Тимерша. Язган мал булгач, үзе әйләнеп бер кайта, диләр.
Каһәрман. Исәнме, Тимерша абый!
Тимерша. Шөкер, энем, үзең исән йөреп кайттыңмы?
Каһәрман. Менә, күргәнегезчә.
Тимерша. Болай әйбәт. Йөргән таш шомара, диләр шул. Кайларда йөрдең?
Каһәрман. Башта — Ачтерханда, балык промыслоларында булдым. Аннан Малороссиядә француз фирмасының шахталарында күмер казыдым. Аннан Одесса портында кручник булдым. Соңгы ике елны сәүдә пароходында матрос булып эшләдем.
Тимерша. Дөньяны күргәнсең икән. Мондый кытлык елны кайтмаска иде, энем.
Каһәрман. Исәбем юк иде дә, көчләп кайтардылар шул.
Тимерша. Нишләп алай?
Каһәрман. Бер маҗарага эләктем.
Тимерша. Нинди маҗарага?
Каһәрман. Баштан ук сөйләсәм, бик озак инде.
Тимерша. Сөйлә, энем, баштан ук сөйлә, бәлкем, безгә дә гыйбрәтле маҗара булыр.
Каһәрман. Безнең сәүдә пароходыбыз быел Көньяк Америкага барды. Сан-Сальвадор портына туктап, өч тәүлек буена фрукты төядек. Шушы йөк ташу вакытында аеруча тырышлык күрсәткән биш матроска шәһәргә чыгып йөрергә пропуска бирделәр. Старшыбыз боцман Пономаренко дигән егет электән дә монда булганы бар икән. Ул безгә шәһәрнең бөтен җирләрен күрсәтеп йөрде. Анда негрлар дигән кара тәнле халыклар да тора икән. Шушы бичаралар кызганыч хәлдә яшиләр... Йорт-җирләре юк, шәһәр читендәге пычрак урамнарда, диңгез буендагы көймәләрдә бала-чагалары белән торалар... Шушындый хәлләрне карап арыганнан соң, бер харчевняга кереп ашарга булдык. Менә бервакытны урамда тавыш, кычкырыш башланды... Нәрсә бар икән дип, тәрәзәдән карасак, ни күзләребез белән күрик — негр егетләрен ак тәнлеләр кыйныйлар... Без харчевня хуҗасын чакырып алдык та, нигә аларны кыйныйлар, әйбер урлаганнармы, дип сорадык. Юк, европалылар кварталына рөхсәтсез кергәннәр, шуның өчен ул кыргыйларны линча хөкеме белән үтерәләр, ди. Бу безгә гаҗәп тоелды. Пономаренко сикереп торды да: «Братишкалар, нигә без аларны үтертәбез, әйдәгез!» — ди. Без яхшы гына салган идек, кызган баштан йөгереп чыктык та кыйнаучы ак тәнлеләрне куып качырдык. Полицейскийлары килделәр. Безне алып китәргә телиләр, без аларга да баш имәдек. Шуннан безнең янга негрлар җыелды, негрлар... елый-елый кочалар, аркаларыбыздан сөяләр. Карт-корылары аякларыбызга егылалар... Диңгезгә кадәр артыбыздан озата бардылар... Ләкин корабка керү белән, безне кулга алдылар. Монда, Русиягә кайткач, суд ясап, бишебезне дә диңгез флотында эшләүдән мәхрүм итеп чыгарып җибәрделәр.
Тимерша. Әйе... Соң бит ул Американы бик бай, бик рәхәт торучы бер ил, дип сөйлиләр.
Каһәрман. Дөрес түгел. Ярлы халыкка, Тимерша абый, бер җирдә дә рәхәт юк... Син шул һаман суык тимерчелектәме?
Тимерша. Ата-бабадан калган безнең һөнәр шул инде. Соң ничек, авыл ошыймы?
Каһәрман. Күңелсез.
Тимерша. Әйе, күңелле түгел шул... Өч ел инде рәттән иген уңмады... Быел да өмет күренми... Крестьяннарны азат итәбез дигән булып, алпавыт хөкемен генә көчәйттеләр. Элек ирегең юк иде, азмы-күпме җирең бар иде. Хәзер ирегең бар, җирең юк. Җирең булмагач, аның коры иреге белән нишлисең? Әнә тагын алпавыт ярты басуыбызны кисеп ала.
Каһәрман. Ул ничек алай булып чыкты соң?
Тимерша. Ул менә болай: алтмыш беренче елны Александр патшаның манифесты буенча безнең авылны Алкиннар коллыгыннан ирекка чыгарганда, губернадан җир планы белән землемер килә. План буенча җир кисеп ала башлагач, безнең авыл картлары күрәләр — хәтта кол чагындагы җирләре дә алпавыт ягына китә. Шуннан тавыш чыгаралар, бөтен авыл белән карт алпавытка баралар. Эшнең зурга китүеннән куркып булса кирәк, карт алпавыт, план чыннан да дөрес төзелмәгән икән, әйдә, электән файдаланган җирегезне чәчә бирегез, дип, межаны искечә калдыра. Шунда безнекеләргә кулыннан кәгазь алырга, рибез планына кертергә иде, ничә әйтсәң дә, томаналык, коры сүзгә ышанып риза булганнар. Атасы үлгәч, малае колачны киң җәеп җибәрде. Чәчә торган җирләре генә җитми башлады. План буенча бу минем җирем, дип, авылны быел судка бирде. Волостьта да, өяздә дә аның файдасына хөкем иттеләр.
Каһәрман. Менә сиңа манифест!
Тимерша. Әйе. Әле мин аргы якта идем. Анда буталыш бара.
Каһәрман. Нинди буталыш?
Тимерша. Һәр авылда янгын сарайлары салдыру, янгын кораллары алдыру турында губернадан бер инструкция килгән. Шуңа каршы чыгалар.
Каһәрман. Янгын кораллары булдыру турында чара күрәләр икән, ул начар эш түгел, Тимерша абый.
Тимерша. Шулай да, энем... Мөселман авылларына чаң куйдыру яхшы нияттән түгелдер, диләр.
Каһәрман. Нинди чаң?

Тимерша. Әнә шул инструкциядә «Янгын сарайлары алдына багана утыртырга, шул багана башына чаң куярга» дигән җире бар икән.

Җиһанша (*тәрәзәдән башын сузып*). Туганай, әни бик тәмле талкан болгатты, ашарга кер.

Каһәрман. Хәзер. Әйдә, Тимерша абый.

Тимерша. Рәхмәт, энем, әле дә бик озак тордым, өйдәгеләр көтә торгандыр.

Каһәрман. Син бик кызыклы сүз әйттең бит әле, Тимерша абый. Димәк, ул инструкция белән безнең өяздән дә килерләр.

Тимерша. Килерләр. Аръяктагы шау-шу басылганны гына көтә торганнардыр.

Каһәрман. Каян аны табарга икән?

Тимерша. Үзем укый белмәсәм дә, кызык өчен мин аны алып кайттым. (*Инструкция бирә.*)

Каһәрман. Укып чыгыйм әле.

Тимерша. Аннан безгә аңлатырсың. Ярый, энем, хәзергә хуш.

Каһәрман. Хуш, Тимерша абый.

Тимерша китә. Көянтәсенә алача асып, Фәрхиназ кайтып керә. Өй янындагы колгага алача элә. Каһәрман сокланып карап тора. Урамнан Мөстәкыйм үтеп бара. Каһәрман белән Фәрхиназны күреп туктап кала. Иргалиләр өй почмагына посып тыңларга керешә.

Каһәрман. Нихәл, Фәрхиназ...

Фәрхиназ. Әйбәт әле, Каһәрман абый.

Каһәрман. Кил, күрешик.

Фәрхиназ. Кирәкми, кулым бик салкын.

Каһәрман. Димәк, йөрәгең кайнар.

Фәрхиназ. Әллә тагы, тотып караганым юк.

Каһәрман. Кил инде, күрешик.

Фәрхиназ. Ай Алла, йөдәттең инде. Хаҗдан кайткан хаҗи түгел лә, күргән — күрешкән, диләр.

Каһәрман. Йөзеңне күрәсем килә, һаман миннән качасың. Аулак калып сөйләшергә теләсәм, тизрәк чыгып сызасың. Күзең кылый, ахры, йә тешләрең кабандыр.

Фәрхиназ. Менә, мә, кара туйганчы, майлы күзең талганчы! (*Үртәп кереп китә.*)

Мөстәкыйм. Начар аучы икәнсең, тутый кошың очырдың! Ха-ха-ха!..

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Маһитап карчыклар ишегалды. Пәрдә ачылганда, Каһәрман, шомырт төбенә чалкан яткан килеш, гармунда эчпошыргыч озын көй уйный. Фәрхиназ читән башыннан тыңлап тора. Көй бетүгә, Каһәрман, өстенә әйбер ыргытып, читән артына поса.

Каһәрман. Кем ул? (*Төрле яктан эзләнә. Тагын уйнарга керешә.*)

Фәрхиназ тагын ыргыта.

Әй, малай, шаярма, дим. Тапсам, кирәгеңне бирермен... (*Тагын уйный башлый.*)

Фәрхиназ тагын әйбер ыргытыйм дигәндә, Каһәрман күреп кала.
Җирдән әйбер алып кизәнә.

Фәрхиназ. Каһәрман абый, чү!..

Каһәрман. Бәхетең, күренеп өлгердең, менә шушы таш белән җибәрә идем.

Фәрхиназ. Кызганмыйчамы?

Каһәрман. Уйнарга бирмисең бит. Кеше монда, җан тиргә батып, яңа чыккан көйне өйрәнергә тырыша, ә син аңа матыйсың. Тукта әле, нигә син күркә шикелле читәнгә кундың? Монда төш.

Фәрхиназ. Килмә, килмә! Мин үзем дә төшәрмен.

Каһәрман. Кара, син нинди кыргый икәнсең.

Фәрхиназ. Шулай булмый ни, сезнең егетләргә бит бармак бирсәң —беләктән, беләк бирсәң — күкрәктән...

Каһәрман. Алай икән...

Фәрхиназ. Каһәрман абый, кирәкми, алай үгез кебек сөзеп карама.

Каһәрман. Күзем тияр дисеңме?

Фәрхиназ. Юк, минем алай күз тиярлек йөзем юк, нур сибәрлек күзем юк.

Каһәрман. Шулай булгач, нигә, карама, дисең?

Фәрхиназ. Күңелгә шом саласың.

Каһәрман. Мин сиңа, Фәрхиназ, сокланып карыйм. Мин читкә киткәндә, яланаяк йөргән бала идең. Ә хәзер нинди таза, нинди матур кыз булгансың...

Фәрхиназ. Алай ук түгелдер инде, күпертәсең.

Каһәрман. Ихлас шулай. Әгәр дә син минем ирегемдә булсаң, каршыма утыртыр идем дә гел сиңа гына карап торыр идем.

Фәрхиназ. Гел генә миңа карап тора алмассың, туярсың.

Каһәрман. Юк, туймас идем.

Фәрхиназ. Тую гына түгел, күрәсең дә килмәс. Көн дә керән ашап кара әле, нишләрсең икән?

Каһәрман. Син шулай керән кебек ачымыни?

Фәрхиназ. Ачуымны китерсәләр, керәннән дә ачырак.

Каһәрман. Китермәсәләр?

Фәрхиназ. Балдан да татлырак.

Каһәрман. Әйтәм аны бүген үги анаң белән ярыша идең.

Фәрхиназ. Әллә аңардан бастырып торыргамы? Җитәр инде, яшь чагымда бик күп кыйнады.

Каһәрман. Кил әле, Фәрхиназ, минем яныма утыр. Монда күңелсез миңа...

Фәрхиназ. Кайтмаска иде, нигә кайттың соң?

Каһәрман. Көчләп кайтардылар бит.

Фәрхиназ. Анда күңелле идеме?

Каһәрман. Күңелле булмаса да, мондагы шикелле эшсезлектән эч пошу юк иде... Зур корабларга утыра идек тә, очсыз-кырыйсыз диңгезләр аша дөнья гизеп, төрле шәһәрләр, төрле кешеләр күрә идек. Ә монда нәрсә?..

Фәрхиназ. Миңа бер дә алай тоелмый. Безнең авыл шундый матур, шундый күңелле... Һәрбер аймагы, һәрбер урамы, һәрбер кешесе сөйкемле күренә. Үткән кышны әниләр авылына утырмага барган идем, бер атна да тормадым, сагынып кайттым. Ярый, син күңелсез янында торып, мин дә күңелсезләнә башладым.

Каһәрман. Һи... Истән чыккан бит. Сиңа тапшырасы әманәтем бар иде. (*Шомырт ботагыннан ката алып.*) Мә, иясенә бирерсең.

Фәрхиназ. Ирләр катасы, каян алдың?

Каһәрман. Кичә Гарифҗаннар мунчасында гармун уйнап утырдык та кайтырга чыктым. Авыл тын... Бары тик анда-монда этләр өргәне, болында бытбылдыклар кычкырганы, әрәмәдә сандугачлар сайраганы ишетелә... Шуларны тыңлап кайта торгач, өйгә җиткәнемне сизми калганмын. Нишләргә? Кереп ятсам, йокы килми. Капка төбенә утырып, тәмәке төрергә керештем. Тыңлыйм, аяк тавышы ишетелә. «Кем ул анда йөри?» дип әйтергә өлгермәдем, сезнең өй артыннан бер кеше чыкты да ындырга таба йөгерә башлады. Мин аның артыннан... Шәп йөгерә икән. Куып җитә алмадым. Сыңар катасын калдырып качты.

Фәрхиназ. И җебегән, шуны да тота алмагансың. Сәетҗан шәкерт булгандыр.

Каһәрман. Сәетҗан шәкерт? Ул анда нишләп йөрсен?

Фәрхиназ. Миңа күңеле төшкән. Көндезләрен су юлында саклап тора. Кичләрен тәрәзә астыма килә. Син аны тотарга да икенче килмәслек итеп тәпәләргә иде.

Каһәрман. Өндәмә, Фәрхиназ, моннан соң андыйларның берсе дә бу тирәгә аяк баса алмас!.. (*Тотып үбә.*)

Фәрхиназ. Менә сиңа, менә сиңа!.. *(Каһәрманның яңагына сугып югала.)*

Өйдән Маһитап чыга.

Маһитап. Улым, нигә яңагыңны тотып торасың?

Каһәрман. Сөйләмә инде, әни, корт чагып китте...

Маһитап. Ай Алла, шешеп китә күрмәсен, кая, көмеш тәңкә басып җибәрим.

Каһәрман. Кирәкми, әни, болай да үтәр әле.

Маһитап. Юк, улым, үтәр дип калдырырга ярамый, азып китүе бар. Кая әле, угы күренмиме? Уһу... битең комач булган бит. Бик усал корт икән... (*Имнәргә керешә.*) Өшкертен-төшкертен, калма качып яшертен. Азмасын-тузмасын, үз турыннан узмасын. Син, улым, өйдә торасыңмы әле?

Каһәрман. Нигә, әни?

Маһитап. Әсмабикә җиңгәң чирләгән, барып карамакчы идем.

Каһәрман. Бар, бар, әни, мин беркая да бармыйм.

Маһитап (*бакчага күзе төшеп*). Һм, мур кыргыры, теге Хөтбетдин кәҗәсе тагын бакчага кергән, абыеңа ничә тапкыр әйттем, төшкән киртәсен рәтләп бир, дидем, юк, тыңламый.

Каһәрман. Хәзер, әни, үзем рәтләп бирермен. *(Бакчага таба китә.)*

Маһитап. Ипләп кенә, улым, имгәтә күрмә!

Абруй керә.

Абруй. Майтап әби, савыт-сабаларың биреп торсаңчы!

Маһитап. Савыт-сабаларны? Алар белән нишлисең?

Абруй. Кунак җыябыз.
Маһитап. Нинди кунак?
Абруй. Фәрхиназны ярәштек, никах укытабыз.
Маһитап. Кемгә?
Абруй. Мөстәкыйм абзыйга.
Маһитап. Куегыз, куй, атасы белән кордаш кешегәме?
Абруй. Булса соң!
Маһитап. Карт бит ул.
Абруй. Мәхәббәт җамал теләмәс, диләр. Кая, эшем бик тыгыз, биш-алты тәлинкәңне алыйм да китим. Җиһанша абый хәзрәтләрне чакырырга киткән иде, йә килеп җитәрләр.
Маһитап. Безнең Җиһаншамы?
Абруй. Әйе, әйтмәдемени? Мөстәкыйм абзый ягыннан ул баш кода булып килде ич.
Маһитап. Әйтәм аны күзгә-башка күренми, Мөстәкыйм табагын ялап йөри икән. Харап иткәнсез баланы, миңа киңәш итәр идегез.
Абруй. Киңәш итешеп торырга Мөстәкыйм абзыйның вакыты булмады, иртәгә калага китә. Бүген никах укытабыз да кичкә кыз куенына кертәбез. Каһәрман өйдәме?
Маһитап. Бакчада, киртә төзәтә.
Абруй. Үзенә әйтерсең, никах мәҗлесенә керсен, әллә нинди сыебыз юк, елына карап бер табак аш та, икмәк белән чәй. Туйны Мөстәкыйм кияү, каладан кайткач шәпләп ясыйм, ди. Кая, чыгарып бирәсеңме, үзем кереп алыйммы?
Маһитап. Минем савыт-сабаларымны Гөлҗамал алып чыккан иде шул.
Абруй. Ярый алайса, үзем кереп алырмын.
Маһитап. Йөрмә инде, килен, йә абынып егылырсың да савыт-сабаларымны ватып әрәм итәрсең.
Абруй. Бу ни диюең, бирәсем килми, дисеңме?
Маһитап. Турысын әйткәндә, шулайрак. Фәрхиназ яше белән пешкән ашыңда минем савыт-сабаларым пычранмасын!.. (*Китә.*)
Абруй. И Ходаем, кыланышы! Бирәсең килмәсә, башыңа капла, әллә синдә генәме? (*Китә.*)

Бакча ягыннан Каһәрман чыга, урам яктан Җиһанша кайтып керә.

Каһәрман. Абый, син кайда идең?
Җиһанша. Каен белән усак арасында!
Каһәрман. Бәлеш, нигә миңа ачуланасың?
Җиһанша. Нәсел черетеп йөрисең шунда. Җан көеге, адәм имгәге!
Каһәрман. Тукта әле, нигә син мине сүгәсең?
Җиһанша. Хәзрәтне күрдем, шайтан коралы ай-гай уйнап, яшьләрне аздырып ята, ди.
Каһәрман. Минә ни өчен икән. Гармун уйнаудан кеше азамы?
Җиһанша. Аза икән шул. Скрипкә, ай-гай заман ахыры алдыннан адәмнәрне аздыру өчен чыгарылган иблис коралы, ди. Син, туганай, ул нәмәкәеңне урыс авылына илтеп сат инде.
Каһәрман. Юк, абый, ул минем бердәнбер юанычым, үзем кадәр алтын бирсәләр дә сатмыйм.
Җиһанша. Яхшылап әйткәнне белмәсәң, балта белән чәрдәкләп ташлармын әле.
Каһәрман. Кулыңны тидереп кара! Үз башыңны чәрдәкләргә дә кыйбат алмам...
Җиһанша. Һи, ристан, башкисәр!.. (*Урамга чыгып китә.*)

Тимерша керә.

Тимерша. Нихәл, Каһәрман!
Каһәрман. Бик әйбәт, Тимерша абый. Бу арада күренмәдең.
Тимерша. Урыс арасында идем. Ишеттегезме, авылга доктор килгән.
Каһәрман. Нәрсәгә?
Тимерша. Инеш суы сасыган, шул чутта, диләр.
Каһәрман. Инеш суы сасыган?
Тимерша. Әйе. Чәй эчкәндә тоймадыгызмы?
Каһәрман. Безнең әни суны чишмәдән китерә.
Тимерша. Авызга алырлык түгел, мунчала исе аңкып тора, шул турыда түбән авыллардан жалоба биргәннәр.
Каһәрман. Доктор нәрсә ди икән?
Тимерша. Кем белә аны? Суны төшеп караган да Мөстәкыймдә сыйланып утыра, ди. Йә, мин биргән теге инструкцияне укыдыңмы?

Каһәрман. Әйе, кат-кат укыдым. Аръяк кешеләренең тавыш чыгарып йөрүләре бик хаклы. Чыннан да шундый мәгънә аңлашыла икән.

Урамда Айдар картның тавышы ишетелә.

Айдар. Әйе, әйе, хуҗакай, Ишниязга бар, җыен җыйсын!

Айдар керә.

Тимерша. Нәрсә бар, Айдар абзый?
Айдар. Авылның бөтен сыерларын җыйнап япканнар.
Каһәрман. Кемнәр?
Айдар. Әлеге дә баягы, шул Алкин этләре инде.
Каһәрман. Ни өчен икән?
Айдар. Янәсе, урманнарын таптыйлар, агачларын сындыралар. Сыер башыннан өч сум штраф сорый, ди. Каян алам мин ул өч сум акчаны? Өч сум акчам булса, ясагымны илтеп түләр идем. Кичә әйберләремне язып чыктылар.

Ишнияз үтеп бара.

Ишнияз. Агай-эне, беркая да китми торыгыз, авылга справник килә.
Айдар. Аңа ни калган тагы монда?
Ишнияз. Янгын сарайлары салу, янгын кораллары алу турында приговор сорыйм, ди.
Айдар. Янарлык каралтым юк, байлар салсыннар. Әнә сыерларны япканнар, шул турыда әйт син аңа.
Ишнияз. Әйттем, Айдар агай, бик нык итеп килгәч үк әйттем, җыеннан соң Алкиннарга барып сөйләшәм, ди.
Айдар. Хәзер сөйләшсен, хайваннар ачтан кычкырып яталар!
Ишнияз. Тукта әле, нигә миңа җикеренәсең?
Тимерша. Ишнияз абзый, доктар нигә инеш суын эчмәскә куша?
Ишнияз. Көннәр эссе булганга ярамый торгандыр.
Айдар. Нигә ярамаганын әйтсен ул, Мөстәкыймне яклыймы?
Ишнияз. Мин анысын белмим инде. Докторларның законы үзе белән йөртелә. Шулай, агай-эне, беркая да китми торыгыз, кичкә җыен җыябыз. (*Китә.*)
Айдар. Янгын сарае салырга, имеш, шул гына калган иде!..
Каһәрман. Анысы аның, Айдар бабай, начар эш түгел, ут-күздән саклану өчен кирәкле каралты. Тик минә ул инструкциядә бер ярамаган җире бар икән.
Айдар. Нинди җире?
Каһәрман. Шул салынырга тиешле булган янгын сарайлары алдына озын багана утыртырга, шул багана башына чаң асарга диелгән.
Айдар. Чиркәү чаңымы? Безгә нигә ул?
Каһәрман. Ул болай, янгын чакларында кагып халыкны җыярга диелгән.
Айдар. Теләсә нәрсә диелсен, энем, бу безгә бара торган эш түгел. Кара ният белән чыгарылган инструкция ул.

Фәезхан керә.

Фәезхан. Әссәламегаләйкем, картлар!
Айдар. Вәгаләйкемәссәлам, Фәезхан! Йә, нинди уңышлар белән?
Фәезхан. Булмады, Айдар агай, булмады. Губернада да, өяз судының хөкемен раслап, безнең прошениегә отказ бирделәр.
Айдар. Ничек инде ул отказ бирделәр?
Фәезхан. Алкин малае тагын шул атбакатын җитәкләп барган.
Айдар. Ә соң безнең атбакат?
Фәезхан. Ул булмады.
Айдар. Нишләп булмады? Ялламадыңмы?
Фәезхан. Яллавын ялладым. Суд буласы көнне генә бизгәк белән чирләде.
Айдар. Әй Фәезхан, Фәезхан, койрыксыз саескан шикелле шыгырдаудан башка эшең булмады. Шулай итеп, оланнар, безнең дөреслек тагын өскә чыкмадымыни?
Фәезхан. Юк, Айдар абзый, хаклык беркайчан да аста калмый ул. Юллык акча табып бирегез, Петербурга китәм. Саматка керәм, анда да булмаса, акпатшаның үзенә җитәм, тик сез миңа акча гына җыеп бирегез.
Каһәрман. Биргәннәр бит инде, кая куеп бетердең?

Фәезхан. Кызык кына, кая куеп бетердең, имеш... Сезнең ул бозау киртәгезне саткан акча нәрсәгә җитә? Калада үзең беләсең, суына кадәр сатып аласың. Шулай, картлар, акча җыеп бирегез, иртәнге намаздан сәфәргә чыгам.

Айдар. Тик без сиңа ул акчаны каян алырбыз икән?.. Сатасы әйбер дә калмады бугай.

Фәезхан. Бар әле, бар! Зират печәнен сатыгыз.

Каһәрман (*Фәезханның борын астына йодрыгын куеп*). Менә шуны иснәп кара әле, нәрсә исе килә икән?..

Фәезхан (*артка таба чигенә барып*). Ай-һай, ни дигән сүзең бу?

Каһәрман. Волостька барыр өчен җан башыннан унар тиен җыйдыргансың. Өязгә диеп болыннарын саттыргансың. Губернага киткәндә, бозау киртәләреннән яздыргансың. Инде Петербургка барам дип, ата-бабаларыбызның өсләренә үскән печәннәренә кадәр тыгынырга уйлыйсыңмы? Башың исән чакта тай моннан!..

Фәезхан. Айдар абзый, әйтсәгезче үзенә...

Айдар. Бар, бар, табаныңны ялтырат!..

Фәезханны куып чыгаралар.

Йә, оланнар, кая барабыз? Кемнән ярдәм сорыйбыз?

Каһәрман. Хәзергә, бабай, беркая да бармыйбыз һәм беркемнән дә ярдәм сорамыйбыз. Боларның барысы турында да җыенда исправник белән сөйләшербез.

Айдар. Справник безгә җир бирер дисеңме?

Каһәрман. Судтан судка сезне алдап йөргән, актык локмаларыгызны авызыгыздан тартып алган Фәезханнар да җир алып бирә алмас.

Тимерша. Әйдә, Айдар абзый, җыенга кадәр картлар белән киңәшик әле, нәрсә әйтерләр. (*Китәләр.*)

Каһәрман уйланып утыра. Маһитап кайтып керә.

Маһитап. Улым...

Каһәрман (*йокыдан уянгандай*). Ә?! Нәрсә, әни?..

Маһитап. Сине ашка чакырганнар иде.

Каһәрман. Кемнәр?

Маһитап. Иргали абзаңнар.

Каһәрман. Тукта әле, әни, нишләп алар мине ашка чакырсын?

Маһитап. Чакырдылар инде, Фәрхиназны биргәннәр.

Каһәрман. Кемгә?

Маһитап. Бүкән Мөстәкыйменә.

Каһәрман. Мин бая гына Фәрхиназны күреп сөйләштем, бернәрсә дә әйтмәде.

Маһитап. Белми торгандыр, аңа сиздерми эшләгәннәрдер. Савыт-саба сорап Абруй кергән иде. Димләүчесе дә табылган — безнең Җиһанша...

Каһәрман. Табак ялаучы...

Маһитап. Сөйләмә инде, улым, гомер буена минем тапканымны ашап ятканы. Өч хатын алып бирдем, берсе белән дә тора алмады. Җәй булса, җыеннан җыенга, базардан базарга йөри. Кыш булса, байларга шаһитлыкка ялланып, судта гомерен уздыра. Кемгә охшап тугандыр!.. (*Өйгә кереп китә.*)

Борчулы хәлдә Сәетҗан йөгереп керә.

Сәетҗан. Каһәрман абый, сиңа киңәшкә килдем, миңа акыл бир.

Каһәрман. Кызмый гына сөйлә, эш нидә?

Сәетҗан. Бер елдан бирле сөеп йөргән кызымны үги атам тартып ала.

Каһәрман. Алса, мин нишли алам?

Сәетҗан. Син — дөнья күргән кеше, миңа нинди киңәш бирерсең?

Каһәрман. Мин каян белим, нигә аны миннән сорыйсың?

Сәетҗан. Фәрхиназны коткарып бир миңа.

Каһәрман. Фәрхиназны? Сиңа?

Сәетҗан. Әйе, миңа... Мин сиңа ни теләсәң, шуны бирермен. Алтын-көмеш белән күмәрмен, тик, зинһар, тыңла сүземне.

Каһәрман. Соңга калгансың, Сәетҗан. Озакламый аңар никах укыталар.

Сәетҗан. Юк, әле дә соң түгел. Без аны коткара алабыз. Син аны миңа урлап бир.

Каһәрман. Сиңа урлап бирергә? Ә соң Фәрхиназ үзе аны теләрме?

Сәетҗан. Нигә безгә аның теләге? Мин хәзер иң яхшы атларымны җигеп киләм дә салабыз да китәбез. Хезмәт ялыңны хәзер үк биреп куйыйм. Менә сиңа биш алтын.

Каһәрман. Эх, Сәетҗан... Син бит күп еллар мәдрәсәдә укыган, ләкин үги атаңнан ерак китә алмагансың. Алтын белән кыз сатып алмакчы буласың. Юк, андый эшкә син башка берәүләрне куш инде.

Сәетҗан китә. Маһитап чыга.

Маһитап. Улым, мин югары очка, Мирсәяф хатынын сыларга барам. И бала, бала, йөрәгеңдә ни барлыгын сизмәдем. Хәзер соң инде. Әнә хәзрәт тә килде. Бар, өйгә кер. Урман — колак, урам күз дигәндәй, авыр хәлең, кеше белмәсен. (*Аркасыннан сөеп китә.*)

Каһәрман әрле-бирле уйланып йөри. Тәрәзә төбеннән гармун алып уйнарга керешә. Читән артында Җиһанша күренә.

Җиһанша. Куй, туганай. Ходай өчен кычкыртма. Мөхсин хәзрәт монда бит!..

Каһәрман гармунын куя. Җиһанша югала. Урам яктан яланбаш хәлдә, атылып, Фәрхиназ керә, Каһәрман муенына сарыла.

Фәрхиназ. Каһәрман абый, коткар мине...

Шаулашып, Иргали, Абруй, Җиһанша керәләр.

Иргали. Кызым, Фәрхиназ, әйдә, өйгә кайт.
Фәрхиназ. Юк, әти, кайтмыйм.
Каһәрман. Иргали абзый, үз балаңны нигә утка саласың?
Абруй. Аны синнән сорамыйлар.
Иргали. Әйдә, кызым, кеше көлдермә.
Абруй. Әйдә, хәзрәтләр көтә.
Фәрхиназ. Кыстамагыз, үлсәм дә мин аңар бармыйм.
Абруй. Без биргәч, барырсың.
Фәрхиназ. Юк, бармам.
Иргали. Әйдә, кызым, карышма!
Каһәрман. Иргали абзый, аз гына булса да миһербанлы бул инде. Ни өчен үз балаңны сатасың?.. Ул бит сиңа алтын тавы тоттырмас. Менә, мә!.. Мин сиңа аннан артыгын бирәм.
Абруй. Әй хәерче, ниләр кылана!.. (*Иргалигә.*) Ни карап торасың? Нигә кызны тартып алмыйсың?
Иргали. Җибәр кызны, җибәр минем баламны!
Каһәрман. Иргали абзый, якын килмә, чәнечәм... (*Пәке чыгара.*)
Җиһанша. Каһәрман, син нишлисең? Бир пәкеңне, бир монда.
Каһәрман. Килмә, абый, килмә, эчеңне айкармын!
Җиһанша. Мә, мә, айкап кара, беткән баш!.. (*Күлмәген күтәреп, корсагын киереп бара.*)
Каһәрман. Алла белән ант итеп әйтәм: берегез дә якын килмәгез!..
Мөхсин керә.

Мөхсин. Бу нинди гауга, бу нинди итагатьсезлек?
Җиһанша. Менә, хәзрәт, күрегез, минем туганым нинди ул!
Мөхсин. Ташла пычагыңны, ташла син, явыз, мәлгунь!.. Ташла, хәсис, ташла, дим, фасыйк, шәмгунь!.. (*Таяк күтәреп һөҗүм итә.*)
Каһәрман пәкесен төшереп җибәрә.

Алыгыз кызны, алыгыз!..

Фәрхиназны култыклап алып, өстерәп китә башлыйлар.

Фәрхиназ. Каһәрман абый, Каһәрман абый, бәхил бул!.. (*Китәләр.*)
Каһәрман. Их, кешеләр, кешеләр, кешеләр түгел, ерткычлар!..
Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мөстәкыйм байның тегермән алды. Әйләнә-тирә тал-тирәк белән капланган. Бер читтә тегермән өстенә менә торган күпер һәм ишек күренә. Вакыт кич. Еракта җыен бара, анда талашкан тавышлар ишетелә. Тегермән эчендә таш тешиләр.
Мөстәкыйм тегермәннән чыга.

Мөстәкыйм. Җыен һаман бара икән. Хәерлегә булса ярар иде. Ашыгыбрак өйләндем бугай, бераз сабыр итәсе калган...

Көянтә-чиләк белән Абруй керә.

Мөстәкыйм. Каенанай нишләп йөри?
Абруй. Чишмә суына килдем, яшь кияүгә чәйгә кирәк бит.

Мөстәкыйм. Минем кәләш ни хәлдә?

Абруй. Алдай-гөлдәй җайланды. Хәзрәтләр никах укып китүгә, яныбызга чыкты да: «Әткәй, әнкәй, гаеп итмәгез инде, Каһәрман коткысына ияреп, әшәкелек эшләдем»,— ди. Син җибәргән киемнәрне әйбәтләп киенде, иннек-кершән салып бизәнде. Чын-чыннан кияү көткән кызга әйләнде.

Мөстәкыйм. Кара син аны, ха-ха-ха!

Абруй. Әле суга барам дип йөдәткән иде. Кит аннан, мин әйтәм, кияү керәсе кызга ярыймы, дим. Көчкә иллалла күндердем.

Мөстәкыйм. Бик әйбәт иткәнсең, каенанай, чыгып йөрмәсен. Ул бит хәзер Мөстәкыйм бай кәләше.

Абруй. Әбәү, тавышланулары... Бу җыеннары яхшылык белән генә бетсә ярар иде.

Мөстәкыйм. Нишли алырлар? Дуларлар-дуларлар да басылырлар.

Абруй. Алай димә, Мөстәкыйм абзый, халыкның бик ачуы кабарган. Ничәләрдә килерсең икән?

Мөстәкыйм. Менә нәрсә, каенанай, мин шундый уйга килдем. Бабайларның өйләре дә тар, олы кешеләрне читкә чыгарып йөртүе дә килешеп бетмәс, дим. Шуның өчен кияү керүне иртәгә калдырып, үз өемдә генә уздырырга булдым.

Абруй. Ай Алла, алай эшләү килешер микән?

Мөстәкыйм. Ник килешмәсен? Ахирәт гамәле түгел бит, сездә булды ни дә, бездә ни?

Абруй. Анысы шулаен шулай да, үзебезгә күрә җыендык, аш-су әзерләдек.

Мөстәкыйм. Алар өчен кайгырасы юк, минем исәптән булыр.

Абруй. Ярый инде, синең теләгеңә каршы килеп булмас. Теге Каһәрман берәр нәрсә эшләмәгәе дип, үзебез дә шикләнеп тора идек, әллә ниләр сөйләп йөри, ди. Синдә булса, ул ягы да хәвефсез булыр.

Мөстәкыйм. Менә шул шул. Бер көн иртә, бер көн соң дигәндәй...

Абруй. Сагынып алсаң, ир кадере башка була ул.

Мөстәкыйм. Ай минем каенанай, кайда кармак сала белә бит ул, ха-ха!.. Каенатайга әйтерсең, минем теләгемә каршы килмәстер инде.

Абруй. Юк, юк, уеңа да китермә, минем сүздән чыкмый ул. Мин китим әле, төнгә калам.

Мөстәкыйм. Фәрхиназга сәлам әйтерсең.

Абруй. Ярый, ярый, әйтермен. (*Китә.*)

Җиһанша керә.

Мөстәкыйм. Бик озак, Җиһанша, бик озак.

Җиһанша. Җыенда идем.

Мөстәкыйм. Бүгенгә бармасаң да ярар иде, күрмәгән җыеның түгелдер.

Җиһанша. Юк, Мөстәкыйм абзый, анда хәлләр бар... Инструкциядәге чаң дигәннәре халыкның чәчен үрә торгызды.

Мөстәкыйм. Нинди чаң?

Җиһанша. Һәр авылда янгын сарае салырга, сарай алдына багана куярга, шул багана башына чаң асарга, диелгән.

Мөстәкыйм. Чиркәү чаңымы?

Җиһанша. Чиркәү чаңы шул... Анда хәлләр бар... Бөтен авыл аякка баскан, безнең Каһәрман, Айдар агайлар справникка сөйләргә дә бирмиләр.

Мөстәкыйм. Алай, димәк, гауга башланды?

Җиһанша. Нинди генә әле. Мине нигә чакырдың?

Мөстәкыйм. Бүген Котлыкай мирза Алкинның казна өчен тарттыра торган ашлыгын тегермәнгә китереп өйделәр, тегермәнче бизгәк белән чирләде. Малае өйдә юк. Сәетҗанны Алкиннарга сыерларны алырга җибәрдем. Шулай итеп, берьялгызым калдым. Син миңа иптәш булырсың.

Җиһанша. Ә соң кияү керү бүген түгелме?

Мөстәкыйм. Иртәгә калдырдым. Шушы кадәр хуҗалыкны ташлап булмый бит. Халыкның да ачуы кабарган чагы.

Җиһанша. Әйе. Җыенда сине дә бик нык телгә алдылар.

Мөстәкыйм. Нәрсә диләр?

Җиһанша. Кабыкларын алдырабыз, договорны бозабыз, диләр.

Мөстәкыйм. Менә, күрәсең, шундый чакта ничек кияү кереп ятасың. Син тышта йөрерсең, мин эчтә булырмын.

Җиһанша. Минем эшем бар иде шул...

Мөстәкыйм. Сәетҗан кайтып өлгерсә, тотмам, китәрсең. Мин арыкны ябыйм әле. (*Китә.*)

Абруй судан кайта.

Җиһанша. Җанкай-җанаш, кара каш!..

Абруй. Акрын, тешсез пәри, кеше-кара ишетер. Нишлисең монда?

Җиһанша. Каравылга килдем. Булдырдык бит, ә?
Абруй. Әйтмә инде, котылдык.
Җиһанша. Төнлә чыгарсың микән?
Абруй. Кая?
Җиһанша. Безнең абзар артына.
Абруй. Каравылда, дисең бит.
Җиһанша. Мин бераз гына, Сәетҗан кайтканчы гына. Чыгарсыңмы?
Абруй. Белмим әле, вакыт җиткәч, күз күрер.
Җиһанша. Әй чәкүшкә танау, назланып торган була. Чыгармын, җаным, дисәң, телең череп төшәр иде-ме?
Абруй. Аллам сакласын, сиңа җаным дип әйтәмме? Андый сүзләр белән үз иремне дә зурлаганым юк әле.
Җиһанша. Ул бит ирең, ә мин — сөйгәнең.
Абруй. Әбәү, мәхәббәтсез, килбәтсез...
Җиһанша. Йә, әйт, чыгарсыңмы?
Абруй. Ярый инде, эт күңеле бер сөяк дигәндәй, чыгармын.
Җиһанша. Әй кыбырсык! (*Тоткалый.*)
Абруй. Җибәр, чукынчык, хи-хи-хи... (*Китә.*)

Мөстәкыйм керә.

Мөстәкыйм. Җиһанша, бар әле, тегермән артына балык тотарга чуашлар килгән. Берсен дә калдырмыйча корык белән ку. (*Җиһанша китә.*)

Исправник керә.

Исправник. Шайтан белсен, бу нинди халык?..
Мөстәкыйм. Әллә приговорны бирмибез, диләрме?
Исправник. Нинди приговор, бунт анда.
Мөстәкыйм. Бунт?
Исправник. Әйе. Чын-чыннан бунт. Җыенны башлап җибәрүгә, теге читтән кайткан егет... исеме ничек әле үзенең?..
Мөстәкыйм. Каһәрман.
Исправник. Әйе, Каһәрман башкисәр чыкты да халыкка сөйли башлады. Аңа ияреп башкалар... Аннан тагы акылдан шашкан бер картыгыз бар икән, килеп каршыма басты да: «Чаң асарга килдеңме? Тизрәк тай, сөякләрең җыйный алмассың», — ди. Таяк белән кизәнә! Хәзер алар бөтен җыен белән Алкин утарына киттеләр.
Мөстәкыйм. Нәрсәгә?
Исправник. Ябылган сыерларын коткарырга.
Мөстәкыйм. Нигә соң шунда бармыйсыз? Алар бит аны таларлар.
Исправник. Берүзем мин нишли алам? Волостьтан ярдәм сорап кеше җибәрдем, килмиләр.
Мөстәкыйм. Ул инструкциягезнең бер чатак җире бар икән шул, уйлап язарга иде.
Исправник. Шайтан белсен аны, кем язгандыр! Безгә аны губернадан җибәргәннәр. Ләкин мин ике тапкыр укып чыктым, андый мәгънә аңлашылмый иде, анда бары янгын вакытларында халыкны җыяр өчен генә диелгән.
Мөстәкыйм. Барыбер тырнак астыннан кер эзләүчеләргә җитә ул. Алкиннарга аларның ачулары кабарды. Шушындый кытлык елны җир гаугасы уйлап табалар, малларны ябалар.
Исправник. Сезнең үзегездә дә гаеп бар, договорда булмаган праволар белән файдалангансыз, көрәк онының нормасын арттыргансыз, кап сугучыларны тереләй талыйсыз.
Мөстәкыйм. Мин нәрсә? Аз-маз гына, вак-төяк, менә син хөкүмәтне әйт, хан заманындагы недоимкаларны түләтә.
Исправник. Мин шуңар аптырыйм, алар ул инструкцияне каян алганнар? Бөтен пунктларын күңелдән беләләр.
Мөстәкыйм. Каян булсын? Каһәрман өйрәтә, ул егет турында мин абыйсыннан бик кызыклы бер хәбәр ишеттем.
Исправник. Нинди хәбәр?
Мөстәкыйм. Аны монда «бүре билеты» белән кайтарганнар икән.
Исправник. Ничек инде «бүре билеты» белән?
Мөстәкыйм. Америка дигән җирдә негр дигән халыкларны яклап бунт чыгаруда катнашкан, шуның өчен аны бер җиргә дә эшкә алмаслык итеп пашпортына мөһер басып кайтарганнар.
Исправник. Менә ул ничек!.. Шуннан, шуннан?..

Мөстәкыйм. Әйдә, тегермән өенә керик әле, шунда сөйләрмен. (*Кереп китәләр.*)

Караңгы төшә. Каһәрман керә.

Каһәрман. Бигрәк тә яхшы, тегермән эшләми, арык та ябылган. Үлек чыккан йорттай тын икән... Ярый, Мөстәкыйм! Мин синнән бүген авыл халкының еллар буе күргән аһ-зарының үчен кайтарам! Мин синнән бүген Фәрхиназ күз яшенең үчен кайтарам! Синең анда кияү кергән минутыңда, тегермәнең көле күккә очачак!.. Фәрхиназ нихәлдә икән?.. Бичара, ак мендәргә битен каплап елый-елый арыгандыр да кара язмышына буйсынырга риза булгандыр... Тукта, бу нинди хатын-кыз шәүләсе?.. Үзе ашыга, үзе як-ягына карана, Фәрхиназ түгелме? Әйе, әйе, ул килә... (*Яшеренә.*)

Фәрхиназ керә.

Фәрхиназ. Уф, йөрәк ничек ашкына... Тик күңелдә тирән бушлык, тәндә көчем калмаган, дәрман юк. (*Утыра.*) Әнә әкрен генә ай калка... Тиздән көзге төсле тонык су өстенә якты нурларын сибәр... Шул чакта сикереп төшәрмен дә мәңге кайтмаслык дөньяга күчәрмен... Тик Каһәрман абый кайда икән?.. Бер генә кат үзен күрергә, аның өчен янган йөрәгемне ачып бирергә иде... Юк шул инде, аны күрә алмыйм... Эх, үләсе килми!.. Ничек итеп шушы айлы төннәрдән, якты көннәрдән туярга да япь-яшь башың белән кара гүргә керергә?.. Торасы да килми, бар өметем өзелгән, бөтен киләчәгем канлы яшькә күмелгән... Карт диюнең хатыны булып, хурлык, мыскыл күреп, гомерем буенча хәсрәт йотып йөргәнче, үлү яхшырак!.. (*Ярга таба бара башлый.*)

Каһәрман. Фәрхиназ! Тукта!

Фәрхиназ. Бу кем? Өнемме бу, төшемме? Йә булмаса өрәкме?

Каһәрман. Юк, Фәрхиназ, бу мин, Каһәрман!.. (*Кочагына ала.*)

Фәрхиназ. Тукта, тукта, карыйм әле, синме соң бу, күз нурым? Әйе, әйе, син икәнсең, син икәнсең, былбылым... Инде хәзер мин үкенмим, син сөйгәнем ятка калсаң да, мин үкенмим, шул минутта Газраиле җаным алса да!

Каһәрман. Кирәкми, андый сүзләр сөйләмә. Мин ташламам, барлык нәрсә ташка әйләнеп башкаема яуса да, мин ташламам сине, таудай авырлыклар өскә килеп ауса да.

Фәрхиназ. Нинди рәхәт миңа, нинди бәхетле мин синең яныңда... Мин бит сине өзелеп сөйдем, белдерергә җаен тапмадым, күз алдыма матур гәүдәң куеп, күпме төннәр керфек какмадым!

Каһәрман. Ә син мине белсәң иде!.. Белсәң иде ничек сөйгәнем! Белсәң иде арабызга кергән кара язмыш өчен ничек көйгәнем...

Фәрхиназ. Тукта, мин өйдән качып чыктым, мине эзләп монда киләләр.

Каһәрман. Син курыкма, Фәрхиназ, бар, таллар арасына кереп тор, мин бераздан ат белән сине алырга килеп җитәрмен.

Фәрхиназ. Аннан?

Каһәрман. Аннан мин сине күрше авылга түтәйләргә илтеп куярмын.

Фәрхиназ. Ә аннан?

Каһәрман. Аннан инде, авылдагы маҗараны ахырына кадәр җиткергәч, кая булса да еракка, кеше күзе төшмәгән җиргә китәрбез. Мин хәзер киләм. (*Китә.*)

Фәрхиназ. Нинди матур, нинди ямьле төн... Күктә йолдызлар да җем-җем итеп торалар. Яшь баласын сөйгән ана кебек, йөзне сыйпап җил исә. Әнә болында көр күңелле тайлар кешнәшә. Әрәмәдә сансыз кошлар сайраша. Судагы бакаларга кадәр үзләренчә моңлап гөрләшә... Хәтта үлән арасында йөргән нәни кортлар, чикерткәләр дә уйнап чырлаша... Әйтерсең лә бар дөньяны бүген шатлык, матурлык каплаган...

Сәетҗан керә.

Сәетҗан. Фәрхиназ, син ничек монда?

Фәрхиназ. Мин ни, теге... Әллә белмисеңме?

Сәетҗан. Нәрсәне?

Җиһанша керә. Тыңлап тора.

Фәрхиназ. Мин бит синең белән качарга дип әйтеп җибәргән идем.

Сәетҗан. Кемгә?

Фәрхиназ. Нәҗми абыйга, әйтмәдеме?

Сәетҗан. Юк. Мин Алкин утарында идем.

Фәрхиназ. Алай булса, бар, аны эзләп тап, ул безне качырырга булды.

Еракта Иргали тавышы.

Иргали. Кызым, Фәрхиназ!..

Фәрхиназ. Харап булдык, тотылдык. Әнә мине эзләп киләләр. Качыр, Сәетҗан.

Сәетҗан. Әйдә, тегермәнгә яшерим.

Тегермән түбәсенә менеп китәләр.

Җиһанша. Менә ничек?.. Сәетҗан белән качарга йөриләр?.. Тизрәк Мөстәкыйм абзыйны табарга кирәк. *(Китә.)*

Тегермәннән Сәетҗан чыга.

Сәетҗан. Менә бәхет, менә шатлык, максатыма инде ирештем. Иң яхшы бер атны җигеп киләм дә Фәрхиназны салып китәм...

Берничә кеше белән Иргали керә.

Иргали. Сәетҗан, безнең Фәрхиназны күрмәдеңме?
Сәетҗан. Юк, Иргали абзый, нигә?
Иргали. Өйдән чыгып киткән. Шунда таба йөгергәнен күргәннәр. Кая гына китте икән?
Сәетҗан. Ә... бая бер шәүлә әрәмәгә кереп бара иде, ул түгел микән?
Иргали. Әйе, әйе, ул булыр. Бу вакытта башка кем йөрсен? Әйдә, безгә кая таба кергәнен күрсәт.

Мөстәкыйм, Абруй, Җиһанша һәм башкалар керәләр.

Җиһанша. Шауламагыз, асыл кошны тотабыз.

Тегермән түбәсенә кереп китәләр. Шаулашып Фәрхиназны алып чыгалар.

Фәрхиназ. Җибәрегез, тотмагыз!.. Аңар хатын булганчы, суга гарык булырмын!.. (*Ычкынып, буага таба йөгерә.*)
Абруй. Тотыгыз, тот! Буага ташлана!..

Сәетҗан Фәрхиназны куып тота, өстерәп алып китәләр.

Сәетҗан. Әткәй!.. (*Мөстәкыйм алдына тезләнә.*) Гафу ит мине.
Мөстәкыйм. Тукта, сиңа ни булды?
Сәетҗан. Фәрхиназны харап итмә, үтермә. Сиңа бармас өчен ул барыбер үзен һәлак итәчәк. Безнең арабызда вәгъдә куелган.
Мөстәкыйм. Атаң алдында шундый сүзләр сөйләргә ничек оялмыйсың? Бар, кит янымнан.
Сәетҗан. Әткәй, сиңа булган хөрмәтне аяк астына салып таптама.
Мөстәкыйм. Ах син, шарлатан!.. Миңа акыл сатасың?
Сәетҗан. Кара аны, моның ахыры начар булыр. Минем гәүдәм аша гына Фәрхиназга ия булырсың.
Мөстәкыйм. Нәрсә, нәрсә дисең?
Сәетҗан. Җибәр, тотма якадан!.. (*Селтәп җибәрә.*)
Мөстәкыйм. Миңа кул сузасың?
Сәетҗан. Җитәр инде, унҗиде ел буе әнкәй белән мине кыйнадың.
Мөстәкыйм. Мин сине, эттән туган малай... (*Таш алып, аңа таба якыная.*)
Сәетҗан (*күсәк күтәреп*). Килеп кенә кара!..

Җиһанша керә.

Җиһанша. Бу нишләвегез? (*Араларына керә.*)
Мөстәкыйм. Кит, Җиһанша, үтерәм мин аны.
Сәетҗан. Җибәр, Җиһанша абый, килсен, кул гына тидереп карасын.
Мөстәкыйм. Бәреп үтермәс борын, югал күз алдымнан!.. Өйгә кайтып аяк басасы булма...
Сәетҗан. Ярый!.. Инеш суын кортлатуыңны, волостьтан килгән духтырны акчага сатып алуыңны халыкка аңлатыйм әле. (*Китә.*)
Мөстәкыйм. Улым, Сәетҗан, Сәетҗан!.. Менә, Җиһанша, күрдеңме? Үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр... Өч яшеннән карап үстерүнең әҗерен ничек кайтарды!
Җиһанша. Нинди духтыр турында сөйли ул?
Мөстәкыйм. Әллә тагы, үзем дә аңламадым. (*Китә башлый.*)
Җиһанша. Мөстәкыйм абзый!.. Үзең беләсең, ике ел инде хатынсыз торам. Галкәй агайның ирдән кайткан кызын сораган идем, тартуына биш пот он сорый, көзгә кадәр син миңа биреп тор инде.
Мөстәкыйм. Син дә тапкансың өйләнер чак, көзгә игеннәр җыйгач кодалар идең.
Җиһанша. Көтмиләр шул. Күрше авылдан сорыйлар икән. Кызы бик әйбәт. Үзе таза, үзе симез, кочакка сыймаслык, лап-лап итеп басып йөргәндә, идән сайгаклары сыгыла. Кызган чакта сугып калыйм инде.

Мөстәкыйм. Карлы хәерчесе кебек соранма, Җиһанша. Быел минем бик чыгымлы ел. Өч йөз потлап әҗәткә өләштем. Мал-туары да күп, яңага кадәр аларга да кирәк бит.

Җиһанша. Тыңла инде, Мөстәкыйм абзый. Синең өчен туганым белән бозылыштым. Фәрхиназга никах укыганда, ялган шаһит булып, гөнаһка чумылдым. Аннан менә хәзер...

Мөстәкыйм. Гөнаһың өчен кайгырма, тәүбә итсәң, Алла кичерер, миңа булышуың өчен рәхмәт.

Исправник керә.

Исправник. Старостаны чакырырга кеше җибәрдеңме?

Мөстәкыйм. Күптән инде.

Исправник. Нигә соң килми ул?

Мөстәкыйм. Белмим шул.

Исправник. Тизрәк барып басасы иде.

Мөстәкыйм. Әнә килделәр.

Ишнияз, Камай, десятниклар керәләр.

Ишнияз. Господин исправник, нигә безне чакырдыгыз?

Исправник. Хәзер Каһәрман белән Тимершаны кулга алабыз.

Камай. Бик әйбәт итәсез. Тимерша һаман күпер башында, халыкны котырта. Айдар картны күрше авылларга җибәрергә уйлыйлар.

Мөстәкыйм. Кемдер килә.

Камай. Каһәрман бугай.

Исправник. Качыгыз, искәртмәстән тотып алабыз.

Ишнияз. Сак булыгыз, үгез кебек таза ул.

Яшеренәләр. Каһәрман керә.

Каһәрман. Их, өлгерә алмадым, өлгерә алмадым килеп... Бичара Фәрхиназны тотып алып киттеләр. Инде нишләргә?.. Айкарга кирәк... Әйе, әйе, бөтен тегермәне белән буасын айкарга кирәк... (*Кесәсеннән бутылка чыгарып, буага ташларга бара*.)

Мөстәкыйм. Кем ул буа янында йөри? Урлашырга килдеңме?

Каһәрман. Төнгә кармак салырга йөрим.

Камай. Кармак таякларың кая соң?

Исправник. Кулыңда нәрсә ул?

Каһәрман. Күрәсең ич, бутылка.

Исправник. Нигә ул сиңа?

Каһәрман. Балык җиме тутырдым.

Җиһанша бер читтән карап тора. Кисәктән Каһәрманга һөҗүм итеп, тотып алалар. Тегермәнгә ябалар.

Җиһанша (*яшеренгән җиреннән чыгып*). Юк, артык чыдый алмыйм! Тизрәк халыкка әйтергә дә туганайны коткарырга кирәк. (*Китә*.)

Тегермәннән Мөстәкыйм белән исправник чыга.

Исправник. Шулай да бутылкасын карыйк әле. (*Бутылканы бушата*.) Нәрсә бу?

Мөстәкыйм. Акбурмы, дим.

Исправник. Түгел, известь. Сездә балыкны известь белән тоталармыни?

Мөстәкыйм. Ишеткәнем дә, күргәнем дә юк.

Исправник. Нигә известь тутырган ул?

Мөстәкыйм. Белмим шул.

Тегермәннән Ишнияз белән Камай чыга.

Исправник. Әйдәгез, Тимершасын алырга киттек.

Камай. Туктагыз, монда таба киләләр.

Тимерша, Айдар, Җиһанша һәм бер төркем халык керә.

Айдар. Сез безгә әйтегез, нигә Каһәрманны яптыгыз?

Җиһанша. Аның ни гаебе бар, ул ни урлаган?

Ишнияз. Агай-эне, пүрәдкә белән генә сөйләгез әле.

Исправник. Безгә мәгълүм булган гаепләре бар. Шуның өчен кулга алдык.

Айдар. Әйтегез, нинди гаеп ул?

Исправник. Аны белүнең сезгә кирәге юк.

Айдар. Юк, кирәк. Дуб-дуамалга кеше ябасыз! Нигә ясак, недоимкалар белән безне буасыз? Нигә Мөстәкыйм кебекләрдән талатасыз? Нигә безгә кара уйлы язулар җибәрәсез?

Тимерша. Айдар абзый, сүз озайтуда маза юк. Каһарманны чыгарасызмы-юкмы?

Исправник. Юк, ул — халык котыртучы. Бу гаебе өчен ул җәза алырга тиеш.

Тимерша. Ул чагында без аны үзебез коткарабыз... Әйдәгез, ишек йозагын ватабыз.

Ишнияз. Агай-эне, сез нишлисез? Әллә авыл белән Себер китәргә телисезме?

Айдар. Ачу килгән чакта Себер ни дә безгә, Сембер ни.

Ишек йозагын ватарга ябышалар.

Исправник. Ярый, сезнең ише бунтовщиклар белән ничек эш итәргә белербез!.. (*Китәләр.*)

Халык төркеме Каһарманны тегермәннән алып чыга.
Сәетҗан йөгереп керә.

Сәетҗан. Абзыйлар, мин сезгә вөҗданым кушканча бернәрсә әйтергә тиеш: безнең инеш суы кортлаган.

Айдар. Кортлаган?

Тимерша. Каян белдең?

Сәетҗан. Бүген авыруларны карарга килгән духтыр әллә нинди трубалар аша буадагы суны тикшереп карады да арыкны ачарга, мунчала кабыкларын буадан чыгарырга кушты. Ләкин эткәй, духтырга взятка биреп, Алкин ашлыкларын тартып бетергәнче эндәшми торырга күндерде.

Каһарман. Кара әле, Сәетҗан, дөрес сөйлисеңме?

Сәетҗан. Коръән алып ант итәм, сүзләрем дөрес. Менә сезгә ак яулык — суны сөзеп карагыз, үз күзегез белән күрерсез. (*Яулыкны алып су янына китәләр, сөзеп карыйлар.*)

Каһарман. Менә күрәсезме?

Тимерша. Карагыз, кара, авылда кешеләр авырый, хайваннар үлә. Менә бәла нәрсәдә икән! Ягез, оланнар, ни дисез?

Җиһанша. Бүген үк кабыкларын алдырырга кирәк.

Айдар. Әйе, әйе, алдырырга. Волостька кеше җибәрик, килеп карасыннар, Мөстәкыйм мөртәтне хөкемгә тартсыннар.

Каһарман. Юк, Айдар бабай. Без аңар хөкемне үзебез ясарбыз.

Тимерша. Дөрес, Каһарман, әйдә башла. (*Известьле бутылканы бирә.*)

Каһарман буага бутылка ташлый. Көчле шартлау тавышы ишетелә.

Җиһанша. Җәмәгать, ни карап торасыз, Алкинның онын талагыз. (*Тегермәнгә кереп китәләр.*)

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мөстәкыйм байның ишегалды. Бер якта — байларча салынган өй, икенче якта — зур амбар. Артта биек койма һәм урыс капка. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә беркем
дә юк. Бераздан капка дөбердәтәләр. Өйдән Файзә чыга, барып капка ача.
Хәдичә керә.

Хәдичә. Ни өчен көпә-көндез бикләнеп утырасыз? Авылда нindидер солдатлар. Ни булды монда?

Файзә. Кичә, безнең тегермән буасын ерып, Алкинның оннарын талаганнар иде. Шул ачудан абҗур командасы китерделәр.

Хәдичә. Әйтәм аны солдат белән урам тулган, бик күпләр, ахры.

Файзә. Ике йөз илле кеше диме шунда. Иртә белән йоклап ятканда, мылтыклар атып, авылга килеп керделәр, халыкның котын алдылар.

Хәдичә. Безнең эткәйләр авылында да шундый ук хәл. Бөтен халык урамда. Нindидер пожар сарае, кыңгырау-чаң турында тавышланалар. Үзе өйдә юкмы әллә?

Файзә. Түрәләр белән йөри торгандыр йә булмаса яшь бикәче янына киткәндер.

Хәдичә. Нинди яшь бикәче?

Файзә. Ул өйләнде бит.

Хәдичә. Өйләнде? Кемгә?

Файзә. Мич чыгаручы Иргали Фәрхиназына.

Хәдичә. Кайчан?

Файзә. Кичә никах укыттылар, бүген кыз куенына керергә йөри.

Хәдичә. Кыстый-кыстый кунакка озатуыннан ук шикләнгән идем, аның нияте менә нәрсәдә булган икән. Нинди оят! Нинди хурлык!.. Гарип булсаң, авыру булсаң, тагын бер хәл иде. Тап-таза килеш өстеңнән хатын алсын да көндәш утына салсын, имеш. Юк, мин бу хурлыкка чыдый алмыйм. (*Өйгә кереп китә.*)

Файзә. Язмышың шулай булгач, чыдамый нишлисең? Татар баеса — хатын ала, урыс баеса — чиркәү сала, дип белеп әйткәннәр.

Иргали керә.

Иргали. Нихәл, Файзә?

Файзә. Шөкер әле, Иргали абый.

Иргали. Өйдәме?

Файзә. Кем?

Иргали. Ирең.

Файзә. Киявем диген.

Иргали. Әй... Куй инде, Файзә, телем әйләнми...

Файзә. Алай булгач, нигә бирдең соң?

Иргали. Яучы белән сихерчене бер, диләр. Көне-төне димләп авыз ачарга да бирмәделәр. Менә хәзер шуның газабын кичереп йөрим. Бала кызганыч... Ашаганы юк, эчкәне юк... Барыбер мин аңар хатын булмыйм, ди. Мин аның холкын беләм, анасына охшаган, тешләгән җирдән өзә торган кыз ул. Әле хәзер яшь хәзрәткә мич чыгарып бетердем дә, шәригатьтә кире кайтару йоласы юкмы, дип сорадым. Никах кайтару гадәте пәйгамбәрләр заманында булган эш, ләкин иренең ихтыяры белән, Мөстәкыймнән сорап кара, бәлки, риза булыр, ди.

Файзә. Ай-һай, Иргали абзый, таш күңелле кеше ул...

Иргали. Үзе өйдәме?

Файзә. Чыгып киткән иде.

Иргали. Ярый алайса, бераздан әйләнеп керермен. (*Китә башлый.*)

Файзә. Иргали абзый, абзар аратасын сындырып айгыр утарга чыккан, башка атларга тынычлык бирми, шул каһәрне ябып куя алмассыңмы?

Иргали. Ярый, Файзә, ябармын.

Файзә. Аңарчы үзе дә кайтыр. Сакланып бар, бик усал ул, иясенә охшаган, тешләшә.

Иргали китә. Сәетҗан керә.

Сәетҗан. Әни!

Файзә. Әйдә, балам, өйгә кер.

Сәетҗан. Юк, әни, кереп тормыйм. Синең белән саубуллашырга гына килдем.

Файзә. Ничек саубуллашырга?

Сәетҗан. Шулай, әни, мин китәм.

Файзә. Китәсең? Кая?

Сәетҗан. Казак сахрасына. Мондагы вәхшәтне күреп тора алмыйм. Беләсеңме, әни, анда нишлиләр? Бөтен келәт-амбарларны тентиләр. Кисмәк төпләреннән чыккан он, ярма бөртекләрен канат белән себереп алалар.

Файзә. Алсалар. Синең үзеңдә гаеп бар. Үги булса да, ул бит сиңа ата тиешле. Әйткән сүзен тыңларга иде.

Сәетҗан. Мин бит, әни, моңа кадәр карышмадым. Нинди генә авырлыклар, кимсетүләр күрсәм дә, барысына да түздем, чыдадым. Ләкин инде биш пот онга сөйгән кызымны сатып ала башлагач, түзмәдем.

Файзә. Читкә китеп син нишләрсең, кара эшкә бер дә күнекмәгән.

Сәетҗан. Кайгырма, әни, казак балаларын укытырмын.

Файзә. Юк, юк, балам, җибәрмим. Атаң гына кайтсын, үзем мин аңардан сорармын.

Сәетҗан. Кирәкми, әни, сорама. Җитәр инде, унҗиде ел түбәнлекләр күреп, колы булып яшәдең. Әйдә, бергә китәбез.

Артта тавыш, кычкырыш.

Файзә. Нишлиләр анда?

Сәетҗан. Солдатлар нindидер бер кешене куып килаләр.

Каһәрман йөгереп керә.

Каһәрман. Сәетҗан, качыр мине.

Сәетҗан. Әйдә, Каһәрман абый. (*Өйалдына яба.*)

Берничә солдат белән Камай керә.

Камай. Кая китте ул, ристан?
Сәетҗан. Улмы?.. Ул урамга чыгып йөгерде...
Камай. Солдатлар, әйдәгез! (*Урамга чыгып китәләр.*)
Файзә. Улым, нигә кешене алдыйсың?
Сәетҗан. Әгәр аны тотсалар, беләсеңме, әни, нәрсә булачак?
Файзә. Булса соң, анда синең ни эшең бар?

Каһәрман чыга. Иргали кереп бер читтә карап тора.

Каһәрман. Файзә түтәй, рәхмәт. Рәхмәт, Сәетҗан. Гомерем булса, онытмам. Тик, зинһар өчен, миңа авыл чыкканчы хатын-кыз киемнәре бирегез. Мин киенеп качыйм.

Сәетҗан. Юк, Каһәрман абый, ярамый, тотарлар. Күрәсең, авыл төрле яктан чолганып алынган, басу капкаларына, урам чатларына солдат куелган. Син төнгә кадәр бездә генә тор, таң алдыннан икәү бергә качарбыз.

Файзә. Кеше килә!..

Сәетҗан. Әйдә чормага... (*Чормага менә торган баскычтан менгезеп җибәрә.*)

Мөстәкыйм керә.

Мөстәкыйм. Кайттыңмы, шарлатан? Син бит читкә китәм дип йөргәнсең.
Файзә. Юк, атасы, болай гына сөйләгәндер. Үз хатасын аңлап кайткан икән, син аны гафу ит.
Мөстәкыйм. Гафу итәргә? Үз атасына кул күтәрүчене гафу итәргәме?
Сәетҗан. Мин синнән гафу итүне сораганым юк бит әле.
Мөстәкыйм. Шулаймыни? Сорамыйсыңмы?
Сәетҗан. Һичбер вакытта.
Мөстәкыйм. Алай булгач, нигә минем ишегалдына кердең?
Сәетҗан. Мин сиңа түгел, әни янына килдем.
Мөстәкыйм. Бар, чык моннан!..
Файзә. Атасы, кызмый гына сөйлә әле.

Сәетҗан. Абжур командасы китердем дә котылдым дип җикеренәмсең? Юк, күрәчәгең алда әле, халык яше бер тотачак, авыл талап җыйган байлыкларың көлгә әйләнеп күккә очачак!..

Мөстәкыйм. Әһә?.. Ут салырга яныйсың?
Сәетҗан. Хуш, әни... (*Китә.*)

Файзә. Китмә, балам, җибәрмим... (*Мөстәкыймнең алдына тезләнә.*) Мөстәкыйм, дөньядагы бердәнбер өметемне җимермә, кичер аны, гафу ит.

Мөстәкыйм. Аны гафу итәргә?.. Мин аны бүген үк арестовать иттерәм.
Файзә. Аның сиңа нинди усаллыгы тигәне бар?
Мөстәкыйм. Ә соң хәзер генә нәрсә диде, ут салырга янады түгелме?
Файзә. Имансыз икәнсең. Ул чагында мин дә синең яныңда калмыйм.
Мөстәкыйм. Калмыйсың? Ха-ха-ха... Аяклы имгәк, миннән китеп кая барасың?
Файзә. Илдә чыпчык үлми, дигән бабайлар. Әйдә, мине талак ит.
Мөстәкыйм. Бик рәхәтләнеп, бер тамак кимер. Бар, хәзер үк мулланы алып кил.

Файзә. Ләгънәт төшсен сиңа! Йөргән җиреңдә муеның борылсын, кеше кулларыннан җаның алынсын, үлгән чакларыңда, ялгыз калып, бер кашык су бирүчең булмасын...

Мөстәкыйм. Бар, диләр сиңа!..

Таяк алып сугарга бара, Иргали килеп артыннан тотып ала.
Файзә китә.

Иргали. Ярамый, Мөстәкыйм.
Мөстәкыйм. Каенатай? Син ничек монда?
Иргали. Синең яныңа килдем.
Мөстәкыйм. Бик әйбәт булган, әйдә өйгә керик, кунак булырсың.
Иргали. Булырбыз әле, хәзер вакытым юк. Мине яшь хәзрәт җибәргән иде.
Мөстәкыйм. Соң? Нинди йомыш белән?
Иргали. Ул әйтә...
Мөстәкыйм. Нәрсә әйтә?
Иргали. Шәригатьтә... Солдатлар авылда озак торырлар микән, ди.
Мөстәкыйм. Тентүне ясап бетерделәр. Каһәрман ристанны тоту белән китәләр. Нигә ул аны сорый икән?
Иргали. Ярый, мин китим инде...

Мөстәкыйм. Тукта әле, каенатай. Теге инструкция буенча, янгыннан саклану өчен, өй түбәләрендәге бөтен калай торбаларны алырга кушалар, безгә дә кирпечтән чыгарырга кирәк булыр, әйдә әле, шуны менеп карыйк. Күпме кирпеч китәр икән.

Иргали. Син, кияү, менеп йөрмә инде, үзем генә карармын. Йә егылып төшәрсең дә берәр җиреңне имгәтерсең...

Мөстәкыйм. Ярый алайса, бар.

Иргали чормага менеп китә. Төенчек күтәреп, өйдән Хәдичә чыга.

Хәдичә?.. Син кайчан кайттың? Кая болай җыендың?

Хәдичә. Мин китәм...

Мөстәкыйм. Китәсең? Кая?

Хәдичә. Әтиләргә...

Мөстәкыйм. Нигә?

Хәдичә. Минем өстемнән яшь хатын алгансың ич.

Мөстәкыйм. Алсам соң!

Хәдичә. Мин кемнән ким? Мин сиңа кай ягым белән ошамыйм?

Мөстәкыйм. Ошыйсың, бар җирең дә килгән, сине өзелеп тә яратам, тик менә бала тапмыйсың. Минем, алдыма утыртып, бала сөясем килә, ә безнең күңел юатырлык бер генә балабыз да юк.

Хәдичә. Нишлим соң, Алла бирмәгәч?

Мөстәкыйм. Син аның өчен кайгырма, мин сине әүвәлгечә сөярмен, әүвәлгечә яратырмын, ашның тәмлесе, киемнең асылы сиңа булыр. Теге карт имгәк белән Фәрхиназны кара өйгә куарбыз да, үзебез, ак өйгә урнашып, йөзне йөзгә, тезне тезгә куеп, тик сөешеп утырырбыз.

Хәдичә. Шулай булса ярар иде дә бит, никтер күңелем ышанмый, һаман яшь хатыныңны гына сөярсең кебек тоела.

Мөстәкыйм. Кит аннан... Синең белән аны алыштыраммы соң! Әйтәм бит, мин аны бала өчен генә алам. Син минем матур тутыем, кара кашым, карлыгачым, сайрый торган сандугачым... Ярый, бар, өйгә кер. Озакламый түрәләр кайтыр, кичкә кунаклар килер, аш-су әзерлә.

Хәдичә. Мөстәкыйм, мине генә сөярсең, мине генә яратырсың, яме!

Мөстәкыйм. Әйе, әйе, сине генә... Бар инде, бар!..

Төеннәрен алып, Хәдичә өйгә кереп китә. Түбәдән Иргали төшә.

Йә, каенатай, карадыңмы?

Иргали. Әйе, карадым. Ике йөз кирпеч җитәр.

Мөстәкыйм. Шунда берьюлы мунча мичен дә чыгарып бирерсең.

Иргали. Кара әле, Мөстәкыйм, мин сиңа бая шуны әйтергә теләгән идем...

Мөстәкыйм. Йә, әйт инде, әйт, берәр әйбер кирәкме?

Ишнияз керә. Иргали китә.

Ишнияз. Җыелган оннарны үлчәтеп капчыкларга тутырттым. Тик син әйткәннән ике йөз потлап артык чыга. Аларны нишләтербез икән?

Мөстәкыйм. Тегермән буасын җимерү расходларын капларга китәр. Бүген үк оннарны Алкиннарга ташыта башлагыз.

Ишнияз. Анысын инде үзләре дә килеп алырлар.

Мөстәкыйм. Юк. Илтеп бирегез, икенче кат бунт күтәрмәскә сабак булыр.

Ротмистр керә.

Ротмистр. Староста! Солдатларга ужин өчен ит әзерләндеме?

Ишнияз. Юк әле, ваше благородие, симез хайван таба алмыйбыз.

Ротмистр. Аннан авылдагы бөтен аксакалларны монда чакырт!

Ишнияз. Әллә тагын җыен буламы?

Ротмистр. Юк. Каһәрман бунтовщикның кайдалыгын соңгы тапкыр сорыйм, әйтмәсәләр, заложник итеп өязгә озатам.

Ишнияз. Десятниклар, Җамали, кая дөмектегез, Камали?! (*Китә.*)

Мөстәкыйм. Димәк, тота алмадыгыз?

Ротмистр. Авылдагы бөтен келәт-амбарлар калмады. Сарай түбәләре, салам аслары штык белән актарылды. Юк, минемчә, ул авылда түгелдер.

Мөстәкыйм. Авылда, авылда! Күптән түгел генә мәчет түбәсеннән төшеп йөгергәнен күргәннәр.

Ротмистр. Алай булгач, кайда соң?

Мөстәкыйм. Борчылмагыз, беркая да китә алмас. Басу капкаларына, урам чатларына сакчы куелган бит. Бүгенме, иртәгәме — барыбер безнең кулда булачак.

Ротмистр. Безгә аны бүген тотарга кирәк. Иртәгә калдырсак, соң булыр, чөнки төнлә белән авылдан качырулары бар.

Айдар белән Җиһаншаны кертәләр.

Ишнияз. Ваше благородие, менә күрше авылдан тотканнар, нишләтергә кушасыз?

Ротмистр. Болар кемнәр?

Мөстәкыйм. Бу карт — халыкны котыртучы, теге бунтовщикның киңәшчеләреннән.

Ротмистр. Әһә, шулаймыни?! Качып кая бармакчы булган идегез?

Айдар. Юк, мин качмадым. Бөтен нәрсәдән мәхрүм итүегезне башка авылларга да аңлатырга барган идем...

Ротмистр. Әнә шул амбарга ябыгыз. Әйдә, бар, карт шайтан!.. (*Төртә.*)

Айдар. Төртмә син миңа, маңка!.. Бабаң белән кордаш мин сиңа!

Мөстәкыйм. Бунт чыгарып йөрүең өчен аркаңнан сөяргә кушар идеңме, карт иблис!

Айдар. Сездән шәфкать сораганым юк, әмма миңа кулыгызны сузмагыз!

Ротмистр. Молчать! Ябып куегыз! (*Алып китәләр.*)

Җиһанша. Мөстәкыйм абзый, мине ни өчен?

Мөстәкыйм. Менә ваше благородиедән сора, нәрсәгә икәнен әйтер.

Ротмистр. Бусы кем?

Мөстәкыйм. Теге атаманның агасы, башлап тегермән талаучы.

Ротмистр. Шулаймыни? Әйдә, бар!

Җиһанша. Сине талау гына аз, тиреңне туныйсы калган икән.

Мөстәкыйм. Ваше благородие, ишетәсезме, миңа яный ул.

Җиһанша. Исән генә котылыйм. Мин сине кызыл үгездән сөздерәм, чәчрәп китим, сөздерәм!..

Җиһаншаны келәткә ябалар.

Мөстәкыйм. Ваше благородие, халык җыйналганчы өйгә кереп торыйк. (*Кереп китәләр.*)

Ишнияз. Камай, Камай, кая дөмектегез, Җамали?!

Камай керә.

Камай. Карлы каргасыдай нигә карылдыйсың?

Ишнияз. Үләм бит инде. Тагын ит, диләр. Командага ашарга сорыйлар.

Камай. Иртә белән генә бер тана суеп бирдек, кая куйганнар?

Ишнияз. Бер салуда ашап бетергәннәр. Сәмруг кош кебек, тагын ужинга ит, диләр.

Камай. Бирәннәр, кай җирләренә тыгыналар икән?

Ишнияз. Шуның өчен дә аларга абжур командасы дип исем биргәннәр. Йә, нишлибез?

Камай. Мөстәкыйм белән сөйләшеп карарга иде, берәр җаен тапмасмы?

Ишнияз. Сөйләштем, авыз ачарга да бирми, үзегез бунт күтәрдегез, теләсәгез ничек туйдырыгыз, ди.

Мөхсин мулла белән Файзә керә.

Камай. Хәзрәт, безнең сиңа киңәшебез бар иде.

Мөхсин тукталып кала, Файзә өйгә кереп китә.

Мөхсин. Сөйләгез, мулла Камалетдин, нинди киңәш ул?

Ишнияз. Иртә белән бер тана суеп солдатларны ашаткан идек, кичкә тагын ит, диләр. Алырга акчабыз, сатарга әйберебез юк, халыктан җыяр идек — үзе ач. Нишләргә кушасыз?

Мөхсин. Әлбәттә, туйдырырга кирәк.

Ишнияз. Анысын, хәзрәт, без үзебез дә беләбез, каян алырга дип синнән киңәш сорыйбыз.

Мөхсин. Зират печәнен сатарга кирәк.

Ишнияз. Ярый ла халык риза булса.

Камай. Мондый чакта халык ризалыгын сорап тормабыз инде, тик син кемгә сатарбыз диген.

Ишнияз. Хакына килешә алсак, әйдә, үзем алырмын.

Мөхсин. Юк, Ишнияз, сиңа сату мәслихәт булмас, чөнки анда күмелгән әрвахларның рухына җитмеш җиде кәррә ясин чыгарга, җитмеш җиде мең кәррә тәсбих тартырга кирәк. Сез ул яктан, әлбәттә, мәхрүм.

Ишнияз. Үзем укый белмәсәм, улым башкарыр.

Мөхсин. Юк инде, аның белеме андый зур эшкә җитәрлек түгел.

Камай. Алай булгач, хәзрәт, кемгә сатарбыз икән?

Мөхсин. Минем өчен гәрчә печән кирәк булмаса да, җәмәгать өстенә килгән авырлыкны күтәрми булмас. Бәс, шулай булгач, үзем алырмын.

Камай. Бик яхшы, хәзрәт, бик зур рәхмәт сиңа.

Мөхсин. Башмак танамны бүре тешләгән иде, шул хайван бер айдан бирле абзарда ята. Шуның бәрабәренә тугырылап, зират печәнен миңа бирерсез.

Ишнияз. Кара әле, хәзрәт, ул бик арыктыр.

Камай. Тамакларына төртелмәс әле. Ярый, хәзрәт, килештек, зират печәне сезнеке.

Мөхсин. Әүвәл-ахыры хәерле булсын. Тизрәк барып суегыз, тиресен миңа калдырырсыз.

Камай урамга чыгып китә, өйдән ротмистр белән Мөстәкыйм чыга.

Ротмистр. Староста, халык җыйналып беттеме?

Ишнияз. Беттеләр, ваше благородие, капка төбендә торалар.

Ротмистр. Монда керсеннәр, амбардагыларын да чыгарыгыз.

Ишнияз. Агай-эне, әйдәгез, монда керегез!..

Капканы ачалар, халык ишегалдына кереп тула, кайберләре койма башларыннан карап тора.

Ротмистр. Капканы бикләп алыгыз, беркемне дә чыгармагыз. (*Капканы ябып биклиләр.*) Аксакаллар, ике адым алга!

Ишнияз. Сезгә әйтәләр бит, нигә сарыклар төсле катып торасыз?

Ротмистр. Картлар, аксакаллар, мин сезнең тегермән талауда булган гаепләрегезне кичерәм, тик сез миңа Каһәрман белән Тимершаларның кайдалыгын әйтегез.

Тынлык.

Ротмистр. Ягез, мин көтәм.

Айдар. Белгән булсак әйтер идек, белмибез.

Ротмистр. Молчать! Синнән сорамыйлар. Сез аның кайда икәнлеген белергә тиеш.

Картлар. Белмибез.

Ротмистр. Күргәнегез дә юкмы?

Картлар. Юк.

Ротмистр. Табып бирергә сүз бирәсезме?

Мөхсин. Мөселманнар, әгәр дә белә торган булсагыз, кил, зинһар, алар өчен үзегезне хафага салмагыз, ул имансызларның исемен күңелләрегездә сакламагыз.

Айдар. Их, хәзрәт, хәзрәт, ничә еллар сиңа оеп намаз укыдым, ничә еллар тапканымның иң тәмлесен сиңа тыгындырдым. Шушындый аяныч көннәр кичергән чагыбызда гына эндәшмәсәң ни була?

Ротмистр. Картлар, соңгы тапкыр сорыйм, әйтәсезме-юкмы?

Картлар. Кайда икәнен белмибез.

Ротмистр. Мулла, синең алдыңда Коръән үбеп ант итсеннәр.

Мөхсин. Аллаһе Тәгалә вә тәбарәкә хәзрәтләренең исеме белән пәйгамбәребезнең...

Айдар. Тфү!.. Сатлыкҗан икәнсең!

Ротмистр. Молчать!.. Өсләрегезне салыгыз!.. Дәүләткә хыянәт итүчеләрне яшереп асрауда гаепләнеп, йөзәр тапкыр шомпол җәзасы аласыз.

Мөстәкыйм. Йә, нәрсә көтәсез, сезгә әйтәләр бит!..

Картлар күлмәкләрен салалар.

Ротмистр. Җиргә ятыгыз!.. (*Картлар яталар.*) Иң соңгы тапкыр сорыйм, әйтәсезме-юкмы?

Картлар (*җиргә яткан килеш башларын күтәрмичә генә*). Юк, әйтмибез.

Ротмистр. Солдатлар, йөзәр шомпол бирегез!..

Һәр карт янына берәр солдат килеп баса, суктыра башлыйлар. Чормадан өй түбәсенә Каһәрман чыгып бар тавышка кычкыра.

Каһәрман. Юк, сукмагыз!.. Минем өчен аларга тимәгез, өйләренә кайтып җылы түшәкләрендә үләргә ирек бирегез.

Ротмистр. Бу нинди кеше?

Мөстәкыйм. Каһәрман...

Ротмистр. Каһәрман? Ул бунтовщик синмени?

Каһәрман. Әйе, мин булам.

Ротмистр. Молчать!.. Тотып алыгыз да җиргә сузып салыгыз!

Каһәрман. Якын килмәгез!.. Мин үзем дә барып ятармын. *(Өстендәге киемнәрен салып түбәгә ташлый да җиргә сикереп төшә.)* Бу картларны җибәрегез. Алар өчен, бөтен авылым өчен мине суктырыгыз!.. *(Алларына барып ята.)*

Халык. Җибәрегез, тимәгез аңа!!!

Халык ишегалдында күбәйгәннән-күбәя, шау-шу көчәйгәннән-көчәя бара.

Ротмистр. Солдатлар, арестованныйларны ябыгыз да бу картларны өйләренә куыгыз.

Ишнияз. Агай-эне, барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз!

Халыкны ишегалдыннан куалар, Каһәрман, Айдар, Җиһаншаларны амбарга ябалар. Ике казак ияртеп, исправник керә.

Исправник. Господин ротмистр! Боларны яклап Тигәнә, Мәңгәр авылларында көчле восстание... Генерал-губернатор Скрятин хәзрәтләре биш йөз кешелек гаскәр белән Казаннан Спаска киткән. Сезгә һич кичекмәстән Мәңгәр волостена барырга әмер иткән.

Мөстәкыйм. Юк, юк, бу һич мөмкин түгел. Алар, сез китү белән, миңа һөҗүм итәрләр, мине таларлар.

Исправник. Монда мин калам, зинһар, тизрәк китегез, бөтен губерна куркыныч астында.

Ротмистр (*солдатка*). Горнистка әйтегез, сигнал бирсен. Урамдагы халыкны өйләренә куыгыз. Хушыгыз, господа!.. (*Күрешеп урамга чыга.*)

Мөстәкыйм озатып кала.

Рота, смирно!.. Шагом марш!.. (*Барабан кагып киткәннәре ишетелә.*)

Исправник. Староста!

Ишнияз. Без монда.

Исправник. Хәзер үк миңа бер десятникны бир, бунтовщикны алып китәргә волостьтан тимер читлек җибәрсеннәр.

Ишнияз. Була ул. Десятниклар, Җамали, кая дөмектегез? Камали!.. (*Китә.*)

Исправник. Ярый, мин хәзер, теге бунтовщикның янына кереп, Тимершаларның кайдалыгын әйттерәм.

Мөстәкыйм. Ай-һай, әйтер микән.

Исправник. Әйтер. Мин аны мәҗбүр итәрмен. (*Җиңнәрен сызганып, изүен чишеп амбарга кереп китә.*)

Абруй белән Гөлҗамал Фәрхиназны җитәкләп керә.

Абруй. Әйдә, Фәрхиназ, әйдә, җанкисәк.

Фәрхиназ. Җибәрегез, мин барыбер аңа хатын булмыйм.

Абруй. Алай сөйләнмә, кияү ишетер.

Өйдән Хәдичә чыгып баскычка палас җәя. Фәрхиназның авызына көчләп кашык белән май каптыра. Кереп китәләр.

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Мөстәкыйм байның өй эче. Пәрдә ачылганда, Фәрхиназ, утырган килеш, бер ноктага карап катып тора. Аның әйләнәсендә кызлар, җиңгиләр
җырлап чәчләрен үрәләр, бизиләр.

Гөлҗамал. Иртә торып битең югач,
Майлап чәчең тарарсың,
Агыйделнең аккошыдай
Илгә даның таралсын.
Кызлар. Җепшек бураннарда туңган
Яшь боландай боекма,
Җәрәхәтле йөрәгеңә
Хәсрәт уты оетма...
Гөлҗамал. Һәр ел саен гөлҗимешләр
Язын ата ал чәчәк,
Ал чәчәкле гөлҗимештәй
Матур синең киләчәк.

Фәрхиназ. Җырламагыз, дусларым, кирәкми. Сез барыбер минем өзелгән өметемне ялгый алмаган кебек, дөрләп янган йөрәк ялкынын да сүндерә алмассыз. Барыгыз, дусларым, өйләрегезгә кайтыгыз да ата-аналарыгызның кайгы-хәсрәтләрен уртаклашыгыз, үз тормышыгызның минеке шикелле булмавын теләп бер Алладан ялынып сорагыз..

Артта Каһәрманның ыңгырашканы ишетелә.

Кемне анда кыйныйлар?
Гөлҗамал. Юк, Фәрхиназ, беркемне дә кыйнамыйлар...
Фәрхиназ. Әнә бит ул ничек ыңгыраша. Каһәрман абый түгелме?
Гөлҗамал. Юк, юк, Фәрхиназ, аны күптән инде волостька озаттылар.

Фәрхиназ тәрәзәгә бара.

Фәрхиназ акыллым, беләсең, хатын-кызга тәрәзә төбенә утырырга кушмыйлар.

Фәрхиназ. Минем өчен хәзер барыбер. Аннан зурракларыннан да курыкмадым. Ата-анамның сүзен тыңламый, никах вакытында тәрәзә аша ташландым, олылар һәм муллалар алдында тел ачтым. (*Тәрәзәне ачып җибәрә.*)

Гөлҗамал. Юк, юк, сиңа анда торырга ярамый.

Фәрхиназ. Курыкма, түтәй, мин хәзер беркая да китмим, шулай ук икенче кат тәрәзәдән дә сикерергә уйламыйм.

Мин бары тик айга карыйм,
Айга карыйм туйганчы,
Соңгы тапкыр Зөһрәкәйгә
Карыйм күзем талганчы.
Әнә, кызлар, күрәсезме? —
Көянтәсен аскан ул,
Саф күңелле кыз булганга,
Айга менеп баскан ул.
Ул мескен дә, минем кебек,
Яшьли ятим калган бит,
Үги ана җәфаларын
Минем төсле күргән бит.
Ялгыз башы мунчаларда,
Абзарларда кунган ул.
Кышкы салкын бураннарда
Яланаяк йөргән ул.
Төнгә кадәр сулар ташып,
Төпсез кисмәк тулмагач,
Боз өстенә тезләнгән дә,
Атлар хәле калмагач,
Елый-елый айга карап
Ялварган ул, баш орган.
Шәфкатьле ай ярдәм итеп,
Үз янына ашырган.
Әй, Зөһрә!..
Дөньясында күпме газап,
Авырлыклар күргәнсең,
Ә шулай да син бәхетле —
Айга кадәр менгәнсең.
Нинди шатлык булыр иде,
Синең кебек булалсам,
Биш пот онга сатылудан
Үз башымны йолалсам.
Юк шул, Зөһрә!
Ярдәм сорап телгә алмаган
Бер затым да калмады.
Чын күңелдән иткән догаларым
Ни өчендер кабул булмады.
Зарар юк...
Күбәләктәй жанкисәгем
Бу газаптан котылыр,

Айлар, еллар үтү белән,
Исемем дә онытылыр...

Шулай бит, кызлар, онытылыр бит? Эндәшмисез, елыйсыз? Еламагыз! Елап минем хәлемне җиңеләйтә алмассыз.

Гөлҗамал. Фәрхиназ, андый сүзләр сөйләмә, болай да бит безгә бик авыр.

Фәрхиназ. Нишлим соң, түтәй? Үкси-үкси елар идем — яшем кипкән, уйнап-көлеп җырлар идем — дәрманым беткән. Дөньясыннан җаным бизеп, бар өметем кайтмас булып, ташлап киткән чакта күңел юатырга, вакыт озайтырга ни дә булса җанга азык кирәк ич.

Гөлҗамал. Юк, юк, бүген сиңа шатланырга, көләргә генә.

Фәрхиназ. Чыннан да, шулай шул... Әйдә, кызлар, такмак әйтеп биибез!

Бас, бас, бас әйдә,
Мулла кызы Зөбәйдә,
Мулла кызы Зөбәйдәнең
Туе икән кайсы айда?

Кызлар. Бүген түгел, иртәгә,
Әтәч кунган киртәгә,
Киләчәк, ди, баш кода
Шул тәкәббер иркәгә.
Өмет итеп санатка,
Эше әйләнгән харапка,
Хәзер инде риза булган
Ак мыеклы солдатка.

Абруй керә.

Абруй. Кызлар, бу якка ирләр керә, Фәрхиназны теге якка алып чыгыгыз. Кияү биргән асыл киемнәрен киендерегез.

Гөлҗамал. Әйдә, Фәрхиназ. (*Китәләр.*)

Мөстәкыйм белән исправник керә.

Мөстәкыйм. Шулай итеп, әйттереп булмады диген.

Исправник. Юк, булмады. Кулын борып карадым, башын боргычладым, ләкин бер генә дә файдалы сүз ишетә алмадым.

Мөстәкыйм. Кая, кайсыгыз бар анда?!

Мичкә белән бал кертеп куялар.

Исправник. Шулай да Тимерша подлец кая китте икән?

Мөстәкыйм. Ул бит дөнья күргән кеше, үз башыннан күпне үткәргән, солдат хезмәтендә, әфисәрен кыйнап, дисциплинарный батальонда хезмәт иткән усал ул.

Исправник. Вон что!.. Аның әле шундый һөнәрләре дә бармыни?

Мөстәкыйм. Улмы? Ул бик хәйләкәр, усал кеше, бөтен нәселләре белән шундыйлар. Ягез, господин исправник, балдан авыз итегез. (*Эчәләр.*)

Камай керә.

Камай абзый, нишләп бик озак йөрдең?

Исправник. Авылда ничек, тынычлыкмы?

Камай. Майлагандай булдылар. Урам чатларына, капка төпләренә җыелганнар да сөйләшәләр, киңәшәләр.

Исправник. Интересно, нәрсә турында киңәшәләр?

Камай. Фәезхан кебекләре патшага прошение белән барырга димлиләр, кайберләре, приговорны бирергә кирәк, диләр.

Исправник. Бирергә диләрме? Дәүләт кораллы көч ул, коралга каршы баш күтәрүчеләрнең өстен булганын минем ишеткәнем дә, укыганым да юк.

Камай. Ярый, мин китим әле, урамга каравыллар чыгарасым бар. (*Китә.*)

Мөстәкыйм. Йә, ваше благородие, тагын берне җибәрик. (*Эчәләр.*)

Исправник. Ни өчен бу чакырткан арба озаклады? Тизрәк китәсе иде бит.

Мөстәкыйм. Минемчә, юкка гына төнгә каршы юлга чыгасыз. Хәвеф-хәтәр булудан курыкмыйсыңмы?

Исправник. То есть нинди хәвеф-хәтәр?

Мөстәкыйм. Кайта торган җирегез чокыр-чакыр арасы, шуның өстенә урман чыгасы бар. Алла сакласын, Тимерша кебек качып йөрүчеләр каршыгызга чыгып куйсалар?

Исправник. Постой, постой, сез чынлап та хаклы.

Мөстәкыйм. Шулай булгач, миндә генә куныгыз.

Исправник. Ләкин бит сезнең кияү керәсегез бар.

Мөстәкыйм. Булса соң, бигрәк тә яхшы. Минем өчен тынычрак булыр.

Камай керә.

Камай. Господин исправник, сораткан арбагыз килде.

Исправник. Менә нәрсә, сотский. Мин бүген китмим, монда гына кунам. Урамнарга тагын да күбрәк каравыллар куегыз. Һәр нәрсәне барлап, тикшереп торсыннар. Бигрәк тә арестованныйларны сакларга иң ышанычлы кешеләрне билгеләгез.

Камай. Тыныч булыгыз, барысы да сез дигәнчә үтәлер. Мин алайса шул турыда чарасын күрим.

Исправник. Әйдә, мин дә сакчыларны тикшереп керим. (*Китәләр*.)

Мөстәкыйм. Хәдичә, Хәдичә!..

Хәдичә керә.

Исправник өчен ак чоланга урын җәй.

Хәдичә. Әллә китмиме?

Мөстәкыйм. Кунгач, билгеле, китми. (*Китә башлый*.)

Хәдичә. Мөстәкыйм!..

Мөстәкыйм. Нәрсә тагы?

Хәдичә. Күңелем тула, елыйсым килә. Шушындый авыр елны нигә кирәк иде өйләнергә, нигә кеше елатырга?! Ул бит таш кебек каткан, аннан сиңа нинди наз да нинди сан булыр икән.

Мөстәкыйм. Сез хатын-кызлар барыгыз да башта шулай балавыз сыгып йөрисез дә соңыннан үзегез үк сыткый сагыз булып ябышасыз. Исеңдәдер, син дә шулай елап йөргән идең.

Хәдичә. Мин еласам, сиңа барасы килмәүдән түгел, әти-әни тәрбиясеннән аерыласым килмәүдән еладым.

Мөстәкыйм. Ул да шуның өчен елый торгандыр.

Хәдичә. Ул еламый, таш кебек каткан.

Мөстәкыйм. Ярый, ярый, иркәләнмә, син бит хәзер карт хатын. (*Китә*.)

Хәдичә. Ярабби, ни өчен генә мине хатын-кыз итеп яраттың?.. Бу хурлыкларны күрмәгән булыр идем...

Фәрхиназны кертәләр.

Абруй. Җиңгәләр, кызлар, әйдәгез, кияү түшәге җәярсез. Чибәр абыстай, син Фәрхиназ янында калып тор инде, берүзенә күңелсез булмасын.

Хәдичә. Ярый, барыгыз.

Абруй белән кызлар, җиңгәләр китәләр.

Фәрхиназ, үләсем исемдә иде, Ләкин синең миңа көндәш булуың турында уема да килгәне юк иде.

Фәрхиназ. Әйе, чибәр абыстай, минем дә шулай иде. Нишлим соң, язмышым шулай булгандыр.

Хәдичә. Әйе, язмыш... Ләкин нигә ул ирләргә түгел?

Фәрхиназ. Иргә ирек бирелгән, пәйгамбәрдән киленгән, диләр бит.

Хәдичә. Хатын көне дөм кебек, кап-караңгы төн кебек. Син кайгырма, Фәрхиназ. Мин сине үз сеңлем кебек күрермен. Шатлык булса да, кайгы булса да уртаклашырбыз.

Фәрхиназ. Рәхмәт, чибәр абыстай, мин дә сине үз апам шикелле итәрмен... Чибәр абыстай, мин теге якка чыгып керим әле.

Хәдичә. Нигә, акыллым?

Фәрхиназ. Кул бавым онытылып калган.

Хәдичә. Син йөрмә, үзем генә чыгып алырмын. Кай җирдә?

Фәрхиназ. Тәрәзә төбендәме, түр сәкесендәме шунда.

Хәдичә. Ярый, мин хәзер килермен. (*Китә*.)

Фәрхиназ (*көзгедән карап*). Раббем!..

Бар гүзәллек сыйфатларын миңа
Нигә бирдең болай мул итеп:
Аксак, сукыр, тинтәк булсам,
Сата алмаслар иде кол итеп.
Зәһәр көчләр, аждаһадай, ыжылдап
Торсалар да минем юлымда,

Үз язмышым үзем хәл кылырлык
Бер чарам бар әле кулымда.
(*Читек кунычыннан кинжал чыгара.*)

Артта Каһәрман тавышы.

Тукта!.. Бу Каһәрман абый түгелме соң,
Авыр газап белән көрәшә?
Әйе, ул шул... Үләр өчен түгел,
Үч алырга миңа эндәшә.
Шулай булгач, инде нигә хәзер
Яшьлегемнән иртә туярга?
Бер хәшәрәт аркасында гына
Үз кулымнан каным коярга?
Кара елан төсле ул үрмәләп,
Тели икән минем куеныма!
Шул чагында бөтен көчем белән
Ник салмаска шуны муенына?
(*Кинжалын читек кунычына яшерә.*)

Хәдичә керә.

Хәдичә. Фәрхиназ, юк бит анда, тапмадым.

Фәрхиназ. Шулаймыни? Әллә өйдә калдырдым микән?

Хәдичә. Белмим шул, мин анда бөтен җирдән эзләдем, юк.

Фәрхиназ. Һи... Кара инде, камзул кесәмдә ич... Гаеп итмә инде, чибәр абыстай, башым әйләнгән шул минем...

Абруй керә.

Абруй. Чибәр абыстай, ак чыбылдык бирәм, дигән идең.

Хәдичә. Хәзер кертермен. (*Китә.*)

Абруй. Син, Фәрхиназ, кайгырма. Яшьлек — юләрлек ул. Миңа мине дә атаң көчләп бирделәр, унҗиде яшь тә тулмаган иде. Башта, синең шикелле, мин дә еладым. Мин дә бармаска теләдем. Абзыйларым, кыйный-кыйный, илле яшьлек картка бирделәр. Шул чагында түккән яшем, иткән юләрлегем хәзер исемә төшсә, үз-үземнән гарьләнәм. Бар да юкка, бар да бикәргә булганнар. Менә, әлхәмделиллаһи шөкер, ун ел инде күгәрчендәй гөрләп торабыз. Бер иргә чыккач, тормыш камыты киеп, юклык арбасына җигелгәч, иреңнең яшьме-картмы булуы турында уйларга да туры килми. Күзеңне ертып йокыдан торуга, кылт итеп икмәк төшә исеңә. Шуннан, каян табармын, кемнән сорармын икән дип уйларга керешәсең. Ә син болар турында уйламассың, синең тормышың бал да май булыр. Моның өчен син безгә үпкәлисең, ачу тотасың. Йә, бетерик, син миннән бәхилме?

Фәрхиназ. Һичбер вакытта да... Җаным авызымнан чыккан чакта да сиңа ләгънәт укырмын...

Хәдичә чыбылдык тотып керә.

Хәдичә. Менә, корыгыз. (*Тышка чыгып китә.*)

Абруй, чыбылдыкны алып, бүлмәгә уза. Тышкы ишектә Иргали күренә.

Иргали. Кызым, мин синең белән күрешергә килдем.

Фәрхиназ. Бик яхшы иткәнсең, әткәй, рәхмәт сиңа.

Иргали. Каравылга чыгасым бар иде. Хуш, кызым... Алла сиңа бетмәс-төкәнмәс дөнья байлыгы, мәхәббәт тигезлеге бирсен, кызым.

Фәрхиназ. Их, әти... Биш пот онга саткан мәхәббәтнең нинди тигезлеге булыр икән?.. Әти, кечкенә чакта әни мәрхүмә сөйләгән бер әкият исемә төште, сиңа шуны сөйлимме?

Иргали. Сөйлә, кызым, сөйлә.

Тышта тәрәзәгә әкрен генә яңгыр сибеп яуганы ишетелә.

Фәрхиназ. Борын-борын заманда бер хан булган. Ул ханның бердәнбер бик матур кызы булган. Ул хан кызын шулкадәр яраткан, кызыннан аерылмас өчен, бөтен ханлыгыннан, хәтта җаныннан да аерылырга ант иткән. Шуннан бу хәбәрне аждаһа елан ишетеп алган да: «Тукта, сынап карыйм»,— дип, төнлә белән хан са-

раена киткән. Билгеле, аждаһалар, тылсым көченә ия булганга, сакчыларга күренмичә сарайга кереп, ханны уяткан. Хан аждаһаны күрүгә, куркып: «Син ничек монда кердең һәм ни өчен минем яныма килдең?» — дип сораган. Аждаһа елан: «Син кызыңны бик яратасың икән дип ишеттем, шул сүз дөресме?» — дигән. Хан: «Әйе, дөрес»,— дип җавап кайтарган. Шуннан соң: «Алай булса, син кызыңны миңа хатынлыкка бир», — дигән. Хан, әлбәттә, риза булмаган. Шуннан елан: «Әгәр дә син кызыңны яхшылык белән бирмәсәң, мин синең ташың өстендә таш калдырмыйм, ханлыгыңны җимерәм, үзеңне хәер сорашырга калдырам», — дип куркыткач, хан: «Кызымны ал, тик, зинһар өчен, ханлыгымны җимереп, үземне хәерчелеккә калдырма»,— дип ялына башлаган. Хан авызыннан бу сүзләрне ишеткәч, елан болай дигән: «Их, синең йөрәгең нинди икән, елан йөрәгеннән дә пычрак һәм яман икән... Сез, кешеләр, һәр сүз саен усаллык, начарлык белән без еланнарны телгә аласыз, ләкин без бервакытта да үз балаларыбызны утка салмыйбыз, байлык, дәрәҗәгә кызыгып сатмыйбыз...»

Иргали (*Фәрхиназ алдына тезләнеп*). Җитәр, кызым, җитәр, артык сөйләмә...

Фәрхиназ. Тор, әти, син бит ир кеше, кызың алдында үзеңне кимсетмә.

Иргали. Син беләсең, кызым, мин — юаш, үз ирексез бер кеше, анаң коткысына ияреп кенә башыңны ашадым.

Фәрхиназ. Зарар юк, мин күнәргә өйрәнгән инде, күнәрмен, хәсрәт җепләремне тиздән өзәрмен. Бар, әти, өйгә кайт.

Иргали. Юк, юк, балам. Бу хәлдә сине ташлап китә алмыйм. Әйдә, өйгә кайтабыз.

Фәрхиназ. Өйгә? Соң бит миңа никах укылган.

Иргали. Мин аны бозам. Әйдә, кызым, өйгә.

Иргали Фәрхиназны җитәкләп китә башлый. Абруй керә.

Абруй. Сез кая болай?

Иргали. Без, Абруйкамал, өйгә кайтабыз.

Абруй. Өйгә кайтасыз? Әллә син тилебәрән орлыгы ашадыңмы?

Иргали. Мин кызымны бирмәскә булдым.

Абруй. Бөтен ил каршында көлкегә калырга, Алла каршында мәңге җәһәннәмгә китәрлек гөнаһка чумарга уйлыйсыңмы?

Иргали. Теләсә нәрсә булсын, үз баламны үзем харап итәр хәлем юк.

Абруй. Ярый!.. Әгәр дә ул бусагаңнан атлап керсә, минем чыгып киткәнем булыр! (*Китә башлый.*)

Иргали (*аның кулыннан тотып туктата*). Абруйкамал, тукта әле.

Абруй. Ябышма миңа, кызың белән торырсың. (*Китә.*)

Иргали. Ярый, кызым, никах йоласын үткәргәнче тор инде, аннан үзем алып китәрмен.

Фәрхиназ. Эх, әткәй, чәчәк затлыгы белән, намус сафлыгы бик кыйбат бит кызларга.

Абруй (*ишектән башын сузып*). Уҗым бозавы, әйдә инде. Кияү көтә монда зарыгып.

Иргали. Хуш, кызым...

Фәрхиназ. Бәхил бул, әти...

Иргали. Нишләп, кызым, бәхилләшәсең?..

Фәрхиназ. Ялгыш әйттем, иртәгә кадәр хуш димәкче идем...

Иргали. Шулай диген, кызым... Хуш, балам... (*Китә.*)

Фәрхиназ. Әйе, әйе, шулай эшләргә кирәк...

Әкрен генә ишек ачыла. Киенеп-ясанып, Мөстәкыйм керә.

Мөстәкыйм. Нихәл, минем күгәрченем, исәнме! Нигә уйга чумдың, чибәрем?

Фәрхиназ. Әни мәрхүмә исемә төште, шуны уйлап тора идем...

Мөстәкыйм. Үлгәннәрне куй, үзебез турында уйларга кирәк. Әйдә керик, җәйгән түшәк көтмәсен.

Фәрхиназ. Җибәр әле, вакыт җиткәч, үзем дә керермен. Минем бал эчәсем килә, кая, миңа бал бир әле.

Мөстәкыйм. Сыйламадыларммы?

Фәрхиназ. Сыйлаганнар иде дә, синең белән бергә эчәрмен дип эчмәдем...

Мөстәкыйм. Шулаймыни? Хи-хи-хи... Хәзер була ул. (*Җамаяк белән бал бирә.*) Алдан әйтеп куям, бик куәтле, исермә.

Фәрхиназ. Зарар юк, бирешмәскә тырышырмын...

Мөстәкыйм. Их, Фәрхиназ, барыбер минеке булдың, юкка юләрлек эшләдең. Ярый, буласы булды, мин аларны кичерәм. Мин сиңа ефәк белән тегелгән, ука белән чигелгән киемнәр алырмын... Минем йокым килә, әйдә керик.

Фәрхиназ. Нигә ашыгасың, өлгерерсең әле...

Мөстәкыйм. Анысы шулай. Үткән төнне йокламадым, шуның өстенә юл кайткан кеше, арылган.

Фәрхиназ. Кая, тагын берне бир әле.

Мөстәкыйм. Кара аны, кызый, тагын әйтәм, мәлҗеп исермә...
Фәрхиназ. Исерсәм, җиңелрәк булыр...
Мөстәкыйм. Ах сине, наянны, хи-хи-хи, җиңелрәк булыр диген, ә?.. (*Эчәләр.*)
Фәрхиназ. Мөстәкыйм абзый...
Мөстәкыйм. Ничек дидең?
Фәрхиназ. Онытып җибәрдем, чынлап та исердем бугай.
Мөстәкыйм. Әйттем мин сиңа, эчмә, дидем.
Фәрхиназ. Синең үз җаның үзеңә кызганычмы?
Мөстәкыйм. Бу нинди сорау?
Фәрхиназ. Болай гына, кызганычмы, дим?
Мөстәкыйм. Мин моңа кадәр үземне кешеләрдән җәберләтү түгел, хәтта чебеннән дә тешләтмәскә тырыштым.
Фәрхиназ. Дөньяда торудан да туймадыңмы?
Мөстәкыйм. Нишләп миңа туярга? Киләчәккә өметләрен җуйган кешеләр генә дөньядан туялар. Миңа нәрсә? Тормышым яхшы, яңадан ун ел ачлык булса да кайгырмыйм. Әгәр дә дөньядан туйган булсам, синең шикелле җир фәрештәсенә өйләнмәгән булыр идем.
Фәрхиназ. Алай булса, мин синнән сорыйм: син үзеңне харап итмә, мине дә гөнаһлы ясама...
Мөстәкыйм. Нәрсә, нәрсә дидең?
Фәрхиназ. Кара, кара, күзе ничек акайды, әллә ышанды да инде, ха-ха-ха.
Мөстәкыйм. Юк, син әллә нинди мәгънәле сүзләр сөйлисең. Кара аны, кызый, кем белән сөйләшкәнеңне онытма!..
Фәрхиназ. Бигрәк тә беркатлы кеше икәнсең... Хатын-кызлар ирләрне сынаучан булалар, мин дә сине сынап карамакчы идем. Шулай да син бик сизгер кеше икәнсең...
Мөстәкыйм. Шулаймы, сизгерме? Минем алдымда сүзеңне уйлап сөйлә.
Фәрхиназ. Әйдә керик, минем корбаным!..
Мөстәкыйм. Ничек, ничек, корбаның?
Фәрхиназ. Тагын ялгыштым, хи-хи-хи... Мин — синең корбаның...
Мөстәкыйм. Шулай диген. Юкса мин ничек синең корбаның булыйм?
Фәрхиназ. Әйдә, кызларны көттермик. Син аларга ишек бавы күчтәнәчен, түшәк-җәймә бүләген кызганмыйча бир.
Мөстәкыйм. Синең өчен булганда, малымны гына түгел, җанымны да кызганмыйм. Менә кара, янчыгымда күпме акчам бар, һәммәсе дә аларга... (*Ишеккә баралар. Ишек эчке яктан бикле. Шакыйлар.*)
Гөлҗамал. Кем ул анда вакытсыз
Албастыдай дөберди?
Мөстәкыйм. Бу мин идем, яшь кияү!
Килдем ишек кагарга.
Гөлҗамал. Бездә алай рөхсәт юк,
Бушлай түшәк багарга.
Мөстәкыйм. Әйтче, балдыз, түшәгеңә
Ак чыбылдык корамсың?
Ишек бавы, түшәк ялы
Сездә күпме тора соң?
Гөлҗамал. Түшәгебез ун көмеш,
Ишек бавы йөз бакыр,
Сораганны бирмәс булсаң,
Килгән юлларың такыр.
Мөстәкыйм. Ярый инде, сатулашма,
Сораганың бирермен,
Тизрәк ачсаң ишекне,
Бик зур рәхмәт диярмен.
Гөлҗамал. Бераз гына көтә тор,
Янчык бавың чишә тор.
Мөстәкыйм. Янчык бавы чишелгән,
Сезгә бүләк сибелгән!..
(*Чылтыратып, идәнгә акча сибеп җибәрә.*)

Ишек ачыла, йөгерешеп кызлар чыгалар, Мөстәкыйм белән Фәрхиназ кереп китә, кызлар идәндәге акчаларны җыялар, бүлмә эчендә коточкыч тавыш ишетелә.

Гөлҗамал. Әбәү, андый ямьсез тавыш белән кайсы кычкыра?
Абруй. Әллә, Ходаем, сугышалармы?
Гөлҗамал. Тындылар...

Чәчләре тузган, йөзе шашкан кыяфәттә, бүлмәдән Фәрхиназ чыга.

Абруй. Фәрхиназ, сиңа ни булды?
Гөлҗамал. Нишләп йөзең агарган?
Фәрхиназ. Әнә карагыз!..
Гөлҗамал. Әнекәем лә...
Абруй. Суйган!!!
Башкалар. Ах!!! (*Кулларындагы тәңкәләрен чылтыратып идәнгә коялар*.)

Ишегалдында талаш, кычкырыш. Хәдичә йөгереп керә.

Хәдичә. Мөстәкыйм, Мөстәкыйм!
Абруй. Чибәр абыстай, нинди тавыш ул?
Хәдичә. Тимершалар килеп, Каһәрманнарны чыгардылар!

Каһәрман белән Тимерша керә.

Фәрхиназ. Каһәрман абый!.. (*Барып муенына сарыла*.)
Каһәрман. Фәрхиназ!..
Тимерша. Мөстәкыйм кая?
Фәрхиназ. Әнә ул, карагыз...
Тимерша. Кем үтерде?
Фәрхиназ. Мин...
Каһәрман. Ашыккансың, Фәрхиназ, мин аны башка җәза белән бетермәкче идем.

Айдар белән, күсәк тотып, Җиһанша керә.

Җиһанша. Каһәрман, күрше авыллар — мәңгәрләр килделәр.
Айдар. Әйдә, улым, Каһәрман, халыкка баш бул, синең белән без утка да, суга да керергә риза.
Каһәрман *(тәрәзәне ачып, урамда җыелган халыкка кычкыра)*. Бөтен авылны уятыгыз, волостька китәбез!
Фәрхиназ. Каһәрман абый, Айдар бабай, Тимерша абый, үзегез белән мине дә алыгыз.
Каһәрман. Әйдә, Фәрхиназ, ни булса да бергә күрербез!..
Пәрдә.

## КЫЮ КЫЗЛАР

*Дүрт пәрдәле комедия*

(«Җиде кыз» исемле халык әкиятеннән файдаланып язылды.)

КАТНАШАЛАР:

Шәйхезаман — мөдәррис.
Җомабикә — аның хатыны.
Зөлкагыйдә
Зөлсәгыйдә
Зөлхәмидә
Байтирәк — аларның хезмәтчесе.
Миртимер — аңлы шәкерт.
Исәнбай — башкорт шәкерте.
Бибкәйнур
Миләүшә
Гайшә
Хаҗия — остазбикә.
Гыйлемдар — аның улы.
Әбелкарип — хәлфә.
Ризван — казый.
Әмирхан — карый.

Шәмгун — мәзин.
Тутакай — фәхешханә тотучы.
Сафура — авыл карчыгы.
Бәхтияр — мөнәҗәтче, бәетче.
Байморат — байгура.
Аксак Вәли
Фазлый
Моратай
Дәүләт
Нигъмәт
Әскали

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Хаҗия өе. Шәһәрчә җиһазланган бүлмә. Сулда, уңда һәм арткы планда ишекләр.
Пәрдә ачылганда Бибкәй, җырлый-җырлый, җиз поднос агарта.

Бибкәй. Авылкаем, матуркаем,
Сагынам сине көн саен.
Туган авылым, бәгырькәем,
Күңел синдә, һәр даим.

Хаҗия керә.

Хаҗия. Балам Бибкәйнур, безнең йортта җырламаска дип ничә тапкыр әйтелгән сиңа...
Бибкәй. Гаеп итмә инде, абыстай, эчем пошканлыктан онытып җырлап җибәрдем.
Хаҗия. Эчең пошса, Аллага гыйбадәт кыл. Белгән догаларыңны укы. Җыр булган йорттан бәрәкәт очар, җыр белән мавыккан кешене кайгы-хәсрәт кочар, ди китап. Авылдан килгән кыргый гадәтләреңне ташларга вакыт, балам. (*Комган алып китә.*)
Бибкәй. Нишлим инде... Көләргә ярамый, җырларга кушмыйлар.

Сафура керә.

Сафура. Саумы, кызым Бибкәйнур!
Бибкәй. Сафура әби, бу синме?.. (*Барып кочаклый.*)
Сафура. Чү-чү, кызым, кысып үтерәсең. Сөбханалла, машалла, шәһәр икмәге килешкән үзеңә. Кара, нинди матурланып, көрәеп киткәнсең.
Бибкәй. Сөйлә, әби, авылданиләр бар?
Сафура. Шатланырлык хәбәрләр юк, кызым. Беләсең, авылда ачлык... Хәллерәк кешеләр терлекләрен суеп ашыйлар. Хәлсезләре, йорт-җирләрен сатып, читкә китәләр. Халык арасында тир хастасы, зәңгелә авыруы...
Бибкәй. Сине күргәч, авылга кайтам икән дип шатланган идем.
Сафура. Юк, кызым, телеңә дә аласы булма. Синең кебек ятим кыз бала түгел, сызгырып торган ирләр дә ачтан интегә. Әле менә минем белән дә ике кыз бала, берәр урын таба алмабызмы дип, калага килделәр.
Бибкәй. Безнең авылданмы? Кемнәр алар?..
Сафура. Күрше авылдан. Ата-аналары вабадан үлгән. Авылга кайту турында, кызым, уйлап та карама.

Хаҗия керә.

Хаҗия. Кунак бар икән.
Сафура. Саумы, Хаҗия?
Хаҗия. Бибкәйнур, өйалдыңа боз каткан, таеп егыла яздым.
Бибкәй. Хәзер, абыстай, кайнар сулап юармын. (*Китә.*)
Хаҗия. Бик озакладың, карчыгым.
Сафура. Дөнья бит, Хаҗия. Нужасы җибәрми.
Хаҗия. Малларың бармы?
Сафура. Бер кашык су белән йотарлык ике гөнҗәлә китердем. Бәхетең бар икән. Берсеннән-берсе матурлар, берсеннән-берсе чибәрләр. Үзләре тагы — укыганнар, галимнәр. Җил-яңгыр да күрми үскән юкә яфрагы төсле сафлар, нәфисләр...
Хаҗия. Ярый, товарыңны күрсәткәч мактарсың.
Сафура. Юк, Хаҗия, алларында да мактармын, артларында да мактыйм. Мондый асыл кошлар гомеремдә беренче кат килеп каптылар. Тик, зинһар өчен, Хаҗия, бәяләре турында рәнҗетмәссең инде.
Хаҗия. Кешегә ошарлык төс-битләре булса, иншалла, хакларыннан тормабыз. Үзләре кая соң?
Сафура. Җиһанша дворында калдырдым.
Хаҗия. Җыен юлбасар оясы җир бит ул. Бар тизрәк, монда алып кил!
Сафура. Бәяләрен күпме куярсың икән?

Хаҗия. Килгәч сөйләшербез. Бар, җәһәт бул!
Сафура. Ярый алайса, мин хәзер килеп җитәрмен. (*Китә.*)
Хаҗия. Йа Ходай, без гасый бәндәләреңне рәхмәтеңнән ташлама.

Гыйлемдарны җитәкләп, Бибкәй керә.

Балам, ни булды сиңа?
Гыйлемдар. Чирләдем, әнәү...
Хаҗия (*Бибкәйгә*). Тизрәк чишендер. Әйдә балам, әйдә, менә монда түргә ят.
Гыйлемдар. Уф, үләм, әнәү, бәхил бул...
Хаҗия. Кай җиреӊ сырхый, балам?
Гыйлемдар. Йөрәгем сикерә, башым чатный, әнәү... Ишан хәзрәткә күренгән идем, ганкәбүт, ди.
Хаҗия. Ганкәбүт?! Гаҗәп, беренче кат ишетүем.
Гыйлемдар. Күп укудан шәкертләрдә була торган ми зәхмәте икән. Уф Алла!..
Хаҗия. Тукта, балам, авызыңнан ниндидер ят ис килә.
Гыйлемдар. Юлда кайтканда, әрнеп сызлавыма тәкатем калмагач, ямщигым урыс авылындагы больницага керткән иде. Шунда доктор дару эчерде.
Хаҗия. Юк, балам, бу дару түгел, аракы исе бу.
Гыйлемдар. Их, әнәү, наданлыгыңа барасың. Даруның һәммәсен дә аракыдан ясыйлар ич. Ярый әле шифасы тиде. Югыйсә юлда үлеп калу ихтималым да бар иде. Йа Алла, анам Газизәм белән күрешерлек гомер бирүең өчен мең-мең шөкерләр булсын сиңа. Мин хәзер бәхетле, мин бәшарәтле хәзер, үз анам янында, үз түшәгемдә җан тәслим итәм.
Хаҗия. Балам, синең телең көрмәкләнә башлады, иманыңны тәлкыйн ит.
Гыйлемдар. Әнәү, минем йоклыйсым килә.
Хаҗия. Әйдә теге якка, анда салкынча, рәхәтләнеп йокларсың.

Китәләр. Бераздан Бибкәй керә.

Бибкәй. Үзе, авырыйм, ди, үзенең бите чөгендер кебек. Кайтты инде, тагы миңа бәйләнер. (*Китә.*)

Хаҗия чыга.

Хаҗия. Йа Алла!.. Исмәгыйльне — пычактан, Йосыфны көнчелектән коткарырга кодрәтеңнән килгән кебек, без гасый бәндәләреңне дә шәфкатеңнән ташлама. Дөньялыкта тәрбиячем, ахирәттә догачым булган бердәнбер баламның авыруын җиңеләйт...

Сафура, Миләүшә, Гайшә керәләр.

Сафура. Әйдәгез, кызларым, тартынмагыз, Хаҗия абыстагыз менә шушы инде.
Хаҗия. Исәнмесез, кызларым, шәлләрегезне чишегез, бишмәтләрегезне салыгыз.

Кызлар чишенәләр.

Менә шулай. Син ни атлы, матуркай?
Миләүшә. Биби Миләүшә.
Хаҗия. Ә син, каракай?
Гайшә. Биби Гайшә.
Хаҗия. Бик яхшы. Сөйкемле балаларга охшыйсыз. Балам, Бибкәйнур!

Бибкәй керә.

Кунакларны теге якка алып чык. Ул мескеннәр туңганнар, күшеккәннәр, чәй белән сыйларсың.
Бибкәй. Әйдәгез, кызлар...

Китәләр.

Сафура. Йә, ничек, Хаҗия, ошадымы?
Хаҗия. Күпме сорыйсың?
Сафура. Унар талир, берәр кашемир күлмәк, бер пар читек-кәвеш бирерсең.
Хаҗия. Нәрсә син, әллә акылдан яздыңмы?!
Сафура. Юк, Хаҗия, бер дә язмадым. Мондый кызлар өчен мин сораган бәя күп түгел. Болар кызлар түгел, хәзинә бит, Хаҗия.
Хаҗия. Мондый кытлык елны хәерче кызларын андый хакка кеше сатып аламы?
Сафура. Үлегенә карап мазары, товарына карап базары, дигән бабайлар. Боларны кайда куйсаң да ярарлык. Асрау итәсеңме, читкә сатып җибәрәсеңме, тәтәйләргә бирәсеңме, һәркайда да үз хакларын алырлар. Бая әйткән сүзләрең дөрес булып чыктылар. Дворга кайтып керсәм, ишегалдына тулган халык, тулган халык... Һәммәсе дә минем кызларымны күзлиләр. «Әби, бу матурларны кая илтәсең, кемгә китердең?» — диләр. Кайсы: «Миңа асраулыкка кеше кирәк иде», кайсы: «Хатын авырый, бала карарга кеше юк иде»,

кайбер шаянраклары: «Өйләнергә исәп бар иде», — дип, төрле яктан сырып алдылар. Берсенә дә эшнең чынын әйтмәдем. — «Үз кызларым, абыйлары янына Крестовниковка эшкә китердем»,— дидем. Шулай, Хаҗия, килешә алмыйбыз икән, акчагыз бакыр, килгән юлыбыз такыр, дибез дә, чыгабыз да китәбез.

Хаҗия. Ярый, алай кыланма. Икесенә ун талир, бер кашемир күлмәк бирермен.

Сафура. Юк, Хаҗия, үземә дә кыйбат торалар. Алар артыннан йөреп күпме аяк киеме туздырдым. Дөнья кадәр күчтәнәчләр биреп, җиңгәләрен тыгындырдым. Үзләренә паспорт алыр өчен түрәләргә өч баш үрдәк кундырдым. Барысыннан да бигрәк, Алла каршында языклы булып, үземне мәңге җәһәннәмлек гөнаһка чумдырдым.

Хаҗия. Син дә язык, гөнаһ турында сөйләгән буласың тагын.

Сафура. Сөйләрсең!.. Ярый ла сез укыган, дәүләтле кешеләр, хаҗга барырсыз, корбан чалырсыз да котылырсыз. Бөтен авырлык минем җилкәдә калыр.

Хаҗия. Җитәр, телеңә салынма. Күпме бирим соң?

Сафура. Әйттем бит инде. Унар талир, берәр кашемир күлмәк, бер пар читек-кәвеш.

Хаҗия. Ул хакка алмыйм.

Сафура. Алмасаң, хәерле булсын. Кызым Биби Миләүшә, балам Биби Гайшә...

Бүлмәдән Миләүшә белән Гайшә чыга.

Миләүшә. Нәрсә, әби?

Гайшә. Әллә китәбезме?

Хаҗия. Юк, балалар, сезгә түгел ул... Барыгыз, чәегезне эчегез... (*Аркаларыннан кагып.*) Барыгыз, балаларым, барыгыз...

Кызлар китә.

Һе, зәнки карчык!.. Күргәнең-күрмәгәнең шул булсын...

Сафура. Юкка кырысланасың, Хаҗия!

Хаҗия. Кая, паспортларын бир!

Сафура. Бирәм, бирәм, анысы югалмас. Мә, хәерләрен күр.

Хаҗия. Син хәзер кызларга артык күренмә, тизрәк чыгып тай.

Сафура. Күлмәк белән читек-кәвеш кайчан соң?

Хаҗия. Аларын соңыннан алырсың. Әнә кеше килә, бар, табаныңны ялтырат...

Сафура китә. Тәсбих тартып, вәкарь белән Тутакай керә.

Тутакай. Исәнме, Хаҗия!

Хаҗия. Биргәнеңә мең шөкерләр булсын. Тутакай, әйдәгез, рәхим итегез.

Тутакай. Аллаһеммә әнзил вә мөнзилән... Эшегезгә хәрәкәт, малыгызга бәрәкәт бирсен, Хаҗия.

Хаҗия. Шулай булсын. Ләкин, Тутакай, Гыйлемдарымны, шәһәрдә күңел куеп укымаганга, быел Кышкар хәзрәт мәдрәсәсенә җибәргән идем. Укый алмаган, чирләп кайткан, сулкылдап ята балакай...

Тутакай. Ярый, Хаҗия, борчылма, иншалла, сихәтләнер. Син, Хаҗия, теге асравыңны миңа бир инде.

Хаҗия. Бирә алмыйм, Тутакай. Бик үткен нәрсә бит, сезгә игелек күрсәтмәс.

Тутакай. Зарар юк. Безнең кулга эләксә, беркая да китә алмас. Андыйларның телен бездә бик тиз табалар.

Хаҗия. Ай-һай, булыр микән. Бик сизгер, бик үткен кыз. Төркстаннан килгән сәүдәгәрләргә сатып җибәрергә теләдем, сизенеп бармады. Итче Хөснуллага өченче хатынлыкка бирергә уйладым, риза булмады. Аннан соң үзем дә бик яратам, эшкә бик уңган, кулыннан килмәгән эше юк. Үзегез беләсез, барыбер кешесез торып булмый, кемне булса да тотарга кирәк.

Тутакай. Кара эшкә башкасын да табарсың, бу минем өчен кулайлы, быел Минзәлә ярминкәсенә барырга җыенам, беләсең, безнең эштә төсе-бите, буе-сыны матур булу шарт.

Хаҗия. Борчылма, Тутакай, мин сиңа аннан да яхшыракларын хәзерләп куйдым. Кызым Миләүшә, кызым Гайшә!..

Миләүшә белән Гайшә керә.

Менә, матуркайларым, таныш булыгыз, сезнең эшкә барачак абыстагыз шушы инде. Күрешегез үзе белән, күрешегез.

Тутакай. Ата-аналарыгыз бармы, кызларым?

Миләүшә. Юк, абыстай, икебез дә ятимнәр.

Гайшә. Быел җәй икесе дә бер көнне вабадан үлде.

Тутакай. Кызганыч... Нишләмәк кирәк, Ходайның тәкъдире шулай булгандыр. Тәүфыйклы, әдәпле балалар күренәсез. (*Миләүшәгә.*) Сиңа ничә яшь?

Миләүшә. Унсигез тулды.

Тутакай (*Гайшәгә*). Ә сиңа, матуркай?
Гайшә. Әллә тагы.
Тутакай. Барыгыз, кызларым, мин сезне бераздан кереп алырмын.
Миләүшә белән Гайшә китә.

Хаҗия. Йә, Тутакай, ни дисең?
Тутакай. Әйе, Хаҗия, кызларың чибәр. Миңа бик ошадылар. Күпме дисең?
Бибкәй керә.

Бибкәй. Абыстай, Туктамыш байларның хезмәтчесе ат җигеп килгән. Бүләк багарга сезне көтәләр, ди.
Хаҗия. Бар, әйт, хәзер чыга, диң.

Бибкәй китә.

Әйдә, Тутакай, көттермик.
Тутакай. Тукта инде, Хаҗия, кызларыңа күпме соравыңны әйтмәдең.
Хаҗия. Курыкма инде, мин сезне җәбер итмәм, иншалла, килешербез. Әйдә, юлда сөйләшербез.

Бибкәй керә.

Гыйлемдар уянса, чәй эчерерсең. Хәле начар булса, миңа хәбәр итәрсең.
Бибкәй. Ярый, абыстай.

Хаҗия, Тутакай һәм Бибкәй китәләр.
Бүлмәдән Миләүшә белән Гайшә керә.

Гайшә. Миләүшә түтәй, без нинди бәхетле.
Миләүшә. Әйтмә инде, акыллым, Аллага шөкер, без хәзер ачлык тырнагыннан котылдык. Хуҗаларыбыз да әйбәт кешеләр булсалар, эшләрбез дә ашарбыз. Киләсе елга икмәк уңса, авылга кайтырбыз.
Бибкәй керә.

Гайшә. Миңа хуҗабыз булачак абыстай бик ошады. Намаз-нияз иясе булырга кирәк. Тәсбихен тарта-тарта, башымнан сыйпап сөйде. Шатлыгымнан күңелем тулып елыйсым килде. Әнкәй мәрхүмне күз алдыма китереп бастырдым.
Бибкәй. Их сез, бичаралар... Бигрәк тә балаларча беркатлы кызлар икәнсез. Сез ул хатынның кем икәнен беләсезме соң?
Миләүшә. Әллә усал хатынмы?
Бибкәй. Ул кабахәтнең исемен телгә алырга да җирәнгеч...
Миләүшә. Әйт, түтәй, кем соң ул?
Бибкәй. Фәхешханә тотучы...
Гайшә. Миләүшә түтәй, нәрсә ул? (*Миләүшә колагына әйтә*). Ә...
Бибкәй. Сезне бит шуңа сатарга телиләр.
Миләүшә. Юк, юк, мин моңа ышанмыйм.
Гайшә. Шундый изге хатыннарның пычрак кеше булуларына мин дә ышанмыйм.
Бибкәй. Күзегез белән күргәч ышанырсыз, ләкин соң булыр. Бу йортта мин бер елдан бирле торам, сезнең кебек нарасый кызларны күз алдымнан бик күп үткәрдем. Аларның кайберләре Төркстан сахраларында канлы яшьләр түксәләр, кайберләре пычрак фәхешханәләрдә газап чигәләр.
Гайшә. Әйттем мин сиңа, килмик, дидем. (*Елый.*)
Миләүшә. Сафура әби кайда соң, аңа сөйләргә иде.
Бибкәй. Ул иблис карчыгын күрә алмассыз хәзер. Сезнең өчен уч тутырып акча алды да күптән тайды инде.
Гайшә. Миләүшә түтәй, нишлибез? Кире авылга кайтып китсәк, юл табарбыз микән?
Миләүшә. Юлны табар идек, акыллым, тик анда кайтып нишләрбез?
Бибкәй. Еламагыз, кызлар. Менә мине дә, сезнең кебек алдап, авылдан китерделәр. Мине дә сезнең кебек сатып җибәрергә теләделәр. Бармадым. Итче картка өченче хатынлыкка бирергә уйладылар, риза булмадым. Үзегез каты торсагыз, сезне дә бернәрсә эшләтә алмаслар. Әй, самавырым ташый торгандыр... (*Чыгып китә.*)
Миләүшә. Нишлибез, Гайшә?
Гайшә. Белмим, башым катты.

Бәхтияр керә.

Бәхтияр. Әссәламегаләйкем...
Миләүшә. Юкка, бабай, кергәнсең, мондый йортлар хәер бирмиләр.

Бәхтияр. Мин хәерче түгел бит, кызым. Мөнәҗәт укучы, бәетләр әйтүче булам.
Миләүшә. Шулаймыни?
Бәхтияр. Сез үзегез кемнәр соң? Утырмага килгән бай, мулла кызлары дисәм, өс-башларыгыз начар...
Миләүшә. Без бүген генә эш эзләп авылдан килдек.
Бәхтияр. Алай икән, төшендем, кызларым, төшендем... Хуҗаларыгыз өйдә юкмы әллә?
Миләүшә. Каядыр китте бугай. Асраулары теге якта.
Гайшә. Бабай, син кайсы авылныкы буласың?
Бәхтияр. Мин, кызым, еректан. Әгерҗебуби дигән җирне ишеткәнең бармы?
Гайшә. Юк, бабай.
Бәхтияр. Менә мин шул яктан.

Бибкәй керә.

Бибкәй. Бәхтияр бабай, бу син түгелме?
Бәхтияр. Әйе, кызым, мин булам. Йә, сөйлә, ничек торасың?
Бибкәй. Сорама инде, бабай, һаман искечә.
Бәхтияр. Теге вакытны әйттем мин сиңа, юкка сүзем тотмадың.
Бибкәй. Сөйләмә инде, бабай, хәзер үзем дә үкенеп бетә алмыйм.
Бәхтияр. Әле дә вакыт узмаган. Бераздан минем янга кер әле, сөйләшеп алырбыз. Ярый, балалар, сау булыгыз.
Миләүшә. Тукта инде, бабай, безгә дә берәр бәетеңне әйт.
Бәхтияр. Ошатырсыз микән соң?
Миләүшә. Ник ошатмыйк, бик ошатырбыз.
Бәхтияр. Ярый алайса, мин сезгә «Җиде кыз бәете»н әйтим.
Гайшә. Нинди җиде кыз?
Бәхтияр. Сабыр, әйткәч белерсең.

Җомга көнне без укыдык
Быел корбан гаетен.
Без әйтиек, сез тыңлагыз
Җиде кызның бәетен.
Борын заман бер авылда
Җиде зирәк кыз булган,
Җидесе дә бер авыздан
Гыйлем укырга булган.
Җидесе дә егет булып
Киенгәннәр берзаман,
Җидесе дә, чәчен кыркып,
Ир булганнар берзаман.
Җидесе дә, таңнан торып,
Илдән чыгып киткәннәр,
Бик күп кыенлыклар күреп,
Каргалыга җиткәннәр.
Каргалының шәкертләре
Җыелышып килгәннәр,
«Тавышлары нечкә» диеп,
Мыскыл итеп көлгәннәр.
Каргалының атларында
Тезген бавы мунчала,
Кызлыкларын белдергәннәр
Су илткәндә мунчага.
Бу хәбәрне ишеткәчтен,
Бар голяма җыйналган,
Беркая да чыгармаска
Каравыллар куелган.
Икенче көн хөкем ясап,
Рисвай галәм иткәннәр,
Битләренә корым сөртеп,
Урам буйлап йөрткәннәр.

Бибкәй. Җүләр кызлар булганнар. Мин булсам, билләһи, тоттырмас идем.
Миләүшә. Их, чыннан да менә шул кызлар кебек уңган, зирәк, кыю булсаң икән дә гыйлем укысаң икән...

Гайшә. Бик харап инде...
Бәхтияр. Буласыгыз киләме?
Миләүшә. Бик килә дә бит... безгә кая инде ул.
Бәхтияр. Теләгегез булса, юлын өйрәтәм.
Миләүшә. Ничек, бабай?
Бәхтияр. Менә шул бәеттәге кызлар кебек ирләр киеме киенәсез дә безнең авылдагы мәдрәсәгә барып укыйсыз.
Миләүшә. Алырлармы соң?
Бәхтияр. Үзем ярдәм итәрмен. Безнең якта ачлык та юк.
Бибкәй. Әйдәгез, кызлар, китәбез.
Гайшә. Кирәкми, куркыныч. Бәеттәге кебек адәм мәсхәрәсе итсәләр...
Бибкәй. Курыкма, иттермәскә тырышырбыз.

Гыйлемдар тавышы килә.

Бәхтияр. Ярый, балалар, сез киңәшә торыгыз, мин күршегездәге кунып чыгу йортында булырмын. Китәргә исәбегез булса, килеп әйтерсез.
Бибкәй. Ярый, бабай, әйтербез.
Бәхтияр. Хушыгыз, балалар.
Миләүшә. Хуш, бабай, хуш!

Бәхтияр китә.

Бибкәй. Китик, кызлар. Күрәсез, хатын-кыз булганыбыз өчен бездән көләләр. Сарык бәрәне урынына хисаплап, безнең белән сату итеп, тамак туйдыралар. Үзебез яратмаган кешегә өченче-дүртенче хатынлыкка биреп, гөлҗимеш чәчәгедәй матур яшьлегебезне кан-яшь белән юдыралар. Минем монда шәһәргә килүем белем алу, дөнья күрү теләге белән иде. Бу бабайның фикере күптән инде минем йөрәгемне җилкетеп, күңелемә мәңге сүнмәс утлар яндырган иде. Китик, кызлар, безгә бит барыбер: ата-аналарыбыз юк, безнең өчен кайгыручы кеше дә булмас. Остабикәләрнең, бай хатыннарының типкесендә яшәгәнче, ичмасам, гыйлем укый алмабызмы?!
Гайшә. Ашарга-эчәргә кайдан алырбыз?
Бибкәй. Илдә чыпчык үлми, дигән бабайлар. Табарбыз. Мин мәдрәсә тормышы белән таныш, самавырчы малай булырбыз, кизүлеккә ялланырбыз.
Гайшә. Юк, юк, мин китмим, авылга кайтам.
Миләүшә. Ярый, син теләсәң нишлә, мин китәм.
Бибкәй. Менә рәхмәт, әйдә теге бабайны күрергә чыгабыз.

Китә башлыйлар.

Гайшә. Туктагыз, мин дә сезнең белән...

Гыйлемдар тавышы килә.

Гыйлемдар. Бибкәйнур! Бибкәйнур, дим!..
Бибкәй. Теге бирән уянды. Сез барыгыз, бабай белән сөйләшә торыгыз.

Кызлар китәләр, Гыйлемдар керә.

Гыйлемдар. Бибкәйнур, әнәү кайда?
Бибкәй. Туктамыш байларда кунакта.
Гыйлемдар. Яхшы. Димәк, син ялгыз?
Бибкәй. Әйе, ялгыз. Нигә?
Гыйлемдар. Болай гына. Хи-хи-хи...
Бибкәй. Бу нишләвең, өметсез?
Гыйлемдар. Бибкәй, күз нурым, сагынып кайттым, былбылым.
Бибкәй. Гыйлемдар абый, зинһар өчен, миңа бәйләнмә.
Гыйлемдар. Мин сиңа гашыйк, Бибкәйнур. Синең гыйшкың уты белән яну аркасында укуга да күңел бирә алмадым, ахрысында, башымны диванага салып, кайтырга мәҗбүр булдым.
Бибкәй. Йөрмә миңа тагылып, мин сине сөю түгел, күрәсем дә килми.
Гыйлемдар. Мин сине мәҗбүр итәрмен!
Бибкәй. Каравыл, ярдәм итегез!..
Гыйлемдар. Кычкырма, мәлгунә...

Бүлмәгә таба өстери башлый, Хаҗия керә.

Хаҗия. Бу нишләвегез?! Җибәр, Гыйлемдар!..
Гыйлемдар. Әнәү, ул миңа ашарга-эчәргә бирми. Ул минем кушканымны тыңламый.
Бибкәй. Абыстай, ул оятсыз, тирес бит...
Хаҗия. Кычкырма, явыз! Югал күземнән!.. (*Тибеп, ишектән озата.*) Бу нинди эш?
Гыйлемдар. Әнәү, валлаһи, таллаһи, минем гаебем юк.
Хаҗия. Җитәр! Ичмасам, күзем белән күргән нәрсәләрне генә миннән танымасаң иде. Нишлим мин синең белән, нишлим?.. (*Елый.*)
Гыйлемдар. Әнәү, бәгърем...
Хаҗия. Мин бит синең өчен тормышымны корбан итеп, барлык кешелек намусымнан ваз кичтем. Мин бит синең өчен Алла каршында коточкыч гөнаһлар эшләп, башка берәүләрнең күз яшьләре белән киләчәк тормышыңны тәэмин итәргә тырышам. Шулар бәрабәренә син минем ышанычымны аяк астына салып таптыйсың. Мине санга сукмыйсың икән, ичмасам, мәхәллә халкының ышанычын җуймаска иде. Бөтен мәхәллә халкы атаң хөрмәтенә сине үзләренә имам итү теләге белән мәдрәсә тәмам иткәнеңне дүрт күз белән көтә. Ә син... Күл буе мәдрәсәсенә бирдем — укымадың. Шиһап хәзрәткә салдым — яратмадың. Бистә хәзрәтенә бирдем — аракы эчеп, рисвай галәм булдың. Зәңгәр мәчет мәдрәсәсенә бирдем — карт марҗа итәгенә тагылып, әлгаязы билләһи, динеңнән дөнә яздың... Инде быел, күп расходлар тотып, Кышкар хәзрәтенә җибәрдем. Инде анда да укымыйча кире кайткансың, кайткансың да үз асравыңа кул салу кебек түбәнлеккә барып җиткәнсең. Бу эшеңне мәхәллә халкы белсә, ни дип җавап бирербез?
Гыйлемдар. Әнәү, кичер, ярлыка мине. Моннан соң берсен дә эшләмәм. Валлаһи, таллаһи, ахыргысы булыр.
Хаҗия. Ант итмә, андый тукран тәүбәләреңне бик күп ишеттем инде.
Гыйлемдар. Ышан, әнәү, Коръән үбеп ант итәм, моннан соң...
Хаҗия. Тукта, теге кызлар кая?
Гыйлемдар. Нинди кызлар?
Хаҗия. Авылдан килгән ике кыз бар иде.
Гыйлемдар. Белмим, әнәү.
Хаҗия. Әллә аларны да куып чыгардыңмы?
Гыйлемдар. Юк, әнәү, минем беркемне дә күргәнем юк.

Тутакай керә.

Тутакай. Хаҗия, мин кызларымны алырга кергән идем.
Хаҗия. Тутакаем, алар әллә кая киткәннәр.
Тутакай. Ничек әллә кая киткәннәр?..
Хаҗия. Кайтып керсәм — юклар. Үзем дә шул турыда Гыйлемдардан сорашып тора идем.
Тутакай. Ярый, юха җылан булып кыланма. Күбрәк бирүчегә саткансыңдыр әле.

Бибкәй, Миләүшә, Гайшә керә.

Әнә бит алар.
Хаҗия. Нигә алай әйтми-нитми чыгып йөрисез? Бу бит авыл түгел, кызларым.
Тутакай. Әйдәгез, балакайларым, мин сезне алырга килдем.
Миләүшә. Рәхмәт, абыстай, без сиңа бармабыз инде.
Гайшә. Безнең паспортларыбызны бирегез.
Тутакай. Паспортларыгызны?
Хаҗия. Кая барасыз?
Гайшә. Анысы сезнең эш түгел.
Хаҗия. Туктагыз, балалар, сезгә ни булды?
Миләүшә. Бернәрсә дә булганы юк. Безнең паспортларыбызны бирегез.
Хаҗия. Юк, балалар, мин сезне җибәрмим, сезнең кебек ятим балаларга ярдәм итү минем изге бурычым.
Бибкәй. Ярый, абыстай, Аллаяр суфи булып кыланма! Яхшы чакта безне тотмагыз.
Хаҗия. Әллә син дә алар беләнме?
Бибкәй. Әйе, мин дә алар белән китәргә булдым.
Хаҗия. Тамагың туйдымыни, хәерче!.. Син минем колым, мин сине беркая да җибәрмим.
Бибкәй. Яхшылыкта җибәрмәсәң, мин синең бөтен кабахәт серләреңне халык алдында ачармын.
Хаҗия. Алла шаһит, кешеләрдән яшерен бер серем дә юк минем.
Бибкәй. Ух оятсыз, олтан бит!.. Күпме яшь кызларны минем күз алдымда башка илләргә сатып җибәрдең. Күпме ятим балаларны...
Хаҗия. Җитәр! Мә паспортыңны, мәгез, кадалыгыз, мәгез, чәнчелегез!.. Ашаткан ашларым, иткән яхшылыкларым тотсын, мәхшәр көннәрендә кулым якагызда булсын!..
Бибкәй. Каргышың казык башына!..

Кызлар китәләр.

Тутакай. Кая, Хаҗия, акчамны бир дә, мин дә китим.
Хаҗия. Нинди акча?
Тутакай. Теге кызлар өчен бая алган идең бит.
Хаҗия. Әнә бар, үзләреннән сора.
Тутакай. Ни өчен алардан? Мин сиңа бирдем, синнән алырга тиеш.
Хаҗия. Әйдә бар, дога кылырмын, хәрәм малыңнан садака булыр.
Тутакай. Бирдем ди, бирми ни синең ише эт корсагына садака! Кая, чыгар тизрәк! (*Барып ябыша.*)
Хаҗия. Нәҗес кулларың белән тотма киемнән, пычрагың буяла.
Тутакай. Бирәсеңме-юкмы, зинахур?
Хаҗия. И әҗәтханә!.. Җыйган малың, ашаган ашың, кигән киемнәрең бар да зина бит. Ичмасам, каршымда торма, кит! Сулышыңнан зина исе килә.
Тутакай. Үзеңне бел, уйнашчы! Хаҗи абзый өстеннән унлап сөяркә тоттың. Хаҗи абзый хаҗда чакта җиде корсак төшердең, синең бит тиле-миле улың да уйнаштан туган.
Хаҗия. Чыгасыңмы, юкмы, җәһәннәм кисәве!.. (*Барып кисәү агачы ала.*)
Тутакай. Мин барыбер синдә хакымны калдырмам.
Хаҗия. Бар, бар, зина капчыгы!
Тутакай. Җикеренмә, мировойга биреп җаның алырмын!

Талаша-талаша чыгалар.

!Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шәйхезаман Мөдәррис өе. Хор белән кызлар сабак укыйлар.

Шәрифҗамал. Кызлар, абыстай килә...

Төзәтенеп, аягүрә басалар. Ишеккә карап, тәгъзим белән башларын иеп торалар.
Җомабикә, Зөлкагыйдә, Зөлсәгыйдә, Зөлхәмидә керә.

Җомабикә. Сабакларыгызны белдегезме?
Барысы. Белдек, абыстай, белдек.
Җомабикә. Садакаларыгызны китерегез, дога кылыйк.

Кызлар садака бирергә хәзерләнәләр.

Шәрифҗамал. Менә, абыстай, әни ярты каз җибәргән иде, солдатка киткән абый өлеше. «Озак кына дога кылып алсын», — диде.
Җомабикә. Аллаһеммә... (*Дога кыла.*) Дөнья-ахирәт байлыгы бирсен.
Гайникамал. Бездән, абыстай, бер табак борчак оны.
Җомабикә. Әниеңә әйт, моннан соң борчак оны җибәрмәсен. Борай оны, яисә акча алып кил, сез бит әүкатле кешеләр. Ару әйбернең, бигрәк тә акчаның савабы күп була, ди китап.
Вазифа. Бездән, абыстай, ун тиенлек көмеш тәңкә.
Җомабикә. Ай рәхмәт. Аллаһе Тәгалә вә тәбарәкә хәзрәтләре бетмәс-төкәнмәс дәүләтләр белән баетсын. Мәшәехләр, әүлиялар хөрмәтенә гаип хәзинәләрен насыйп итсен. Дөнья-ахирәт тынычлык биреп, җиде җәннәт ишекләрен ачып куйсын. Әниең саумы? Нигә бер дә күренми?
Вазифа. Тугыз ягында кунакта иделәр, кичә генә кайттылар.
Җомабикә. «Абыстай сәлам әйтте» диң, килеп утырсын.
Вазифа. Ярый, абыстай.
Җомабикә. Бар. Урыныңа утыр. (*Кызларга.*) Садакаларыгызны биреп бетердегезме?
Гайникамал. Бетте бугай, абыстай.
Җомабикә. Мәгъсүмә, син нишләп анда посып торасың?
Мәгъсүмә. Хәер акчамны югалттым.
Җомабикә. Ничек югалттың?
Мәгъсүмә. Авызыма кабып килә идем — йотып җибәрдем.
Җомабикә. Син дә мине алдарга уйлыйсыңмы? Кая, букчаңны бир әле. (*Тенти.*) Бу нинди хат?
Мәгъсүмә. Хат түгел, абыстай, Исме Әгъзам догасын күчереп язган идем.
Җомабикә. Ә нигә бисмилласы юк? Зөлсәгыйдә, укып бир әле.
Зөлсәгыйдә (*укый*). Әлхатте нисфөлмөләкат, син җаныйга сагынып яздым сәлам хат...
Җомабикә. Егетләргә хат яздың?
Мәгъсүмә. Юк, абыстай, язмадым. Су юлыннан тапкан идем.
Җомабикә. Куй кулыңны!..

Мәгъсүмә ике кулын өстәл өстенә куя.

Менә монысы алдавың өчен. (*Кыйный.*) Менә монысы кулыңа каләм тотып хат язуың өчен. Менә монысы бозыклык белән шөгыльләнүең өчен. Елама, нигә елыйсың?

Мәгъсүмә. Авырта ич...

Җомабикә. Авыртса, икенче тапкыр егетләргә хат язмассың. Бар, утыр. Килегез, сабакларыгызны тыңлатыгыз.

Гайникамал. Әгузе билләһи минәшшәйтанир-раҗыйм, бисмилләһиррахманирахим. Кәбсен кәләмәсени кәлимим сүннә кәлимәтен өтертен кәлимәтен, тысынтая таштитасыни таебәтен өтертен таебәтен...

Җомабикә. Рәхмәт. Киләсе сабакка менә шушы ике сүзне тыңлатырсың. Бар, утыр.

Вазифа килә.

Вазифа. Кемгә килер алдындин, кемгә килер артындин. (*Туктап кала.*)

Җомабикә. Йә, йә, ник туктадың? Каушама.

Вазифа. Оныттым... (*Елап җибәрә.*)

Җомабикә. Ярый, елама, исеңә төшкәч килеп тыңлатырсың, бар, утыр.

Фәхерниса килә.

Фәхерниса. Күзне бирде күргәле,
Гакыл бирде белгәле,
Хак ядыны әйтергә
Телне бирде тидия.

Тешне бирде тешләргә,
Борын бирде иснәргә,
Колак бирде тыңларга
Һәр тишектән тидия.

Җомабикә. Ничек, ничек дисең?

Фәхерниса. Колак бирде тыңларга
Һәр тишектән тидия.

Җомабикә. Беттеме?

Фәхерниса. Юк әле.
Кулны бирде тотарга,
Тамак бирде йотарга,
Аяк бирде атларга
Туды-сюды тидия.

Җомабикә. Бу шайтан такмагын кайдан өйрәндең?

Фәхерниса. Миртимер абыйдан.

Җомабикә. Динсез дәһри! Мин ул алласызны хәзрәткә әйтеп пешертим әле. Ә сиңа, дин сабагын бозуың өчен, борчак җәзасы бирәм.

Зөлхәмидә. Әнкәй, туйга алырга килгәннәр.

Җомабикә. Хәзер чыгам, кызым. Барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз, ата-аналарыгызга, абыстай туйга китте, диярсез.

Кызлар тора башлый.

Туктагыз, Байтирәк, утарда сыер тизәкләре күбәйгән, дигән иде, барыгыз, абзарларны тазартыгыз.

Кызлар китәләр.

Менә нәрсә, кызларым, сезгә шуны әйтеп калдырам, мин югында кеше килсә, зинһар өчен, сөйләшмәгез.

Зөлхәмидә. Тукта әле, әни, нигә син безне кеше белән сөйләүдән тыясың, әллә без баламы?

Җомабикә. Баладан да болайрак. Ничә мәртәбә әйттем, сүземне тыңламыйсыз. Беркөнне мин ашта чакта көмеш әйберләр саткан булып бер хатын кергән идеме? Менә шул хатын сезне күзләргә килгән булган.

Зөлхәмидә. Безне күзләргә? Кемгә?

Җомабикә. Мукшур хәзрәтенең улына.

Зөлхәмидә. Ах!..

Зөлсәгыйдә. Соң?..

Җомабикә. Аның алдында бөтен гаепләрегезне ачкансыз да салгансыз. «Муллагызның кызлары берсе саңгырау, икенчесе сакау, өченчесе тыңкыш танау икән»,— дип киткән, ди.

Зөлсәгыйдә. Кайдан ишеттең?

Җомабикә. Авыл башындагы Хуҗакайга кереп чәй эчкән, шунда сөйләгән. Менә шул: мин югында нинди генә кеше керсә дә — сатучымы, хәерчеме — берсе белән дә сөйләшмәгез.

Зөлсәгыйдә. Ярый, әнкәй, ярый, сөйләшмәбез.
Җомабикә. Ярый, мин киттем. Атагызның тамагы көеп кайтыр, самавыр куеп торыгыз.

Китә. Зөлкагыйдә озата чыга. Зөлсәгыйдә кершән ягынырга керешә.

Зөлхәмидә. Апа, миңа фал ачыйк әле.
Зөлсәгыйдә. Күрәсең ич, бушамыйм.
Зөлхәмидә. Бик харап инде, кершән яга, имеш. Ачыйк инде.
Зөлсәгыйдә. Йөдәтмә, әнә чәчеңне тара.
Зөлхәмидә. Әем лә, ачыйк инде.
Зөлсәгыйдә. Фу, билләһи, сыткый сагыз, тигәнәк.

Китә. Зөлкагыйдә керә.

Зөлхәмидә. Апа, хәзер миңа фал ачасың.
Зөлкагыйдә. Нәрсә, качасың, дисеңме?
Зөлхәмидә. Юк, фал ачасың, дим.
Зөлкагыйдә. Минем эшем бар, акыллым, әтигә самавыр куям.
Зөлхәмидә. Ачыйк инде, аннары куярсың.
Зөлкагыйдә. Синең шул булыр инде. Бернәрсә исеңә төшсә, тынгы бирмәссең. Кая, фалнамәңне бир.
Зөлхәмидә. Беркөнге кебек начар булмасын.
Зөлкагыйдә. Бәхетеңә нәрсә чыгар бит. Тыңла, Җагфар Садыйк боерыр ки, и фал иясе, бу фал сиңа килепдер, каму хаҗәтең рава булачак. Вә дәхи бер кеше илә дуслык итәсең. Хак Тәгалә сиңа бер угыл бирә, иншалла, морадыңа ирешәчәксең.
Зөлхәмидә. Апа, минем шулай бер генә балам буламы?
Зөлкагыйдә. Ә?
Зөлхәмидә. Минем бер генә балам буламы, дим.
Зөлкагыйдә. Юк, бик күп була.
Зөлхәмидә. Ә нигә соң китапта, бер генә була, дигән?
Зөлкагыйдә. Ул бит, беренче тапкырында гына бер була, дигән.
Зөлхәмидә. Калганнарында игезәк буламы?
Зөлкагыйдә. Белмим инде, белмим, юк-бар белән башымны катырма. (*Китә.*)
Зөлхәмидә. Апа, дим... (*Тыпырчынып елый.*)
Зөлсәгыйдә керә, көзге каршысына килеп, җырлап сөрмә тарта.

Зөлсәгыйдә. Кани Ләйлә, кани Мәҗнүн,
Кани Йосыф Зөләйхасы,
Кани Фәрһат, кани Ширин,
Кани Таһир Зөһрәсе.
Зөлхәмидә. Апа, миңа да сөрмә тарт әле.
Зөлсәгыйдә. Матап йөрмә, әнә балагыңны тык.
Зөлхәмидә. Ярар, анысын синнән сорамыйлар.
Зөлсәгыйдә. Сорамасаң, мине борчыма.
Зөлхәмидә. Борчыйм. (*Төртә.*)
Зөлсәгыйдә. Төртмә, сөрмәмне бозасың.
Зөлхәмидә. Миңа тартасыңмы?
Зөлсәгыйдә. Тартмыйм!
Зөлхәмидә. Тартмасаң, ирек бирмим. (*Төртә.*)
Зөлсәгыйдә. Тимә инде, гөлкәем, син акыллы бит.
Зөлхәмидә. Юмалама, салам кыстырма, тарт миңа.
Зөлсәгыйдә. Бераз көт, аннан сиңа тартырмын.
Зөлхәмидә. Юк, башта миңа тарт. (*Төртә.*)
Зөлсәгыйдә. Алла, Алла, бәбәгемне чыгардың. Менә сиңа, менә, мунча пәрие.

Сугышалар. Шәйхезаман керә.

Шәйхезаман. Ни буләсез, нинди тавыш бу?
Зөлсәгыйдә. Әткәй, менә бу өрәгең күземә төртте.
Зөлхәмидә. Ә ул минем беләгемне чеметте.
Шәйхезаман. Бәрәкалла, дуңгызлар, барыгыз моннан! (*Куып чыгара.*) Бу нинди тыйнаксыз балалар булды соң? Ялгыз калдылармы, талашырга керешәләр. Ичмасам, кияүләре дә килмиләр, өчесен берьюлы тотып бирер идем, әрәмтамаклар!

Байморат керә.

Байморат. Әссәламегаләйкем.

Шәйхезаман. Вәгаләйкемәссәлам, Байморат. Әйдә, теге якка узыйк.

Байморат. Узып тормыйм, хәзрәт, син беркөнне, ярминкәгә бергә барырбыз, дигән идең. Без бүген Солтангәрәй байлар белән юлга чыгарга ниятләп торабыз.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, иртәрәк түгелме соң?

Байморат. Ярминкәнең кызыгы баштагы көннәрдә була. Җыен шантрапа халык килеп тулгач, яхшы фатир да булмый. Алданрак барсаң, җан теләгән товарны да сайлап аласың. Аннан син, сатасы корбан тиреләрем дә бар, дигән идең.

Шәйхезаман. Анысы шулай, ләкин мин бер-ике көн сабыр итмәкче идем.

Байморат. Хәерле булсын, үзең әйткәнгә генә кергән идем. Сиңа насыйп түгел, күрәсең. Быел бик шәп тәтәйләр булачак икән.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, каян белдең?

Байморат. Солтангәрәй бүген өяздән кайтты. «Быел Тутакай дигән мөселман хатыны тотачак»,— ди. Шул кичә, егерме олауга кызлар, музыкантлар төяп, безнең өяз каласыннан үтеп киткән. Ул кызлары да, кызлары, ди, хәзрәт. Бер кашык су белән йотарлык, ди. Тыныч чакта, мужик халкы килгәләгәнче, аларның хәлләрен белеп чыгар идек.

Шәйхезаман. Анысын инде алдан ук әйтеп булмый, мулла Байморат, ләүхелмәхфуздә ни язылган булса, шуны күрербез.

Байморат. Үткән ел кафирәләргә дә күпме акча туздырдык. Болар бар да мөслимәләр икән. Араларында оҗмах хуры кебекләре бар, ди.

Шәйхезаман. Тәүбә әстәгъфирулла диген, мулла Байморат. Оҗмах хурлары белән тиңләштерүең урынсыз. Алайса безгә дә барырга мәслихәт, дисең?

Байморат. Шулай дим, хәзрәт.

Шәйхезаман. Ләкин мин бит әзерләнмәгән, корбан тиреләрем дә каралмаган.

Байморат. Нәрсәсен карыйсың? Хезмәтчең Байтирәккә кушсаң, бер сәгать эчендә барысы да әзер булыр. Аннан соң, хәзрәт, ул Байтирәгеңне алып йөрмә, бик очлы күзле нәрсә бит, барны-юкны күрүчән.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, мулла Байморат, бик дөрес әйтәсең.

Байморат. Тиреләреңне бер чанага төят тә минем хезмәтчемә бирерсең, үзең минем янга да сыярсың. Нәрсәгә ике хезмәтче туйдырып йөрергә. Аннан, хәзрәт, менә бу хатны укы әле.

Шәйхезаман (*укып*). Сөбханалла, машалла, кайдан алдың?

Байморат. Өченче көн иртән базарга бара идем, мәчет алдында башкорт шәкерте Исәнбай тора. «Байморат абзый, зинһар өчен, менә шул хатны пуштага салмассыңмы»,— ди. «Ярый, — мин әйтәм, — ярый, салырмын»,— дим. Хатны алдым да базарга киттем. Юлда барганда, күңел нәрсәдер сизә. Йөрәгем пылт-пылт итеп тибә бит. «Бу хатта ни дә булса булырга кирәк», — дим. Ачып укыгач, чыннан да шулай булып чыкты. Күрәсең, ниләр язган.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, рәхмәт сиңа, мин ул сасыкларны чакыртып пешерим әле.

Байморат. Шулай ит, хәзрәт, син аны үзебезчә, мөселманчалап... Ярый, мин кайтып җыена башлыйм.

Шәйхезаман. Ярый, бар, мин дә сәфәр хәстәрен күрәм.

Байморат китә.

Байтирәк, Байтирәк!

Байтирәк (*арттан*). Әү, хәзрәт?

Шәйхезаман. Өйгә кер әле!.. (*Көйләп*.)

Айдыйн чырак йөзләреңне күрсәм,
Шөкри ләббендин бер генә сөрсәм,
Берничә көн хезмәтеңдә булсам,
Һәр нә бәлане үземгә алсам.

Байтирәк керә.

Байтирәк. Ни йомыш, хәзрәт?

Шәйхезаман. Без Минзәлә ярминкәсенә барырга булдык. Хәзер корбан тиреләрен збутлы чанага яхшылап төя, күк алашаны җигәрсең.

Байтирәк. Миңа да хәзерләнергәме?

Шәйхезаман. Бәрәкалла, анда сиңа ни калган?.. Өйдәге эшләреңне карарсың, абзардагы тиресләрне түгәрсең.

Байтирәк. Ә корбан тиреләрен кем карап бара?

Шәйхезаман. Байморат хезмәтчесен алабыз.

Байтирәк. Мулла абзый, мине алып барырга вәгъдәң бар иде.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, киләсе елга Спас ярминкәсенә барырсың.
Байтирәк. Ул вакытта кызу эш өсте була, мин бушамыйм.
Шәйхезаман. Бәрәкалла, анда булмаса, киләсе кышка Минзәләгә алып барырмын.
Байтирәк. Хәзрәт, һәр ел саен вәгъдә бирәсең, вакыты җиткәч, ни дә булса хәйлә табасың.
Шәйхезаман. Хуҗаң белән бәхәс итмәк җаһиллек галәмәте. Хуҗаң ни кушса, шуны тыңларга кирәк.
Байтирәк. Юк инде, хәзрәт. Җәй, кыш димим, баш күтәрми көч куям, бөтен эшеңне эшлим, бер тиен акча чыгартмыйм.
Шәйхезаман. Бәрәкалла, шуның өчен дә син минем хезмәтчем. Эшләмәгәч, мин сине нәрсәгә ашатып тотыйм. Бар, Шәмгун мәзинне, Әбелкарип хәлфәне, Ризван казыйны, Әмирхан карыйны, Исәнбай белән Миртимер шәкертләрне чакырып кил. Аннан корбан тиреләрен төярсең.
Байтирәк. Кара әле, хәзрәт...
Шәйхезаман (*бүлдерә*). Башка сүз юк, мәгъзүр!

Байтирәк китә. Зөлхәмидә керә.

Зөлхәмидә. Әткәй, безнең әнкәйнең исеме ничек?
Шәйхезаман. Бәрәкалла, үз анаңның исемен дә белмисеңме?!
Зөлхәмидә. Белә идем дә, оныттым.
Шәйхезаман. Җомабикә.
Зөлхәмидә. Ә, шулай иде шул! Әткәй, җир тетрәү, зилзилә нидән була?
Шәйхезаман. Дөнья, кызым, зур диңгез, диңгез өстендә зур балык, балык мыегында зур үгез, үгез мөгезендә җир тора. Кайвакытларда шул үгезне чебен килеп тешли дә бераз гына кыймылдап куя, менә шуңардан җир селкенү хасил була.
Зөлхәмидә. Ул үгезне кигәвен тешләсә, ахрызаман буламы?
Шәйхезаман. Бәрәкалла, нишләп аңардан ахрызаман булсын!
Зөлхәмидә. Ник булмасын? Үгезләр кигәвеннән бик куркалар бит. Челләдә койрыкларын кадап чабалар.
Шәйхезаман. Аллаһе Тәгалә үзенең кодрәте белән ул кигәвеннәрне үгез янына җибәрми тора.
Зөлхәмидә. Ә нигә соң чебеннәрне җибәрә?
Шәйхезаман. Ярый, кызым, андый затлар турында сорашма, зур гөнаһ дәһрилек була, ди китап.

Җомабикә керә.

Зөлхәмидә. Әнкәй, күчтәнәч алып кайттыңмы?
Җомабикә. Кайттым, кызым, мә, тигезләп бүләрсез.

Төенне бирә, Зөлхәмидә алып китә.

Шәйхезаман. Кил әле, остазбикә, бик мөһим мөсахәбәм бар.
Җомабикә. Нинди мөсахәбә ул?
Шәйхезаман. Үткән ел халык буталышы уңае белән Карасу авылында өч мулланың указын алганнар иде бит. Менә шул муллалар урынына Әбелкарип хәлфәне, Ризван казыйны, Әмирхан карыйны муллалыкка тәкъдим итеп, мөфти хәзрәтләренә хат язган идем. Бүген үз мөбарәк кулы белән язылган хатын алдым. «Сез күрсәткән зат Шәрифләрне лаеклы санап тәсдыйк итәбез, авыл халкыннан тамга җыеп җибәрегез» дип язганнар.
Җомабикә. Мин сине, хәзрәт, аңламыйм, ни дип кеше өчен тырыша торгансыңдыр? Алар киткәч, мәдрәсәңдә кем калыр?
Шәйхезаман. Кайгырма, мажик әйтмешли, камыты булса, киючесе табылыр. Аларны мулла итәргә йөрүемнең сере бар, остазбикә. Беләсең, берсе саңгырау, икенчесе сакау, өченчесе тыңкыш танау кызларыбыз бар. Ул гарипләрне кемгә булса да бирергә кирәктер бит инде.
Җомабикә. Анысы бик дөрес, хәзрәт, бик вакыт.
Шәйхезаман. Шулай булгач, мин аларны муллалык указына кушып бирмәкче булам.
Җомабикә. Әгәр дә алар риза булмасалар?
Шәйхезаман. Шәкерт халкына мулла булырга дисәң, сукыр карчыкка да өйләнер. Мин хәзер аларны үз яныма чакырттым, җайлап кына белдереп куярга уйлыйм.
Җомабикә. Ярый, әүвәле-ахыры хәерле булсын.
Шәйхезаман. Әйе, шулай булсын. Аннан, остазбикә, миңа өс-баш, ашарга, эчәргә хәзерлә. Байморат, Солтангәрәй байлар белән Минзәлә ярминкәсенә китәбез.
Җомабикә. Ай Алла, бик иртә бит, хәзрәт.
Шәйхезаман. Без шулай уйладык инде.
Җомабикә. Нигә инде алар артыннан йөрергә? Алар — сәүдәгәр халкы.
Шәйхезаман. Бәрәкалла, минем дә сатасы корбан тиреләрем бар, алдан барып кыйбатрак сатып булмасмы? Аннан ат базарыннан берәр Сембер тае алырга ниятләп торам. Бигрәк тә, әле сөйләгәнчә, теге имгәк-

ләрне бирергә булгач, буш кул белән җибәрү ярамас. Аларга да берәр кат өс-баш, йорт җиһазлары алырга кирәк.

Шәмгун керә.

Шәмгун. Әссәламегаләйкем...

Җомабикә китә.

Шәйхезаман. Вәгаләйкемәссәлам.
Шәмгун. Ник чакырттың, хәзрәт?
Шәйхезаман. Мин бүген мәчет астына төшкән идем, ни өчендер утын азайган.
Шәмгун (*күзләрен челт-челт йомып*). Көннәр бик суык бит, хәзрәт.
Шәйхезаман. Шулай микән. Мин башкачарак ишеткән идем. Төнлә белән өеңә ташыйсың, сиркалек итәсең икән.
Шәмгун. Ифтира, хәзрәт, ихлас ифтира, мәзин башым белән утын урлап йөримме, Алла сакласын. Бигрәк тә Алла йортыннан. Кайсы оятсызы бөһтан бәла яга икән? Илаһи...
Шәйхезаман. Суфиланма, мәзин, урлыйсың, төнлә белән берничә тапкыр шәкертләр күргән.
Шәмгун. Юк, хәзрәт, валлаһи юк. Чыралык өчен киптерергә алып кайтканымны күргәннәрдер.
Шәйхезаман. Танма, мәзин, икърар ит. Кулың барлыгы миңа күптән билгеле, ифтар вакытларында мәчеттә җимеш тотмыйсың. Үткән ел михраптан паласны да син генә юкка чыгардың. Ярый инде, мажиклар алдында йөзең кызартасым килмәде. Узган эшкә салават. Менә нәрсә, мәзин, мин бүген Минзәлә ярминкәсенә китәм. Безнең йортка, мәдрәсәгә күз-колак булырсың.
Шәмгун. Ярый, хәзрәт, булырмын. Тик бер-ике көн сабыр итеп торганда яхшырак булыр иде. Чөнки Сөләйман хаҗи әҗәл якасында тора. Бая мине догаи мөнҗия укып өшкерергә чакырткannar иде, бик беткән. Иншалла, шушы арада тәпиен сузса кирәк.
Шәйхезаман. Ярминкәгә баруны бүгеннән кичектерергә ярамый. Мин кайтканчы үлә калса, минем хәссәмне алып куярсың. Кара аны, әгаһ бул, минем өлешемә нәфсеңне сузма, теге күрше урыс базарында эчеп үлгән сәүдәгәр киемнәрен дә үзеңә генә йомдың.

Исәнбай белән Миртимер керә.

Икесе бергә. Әссәламегаләйкем.
Шәйхезаман (*сәламнәрен алмый*). Бар, мәзин, китәргә рөхсәт.

Шәмгун китә, кисәктән тупас рәвештә шәкертләре өсләренә кычкыра.

Сасык!.. Бу хатны син фасыйк яздыңмы?
Исәнбай. Нинди хат ул, тәкъсир? Һичбер нәрсә аңламыйм.
Шәйхезаман. Аңламасаң, укып күрсәтим. (*Укый*.) «Кадерле атам, сезгә шуны мәгълүм итәем: юкка гына мине бу мәдрәсәгә җибәрдең, монда тәртип-низам юк, гыйлем алуны уйларга да ярамый. Хәлфәләре генә түгел, хәтта мөдәррисенә кадәр карт аюдай тупас, песи башлы ябалактай томана». Син яздыңмы?.. Мин синнән сорыйм, нигә җавап бирмисең?
Исәнбай. Әйе, хәзрәт, мин язган идем.
Шәйхезаман. Үз остазыңның дәрәҗәсен төшерергә, укый торган изге йортыңның яманатын сатарга кемнән өйрәндең?
Исәнбай. Гафу сорыйм, тәкъсир. Моннан соң язмас идем.
Шәйхезаман. Сасык, бетле дуңгыз, корчаңгы ишәк! Мажик кызлары янына — аулак өйләргә барып курай уйныйсың. Ят!..
Исәнбай. Кичер, гафу ит, тәкъсир...
Шәйхезаман. Ят, диләр сиңа!..

Исәнбай сузылып идәнгә ята. Шәйхезаман, алагаемга кизәнеп,
камчы белән суга.

Тор!.. Бер юлга кичерәм, икенче кат эшләсәң, бәддога укып мәдрәсәдән куармын... Бар!
Исәнбай китә. Шәйхезаман Миртимер өстенә килә.

Бу ни бу?
Миртимер. Мин төшенмим, хәзрәт, ни турында әйтәсез?
Шәйхезаман. Синең кесәңнән алганнар, йә әйт, нәрсә бу?
Миртимер. Дохан, тәкъсир.
Шәйхезаман. Ни өчен урыс тәмәкесен кесәңдә йөртәсең?
Миртимер. Минем тешем сызлый. Теш сызлауга шифасы тия, дигәч, урыс авылыннан алдырган идем.

Шәйхезаман. Ялган сөйлисең. Һәрвакытта шуны тартасың, диләр. Хәлфәләреңнең үгет-нәсихәтен тыңламыйсың, шәкертләрне бозыклыкка өндисең. Дөнья гыйлемнәре укырга кирәк дип, дәһри Шиһап Мәрҗани, сукыр Каюмнар фикерен мәдрәсәмдә таратасың.

Миртимер. Ул фикерне мин генә сөйләмим, хәзрәт.

Шәйхезаман. Каршы сөйләмә, эттән туган дуңгыз баласы!

Миртимер. Ул сүзләрне, хәзрәт, дөньяда кешеләрчә яшәргә үзен хаклы санаган һәрбер шәкерт авызыннан ишетерсез. Үзегез уйлап карагыз: башка милләтләр, гыйлем-мәгърифәткә омтылып, дөнья белемнәре укыйлар. Идел өсләрендә пар машиналары йөртәләр, тимер юллар салалар. Без соң мәңге шулай томаналык, наданлык тәгассебендә калырбыз микәнни?

Шәйхезаман. Үтерәм мин сине... (*Камчы тотып каршысына бара, аннан соң куркып туктап кала.*) Чык, сасык, чык!

Миртимер китә.

Ах, дөббәтөльярыз, Нәмрүт нәселеннән яратылган явыз!..

Җомабикә керә.

Җомабикә. Нигә холыксызланасың?

Шәйхезаман. Миртимер дигән сасыкны чакырткан идем, каршы сөйләп ачуымны кабартты. Кая, артыш таягымны бир әле, артыннан җитеп, тукмап үтерим үзен.

Җомабикә. Кирәкми, хәзрәт, ул бик усал нәрсә бит, үткән ел Әбелкарип хәлфәне кыйнап башын ярган кебек, тотар да сине дә кыйнар.

Шәйхезаман. Кыйнар, дисеңме?

Җомабикә. Кыйнар, хәзрәт, кыйнар! Усал белән тапма да, бүлешмә дә, дигәннәр.

Шәйхезаман. Дөрес шул, мажик баласы бит, аннан барысын да күтәргә була.

Җомабикә. Әйдә, чәй өлгерде, эчеп алыйк.

Китәләр. Курка-курка гына, Әбелкарип, Ризван<br>һәм Әмирхан керәләр.

Әбелкарип. Бәлфараз, бу хәзрәт безне ни өчен чакыртты икән?

Ризван. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда, беркөнне мәдрәсә мичен акшарларга килгән мажик хатыны турында булса кирәк. Бәс, шулай булгач...

Әмирхан. Аның өчен генә булса берни дә түгел. Минем күңелемне икенче бер шик борчыйдыр.

Әбелкарип. Бәлфараз, нинди шик ул, карый?

Әмирхан. Кичә ястү намазында Коръән укуны, сафсата, Чулак Хәйригә тапшырып бик зур ялгышлык эшләдек. Ул, агач авыз, Бохар мәкаме урынына, Шәйморза белән яра башлады. Мәчеттән чыгып качардай булдым. Җитмәсә тагын Солтангәрәй байларга читтән килгән кунаклар да бар иде.

Ризван. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда, ул — кечкенә мәсьәлә. Бәс, шулай булгач, узган атна кич хәйзи вә нифас турындагы моназара өчен чакырмады микән?

Әбелкарип. Сез шулай уйлыйсызмы?

Ризван. Бәлки, шулай дим. Юкса башкача ни өчен булырга мөмкин?

Әмирхан. Һәрхәлдә яхшылыкка түгелдер.

Ризван. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда, ул кадәр пошиман улырлык шәй юк, бәс, шулай булгач, бәндә хатадан хали түгел, Алла гафуррахим, диярбез. (*Песи кебек атлап ишеккә китә, башын тыгып карый.*)

Әбелкарип. Нишлиләр?

Ризван. Абыстай белән пар күгәрчендәй гөрли-гөрли чәй эчәләр.

Әмирхан. Йөзе ничек, бик ачулы түгелме?

Ризван. Айның ундүртенче кичәсе шикелле. (*Икенче ишеккә китә.*)

Әмирхан. Алай булса, иншалла, хәерлегәдер.

Әбелкарип. Ганка, тагы нишлисең?

Ризван. Мәхдүмәләрне күзлим.

Әмирхан. Соң, андалармы?

Ризван. Күренмиләр, чаршау тартылган.

Әбелкарип. Куегыз, ганкалар, тамагыгызны сузмагыз. Бәлфараз, хәзрәт чыгып артыш таягы белән тукмар.

Әмирхан. Ул сафсаталарны күреп сөйләшәсе иде бит. (Те*л астына сала.*)

Ризван. Кая, миңа да бир әле.

Әбелкарип. Бәлфараз, без дә калмыйк өлештән.

Әмирхан. Сез сафсаталарның шул булыр инде, үзегез алмыйсыз, кешенекенә нәфсегезне сузасыз.

Әбелкарип. Бәлфараз, мәхдүмәләрне күргәнегез бармы соң? Ул ганкалар төскә-биткә, холык ягыннан ниндиләр икән?

Әмирхан. Нинди булсын? Хатын-кыз кавеме башта бик тәкәббер, һавалы була.

Ризван. Безнең мәхдүмәләр андыйлардан түгел. Беркөнне шулай икенде намазына барышым, хикмәти Хода, иттифакый рәвештә шушы тәрәзәгә күзем төшмәсме. Оҗмах хуры кебек өч кыз бала, йөзләрендә нур уйнатып, миңа таба күз сала. Шуннан, кулымны күкрәгемә куеп, ишарә сәламе бирдем.

Әбелкарип. Соң, шуннан бәлфараз...

Ризван. Шуннан алар өчесе дә минем сәламемне алдылар да, илаһи матур чырай белән көлеп, миңа баш иделәр.

Әбелкарип. Ышанмыйм, алдыйсың, ганка!..

Ризван. Ихлас әгәр. Мәрткә киткән изге төсле, баскан җирдә катып калганмын.

Әбелкарип. Хуш, хуш, шуннан, бәлфараз...

Ризван. Азан тавышына уяндым. Мәчеткә кереп намаз укырга керешсәм дә, күңелем тынычлана алмады. Дүрт рәкагать фарыз урынына өч рәкагать сөннәт дип ниятләгәнмен. Шуннан соң әллә никадәр турыларыннан узып карадым, нурлы йөзләрен күрә алмадым. Менә шул морадыма ирешү өчен, мин бүген язган мәктүбемне бирмәкче булам.

Әмирхан. Кайсына? Алар өчәү бит.

Ризван. Минем өчен кайсына булса да ярый.

Әмирхан. Аларның берсе саңгырау, икенчесе сакау, диләр түгелме соң?

Ризван. Эш аларның саңгыраулыгында йә булмаса сакаулыгында түгел. Бөтен хикмәт мөдәррис кияве булуда. Мәхдүмәләрнең берсенә никахланып алсаң, муллалык ләвәзиме дә, дәүләт байлыгы да, шөһрәт абруе да табыла. Хатының ошамый икән, бераз тормышыңны җайлагач, икенче яшь бикәчкә өйләнәсең. Анысы ошамый икән, өченчесен аласың. Әлхәсиле валькәлам, бал корты шикелле, чәчәктән чәчәккә кунып йөрисең.

Әмирхан. Безгә дә шулай эшләү мәслихәт булыр иде, ләкин язган хатым юк.

Ризван. Борчылма, карый, кирәк булса, табарбыз. Менә алар миндә ничаклы.

Әбелкарип. Ганкалар, сез инде без фәкыйрьне дә онытмагыз, бер данәсен миңа да бирегез.

Әмирхан. Шулай итеп, мажик әйтмешли, баҗайлар булабыз.

Әбелкарип. Хәзрәт кияүләре диң, агач авыз, алаша.

Зөлкагыйдә, Зөлсәгыйдә һәм Зөлхәмидә талаша-талаша керәләр.

Зөлсәгыйдә. Бир минем иннегемне, нигә урладың?

Зөлсәгыйдә. Талашмагыз, әтигә әйтәм.

Зөлхәмидә. Бәрәч, кеше бар икән...

Кача башлыйлар.

Ризван (*каршыларына төшеп*). Мәхдүмәләр, сабыр итегез, бер кечкенә йомышым бар. Менә шушы хатны алсаңчы, күңел түрләреңә салсаңчы.

Әмирхан. Монысын миннән алыгыз, кош теледәй җавап язып.

Әбелкарип. Миннән сезгә бер нама, кабул итәрсездер, иншалла.

Кызлар хатларны алып китәләр.

Әмирхан. Болай булгач, эш пеште дигән сүз.

Ризван. Мажик әйтмешли, барып та чыкты, бәреп тә екты, мәхдүмәләр безнеке.

Әбелкарип. Амин, шулай булсын, бәлфараз...

Ризван. Хәзрәт чәй эчеп туйды, рәхим итеп керик.

Әбелкарип. Әйдәгез, Аллага тапшырдык.

Китәләр. Зөлкагыйдә, Зөлсәгыйдә, Зөлхәмидә керә, өчесе өч җиргә басып, хат укырга керешәләр.

Зөлкагыйдә. Әлхәтте нисфелмөлакәт.

Зөлсәгыйдә. Син җаныйга сагынып яздым сәлам хат.

Зөлхәмидә. Кабул күрсәң укып бак, күрмәс булсаң, ертып утка як.

Зөлкагыйдә. Агзальнас вәкәрәмәлхавас улан җанымның җаны...

Зөлсәгыйдә. Күземнең карасы...

Зөлхәмидә. Бәгърем парәсе...

Зөлкагыйдә. Дәртем дәвасы...

Зөлсәгыйдә. Син җаныйны ничек итеп үземә аласы?

Зөлхәмидә. И җаным, кара кашым, карлыгачым.

Зөлкагыйдә. Сайрый торган сандугачым.
Зөлсәгыйдә. Камыш бармагым, көмеш тырнагым.
Зөлкагыйдә. Энҗе тешем, гөл йөзем.
Зөлсәгыйдә. Син җаныйны сагына, сагына...
Зөлкагыйдә. Елап уза кичем, көндезем. Мескен...
Зөлхәмидә. И җаным. Сиңа гашыйк булганнан бирле.
Зөлкагыйдә. Ятсам, йокы кермидер.
Зөлсәгыйдә. Торсам, күңелем тынмыйдыр.
Зөлхәмидә. Капсам, тәгам үтмидер. Бичара...
Зөлкагыйдә. Син мәгъшукама сәламнәрнең гәүһәрен...
Зөлсәгыйдә. Сәналәремнең җәүһәрен...
Зөлхәмидә. Ирсал вә таблиг әйләдем.
Зөлкагыйдә. Бәнем шушы хатыма каршы кош теледәй намә күндерсәң, үзеңне күргән кебек...
Зөлкагыйдә. Үзеңне күрсәм, кочагыңда булган кебек...
Зөлхәмидә. Кочагыңда булсам, оҗмахка кергән кебек булыр идем. Ах!..
Зөлкагыйдә. Үпкәләмә, бәгърем, әйткәнгә, үкенерсең гомерең үткәнгә...
Өчесе бергә. Кыйтмир бәдүх...
Зөлхәмидә. Апа, нишлибез?
Зөлкагыйдә. Ә... Кемне тешлибез?
Зөлсәгыйдә. Җавап язарбызмы, дим.
Зөлкагыйдә. Язабыз, бик матурлап язабыз. Әнкәй дәү абыйларга киткәч, аулак өйгә чакырып кунак итәрбез.

Җомабикә керә.

Җомабикә. Кызларым, килегез әле, мин сезгә бик шатлыклы хәбәр ирештерим. Атагыз сезне кияүгә бирәм, ди.
Зөлсәгыйдә
Зөлхәмидә

Рәхәтләнеп көләләр.

Зөлкагыйдә. Ә?..
Җомабикә. Өчегезне берьюлы кияүгә бирәм, ди.
Зөлкагыйдә. Бер кешегәме?
Җомабикә. Нишләп бер кешегә булсын! Өчегезгә берьюлы менә дигән кияүләр тапкан.
Зөлсәгыйдә. Кемнәр алар?
Җомабикә. Ирләр чыга, әйдәгез.

Китәләр. Шәйхезаман, Әбелкарип, Ризван, Әмирхан керә.

Шәйхезаман. Шулай, әфәнделәр, мин кайтканчы мәдрәсәгә күз-колак булуны, шәкертләр өстеннән карап торуны сезгә тапшырам.
Әбелкарип. Яхшы, тәкъсир.
Шәйхезаман. Мәзинне тикшереп торыгыз, утынны урлап ташымасын. Аннан бүген үк Миртимер мөртәтне мәдрәсәдән куыгыз.
Ризван. Бик куар идек, хәзрәт, беләсең, ул безнең сүзне тыңламый. Бәс, шулай булгач, үзегез чарасын күреп китсәгез яхшырак булыр иде.
Шәйхезаман. Ярый, китешли сотник Гарәфигә әйтермен. Бергәләп куарсыз. Аннан мин сезгә харикыльгадә булган бер серемне чишмәкче булам. Сез өчегез дә минем мәдрәсәмнең өрлек баганалары булып килдегез. Миңа булган ихтирамыгыз, мөкатдәс динебезгә иткән хезмәтегез өчен намаз арты саен Аллаһе тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләреннән мөкафәт сорый идем. Ниһаять, минем сорауларым бушка китмәде, бүген мөфти хәзрәтләреннән хат алдым, өчегезне берьюлы Карасу авылына имам итеп билгеләгәннәр.
Әбелкарип. Хәзрәт...
Ризван. Тәкъсир...
Әмирхан. Ихласмы?
Шәйхезаман. Әйе, дөрес, менә мөфти хәзрәтләренең үз кулы белән язган хаты.
Әбелкарип. Тәкъсир, хәзрәт... (*Елап җибәрә.*)
Ризван. Гомеребез буе колыгыз булып хезмәт итәрбез.
Әмирхан. Табаныгызны үбәргә рөхсәт итегез, тәкъсир.

Аякларын кочаклап үбәләр.

Шәйхезаман. Кирәкми, әфәнделәрем, андый хөрмәткә мин үземне лаеклы санамыйм. Сез бары тик үзегезнең Алла каршында иткән туры хезмәтләрегезнең мөкафәтен генә алдыгыз.

Ризван. Юк, юк, тәкъсир. Сезнең аркада гына без кеше булдык.

Әмирхан. Сез җанабе галинең изге җанлыгы аркасында гына бу шәрәфкә ирештек.

Бәхтияр керә.

Бәхтияр. Әссәламегаләйкем.

Шәйхезаман. Вәгаләйкемәссәлам, Бәхтияр агай, бу айларда ник күренмәдең?

Бәхтияр. Читтә, кәсептә идем.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, бик яхшы. Нинди йомышлар белән?

Бәхтияр. Мин сезгә өч ятим бала китергән идем.

Шәйхезаман. Нинди балалар?

Бәхтияр. Мин йөргән җирләрдә ачлыктан ата-аналары үлеп ятим калганнар. Укырга, гыйлем алырга теләкләре зур. Менә шул балаларны үз мәдрәсәгезгә алсагыз иде.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, кая соң алар?

Бәхтияр (*ишек ачып кычкыра*). Улларым, бирегә, хәзрәт янына керегез.

Егетләр киеменнән Бибкәй, Миләүшә, Гайшә керә.

Әйдәгез, улларым, тартынмагыз, хәзрәткә сәлам бирегез.

Кызлар. Әссәламегаләйкем!..

Шәйхезаман. Вәгаләйкемәссәлам. Хуш килдегез, шәкертләр.

Әбелкарип. Ләвәшләр килде, бәлфараз...

Ризван. Кыстыбыйлар дисәңче, надан.

Шәйхезаман. Кайсы җирнеке буласыз?

Бибкәй. Без, хәзрәт, ерактан.

Бәхтияр. Казан артыннан.

Шәйхезаман. Ни өчен үз илегездә укымадыгыз?

Бибкәй. Бездә ике елдан бирле ачлык.

Миләүшә. Бигрәк тә, хәзрәт, сезнең кебек гыйлем иясеннән сабак аласыбыз килде.

Шәйхезаман. Бәрәкалла. Гыйльме нафига бирсен. Әһле голямалар зәмрәсенә керергә насыйп итсен. Нинди дәресләр укыдыгыз?

Бибкәй. Безнең укуларыбыз зур түгел, мин Баб ябигга төшкән идем.

Миләүшә. Мин Мохтәсарны чыктым.

Гайшә. Мин сарыфта гына идем.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, әһле гыйлемнең кечкенәсе, әһле дөньяның иң кәттәсе, ди китап. Сез, яшьләр, әкренләп өйрәнерсез. Исем шәрифләрегез ничек?

Бибкәй. Минеке Миңлекәй.

Миләүшә. Минем Вәлишә.

Гайшә. Минеке Гайшә, әй юк, Гайса.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, бик күркәм. Миңлекәй, Вәлишаһ һәм Гайса икән. Яхшы балаларга охшыйсыз. Ярый, мин сезне мәдрәсәгә укырга алам. Ләкин, казый әфәнде, кая урнаштырырсыз икән?

Бәхтияр. Беразга миндә генә торсыннар, хәзрәт.

Әбелкарип. Нигә синдә? Бәлфараз, берсен мин алырмын. Самавырчы малаемны яратмыйм. Менә бу кечкенәсен миңа бирегез.

Ризван. Юк, хәлфә, мантыйк ноктаи назарыннан караганда, синең начармы, яманмы — бар, менә минем бөтенләй юк. Бәс, шулай булгач, ул баланы үзем алырмын.

Әмирхан. Юк инде, хәзрәт, кечкенәсен миңа бирегез.

Шәйхезаман. Сүз көрәштермәгез. Байтирәк, Байтирәк!

Байтирәк керә.

Байтирәк. Әү, хәзрәткәем, сиңа тагы ни кирәк?

Шәйхезаман. Менә бу балаларны берничә көнгә үз яныңа алырсың. Мин кайтканчы, утардагы тиресләрне түктерерсең.

Байтирәк. Ярый, хәзрәт.

Байморат керә.

Байморат. Без килдек, хәзрәт.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, мулла Байморат. Байтирәк, корбан тиреләрен төяп бетердеңме?

Байтирәк. Күптән инде. Ат та җигелгән.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, рәхмәт сиңа. Мин киенеп, фатыйха биреп чыгыйм алайса.

Байморат. Әйдә, хәзрәт, юл кешесенең юлда булганы яхшы.

Кереп китәләр.

Байтирәк. Әйдәгез, егетләр.

Китәләр. Зөлкагыйдә, Зөлсәгыйдә, Зөлхәмидә йөгереп керәләр, тәрәзәдән карыйлар.

Зөлсәгыйдә. Нинди матур шәкертләр.
Зөлхәмидә. Апа, кара әле, алар нинди чибәрләр.
Зөлкагыйдә. Ә?!
Зөлхәмидә. Егетләрне кара, дим.
Зөлсәгыйдә. Миңа уртанчысы бик ошый.
Зөлхәмидә. Миңа кечкенәсе булса да ярый.
Зөлкагыйдә. Миңа иң өлкәне, зурысы.
Зөлсәгыйдә. Бүген үк бик матурлап хат язам. Аулак өйгә чакырып кунак итәбез.

Әбелкарип, Ризван, Әмирхан керә.

Зөлхәмидә. Әбәү, оятлы булдык ич.

Бүлмәләренә качалар.

Әбелкарип. Ишеттегезме, аулак өйгә чакырабыз, диләр.
Ризван. Бәс, шулай булгач, яннарына чумабыз.

Кызлар янына кереп китәләр.
Шәйхезаман, Җомабикә, Байморат чыга.

Шәйхезаман. Хуш иттек, остазбикә, хуш.
Җомабикә. Хуш, хәзрәт, исән йөреп кайт.
Шәйхезаман. Амин!.. Шулай булсын... Хушыгыз, кызларым....

Чыгып китәләр. Кызлар, пумала, кисәү агачы һәм себерке тотып,
хәлфәләрне кыйнап чыгаралар.
Пәрдә төшә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәдрәсә. Бер якта җәмәгать сәкесе. Артта хәлфәләр бүлмәсе. Ике якта зур аркалар. Пәрдә ачылганда, шәкертләр шыгырдавыклы уйныйлар. Бер читтә
Миләүшә белән Гайшә сабак ятлый. Аксак Вәли керә.

Вәли. Ләкатә таптым, ләкатә.
Фазлый. Минеке.
Вәли. Нәрсә?
Фазлый. Күлмәк төймәмне югалттым.
Вәли. Түгел. Ләкатә таптым, ләкатә...
Моратай. Минеке.
Вәли. Нәрсә?
Моратай. Кызыл башлы карандаш.
Вәли. Түгел. Ләкатә таптым, ләкатә.
Дәүләт. Минеке.
Вәли. Нәрсә?
Дәүләт. Күркә каурыемны югалттым.
Вәли. Түгел. Менә ул нәрсә. (*Күрсәтә.*) Пәке.
Нигъмәт. Пәке... Кая, бир, минеке.
Вәли. Ансат кына, бир, имеш. Тотмыйсыңмы, менә, мә!.. Мин аны ашханә идәненнән таптым.
Нигъмәт. Алдыйсың, аксак дуңгыз, сандыктан алгансың. Бир, диләр сиңа!
Вәли. Сузма кулыңны, танавыңа бирермен!
Нигъмәт. Биреп кенә кара, яңак итеңнән тәбикмәк ясармын. Бирәсеңме-юкмы?
Вәли. Нишләп бирим. Өч тапкыр кычкырдым, белмәдең бит.
Нигъмәт. Бирмисеңме?

Вәли. Юк.

Нигъмәт таларга керешә.

Фазлый. Бирешмә, чәйдәш, салма савытына кундыр.
Моратай. Менә шулай, сабакташ...

Сугыш кызганнан-кыза. Башкалар көч биреп тора. Ризван керә.

Ризван. Ник сугышасыз, сасыклар?
Нигъмәт. Казый абзый, менә бу аксак шайтан пәкемне урлаган.
Вәли. Җаның сатма, чәкүшкә танау! Казый абзый, мин аны ашханә идәненнән таптым. Урласам, ләкатә кычкырмас идем.
Ризван. Кая, пәкене миңа бирегез. Хөкем ноктаи назарыннан карап, кемгә икәнен әйтермен.
Вәли. Казый абзый, мәетне бүген күмәләрме?
Ризван. Җеназа укырга ишан хәзрәтне көтәләр. Ул килеп өлгерсә, күмү бүген булачак.
Әскали. Казый абзый, хәмелнең суммасы күп микән?
Ризван. Яхшы, диләр, урыс авылындагы чалаванникка барып илле сумлык бакыр акча алыштырып кайттылар. Шулай булгач, шактый гына булса кирәк. Гайса, бире кил әле.
Гайшә. Ни йомыш, казый абзый?
Ризван. Менә шушы хатларны мәхдүмәләргә кертеп бирерсең. Кара аны, аналары сизмәсен, аннары итче Яхъя бик симез ат суйган, ди, бер биш кадак йомры карта алып кайтырсың.
Гайшә. Ярый, казый абзый. (*Китә.*)

Ризван бүлмәгә кереп югала.

Вәли. Карагыз әле, нигә бу зәхмәтләр безгә катнашмыйлар, утырмага килгән кызлар кебек катып торалар.
Фазлый. Әй сез, саламторханнар! Бүген атна кич бит, ни өчен уенга катнашмыйсыз?
Миләүшә. Уйныйсым килми.
Вәли. Әнисен сагына торгандыр. Хәзер аның әнисе коймак пешерә, юллык тишегеннән табагачын сузган да: «Вәлишә бәбкәм, кайт, коймак пешердем»,— дип кычкыра.
Миләүшә. Кара әле, нигә син эт шикелле өрәсең?
Вәли. Ачуың киләмени? Егетләр, моның серкәсе су күтәрми икән, мәдрәсә тәртибенә өйрәтик, ыри, ыри, ыри...
Әскали. Мияу, мияу... (*Песи булып кылана.*)
Фазлый. Әлмужикунелмужикун әгләмүәннәкем мөнафикун...
Нигъмәт. Мырык, мырык, мырык... (*Дуңгыз булып кылана.*)
Дәүләт. Вәмаләйса би хадисән, ләйсә би нәҗисән...
Вәли. Вау, вау, вау!.. (*Эт булып өрә.*)

Бибкәй керә.

Бибкәй. Нигә аны үртисез?
Вәли. Кара, кара ни кыланган була, садакасыз әрвах...
Бибкәй. Мин сине, аксак дуңгызны...
Вәли. Нәрсә?! Егетләр, шәкерт салмасы белән сыйлыйк! Дөмберт!
Киштәдән мендәр алып һөҗүм итәләр. Исәнбай белән Миртимер керә.

Исәнбай. Туктагыз, ни өчен аларны кыйныйсыз?
Вәли. Кыйнамыйбыз, мәдрәсә гадәтенә өйрәтәбез.
Миртимер. Ташлагыз, егетләр, кирәкми!
Вәли. Борыннарын чөймәсеннәр, яхшылап төшендерик әле, аннан безне таныргa яхшырак булыр.
Исәнбай. Җитәр, дим мин сезгә!
Вәли. Нигә яклыйсың, кыстыбыйларыгыз түгелдер бит?
Миртимер. Телеңне тыясыңмы, чатан дуңгыз!..
Вәли. Бик куркам инде!
Миртимер. Ах, авызыңа шайтан төкергән нәрсә... (*Куып китә.*)
Исәнбай. Ә сез ни көтәсез, таегыз моннан! (*Калганнарын куып чыгара.*)
Бибкәй. Исәнбай абый, алар белән нишлик инде?
Миләүшә. Бүген мине ашханәдә елатканчы үртәделәр. Өс-башымны пычратып, битемне корымга буядылар.

Исәнбай. Ләгънәт төшкән мәдрәсә гадәте... Һәрбер яңа килгән шәкертне газаплап интектерү, ана сөте шикелле, каннарына урнашып, гореф-гадәт булып әверелгән. Сез аларга әһәмият бирмәскә тырышыгыз. Өрерләр-өрерләр дә арыгач туктарлар.

Миртимер керә.

Тоттыңмы?
Миртимер. Тотарсың аны, гыйфрит бит ул, чормага менеп бикләнде.
Исәнбай. Әйдәгез, егетләр, мәчет манарасына күгәрчен тотарга менәбез.
Бибкәй. Күгәрчен тотарга, нәрсәгә ул?
Исәнбай. Менә кызык! Аш пешерергә.
Миләүшә. Кызганмыйсызмы? Гөнаһсыз кошлар бит алар.
Исәнбай. Булса соң?
Миләүшә. Кит, Исәнбай абый, ул нарасыйларны кулың барып ничек суярсың?
Исәнбай. Тоттырсалар, шатлана-шатлана суябыз инде. Ләкин бу елларда ни өчендер алар да азайды.
Бибкәй. Кирәкми, мескеннәрне әрәм итмәгез.
Миртимер. Кызык кына кешеләр сез. Бер дә дөньяда торганыгыз, мәдрәсәдә укыганыгыз юкмыни соң?
Бибкәй. Бар да бит, безнең якта андый гадәт юк.
Миртимер. Дөнья шулай корылган инде. Күгәрченнәрне генә түгел, дөньяның хуҗасы, аның иясе булган кешеләрне дә җәберлиләр. Хәтта кайвакытларда комсыз көчлеләр тарафыннан алар бөтен нәселләре белән һәлак ителәләр.
Исәнбай. Әйдәгез, киттек, Миртимер, кылларыңны алдыңмы?
Миртимер. Алдым, кесәдә.

Китә башлыйлар, бүлмәсеннән Ризван чыга.

Ризван. Миртимер, син кайчан мәдрәсәдән китәсең инде?
Миртимер. Кайчан ризыгым бетәр, шунда китәрмен.
Ризван. Син алай дисең дә бит, хәзрәт безне кыса. Син бүген чык инде.
Миртимер. Юк белән мине борчымагыз, мин беркая да чыкмыйм.
Ризван. Яхшылап әйткәнне аңламасаң, без сине сотскийга әйтербез.
Миртимер. Нәрсә?!

Бара башлый, Ризван куркып кача.

Исәнбай. Ха-ха-ха...

Китәләр, Гайшә керә.

Гайшә. Менә, казый абзый, карта булды.
Ризван. Һай рәхмәт, афәрин үзеңә. Ә соң мәхдүмәләр ни диде?
Гайшә. Хатларыгызны, казый абзый, алмадылар. Моннан соң хат язып та маташмасыннар, этигә әйтеп кистерербез, диләр.
Ризван. Гаҗәп, шулай да гаҗәп... Гайса дус, әллә нишләп аркам кычытып китте, борча кердеме, дим, һич чыдап булмый бит. Кашып алсаңчы.

Күлмәген күтәреп, сәкегә сузылып ята, Гайшә кашырга керешә.

Менә, менә, менә... Югарырак... Түбәнрәк... Гайса дус, син бүген минем янда ятырсың, җәмәгать сәкесендә сиңа салкындыр, астыңа да юк.
Гайшә. Юк, казый абзый, салкын түгел. Мин иптәшләремнең куеннарына керәм дә песи баласы кебек рәхәтләнеп йоклыйм.
Ризван. Түбәнрәк, аскарак... кабыргадан, бөергәрәк. Менә шулай, менә шулай... Уңгарак, сулгарак, комычкарак. Аскарак... Кытыклама, иманымны качырасың! Кытыклама, дим, мәлгунь! Хи, хи, хи... Ай, җибәр, үтерәсең!

Сәкедән егылып төшә, Гайшә кача.

Ах, явыз малай, бүген минем янга ят әле, мин сине шундый итеп кытыкlармын.

Ашыгып Шәмгун керә.

Шәмгун. Җәмәгать, ишан хәзрәт килде, җеназага!
Вәли. Тәһарәтелбәдәни, суктым ектым кәҗәне...

Бөтен шәкерт бердәм кабынып китә, берсе икенчесен таптап, комганнар, сөлгеләр алалар, тәһарәткә китәләр.

Шәмгун. Ризван казый, бая өйлә намазында нәрсәдер әйтергә булган идең.

Ризван. Әйе, синдә бүген аулак өй бугай.

Шәмгун. Шулайрак, хатын белән бала-чагаларны төяп каенатайларга кунакка җибәрдем.

Әбелкарип. Без бүген синең өеңдә әбелхәятләп алмакчы идек. Бәлфараз, ни әйтерсез икән?

Әмирхан. Хәрәҗәте, әлбәттә, бездән булыр.

Шәмгун. Бик яхшы булыр иде. Сезне кунак итәргә дигән вәгъдәм дә бар иде. Ләкин халыкка беленеп хәзрәткә җиткерүләре бар.

Ризван. Без аны сизелмәслек итеп эшләрбез. Бәс, шулай булгач, ястүдән соң кеше аяк эзе басылгач, тәрәзәләрне палас белән капларбыз да мыштым гына утырырбыз.

Шәмгун. Анысы шулай. Тик менә карый әфәнденең холкы бик начар, бераз эчеп алдымы акырырга-бакырырга, сугышырга, әйбер ватарга керешә. Шуның өстенә оятсыз сүзләр белән сүгенә. Исегездәме, үткән Корбан бәйрәмендә нишләде? Борынымны тешләп өзә язды. Шуннан соң мин аның белән утырмаска булдым.

Әмирхан. Ул чагында әфиүн эчкән идек, беләсез, ул кешенең акылын ашый торган кәсәфәт. Шул хәлләрдән соң мин үзем дә ул агуны эчмәскә тәүбә иттем.

Ризван. Сез тыныч булыгыз, мәзин, без аңа ирек бирмәбез. Усаллана башласа, кул-аягын бәйләрбез дә базга салырбыз.

Шәмгун. Ярый алайса, кая, акчагызны бирегез, хәзер үк кеше җибәреп алдырам. Карагыз аны, мәдрәсә шәкертләренә сиздерә күрмәгез.

Әбелкарип. Ул турыда хафаланмагыз. Без шәкертләр арасында, Тулбай авылына мөназарага барабыз, дип, хәйлә хәбәре таратабыз. Бәлфараз, шулай булгач, безне эчеп утыралар дип кем уйлар.

Ризван. Анысы да монысы, бу Миртимер шәкерт белән нишлибез? Мин бая тагын бер кат әйтеп караган идем, юньләп сөйләшми дә. Хәзрәтнең холкын беләсез. Кайтып керсә, ни дип җавап бирербез.

Шәмгун. Нигә соң куркып торасыз, куыгыз да чыгарыгыз.

Ризван. Ансат кына, куыгыз да чыгарыгыз, имеш. Бар, син аның белән сөйләшеп кара. Ул бит мажик баласы.

Шәмгун. Исегез киткән икән, менә күрегез дә торыгыз, куам да чыгарам.

Исәнбай белән Миртимер тәһарәт алып керә.

Шәмгун (*гайрәтләнеп, ачу белән кычкыра*). Миртимер!

Миртимер. Ни бар, мәзин абзый?

Шәмгун. Юк... Әссәламегаләйкем!

Миртимер. Берәр йомышың бар идеме әллә?

Шәмгун. Минем болай бер йомышым да юк... Менә Ризван казый нәрсәдер әйтергә теләгән иде.

Ризван. Минме?

Әбелкарип. Миртимер, Исәнбай, без бүген Тулбай шәкертләреннән мөназарага чакырып өндәү хаты алган идек. Бәлфараз, сез дә барырга теләмисезме?

Исәнбай. Без мөназарачылар түгел, анда нишләп йөрик ди.

Әбелкарип. Барасыгыз килсә дип кенә әйтүебез иде. Бәлфараз, бармыйсыз икән, бигрәк тә яхшы. Шәкертләргә күз-колак булырсыз, без, Аллаһы бирсә, хәмелдән соң китәргә булдык.

Шәкертләр тәһарәттән керәләр.

Ризван. Булдыгызмы?

Моратай. Булдык, казый абзый.

Әбелкарип. Бәлфараз, булсагыз — әйдәгез.

Китә башлыйлар.

Әмирхан. Туктагыз, мәдрәсә сакларга кем кала?

Әбелкарип. Кем кизү булса, шул калыр.

Вәли. Юк инде, хәлфә абзый, гомер эчендә беренче тапкыр туры килгән мул садакадан кизүнең дә, иске шәкертләрнең дә колак кагасы килмәс. Әнә яңа килгән шәкертләрне калдырырга кирәк.

Ризван. Минемчә дә шулай эшләү мәслихәтрәк булыр.

Бибкәй. Хәлфә абзый, казый абзый, без дә барыйк инде.

Әбелкарип. Җәмәгать фикеренә каршы сөйләү, ул ни дигән сүз?! Каласыз! Карагыз аны, яхшы саклагыз!

Әмирхан. Урлаша күрмәгез!

Әскали. Хәлфә абзый, мәетне өйдән алып чыктылар.

Әбелкарип. Шулаймы? Әйдәгез, Аллага тапшырдык.

Китәләр.

Бибкәй. Бераз акча эшләп булмасмы дип өметләнгән идем, булмады.

Миләүшә. Козгыннар кебек карылдарга керештеләр.

Гайшә. Юкка гына без монда килдек. Күрәсез, эткә сан бар, безгә юк.

Миләүшә. Чыннан да, очраган саен кимсетәләр, хурлыйлар...

Бибкәй. Шулай инде, акыллыларым. Гыйлем алу — энә белән кое казу, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Авыр булса да, түзәргә кирәк.

Гайшә. Аннан бу мулла кызлары белән нишлибез инде? Мине Ризван казый хат белән җибәргән иде. Өйләренә барып керүгә, сарып алдылар да сорашырга керештеләр. Ничек торасыз, имеш, ашарга-эчәргә аптырамыйсызмы, шәкертләр үзегезне какмыйлармы, имеш.

Миләүшә. Син нәрсә дидең соң?

Гайшә. Нәрсә дим? Мулла кызларының шулкадәр оятсыз булуларына аптырадым да калдым.

Бибкәй. Әйтәм аны турыларыннан уза башладыңмы, тәрәзә кагалар, кул болгыйлар. Димәк, алар безгә гашыйк булганнар.

Гайшә. Булганнар, булганнар. Без сезсез тора алмыйбыз, диләр. Хәлфәләрнең хатларын кире җибәрделәр.

Бибкәй. Алай да кызык...

Байтирәк керә.

Байтирәк. Нихәл, егетләр?

Бибкәй. Әйдә, Байтирәк абый.

Байтирәк. Әллә беркем дә юкмы?

Миләүшә. Бар да зияратка, хәмелгә олактылар.

Байтирәк. Сез нигә бармадыгыз?

Гайшә. Алып бармадылар, мәдрәсә сакларга калдырдылар.

Байтирәк. Соң ничек, мәдрәсә тәртибенә ияләшәсезме?

Бибкәй. Әкренләп ияләшеп булыр иде дә, бик кимсетәләр.

Байтирәк. Кемнәр?

Бибкәй. Берничә усал шәкерт бар.

Миләүшә. Аксак Вәли.

Гайшә. Тана күз Моратай дигәннәре.

Байтирәк. Ярый, мин аларны бүген үк күреп колакларын борырмын. Аннан майлагандай булырлар... Беләсезме, мин сезгә нигә килдем?

Бибкәй. Юк, белмим.

Байтирәк. Яучы булып.

Гайшә. Нинди яучы?

Байтирәк. Безнең мулла кызлары сезгә гашыйк булганнар.

Бибкәй. Шаяртасың?

Байтирәк. Билләһи менә. Зар-интизар булып, сезнең белән күрешергә телиләр.

Бибкәй. Без аларны үзебез дә сизгән идек. Тик шулкадәресе бар: без бит монда гыйшык тотарга түгел, укырга килдек.

Байтирәк. Бик әйбәт. Берсе икенчесенә уңайсызламый. Укыгыз да, гыйшык та тотыгыз.

Миләүшә. Сөймәсәк тәме?

Байтирәк. Әйе, сөймәсәгез дә. Үзегез өчен түгел, көнегез өчен сөегез. Бәхтияр абый сезнең хәлне миңа сөйләде.

Бибкәй. Нинди хәлне?

Байтирәк. Ятим балалар булуыгызны, өйдән бернинди дә ярдәм алмавыгызны.

Гайшә. Уф... Алай булса ярый.

Байтирәк. Әллә башка якларыгызны да беләме?

Гайшә. Юк, белми...

Байтирәк. Алай булгач, нишләп көрсендең?

Гайшә. Авылда миңа бер кыз сарылып йөргән иде, мин яшь әле дип алмадым. Бәхтияр бабай әллә шуны сиңа сөйләгәнме, дигән идем.

Байтирәк. Йә, егетләр, ни дисез?

Бибкәй. Булмый, Байтирәк абый, без әле бик яшьләр.

Байтирәк. Сез бераз гына йөргән булып кыланыгыз... Алар сезне ашатырлар, эчертерләр, хәтта киендерерләр дә.

Миләүшә. Кирәкми, әйберләре дә, үзләре дә кирәкми.

Байтирәк. Сез алай тәкәббер булмагыз, тәкәбберлек — шайтан фигыле, ди китап.

Гайшә. Тәрәзә артында ниндидер хатын-кызлар йөри.
Байтирәк. Мәхдүмәләр, сезнең белән күрешергә килгәннәр. Барыгыз, сөйләшегез.
Бибкәй. Кара әле. Байтирәк абый, оятсызлык була бит.
Байтирәк. Күп сөйләнмә, якты йөз, ачык чырай күрсәтергә тырышыгыз.
Бибкәй. Әйдәгез, егетләр, ни булса да булыр.

Китәләр. Икенче яктан Исәнбай белән Миртимер керәләр.

Исәнбай. Саумы, Байтирәк абый?
Байтирәк. Бик яхшы. Исәнбай, нишләп болай иртә кайттыгыз?
Миртимер. Салкын буран. Өч тиен садака өчен катып үләр хәлем юк.
Байтирәк. Халык бармы?
Исәнбай. Исәбе дә, хисабы да юк. Күрше авыллардан да килгәннәр.
Байтирәк. Фәкыйрь кеше үлсә, җеназа укырга кеше табып булмый. Байлар үлсә, үләксә янына җыелган козгыннар төсле җыелалар.
Исәнбай. Теге егетләр кайда?
Байтирәк. Безнең ишегалдында утын яралар.
Миртимер. Нигә үзең түгел?
Байтирәк. Бүген, атка печән салганда, утлыкка егылып, кул- башымны имгәттем.
Миртимер. Байтирәк абый, бүген безнең мәдрәсәдә аулак булырга тора. Хәлфәләр Тулбай авылына мөназарага китәләр. Шул уңайдан файдаланып, шәкертләрнең күңел ачу кичәсен ясарга җыенабыз. Син берәр нәрсә сөйли аласыңмы?
Байтирәк. Белмим шул, миннән ни генә чыгар икән.
Исәнбай. Син бит әкият сөйләргә оста, бер-ике көлке әкият сөйләрсең.
Байтирәк. Әкият сөйләргә дисәң була.
Миртимер. Булды гына. Әйдә, Исәнбай, самавырны ал да, син чәй куярсың, мин аш салам.

Самавыр алып китәләр. Эчләре катып көлә-көлә, Бибкәй, Миләүшә, Гайшә керә.

Бибкәй. Уф, үләм...
Миләүшә. Менә әкәмәт, билләһи...
Гайшә. Эчем катты, уй...
Байтирәк. Туктагыз, нинди кызык табып көләсез?
Бибкәй. Көлми нишлим? Килде дә муеныма сарылды. Үзе саңгырау икән.
Миләүшә. Минеке сакау... Хи-хи-хи...
Гайшә. Минеке тыңкыш танау, хи-хи-хи...
Бибкәй. Кара, ничаклы күчтәнәч китергән. Ярты каз, тары ярмасы, кәрәзле бал.
Миләүшә. Бер сәке карлыган кагы, кипкән шомырт.
Гайшә. Бер каплама май, бавырсак.
Байтирәк. Менә күптән шулай кирәк иде, юкка киреләнеп торасыз.
Бибкәй. Егетләр, чәй куегыз, мәхдүмәләр күчтәнәче белән Байтирәк абыйны кунак итәбез.
Миләүшә. Әйдә, Гайса.
Гайшә. Бәрәч... Исәнбай абыйның самавыры кая?
Байтирәк. Үзләре ашханәгә алып киттеләр.
Миләүшә. Алар зияратта бит...
Байтирәк. Ярты юлдан борылып кайтканнар.
Гайшә. Әйдә, Вәлишә, аларга да сөйләп көлдерик әле.

Китәләр.
Байтирәк. Шулай диң, Миңлекәй, мулла кызы белән гыйшык тотам, диң?
Бибкәй. Әй, калдыр әле, җирәндерәсең. Син үзең турында сөйләргә булган идең, сөйлә әле.
Байтирәк. Нәрсәгә ул?
Бибкәй. Мин бит синең белән бик кызыксынам.
Байтирәк. Шулаймы?
Бибкәй. Шулай шул...
Байтирәк. Кызык, нишләп ул алай икән?
Бибкәй. Минем сиңа охшаган бер абыем бар иде. Бичара, үлде... Йә, сөйлә инде.
Байтирәк. Минем үткән көннәремдә кызыксынырлык бернәрсә дә юк. Алар минем исемә төшсә, барлык дөньясына ләгънәт әйтәсем килә. Минем әтине, алпавыт ашлыгын саклаганда, кырда яшен сугып үтергән. Сигез яшькә җиткәндә әни дә үлде. Шуннан мин, үксез бала булып, өйдән өйгә йөреп, бала карадым. Аннан инде байдан байга, мулладан муллага ялланып хезмәт итү көннәрем башланды.

Бибкәй. Кызганыч.

Байтирәк. Әйе. Минем күргәннәрне тыңласаң, шатлана алмассың. Ярый, аларны искә төшермик, Миңлекәй, син миңа әйт әле, нишләп синең кулларың бик кечкенә?

Бибкәй. Әллә тагы. Нигә сорыйсың?

Байтирәк. Болай гына... Кара инде, гел хатын-кызлар кулына охшаган.

Бибкәй. Үсәр әле, мин бик яшь бит, бары унсигез генә тула.

Байтирәк. Анысы шулай, тик менә...

Гайшә, Миләүшә, Миртимер, Исәнбай самавыр күтәреп керә. Сәкегә чәй урыны хәзерлиләр.

Гайшә. Кеше юкта, тыныч чакта рәхәтләнеп утырыйк әле.

Миләүшә. Байтирәк абый, Миңлекәй, әйдәгез чәйгә.

Тезелешеп утыралар. Нигъмәт белән Әскали Дәүләтне җитәкләп кертәләр.

Дәүләт. Ай кулым, ай аягым...

Байтирәк. Ни булды?

Нигъмәт. Кул-аягын өшетте.

Байтирәк. Их сезне! Нигә монда керттегез? Кар белән уарга кирәк. Миртимер, әйдә миңа булышырсың.

Дәүләтне алып китәләр.

Миләүшә. Бичара, кул-аяксыз нишләр инде ул ?

Гайшә. Сөйләмә инде, терелсә генә ярар иде.

Арттан әрнеп кычкырган Дәүләт тавышы ишетелә.

Бибкәй. Карагыз әле, Байтирәк абый Дәүләтне чишендергән дә кар белән уа.

Миләүшә. Абау... Карап тора алмыйм...

Гайшә. Бу Байтирәк абый бигрәк тә кансыз кеше икән, бераз гына кызганмый да.

Исәнбай. Менә, егетләр, шәкерт тормышы шул инде ул. Унбиш-егерме ел шушы чүплек базында черегәннән соң, дөньядагы барлык хорафатларны башыбызга җыябыз да тормыш көтәргә, сәләхиятсез, дөньяга яраксыз, рухани гарип кешеләр булып чыгабыз.

Байтирәк, Миртимер керә.

Бибкәй. Байтирәк абый, Дәүләт бик каты өшегәнме?

Байтирәк. Ул кадәр куркынычлы түгел, шулай да тырнаклары төшәргә тиеш.

Миртимер. Мин шуңа аптырыйм, кеше, акчага, юк-бар нәрсәгә комсызланып, үзенең алтыннан кадерле булган тормышына, дөньяда яшәү хокукына хыянәт эшләсен, имеш.

Исәнбай. Безнең бөтен бәлабез дә шунда. Чөнки яхшы белән яманны аңлау тойгыларыбыз хорафат пәрдәләре белән томаланып, сизү тойгыларыбыз ишәк миедәй тупасландырылган. Мин мәет артыннан барганда, шәкертләр өстенә карап уйладым. Бичараларның өстендә бер кат җилән, аякларында табансыз читек, шул көенчә чатнама суыкта мәет күтәреп баралар. Ни өчен?.. Өч тиен бакыр хәмел садакасы яисә мәетне кабергә иңдерү сөлгесе өчен, билдән карга чума-чума, үз тормышын корбан итә. Юк!.. Моннан соң бу сазлыкта кала алмыйм. Миртимер, мин дә сиңа иптәш булам. Кайда булса кешечә яшәүче халыклар арасына китик.

Миртимер. Әйдә, дустым Исәнбай, үлек җаннар базыннан котылыйк.

Байтирәк. Шәкертләр, алыгыз мине дә. Мин дә. Мин дә артык муллада тора алмыйм.

Исәнбай. Әйдә, Байтирәк абый, безнең якка, Урал заводларына эшкә китәбез.

Бибкәй. Абыйлар, алыгыз безне дә, без дә моннан китәбез.

Шау-шу килеп, агач башмакларын шакылдатып, шәкертләр кайтып керә. Кайсы сикергәли, кайсы йөгереп йөри, кайберләре аяккулларын уа, кайберләре,
туңган әгъзаларының әрнүенә чыдаша алмыйча, сыкрап еларга керешә.

Пәрдә төшә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук мәдрәсә эче. Вакыт кич. Пәрдә ачылганда, Фазлый күлмәгенә ямау
салып утыра. Аксак Вәли керә.

Вәли. Фазлыйәхмәт, син ишеттеңме, бүген бездә Миртимер, Исәнбай шәкертләр күңел ачу кичәсе дигән мәзәк ясыйлар икән. Бәетче Бәхтияр, скрипкачы Фәезхан картларны чакырганнар. Аннан тагы теге яңа килгән «кыстыбыйлар» да һөнәрләрен күрсәтәчәкләр, ди.

Фазлый. Ярый, без әзергә һәрвакытта хәзер.

Моратай керә.

Моратай. Сез ишеттегезме: үткән төнне Хуҗәхмәт морҗасыннан убыр чыкканны күргәннәр.

Фазлый. Кит аннан!

Вәли. Кемнән ишеттең?

Моратай. Мажик егетләре аулак өйдән кайтканда күргәннәр. Тубал кадәр ут булып ат зияратына таба очып киткән, ди. Шуның аркасында иртә белән өч хатын бала төшергән, җиде бия колын салган, ди. Шул турыда бүген староста, сотниклар киңәшкәннәр дә җиде җиргә каравыл куярга булганнар. Без дә сакламыйбызмы?

Вәли. Сакларга, сакларга кирәк. Берсенә үзем чыгам.

Миртимер керә.

Миртимер. Вәлиәхмәт, синең такмакка осталык бар, күңел ачу кичәсендә катнашмыйсыңмы?

Вәли. Юк, минем бүген башка мөһим эшләрем бар.

Китәләр. Байтирәк керә.

Байтирәк. Миртимер, эшләр сүтелде, хәзрәт кайтты.

Миртимер. Хәзрәт кайтты?! Нишләп алай вакытсыз?

Байтирәк. Үзем дә аптырап калдым. Шундый ачулы, шундый кайгылы, күрсәң котың очарлык. Беркем белән дә сөйләшми. Кайтты да үз ягына кереп бикләнде. Ярминкәдән бүләк тә, бер әйбер дә алмаган. Бүген кайтканын да кешегә әйтмәскә куша.

Миртимер. Шулай да гаҗәп. Йә ни дә булса ярминкәдә берәр хәл булгандыр.

Байтирәк. Күңел ачу кичәсе белән нишлибез?

Миртимер. Нишлик, шаулатып үткәрәбез.

Байтирәк. Хәзрәт сизеп куймасын, дим.

Миртимер. Сизсә тагы, нигә куркасың?

Байтирәк. Курыкмыйм. Сиңа ачулы, кыйнап ташлавы бар.

Миртимер. Кулын гына тидереп карасын, мулла дип тормам. Безнең өчен хәзер барыбер — иртәгә китәбез. Шулай түгелме?

Байтирәк. Анысы шулаен шулай да.

Миртимер. Шулай булгач, ичмасам, үзебездән соң сагынып сөйләргә бер хатирә калдырыйк.

Артта агач башмаклар тавышы.

Әнә шәкертләр ястүдән чыга, озакламый башлыйбыз. Ләкин син монда хәзрәтнең кайтуын беркемгә дә белдермә.

Шәкертләр керә.

Байтирәк. Исәнбай, нишләп бик озакладыгыз?

Исәнбай. Мәзиннең азан әйткәнен көтеп тордык. Ә ул безнең хәлфәләр белән Тулбай авылына мөназарага киткән икән.

Миртимер. Егетләр, утларны сүндерегез, тәрәзәләрне каплагыз.

Утлар сүнә, тәрәзәләрне иске палас, сәләмә юрган, ашъяулыклар белән каплыйлар. Ут кабынганда, Миртимер җәмәгать сәкесе өстендә басып тора. Калган шәкертләр сәке тирәсенә тезелеп утырган.

Кардәшләр! Күңел ачу кичәбезне башлыйбыз. Беренче булып сезнең алдыгызда Исәнбай сабакташ курайда уйный. Аннан Байтирәк абый әкият сөйләр. Аннан Гайса белән Миңлекәй шәкертләр «Җизнәкәй белән балдызкай» көенә җырларлар. Аннан Вәлишә кордаш кубызда уйнар, аннан камыр бит күрсәтү, аю биетүләр булыр.

Вәли. Чын аюмы?

Миртимер. Юк, үлгән аю. Шулай, кордашлар, башлыйбыз. (*Аска төшеп утыра*.)

Курай тотып, сәкегә Исәнбай чыга.

Исәнбай. Бу көйгә, дуслар, «Шәүрәкәй» диләр.

Уйный, бөтенесе йотлыгып тыңлый.

Әскали. Әйбәт, әйбәт, Исәнбай!
Нигъмәт. Афәрин, бик күңелле булды!
Моратай. Тагын берне уйна инде.
Исәнбай. Монысына «Колый кантон» диләр. (*Уйный.*)
Вәли. Рәхмәт сиңа, Исәнбай.
Фазлый. Бик матур уйнадың, миңа да өйрәтсәң икән.
Сәкегә Байтирәк менә.

Байтирәк. Бер Чистай хәерчесенә: «Нигә болай адәм мәсхәрәсе булып сорашып йөрисең, ичмасам, берәр байга керер идең», — дип әйткәч: «Мин баен-ярлысын тикшереп тормыйм, өй борынча берсен дә калдырмый кереп йөрим»,— дип әйтте, ди.
Фазлый. Шул гынамы?
Байтирәк. Нигә, кызык түгелме?
Фазлый. Кызыгын кызык та, бик кыска.
Байтирәк. Ошый торган булса, тагын сөйләрмен.
Моратай. Сөйлә, сөйлә, озынрак булсын.
Байтирәк. Кан азлыктан интегүче бер чирләч кешегә хайван каны эчәргә кушканнар. Шуннан соң моның хатыны иртәгесен торган да, күрше авылдагы итчегә барып, бер җамаяк үгез каны алып кайткан. Ләкин теге чирләч кеше канны эчми дә эчми бит. Хатын: «Эч, терелерсең, кеше булырсың»,— дип ялына, ләкин тискәре кеше: «Үтерсәң дә эчмим»,— ди икән. Шуннан зәһәр хатынның ачуы чыгып, ирен пешерергә керешә: «Син тискәренең шул булыр инде, гомер буена кирелегең белән җаныма тидең, вакытсыз чәчемне агарттың, болай сүземне тыңламыйсың икән, ичмасам, шулкадәр җиргә җәяү барып кайту кебек авыр хезмәтемне тәкъдир итеп, биргән канымны эчәр идең»,— дип елый ук башлаган. Шуннан соң бичара чирләч ир тирән итеп бер сулаган да: «И хатын, хатын, гомереңбуена зәһәрле телең белән канымны эчеп, как сөяккә калдырмаган булсаң, шулкадәр җиргә сиңа җәяү йөрергә, миңа мәкрүһ канны эчәргә дә туры килмәс иде»,— дип әйтте дә, җамаяк белән үгез канын эчеп тә җибәрде, ди.
Вәли. Кызык, валлаһи, бик кызык.
Моратай. Байтирәк абый, тагын берне сөйлә әле.
Байтирәк. Шулай көннәрнең берендә бер мөрит, ишан хәзрәтнең кулын үбеп кайтканда, безгә кунарга туктады. Вакыт төн иде. Мулла абзыйлар янында чәй эчте дә минем янга, мал өенә йокларга керде. Минем белән бер сүз дә сөйләшмәде. Кичке намазларын укыды да сәндерәгә менеп йокларга ятты. Мин чабата ясарга керештем. Күп тә үтмәде, мөрит гырлый-гырлый йокыга китте. Ә мин җырлый-җырлый чабата кайтарам. Бервакытны әлеге мөрит төшендә диңгез һәм шул диңгез янында басып торучы ишан хәзрәтен күрә. Шуннан мөрит: «Әй, шәйхем, бу нинди диңгез?» — ди. Күп уйлап тормадым, ишан хәзрәт булдым да: «Мәгърифәт диңгезе», — дип җавап кайтардым. Шуннан мөрит: «Хәзрәт, чумыйммы?» — ди. Мин аптырап калдым. Йә шәйхем, чумыйммы?» — дип, бу тагын кычкыра. Мин һаман эндәшмим. «Рөхсәт ит, шәйхем, мәгърифәт диңгезенә чумыйм»,— ди. Шуннан мин: «Чумсаң чум инде»,— дип әйтергә дә өлгермәдем, мөритем башы белән йөзтүбән лап итеп лаканга чумды. (*Сәкедән төшә.*)

Кызлар киеменнән — Гайшә, корымнан сакал-мыек куйган Бибкәй сәкегә чыга. «Җизнәкәй» көенә җырлыйлар.

Гайшә. Бу бармагың ник кәкере, җизнәкәй?
Бибкәй. Көмеш балдак кигәнгә, балдызым, ялгызым.
Гайшә. Бу йөзләрең ник саргайган, җизнәкәй?
Бибкәй. Сине өзелеп сөйгәнгә, балдызым, ялгызым.
Гайшә. Түтәй белсә, ни диярбез, җизнәкәй?
Бибкәй. Курыкма, беркем тоймас, балдызым, ялгызым.
Гайшә. Әем, әем, зур язык бит, җизнәкәй.
Бибкәй. Бер үпкәннән җир упмас, балдызым, ялгызым.

Үбешәләр.

Башкалар. Яшәгез, афәрин.

Сәкедән төшәләр. Кубыз тотып, сәкегә Миләүшә чыга. Берничә көй уйный. Шашкан хәлдә яланбаш Әмирхан, аның артыннан Әбелкарип, Ризван карый керә.

Әбелкарип. Сабыр, карый, бәлфараз, тавышланмыйча гына.
Ризван. Тынычлан, Ходай өчен тынычлан.

Бүлмәләренә китәләр.

Исәнбай. Мөназарага барабыз дип, менә кайда булганнар икән!
Байтирәк. Миртимер, Исәнбай, бире килегез әле. Мин бер әкәмәт ясыйм.
Миртимер. Ничек?
Байтирәк. Хәзер өйгә кайтам да хәзрәтне китерәм.
Исәнбай. Кирәкми, әләкчелек була бит.
Миртимер. Бер дә түгел. Шәкертләр өстеннән бөтен кабахәтлекне шулар эшләп ята бит. Әйдә, аларның кем икәнлекләрен үз күзләре белән күреп дуласын. Бар, Байтирәк абый.

Байтирәк китә. Күлмәксез килеш Әмирхан керә.

Әмирхан. Җибәрегез, тотмагыз мине. (*Хәлфәләрне селтәп җибәрә.*)
Миртимер. Яхшы түгел, карый әфәнде, кыяфәтеңне кара.
Әмирхан. Синең миндә ни эшең бар, ганка, сафсата, мажик баласы, сасык!
Миртимер. Җикеренмә, карый, куркыта алмассың!
Әмирхан. Үтерәм мин сине. Син үлгәннән Аллага да, муллага да зыян юк. Җир йөзендә бер хәсис кимер. Ә сез нигә миңа карап торасыз?
Бибкәйне тота.

Бибкәй. Җибәр, карый абзый, авырттырасың.
Миртимер. Яхшылыкның кадерен белмәдең.

Әмирханны тотып ала да идәнгә сузып сала.

Исәнбай, булыш миңа, хәзер айнытабыз, чәчен уыгыз.

Уалар.

Әмирхан. Каравыл, үтерәләр!
Миләүшә. Хәзрәт килә!

Шәйхезаман белән Байтирәк керә.

Шәйхезаман. Бу нинди шайтан туе? Бу нинди иблис өмәсе?
Байтирәк. Менә, хәзрәткәем, күр: эчеп кайтканнар.
Шәйхезаман. Тегеләре кайда соң?
Исәнбай. Бүлмәләрендә җырлап утыралар.
Шәйхезаман (*өсләрен салып ташлый*). Ят, сасык!
Әмирхан. Тәкъсир...
Шәйхезаман. Тотынма, нәҗес, ят, диләр сиңа!

Әмирхан ята, Шәйхезаман камчы белән чаж-чож суга.

Алыгыз, теге үләксәләрен китерегез...

Әбелкарип белән Ризван Шәйхезаман алдына килеп авалар.

Әбелкарип. Кичер, хәзрәт.
Ризван. Гафу, тәкъсир...
Шәйхезаман. Кайда эчтегез?

Эндәшмиләр.

Мин сездән сорыйм, кемдә эчтегез?
Әбелкарип. Шәмгун мәзиндә.
Шәйхезаман. Шәмгун мәзиндә? Ах ул кәҗә сакал, утын карагы! Табып китерегез миңа ул әбуләһәпне!
Байтирәк. Бар, Миңлекәй, чакырып китерегез.
Бибкәй. Вәлишә, Гайса, әйдәгез!

Китәләр.
Шәйхезаман. Ятыгыз, хәсисләр!

Әбелкарип, Ризван сузылып яталар.

Байтирәк, мә камчы! Кызганмыйча сук шул явызларны! Никадәр каты суксаң, шулкадәр савабы күп булыр.

Байтирәк. Хәзрәт, әллә хәзергә калдырып торасызмы?

Шәйхезаман. Нәрсә? Син аларны кызганырга уйлыйсыңмы?

Байтирәк. Юк, хәзрәткәем. Боларны кызганырга ярыймы соң? Киресенчә, икенче кат эшләмәслек итеп үзәкләренә үткәреп сугарга иде, ләкин, күрәсең, гырылдап йокыга киттеләр. Боларга хәзер камчы түгел, бүрәнә бастырсаң да сизмәсләр. Без аларны иртәгә, айныгач сугарбыз.

Шәйхезаман. Дөрес, улым Байтирәк. Күземә күрсәтмәгез. Бүлмәләренә кертеп ташлагыз.

Сөйрәп китәләр.

Миртимер. Менә, хәзрәт, күрдегезме? Сезнең мактаулы шәкертләрегез нишләделәр? Мәдрәсәгезнең данын, абруегызның намын пычраттылар.

Шәйхезаман. Әйе, әйе, синең сүзләрең дөрес. Ул хәясызлар булган ышанычымны аяк асларына салып таптадылар.

Вәли керә.

Вәли. Хәзрәт, бер кеше килгән, сезне күрергә тели.

Шәйхезаман. Мондый вакытсыз чакта нинди кеше ул?

Вәли. Юлаучы бугай.

Шәйхезаман. Әйтегез, керсен.

Вәли китә. Ястык, мендәр, комган, самавыр күтәреп, Гыйлемдар керә.

Гыйлемдар. Әссәламегаләйкем!

Шәйхезаман. Вәгаләйкемәссәлам. Сез кайдан, мосафирмы, мөһаҗирме, әфәндем?

Гыйлемдар. Без ерактан, тәкъсир, Казан каласыннан. Сез могтәбәрдә гыйльме тәхсил итәргә килдек.

Шәйхезаман. Бәрәкалла. Кайда, нинди зат шәрифләрдә укыдыгыз?

Гыйлемдар. Күл буе Сөләйман хәзрәт мәдрәсәсендә укый идем. Ләкин андагы тәртип, низам, әхлак кагыйдәләре белән килешә алмадым. Чөнки мин үзем мантыйк хан.

Шәйхезаман. Ата-аналарыгыз исәннәрме?

Гыйлемдар. Анам сау-сәламәт, атам, мин кечкенә чакта, хаҗ сәфәреннән кайткан чакта юлда үлеп, шәһит булган.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, изге җаннардан икән.

Гыйлемдар. Сезнең дан-шөһрәтегез, шанлы мәгърифәтегез бөтен Русия туфрагына таралган. Сез җәнабегалиләрдән дәрес алу шәрәфенә ирешсәм, үземне иң бәхетле коллардан санар идем.

Шәйхезаман. Иншалла, морадыгызга ирешәчәксез. Сезнең кебек гыйлем иясе булган кешеләргә ишекләрем һәрвакытта ачык.

Бибкәй, Миләүшә, Гайшә керәләр.

Бибкәй. Хәзрәт, мәзин абзыйның ишеген кактык-кактык, ачучы булмады.

Шәйхезаман. Ярый. Кайтышлый ул сарыйкка үзем керермен. Барыгыз, йоклагыз.

Кызлар китә башлыйлар. Гыйлемдар Бибкәйгә барып ябыша.

Гыйлемдар. Туктагыз!

Бибкәй. Җибәр мине, нигә тотасың?

Гыйлемдар. Качмагыз, барыбер котыла алмассыз!

Шәйхезаман. Әфәндем, нигә ул шәкертләрне борчыйсыз?

Гыйлемдар. Хәзрәт, алар шәкертләр түгел, хиҗапсыз кызлар.

Шәйхезаман. Кызлар? Әфәндем, әллә сез акылдан яздыгызмы?

Гыйлемдар. Ышаныгыз, хәзрәт, алар өчесе дә кызлар.

Шәйхезаман. Сез аларны кайдан беләсез?

Гыйлемдар. Бездә асраулыкта торалар иде. Әнкәйнең алтын-көмешләрен урлап качтылар.

Байтирәк. Ышанма, хәзрәт, тилебәрән орлыгы ашаган җүләргә, ышанма, хәзрәт. (*Кызларга китәргә ымлый*.)

Шәйхезаман. Юк, юк, ышанмыйм, чөнки бу мөмкин түгел.

Гыйлемдар. Тикшереп карагыз, минем сүзләремнең дөреслеген белерсез.

Вәли. Чыннан да, хәзрәт, мәхдүмнең сүзләре дөрес булырга кирәк. Чөнки мин дә алардан шикләнеп йөри идем.

Шәйхезаман. Кая, өчесен дә минем каршыма китерегез.

Вәли. Хәзер була, хәзрәткәем.

Бер төркем шәкертләрне ияртеп китә.

Байтирәк. Юкка мәшәкатьләнәсең, хәзрәт. Кызмы, егетме икәнлекләрен мин бик яхшы беләм инде. Тирес түккәндә, минем белән мал өендә кундылар, ышанма ул карачкыга.

Шәйхезаман. Шулай да тикшереп карыйк әле.

Бибкәй, Миләүшә, Гайшәне тотып кертәләр.

Вәли. Качып баралар иде. Мәчет капкасы төбендә куып тоттык.

Шәйхезаман. Үз телегездән икърар итегез, сез егетләрме, кызлармы?

Бибкәй. Ышаныгыз, хәзрәт, егетләр.

Гыйлемдар. Ялган, хәзрәт, валлаһи ялган. Коръән алып ант итәм.

Вәли. Хәзрәт, нәрсәгә алар белән сатулашып торырга. Тотарга да чишендереп карарга кирәк.

Шәйхезаман. Рөхсәт, карагыз. Әй, юк, үзем карыйм. Әйдә, бүлмәгә кертегез.

Байтирәк. Хәзрәт, сабыр итегез. Алай эшләү әдәпсезлек була бит, абыстайдан яхшы түгел. Кызмы, егетме икәнлекләрен башкача да белергә була. Менә алыйк, ирләрнең бугазларында төерләре була, хатын-кызларда ул булмый. Шулай гына карагыз.

Шәйхезаман. Дөрес әйтәсең, улым Байтирәк. Кая, китерегез, бугазларын карыйм.

Шәйхезаман каршысына кызларны китереп бастыралар.
Берәм-берәм карап чыга.

Әйе, җәмәгать, мәхдүмнең сүзләре дөрес, өчесе дә кызлар.

Башкалар. Кызлар?

Шәйхезаман. Йа Ходай, нинди гөнаһ-шомлыкларым аркасында бу афәтләрне миңа җибәрдең? Сез миңа әйтегез, ни өчен мине рисвай галәм ясап, мәдрәсәмнең данын пычраттыгыз? Ни өчен сез Алла каршында шундый җинаятьләр эшләп тә кыямәт гөнаһлы булдыгыз? Оят пәрдәләрегезне йөзегездән ташлап, бөтен мөселман дөньясына мәсхәрә булырга, пигамбәребезнең шәфәгатеннән мәхрүм калырга нәрсә сезне мәҗбүр итте?

Миләүшә. Сез мәҗбүр иттегез.

Барысы. Без?

Бибкәй. Әйе, сез! Кешелекнең матур сыйфаты булган кызлыгыбыздан ваз кичәргә сез мәҗбүр иттегез! Бишектән алып буйга җиткәнчегә кадәр, гореф-гадәт йолалары белән богаулап, гыйлем өйрәнү хокукларыбыздан мәхрүм иттегез! Унбер яшебездән йөзебезгә пәрдә ябып, үз гаиләбездә генә булса да өстәл янында ашаудан тыеп, песи җамаягы белән чаршау эченә кудыгыз, һәрбер начарлыкның сыйфатына хатын-кызны тиңләп, «чәче озын, акылы кыска» дигән хурлык билгесен тактыгыз! Хәтта килен булып төшкәч тә, җиде ел килен камзулы кидереп, биатай, бианай кебек иң якыннарыбыздан да тел яшерергә киңәш бирдегез! Теләгән чагыгызда бездән көләргә, теләгән кадәр гыйффәтебезне җуярга, теләгән кадәр өстебездән көндәш алырга, - сөяркәләр тотарга дин исеменнән фәтва бирдегез! Ул гына да түгел, үлгәннән соң да тынычлык бирмичә, үле гәүдәбезне хурлап, өч кат кәфен сарырга, кабер өстебезгә имән казык кагарга сез куштыгыз!

Шәйхезаман. Җитәр, оятсыз!

Миләүшә. Юк, җитмәсен! Әйт, Бибкәй, алар үзләре бит дөньядагы барлык кабахәтлекне эчләренә җыйнап, халык арасына фахишлек таратып яталар, алар үзләре бит...

Шәйхезаман. Тукта, дим, хиҗапсыз! Сугып үтермәс борын күз алдымнан алыгыз! Алыгыз да, бөтен авыл халкын уятып, урам буенча йөртегез.

Вәли. Әйдәгез, тотыгыз!

Байтирәк. Туктагыз! Хәзрәт, хәзер бик соң инде. Халыкны уятып борчымыйк, бүгенгә мәчет астындагы бүлмәләргә генә ябып куйыйк, иртәгә җыен җыйдырып, халыкка белдерербез. (*Гайрәт белән.*) Ул динсез кафирәләрне шәригать кануннары белән хөкем итәрбез.

Исәнбай. Әйе, әйе, хәзрәт. Байтирәк абый дөрес әйтә. Сез ни диярсез тагы?

Шәйхезаман. Минемчә дә шулай эшләү мәслихәт булыр. Мәчет астындагы бүлмәләргә аерым-аерым ябарга кирәк. Әйдәгез, кызларны шунда илтегез!..

Шаулашып, кызларны алып китәләр.

Пәрдә төшә.

**ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ**

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Мәчет алды. Тышкы ишектән кергәч, ике якка менеп китә торган киң баскычлар. Югары катта мәчет ишеге күренә. Ишекнең бер ягында манарага менә торган тар баскыч. Аскы катта мәчет астына керә торган берничә башмак бүлмәләре һәм ишекләр. Пәрдә ачылганда, шаулашып кызларны кертәләр, бүлмәләргә ябып
куялар.

Исәнбай. Хәзрәт, боларны каравылларга кешеләр куярга кирәк булыр.

Вәли. Хәзрәт, миңа тапшырыгыз, үзем саклармын.

Шәйхезаман. Юк, Вәлиәхмәт. Ул мәлгуньләрне минем туры хезмәтчем Байтирәк саклар. Исәнбай белән Миртимерләр ярдәмче булырлар. Син, Вәлиәхмәт староста, сотник абыйларыңа барырсың, справникны чакыртсын, ишан хәзрәтне алырга ат җибәрерсең. Иртә намаздан чыгуга хөкем итәрбез.

Вәли. Ярый, хәзрәт. (*Китә.*)

Шәйхезаман. Улым, Байтирәк, бу тирәдә беркемне дә калдырма. Берсен дә яннарына җибәрмә.

Байтирәк. Яхшы, хәзрәткәем. Шәкертләр, таралыгыз! Берегез дә монда калмагыз, барыгыз, бар, йоклагыз. (*Шәйхезаманнан башкаларны куып чыгара.*)

Шәйхезаман. Байтирәк, өсләреннән йозак белән бикләп ал, ачкычларын миңа бирерсең.

Байтирәк. Алай эшләү ярап бетәр микән, хәзрәт? Нигә дисәң, иртә беләнгә кадәр тышка йөриселәре булыр. Үзең әйткәндәй, болар кебек динсез кафирәләрдән изге йортыбызны хәдәсләтеп булмас.

Шәйхезаман. Анысы дөрес, улым Байтирәк. Ярый алайса, ачкычларны үзеңдә сакла. Тик, зинһар өчен, йоклый күрмә, беркемне дә яннарына җибәрмә.

Байтирәк. Тыныч бул, хәзрәт, мин барында бер кеше дә якын килә алмас.

Шәйхезаман. Ярый, улым, Аллага тапшырдык, мин китим.

Байтирәк. Бар, хәзрәт, бар. Туңа күрмә, тышта бик салкын, авыз-борыныңны урарга шарф биримме?

Шәйхезаман. Кирәкми, рәхмәт, улым.

Байтирәк Шәйхезаманны озата. Миртимер белән Исәнбай керә.

Миртимер. Байтирәк абый, кызлар харап булды бит.

Исәнбай. Нишлибез?

Байтирәк. Куркырлык бернәрсә дә юк. Үзебезнең кулда бит. Барыгыз, Бәхтияр бабайны уятыгыз. Ничек кенә булса да бер-ике олау әзерләсен. Кызларны алабыз да моннан качабыз.

Исәнбай. Әйдә, Миртимер!

Миртимер. Әйдә, Исәнбай.

Йөгереп китәләр.

Пәрдә төшә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук Байтирәк сакта тора. Исәнбай, баскычка утырып, әкрен генә курайда уйный. Шул көйгә кушылып, аста Гайшәнең җырлаганы ишетелә.

Байтирәк. Җитәр инде, Исәнбай, эчне пошырма, йә хәзрәт килеп чыгар.

Исәнбай. Күңелсез бит. Ичмасам, Миртимер дә кайтмыйдыр.

Байтирәк. Нишләп кенә калды соң?

Исәнбай. Әйтәм бит инде, Бәхтияр бабай белән күрше урыс авылына, ямщик эзләргә киттеләр.

Байтирәк. Алай булгач, нишләп торалар?

Исәнбай. Мин кайдан белим.

Байтирәк. Шәкертләр йоклап бетте. Авылда да ут әсәре калмады. Исәнбай, минем күңелем тынычланмый, Бәхтияр бабайларга бар, кайтмадылармы икән?

Исәнбай. Ярый, мин киттем алайса.

Байтирәк. Бар, зинһар өчен, тизрәк кайтырга тырыш.

Исәнбай. Хәзер, бер аягым монда, икенчесе тегендә булыр.

Китә. Байтирәк озата чыга. Мөнәҗәт әйтеп, Шәйхезаман керә.

Шәйхезаман. Сәхәр тормак гыйбадәттер,
Сәхәр тормак сәгадәттер,
Сәхәр тормак гыйнаятьтер,
Сәхәр тормакны гадәт кыл.

Тышта шулкадәр буран, күз ачарлык та түгел. Шулай да никтер күңел монда ашкына.

Байтирәк. Кем ул анда йөри? Хәзер бәреп үтерәм!

Шәйхезаман. Чү, улым Байтирәк, бу мин.

Байтирәк. Ә, хәзрәт икән. Нишләп киләсе булдыгыз?

Шәйхезаман. Бу мәгъюбәләр Алла каршында зур гөнаһлы булсалар да, җан иясе бәндәләре бит. Усал күңелле кешеләрдән саклау минем изге бурычым. Шәкерт халкы йөрмиме?

Байтирәк. Бар да йоклыйлар, тик Әбелкарип хәлфәләр генә ятмыйлар.

Шәйхезаман. Ни эшләре бар икән?

Байтирәк. Аларның күңеле, хәзрәт, яхшылыкта түгел. Кызлар янына керергә тәмгыларын тәртә буе сузып йөриләр.

Шәйхезаман. Ах, үләксәләр! Шушы көнгә кадәр мин аларның начарлыкларын ничек сизмәдем икән соң? Син нәрсә дидең?

Байтирәк. Башта яхшылап әйтеп карадым, тыңламадылар. «Хәзрәткә барып әйтәм» дип кенә куркытып чыгардым.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, яхшы иткәнсең! Әгәр дә яңадан килә калсалар, аякларына күсәк белән сук! Икенче кат бозыклык артыннан йөрмәслек булсын. Улым, зинһар өчен, кызларны яхшы сакла! Дөнья-ахирәт җаваплылык синең белән минем өстә бит.

Байтирәк. Юк, юк, хәзрәт. Син бит мине яхшы беләсең. Кайчан сиңа хыянәт иткәнем бар?

Шәйхезаман. Ансы дөрес, улым, син — минем туры хезмәтчем. Әле бүген истихара намазын укып бетергәннән соң да синең турыда уйладым. Байморат коткысына ияреп, сине Минзәлә ярминкәсенә алып бармый хәтереңне калдырдым. Туры хезмәт итүеңне искә алып, көзгә еллар имин булса, игеннәр уңып, гошерләр мул булса, фитыр садакалары, корбан тиреләре күп керсә, үзеңә берәр мажик кызын хәләл җефетлеккә алып бирергә булдым.

Байтирәк. Рәхмәт инде, хәзрәткәем, рәхмәт.

Шәйхезаман. Улым, Байтирәк, бире кил әле. (*Читкә алып китә.*) Мин ярминкәдә чакта безнең авылда убыр күргәннәр. Убыр, әлбәттә, хатын-кыз җенесеннән була. Ул убыр шушы мәлгунәләрнең берәрсе түгел микән?

Байтирәк. Әйтә алмыйм, хәзрәткәем.

Шәйхезаман. Убырлы кешенең баш түбәсе тишек була икән. Шуның өчен мин аларның яннарына кереп, башларындагы убыр тишекләрен карарга уйлыйм.

Байтирәк. Нигә яннарына керергә, хәзрәткәем, хәзер үзләрен монда чыгарыйк та икәүләп карыйк.

Шәйхезаман. Юк шул, улым Байтирәк, көн яктысында, шулай ук төн яктысында да ул каһәр күренми икән. Аны күрү өчен караңгы һәм аулак булу кирәк, ди китап.

Байтирәк. Кара син аны, Ходайның хикмәте.

Шәйхезаман. Мин ул мәлгунәләрнең олысыннан шикләнәм. Шуның өчен аның янына кереп, баш түбәсендәге убыр тишеген карарга уйлыйм. Син ни дисең?

Байтирәк. Синең теләгеңә каршы бара алмыйм, хәзрәт. Хуҗа әмеренә буйсыну — минем изге бурычым. Тик хәзер түгел, кеше аяк эзе басылгач, беренче әтәч кычкыргач килерсең.

Шәйхезаман. Шулай дисеңме?

Байтирәк. Әйе, шулай дим. Безнең шәкерт халкын беләсең, күңелендә тузан кадәр яман ният булмаса да, әллә нәрсә уйлаулары бар. Шулай, хәзрәт, беренче әтәч кычкыргач, ипләп кенә килерсең дә мин сине кыз янына кертермен.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, рәхмәт. Беренче әтәч кычкыргач дисең алайса?

Байтирәк. Әйе, хәзрәт, беренче әтәч кычкыргач та мин сине зөфаф кичәсенә кертермен.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, хи-хи-хи... Мал иясенә охшый, диләр, бик дөрес икән. Хуҗаңның ни теләгәнен сизәсең. Мә, әҗерен хәзер үк биреп куйыйм.

Байтирәк. Кирәкми, хәзрәт, кирәкми.

Шәйхезаман. Ал, берәр җиреңә ярап куяр.

Байтирәк. Рәхмәт, хәзрәт. Син, булмаса, менә монда мәчеткә генә кереп тор. Вакыт җиткәч, чакырып алырмын.

Шәйхезаман. Бәрәкалла, бигрәк тә яхшы булыр. Беренче әтәч кычкыргач дисеңме?

Байтирәк. Әйе, хәзрәткәем, беренче әтәч кычкыргач кыз янында булырсың...

Шәйхезаман. Бәрәкалла, хи-хи-хи... (*Мәчеткә кереп китә.*)

Байтирәк. Мин сиңа шундый убыр тишеге күрсәтермен әле, ялчы Байтирәкне гүреңә кадәр оныта алмассың!

Әбелкарип, Ризван, Әмирхан керә.

Әбелкарип. Байтирәк, Байтирәк, дим.

Байтирәк. Кем ул?

Әбелкарип. Бу без идек.

Байтирәк. Нишләп тагы йөрисез?
Әбелкарип. Без шундый карарга килдек.
Ризван. Ул карар катгый карар.
Әмирхан. Аны һичкем боза алмас.
Байтирәк. Әкрен, карый, тавышыгыз гөбедән чыккандай яңгырый.
Ризван. Без, кызларга өйләнеп, савабы-җария эшләмәкче булдык. Бәс, шулай булгач, бу каһәр төшкән хәзрәт мәдрәсәсеннән китәбез.
Байтирәк. Ниятегез яхшы, Алла ярдәм бирсен.
Әбелкарип. Ләкин шулкадәресе бар: ул кызлар риза булырлар микән?
Байтирәк. Ник булмасыннар. Берегез атаклы хәлфә, икенчегез данлыклы казый, өченчегез булса мәһабәт карый. Минемчә, һичсүзсез риза булырлар. Тик мин сездән шуны сорарга тиеш: сез чынлап та хәләл җефетлеккә дисезме йә булмаса алай-болай күңел ачарга гына уйлыйсызмы?
Әбелкарип. Бәлфараз, күңелләребезне тапсалар, холык яклары белән охшап куйсалар, һичшиксез өйләнәчәкбез.
Ризван. Анысын алдан ук вәгъдә биреп булмый инде, мулла Әбелкарип Тамбурый. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда, күз күрер. Бәс, шулай булгач, хәзерге теләгебез алар белән аерым-аерым сөйләшү...
Әмирхан. Әйе, әйе, ата-аналарын, кардәш-ыруларын сорашудан гыйбарәт булачак. Аңладыңмы?
Байтирәк. Әйе, аңладым, бик яхшы аңладым. Ярый, мин алар белән сөйләшеп карармын.
Әбелкарип. Һай, рәхмәт. (*Аркасыннан кагып.*) Уңган егет бит ул безнең Байтирәк.
Ризван. Шул эшне безнең файдага башкарып чыгарсаң, аяк-кул күчтәнәчен дә бирербез.
Байтирәк. Анысы кирәкми, сезнең өчен күчтәнәчсез дә эшләрмен.
Әмирхан. Юк, юк, коры кашык авызны ерта, дигән бабайлар. Күчтәнәчнең мулын алырсың.
Байтирәк. Кемнәрдер килә, хәзрәт булмасын. Барыгыз, икенче әтәч кычкыргач монда булырсыз.
Әбелкарип. Ярый, ярый. Хәзергә хуш.
Байтирәк. Хуш, хәлфәләр, хуш.
Әмирхан. Икенче әтәчтән соң, дисең алайса?
Байтирәк. Әйе, икенче әтәчтән соң кызлар янына кертермен.
Әбелкарип. Һай, рәхмәт синең һимматеңә, хи-хи-хи ...

Китәләр. Икенче яктан Исәнбай белән Миртимер керә.

Исәнбай. Байтирәк, булды, малай.
Байтирәк. Чынлап тамы?
Миртимер. Бик шәп ике пар ат яллладык, озакламыйча килергә булдылар. Ләкин ямщикләргә акча җитми, кайдан алырбыз икән?
Байтирәк. Кайгырма, рәт чыгарга тора. Сез хәзер шыпырт кына барып абыстайны уятыгыз да монда алып килегез.
Исәнбай. Абыстайны? Нәрсәгә ул?
Байтирәк. Искиткеч хәйлә тозагы корам.
Миртимер. Нинди тозак?
Байтирәк. Ансын соңыннан белерсез. Хәзергә абыстай янына барыгыз да: «Мулла абзый, Әбелкарип, Ризван казый, Әмирхан карыйлар кызлар янына керергә йөриләр»,— диегез.
Миртимер. Хәзрәт сизмәсме?
Байтирәк. Нишләп сизсен, ул карт бүре хәзер минем капкында.
Миртимер. Ничек капкында?
Байтирәк. Әйттем бит, соңыннан сөйләрмен, дип. Зинһар өчен, барыгыз ...

Исәнбай Миртимерләрне озата. Икенче яктан Байморат белән
Шәмгун керә.

Байморат. Нихәл, Байтирәк, йокы килмиме?
Байтирәк. Килсә нишлисең. Хезмәтең шул булгач, түзәсең инде.
Шәмгун. Хәзрәт биредә булмадымы?
Байтирәк. Булды, хәзер мәчеттә истихара намазында.
Шәмгун. Шулаймыни?
Байморат. Байтирәк, без сиңа бик кечкенә бер йомыш белән килгән идек.
Байтирәк. Нинди йомыш, Байморат абзый? Сез дигәндә, аяк идәндә.
Байморат. Үзең беләсең, Мәфтуха җиңгәң тузды, таушалды, ир күңелен таба алмый башлады. Шулай ук мәзиннең дә хатыны картайган. Без шул турыда мәзин белән сөйләштек тә, Аллага тапшырып, теге кызларга өйләнергә булдык.
Шәмгун. Әрәм булмасыннар, ни әйтсәң дә үзебезнең мөселманнар бит.

Байтирәк. Хәзрәт белән сөйләшеп карагыз, ул рөхсәт итсә, мин каршы килмим.
Шәмгун. Ансы шулай. Ләкин бу эштә ике якның да риза булулары кирәк, ди китап. Шуның өчен дә без башта кызларның  үзләре белән сөйләшеп, аннан соң гына хәзрәткә әйтергә булган идек.
Байтирәк. Юк, башта хәзрәт белән сөйләшегез. Беләсез, мин аның туры хезмәтчесе.
Байморат. Курыкма, без сине буш итмәбез.
Шәмгун. Әйе, әйе, Байморат андый эшкә хирыс кеше, иншалла, акча кызганмас.
Байтирәк. Белмим шул, хуҗама хыянәт итү ярар микән.
Байморат. Аңа шул таман булыр, яхшылыкны белә торган кеше түгел ул. Кадер-хөрмәт күрсәтеп, атыма утыртып ярминкәгә алып бардым, тәтәйләргә кереп акчаларын алдырды да миңа бәйләнә башлады. Мә ал, без яшь кәләшле булыйк, син акчалы бул.
Байтирәк. Ярый инде, хәерле булсын. Өченче әтәчтән соң килерсез.
Байморат. Бик озак... Нигә инде хәзер үк түгел?
Байтирәк. Хәзрәтнең килеп чыгуы бар. Беләсез бит аның гадәтен.
Шәмгун. Ансы дөрес инде, бернәрсә булса, котырган гыйфрит кебек өскә ташлана.
Байморат (*сәгатен карап*). Шулай да шактый көтәргә туры килә бит.
Шәмгун. Нишлисең, көртлек әйткәндәй, бер төн икән, түзәрбез инде.
Байморат. Кара әле, Байтирәк, кызлар — өчәү, без икәү генә, өченчесенең көнләшүе, күңеле калуы бар. Өченчегә яңа килгән Казан шәкертен алсак ничек булыр икән?
Байтирәк. Алыгыз, бик әйбәт булыр.
Байморат. Һай рәхмәт, энем, яхшы егет икәнсең. Әйдә, мәзин...
Байморат. Өченче әтәчтән соң, диденме әле?
Байтирәк. Әйе, өченче әтәчтән соң кызлар янында булырсыз.
Шәмгун. Хи-хи-хи...

Китәләр. Байтирәк кызларны ачып чыгара.

Байтирәк. Җанкисәкләрем, әйдәгез.
Бибкәй. Кая?
Байтирәк. Ансын баргач белерсез.
Миләүшә. Без беркая да бармыйбыз!
Гайшә. Без үлсәк тә моннан китмибез!
Байтирәк. Мин бит сезгә яхшылыкка әйтәм.
Бибкәй. Их, Байтирәк абый, мин сине болай булырсың дип уйламаган идем.
Миләүшә. Ләкин ялгышасың, барыбер морадыңа ирешә алмассың.
Байтирәк. Туктагыз әле, нигә миңа ачуланасыз?
Гайшә. Ярый инде, икейөзле булып кыланма, без барсын да ишетеп тордык.
Бибкәй. Җыен кабахәт, хәшәрәтләрдән акча алып безнең намусыбызны сатарга уйлыйсың, ләкин ул булмас... Без — хатын-кызларның хокукларын дауларга чыккан кызлар, без барыбер сезгә бирешмәбез.
Миләүшә. Яныбызга килеп кенә карасыннар, бугазларын чәйнәп өзәрбез.
Гайшә. Эчләрен тибеп агызырбыз, тырнакларыбыз белән күзләрен казып чыгарырбыз!
Байтирәк. Хай-хай-хай... Их, кызлар... Ит яхшылык, көт явызлык дигәндәй булды бу. Сезнең өчен акча алуларым, сезне яманатлы итеп күрсәтергә тырышуларым бар да хәйлә генә, бар да сезне коткару өчен генә...
Без сезне җаныбыз-тәнебез белән менә шушы үрмәкүч тозагыннан, иртәгә булачак дәһшәтле хөкем тырнагыннан коткарырга йөрибез. Сез курыкмагыз, бөтен чаралар күрелгән, озакламый атлар килеп җитәчәк. Шул атларга утырырбыз да әйдә!..
Гайшә. Арттан куа чыгып, тотып алсалар?
Байтирәк. Тота алмаслар, мин аларны шундый хәйлә җепләре белән чорныйм, мең башлы дию, хәйләкәр гыйфрит үзе дә чишә алмас. Мин аларны шундый кеше көлкесе ясыйм, ялчы Байтирәкне балаларының балаларына кадәр оныта алмаслар.
Бибкәй. Мин моңа кадәр муллаларга, дин башлыкларына ышанып, хөрмәт йөзе белән карый идем. Бая сөйләгән сүзләрен ишеткәч, исем дә, акылым да китте.
Байтирәк. Мин дә шулай идем. Ә менә муллаларда ялчы булып хезмәт итү дәверемдә аларны шулкадәр өйрәндем, сезгә генә түгел, бөтен дөньядагы кешеләргә сабак бирерлек тәҗрибәм бар. Аларда Алла да, иман да, оят та юк. Бары тик хәйлә дә алдау, үз корсакларын тутыру гына. Ярый, кызлар, сүзгә мавыгып оныта язганмын. Әйдәгез, җанкисәкләрем, манарага менегез.
Бибкәй. Манарага?
Миләүшә. Анда нигә?
Байтирәк. Ансын төпченмәгез, әйдәгез, менегез.
Гайшә. Менмибез, анда суык җил.

Байтирәк. Бераз түзәрсез.

Миләүшә. Монда гына торсак ярамыймы?

Байтирәк. Ярамый шул! Озакламый бу бүлмәләргә абыстай һәм очраган бер ирнең муенына сарылырга йөргән мәхдүмәләр белән сасы кәҗә тәкәләрен ябам. Чү! Аяк тавышы килә, тизрәк менегез.

Кызлар манарага менеп китәләр. Өч кызын ияртеп, Җомабикә керә.

Җомабикә. Кайда ул карт иблис?

Зөлкагыйдә. Кайда ул өтелгән ата каз?

Зөлсәгыйдә. Кайда ул бетле торна?

Зөлхәмидә. Кайда ул корчаңгы тәкә?

Байтирәк. Тавышланмагыз, бөтен эшне харап итәсез.

Җомабикә. Әйт, Байтирәк, башкорт Исәнбайның сүзләре дөресме?

Байтирәк. Бәхетсезлеккә каршы, дөрес, абыстай. Сезне алырга мин җибәрдем. Аларның күңеле теге кызларга төшкән, сезгә хыянәт итәргә телиләр.

Җомабикә. Ах, мин ул карт ишәкне, тубырлы алашаны!

Зөлкагыйдә. Кем талаша?

Җомабикә. Алаша, дим, ишетмәсәң тик кенә тор! Әйтәм аны сакал-мыекларын кыскартып, яңа күлмәк-ыштаннар киеп, купшыланып чыгып китте. Байморат байларга барам, имеш. Аның нияте менә кайда икән! Үзе кайда соң, әллә кызлар янындамы?

Байтирәк. Мәчеттә, качып тора. Беренче этәче кычкыруга, монда төшәчәк.

Җомабикә. Ах, карт иблис, тукта, сакалыннан өстерәп төшерим әле!

Байтирәк. Алай ярамый, абыстай, бөтен эшне харап итәсең. Алар сезгә мәкерле рәвештә хыянәт итәргә, намусыгыздан көләргә телиләр икән, сез дә алардан хатын-кызларча, үткен акыл белән үч алырга тиешсез. Шуның өчен дөньяда булмаган гыйбрәтле хәйлә табарга кирәк.

Җомабикә. Бу минутта минем йөрәгемдә ачудан башка бернәрсә дә юк.

Байтирәк. Мин сезнең хәлне аңлыйм, абыстай, бу хурлыкка кеше түгел таш та чыдамас иде. Туры хезмәтчегез өйрәткән хәйләне кабул итәргә гарьләнмәсәгез, миндә бер хәйлә кисәге бар барын.

Җомабикә. Сөйлә, Байтирәк, нинди хәйлә ул?

Байтирәк. Сез хәзер һәркайсыгыз, аерым-аерым булып, шушы бүлмәләргә керәсез.

Җомабикә. Анда нишләргә?

Байтирәк. Бернәрсә дә эшләмисез, аларның килгәннәрен сабырлык белән көтеп торасыз.

Җомабикә. Шуннан ни була?

Байтирәк. Шуннан әкрен генә атлап поса-поса гына кияүләр килә, ә мин аларның килгән берсен сезнең янга ябып торам.

Зөлсәгыйдә. Әнкәй, бу чынлап та кызык була икән.

Зөлхәмидә. Аннан нишләргә?

Байтирәк. Нишләргә икәнен анда үзегез карарсыз инде. Менә шулай эшләгәндә, каракны өстендә тоткан буласыз.

Җомабикә. Әйбәт хәйлә, уйлап табуыңа рәхмәт. Мә, тугрылыгың өчен күчтәнәч.

Байтирәк. Кирәкмәс, абыстай, мин бит күчтәнәч алыр өчен эшләмим.

Кызлар. Ал, ал. Байтирәк абый, бездән дә ал.

Байтирәк. Ярар инде, берәр ятим балага бирермен. Әйдә, абыстай, бүлмәләргә керегез.

Җомабикә. Хәзер үкме?

Байтирәк. Билгеле, хәзер үк. Озакламый, беренче этәч кычкыруга, яшь кияүләр килеп җитәчәк.

Зөлсәгыйдә. Байтирәк абый, теге уйнашчы кызлар кайда соң?

Байтирәк. Мин ул кафирәләрне мәчет астына яптым.

Этәч тавышы.

Әтәч кычкыра. Тизрәк керегез.

Һәркайсы бүлмәләргә аерым-аерым керәләр. Байтирәк өсләреннән бикләп ала, Шәйхезаман мәчеттән чыга.

Шәйхезаман. Әтәчләре дә бүген дөмекте, кычкырмый да кычкырмый, көтә-көтә аптырап беттем. Улым Байтирәк, мин бая бик зәһәрле хатын-кыз тавышы ишеттем, абыстаң килмәгәндер бит?

Байтирәк. Юк, хәзрәт, килмәде.

Шәйхезаман. Нинди тавыш булды икән соң ул?

Байтирәк. Курыкканга куш күренә дигәндәй, шулай тоелган гынадыр.

Шәйхезаман. Шулай дисеңме?

Байтирәк. Әйе, хәзрәткәем, шулай дим.

Шәйхезаман. Кара әле, улым Байтирәк, мин бая ул кызларны артыграк ачуланып, хәтерләрен калдырдым бугай. Ул мәлгунә мине хуш күрер микән?

Байтирәк. Хәзрәт кадәр хәзрәт белән зөфафта булгач, хуш күрмиме соң. Бая тышка чыгарып керткәндә әйткән идем дә, авызы бияләй кадәр җәелде.

Шәйхезаман. Булмас ла!

Байтирәк. Икмәктер, хәзрәт.

Шәйхезаман. Бәрәкалла... (*Акча бирә.*) Алай булса, Аллага асмарладык.

Байтирәк. Шулай иттек, хәзрәт. Әүвәле-ахыры хәерле булсын!

Шәйхезаман. Амин, шулай булсын! Улым Байтирәк, моңа кадәр мин сине белми йөргәнмен, син бик яхшы күңелле кеше икәнсең. Бу яхшылыкларны кемнән өйрәндең?

Байтирәк. Синнән, хәзрәткәем, синнән.

Шәйхезаман. Бәрәкалла. Мә, үзеңә тагын күчтәнәч.

Байтирәк. Рәхмәт, хәзрәт, мин фәкыйрьне шатландырган өчен, Алла сине зурласын.

Шәйхезаман. Иншалла, ярый, улым, хуш. Йоклап китсәм, иртә намазга уятырсың.

Байтирәк. Ярый, хәзрәт, уятырмын.

Шәйхезаман. Айдин чыгар йөзләреңне күрсәм,
Шөкри ләббендин бер генә сөрсәм,
Берничә көн хезмәтеңдә булсам,
Һәр нә бәлаләрне өскә алсам.

Кереп китә. Байтирәк өстеннән йозак белән бикләп ала. Исәнбай керә.

Исәнбай. Байтирәк абый, буран басылды, атлар килде. Чыгып утырырга сине көтәбез.

Байтирәк. Яхшы. Барыгыз, зиярат янына чыгып торыгыз. Мин озакламый кызлар белән барып җитәрмен.

Исәнбай. Ни өчен хәзер түгел?

Байтирәк. Уйлаган эшем үз ноктасына җитмәгән әле.

Бүлмәдә дөбердәү тавышы.

Исәнбай. Нишлиләр анда?

Байтирәк. Мулла абзый белән абыстай тибешә торгандыр.

Исәнбай. Әллә икесен бергә яптыңмы?

Байтирәк. Әйе, хәзер калганнары чиратта тора.

Исәнбай. Иллә башкисәр икәнсең. Булган эшне оттырып куймасаң ярар иде.

Байтирәк. Ялчы Байтирәкне отар өчен бу дөньяга кеше тумаган әле.

Икенче әтәч тавышы.

Бар, әнә киләләр.

Исәнбай китә. Әбелкарип, Ризван, Әмирхан керәләр.

Әбелкарип. Уф, йөрәк ничек сикерә. Карый әфәнде, тотып кара әле.

Ризван. Тотып карамыйча да ышанам, үземдә дә шундый ук хәл. Бәс, шулай булгач, иншалла, яхшылыкка ашкына ул. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда...

Әмирхан. Казый әфәнде, мантыйгыңны башка вакытта сөйләрсең, эшкә килик. Байтирәк!

Байтирәк. Әү, карый абзый?

Әбелкарип. Йә, сөйләштеңме?

Байтирәк. Бик яхшылап, бәхетегез бар икән.

Ризван. Нәтиҗәсе ничек?

Байтирәк. Өчесе дә бер авыздан риза булдылар.

Әмирхан. Бәрәкалла, бик күркәм булган.

Ризван. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда, эш нәрсәдә соң?

Байтирәк. Эш беткән, көлтә җыясы гына калган.

Әмирхан. Алай булса, әйдәгез, җанкәйләрне көттермик.

Китә башлыйлар.

Байтирәк. Әфәнделәр, сезнең бит миңа вәгъдәгез бар.

Әбелкарип. Нинди вәгъдә?

Байтирәк. Сез мине бүләкләргә булган идегез.

Әбелкарип. Ә, әйе. Ләкин соңыннан алырсың, хәзер вакытыбыз юк.

Байтирәк. Юк, хәзер бирегез. Калган эшкә кар ява, дигән бабайлар.

Ризван. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда, моның чонтамы, ягъни мәсәлән, мәгънәсе ничек була инде?

Байтирәк. Моның мәгънәсе шул: халыкта кияүләрне кыз янына керткәндә ишек бавы бүләге дигән бер гадәт бар. Күрәсез, монда кызлар юк, алар өлешен миңа бирәсез.

Ризван. Мин ришвәт бирүне мәслихәт тапмыйм. Чөнки ул, шәригать ноктаи назарыннан караганда, зур гөнаһ була.

Байтирәк. Алай булса, таегыз моннан, тай! Бушлай Ходай кушмый.

Әмирхан. Юк, Байтирәк, бирмибез дип кистереп әйткәнебез юк бит әле.

Байтирәк. Әйдә, әйдә, алырга гына өйрәнгәнсез, бер дә бирәсегез килми, ә?

Әбелкарип. Йә, җәмәгать, ни дисез?

Ризван. Күрәсең, мантыйк ноктаи назарыннан караганда, бирми булмас. Әйдәгез, кашыныгыз!

Әбелкарип. Карый әфәнде, минем өчен син генә биреп тор.

Әмирхан. Юк инде, үз кесәңнән чыгар. Ялан-ялан кеше җилкәсенә салынма.

Байтирәк. Буласызмы, юкмы?

Әмирхан. Мә, хәердән булыр.

Ризван. Дога кылып ал.

Әбелкарип. Әүвәле-ахыры хәерле булсын.

Байтирәк. Күптән шулай кирәк иде. Югыйсә ат базарындагы төсле сатулашып торасыз. Кем кайсы янына керә?

Әбелкарип. Без үзебез иң өлкәне, иң гүзәле янында булырга тиеш.

Әмирхан. Юк, Әбелкарип Тамбурый, өлкәне янына мин керәм!

Әбелкарип. Юк, мин керәм!

Әмирхан. Юк, мин керәм!

Ризван. Карагыз әле, карачкылар, нигә дәрәҗәгезгә карап үрелмисез. Мантыйк ноктаи назарыннан караганда, өлкәне — безнеке, Аллаһы боерса.

Әмирхан. Тукта әле, Ризван Кискәви, нишләп синеке?

Әбелкарип. Әйе, нишләп, бәлфараз, сезнеке?

Ризван. Мин — сезнең казыегыз, бәс, шулай булгач, өлкән кыз безнеке. Сезгә, Әбелкарип Тамбурый — уртанчысы, ә сезгә, Әмирханыл Колгави — кечкенәсе дә ярап торыр.

Байтирәк (*ишекне ачып*). Барыгыз, көлдә аунап көнегезне күрегез. Эт-мәчедәй гомер сөрегез.

Өчесе бергә. Амин!

Синең гыйшкың касәсеннән
Ләззәт шәрабын эчсәм.
Мәңге үкенмәм бу вафасыз
Дөньясыннан ваз кичсәм.

Кереп китәләр. Байтирәк аларның өсләреннән бикләп ала. Миртимер белән Исәнбай керә.

Миртимер. Байтирәк абый, атлар туңа, дип, ямщиклар зарлана, әйдә киттек.

Байтирәк. Инде китсәк тә ярый. Әйдәгез!

Манарага менеп китәләр. Бераздан Бибкәй белән Байтирәк чыга.

Бибкәй. Байтирәк абый, кая барабыз?

Байтирәк. Кая таба күз карар, шунда булыр безнең юлыбыз.

Китәләр. Исәнбай белән Миләүшә чыга.

Исәнбай. Әйдә, Гөлкәй, Биби Миләүшә.

Миләүшә. Әйдә, туган Исәнбай.

Китәләр. Гайшә белән Миртимер чыгалар.

Миртимер. Киреләнмә әйдә, Гайшә җанкисәк.

Гайшә. Кирәкми, мин куркам.

Миртимер. Алай булса, кал шунда.

Гайшә. Тукта, Миртимер абый, ал мине.

Китәләр. Еракта өченче әтәч тавышы ишетелә. Түшләре белән идәннән шуып, Шәмгун, Байморат, Гыйлемдар керә.

Шәмгун. Бер тавыш та ишетелми.

Байморат. Мәет чыккан өй төсле нинди шомлы, тын.

Гыйлемдар. Эч пошыргыч караңгы. Җитмәсә салкын, каяндыр җил өрә.

Шәмгун. Байтирәк, Байтирәк!
Байморат. Нигә эндәшми ул малай?
Гыйлемдар. Әллә йоклап калганмы?
Шәмгун. Бигрәк тә яхшы. Кирәге дә шулкадәр генә.
Байморат. Бар әле, мәхдүм, карап кил. Берәр җирдә посып йокламыйммы?
Гыйлемдар. Яхшы, Байморат абзый. (*Төрле җирдән эзли.*) Юк, беркем дә күренми. Каядыр мышнаган тавышлар гына ишетелә.
Шәмгун. Әллә чынлап та теге күсәк малай безнең кызлар янына чумганмы?
Байморат. Аңардан булыр да. Ул бит имансыз егет.
Гыйлемдар. Мәзин абзый, бүлмәдә ир кешеләр тавышы бар.
Шәмгун. Чынлапмы?
Байморат. Юктыр, шәкерт, ялгышасыңдыр.
Гыйлемдар. Бар, Байморат абый, ышанмасагыз тыңлап карагыз.

Тыңлыйлар.

Шәмгун. Әйе, бар, тәхкыйк бар.
Байморат. Димәк, теге ристаннар безне алдаганнар.
Шәмгун. Кемнәр?
Байморат. Ялчы Байтирәк, башкорт Исәнбай, кизү Миртимер.
Шәмгун. Ай, каһәр төшкән нәрсәләр. Әйтәм аны кич буенча чабышып йөрделәр.
Байморат. Димәк, кыз янына кертәбез дип бездән акча алдылар да, үзләре үк безнең кызларыбызның куеннарына кергәннәр.
Шәмгун. Күрәсең, шулай булып чыга. Нишлибез?
Гыйлемдар. Хәзрәтне уятырга, халыкны җыярга, күз алдында зина кылып ятмасыннар.
Байморат. Бик дөрес әйтәсең, мәхдүм. Бар, мәдрәсә шәкертләрен уят, каравыл салып халык җый. Гыйбрәт күрергә килсеннәр.
Гыйлемдар. Җәмәгать, зиначылар тоттык, монда керегез!

Кычкыра. Йөгереп китә. Бүлмәдәгеләр, чыгарга теләп, ишекләрне дөбердәтәләр. Артта шау-шу, кычкырыш.

Шәйхезаман. Байтирәк, мәлгун, кая дөмектең? Ач ишекне, башкисәр!
Байморат. Мәзин, качарга телиләр. Зинһар, чыгарма.

Ишекләрне җилкәләре белән төртеп торалар. Шәкертләр, крестьяннар төркеме керә. Ишекләрне җимереп, Җомабикә белән Шәйхезаман чыга. Халык аптырап кала.

Байморат. Йә Ходай!
Шәмгун. Хәзрәт белән абыстай...
Шәйхезаман. Кая ялчы Байтирәк, башкорт Исәнбай, кизү Миртимер? Кая?
Гыйлемдар. Алар, хәзрәт, менә монда, кызлар янында булырга кирәк.
Шәйхезаман. Чыгарыгыз, зина кылып ятмасыннар.

Ишекләрне ачалар, Ризван белән Зөлкагыйдә, Әбелкарип белән Зөлсәгыйдә, Әмирхан белән Зөлхәмидә чыга. Шашып калалар.

Шәйхезаман. Бу нинди кәрамәт?
Байморат. Бу нинди әкәмәт?
Шәмгун. Бу нинди могҗиза?
Шәйхезаман. Кая минем ялчым, башкисәр?
Әбелкарип. Кайда ул безне алдаучы?
Ризван. Кайда ул безне хурлаучы?
Әмирхан. Кайда ул безне мыскыл итүче?
Байморат. Кайда ул безнең акчабызны алдап алучы?
Шәйхезаман. Мин сездән сорыйм! Табып китерегез миңа алдар Байтирәкне, башкорт Исәнбайны, кизү Миртимерне! Зиначы кызлар белән аларны да хөкем итәбез!
Бәхтияр. Әй хәзрәт, хәзрәт, оят кирәк иде әзрәк... Алар күптән очтылар инде. Хи-хи-хи.
Шәйхезаман. Бәрәкалла, ничек очтылар.
Бәхтияр. Күрше авыл ямщикларын яллап, кызлар белән качтылар. Хи-хи-хи...
Барысы. Качтылар?!

Таш булып катып калалар.

Пәрдә.

# БАШМАГЫМ

*Музыкаль комедия өч пәрдәдә*

КАТНАШАЛАР:

Кәрим бай — Казан сәүдәгәре.
Фәхрия — аның хатыны.
Сәрвәр — аларның кызы.
Галимҗан — яңа гына рус учительская школасын тәмамлаган яшь егет.
Зыя — Себер бае.
Гыйльми — Кәримнең кияүдәге кызы.
Вафа — аның ире, мәзин.
Гаффар — Кәрим байның кучеры.
Җаппар — дворник.
Җиһан — асламчы карчык.
Хәлимә
Нәсимә
I эзләүче
II эзләүче

Кәрим бай хезмәтчеләре, асраулары, приказчиклары. Сабан туенда — грузчиклар, шәкертләр, эшчеләр, кустарьлар, төрле катлау шәһәр кешеләре.

Вакыйга Бөек Октябрь революциясенә кадәрге чорда бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кәрим байның матур итеп җиһазландырылган залы: йомшак мебельләр, тәрәзәләрдә челтәрле пәрдәләр, стенада күкеле зур сәгать, шамаилләр, түшәмнән алып идәнгә кадәр көзге куелган. Төрле якка китә торган ишекләргә шторалар эленгән. Пәрдә ачылганда, Сәрвәр көзге алдында бизәнә. Кунак кызлары хор белән җырлыйлар.

Хор. Тау башында бөрлегән.
Бөрлегән.
Тау астында төрле үлән,
Төрле үлән.
Син җаныйга күзем төшсә,
Бер тереләм, бер үләм.
Ай, кызлар, вай, кызлар,
Бер тереләм, бер үләм.
Бакчаларда карлыган,
Карлыган.
Кемнәр җыймый калдырган,
Калдырган?
Яңа туган ай шикелле,
Ике кашын алдырган.
Ай, кызлар, вай, кызлар,
Ике кашын алдырган.
Күктә якты йолдызым,
Йолдызым.
Суда йөзгән кондызым,
Кондызым.
Кичен йөзең күрә алмыйм,
Килче, зинһар, көндезен.
Ай, кызлар, вай, кызлар,
Килче, зинһар, көндезен!

Хәлимә. Нәсимә, синнән бернәрсә сорыйм әле, син нинди ирләрне яратасың?

Нәсимә. Мин зур таза гәүдәле, калын тавышлы, озын кара мыеклы, мәһабәт ирләрне яратам. Ә син үзең?

Хәлимә. Мин акчалы, бай ирләрне яратам. Әмма инде мыеклы ирләрне җенем дә сөйми. Шул бернәрсәгә ярамаган мыекларын нигә үстерәләр икән? Аларны ничек итеп хатыннары...

Сәрвәр (*бүлдереп*). Җитәр, кызлар, бик тирәнгә кереп киттегез!

Нәсимә. Сәрвәр, син нинди ирләрне яратасың?
Сәрвәр. Әтине, бабайны, абыйны.
Хәлимә. Без андыйларны әйтмибез.
Сәрвәр. Нигә, алар ирләр түгелме?
Хәлимә. Ирләрен ирләр дә... Без бит, егетләрнең ниндиен, дибез.
Сәрвәр. Сез дигәнчә түгел минем теләк,—

Мин яратам ирнең аңлысын.
Үзе акыллы, үзе тәрбияле,
Үзе укыган, зирәк, санлысын.
Буйга-сынга, төскә-биткә,
Матур булсын килбәткә.
Ия булсын ил өстендә
Данга, шөһрәт, кыйммәткә!
Менә шундый бер егеттән
Көн дә алам мин нәма.
Көн дә сагынып, көн дә зарыгып,
Көн дә миңа хат яза.
(*Хатлар күрсәтә.*)

Хор. Андый хатлар язучының

Кем икәнен беләмсең?
Хатка каршы хатлар язып,
Аның күңелен күрәмсең?

Сәрвәр. Ничек итеп хатлар языйм аңа?

Үзен күреп, кызлар, белмәгәч.
Ничек итеп күңлен күрим аның,
Исмен әйтеп хатка язмагач?
Күптән инде мине аулаган,
Күз карашым аңлаган.
Бер матур бар барын, кызлар,
Мәхәббәтем баглаган.
Булса иде әгәр минем
Шул хат язган егетем,
Сайлар идем гомерлеккә
Итеп хәләл җефетем.

Хор. Ул егетне эзләп тап син,

Тап син аны тизрәк,
Тормышыгыз бергә булсын,
Бездән сиңа шул теләк.

Баш өстенә зур төен куеп, асламчы карчык Җиһан керә.

Сәрвәр. Җиһан әби килгән! Саумы, әби, исәнме!
Җиһан. Шөкер, кызым, үзең нишләп торасың?..
Хәлимә. Бу арада күренмәдең, Җиһан әби.
Нәсимә. Сагындырып бетердең.
Хәлимә. Күрсәт, әби, ниләр безгә китердең?
Җиһан. Ашыкмагыз, сабыр итегез,

Бераз гына читкә китегез!
Менә сезгә энҗе калфак,
Менә асыл ашъяулык,
Менә затлы ефәк шәлләр,
Менә көмеш кулбаулык.

Хор. Ашыкмагыз, сабыр итегез,

Бераз гына читкә китегез!

Җиһан. Менә әйбәт гатыршамай,

Менә җофар сабыны.
Менә кершән, күз сөрмәсе,
Менә кәрчит асылы.

Сәрвәр һәм кызлар, берәр әйбер алып, көзге каршына киләләр, көязләнәләр, кайберләре бииләр. Фәхрия керә.

Фәхрия. Күрми дә торам, кунак бар икән!

Җиһан. Исәнме, Фәхрия!

Фәхрия. Әлхәмделиллаһи шөкер, Җиһан әби, кунаклар каршылап йөрибез. Шәһәрдә бит бүген сабантуй!

Җиһан. Сөйләмә инде, бөтен урамнар гөж килә. Каян шулкадәр кунак-төшем килгәндер?

Фәхрия. Шуның өстенә тагын үзен көтәбез. «Чегутны едим»,— дип, тилиграм суккан.

Җиһан. Сөбханалла, бик әйбәт булган.

Фәхрия. Кызым, асрауларга әйт: Җиһан әбигә самавыр яңартсыннар.

Сәрвәр. Әйдәгез, кызлар!

Сәрвәр белән кызлар китәләр.

Фәхрия. Җиһан әби, теге әйберең булдымы?

Җиһан. Булды, кызым, булды. Алып та килдем. (*Шешә күрсәтеп.*) Менә ул — зәмзәм!

Фәхрия. Зәмзәм?

Җиһан. Хаҗ Шәрифтән кайткан зәмзәм суыннан ясалган. (*Бирә.*)

Фәхрия. Нишләтергә соң моны, аш-чәенә салып бирергәме?

Җиһан. Юк, кызым, Мөхәмматкәримең йоклагач, үзенә сиздерми генә, канат белән аяк бармаклары арасына сөртергә кирәк.

Фәхрия. Ай-һай, Җиһан әби, аннан гына файдасы булыр микән соң?

Җиһан. Була икән шул, Фәхрия, була! Менә шушы шифалы майны сөрткәннән соң, ирең берәр бозыклык эшләргә уйласа, тәпи бармакларын көзән җыерып, күңеленә хәбәр сала икән. Менә шуннан соң инде Мөхәмматкәримеңне син күр дә мин күр: өйләнәм дигән сүзне теленә дә алмас. Әле шуны өшкереп ясаучы тол остабикә әйтә: «Җиһан әби, моннан ары өшкереп бирмәм инде»,— ди.

Фәхрия. Ни өчен икән?

Җиһан. Безнең бай хатыннары бер дә бүләк бирә белмиләр, ди.

Фәхрия. Шифасы тиярлек булса, акчасыннан эш тормас иде. Син беләсеңдер инде, Җиһан әби, күпме бирергә икән соң?

Җиһан. Ай Алла, дөнья күрмәгән хатын түгел, үзең белеп бир инде. Бер кирәк кеше тагын да кирәк булыр дисәң, мулрак бирсәң дә ярый...

Фәхрия. Мә әле, Җиһан әби, тот. Үзе кайткач, тагын буш итмәм. (*Акча бирә.*) Мин моны бала-чага күргәнче яшереп куйыйм әле. (*Китә.*)

Җиһан. Кара инде бу тинтәккә:

Тагылып йөргән һәр итәккә
Ире кебек кешеләрне
Кертмәк була ул тәртипкә.
Тотып үзен чумдырсаң да
Мондый майларның күленә,
Шифа бирмәс инде Тәңрем,
Аның азгын ул күңленә.
«Юләр белән исәрләрне
Җиргә чәчеп маташмагыз,
Үзләре дә үсәләр»,— дип,
Белеп әйткән шул бабайлар.
Бик дөрес!

Сәрвәр йөгереп керә.

Сәрвәр. Әнкәй, чәй әзерләгәннәр!..

Җиһан. Акрын, кызым... Менә шуны ал әле. (*Хат бирә.*)

Сәрвәр. Тагын шуңарданмы?

Җиһан. Башка кемнән булсын ди? Җавабыңны яз.

Сәрвәр. Мин аны белмим, кем соң ул? Нинди ата-ана баласы?

Җиһан. Миндә фатирда тора. Ата-аналары Тәфкилевләрнең кол крестьяннары булганнар, аңа ун яшь тулганда, икесе бер көнне вабадан үлгәннәр. Авылда туган. Кардәшләре булмагач, аны каладагы приютка биргәннәр. Аннан инде учительләр школасына кереп, быел укып бетерде. Хәзер үзен Тәтеш шәһәренә татар балаларын урысча укытырга билгеләгәннәр, берничә көннән шунда китәргә җыена. Бәхетең инде, бәхетең. Хәзер үк җавап яз.

Фәхрия керә.

Фәхрия. Җиһан әби, озак көттердем бугай.

Җиһан. Ярар, ярар, Фәхрия, барасы җирләрем юк әле.

Сәрвәр. Әнкәй, чәй әзерләделәр.

Фәхрия. Ярый, кызым. Әйдә, Җиһан әби, сусагансыңдыр.

Җиһан. Бер дә эчәсем килми иде, Фәхрия...

Җиһан белән Фәхрия китәләр. Сәрвәр, ишек чаршауларын төшереп, хат укый. Чаршау артларына яшеренеп, кызлар карап торалар.

Сәрвәр. Син, егеткәй, йөрәгемә
Гыйшык уклары аттың.
Ялкын төсле хатлар язып,
Яшь йөрәккә ут яктың.
Хатларыңны бик хуш күрәм,
Күңлем түренә куям...
Хатлар белән сөйләшмәсәк,
Мин сине каян күрәм?
Кызлар. Ах, шаян кыз, ах, наян ул,
Бүген тагын хат алган.
Берьялгызы ләззәтләнә,
Безгә әйтсә ни булган?
Сәрвәр. Тик шунысы бик кызганыч:
Сүзләрең күп, үзең юк.
Бер туйганчы карар идем,
Күз алдымда үзең юк.
Хатларыңны бик хуш күрәм,
Күңлем түренә куям...
Хатлар белән сөйләшмәсәк,
Мин сине каян күрәм?..
Кызлар. Ах, шаян кыз, ах, наян ул,
Бүген тагын хат алган!
Берьялгызы ләззәтләнә,
Безгә әйтсә ни булган?

Хәлимә йөгереп керә.

Хәлимә. Сәрвәр, сөенче, сөенче!
Сәрвәр. Нәрсә бар? Нинди сөенче?
Хәлимә. Кәрим абзый кайтты!

Кызлар бүлмәгә кереп китәләр. Бераздан йөгерешеп чыгалар да шаулашып тышка узалар. Җиһан чыга.

Җиһан. Аларның ярминкәсе ябылуга, минем ярминкәм ачыла! Теге майны хәзер ташып кына тор!

Әйберләр күтәргән Кәрим бай белән Фәхрия һәм башкалар шаулашып керәләр.

Кәрим. Уф... Юл газабы — гүр газабы, дип белеп әйткәннәр. Тәмам эштән чыгып арыдым. (*Өсләрен сала*.)

Җиһан. Сау кайттыңмы, Кәрим балакай?

Кәрим. Сезнең хәер догада, Җиһан әби.

Фәхрия. Сәүдәләрең ничек, уң булдымы, атасы?

Кәрим. Әлхәмделиллаһи шөкер, анасы. Менә сиңа ярминкә бүләге. (*Бирә*.)

Фәхрия. Рәхмәт инде, атасы.

Кәрим. Менә боларын кияүләргә бирерсең. (*Бирә*.)

Фәхрия. Сөбханалла, аларны да онытмагансың!

Кәрим. Менә монысын, кызым, иптәш кызларыңа өләшерсең. Иннек, кершәннәр. (*Бирә*.) Менә монысы, Җиһан әби, сиңа. Намаз артыннан дога кылырсың. (*Бирә*.)

Җиһан. Рәхмәт инде, Кәрим балам, рәхмәт. Тапкан малларыңа бәрәкәт бирсен Ходаем.

Кәрим. Кая әле, кызым, сакбаяжны бир әле, сиңа анда бик шәп бүләк бар!

Сәрвәр. Нинди бүләк ул, әткәй?

Кәрим. Хәзер күрерсең. Тарги белән суктырып алдым. Ул арттыра, мин арттырам, ул арттыра, мин арттырам!..

Фәхрия. Кем ул, атасы?

Кәрим. Оренбурның Садыйк Вафасы. Бөтен алтари йортын шаулаттым. Алтари ясаучы әйтә: «Ай-яй, Кәрим Хисаметдинов, задурный икәнсең!» — ди. «Бу бит минем кызыма, аның өчен булганда тораммы инде хакына?» — дидем. Менә, кызым, сиңа бүләгем!.. (*Башмаклар бирә*.)

Сәрвәр. Ах! Нинди матур башмаклар!..

Кәрим. Ул үзе дә биш йөз сум...
Фәхрия. Биш йөз сум?!
Хор. Котлы булсын, котлы булсын!
Атаң сине зурлаган.
Мондый матур зур бүләкне
Бездә беркем күрмәгән.
Күрмәгән!
Күрмәгән!!
Күрмәгән!!!
Өндә түгел төшләргә дә
Кермәгән!
Кермәгән!!
Кермәгән!!!
Җиһан. Кәрим улым, Кәрим улым,
Даның китәр калага.
Шундый атаң-анаң булу —
Нинди шатлык балага!
Хор. Балага!
Балага!!
Балага!!!
Тигез гомер бирсен инде
Аларга!
Аларга!!
Аларга!!!
Сәрвәр. Рәхмәт сиңа, рәхмәт, эткәем!..
Кәрим. Шатлык белән киеп туздыр, бәбкәем.

Кызлар белән Сәрвәр китә.

Фәхрия. Атасы, мунча яктырган идем, өлгергән. Аннан, аш та сосып куелган, башта мунча кереп...

Кәрим. Ашап алырбыз. (*Бер читтә әйберләре белән әвәрә килүче Җиһан карчыкка ымлап.*) Минем монда язу-сызу белән шөгыльләнәсем бар иде...

Фәхрия. Хәзер, хәзер, әйтермен. Җиһан әби, мунча кереп чыгарга теләмисеңме?

Җиһан. Теләмәгән кая, кызым, бик телим! Бу арада сөяк-санакларым да сызлап тора иде.

Фәхрия. Алай булса, бар, кирәк әйберләре әзерләп куелган. Зур казанда суы булыр. Ләүкәсендә яңа себерке. Сабын белән мунчаласы — тәрәзә төбендә. Ачы катык кирәк булса, асраулардан сорарсың. Әйдә, әйберләреңне теге якка куярсың.

Фәхрия белән Җиһан китәләр. Кәрим язарга утыра. Бераздан язган текстын укый.

Кәрим. Нижгородский ярминкә,
Августовна Мәтильдә.
Прибыл благопалучно,
Без тебя здеч скучно.
Скор Мәскәү поедем,
Бух дас, тебя увидим.
Письмо пиши мой мәгәҗин.
Твой любим хәҗәен.
Хәзер үк җибәрергә кирәк, вәгъдәсез дип үпкәли башлар. (*Тәрәзәгә барып.*) Гаффар, Гаффар, дим!

Гаффар керә.

Гаффар. Нәрсә, бай абзый, ат җигәргәме?!
Кәрим. Юк, пуштага барып, тилиграм сугып кайтырсың. Менә акчасы. Кбитанциясен миңа бирерсең.
Гаффар (*телеграмма текстын алып*). Ярый, бай абзый. (*Китә.*)

Фәхрия керә.

Фәхрия. Әйдә, атасы, ашап алыйк.
Кәрим. Кил әле, сиңа сүзем бар.

Кәрим белән Фәхрия утыралар.

Кәрим. Мин, Фәхрия, Сәрвәрне килешеп кайттым бит.
Фәхрия. Килешеп кайттың? Кемгә?
Кәрим. Зыя әфәнде Гафуровка.
Фәхрия. Кайсы, былтыр килгән Гафуровкамы?
Кәрим. Әйе, Себер бае Гафуровка инде.
Фәхрия. Улларым юк, дигән иде түгелме?
Кәрим. Үзенә.
Фәхрия. Үзенә? Соң бит ул бик карт кеше.
Кәрим. Булса соң! Эш картлыкта түгел, байлыкта.
Фәхрия. Куй инде, куй. Синең белән кордаш кеше ич.
Кәрим. Зыя әфәнде кебек бай кешеләр бервакытта да картаймыйлар. Үткән ел миңа виксель белән илле сигез меңлек товар биргән иде, бик күп зыян иттем, түли алмадым. Хәзер шуны кыса башлагач, кызны биреп котылмыйча чарам калмады.
Фәхрия. Юк, юк, агай-энеләр белән сөйләшергә дә акча табып кайтарырга кирәк.
Кәрим. Булмый инде, Фәхрия! Ул бит хәзер безнең шәһәрдә.
Фәхрия. Безнең шәһәрдә?!
Кәрим. Әйе. Минем белән бергә Казанга килде. Гостиницага төшердем. Сәрвәргә алып кайткан башмакны да бүләк итеп ул бирде. Иртәгә никах укытып китәм, ди.
Фәхрия. Әйтмә дә, сөйләмә дә! Мин риза түгел. Бердәнбер баламны, картка биреп, кан елатыр хәлем юк.
Кәрим. Ул чагында Болак күпере буена чыгарсың.
Фәхрия. Ничек Болак күпере буена?
Кәрим. Шулай, иртәгә үк кибетләргә йозак эләрләр. Өйдәге бар әйберләрне сатып, үзебезне тәрәзәдән чөярләр. Урамнан уза башласаң: «Банкротка калган Кәрим бай!» — дип, теш ыржайтып көләрләр. Шуннан инде икәүләп Болак күпере буена чыгарбыз да узган-барганнарга кулыбызны сузарбыз... Шәп бит, ә?.. (*Юри елаган була*.)
Фәхрия (*куркып*). Юк, юк, атасы, алай димә! Алла сакласын... Әйдә, аш суына, ашап алыйк.

Фәхрия белән Кәрим китәләр. Сәрвәр белән кызлар чыга.

Сәрвәр. Башмагымның башы башка,
Зиннәтләнгән асыл ташка.
Көн дә кисәм аштан ашка,
Тиз тишелер табаннары.
Кызлар. Көн дә кисәң аштан ашка,
Тиз тишелер табаннары.
Сәрвәр. Мин киярмен аны саклап,
Йөрермен мин вак-вак атлап.
Кер тидермәм бер җиренә,
Салгач куям өстен каплап.
Кызлар. Кер тидермә бер җиренә,
Салгач куй син өстен каплап.

Сәрвәр аякларыннан башмакларын салып көзге алдына куя да читкә китеп сокланып карап тора.

Сәрвәр. Нинди матур күренәләр,
Ерактан караган чакта.
Җем-җем итә укалары,
Йолдызлар шикелле хәтта.
Кызлар. Җем-җем итә укалары,
Йолдызлар шикелле хәтта.

Артта пароход тавышы ишетелә.
Сәрвәр. Кызлар! Ишетәсезме? «Нептун» пароходын Кабан күленә төшерделәр. Димәк, ул хәзер кузгала. Әйдәгез, чыгып карыйбыз.
Китә башлыйлар.

Хәлимә. Туктагыз! Сәрвәр, башмакларың шунда каламы?
Сәрвәр. Әйдә калсын, без бит хәзер керәбез.

Китәләр. Икенче ишектән, кычкырып, Гаффар керә.

Гаффар. Бай абзый, бай абзый, дим!

Ашыгып бүлмәдән Кәрим чыга.

Кәрим. Нәрсәгә шулкадәр акырасың, пожар бармы әллә?

Гаффар. Синең бу Мәтильдә Августовна дигән хатының!..

Кәрим. Чү, дим, гыйбеди! Ипләп кенә сөйлә, нәрсә бар?

Гаффар. Тилиграмны алмыйлар.

Кәрим. Нишләп?

Гаффар. Бердән, адресы юк, диләр. Аннан, бай абзый, тилиграм алучы егетләр, кулдан-кулга йөртеп укыйлар да эчләре катып көләләр. «Каян син аны таптың, ничек аның белән таныштың?» — диләр. Нинди тилиграм соң ул, бай абзый?

Кәрим. Ярый, ярый, күпне белсәң, тиз картаерсың. Бар, эшеңдә бул!

Фәхрия керә.

Гаффар (*Фәхрияне күрмичә*). Шулай да, бай абзый, ул Мәтильдәне...

Кәрим (*аны бүлдереп*). Бар инде, бар, багажларны алып кайт!.. (*Төрткәләп чыгара.*)

Фәхрия *(шикләнеп)*. Нинди Мәтильдә турында сөйли ул?

Кәрим. Атка Мәтильдә дип исем кушыйк, салдатта минем әфичәрнең аты да Мәтильдә кушаматлы иде, ди.

Фәхрия. Менә дигән атка шундый тозсыз исем кушып мәсхәрәләмәсә... Йә, ярар, атасы, Җиһан әби мунчадан чыкты, ишегалдында хәл җыеп утыра. Әйдә, кереп юыныйк, гөнаһларны чистартыйк.

Кәрим. Нинди гөнаһларны?

Фәхрия. Болай, ерак юлдан кайттың ич.

Кәрим. Шулай диң, юкса мин фәрештәдәй саф кеше! Нинди гөнаһым булсын ди?

Кәрим белән Фәхрия китәләр. Бераздан, кулына төеннәр тотып,
Галимҗан керә.

Галимҗан. Мәскәүләрдән килгән, ай, ука чук,
Бу шәһәрдә алар бер дә юк.
Сагынып килдем, сине күрер өчен,
Берәр хәйлә табып, монда чык!
Күл буенда үскән төнбоектай,
Сине сөйгән моңсу яр көтә.
Күреп йөзең, ишетеп тәмле сүзең,
Бер сөйләшсәм, миңа шул җитә.

Чыннан да, нишләргә инде бу Сәрвәр белән? Ничә тапкыр хатлар яздым, берсенә дә җавап бирмәде. Әмене бүген Җиһан әбине дә җибәреп карадым. Күрәсең, аның да файдасы тимәде. Аптырагач, инде кеше киемен киеп, үзем килергә мәҗбүр булдым. Нәрсә анда ялтырый?

Башмагыңның, ай, башлары
Асыл ташка күмелгән.
Иртән истә, кичен төштә,—
Һич чыкмыйсың күңелдән.
Башмагыңның, ай, башлары
Бигрәк матур өлгеле.
Үзең — кызларның сөмбеле,
Тавышың — гөлләр былбылы.
Хатларыма хат язмауга
Аптырады бу башым.
«Сөям»,— диеп бер генә әйтсәң,
Ни була соң, җанашым?
Башмагыңның чәмчәләре
Үрнәк итеп чигәрлек.
Бер Ходаем нигә биргән
Сиңа мондый чибәрлек?
Башмагыңа тезәр идем
Алмаз, якут ташларын.
Сөрмәле күз, зифа буең
Әйләндерде башларым.
Башмагыңның хәтфәләре
Сатыла микән аршынга?
Шушы башмакларың киеп

Йөрсәң иде каршымда...

Тукта әле, болар кая киттеләр икән?

Карана-карана, эчке бүлмәләргә таба китә. Тирләп-пешеп, Җиһан карчык мунчадан кайтып керә.

Җиһан. Барып мунчасына кердем,
Бик күп рәхәтләрен күрдем.
Шәфәгать кыл, Раббем, үзең,
Әгәр исе тигән булса!
Самавыры булса иде,
Бал, варинҗа куйса иде,
Лимунын да киссә иде,
Тәмләп чәен эчәр идем.

Аргы бүлмәдән Галимҗан чыга.

Җиһан. Син ничек монда, Галимҗан?

Галимҗан. Чү... Җиһан әби, мин Галимҗан түгел, Сәлимҗан.

Җиһан. Нинди Сәлимҗан?

Галимҗан. Сине көтеп тордым-тордым да, кайтмагач, Гыйлаҗ байда приказчик булып хезмәт итүче дустым Сәлимҗан янына кердем. Ул шушы товарларны Кәрим байларга илтергә җыена иде. «Бир,— мин әйтәм,— үзем генә илтеп бирим»,— дип алдым да, аның киемнәрен киенеп, монда йөгердем. Ләкин берсе дә өйдә күренми.

Җиһан. Аталары мунчада, калганнары бар да күл буенда, пароход карыйлар.

Галимҗан. Йә, ничек соң, Җиһан әби, минем хатны бирдеңме?

Җиһан. Әйе, хатыңны бирүен бирдем, тик монда бик күңелсез хәбәр бар әле.

Галимҗан. Нинди хәбәр?

Җиһан. Сәрвәрне ярәшкәннәр.

Галимҗан. Кемгә?

Җиһан. Нindидер бер Себер баена. Иртәгә никах укытабыз, диләр.

Галимҗан. Алай!.. Бер ел буе янып-көюләрем бушка булган икән... Менә ул, Җиһан әби, байлык-фәкыйрьлек безне нишләтә...

Җиһан. Кайгырма, улым, җаен табарбыз. Ал менә шул башмакларны, алар сезгә ярдәм итәрләр.

Галимҗан. Ничек инде «ярдәм» итәрләр?

Җиһан. Кияү булачак кеше аларны вәгъдә бүләге итеп җибәргән.

Галимҗан. Сәрвәр шуны риза булып алганмы?

Җиһан. Ул, бичара, берни дә белми әле. Мә, ал да тизрәк, тай моннан!

Галимҗан. Тукта әле, әби, бу караклык була түгелме?

Җиһан. Мәхәббәт турында булган чәлдерүләр гаепкә алынмый.

Галимҗан. Шулай да мин ни өчен алуымны белергә тиештер!

Җиһан. Соңыннан белерсең. Бер кечкенә хат кисәге язып калдыр, миннән шикләнерлек булмасын. (*Пышылдап кына әйтеп тора*.)

Галимҗан яза.

Җиһан. Әнә кайталар, бар, арткы ишектән генә тай!

Галимҗан чыгып китә. Җиһан юри генә намаз укырга керешкән була.
Шаулашып, кызлар кайтып керәләр.

Сәрвәр. Кызлар, шауламагыз, Җиһан әби намаз укый.

Хәлимә. Сәрвәр, мондагы башмакларың кайда?

Сәрвәр. Чыннан да, кайда икән? Әнкәй, син минем башмакларымны алмадыңмы?

Фәхрия. Юк, кызым, алмадым. Кая куйган идең соң?

Сәрвәр. Менә шушында, көзге алдына гына бастырып киткән идем, кайтып керсәм — юк.

Кәрим керә.

Кәрим. Нәрсә юк?

Фәхрия. Башмаклары юк.

Кәрим. Башмаклары юк?! Ах сез, ачык авызлар! (*Җиһанны күреп*.) Җиһан әби!

Фәхрия. Аңа тимә инде, атасы, намазын бозасың.

Кәрим. Башка вакытта укыр. Җиһан әби, дим!

Җиһан. Нәрсә, улым Мөхәмматкәрим?

Кәрим. Башмаклар кайда?
Җиһан. Белмим шул. Ә... мин мунчадан кайтып кергәндә, бөтен ишекләрегез шыр ачык иде.

Вафа белән Гыйльми керә.

Вафа. Исән кайттыңмы, бабакай?
Кәрим. Исән, исән!
Гыйльми. Сау кайттыңмы, атакай?
Кәрим. Сау, сау!
Вафа. Ни булды соң, бабакай?
Гыйльми. Сөйләп бирче, атакай!
Кәрим. Телем бармый, сүз табалмыйм мондый хурлыкка! (*Чыгып китә.*)
Фәхрия. Ходаем, тагын савыт-сабаларны кырмаса ярар иде! (*Чыгып китә.*)
Сәрвәр. Әткәй миңа Мәкәрҗәдән,
Апакай,
Бүләк итеп башмак алган,
Җизнәкәй!
Гыйльми. Сөйләп бирче, Сәрвәр сеңлем,
Вафа. Балдызым, ялгызым.
Сәрвәр. Бүләк итеп алып кайткан
Башмаклар
Өйдән юкка чыктылар,
Җизнәкәй.
Гыйльми. Ах, нинди зур бәхетсезлек,
Вафа. Балдызым, ялгызым.

Бер яктан Кәрим белән Фәхрия, икенче яктан Гаффар керә.

Гаффар. Бай абзый, багажларны алып кайттым, кая кертергә?
Кәрим. Әй, чәнчелеп кит әле багажларың белән! Әнә башмаклар югалган! Әйдәгез, өйнең астын өскә китереп эзләгез!
Җиһан. Туктагыз әле, монда ниндидер бер язу бар.
Кәрим. Кая, кая, нинди язу ул? Яле, кияү, укып бир әле!
Вафа (*укый*). Ошбу хатны язучы,
Саулык теләп калучы,
Фәлән улы мин фәләндер —
Башмакларны алучы.
Кәрим. Димәк, урлаганнар? Үләм, суелам!!!
Вафа. Полицага хәбәр итик,
Бабакай!
Гыйльми. Бәлки, бурны табарлар,
Атакай?
Җиһан. Җәвит иткәч, тапмый булмас,
Сәрвәр кызым, балакай.
Гыйльми. Син борчылма, Сәрвәр сеңлем,
Вафа. Балдызым, ялгызым.
Хор. Полицага хәбәр итәргә кирәк,
Бурны табып китерсеннәр тизрәк.
Әйдә, хәзер шунда барыйк,
Түрәләргә хәбәр салыйк.
Киттек башмакны эзләргә,
Эзләргә,
Бурның артыннан күзләргә,
Күзләргә.
Насыйп итсен табып кайту, ай,
Безләргә,
Чыдам бирсен инде Ходай
Сезләргә.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кәрим байның бакчасы. Түрдә террасалап салынган зур йорт күренә. Бер якта — биек таш койма. Икенче якта — ишегалдына китә торган бәләкәй капка. Сәхнәнең нәкъ уртасында беседка. Пәрдә ачылганда, беседка эчендә Сәрвәркайгырып утыра.

Сәрвәр. Эзләп киттеләр башмакны,
Кара инде мин ахмакны;
Бер кешесез калдырганмын
Шундый кыйммәтле башмакны.

Галимҗан кереп тыңлап тора.

Әнкәй бертуктаусыз тирги,
Сүз әйтергә ирек бирми.
Әткәй дә, тик ятасың, ди,
Башмагыңны эзләп йөр, ди.
Галимҗан. Башмак өчен кайгырма син,
Ул бәладән тиз йолам.
Бик күп санда хатлар язган
Әрсез егет мин булам.
Сәрвәр. Бик күп санда хатлар язган
Ул синмени, ах шаян!
Галимҗан. Башмакларың да...
Сәрвәр. Башмакларым да?
Галимҗан. Миндәләр.
Сәрвәр. Синдәләр?
Галимҗан. Юри генә алган идем.
Сәрвәр. Мине борчып, син, наян.
Галимҗан. Ул мәсьәлә берни түгел,
Хәлең мөшкел, кыз бала.
Шундый гүзәл яшьлегеңә
Бер албасты кул сала.
Сәрвәр. Нәрсә бар соң, әйт тизрәк,
Түзми минем яшь йөрәк.

Фәхрия керә.

Фәхрия. Кызым, нишлисең монда?
Сәрвәр Мин, әнкәй... гөлләргә су сибәм...
Фәхрия. Бар, кызым, синнән башка да сибәрләр. Сиңа, егет, монда ни кирәк?
Галимҗан. Безнең кибеткә заказлар биргәнсез икән...
Фәхрия. Син кем соң?
Галимҗан (*Сәрвәргә күз кысып*). Гыйлаҗ байның приказчигы — Сәлимҗан.
Фәхрия. Ай-һай, алар кибетендә мин сине бер дә күргәнем юк.
Галимҗан. Мин кызыл мал бүлегендә сәүдә итәм. Ул товарлар сезнең үзегездә дә җитәрлек. Шулай булгач, билгеле инде, мине белмисез. Менә товарлар алып килгән идем.
Фәхрия. Китерүең өчен рәхмәт. Мә, юл аягы итеп биш тиен. Кызым, әйберләрне өйгә алып кер.
Сәрвәр. Күрәсең ич, әнкәй, бушамыйм. Үзең генә алып кер инде.
Фәхрия теләр-теләмәс кенә әйберләрне ала да китә башлый. Күзе Галимҗанга төшеп, туктап кала.

Фәхрия. Кара әле, егет, нигә китмисең инде? Аяк ялы да бирдем. Әллә азсынасыңмы?
Галимҗан. Яңгыр яварга тора, бераз сабыр итим инде.
Фәхрия. Алай булса, әйдә, кызым, өйгә кер.
Сәрвәр. Кара әле, әнкәй...
Фәхрия. Карыйсы-нитәсе юк, бик яхшы күрәм... Озакламый учительницаң да килер. Әйдә, сабакларыңны укый тор. (*Сәрвәрне җитәкләп алып китә.*)
Галимҗан. Ах, җанашым,
Сөрмәле күз, кыйгач кашым,
Күрә алмадым сине күзем туйганчы.
Сөйләп бирә алмадым сиңа белгәннәрем,
Комсыз атаң байга сатып куйганчы.
Кил, чык, җаным,
Кил, чык, ярым.

Кил, чык, тагын күримче...
Кил, чык, җаным,
Кил, чык, ярым,
Барсын сөйләп биримче...
Ут янында очып йөргән күбәләктәй,
Мәхәббәтең белән дөрләп мин янам.
Йә өйләнеп син гүзәлгә ия булам,
Йә мәҗнүндәй акылдан мин язам.
(*Ишеккә барып.*)
Кил, чык, җаным,
Кил, чык, ярым.
Кил, чык, тагын күримче.

Кәрим кереп тыңлап тора.

Кил, чык, җаным,
Кил, чык, ярым.
Барсын сөйләп биримче.

Кәрим. Тукта әле. «Кил, чык»,— дип, кемне чакырасың болай?

Галимҗан. Беркемне дә чакырмыйм. «Сыерчык»,— дим.

Кәрим. Нинди сыерчык?

Галимҗан. Менә шушы оядан бер сыерчык баласы чыгып сайрый иде, тотыйм дигәндә генә, очты да китте.

Кәрим. Шулай да син нишләп безнең бакчада йөрисең? (*Җиләнен салып агачка элә.*)

Галимҗан. Фәхрия апа безнең Гыйлаҗ байның кибетенә заказлар биргән икән, шуларны китердем.

Кәрим. Тукта әле, тукта. Син бит теге учительләр школасында укучы Галимҗан?

Галимҗан. Юк, мин аның туганы Сәлимҗан. Без аның белән игезәкләр. Ул учительләр школасында укый. Мин Гыйлаҗ байда приказчик. Йә, Кәрим абзый, башмакларыгыз табылмадымы?

Кәрим. Аны сиңа кем әйтте?

Галимҗан. Бөтен шәһәр халкы сөйли бит.

Кәрим. Шулаймыни? Гайбәтчеләргә эш булган икән.

Галимҗан. Соң ничек, очы күренмиме?

Кәрим. Юк, энем, юк. Суга төшкән таш шикелле, эзе дә, исе дә юк.

Галимҗан. Кызганыч, башмаклары бик әйбәт иде шул.

Кәрим. Ә син аны каян беләсең?

Галимҗан. Болай... Халык сөйләве буенча әйтәм. Ярый, Кәрим абзый, хуш.

Кәрим. Тукта әле, энем, синең, мин әйтәм, русча язу-сызуга осталык бардыр инде, дим.

Галимҗан. Бераз булдырам.

Кәрим. Алай булса, син миңа бер хат белән прошение язып бирә алмассыңмы?

Галимҗан. Ярый, Кәрим абзый, син дигәндә, аяк идәндә. Нинди хат соң ул?

Кәрим. Синнән, энем, яшерен-батырын юк инде, ул хат шухыр-мухыр хаты. Шуның өчен син аны сер итеп сакларга тиешсең.

Галимҗан. Кабер инде, Кәрим абзый, мин бит ир кеше!

Кәрим. Әйдә алайса, башладык. Августовна Мәтильдә, диң. Бик әйбәтләп башта сәлам яз.

Галимҗан. Кем соң ул, Кәрим абзый?

Кәрим. Бер кош инде, энем, кош. Бая син күргән сыерчык баласыннан бер дә ким түгел.

Галимҗан. Бик чибәрмени?

Кәрим. У-у-у! Бер кашык су белән йотарлык. Париждан килгән. Мәкәрҗәдә берүзенә ике бүлмә алып тора. Менә карточкасын кара әле. (*Күрсәтә.*)

Галимҗан. Ай-яй, мондый асыл затны кулга ничек төшердең?

Кәрим. Кесәңдә акчаң булса, төшә икән ул, энем! (*Артта кызлар тавышы.*) Әйдә, өйгә керик, безгә монда ирек бирмәсләр.

Кәрим белән Галимҗан өйгә кереп китәләр. Кызлар белән Сәрвәр чыгалар. Сәрвәр бик шат.

Сәрвәр. Теге егет килгән иде,
Купшы киемен киеп.
Нидер әйтмәк булган иде,
Бүлдерде әнкәй кереп.

Кызлар. Баймы үзе, йә купецмы,
Йә алпавыт, сәүдәгәр?

Йә һөнәрче, йә йомышчы,
Йә шәкертме, хәйләкәр?

Сәрвәр. Чын йөрәктән сөяр өчен,
Бай, сәүдәгәр им түгел.
Мал-байлыгы булмаса да,
Фәрештәдән ким түгел.

Кызлар. Юк йомышын бар итеп,
Тагын киләм дидеме?
Аулак җирдә күрешергә
Сиңа вәгъдә бирдеме?

Галимҗан чыга. Кызлар, аны күреп, вуаль белән йөзләрен каплыйлар. «Вуаль балеты» башлана. Галимҗан, биеп, кызлар арасыннан Сәрвәрне эзли. Кәрим килеп чыга.

Кәрим. Бу нинди могҗиза?!

Кызлар китәләр.

Галимҗан. Ай-яй, Кәрим абзый, үзең әйткәндәй, бу кошларны каян җыеп бетердең?

Кәрим. Ярый, ярый, телеңә салынма! Күрәм, очлы күзле егеткә охшыйсың. Конверт алып килгәнче дә түзмәгәнсең, тизрәк монда, кызлар янына чумгансың да, ха-ха-ха!.. (*Галимҗанга җырлап күрсәтә.*) Менә, адресын яз. Нижгородский ярминкә, номера «Волга», Августовна Мәтильдә.

Галимҗан. Фамилиясе?

Кәрим. Нигә фамилия?.. Аны фамилиясез дә беләләр.

Галимҗан. Ярый алайса, шулай дип язып куярбыз: мә, кулыңны куй.

Кәрим. Кулны аны һәркем куя ала, мин аңа җиде бабадан килгән йөзек кашындагы пичәтемне басамын. (*Хатка печатен баса.*)

Галимҗан. Бигрәк әйбәт булды бу, Кәрим абзый. (*Хатны конвертка салып ябыштыра.*)

Кәрим. Рәхмәт, энем. Хәзер мин аны пуштага җибәртәм. Гаффар, Гаффар, дим!

Галимҗан. Кирәкми, Кәрим абзый, почмактагы почта ящигына үзем сала китәрмен.

Кәрим. Шулай дисеңме? Бәрәкалла, бик әйбәт.

Галимҗан. Ярый, Кәрим абзый, хуш.

Кәрим. Сабыр, энем, прошение язмадык бит әле.

Галимҗан. Аны язудан файда булыр микән соң?

Кәрим. Ник булмасын? Полицмейстер, шул прошение буенча сыщикларны эзләргә чыгарам, ди.

Галимҗан. Сыщикларны гына түгел, Казандагы бөтен шайтаннарны куып чыгарсалар да, таба алмаслар. Иң яхшысы — ул хезмәтне син миңа тапшыр.

Кәрим. Сиңа? Кемдә икәнен беләдеңме?

Галимҗан. Анысы сер инде.

Кәрим. Ярый, сер булса сер булсын, табып кына бир.

Галимҗан. Эзләү хезмәтенең әҗере ничек булыр бит!

Кәрим. Аннан эш тормас.

Галимҗан. Шулай да?

Кәрим. Гыйлаҗ байдан чыгартып, үз кибетемә приказчик итеп алырмын.

Галимҗан. Юк, аның өчен эшләмим.

Кәрим. Ярый алайса, Акком асты урамында, бурычка, бакалея кибете ачып бирермен. Әкренләп түләрсең.

Галимҗан. Юк, минем теләк икенче бер әйбер тирәсендәрәк иде.

Кәрим. Әйтеп кара, нинди әйбер икән ул? Төлке-тамак, кама бүрекме?

Галимҗан. Түгел.

Кәрим. Яшел чапан, кәҗүл читекме?

Галимҗан. Юк, алар да түгел.

Кәрим. Нәрсә соң, юрга ат белән таш пулат сорамыйсыңдыр бит? Йә, әйт инде!

Галимҗан. Оялам...

Кәрим. Оялма син, оялма. Йә, әйт инде, ай Алла!

Галимҗан. Байлык миңа кирәк түгел,
Кирәк түгел асыл зат.
Кирәк түгел таш пулатлар,
Зур дәрәҗә, юрга ат.
Минем теләк бик кечкенә,

Бик кечкенә бер бүләк.
Бу күңелсез яшьлегемә
Дәрт бирерлек ямь кирәк.
Ул ямь сездә, Кәрим абзый,
Сез дә шуны белегез:
Башмак табу хезмәтенә
Сәрвәркәйне бирегез!

Кәрим. Ничек, ничек дидең?..

Галимҗан. Сәрвәркәйне бирегез, дим.

Кәрим. Ах син, жулик малай! Башыңны сугып ярмас борын чыгып кит моннан!!!

Кәрим зонт күтәреп һөҗүм итә. Галимҗан, Кәримнең агачта эленеп торган җиләнен алып, башыннан каплый да чыгып китә. Өйдән Фәхрия чыга.

Фәхрия. Нәрсә булды, сиңа әйтәм!

Кәрим (*җиләнен салып*). Теге Гыйлаҗ байның приказчигын кыйнап чыгардым.

Фәхрия. Җилән астыннанмы? Ни өчен?

Кәрим. «Сәрвәреңне миңа бир, югалган башмакларыгызны табып бирәм», — ди. Шул тар балакка кадәр көлә бит.

Фәхрия. Юк, атасы, ул чынлап сөйли торгандыр. Сәрвәр белән араларында ни дә булса бар бугай. Нигә дисәң: бая мин монда килеп чыксам, ни күзләрем белән күрим... сөйләшеп торалар иде.

Кәрим. Шулаймыни?.. Алай булса, никахны ашыктырырга кирәк. Алла сакласын, Арыслановлар кызы шикелле, шул приказчик кисәгенә ябышып чыгар да куяр.

Фәхрия. Соң ничек, башмакның очы күренмиме?

Кәрим. Юк, анасы, юк. Бардым беренче частька, аннан икенче частька. Полицмейстерны күреп сөйләштем, бары да ярдәм итәрбез дигән булдылар. Ай, бу башмак башмак кына булмады, башка бәла булды бит! Менә озакламый кияү килер, икесен күрештерербез, шул чагында аягында башмаклары булмаса, ни дип җавап бирербез? Синең аш-суларың әзерме?

Фәхрия. Әзер. Чит кешеләр булмый торгандыр бит.

Кәрим. Аллам сакласын, безнең Казан халкын чакырырга ярыймы, бай кияүне тартып алулары бар. Мин хәзер кияүне алырга җибәрәм. Гаффар, Гаффар, дим!

Гаффар керә.

Гаффар. Нәрсәгә чакырдың, бай абзый?

Кәрим. Син хәзер резин көпчәккә кара айгырны җигәрсең.

Гаффар. Нәрсә, бай абзый, сабан туена барабызмы әллә?

Кәрим. Юк, «Болгар» номерында торучы Зыя әфәнде Гафуровны алып килерсең. Кара аны, күзеңне ачып йөр. Ул зур гәүдәле, иләмсез кеше. Безнең Казанның чокырлы-чакырлы урамнарыннан атыңны чаптырып, көпчәкне сындыра күрмә. Бөтен шәһәргә мәсхәрә ясарсың. Губернатор кучеры кебек, иплән кенә алып кил.

Гаффар. Ул турыда, бай абзый, кайгырма. Мин бит солдатта чакта янараллар йөрткән Гаффар!

Кәрим. Алдан мактанма, сүзең көфер килмәсен. Бар, эшеңдә бул.

Гаффар китә.

Кәрим. Фу!.. Башмак артыннан йөреп, тамагым кипте. Куйган самавырың юкмы?

Фәхрия. Бар, өстәлдә утыра. Әйдә, эчеп алырбыз.

Өйдән Сәрвәр чыга.

Сәрвәр. Әткәй, сабан туена халык китә башлады, без кайчанрак барырбыз икән?

Фәхрия. Әй кызым, шушындый башмак югалту кебек кайгылы көнебездә анда нишләп йөрербез икән?

Сәрвәр. Күңел ачып кайтырбыз. Үзегез бармыйсыз икән, миңа рөхсәт бирегез.

Кәрим. Юк, кызым, үзебез дә бармыйбыз, сиңа да рөхсәт бирмибез.

Сәрвәр. Кунак кызларының да барасы килә.

Кәрим. Аларны тотмыйбыз, барсыннар. Сиңа ярамый.

Сәрвәр. Кара әле, әти...

Кәрим. Җитте! Бу нинди итагатьсезлек?!

Кәрим белән Фәхрия кереп китәләр. Сәрвәр кайгырып кала. Койма башында Галимҗан күренә.

Галимҗан. Сәрвәр, Сәрвәр, дим!

Сәрвәр. Нәрсә бар?

Галимҗан. Бая сиңа әйтә алмадым, син җаный, саклан, башыңны ашарга йөриләр.

Сәрвәр. Ничек ашарга?

Галимҗан. Байлык, акчага кызыгып, сине Себер баена саталар.

Сәрвәр. Саталар?!

Галимҗан. Син кайгырма, чәнчелеп китсәләр дә, мин сине аларга бирмим. Тик минем сүзләремне генә тыңла.

Артта Кәрим тавышы: «Кем ул анда коймага менгән? Төш, дим, төш!» Себерке белән Галимҗанга суга, Галимҗан югала. Кулына себерке тотып, сәхнәгә ачулы

Кәрим керә.

Кәрим. Туры килерсең әле, урамда тотып яңакларга да мин күп алмам!

Сәрвәр. Әткәй, син мине байлыкка кызыгып сатасың икән.

Кәрим. Аны сиңа кем әйтте?

Сәрвәр. Теләсә кем булсын, шул сүз дөресме?

Кәрим (*йомшарып*). Кызым, әтиең сине начар кешегә сата... әй, юк, бирәме соң? Зыя Гафуров бөтен Себердә иң бай кеше санала. Аның өчен син миңа рәхмәт әйтерсең.

Сәрвәр. Мин аңа барганчы, үз-үземне харап итәрмен, Кабан күленә ташланырмын.

Кәрим. Кызым Бибисәрвәр, син минем бердәнбер балам, бердәнбер кадерле кызым...

Сәрвәр. Дөрес түгел!.. Әгәр дә мин кадерле булсам, карт кияүгә бирмәс идегез. Әткәй, ялынып сорыйм, харап итмәгез мине... Мин ул кешегә бармыйм!

Кәрим. Ата-анаң кушкач, барырсың!

Сәрвәр. Юк, бармам!

Кәрим. Барырсың!!! (*Өйгә кереп китә.*)

Сәрвәр ялгыз кала.

Сәрвәр. Ах, егетем, бар өметем хәзер,
Киләчәгем — синең кулыңда.
Ак бәхеткә диеп омтылганда,
Кара елан ята юлымда.
«Яшьлек — байлыктан кадерле»,— дисәк,
Коткар мине, коткар, җанкисәк!
Ах, егетем, белсәң иде хәзер
Күз алдымда минем кара төн генә...
Шул кара төн офыгыннан инде
Эзләгәнем фәкать син генә.
«Яшьлек — байлыктан кадерле»,— дисәк,
Коткар мине, коткар, җанкисәк!

Вафа керә, Сәрвәр янына килә.

Вафа. Балдызым, нишләп монда ялгызың?

Сәрвәр. Җанымны кая куярга белмәгәндә, эч пошырып йөрмә әле! Бар әнә, азаныңны әйт! (*Китә.*)

Вафа. Ничә еллар күзем салып
Йөрим сиңа, балдызым.
Пыскып янган чи кисәүдәй,
Мин янамын ялгызым.
Белмисең шул, белмисең,
Миңа күңел бирмисең.
Миндәй уңган җизнәкәйгә
Апаң бер дә пар түгел.
Таштай каты, боздай салкын,
Ир назлаучы җан түгел.

Кәрим чыга.

Сөям сине, сөям шул,
Ах, балдызым, диям шул.

Кәрим. Кемне сөясең?

Вафа. Юк, бабай, башмак өчен көям, дим.

Кәрим. Сөйлә, көеп нишләдең?
Вафа. Өч тапкыр талчукны әйләндем. Ике тапкыр ламбардка кердем. Бер тапкыр Яңа бистә кадәр җиргә җәяү бардым.
Кәрим. Нигә җәяү, нигә трамвайга утырмадың?
Вафа. Ашыкканда трамвайга утыралармыни?
Кәрим. Аннан?
Вафа. Аннан базардагы агай-энеләргә, чаттагы извозчикларга, кибеттәге приказчикларга, биржадагы подрядчикларга, хәрчәүнидәге половойларга, йөк ташучы ломовойларга күз-колак булырга куштым. Бары да, карарбыз, диделәр.
Кәрим. Ишкәнсең икән ишәк чумарын! Тагын?
Вафа. Тагын урамда Галимҗанны күргән идем.
Кәрим. Кайсы Галимҗанны?
Вафа. Учительләр школасында укучы Галимҗанны.
Кәрим. Саташасың. Гыйлаҗ байның приказчигы Сәлимҗанныдыр.
Вафа. Түгел. Мин Гыйлаҗ приказчигын белмим, бу шул, Галимҗан иде.
Кәрим. Соң, соң, нәрсә ди?
Вафа. Юкка гына йөрисез, барыбер таба алмассыз, ди.
Кәрим. Табармын! Шәһәрдәге бөтен полицияне аякка бастырырмын, сыщиклар яллармын, җәһәннәмнең астына яшерсәләр дә, эзләп таптырырмын! Син хәзер Двор Фәхригә бар, бабай буш итмәм, дип әйтте, диң. Аларга бит тегендирәк кешеләр төшкәли икән.
Вафа. Ярый, бабакай, чәйдән соң барырмын.
Кәрим. Мондый кыяматтә нинди чәй ди ул? Кайткач тыгынырсың.
Вафа. Ярый, бабакай, ачуланма инде. (*Китә.*)
Кәрим. Тукта инде, Чемун Петровичка кереп, прошение яздырып чыгарга кирәк. (*Китә.*)

Өйдән борчулы Сәрвәр чыга.

Сәрвәр.Үсеп буйга җиткән идем,
Бәхет, шатлык көткән идем.
Ярым белән кавышуны
Чынлап өмет иткән идем.
Үз әткәем харап итте,
Бар шатлыгым ташлап китте,
Гомерем буе кайгы йотып,
Көн күрергә вакыт җитте...
Әгәр сүзләрең дөрес булсалар,
Минем тормыш бетте дигән сүз.
Төпсез упкынның алдында торам,
Егет булсаң, хәзер кулың суз.

Кызлар керәләр.

Кызлар. Нәрсә булды, Сәрвәркәем?
Ник боектың, алтыным?
Күзләрең дә сүнгән хәзер,
Кая синең шатлыгың?
Сәрвәр. Ах, дусларым, сөйли алмыйм,
Башым хәзер әйләнгән.
Бу күңелсез боегулар
Бер хәбәргә бәйләнгән.
Кызлар. Нинди бетмәс хәбәрләр ул?
Бер елмаеп көл инде.
Җан дусларың белән бергә
Күңел ачып йөр инде.
Сәрвәр. Теге егет килгән иде
Тагын минем каршыма.
Мәңгелеккә яшь түгәрлек
Кайгы салды башыма.
Кызлар. Сөйлә, сөйлә, нәрсә диде?
Сөйлә, дустым, тизрәк.
Сөйлә, серең яшермичә,

Сөйлә, түзми яшь йөрәк.

Сәхнә артында ат килеп туктый. Шуны ишетеп, Сәрвәр бәләкәй капка янына йөгереп бара.

Сәрвәр. Әнә, кызлар, күрегез!.. Минем кара бәхетем килә!
Хәлимә. Әнекәем лә... Бу нинди мәхәббәтсез кеше?
Нәсимә. Кара, кара, арбадан да төшә алмый.
Хәлимә. Әйдә, Сәрвәр, ул монда керә.

Кызлар Сәрвәрне алып китәләр. Иләмсез зур корсаклы
Зыя Гафуров керә.

Зыя. Төмән, Табул минем кулда,
Сими, Тургай, Акмулла.
Тиздән Себер сәүдәсенә
Минем байлык баш була.
Ашаганым әлбә генә,
Кигәннәрем хөллә генә.
Ашаганым хөллә генә,
Кигәннәрем әлбә генә.
Фу, җен, ялгыштым!
Тире-яры, ял-койрык,
Йон-ябага җыямын.
Мәскәү кебек шәһәрләргә
Меңәр вагон куямын.
Сансыз иткән табышым,
Юк дөньяда сагышым.
Сансыз иткән сагышым,
Юк дөньяда табышым.
Фу, җен, ялгыштым!
Бөтен җирем килешсә дә,
Тик хатыным өч кенә.
Шул өч хатын арасында
Син булырсың төш кенә.
Сандык тулы алтыным,
Өчәү генә хатыным.
Сандык тулы хатыным,
Өчәү генә алтыным.
Фу, җен, ялгыштым.

Кәрим кайтып керә.

Кәрим. Сөбханалла, машалла, Зыя әфәнде, килеп тә җиткәнсез. Зинһар, гафу итегез инде, башмак бәласе артыннан йөреп, сезне каршы да ала алмадым.
Зыя. Нинди башмак бәласе?
Кәрим. Әйтергә дә оят... Сез бүләк иткән асыл башмакларны югалттык.
Зыя. Югалттыгыз? Ничек?
Кәрим. Әйдәгез кунак бүлмәсенә. Бәйнә-бәйнә шунда сөйләрмен.

Зыя белән Кәрим кереп китә. Ярсыган рәвештә, өйдән Сәрвәр чыга, музыка астында үзен кая куярга белмичә аптырап йөри. Җиһан керә.

Җиһан. Сәрвәр кызым, газап чикмә,
Күз яшеңне юкка түкмә.
Сөйгәнеңнән хат китердем,
Бушка вакыт әрәм итмә.
Сәрвәр. Әбкәем...
Әбкәем!..
Җиһан. Чыкмас борын әткәң-әнкәң,
Укы тизрәк син, бәбкәем.
Сәрвәр. И гүзәлем,

Җиһан. Барма картка,
Сәрвәр. Син җанымның
Җиһан. Кисәге.
Сәрвәр. Карт кешенең
Җиһан. Мисле шулдыр —
Сәрвәр. Артка чыгар
Җиһан. Терсәге.
Сәрвәр. И гүзәлем,
Җиһан. Барма картка,
Сәрвәр. Багып аның
Җиһан. Малына,
Сәрвәр. Гомерлеккә
Җиһан. Хәсрәт алма
Сәрвәр. Син үзеңнең
Җиһан. Җаныңа.
Сәрвәр. И гүзәлем,
Җиһан. Барма картка
Сәрвәр. Әрәм итеп
Җиһан. Гомереңне.
Сәрвәр. Кап корсаклы
Җиһан. Хәшәрәткә
Сәрвәр. Син җибәрмә
Җиһан. Кадреңне.
Сәрвәр. Мондый үгет-нәсихәттән
Миңа хәзер ни файда?
Егет булса, тапсын иде
Коткарырга бер хәйлә.
Җиһан. Сабыр, кызым, сабыр, димен,
Әйтәм соңгы сүземне:
Ул кушканнарны тыңласаң,
Коткарачак үзеңне.

Артта кызлар тавышы.

Әнә киләләр, утыр шунда, авыруга сабыш, хаста булып кылан.

Сәрвәр авыруга сабыша.

Сәрвәр. Ах, ах...
Җиһан. Катырак, катырак.

Хәлимә белән Нәсимә керә.

Хәлимә. Сәрвәр, сиңа ни булды?
Сәрвәр. Авырыйм, кызлар, башым әйләнә...

Вафа, Гыйльми, Фәхрия керәләр.

Вафа. Нихәл, исән торасыңмы, балдызым?
Сәрвәр. Әллә нишләп кәефем китте, җизнәкәй.
Гыйльми. Ни булды соң сиңа, сеңлем,
Вафа. Балдызым, ялгызым.
Гыйльми. Сөйләп бирче безгә барын,
Вафа. Балдызым, ялгызым.
Сәрвәр. Башым минем бик авырта, җизнәкәй.
Вафа. Әйдә, алайса, бүлмәгә кер,
Гыйльми. Сәрвәркәй.
Вафа. Дога укып өшкерермен,
Балдызым, ялгызым.
Кызлар. Аннан, бәлки, сихәтләнер,
Вафа. Балдызым, ялгызым.
Фәхрия. Юк, юк, сиңа һич ярамый,

Гыйльми. Мин әйтәм,
Фәхрия. Шәригатьчә түгел алай,
Гыйльми. Сиңа әйтәм.
Фәхрия. Җиһан әбидән укытыйк
Җиде ясин догасын.
Гыйльми. Бәлки, бирер хак Тәгалә
Фәхрия. Аның сулыш дәвасын.
Җиһан. Булса да күп өйдән өйгә
Керәсем.
Фәхрия. Хәле авыр Сәрвәркәйнең,
Күрәсең.
Җиһан. Бик әйбәтләп өшкерермен,
Укып әлхәм сүрәсен.

Вафадан башкалар Сәрвәрне алып китәләр.

Вафа. Синең янда булу миңа
Насыйп түгел, күрәсең. (*Китә.*)

Кулына себерке тотып, Җаппар керә. Авыз эченнән мыгырданып, бакча себерергә керешә. Тупас хәрәкәтләре белән кемгәдер ачулануын белдерергә
тырыша. Гаффар кереп аңа карап тора.

Гаффар. Җаппар абзый, нигә ул кадәр чәпчедең?

Җаппар. Чәпчү генә түгел, чәнчелеп китәрсең! Көн юк, төн юк, ял бирмиләр, бәйрәм димиләр, ат шикелле эшлисең дә эшлисең, юньле сүз дә ишетмисең. «Син әрәмтамакның карамавы аркасында, коймадан кеше керә, биш йөз сумлык башмакларны урлаттык, түләтәм»,— ди.

Гаффар. Синнәнме?

Җаппар. Миннән шул! Ун ел буена жалунҗа бирмим,— ди.

Гаффар. Андыйга оста ул, булдырыр.

Җаппар. Пычагым булдырыр! Иртәгә үк заводка китәм.

Гаффар. Анда яхшы дисеңме?

Җаппар. Булмаса да, ач тамагым — тыныч колагым дигәндәй, ике кулыма бер эш булыр. Дворник, диләр дә бөтен эшләрен миннән эшләтәләр. Ул хатынны әйткән дә юк инде, бичара! Иртә таңнан кара төнгә кадәр алар эшендә. Малаема кадәр тынычлык бирмиләр, йомыштан йомышка йөртеп, теңкәсенә тияләр. Син миңа әйт әле, нигә безне кыса ул?! Әллә без аның колымы?!

Гаффар. Тукта әле, нигә миңа җикеренәсең?

Җаппар. Син аңа якынрак кеше, һәрвакытта аның белән бергә йөрисең, әйт үзенә.

Гаффар. Әйе, әйтерсең! «Хәзер куып чыгарам»,— дип акырырга тора. Кайтып керү белән миңа да бәйләнде, атка солыны күп тоткансың, арба маен кая куеп бетердең, имеш. Әйтерсең мин аны ипигә сылап ашаган. Ярминкәдән кайтып балаларга бер уч күчтәнәч тә бирмәде.

Җаппар. Саранның сараны. Карун инде.

Гаффар. Кирәкмәгән җирдә бик юмарт, төннәр буена тәтәйләрдә типтерә. Йөргән җирендә дә тик тормый икән. Әле бүген миннән ниндидер бер Мәтильдәгә тилиграм җибәртте. Әйдә шуны, Җаппар абзый, хатынына җиткерик, кыздырсын үзен.

Җаппар. Бик әйбәт булыр иде дә, тик ничек?

Гаффар. Чыгалар, әйдә әле...

Җаппар белән Гаффар китәләр. Сәрвәрне җитәкләп, Җиһан чыга.

Җиһан. Әйдә, кызым, мондый вакытта кыю булырга кирәк.

Сәрвәр. Тукта әле, әби, әткәй: «Кая бардың?» — дип сораса, ни дип җавап бирермен?

Җиһан. Әйттем бит инде, күрәзәчегә башмакларны каратырга бардым диярсең.

Сәрвәр. Ышанмасалар?

Җиһан. Берничә тапкыр Алла белән ант итәрсең.

Сәрвәр. Алай эшләү язык була бит.

Җиһан. Карт кияүгә көчләп биргәндә язык — казык башында.

Сәрвәр. Юк, әби, булмый, куркам.

Җиһан. Ярый, теге ит бүкәненең хатыны булгач, әллә нәрсәләр эшләргә риза булырсың да, эш узган булыр. Хуш, мин киттем!

Сәрвәр. Тукта, әби! Әйдә, Аллага тапшырдым!..

Җиһан белән Сәрвәр китә. Шат күңелле Кәрим бай өйдән җырлап чыга.

Кәрим. Булды, булды, булды шул,
Бәхет кулын сузды шул,
Көнче дошманның сүзләре
Аяк асты калды шул!
Кәрим бай, Кәрим бай!
Эшең хәзер бик уңай,
Үз гомереңдә төпкә утырттың
Бик күпләрне син шулай.
Бай кияүле дәүләт белән
Дөньясында типтерәм!
Ярминкәдән ярминкәгә
Кызлар белән сиптерәм!
Кәрим бай, Кәрим бай!
Эшең хәзер бик уңай!
Үз гомереңдә төпкә утырттың
Бик күпләрне син шулай.

Фәхрия өйдән чыга.

Фәхрия. Кунагың кая, сиңа әйтәм, әллә киттеме?

Кәрим. Юк, госел бүлмәсендә, тәһарәт яңарта.

Фәхрия. Кара әле, сиңа әйтәм, ялгышмыйсыңмы? Бу кияү булачак кешең үзе юан, үзе карт, үзе шадра, үзе иләмсез...

Кәрим. Мәхәббәт җәмал теләмәс, дигән бабайлар. Аның кесәсе бик чибәр, бөтен Себер, казах даласы аның кулында. Бар, син хәзер әйт, Сәрвәрне киендерсеннәр, бераздан үзләрен күрештерәбез.

Фәхрия. Күрештерәбез? Гадәттә булмаганнымы?

Кәрим. Зыя әфәнде: «Бер кат авызым еште инде, монысын күреп алам»,— ди.

Фәхрия. Шул кыяфәте белән дә сайлап алам дигән буламы? Сәрвәр авырып тора әле.

Кәрим. Нәрсә булган?

Фәхрия. Кисәктән генә туңа, калтырана башлады. Җиһан әби үзен өшкерә.

Кәрим. Җиһан әби өшкерә? Чеп-чи надан ич ул!

Фәхрия. Надан булса да, сулышын аның бик шифалы, дип сөйлиләр.

Кәрим. Әйе, кызың тирәсендә күбрәк йөртсәң, бөтенләй дә өшкереп куяр ул.

Фәхрия. Әнә кунагың тәһарәт алып бетергән.

Кәрим. Бар, Сәрвәрне киендерегез.

Зыя чыга. Фәхрия китә.

Кәрим. Әйдәгез, Зыя әфәнде, бирегә, сәйранга рәхим итегез.

Зыя. Яхшы, яхшы, Кәрим әфәнде.

Кәрим. Шулай итеп, Зыя әфәнде, никахны иртәгә өйләдән соң укытырга булдык.

Зыя. Ярый, Кәрим әфәнде. Истә чакта мин сезнең виксельләрегезне биреп куйыйм әле.

Кәрим. Кирәкмәс иде, Зыя әфәнде, иртәгә никахтан соң бирер идегез.

Зыя. Юк, мин янда кәгазь йөртүне яратмыйм. Мәгез, нәкъ илле сигез мең.

Эзләүчеләр керәләр.

I эзләүче. Князь Кәрим Хисамутдинов кайсыгыз була?

Кәрим. Без идек. Сезнең үзегезне кем дип таныйк?

Эзләүчеләр. Кайда акча, кайда букча,
Кайда байлык күзлибез.
Кайда качып, кайда посып,
Каракларны эзлибез.
Кайда базда, кайда сазда,
Кайда эзне юабыз.
Кайда бандит, кайда жулик,
Кайда сукбай куабыз.
Кайда камап, кайда ямап,
Кайда тотып алабыз.
Кайда этеп, кайда төртеп,

Казематка салабыз.

Кәрим. Әфәнделәр, башмакларның ничек югалуы турында менә бу прошениедә бәйнә-бәйнә язылган.

I эзләүче. Әйе, прошение ачык һәм пунктуальне язылган. Каракның берәр эзе-фәләне калмаганмы?

Кәрим (*кесәсеннән чыгарып кәгазь күрсәтә*). Менә язу калдырган.

I эзләүче (*кәгазьне алып, иснәп карый*). Бик үткен карак булырга кирәк. Имзасын куймаган.

II эзләүче. Тик югалган башмакларның бәясен генә күрсәтмәгәнсез.

Кәрим. Анысы тәгаен кирәкме?

II эзләүче. Һичшиксез. Чөнки, өегезгә чакыртуыгыз өчен закон уложениесенең бер йөз дә җитмеш бишенче статьясы буенча, сез безгә шул суммадан биш процент акча түләргә тиешсез.

Кәрим. Кызык икән. Әйберем дә югалсын, акча да түлә, имеш!

I эзләүче. Шуның өчен дә ул, әфәндем, закон! Күпме куябыз?

Зыя. Биш йөз сум.

II эзләүче. Алай булса, биш бишең — егерме биш... Тиешле булган егерме биш сумны безгә бирегез!

Кәрим. Зыя әфәнде, минем акчам банкта иде, биреп торыгыз, мин сезгә иртәгә түләрмен.

Зыя. Ярый, ярый, Кәрим әфәнде. Мәгез, сезгә чек. (*Чек бирә.*)

I эзләүче. Хәзер сез югалган башмакларны табу хакы итеп, закон уложениесенең бер йөз дә сиксән өченче статьясы буенча, әлеге сумма исәбеннән ун процент алдан түләп куярга тиешсез.

Кәрим. Соң, бит әле яңа гына алдыгыз.

II эзләүче. Анысы югалган әйбернең урынына чакыру өчен иде.

I эзләүче. Монысын эзләү — хезмәт хакы итеп сорыйбыз.

Кәрим. Зыя әфәнде, моңа ни дисез?

Зыя. Бирергә кирәк.

Кәрим. Бирергә булса, әйдә, бирегез, минем акчам банкта.

Зыя. Мәгез, рәхим итеп алыгыз. (*Тагын чек бирә.*)

Кәрим. Иншалла, башмакларны табарсыздыр инде?

I эзләүче. Тыныч булыгыз, без ул караклар...

II эзләүче. Без ул каракларны, диң.

I эзләүче. Әйе, без ул каракларны эзләп табарбыз, тик сездән тагын да...

Кәрим. Закон буенчамы?

II эзләүче. Юк, монысы гадәт буенча, һәр борынга бишәр сум чәйлек.

Кәрим. Зыя әфәнде, сез ничек уйлыйсыз?

Зыя. Бирергә кирәк.

Кәрим. Бирергә булса, әйдә бирегез. Минем акчам банкта.

Зыя. Мәгез, бусын акчалата алыгыз. (*Акча бирә.*)

Эзләүчеләр. Тыныч булсын күңелегез,
Башмакларны табарбыз.
Ул мошенник каракларны
Казематка ябарбыз.

Эзләүчеләр китәләр.

Кәрим. Инде хәзер, Зыя әфәнде, мин сезне кызым белән таныштырам. (*Ишеккә барып.*) Кызым, Сәрвәр, Сәрвәрбикә, дим!

Өйдән Хәлимә белән Нәсимә чыга.

Кәрим. Барыгыз, Сәрвәрне бирегә җибәрегез.

Хәлимә. Нигә, ул биредә юкмыни?

Кәрим. Нишләп ул биредә булырга тиеш?

Нәсимә. Чөнки алар Җиһан әби белән бирегә, бакчага чykканнар иде.

Кәрим. Чыккач, кая соң, кая?!

Хәлимә. Мин аргы баштан карап килим әле, шунда утырмыйлармы? (*Бакчага китә.*)

Нәсимә. Мин бүлмәләрдән карап килим әле. (*Өйгә кереп китә.*)

Зыя. Кәрим әфәнде, бу нинди эш бу?

Кәрим. Борчылмагыз, Зыя әфәнде, хәзер аны табып чыгарырлар.

Өйдән Нәсимә чыга.

Нәсимә. Кәрим абзый, мин бөтен бүлмәләрдән карадым, берсендә дә юк.

Бакча ягыннан Хәлимә чыга.

Хәлимә. Кәрим абзый, ул бакчада юк.

Өйдән Фәхрия чыга.

Кәрим. Кызың кая?
Фәхрия. Кая булсын, бүлмәсендәдер.
Кәрим. Анда микән соң, кереп кара әле.
Фәхрия. Ай Алла... Әле яңа гына үзен Җиһан әби өшкереп тора иде.
Кәрим. Әйе, әйе, өшкергән! Әйттем мин сиңа, шул убырлы карчыкны якын җибәрмә, дидем! Юк, сулышы шифалы, имеш! Менә хәзер тап инде кызыңны! Әй сез, әрәмтамаклар, берегез дә калмый, бирегә!!! (*Кычкыра*.)

Төрле яклап хезмәтчеләр, приказчиклар, асраулар кереп тулалар.
Вафа кайтып керә.

Кәрим. Мин сездән сорыйм: кая Сәрвәр?!
Вафа. Сәрвәр? Мин аларны хәзер генә күрдем ич.
Кәрим. Кайда?
Вафа. Кабан күле буенда.
Кәрим. Кем белән?
Вафа. Җиһан карчык белән.
Кәрим. Алар анда нишлиләр?
Вафа. Пароходка утырып, сабан туена киттеләр.
Кәрим. Ә?.. Сабан туена киттеләр? Мәми авыз! Нигә тотмадың, нигә җибәрдең?
Вафа. Мин аларны сезнең рөхсәт белән баралар дип уйладым.
Зыя. Кәрим әфәнде, бу миңа бер дә ошамый! Башмаклар югалды, кызың чыгып качты, мин хәзер виксельләремнең очып китүеннән курка башладым, сез аларны миңа кайтарып бирегез.
Кәрим. Алар өчен борчылмагыз, Зыя әфәнде. Алар бик ышанычлы җирдә — минем кесәмдә, ә кызны инде табарбыз. Гаффар, кара айгырны җик, эзләргә китәбез! (*Китә*.)
Зыя. Шулай да, Кәрим әфәнде, виксельләрне миңа биреп куегыз әле. (*Кәрим артыннан китә*.)
Хор. Мөмкин түгел яшь кошчыкны
Ябып кую читлеккә.
Китте очып ул бүгеннән
Ireккә,
Ireккә!
Беркайчан да бу якларга
Кире әйләнеп кайтмас.
Чөнки монда кунар агач
Ул тапмас,
Ул тапмас!
Бер генә дә җанга рәхәт
Ямь тапмас,
Ямь тапмас!
Инде хәзер киң далада
Бөдрә таллар сайласын.
Шул талларга көн дә кунып
Сайрасын,
Сайрасын!
Моңлы, нәфис авазлары
Еракларга яңгырасын,
Һәркем аны таңда торып
Тыңласын,
Тыңласын!
Әйдә, шунда озак еллар
Моңлансын,
Моңлансын!

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Пәрдә ачылмастан, музыка астында халыкның сабан туена барышы бирелә: авансценадан төркем-төркем булып ирләр, егетләр, кызлар, хатыннар, йөгерешчеләр, көрәшчеләр, ат чабучы малайлар, мәдрәсә шәкертләре, хәлфәләр, һөнәрчеләр, грузчиклар үтеп китә-

ләр. Барысы да бәйрәм киеменнән. Алардан соң колга башларына сөлге, яулык, түбәтәй, чиккән такыя, читекләр элгән сабан туе башлыклары узалар. Аннан, иптәш егетләрен ияртеп, Галимҗан китә. Алар артыннан, күзәтеп, эзләүчеләр баралар. Алардан соң өс-башларын алыштырып кигән хәлдә, Җиһан белән Сәрвәр уза. Алар артыннан Кәрим белән Гафуров китә. Иң ахырдан Хәлимә, Нәсимә, Вафа, Гыйльми, Җаппарларны ияртеп,

Фәхрия үтеп китә. Пәрдә ачыла.

Аркадия бакчасы. Бер якта террасалап салынган җәйге ресторан бинасы тора. Анда берничә өстәл. Артта Кабан күле, аның аръягында Казан шәһәренең тау як

өлеше һәм Кремль күренә. Террасада Галимҗан.

Галимҗан. Сахраларга чыксам ялгыз башым,
Сахраларда синсез ямь булмас.
Бер көрәшкәч, озак без сөйләшик,
Көрәшүләр тагын тиз булмас.
Көтәм сине, өзелеп мин көтәм,
Кил яныма, бәгърем, кил, иркәм.
Сахраларга чыгып, хәлләр җыям,
Хәлләр җыям карап тирәккә.
Буй-сыннарың тора күз алдымда,
Мәхәббәтең тирән — йөрәктә.
Көтәм сине, өзелеп мин көтәм,
Кил яныма, бәгърем, кил, иркәм.
Сахраларга чыгып йөргән чакта,
Мин хушланам чәчәк исенә.
Шул чәчәкләр исен иснәү белән,
Син төшәсең минем исемә.
Көтәм сине, өзелеп мин көтәм,
Кил яныма, бәгърем, кил, иркәм.

Әллә сабан туе бетте инде, халык шаулаша. Ә алар һаман юк.

Карана-карана, I эзләүче үтеп китә.

Галимҗан. Ни өчен бу кеше минем арттан йөри икән? Әһә!.. Кәрим бай: «Полициягә хәбәр иттем, сыщиклар җибәрергә булдылар»,— дигән иде, бу шуларның берсе микәнни?

Иптәш егетләре керә.

Дусларым! Минем арттан күзәтәләр. Башмакларны үзегез белән алыгыз. Миңа шундый ук төен бирегез. Әнә алар тагын монда киләләр. Сез китегез.

Егетләр китәләр. Эзләүчеләр керә.

I эзләүче. Әфәндем, сез ни өчен сабан туе кызыкларын карамыйсыз?
Галимҗан. Иптәшемне көтәм, сыйланырга булган идек.
II эзләүче. Әйдәгез, безне сыйлагыз.
Галимҗан. Минем акчам юк.
II эзләүче. Кызганыч.
I эзләүче. Рөхсәт итегез «Дюшес» папиросы белән сыйларга?
Галимҗан. Рәхмәт, үземдә яхшырагы бар.
I эзләүче. Нинди товар белән сату итәсез?
Галимҗан. Карагыз әле, әфәнделәр, нигә сез мине мондый сораулар белән борчыйсыз?
II эзләүче. Сезнең белән танышасыбыз килә.
Галимҗан. Ә менә минем сезне күрәсем дә килми. (*Торып китә башлый.*)
I эзләүче. Кулыгызны күтәрегез!
Галимҗан. Карагыз әле...
II эзләүче. Сөйләнмәгез!

Галимҗан теләр-теләмәс кенә кулын күтәрә, култык астындагы төене җиргә төшә, эзләүчеләр аны алып актаралар.

I эзләүче. Бу нинди чүпрәкләр?
Галимҗан. Сабан туенда көрәшеп алган бүләкләрем. Җәмәгать урынында тупаслык эшләүчеләрне кем дип таныйм?
II эзләүче. Менә без кем булабыз! (*Билетын күрсәтә.*)
I эзләүче. Шулай да без аның кулын куйдырып карыйк әле. Менә шул кәгазьгә нинди дә булса бер сүз язып бирегез.

Галимҗан. Сезгә нигә ул?

II эзләүче. Тикшерү аныклыгы өчен.

Галимҗан сул кулы белән яза башлый.

II эзләүче. Нигә уң кулыгыз белән түгел?

Галимҗан. Мин сулагай: бервакыт шушы кулым белән үгезне сугып үтергән идем. Әйдәгез көч сынашабыз!

II эзләүче. Йә, йә... язуыңны бел!

Галимҗан (*яза да иҗекләп укый*). Ду-рак!

I эзләүче. Кем дурак, безме?

Галимҗан. Түгел, мин дурак.

II эзләүче. Шулай диң. «Син» дигән сүзне өстәп яз.

Галимҗан (*язып укый*). Син ду-рак.

II эзләүче. Болай булгач инде, әлбәттә, эш башка. (*Галимҗан калдырган язу белән чагыштырып карый да I эзләүчегә.*) Аның кулына якын да килми.

I эзләүче. Сезнең әтиегез кем була?

Галимҗан. Урман Чытырманов.

I эзләүче. Беренче кат ишетүем. Кем соң ул?

Галимҗан. Присяжный поверенный, сезнең полицмейстерыгызның иң якын дусты.

II эзләүче. Нигә сез аны башта ук әйтмәдегез?

Галимҗан. Сез аны миннән сорамадыгыз.

I эзләүче. Гафу итүегезне үтенәбез. Безнең хезмәт шундый бит.

II эзләүче. Сез, әлбәттә, бу тентү вакыйгасын беркемгә дә белдермәссез, сер итеп сакларсыз, дип ышанабыз.

Галимҗан. Әлбәттә.

II эзләүче. Борчуыбыз өчен кичерегез. Хушыгыз.

Галимҗан. Алдыгыздан артыгыз.

Эзләүчеләр китәләр. Галимҗанның иптәшләре керәләр.
Эзләүчеләрдән көләләр.

Галимҗан. Дусларым! Әйдәгез, Сәрвәрләрне эзләргә киттек. Татлы ашамлыклар сата торган җирдә йөрмиләр микән? Безнең Казан кызларын тәмле ашарга ярата, диләр бит.

Галимҗан иптәшләре белән китә. Кәрим белән Зыя керә.

Зыя. Кәрим әфәнде, юкка гына без аларны моннан эзлибез. Алар, минемчә, кайда булса да аулак җирдә булырлар.

Кәрим. Зарар юк, карарга булгач, бөтен җирне карыйк инде, Зыя әфәнде.

Эзләүчеләр йөгереп керәләр.

I эзләүче. Булды, князьләр, булды!

Зыя. Нәрсә булды?

Эзләүчеләр. Палаткалы кибеттә,

Ниндидер бер егеттә
Башмакларны күргәннәр,
Тоталмыйбыз ничек тә.
Бүлектәге түрәгә
Бер атлыны чаптырдык.
Булышырга, ярдәмгә,
Бер көтү эт чакырдык.
Алар килеп җиткәч тә,
Сабан туе беткәч тә,
Шиклеләрне тентибез,
Кайгырмагыз сез һич тә.

Кәрим. Әй әфәнделәр, башмак бәласе ул баласы гына, мичтә калган аның анасы дигәндәй, безнең башта хәзер башка бәла казасы.

II эзләүче. Нинди каза?

Кәрим. Кызыбызны урлаттык.

II эзләүче. Кемнән?

Кәрим. Бер убырлы карчыктан. Менә шуны эзләп йөрибез. Зинһар, безгә ярдәм итегез.

II эзләүче. Була ул, князь, хәзер табып бирәбез.
I эзләүче. Тик башта сез кызыгызның суммасын әйтегез.
Кәрим. Нинди суммасын?
II эзләүче. Үзегезгә тору бәясе.
Кәрим. Зыя әфәнде, нинди бәя куябыз?
Зыя. Белмим. Кызлар белән сәүдә иткәнем юк. Ата кеше, үзегез белегез.
Кәрим. Әгәр дә миңа кайтарып биргән илле сигез меңлек виксельләр бәясен куйсак?
Зыя. Ярый, куегыз.
I эзләүче. Ул чагында, закон уложениесенең бер йөз дә сиксән өченче статьясы буенча, чакыру өчен биш процент акча түлисез.
Кәрим. Алдашмагыз, чакыру булмады, сез үзегез килдегез.
II эзләүче. Ярый алайса, чакыру проценты төшеп кала. Эзләү өчен тиешле булган ун процентны бирегез. Ягъни кызыгызның үзегезгә тору бәясе илле сигез меңнән — биш мең сигез йөз сумны хәзер үк бирәсез.
Кәрим. Зыя әфәнде, ни дисез?
Зыя. Бирергә кирәк.
Кәрим. Бирергә булса, әйдә бирегез. Минем акчам банкта.
Зыя. Ярый алайса, тагын мин сезгә чек бирим. Әүвәле-ахыры хәерле булсын. (*Чек язып бирә.*)
I эзләүче. Хәзер безгә кызыгызның аерым тамга-билгеләрен әйтегез.
Кәрим. Ничек инде ул «тамга-билгеләрен»?
II эзләүче. Буеның озынлыгы күпме?
I эзләүче. Авырлык үлчәве ничаклы?
II эзләүче. Күзләре нинди, кылый түгелме?
I эзләүче. Сакаулыгы юкмы телендә?
II эзләүче. Бераз гына бөкре түгелме?
I эзләүче. Аяклары ничек, кәкреме?
II эзләүче. Сипкел белән шадрасы юкмы битендә?
I эзләүче. Борыны курнос, тыңкыш түгелме?
II эзләүче. Кай җирендә миңе бар?
I эзләүче. Ничә теше алынган?
Кәрим. Җитте, җитте, Ходай өчен, туктагыз! Зыя әфәнде, бу сорауларга, бәлки, сез генә җавап бирерсез.
Зыя. Ничек итеп мин җавап бирим? Мин бит сезнең кызыгызның үзен түгел, күләгәсен дә күргәнем юк әле.
Кәрим. Әйдәгез, әфәнделәр, ристоранга. Шунда сөйләшербез.
II эзләүче. Менә бу акыл, ичмасам.

Зыя, Кәрим, эзләүчеләр ресторанга керәләр.
Җиһан белән Сәрвәр керә.

Җиһан. Әйдә, кызым, әйдә, менә шунда утырыйк.
Сәрвәр. Җиһан әби, кеше күреп әтиләргә җиткерсәләр нишләрбез?
Җиһан. Күңелебез тозаклы, телләребез йозаклы дигәндәй, безне кемнәр күрсеннәр дә кемнәр белсеннәр? Шулай да мин көрәш тирәсеннән карангалап килим әле.
Сәрвәр. Юк, юк, әби, үзем генә мин куркам.
Җиһан. Курыкма, кызым, монда һәммәсе дә үз эшендә. Син шул тирәдә йөреп тор. Мин хәзер әйләнеп килермен. (*Китә.*)
Сәрвәр. Ах, мәхәббәт, синең колың булып,
Үз-үземне утка салдым мин.
Көчле бураннарда юл адашкан
Юлчылардай ялгыз калдым мин.
Күңлем тулы төрле шик кенә,
Монда миңа бар да чит кенә.
Ах, мәхәббәт, тәмле хисләр белән
Хыяллатып, күңлем җилкеттең.
Яшь боландай куркак йөрәгемә
Чын кыюлык дәрте беркеттең.
Күңлем тулы төрле шик кенә,
Монда миңа бар да чит кенә.

Җиһан белән Галимҗан керә.

Җиһан. Менә, кызым, зарыгып көткәнең — каршыңда.

Галимҗан. Исәнмесез, Сәрвәр туташ!
Сәрвәр. Аллага шөкер әле.
Җиһан. Күреш, кызым, күреш, оялма. Балалар, әнә тегендә табарак, аулакка, «Пәри почмагы»на барыгыз.
Галимҗан. Әйдә, Сәрвәр туташ, шунда, аулакка... (*Култыкларга тели*.)
Сәрвәр. Җибәрегез!.. Мин үзем дә барырмын.

Сәрвәр, Галимҗан, Җиһан китәләр. Гаффар белән Җаппар керә.

Гаффар. Уф, эт булып арыдым!
Җаппар. Әйтмә дә, мин телдән калдым!
Гаффар. Үзебез дә дураклар инде, кеше рәхәтләнеп бәйрәм итә, сабан туе кызыкларын күрә. Ә без синең белән байның кияү эзләп киткән кызы артыннан йөрибез.

Бер-бер артлы Хәлимә, Нәсимә, Вафа, Гыйльми,
Фәхрия керәләр.

Хәлимә. Күрмәдегезме?
Гаффар. Юк.
Нәсимә. Тапмадыгызмы?
Җаппар. Юк, кызлар, юк.
Вафа. Очратмадыгызмы?
Гыйльми. Күргән кешеләр юк микән?
Җаппар. Аны каян беләсең мондый ахырзаманда.
Фәхрия. Алай булгач, нигә монда катып торасыз?
Гаффар. Күрәсең бит, байбикә, эзләп утырабыз.
Вафа. Әйдәгез, «Пәри почмагы» дигән җиргә барыйк, шунда түгелләр микән?

Барысы да китәләр. Галимҗан белән Сәрвәр керә.

Сәрвәр. Иртәгә үк яучы җибәр,
Әткәй-әнкәй аңар күнәр,
Шунда безнең чын мәхәббәт
Хәйлә-мәкерләрне җиңәр.
Галимҗан. Яучы белән мөмкин түгел,
Аңла, зинһар, бу — хатаң.
Учительгә кыз бирәме
Байлык сөйгән ул атаң?
Сәрвәр. Юк, юк, Галимҗан, кыстама,
Ул тәкъдимгә күнә алмыйм,
Әткәй-әнкәй ризалыгын
Алмый сиңа чыгалмыйм.
Галимҗан. Ул чагында китәм инде,
Хуш, исән бул гомергә.
Телим сиңа шул бай белән
Тигез гомер сөрергә.
(*Башмакларны биреп, китә башлый*.)
Сәрвәр. Тукта, тукта!
Ташлап китмә.
Шул пәригә әрәм итмә.
Син дә мин дип газап чикмә,
Мә, ал мине гомерлеккә!..
Икәү бергә. Менә шулай, менә шулай...
Зур бәхеткә ирештек.
Кабергәчә аерылмаска
Инде куллар бирештек.

Җиһан керә.

Җиһан. Күрәм, балалар, эшегез пешкән, ахры.
Галимҗан. Шулайрак, Җиһан әби.
Җиһан. Алай булса, балалар, җылы көйгә никахыгызны да укытып килегез.
Галимҗан. Кемнән?

Җиһан. Күл буендагы Таш мәчет мәдрәсәсендәге Ибраһим хәлфәдән. Мин аның белән сөйләштем. Килсеннәр, «Иҗабе кабул» ясармын, диде. Көймә белән барыгыз да укытып килегез.

Галимҗан. Ай безнең Җиһан әби! Барысын да белеп эшли ул! Мә, үзеңә хезмәт ялыңа! (*Акча бирә.*) Әйдә, Сәрвәр, киттек!

Сәрвәр белән Галимҗан китәләр.

Җиһан. И Галимҗан, бик булдыклы бала икәнсең,
Тел очымда исмең һаман ядлармын.
Миңа биргән шушы әҗер-ярдәмеңне
Һич онытмый инде истә саклармын.
Куандырдың, сөендердең,
Көзге көнем яз иттең.
Шатлыкларым эчемә сыймый,
Боек күңелем саз иттең.
Бик уңган шул әбиегез,
Гомер бирсен, диегез.
Миннән сезгә изге теләк, балаларым,—
Күгәрчендәй сөешеп гомер итегез.
Бетмәс байлык, түгәнмәслек дәүләт белән,
Карт имәндәй, өлкән яшькә җитегез.
Алты малай, җиде кызның
Ата-анасы булыгыз.
Шушы бәхет өчен инде
Миңа дога кылыгыз.
Җиһан бит ул, Җиһан ул,
Бигрәк зирәк, уңган шул!

Исерек хәлдә Кәрим керә. Җиһанны күреп туктап кала. Киемнәрен төзәтеп, бүреген кыңгыр салып кия. Җиһан янына килә.

Кәрим. Тутакай, яныгызга утырырга ярыймы?

Җиһан (*тавышын үзгәртеп, яшьләрчә кыланып*). Утырыгыз, рәхим итегез...

Кәрим. Күңел ачарга чыктыгызмы?

Җиһан. Әйе, шулай иде шул...

Кәрим. Бик күркәм, бик яхшы... Ләкин ни өчен сабан туе кызыкларын карамыйча, берүзегез генә монда утырасыз?

Җиһан. Сабан туе — ирләр бәйрәме. Минем кебек япа-ялгызга анда нинди ямь?

Кәрим. Ирегез кайда, әллә Мәкәрҗәдәме?

Җиһан. Юк, үткән ел вафат булган иде.

Кәрим. Шулаймыни? Бәрәкалла, бик күркәм эш, бик әйбәт... Соң ничек, ирсез гомер сөрү кыен түгелме?

Җиһан. Кыен булса нишлисең, түзәсең инде...

Кәрим. Җиләк кебек чагыгызны әрәмгә үткәрмәскә, иргә чыгарга иде.

Җиһан. Күңелгә ошардае туры килгәне юк әле...

Кәрим. Алай булса, тутакай, мин сине бик әйбәт бер иргә димлим әле, ризамы?

Җиһан. Белмим шул. Нинди кешедер бит ул?

Кәрим. Алла биргән бәндә инде! Бәхетең бар икән, шәһәрдә ике мәгәҗине, авылда ике утары бар. Йә, ни дисең?

Җиһан. Үзен күреп сөйләшмичә, бер сүз дә әйтә алмыйм. Бәлки, ул аксак-туксактыр...

Кәрим. Юк, юк, тутакай, бөтен җире сау-сәламәт, минем кебек япь-яшь бер кеше. Йә, ризамы?

Җиһан. Кем соң ул?

Кәрим. Менә мин үзем. Йә, ни дисең?

Җиһан. Белмим шул...

Кәрим. Кая, тутакай, болай таба карап утырчы.

Җиһан. Кирәкми, мин бик оялам...

Кәрим. Оялма, оялма, без бит хәзер үз кеше. Кая, йөзеңне ач әле.

Җиһан, йөзен ачып, Кәримгә таба әйләнә. Кәрим аптырап кала.

Кәрим. Ә... убырлы карчык, эләктеңме!.. Кая куйдың минем кызымны?

Җиһан. Мин синең кызыңны белгәнем дә, күргәнем дә юк, җибәр мине.

Кәрим. Әй, Гаффар, бире кил әле!..

Гаффар керә.

Кәрим. Менә кыз урлаучыны тоттым, саклап тор, мин сыщикларны алып киләм. (*Китә*.)
Гаффар. Йә, Җиһан әби, инде нишлибез? Син хәзер ристан, мин — сакчы.
Җиһан. Син мине, улым, җибәр, качты диярсең.
Гаффар. Алай гына ышанмаслар. Син минем борынга сук әле.
Җиһан. Ни өчен?
Гаффар. Сук, дим, тизрәк.
Җиһан. Тиктомалга нишләп мин синең чүмәлә кадәр танавыңа сугыйм ди?
Гаффар. Мин аларга: «Һөҗүм иттеләр!» — диярмен. Әйдә, сук!

Гаффар күзен йомып, борынын куеп тора. Җиһан алагаемга суга да кача. Гаффар борынын сөртә.

Гаффар. Ай-яй, яхшы кундырды бу... (*Кеше килгәнне күреп, сәхнә уртасына сузылып ята*.)

Эзләүчеләрне ияртеп, Кәрим керә.

Кәрим. Гаффар, син кайда?
Гаффар (*ыңгырашып*). Монда...
Кәрим. Син нишләдең, әллә үлдеңме?
Гаффар. Шулай бугай.
Кәрим. Сихерче карчык кайда?
Гаффар. Белмим, бернәрсә дә хәтерләмим. Ниндидер шайка миңа һөҗүм ясады.
I эзләүче. Ничә кеше иделәр?
Гаффар (*бармаклары белән санап*). Кырыклап.
II эзләүче. Кая таба киттеләр?
Гаффар. Әнә тегеләйгә...

Эзләүчеләр кире якка таба китә башлыйлар.

Кәрим. Туктагыз әле, нигә сез кире якка таба китәсез?
I эзләүче. Бу безнең эзләү методыбыз. Әйләндереп, чолгап алабыз.

Эзләүчеләр китәләр. Арып-талып, Зыя Гафуров керә.

Зыя. Кара инде, бу каһәрләр
Мине ташлап качтылар.
Башмак, виксель һәм акчалар —
Бар да җилгә очтылар.
Аһ, юләр мин, юләр мин,
Бу хурлыктан үләм мин.
Өч хатыным җитмәгәнме,
Нигә йөрдем котырып?
Кәләш тә юк, җанаш та юк,
Калдым комга утырып.
Аһ, юләр мин, юләр мин,
Бу хурлыктан үләм мин!

Кәрим. Зыя әфәнде, әйдә инде, сине көтәбез.
Зыя. Кая тагын?
Кәрим. Ристоранга. Хәл бетте бит, парлап җибәрик.
Зыя. Әйдә, мин хәзер аракы гына түгел, агу эчәргә риза.

Зыя белән Кәрим китәләр. Таза гәүдәле көрәшче Мортазаны кулларында күтәреп, грузчиклар керәләр.

Хор. Син, каһарман, батырларча
Ектың барсын бик таза.
Мәйдан тоткан даның белән
Мәңге яшә, Мортаза!
Сәет Баттал Газый кебек
Көч-гайрәт бар икән.
Данлы Казан шәһәрендә
Сиңа мәйдан тар икән.
Һәй-һәй-һәй-һәй!..
Бире, дуслар, бакчага,
Шәпләп күңел ачарга!

Сабантуйлар көн дә түгел,
Озын елга бер генә.
Шул сабантуй хөрмәтенә
Бәйрәм итик көр генә.

Төрле халык уеннары, яшь егетләр белән кызларның биюләре башлана. Бию бетүгә, еракtан тавыш ишетелә. Бары да тыңлыйлар. Бераздан, Җиһанны өстерәп, Кәрим керә.

Кәрим. Тоттым, каракны тоттым!..

Халык җыела. Фәхрия, Вафа, Гыйльми, Җаппар, Хәлимә, Нәсимә керәләр.

Фәхрия. Нәрсә булды, нинди тавыш бу?
Кәрим. Менә Сәрвәрне урлап качучы сихерче карчыкны тоттым!
Фәхрия. Җиһан әби, минем Сәрвәрем кайда?
Кәрим. Әйе, кая куйдың минем кызымны?
Вафа. Кая яшердең минем балдызымны?
Гыйльми. Кая яшердең минем сеңлемне?

Эзләүчеләр йөгереп керәләр.

Эзләүчеләр. Таптык, князь, таптык!
Кәрим. Кая ул?
Эзләүчеләр. Әнә, әнә, җырлап киләләр!
Кәрим. Качыгыз! Искәртмәстән тотып алабыз!

Төрлесе төрле җиргә качалар, Галимҗан белән Сәрвәр җырлап керә.

Галимҗан. Мәңге сүнмәс яшьлек уты төсле
Кичке шәфәкъ әле батмаган.
Бар халыкны уен-көлке кочкан,
Бар дөньяны шатлык каплаган.
Икәү бергә. Нинди рәхәт, нинди бәхет безгә,
Күккә ашардай йөрәк талпына!
Җәй кошлары сайрап бәйрәм итә
Безнең кавышу көне хакына.
Сәрвәр. Кара айга, кара сансыз йолдызларга:
Нинди матур алар балкыйлар.
Җем-җем итеп, өскә нурлар сибеп,
Безнең туйны зурлап котлыйлар.
Икәү бергә. Нинди рәхәт, нинди бәхет безгә,
Күккә ашардай йөрәк талпына!
Җәй кошлары сайрап бәйрәм итә
Безнең кавышу көне хакына.
Кәрим (*чыгып*). Җитәр!.. Чыдарлыгым калмады!
Сәрвәр. Харап булдык! (*Куркып ава*.)
Фәхрия. Әй, бәбкәем, әллә үлдеңме?
Кәрим. Шайтан да булмас, алыгыз шул өстерәлчекне!

Эзләүчеләр бара башлыйлар.

Галимҗан. Сабыр, Кәрим абзый, сабыр!..
Кәрим. Син салам сыйрак белән соңыннан сөйләшербез. Алыгыз шул үләтне!
Галимҗан. Әфәнделәр, якын килмәгез, аңа сезнең кагылырга хакыгыз юк.
Кәрим. Ничек хакыбыз юк, ул минем кызым!
Галимҗан. Дөрес, кызыгыз иде, хәзер ул минем хәләл җефетем!
Кәрим. Ах син, жулик малай! Бездән көләсең!
Галимҗан. Юк, Кәрим абзый, көлмибез. Безнең эш беткән инде, Сәрвәр, ә?
Сәрвәр. Э, э!
Кәрим. Ничек беткән, ничек?
Вафа. Әфәндем, эш нәрсәдә соң, сөйләп бирсәнче?

Галимҗан. Без Сәрвәр белән бер-беребезне яратышып йөри идек, сез аны Себер баена бирә башлагач, хәлфәгә бардык та «Иҗабе кабул» никахы укыттык.

Кәрим. Юк, юк, синең шикелле шарлатан хәлфәләр укыган никахны мин танымыйм!..

Галимҗан. Кәрим абзый, май кап!

Кәрим. Мин хәзер полицмейстерга барам. Эшне духовный субранҗәгә салам, син жуликны яптырам.

Галимҗан. Кәрим абзый, май кап, дим.

Кәрим. Май да капмыйм, бал да капмыйм, син малайны яптырам, яп-ты-рам!!!

Галимҗан. Ул чагында мин дә сине печатьле хатың белән каптырам!! (*Кесәсеннән конверт чыгарып ача башлый*.)

Кәрим. И!.. Караңгыда танымый да торам! Исәнме, энем Сәлимҗан?

Галимҗан. Түгел, Кәрим абзый, Галимҗан, диң.

Кәрим. Ничек Галимҗан? Син бит Гыйлаҗ байның приказчигы Сәлимҗан!

Галимҗан. Юк, Кәрим абзый, алар бар да хәйлә генә иде. Сәлимҗан да, Галимҗан да ул бер кеше — мин булам.

Кәрим. Кеше түгел — гыйфрит икәнсең! (*Галимҗанның колагына*.) Бир хатны!

Галимҗан. Туйдан соң.

Зыя (*арттан*). Кәрим әфәнде, син кайда?

Вафа (*аңа каршы барып*). Кил бирегә, йөрмә анда!

Зыя керә.

Зыя. Минем матур кәләшкәйне
Кайдан эзләп таптыгыз?
Галимҗан. Башмакларыңны ал менә,
Кыздан колак кактыгыз.
Җиһан. Яшь кәләшле булам диеп,
Ай-һай, зәһәр каптыгыз.
Галимҗан. Сәрвәркәем, әйдә киттек.
Сәрвәр. Морадларга инде җиттек.
Хор. Сезнең арттан йөри-йөри,
Без дә инде арып беттек!
Башмак та, кыз да табылды!!!
Киттек, туй ясарга киттек!!!

Пәрдә.

# ТАЙМАСОВЛАР

**(Патриотлар)**

*Пьеса өч пәрдәдә, алты күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Таһир Таймасов — карт эшче.
Шәмсия — аның хатыны.
Шәйхаттар
Солтан
Шәүкәт
Марат
Гөлшат
Кадрия — Солтанның хатыны.
Сания — күрше кызы.
Маһирә — артистка.
Искәндәр — теш врачы.
Кәнҗебикә — Шәмсиянең сеңлесе.
Шамил — Гөлшатның дус егете.
Шофер.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Тамашачыларга карап, зур дача балконы тора. Өйләнә-тирәдә алма, чия агачлары. Артта бормаланып Идел ага. Аның аръягында — болын, урманнар. Урман өстеннән Казан шәһәре күренә. Пәрдә ачылганда, Марат гамакта китап укып ята. Өйдән Шәмсия чыга.

Шәмсия. Улым, Марат, Марат, дим!

Марат. Нәрсә бар тагын?

Шәмсия. Әллә чукракландыңмы, нигә эндәшмисең?

Марат. Танк турында бик кызыклы китап укый идем.

Шәмсия. Куй әле шул танкларыңны. Өйдә су беткән, чиләкләрне ал да чәйгә чишмә суы алып мен.

Марат. Нигә инде хуҗа хатыныннан ташытмыйсың?

Шәмсия. Ул өйдә юк, калада.

Марат. Ул чагында апа ташысын.

Шәмсия. Аның кунаклары бар.

Марат. Әнкәй, күрәсең ич, минем эшем бар. Җиңгигә дә кушарга була бит.

Шәмсия. Җиңгәңә авыр әйберләр күтәрергә ярамый.

Марат. Миңа ярыймы?

Шәмсия. Бар, бар, телеңә салынма, кушканны эшлә.

Марат. Өй тулы хатын-кыз өстеннән егет башың белән су ташып йөр инде.

Шәмсия. Комы, балчыгы белән тутырма, әйбәтләп тондырып ал.

Марат китә. Җырлап Таһир керә.

Таһир. Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.

Шәмсия. Кайда йөрисең?

Таһир. Тау башында бакчада идем. Тукай кордашның шигырьләрен укыдым.

Шәмсия. Акрынрак, килен бала йоклата.

Таһир. Нәрсәгә күпеHowever епйөри ул?

Шәмсия. Кичә Солтангәрәй кайтырга булган икән дә, ни өчендер кайта алмаган, шуңа үпкәләгән. Пароход килә.

Таһир. Идел пароходы... Их... күңелле дә соң безнең Идел буйлары!.. Мондый матурлык, мондый хозурлык дөньяның бер җирендә дә юк.

Шәмсия. Каян беләсең? Дөньяны йөреп чыкканың юк ич синең.

Таһир. Йөреп чыкканым булмаса да, бик күп җирдә булганым бар. Дүрт-биш ел Кырымда, Кавказда ял иттем. Гражданнар сугышы елында Урта Азиядә Тянь-Шань таулары арасында булдым. Әмма мондагы кебек йомшак җилләрне, ягымлы кояшны, хәтфә төсле яшел болыннарны күрмәдем. Кырым-Кавказ дип авыз суларын корыталар, безнең монда ул курорт.

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.
Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...
(*Шәмсияне кочаклый.*)

Шәмсия. Кара, кара, әллә котырдыңмы? Җибәр, юньсез. *(Иснәп.)* Ә?.. Әйтәм аны телең ачылган, төшереп кайткансың икән.

Таһир. Бераз гына булды, Шәмсия. Пристаньга төшкән идем, бик яхшы сыра китергәннәр.

Шәмсия. Карт башың белән сыраханәгә кереп эчмәсәң, ярамагандыр шул.

Таһир. Эчсәм ни булган?

Шәмсия. Май ашаган песи кебек күзең майланган. Олы кешегә килешми.

Таһир. Бик килешә, сөяк-санаклар камырдай йомшарды.

Шәмсия. Картайганчы акыл кермәде, җиткән улларың, үскән кызларың бар, ә син, юләр, эчеп йөрисең.

Таһир. Бозмасын иде мәҗлес күркен
Акчасы беткән кеше;
Измәсен иде яшьләрне дә
Күптән яше үткән кеше.

Шәмсия. Әй, карт маймыл, үзе яшь, имеш.

Таһир. Яшь шул. Йөрәгем яшь, шуңа күрә бераз төшереп тә җибәрдем. Исеңдәме, без синең белән моннан утыз ел элек, авылдан килгәч, Алафузов баракларында газап чиккән идек? Ике ел тимер мич белән торып, өлкән балаларга салкын тидердек... Ә хәзер Таһир Таймасов Идел буендагы менә дигән дачада семьясы белән ял итә. Элекке вакытта эшче халыктан берәрсе генә булса да дачада торганны күргәнең бар идеме?

Шәмсия. Дача тагы. Җәй буена бер тапкыр, самавыр күтәреп, балалар җитәкләп, Бакалтайга чыгып керсәк тә, түбәбез күккә тия иде.

Таһир. Менә шул шул. Кара инде безнең балаларга: берсе орденлы танкист, икенчесе инженер, өченчесе шагыйрь, дүртенчесе доктор, бишенчесе урта мәктәп бетерә.

Шәмсия. Балалар дигәннән, ул Маратыңны тый әле. Кичә пристаньга зур пароход туктаган иде, бөтен Ослан балаларын ияртқән дә пароходның иң югарыгы җиреннән карлыгач булып Иделгә сикерә.

Таһир. Сикерсә, бик әйбәт. Очучы йә парашютчы булыр.

Шәмсия. Әй... Тел әрәм итеп шуның белән сөйләшеп торган булам. Әнә Хантимеровларның Марат белән бер яшьлек Чыңгызлары анасының рөхсәтеннән башка комлыкка да чыкмый. Синеке булса, пароход түбәсеннән сикерә.

Таһир. Хантимеровлар малае кебек балаң булуга караганда, булмавы мең өлеш артыграк. Ул баламыни?! Каза ул. Балаң булса, үткен булсын, кыю булсын. Мин, гомумән, юаш-куркак кешеләрне яратмыйм.

Кадрия керә.

Шәмсия. Йокладымы?

Кадрия. Көчкә.

Шәмсия. Уникенең берсе, унсигезнең сыңары дигәндәй, әллә нәрсә булды инде ул балага. Ашарга бирсәң — ашамый, йокларга салсаң — йокламый.

Кадрия. Шаулыйлар ич, бу тавышка бала ничек йокласын, шуның өстенә көн эссе.

Таһир. Иркәлисең, килен, иркәлисең, баланы алай тәрбияләргә ярамый.

Кадрия. Әй, куйсана, әткәй, әллә кыйнарга кушар идеңме?

Таһир. Юк, кушмыйм. Баланы никадәр иркәләсәң, шулкадәр бозыла гына. Чыгар бакчага, уйнасын, арысын, аннан ашар да рәхәтләнеп йоклар да.

Шәмсия. Әнә тагы уянды.

Кадрия. Рөстәм, бәгырем, хәзер барам, елама... (*Китә.*)

Таһир. Без дә үстек, Шәмсия, безнең балалар да үстеләр. Докторны да белмәделәр, авыруын да күрмәделәр. Әнә минем шагыйрем кайта.

Шәүкәт керә.

Шәмсия. Улым, бүген кайтмыйм дигән идең бит?

Шәүкәт. Шулай дигән идем дә, әнкәй, кадерле кунагыбыз хөрмәтенә кайтырга туры килде.

Таһир. Нинди кунак тагы?

Шәүкәт. Шәйхаттар абый кайтты.

Шәмсия (*кулындагы әйберләрен төшереп җибәрә*). Кайчан?

Шәүкәт. Бүген иртәнге самолет белән.

Шәмсия. Әйтәм аны ике-өч көннән бирле сул күз кабагым тарта иде, шуңа икән.

Таһир. Үзе кайда соң, нигә монда алып килмәдең?

Шәүкәт. Шәһәр комендантына күренергә китте, озакламый Солтан абый машинасы белән монда киләчәкләр.

Таһир. Әйдә, Шәмсия, аш-суыңны хәзерлә.

Шәүкәт. Менә, әткәй, яңа газеталар китердем.

Су күтәреп, Марат керә.

Шәмсия. Улым, Марат, тиз генә колхоз бакчасына барып, бер-ике пот әнеч алма алып кайт.

Марат. Тукта инде, әнкәй, бераз гына хәл җыйыйм.

Шәмсия. Соңыннан җыярсың, әнә Шәйхаттар абыең кайта.

Марат. Кем әйтә?

Шәмсия. Менә Шәүкәт абыең Казанда күргән.

Марат. Шәүкәт абый, чынлап та Шәйхаттар абый кайтамы?

Шәүкәт. Әйе, Марат, озакламый монда булачак.

Марат. Алай булгач, ух... (*Сикереп куя.*) Кая, әнкәй, капчыгыңны бир.

Шәмсия. Әйдә, акча да алырсың. (*Китәләр.*)

Таһир. Улым, мин кичә җәен тоттым.

Шәүкәт. Чынлапмы?

Шәмсия өйдән чыга.

Шәмсия (*бүлдереп*). Бая кызулык белән сораша алмадым. Шәйхаттар абыең бөтенләйгә кайтканмы, әллә кунакка гынамы?

Шәүкәт. Ике айга отпуск биргәннәр. Бер аен монда үткәрәм, бер айга Кавказга барам, ди. Шуннан, әткәй?

Таһир. Шуннан, улым, әниеңә сиздерми генә таңнан тордым да кармак карарга киттем. Су өсте шундый тын иде...

Шәмсия (*бүлдереп*). Абыеңның өс-башы ничек, әйбәтме?

Шәүкәт. Бик яхшы, әнкәй, барысы да яңадан. Абый үзе тазарган, тагын да матурланган. Күрсәгез, таный алмассыз. Сөйлә, әткәй.

Таһир. Шулай барып җитеп буекка ябыштым да әкрен генә җептән тарта башладым...

Шәмсия. Абыең өйләнәм-фәлән дип сөйләнмиме?

Шәүкәт. Ул турыда сөйләшергә туры килмәде. Йә, әткәй?

Таһир. Шулай әкрен генә җептән тарта башладым, ләкин җеп тартылмый, бу нәрсә, мин әйтәм. Төпкә эләккән дисәм, Идел уртасында нинди төп булсын, дим. Шуннан ни булса да булыр дип тарта башлаган идем, коточкыч...

Шәмсия. Килгәндә өйгә керденме?

Шәүкәт. Юк, әнкәй, кереп тормадым.

Таһир. Коточкыч...

Шәмсия. Ишекне яхшылап бикләсәләр ярар иде.

Таһир. Коточкыч...

Шәмсия. Зачетларың ничек соң?

Шәүкәт. Биреп бетердем, бүген берьюлы ике предметтан алдылар. Шуннан, әткәй?

Таһир. Сөйләмим.

Шәүкәт. Нигә?

Таһир. Әй, сез балык тотуның тәмен белә торган кешеләрмени?

Шәүкәт. Менә инде, үпкәләде дә.

Таһир. Монысы тагын, күзле бүкән.

Шәмсия. Шул балыгың белән колагымны тондырып бетердең инде. Миңа гына өч-дүрт тапкыр сөйләдең. Бер ун тапкыр күргән-белгәннәргә сөйләгәнеңне тыңладым.

Шәүкәт. Йә, әткәй, сөйлә инде.

Таһир. Юк, сөйләмим, хәтеремне калдырдың.

Шәүкәт. Сөйлә инде, үзеңә бик әйбәт бер күчтәнәч китердем.

Таһир. Кая, нинди күчтәнәч?

Шәүкәт. Менә, төрепкә тәмәкесе.

Таһир. Әй, күчтәнәч дигәч, башка нәрсәме дип торган идем. Ярый инде, улым, рәхмәт. Шуннан, улым, коточкыч зур балык өскә килеп чыкты да кармакны өзеп ычкынды.

Шәүкәт. Ычкынды?

Таһир. Әйе, улым, ычкынды.

Шәүкәт. Чынлап та җәен ите ашыйбыз икән дип тыңлап торган идем.

Таһир. Ычкынмаса тота идем дә, ычкынды шул.

Шәүкәт өйгә кереп китә.

Шәмсия. Балыкчы белән сунарчыдан ялганчы кеше юк инде. Аларның йә ычкына, йә җепләре өзелеп харап итә, йә, кулдан төшеп, суга кереп китә.

Марат чыга.

Марат. Менә, әнкәй, алма булды.

Шәмсия. Рәхмәт, улым, чоланга кертеп куй.

Киемнәрен чишенеп, өйдән Шәүкәт чыга.

Шәүкәт. Әйдә, Марат, су коенырга барасыңмы?

Марат. Хәзер, абый, бераз көт. (*Алма күтәреп өйгә кереп китә.*)

Шәмсия. Улым, Шәүкәт, Гөлшатларны күреп әйтерсең, самавырым өлгерде, чәйгә кайтсыннар.

Шәүкәт. Ярый, әнкәй.

Марат чыга.

Марат. Әйдә, абый.

Шәмсия. Улым, Марат, мин сине йомышка җибәрмәкче идем.

Марат. Кая тагын?

Шәмсия. Алма бәлеше пешерсәк, камырга сөт кирәк.

Марат. Су коенып кайтыйм инде, әнкәй, аннан барырмын.

Шәмсия. Аннары соң була, озакламый абыеңнар кайтыр, аңарчы камырны мичкә тыгарга кирәк.

Марат. Фу, билләһи, бетмәде.

Шәүкәт. Ярый, Марат, мин киттем, сөттән кайткач төшәрсең.

Марат. Ярый ла... (*Икесе ике якка китәләр*.)

Шәмсия. Атасы, Шәйхаттар балык ярата иде, бәлеш пешерсәк, балыгыбыз юк.

Таһир. Хәзер табабыз аны, түбән Алексейга төшәм дә сатып алам, шул гына.

Шәмсия. Бар алайса, еллап йөрмә, мин хәзер мичкә ягам.

Таһир китә. Кәнҗебикә керә.

Кәнҗебикә. Исәнме, апа!

Шәмсия. Әнекәем лә, Кәнҗебикә түгелме?

Кәнҗебикә. Әйе, апа, мин. Сау гына торасызмы?

Шәмсия. Шөкер әле, каян сине җил китереп ташлады?

Кәнҗебикә. Менә калага килгән идем дә, өегезгә барсам, ишегегез бикле. Шуннан бер күрше малаегыз монда өйрәтеп җибәрде.

Шәмсия. Калага берәр йомыш белән килгән иденме?

Кәнҗебикә. Синнән яшерен-батырын түгел инде, апа, мин кала белән авыл арасында кыты-мыты итәргә керештем.

Шәмсия. Алай икән. Соң, ничек, файдасы каламы?

Кәнҗебикә. Аллага шөкер, йөрсәң, кала икән, ике пот май китергән идем, гөрәнкә башына биш сум табыш белән сатып бетердем.

Шәмсия. Ничек яшисез, кияү ни хәлдә?

Кәнҗебикә. Бер көйгә. Ишеткәнсездер, теге елларны бик кыстылар, кыерсыттылар. Киявегез өч ел Биламорда йөреп кайтты. Соңгы елларда, Аллага шөкер, алай какмыйлар-сукмыйлар, колхозда эшләп ятабыз.

Шәмсия. Бәхетең бар икән, бәйрәм көнебезгә юлыктың.

Кәнҗебикә. Нинди бәйрәм тагын ул?

Шәмсия. Казанга Шәйхаттар кайткан, аны көтәбез.

Кәнҗебикә. Ул кайда иде соң?

Шәмсия. Кытай ягында гаскәри хезмәттә иде, күптән түгел генә үзен орден белән зурладылар.

Кәнҗебикә. Шулаймыни?

Шәмсия. Аннан Гөлшатыбыз докторлыкка укып бетерде, шул уңай белән иптәшләрен кунакка җыйган иде.

Кәнҗебикә. Солтангәрәйне өйләнгән икән дип ишеткән идек, хатыны нинди кеше, әйбәтме?

Шәмсия. Болай төскә-биткә чибәр, укыган, агроном, ләкин бик аксөяк, өй эшен бер дә яратмый. Синең килүең яхшы булды әле, миңа булышырсың.

Марат керә.

Марат. Әни, сөтеңне өйгә кертеп куйдым.

Шәмсия. Рәхмәт, улым. Апаң белән күреш, әллә танымыйсыңмы?

Кәнҗебикә. Танымас та шул, сезгә килмәгәнгә ун ел тула инде.

Марат. Таныйм, Кәнҗебикә апа бит.

Кәнҗебикә. Бу кайсысы була соң, игезнең сыңарымы?

Шәмсия. Түгел. Игезләр Гөлшат белән Шәүкәт ул. Бу — Марат, җиде айдан туган төпчегем.

Кәнҗебикә. Кара син аны, нинди зур егет булган.

Шәмсия. Улым, син миңа утын ярып бир инде.

Марат. Әнкәй, анысын әткәй дә эшли ала, нигә тагы миңа кушасың инде?

Шәмсия. Әтиең өйдә юк, бар, бәбкәм, вак кына итеп ярып бир. Әйдә, Кәнҗебикә, өйгә кер.

Марат белән Кәнҗебикә китә, Гөлшат керә.

Гөлшат. Әнкәй, Шәйхаттар абый кайта диме?

Шәмсия. Әйе, кызым. Кайта шул...

Гөлшат. Нинди зур шатлык...

Шәмсия. Әйтмә инде, кызым, ишетүгә үзем дә аптырап калдым.

Гөлшат. Мин аны шулкадәр сагындым, шулкадәр сагындым. Күргәч, еламыйча чыдамам.

Шәмсия. Кызым, кунакларың кайда соң?

Гөлшат. Әнә Шәүкәт белән кайтып киләләр.

Маһирә, Шәүкәт, Сания, Шамил керә.

Маһирә. Шәмсия апа, тизрәк самавырыңны куй, үләм, эчәсем килә.

Шәмсия. Куйдым, Маһирә, куйдым, кайнап та чыккан.

Таһир керә.

Сания. Әбәү, нинди зур балык. Әллә тере инде?
Маһирә. Таһир абзый, үзең тоттыңмы?
Таһир. Билгеле, үзем.
Маһирә. Нәрсәгә эләктердең?
Таһир. Көмеш кармакка.
Маһирә. Кармакның көмеше дә буламыни?
Гөлшат. Шаярта, акчага алдым дигән сүзе.
Таһир. Туктагыз, машина тавышы...
Гөлшат. Абыйлар кайтты бугай.

Таһир белән Шәмсиядән башкалар китәләр. Бераздан Шәйхаттар, Солтан һәм башкалар керә.

Шәйхаттар. Әнкәй, исәнме!
Шәмсия. Балам, Шәйхаттар... Сине күрер көнем дә бар икән.
Шәйхаттар. Әткәй, саумы!
Таһир. Бик яхшы, улым... (*Күрешәләр*.)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шунда ук. Кичкә таба. Сәхнәдә беркем дә юк. Өйдә патефон уйнаган тавыш ишетелә. Балконга Кадрия, аның артыннан Солтан чыга.

Солтан. Кадрия, әллә авырыйсыңмы? Ташла инде шул үпкәләүләреңне. Кадрия, йә, миңа кара инде. (*Якын бара, Кадрия терсәге белән төртеп бакчага төшеп китә*.) Кадрия, син кая барасың? (*Аның артыннан югала*.)

Марат белән Искәндәр керә.

Марат. Апа, апа, дим...

Гөлшат чыга.

Менә сиңа кунак бар.
Гөлшат. Ә, Искәндәр! Әйдәгез, өйгә рәхим итегез.
Искәндәр. Гөлшат туташ, мине гафу итегез, кичә клиникада мөһим эшләрем булу сәбәпле, сезнең — студентларның — чыгарылыш тантанасында була алмадым. Соң булса да, врач булуыгыз белән тәбрик итәргә рөхсәт итегез.
Гөлшат. Рәхмәт, Искәндәр.
Искәндәр. Менә шушы кечкенә бүләгемне алсагыз иде. (*Парфюмерия гарнитуры бирә*.)
Гөлшат. Зурлавыгыз өчен рәхмәт сезгә.

Шәмсия чыга.

Шәмсия. Кызым, нигә кунакны чәйгә алып кермисең?
Гөлшат. Әнкәй, Искәндәр иптәш миңа бик зур бүләк китергән.
Шәмсия. Рәхмәт аңарга. Гаеп итмәгез, сез кем буласыз?
Искәндәр. Теш клиникасының докторы Искәндәр Абашев булам.
Шәмсия. Шулаймыни? Бик әйбәт, бик яхшы һөнәр иясе икәнсез. Әйдәгез, чәйгә.

Кереп китәләр. Бакчада Кадрия күренә, аның артыннан Солтан килә. Балконга менәләр, икесе ике җирдә сүзсез торалар.

Солтан. Их, бүген һава нинди саф... Кадрия, Идел өстенә кара әле, көзге төсле тип-тигез... Кадрия, син бүген шундый матурайгансың...
Кадрия. Эндәшмә миңа...
Солтан. Уһу, ничек ачулы... Сагындыңмы?
Кадрия. Телеңне әрәм итмә, барыбер сөйләшмим.
Солтан. Гафу ит, кичә кайта алмадым.
Кадрия. Хәлеңнән килмәгәч, вәгъдә бирмиләр аны. Имеш, иртәгә Осланга киләм. Бергә-бергә көймәдә йөрербез, куыша-куыша су коенырбыз, имеш.
Солтан. Нишлим, көтмәгәндә бик мөһим эш чыгып куйды, кисәктән генә бер инженерыбыз авырып китте, аның урынына төнге сменага калырга туры килде.
Кадрия. Нигә соң башкалар калмыйлар?

Солтан. Туры килгәндә, алар да калалар.

Кадрия. Юк, Солтан, сиңа әллә нәрсә булды, син һаман өлгермисең, һаман сиңа вакыт җитми, минем турыда, семьяң турында уйлап та карамыйсың.

Солтан. Дөрес, Кадрия. Соңгы айларда сиңа җитәрлек игътибар бирә алмадым. Ләкин минем оборона заводында эшләвемне онытырга ярамый. Күрәсең бит, капиталистик илләрнең дипломатлары илдән илгә самолетларда очалар, курьер поездларында чабалар. Без шуларны хис итәргә тиештер дип беләм.

Кадрия. Ләкин, үз интересыңнан кул селтәп, семья тормышыңны да онытырга ярамый.

Солтан. Әлбәттә, шулай һәм мин аны онытканым да юк. Мин дә бит кеше. Минем дә сөясем, иркәләнәсем, менә шушы Кадриямне назлыйсым килә. Менә озакламый отпуск алам, аннан икәүләп Кавказга ял итәргә китәрбез. Аннан кайтуга, яңа салына торган йорттан яхшы квартира бирәләр. Аннан инде, әткәйләрдән башка чыгарбыз да, рәхәтләнеп тора башларбыз. Йә, миңа кара әле.

Кадрия. Кирәкми, карамыйм.

Солтан. Менә Гөлшат белән икегезгә пардан сәгатьләр алдым.

Кадрия. Ах, нинди матурлар, кыйбат торалармы?

Солтан. Бирелгән бүләкнең хакын сорамыйлар. Йә инде, үпкәң беттеме?

Кадрия. Җен, эндәшмәм дигән идем. Тәмле теле белән эретте.

Солтан. Их, Кадрия, эштән бизәргә, эштән качарга ярамый. Эш кенә кешеләрне берләштерә, эш кенә кешеләргә семья тормышын төзергә ярдәм итә. Хәзер бала зур инде, сиңа да эшкә керергә кирәк. Югыйсә тормыштан артта калырсың.

Кадрия. Солтан, әйдә бакчага чыгабыз.

Солтан. Әйдә, шуннан Иделгә коенырга төшәрбез. (*Китәләр.*)

Өйдән Маһирә чыга, бакчадагы гамакка ятып китап укырга керешә. Шәүкәт чыга. Маһирә янына килеп, җырлап, гамакны тирбәтә.

Шәүкәт. Йокла, балам, йом күзең,
йом күзең,
Йокла, өмет йолдызым,
йолдызым.
Кичтән йокың кала да,
кала да,
Елап үтә көндезең,
көндезең.

Маһирә. Чү, егасың, Шәүкәт, егасың, дим...

Шәүкәт. Маһирә, өченчекөн газетада басылган минем «Патриотлар» дигән шигыремне укыдыңмы?

Маһирә. Әйе, укыдым.

Шәүкәт. Соң, ничек, тәнкыйтеңне ишетик.

Маһирә. Мин синең шигырьләреңне, Шәүкәт, яратам. Синең шигырьләреңдә җанга рәхәтлек бар.

Шәүкәт. Үземне ничек?

Маһирә. Үзеңне яратмыйм.

Шәүкәт. Ни өчен?

Маһирә. Ни өчен икәнен әйтмим.

Шәүкәт. Әйт инде, нинди гаебем бар? Мин алай тәнкыйтьтән курыкмыйм, ошамаган җирем бар икән, тот та күземә карап әйт.

Маһирә. Әйтмим, яратмыйм булгач яратмыйм. Шул гына.

Шәүкәт. Туры «комплимент»ың өчен рәхмәт. Ә мин, ишәк, аңа багышлап шигырьләр язган булам.

Маһирә. Миңамы?

Шәүкәт. Әйе, сиңа шул, син таш йөрәккә.

Маһирә. Кая, бир, укыйм әле.

Шәүкәт. Юк, укыма... Саф йөрәктән булган мәхәббәтем мәсхәрә ителгәч, җансыз лирам сиңа азык була алмас. (*Кулындагы кәгазен ертып ташлый.*)

Маһирә. Шәүкәт, нигә ерттың, нигә әрәм иттең? (*Җирдәге кәгазь кисәкләрен җыйнап.*) Менә инде укырлык та калмаган. Мәхәббәткә шулай җиңел карарга ярыймы? Мин бит шаярып кына әйткән идем.

Шәүкәт. Күптән шулай диләр аны. Тыңла, укыйм.

Маһирә. Әллә күңелдән беләсеңме?

Шәүкәт. Үз шигыремне дә яттан белмәгәч, мин нинди шагыйрь булам ди. Шигырьнең исеме — «Мәхәббәт».

Чын мәхәббәт алларында, иркәм,
Кемнәр генә тезен чүкмәгән?!
Кемнәр генә аның уты белән

Янып, каты газап чикмәгән?!
Бөек шагыйрь, хәтта философлар —
Бар да шулай өзелеп сөйгәннәр,
Җырларының көчле лирикасын
Мәхәббәткә алар биргәннәр.
Луизасын ничек сөйгән булса
Саф йөрәкле батыр Фердинанд,—
Мин дә сине шулай өзелеп сөям,
Шашып сөям барлык җан белән.
Мин, картаеп бөкрәйсәм дә,
Назлап сине һаман сөярмен.
Соңгы сулышым чыккан минутта да,
Сөям сине, бәгырем, диярмен...

Маһирә. Әйдә, әйдә, дәвам ит.

Шәүкәт. Бетте инде.

Маһирә. Их, иң кирәкле җиренә җиткәч кенә өзгәнсең.

Шәүкәт. Сәнгать һәм шигърият, бөтенесен әйтеп бетермичә, кыскача, төп фикерне генә бирергә тиеш. Йә, ничек?

Маһирә. Ярыйсы гына, татар тәнкыйтьчеләре әйтмешли, кытыршы әле, шомартасы бар. Күп урыннарда иҗекләрең сакланмый, кафияләрең ятышсыз чыгалар. Бигрәк тә соңгы өлешен көчәйтергә кирәк.

Шәүкәт. Билгеле, шулай. Мин бит аны бүген генә яздым. Шигырь бит ул бик күп көч куеп, озак вакытлар эшләү нәтиҗәсендә генә чын сәнгать үрнәге булу дәрәҗәсенә ирешә ала.

Маһирә. Шәүкәт, сиңа артист булу кирәк иде, чөнки синдә артист өчен кирәк булган сыйфатларның барысы да җитәрлек.

Шәүкәт. Шагыйрьлек өчен юкмы?

Маһирә. Алай димим, шулай да мин сине артист итәсем килә.

Шәүкәт. Юк инде, Маһирә, әдәбият патриоты булып калырга рөхсәт итегез. Киләсе елга институтны бетерәм дә, Гоголь әйтмешли, «кәгазь буярга керешәм». Маһирә, син һаман минем баягы сорауга җавап бирмисең.

Маһирә. Кайчан институтны укып бетерәсең, шул көнне миннән җавап алырсың.

Шәүкәт. Димәк, син принципиаль яктан каршы түгелсең, шулаймы?

Маһирә. Анысын инде сер итеп сакларга рөхсәт итегез.

Шәүкәт. Маһирә, син нигә мине газаплыйсың?

Маһирә. Шәүкәт, тотма беләктән, авырттырасың.

Шәүкәт. Авыртсын, миңа карата таш йөрәкле булуыңның җәзасы булыр.

Маһирә. Шәүкәт, җибәр, дим.

Шәүкәт. Җавап бирмичә җибәрмим.

Маһирә. Ул чагында каравыл кычкырам.

Шәүкәт. Булдыра алмассың.

Маһирә. Булдыра алмыйммы? Таһир абзый... (*Кычкыра.*)

Таһир чыга, Шәүкәт качып китә.

Таһир. Нәрсә бар, ни булды?

Маһирә. Юк, берни дә булмады.

Таһир. Кем соң кычкырды?

Маһирә. Мин... ни... елан күргән идем.

Таһир. Тау башында коры җирдә елан буламы?

Маһирә. Белмим шул. Әллә кәлтә елан булды инде.

Таһир. Ике аяклы елан булгандыр. Ә мин кармакка эләккәнсең дип курыккан идем. (*Китә.*)

Маһирә. Шәүкәт, син кайда?.. (*Агач арасына кереп югала.*)

Гөлшат белән Искәндәр чыга.

Искәндәр. Гөлшат, теге нинди егет ул?

Гөлшат. Кайсы?

Искәндәр. Әнә таза гына, тупас кына, синең белән янәшә утырган.

Гөлшат. Ә, Шамилне әйтәсең икән.

Искәндәр. Кем соң ул?

Гөлшат. Әтиләр белән бергә заводта эшли, производстводан аерылмыйча, очучылар мәктәбендә укый.

Искәндәр. Әйтәм аны үзен бик иркен тота. Мин аның урынында булсам, интеллигенция арасында барган сүзгә кысылмас идем.

Гөлшат. Аның турында юкка алай уйлыйсың. Бик акыллы егет ул.

Искәндәр. Күренеп тора, май чүлмәге тышыннан билгеле, ди. Монда нишләп йөри ул?

Гөлшат. Менә кызык… Бала чактан бирле бергә уйнап үскән иптәшем, минем бәйрәм көнемә кунакка килгән. Йә, Шәйхаттар абый, сиңа ошадымы?

Искәндәр. Әйе, кешеләр күз алдында үсәләр. Шәйхаттар күптән түгел генә шаян бер малай иде. Ул хәзер нинди үзгәргән, нинди җитдиләнгән. Их, Гөлшат, минем хәрби кеше буласым килә, әгәр дә Ватаныбыз чигенә дошман үтеп кереп сугыш була калса, мин, хөкүмәтнең чакыруын көтмичә, үз теләгем белән сугышка китәр идем.

Гөлшат. Кара, сез герой икән.

Искәндәр. Һу... Нинди генә әле. Мин бөтен табигый яратылышым белән герой булырга тиешле кеше. Чөнки миндә җитезлек, физик тазалык, һичбер нәрсәдән курыкмаучанлык бар. Әгәр дә мин хәрби булсам, күкрәгемне орден белән тутырып, берничә тапкыр герой исемен алган булыр идем. Ләкин медицинага эләгеп харап булганмын. Шуның өчен дә мин үз профессиямне яратмыйм.

Гөлшат. Ялгышасың, Искәндәр. Медицина безнең илдә иң кадерле, иң почетлы хезмәт санала.

Искәндәр. Анысы шулай, ләкин минем батырларга хас булган натурам өчен лаеклы эш түгел.

Шамил керә.

Шамил. Гөлшат, әйдә тау башына, аннан соң көймәдә йөрергә чыгарбыз. (*Култыклый.*)

Искәндәр. Чибәр егет, башта кызлардан рөхсәт сорыйлар.

Шамил. Безнең рөхсәт күптән соралган, шулай түгелме, Гөлшат?

Гөлшат. Әйдә, Искәндәр. (*Култыклый. Өчәүләп китәләр.*)

Өйдән Шәйхаттар белән Таһир чыга.

Шәйхаттар. Шулай, әткәй, кешелек дөньясын һәлакәттән коткару вазифасы безнең өскә йөкләтелгән. Тиздән дөньядагы иң соңгы снарядны совет тубыннан атарбыз да бөтен дөнья хезмәт иясенә сугышсыз, кан коешсыз туганлык ватаны ясарбыз.

Таһир. Кара әле, улым, безнең совет туплары ничә чакрымга аталар?

Шәйхаттар. Төрлеләре бар, әткәй. Тупларның калибрын да, шулай ук ничә чакрымга атарга тиешлеген дә сугыш тактикасы билгели. Ә тактика үзе — үзгәреш процессында. Киләчәктә моңа хәтле булмаган каты сугышлар көтелә.

Шәмсия керә.

Шәмсия. Балыкчы картың килгән.

Таһир. Кайда ул?

Шәмсия. Капка төбендә.

Таһир китә.

Улым, Шәйхаттар, өйләнү, тормыш кору турында уйларга иде инде.

Шәйхаттар. Вакыт тигәне юк бит әле, әнкәй.

Шәмсия. Өйләнү өчен озак вакыт кирәкми, улым, һаман шулай тол дүдәк булып йөрмәссең бит.

Марат кереп тыңлап тора.

Шәйхаттар. Турысын әйткәндә, әнкәй, шулайрак дип кайткан идем.

Шәмсия. Бик яхшы, улым. Без әтиең белән дә сөйләшкән идек. Хафиз абыйларыңның Саниясе сиңа пар булыр иде. Үзе яшь, укыган, үзе тагы холык ягыннан да әйбәт.

Марат. Әнкәй, җиләкче хатын килгән.

Шәмсия. Варенье кайнатырга сораган идем, шуны китергәндер. (*Китә.*)

Шәйхаттар. Ну, Марат, үсеп буламы?

Марат. Күргәнеңчә, абый, үсәбез.

Шәйхаттар. Дәресләр ничек?

Марат. Яхшы, отличнога укыйм. Киләсе елга урта мәктәпне бетерәм.

Шәйхаттар. Молодец, энекәш.

Марат. Абый, бире кил әле. (*Читкә алып.*) Син әтиләргә белдерә күрмә, мин берничә тапкыр үз теләгем белән Кызыл Армиягә язылырга барган идем, яшең җитми дип алмыйлар. Син мине берәр хәрби мәктәпкә урнаштыр инде.

Шәйхаттар. Булмый, Марат, син бик яшь әле.

Марат. Нишләп яшь булыйм? Кышка унсигез тула, паспорт алганыма инде ике ел була.

Шәйхаттар. Аннан, мин ишеттем, син шоферлар курсына укырга кергәнсең диме?

Марат. Әйе, көзгә укып бетерәм.
Шәйхаттар. Молодец, энекәш, тик кара аны, укуыңа зыян китермә.
Марат. Курыкма, абый, Марат сынатмас. Син, абый, мине урнаштыр инде.
Шәйхаттар. Юк, Марат, алай төрле якка ташланып йөрергә ярамый. Бик яхшылап урта мәктәпне бетер. Аннан мин сине менә дигән танкистлар мәктәбенә урнаштырырмын.
Марат. Юк шул, абый, минем тизрәк хәрби кеше буласым килә. Син хәзер үк урнаштыр инде.
Шәйхаттар. Юк, Марат, булмый.
Марат. Шуны да эшли алмагач, синең орденлы абый булуыңнан миңа ни файда?!
Шәйхаттар. Орденны протекция өчен бирмиләр. Шулай, Марат. Син бик яшь әле. Кызыл Армиядәге дисциплинага чыдый алмассың. Хәзер бит, ай-яй...
Марат. Минме чыдый алмам? Әйдә көрәшәбез, кем җиңәр икән. (*Барып биленнән тота.*)

Сания керә.

Сания. Шәйхаттар абый, сезне алырга җибәрделәр. Көймәдә йөрергә чыгабыз, диләр.
Шәйхаттар. Ярый, Сания, мин өстемне генә алыштырып чыгыйм. (*Өйгә кереп китә.*)
Марат. Сания, бире кил әле. (*Читкә чакыра.*) Менә сиңа күчтәнәч.
Сания. Шәйхаттар абыйданмы?
Марат. Нишләп аннан булсын, үземнән.
Сания. Каян алдың?
Марат. Кеше кесәсеннән урладым.
Сания. Алай димим, акча каян алдың димәкче идем.
Марат. Әллә син мине өч сумга шоколад алырлык акча таба алмый торган булдыксыз егет дип уйладыңмы? Кичә колхоз клубына радио куйдым, шуның өчен илле сум бирделәр. Мә, кеше күргәнче ашап бетер.
Сания. Күрсә ни була?
Марат. Булмый да, мин оялам.
Сания. Син шулай оялчанмыни?
Марат. Оялчан шул, шуның аркасында сиңа да әйтәсе сүземне әйтә алмый йөрим.
Сания. Нинди сүз ул?
Марат. Ярый инде, калсын бу юлы.
Сания. Йә, әйт инде, Марат, минем беләсем килә.
Марат (*икеләнеп торганнан соң, кисәк кенә*). Алай булса, менә бел, син нигә Шабанов белән дусланып йөрисең?
Сания. Йөрсәм ни була?
Марат. Трепач бит ул, ике предметтан начар билгесе бар. Чак-чак кына классында калмады. Атасы профессор, имеш, гетр киеп, суконный галстуклар тагып йөргән була, әйтерсең чит ил кешесе.
Шәйхаттар чыга.

Шәйхаттар. Әйдә, Сания, киттек.
Сания. Әйдә, Шәйхаттар абый.
Шәйхаттар. Под ручку алырга мөмкинме?
Сания. Пожалуйста. (*Китәләр.*)
Марат. Пожалуйста, имеш... Юкка гына кычыткан чыпчыгына шоколадымны ашаттым. (*Артларыннан китә.*)

Бакчада, култыклашкан хәлдә, Гөлшат белән Шамил күренә, алар артыннан мескен генә булып Искәндәр бара.

Шамил. Без инструктор белән машинага утырдык та җирдән югарыга күтәрелдек. Озак та очмадык, куе томан, яңгыр болытлары безне чорнап ала башлады. Ләкин без һаман очабыз, һаман калын болытлар куелыгын ярып күк бушлыгын кочабыз. (*Үтеп китәләр.*)

Мендәр-ястыклар күтәреп, өйдән Шәмсия чыга. Верандага урын җәяргә керешә, бакчадан Марат керә.

Шәмсия. Улым Марат, син ни өчен көймәдә йөрергә чыкмадың?
Марат. Чыгасым килмәде...

Шахмат тотып, өйдән Таһир чыга.

Таһир. Улым Марат, әйдә әле, кичәге партияне уйнап бетерик.
Марат. Таптың, әткәй, шахмат уйнар чак. (*Өйгә китә.*)
Таһир. Ни булган аңа?
Шәмсия. Ни булсын, уйныйсы килми торгандыр.
Таһир. Мин таңнан балыкка китәм, уятырсың.

Шәмсия. Йөрми тор әле, иртәгә мин калага барам. Өй сакларсың.
Таһир. Анда ни эшең калган?
Шәмсия. Теге теш докторы белән сөйләштем, тешләремне төзәтеп бирәм, ди.
Таһир. Кирәкмәс иде, Шәмсия. Болай да тешләрең бик үткен, аннан мине чәйнәп өзәрсең.
Шәмсия. Бик әйбәт егет икән.
Таһир. Кызың артыннан йөргәч, билгеле, әйбәт була инде ул.
Шәмсия. Гөлшатка бүләкләр китергән.
Таһир. Мин бер дә ошатмадым, вак кеше булырга кирәк, Гөлшат абынып куймаса ярар иде. Ярый, мин ятам, урын җәйгәнме?
Шәмсия. Җәйгән, җәйгән, бар, такылдап утырма.

Таһир китә. Тышта караңгылык башлана. Ерактан электр утлары балкыган Казан күренә. Солтан белән Кадрия керә.

Кадрия. Әнкәй, Рөстәм еламадымы?
Шәмсия. Юк, килен, шул ятудан йоклый да йоклый.
Кадрия. Әйдә, Солтан, керик.
Солтан. Бар, Кадрия, керә тор, мин тәмәке генә тартам.

Кадрия китә.

Әнкәй, Кадрияне эшкә керергә күндердем.
Шәмсия. Бик яхшы булган, улым, кулында һөнәре була торып, бала карап ята иде.
Солтан. Иртәгәдән Рөстәмне үз тәрбияңә алырсың.
Шәмсия. Ярый, улым, мин бала караудан иренмим. Тик килен генә кысылмаса ярар иде.
Солтан. Кысылмас, мин аңа яхшылап аңлаттым, үзе дә риза булды. Бигрәк тә бабайларга җибәрмә, иркәләп бозалар. Аннан, әнкәй, менә сиңа расходка акча.
Шәмсия. Кирәкмәс иде, улым, узган атнаны биргәнең дә бетмәгән әле.
Солтан. Ал, әнкәй, бу арада кунак-төшем күп булды, бер әткәйгә авырдыр.
Шәмсия. Үзегезне карарга иде инде, улым.
Солтан. Үзебезгә җитәрлек, сезгә дә булсын. Мин кичә квартальный планны арттырып тутыруыбыз өчен биш мең сум премия алдым.
Шәмсия. Алай булса ярый, улым.

Китәләр. Зур пароход узганы ишетелә. Тышта караңгылана. Ерактa, Идел өстендә, татарча җырлаган тавышлар ишетелә. Әкрен генә ай калка, гитара тотып, өйдән Марат чыга. Үзе уйнап җырлый.

Марат. Тышка чыксам, айга карыйм,—
Ай да ялгыз минем күк;
Яшь йөрәгем түрләрендә
Сиңа сөйләр сүзем күп.

Шәмсия чыга.
Шәмсия. Улым, Марат, син нигәдер күңелсез, әллә берәр җирең авыртамы?
Марат. Юк, әнкәй, бер җирем дә авыртмый.
Шәмсия. Алай булгач, нигә күңелсез?
Марат. Болай гына...
Шәмсия. Әйдә, балам, кереп ят.
Марат. Юк, әнкәй, мин утырам әле.

Шәмсия китә.

Их... Әллә нәрсә генә эшлисе иде. (*Үзе уйнап, русча җырлый.*)
Если завтра война,
Если завтра в поход,
Будь сегодня
К походу готов...

Гөлшат, Маһирә, Сания, Искәндәр һәм башка кызлар астан менәләр.

Гөлшат. Кызлар, тау башына утырып ял итик.
Сания. Төне дә төне, бигрәк тә күңелле инде. (*Марат уйнавында дәвам итә.*)

Гөлшат (*кычкырып*). Марат, безнең янга кил...
Маһирә. Ул ни өчендер бүген күңелсез... Их, яратам да шул гитара тавышын...
Сания. Әнә Шәйхаттар абыйлар да менделәр.

Шәйхаттар, Шәүкәт, Шамил һәм башкалар менәләр.

Шәйхаттар. Кызлар, җырлагыз әле, минем күптәннән бирле татар көйләрен ишеткәнем юк. (*Марат «Идел» көенә уйный, аңа кушылып, Сания җырлый.*)
Сания. Иделкәем алкын, суың салкын —
Һәр көн төшеп синнән су алам,
Көзгеләрдә үзем күргән төсле,
Йөзем күреп синдә куанам.
Хор. Шунда туып, шунда көлеп,
Шунда суың эчтек без;
Шунда уйнап, шунда җырлап,
Шунда гөрләп үстек без.
Шәүкәт. Карагыз, бер моторка килеп туктады.
Сания. Дулкыны, дулкыны... Зур пароходныкыннан бер дә ким түгел.
Шамил. Ниндидер бер хәрби кеше төште.
Шәйхаттар. Ягез, кызлар, ник туктадыгыз, җырлагыз әле.
Сания. Иделкәем алкын, суың салкын,
Ерakларга даның тарала;
Салкын суларыңны эчкән яшьләр
Һәрбер эштә уңган санала.
Хор. Шунда туып, шунда көлеп,
Шунда суың эчтек без;
Шунда уйнап, шунда җырлап,
Шунда гөрләп үстек без.

Кызылармеец керә.

Кызылармеец. Гафу итегез, Шәйхаттар Таймасов кем була?
Шәйхаттар. Мин булам.
Кызылармеец. Сезгә пакет китердек. (*Бирә.*)
Шәйхаттар (*ачып укый*). Яхшы, мин хәзер, бераз шунда көтегез. (*Китә.*)
Маһирә. Нәрсә бар икән?
Гөлшат. Белмим шул.
Сания. Иптәш, нинди язу китердегез?
Кызылармеец. Әйтә алмыйм.

Өйдән Шәйхаттар, Таһир, Шәмсия, Солтан һәм Марат чыга.

Шәйхаттар. Әткәй, әнкәй, мине шәһәр комендантына чакырганнар.
Шәмсия. Ходаем, нәрсә генә бар икән?
Шәйхаттар. Хуш, сау булыгыз, әткәй һәм әнкәй, Солтан, Марат, хушыгыз. (*Баскычтан бакчага төшә, бөтенесе белән күрешә.*) Хушыгыз, иптәшләр!.. (*Яр астына төшеп китә, мотор тавышы ишетелә.*)
Башкалар. Хуш, Шәйхаттар абый, хуш... (*Кул селтәп озатып калалар.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Таймасовлар квартирасы. Төрле якта ишекләр. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә беркем дә юк. Бераздан звонок тавышы. Кухня ягыннан Шәмсия чыга.

Шәмсия. Кайсы чәнчелгересе шулкадәр баса икән? (*Ача.*) Ә, син икәнсең...

Кәнҗебикә керә.

Кәнҗебикә. Мин идем шул, исән тордыгызмы, апа?
Шәмсия. Беркөе генә. Каян болай?

Кәнҗебикә. Ленинградтан кайтып килешем.
Шәмсия. Ленинградтан? Анда нәрсәгә бардың?
Кәнҗебикә. Менә товарлар алдым.
Шәмсия. Тотсалар, ябып куялар бит.
Кәнҗебикә. Япты ди, пычагымны, сату итеп йөри дип мине кем уйласын. Шәйхаттардан хәбәр килгәне бармы?
Шәмсия. Әле өченчекөн генә Пульша ягыннан Ленинградка кайттык дип язган иде. Сиңа очрамагандыр инде?
Кәнҗебикә. Анда кеше күреп буламы? Сугыш булыр, ахры, вагонда шулай дип сөйләделәр.
Шәмсия. Әйтмә инде, Кәнҗебикә, үзем дә шул турыда куркып торам. Кичә балалар да газеттан финнар белән нәрсәдер барлыгы турында укыганнар иде. Син торып тор, теге балага манный буткасы пешергән идем, шуны ашатып алыйм. (*Китә.*)

Сөлге белән сөртенеп, яланөс, тыштан Марат керә.

Марат. Исәнме, апа?
Кәнҗебикә. Бик әйбәт, улым. Нишләп болай шыр ялангач йөрисең?
Марат. Тышта кар белән ышкындым.
Кәнҗебикә. Кар белән ышкындым дисеңме?
Марат. Әйе, апа, нигә аңа исең китә?
Кәнҗебикә. Суык тиеп үләрсең бит, юләр!
Марат. Менә инде белмәдең. Кыш көне кар белән ышкыну, салкын су белән юыну кешене салкынга күнектерә һәм нервларны ныгыта, ди врачлар.
Кәнҗебикә. Үлмәсәң, әллә ни дә ишетерсең. (*Күрше бүлмәдә такмак әйтеп биегән тавыш ишетелә.*) Кем ул анда дөберди?
Марат. Ә, әнкәй ул, биеп-җырлап бала ашата. Хәзер, әни, үзем ашатырмын... (*Биеп, бүлмәгә кереп китә.*)

Хәле бетеп Шәмсия чыга.

Шәмсия. Уф, үләм инде бу бала белән, каршысында биеп-җырлап тормасаң, һич ашамый.
Кәнҗебикә. Апа, бу Маратың әллә акылдан шашканмы? Яланөс тыштан сөлге белән сөртенеп керде, шушындый чатнама суыкта, кар белән ышкындым, ди.
Шәмсия. Әй, Кәнҗебикә, анысы бернәрсә түгел, ул әле көнаралаш Казанкага су коенырга йөри.
Кәнҗебикә. Әнекәем лә, ничек салкын тидерми! Ничек иманы качып үлми ул?
Шәмсия. Киресенчә, мунчадан чыккандай кып-кызыл булып кайтып керә.
Кәнҗебикә. Үзегезне дә әйтер идем инде, нигә ирек бирәсез, нигә узындырасыз?
Шәмсия. Әйдә, йөрсен, сәламәтлек өчен файдалы, диләр ич.
Кәнҗебикә. Элек вакытта архириларны бәкегә чума икән дип сөйлиләр иде, башка кешеләрне ишеткәнем юк иде. Ярый, апа, мин аптобус белешеп кайтыйм, әйберләрем синдә торсыннар.
Шәмсия. Ярый, бар, бераздан чәй эчәргә кайтырсың.

Кәнҗебикә китә, бүлмәдән Марат чыга.

Улым, помой чиләгем тулган, түгеп керсәңче.
Марат. Ярый, әнкәй, түгәрмен.
Шәмсия. Аннан, улым, иртәдән бирле радио эшләми, ни булды икән?
Марат. Өй түбәсендә малайлар йөреп бозгандыр. Хәзер, әнкәй, менеп карармын.
Шәмсия. Шулай ит әле, улым, бер өйрәнгәч, радиосыз тору күңелсез икән. (*Кереп китә.*)

Марат, көзге каршысына килеп, гимнастика ясый. Сания керә.

Сания. Марат, Гөлшат апа өйдәме?
Марат. Юк, эшкә китте.
Сания. Ул бит, бүген эшләмим, төнге дежурствога барам, дигән иде.
Марат. Шулай иде дә, иртәнге сәгать алтыда телефон белән чакырып алдылар.
Сания. Нигә икән?
Марат. Бер авыруның хәле начарланган, профессор операция ясарга булган.
Сания. Алай икән.
Марат. Әйе, шулай.
Сания. Ярый, мин китим. Гөлшат апага кайткач әйтергә онытма, безгә кереп чыксын әле.
Марат. Сания, тукта әле, мин сиңа аттестатымны күрсәтим.
Сания. Нинди аттестат?

Марат. Мин шоферлар курсын укып бетердем. Мин хәзер, теләгән машинага утырып, шофер була алам.

Сания. Бик харап инде, синнән башка кеше таптатучылар аз иде.

Марат. Шофер булу бик зур эш ул. Мин хәзер моторны биш бармагым кебек беләм. Тракторга, танкка, хәтта самолетка да утыра алам.

Сания. Юкка энергияңне әрәм итеп йөрисең, бала, барыбер шофер буласы кеше түгел, командир булам, дисең ич.

Марат. Бигрәк тә яхшы, һәрбер командир машинаны белергә тиеш. Беркөнне мин комдивны күрдем, хатынын, балаларын түргә утырткан да, үзе шофер булган. Менә күрдеңме? Шофер булуның зыяны юк аның, кайчан булса да бер кирәк була ул.

Сания. Ярый, мин киттем.

Марат. Кичә Бауман урамыннан кем белән бара идең?

Сания. Синең өчен кем булса да барыбер түгелме?

Марат. Түгелдер шул. Бер булса, сорамас идем.

Сания. Кара әле, Марат, нигә син мине каравыллап йөрисең? Театрга барсам, анда буласың. Киного керсәм, артымнан керәсең, нигә ул алай?

Марат. Нигә икәнен әйтимме?

Сания. Әйт.

Марат. Оялам...

Сания. Күземне йомып торам, әйдә, әйт.

Марат. Юк, булмый. Мин сиңа язып кына бирим, яме?

Сания. Ярый, бир. (*Марат язып бирә дә бүлмәгә кача, Сания укый.*) «Мин сине сөям». Әйтәм аны артымнан йөри... (*Утырып яза.*) Марат, хатыңа каршы хат яздым. Өстәлдә калдырам, алып укырсың.

Китә. Йөгереп, бүлмәдән Марат чыга, өстәлдәге хатны алып хис белән укый.

Марат. «Марат, акыллым, кеше көлдереп йөрмә... Син бик яшь әле. Турысын әйткәндә, борының да кипмәгән. Моннан соң минем артымнан йөрисе булма, сабагыңны тырышып укы. Әгәр дә сүземне тыңламасаң, әтиеңә әйтеп, кистерермен». Яшь, имеш... (*Ишеккә барып кычкыра.*) Син, Сания, минем яшькә карама, менә монда янар таулардай кайнаган мәхәббәт утына кара...

Таһир керә.

Таһир. Нинди ут турында сөйләнәсең?

Марат. Ул, ни, әткәй, теге... Кайда гына куйдым соң?..

Таһир. Тукта әле, син нигә койрыгы көйгән мәче төсле өзгәләнәсең?

Марат. Әнә малайлар радионы бозганнар, шуны төзәтергә йөри идем. (*Китә.*)

Таһир чишенә, Шәмсия керә.

Шәмсия. Кайттыңмыни, атасы?

Таһир. Юк, китеп барышым.

Шәмсия. Әй, кыланышы.

Таһир. Исән кайттыңмы дип сорыйлар аны.

Шәмсия. Исән булмаска, шайтан тисенме сиңа. Нәрсәгә җенләнеп кайттың?

Таһир. Минем рационализаторлык тәкъдимемне тикшерделәр.

Шәмсия. Соң, нәрсә диделәр?

Таһир. Заводның баш инженеры әйтә: сез, ди, тәкъдимегезне фәнни яктан ачып салмагансыз, ди, бу бары тик практик яктан гына карап төзелгән, ди. Аннан соң, фабриканың эшләп чыгару нормасын күтәрү, шулай ук Мәскәү белгечләре төзегән планны үзгәртү безнең эш түгел, ди. Юк, безнеке, дидем. Алексей Стахановка да сезнең кебек белгечләр шундый ук бәя биргәннәр иде, ләкин ул, академиклар төзегән нормаларны җимереп, социалистик эш методы нормасын төзеде, дидем.

Шәмсия. Кирәкмәс иде, карт. Гомереңә кеше белән булышуыңны ташламыйсың.

Таһир. Ташламыйм шул, алар һаман да искечә эшләргә, ниндидер бюрократ белгечнең төзегән уку китабы буенча барырга уйлыйлар. Алар фән белән теориянең тәҗрибә аркасында туганлыгын инкяр итәргә тырышалар. Кая, газеталар бармы?

Шәмсия. Ни өчендер бүген килгәне юк әле.

Таһир. Берәр яңа хәбәр булырга кирәк. Әйе, Шәмсия, дөньялар бутала. Безне дә сугышка тартырлар, ахры.

Шәмсия. Әллә шундый хәбәр ишеттеңме?

Таһир. Бүген радио буенча иптәш Молотов сөйләячәк дип иртән хәбәр иткәннәр.

Кулына газеталар тотып, Марат йөгереп керә.

Марат. Шатлык, әткәй, шатлык...
Таһир. Нинди шатлык?
Марат. Сугыш була.
Шәмсия. Тилебәрән орлыгы ашаган нәрсә, сугыш булгач, шатлык буламы?
Марат. Була шул. Буржуйларны, капиталистларны кыйныйбыз.
Таһир. Кая әле, укып җибәрик.
Марат (*укый*). «26 нчы ноябрь 15 сәгать 45 минутта «Майнила» тирәсендә урнашкан безнең гаскәрләргә көтелмәгәндә Финляндия ягыннан артиллериядән атыш башланган. Биш кызылармеец, ике командир үтерелгән. Җиде кызылармеец яраланган».
Таһир. Ох, этләр, этләр, кемгә каршы кул күтәргәннәр бит, ә!
Марат. Әйдә, эти, күтәрсеннәр, үз башларына булыр. Өч көн эчендә без аларның бөтен Финляндиясен айкап чыгарырбыз.
Таһир. Юк, улым, алай җиңел карарга ярамый. Алар үзләре генә түгел. Алар артында башка капиталистик дәүләтләр тора.

Почтальон керә.

Почтальон. Сезгә телеграмма.
Таһир. Каян?
Почтальон. Ленинградтан.
Шәмсия. Ленинградтан?
Почтальон. Хушыгыз. (*Китә*.)
Таһир. Күзлегем кая соң? Улым, укы әле.
Шәмсия. Шәйхаттар абыеңнанмы?
Марат. Түгел, армия командующиеннан...
Шәмсия. Нәрсә язган, укы инде.
Марат. Юк, әнкәй, укый алмыйм...
Таһир. Кая, бир миңа...
Шәмсия. Ни булган, әллә Шәйхаттар авырумы?
Таһир. Ул үлгән...
Шәмсия. Үлгән?
Таһир. Әйе, Шәмсия, үлгән. (*Яшькә тыгылып укый*.) «Сезнең улыгыз Шәйхаттар Таймасов изге Ватаныбызны саклау постында батырларча һәлак булды, авыр кайгыгызны уртаклашабыз...»
Шәмсия. И бала, бала, соңгы тапкыр күрүем булган икән. Ичмасам туйганчы сөйләшә дә алмадым. Атасы, шулай ук дөрес булыр микәнни?
Таһир. Тукта, Шәмсия, акылымны башыма җыярга ирек бир. Күз алларым караңгыланып, бөтен тәнемне бизгәк калтырата башлады.
Марат. Мә, әткәй, су эч...
Таһир. Кирәкми, улым, бу — хәлсезлектән түгел, дошманнардан үч алырга өндәп кабынган ачу ялкыннарыннан ул. Улым Марат, абыеңнарга, Гөлшат апаңа шалтырат. Хәзер үк кайтып җитсеннәр. (*Марат телефонга бара*.)
Марат. 8-48, Солтан абый, Марат сөйли, хәзер үк өйгә кайт.
Шәмсия. Хәрби мәктәпкә китәм дигәч тә, күңелем сизгән икән. Никадәр җибәрмәскә тырыштым, ничә әйтсәм дә, баланы син өндәдең.
Таһир. Куй, Шәмсия, ахмак сүзне сөйләмә. Ләкин дошманнар үзләре өчен куркынычлы булган ут белән уйныйлар. Шунысы кызганыч, арысландай бала котырган этләр кулыннан югалды...
Марат. Әткәй, сабыр, радиода мөһим хәбәр бар.
Радио. Тыңлагыз, тыңлагыз! Москва, Коминтерн станциясе сөйли. Хәзер СССР Халык Комиссарлары советы председателе Вячеслав Михайлович Молотовның радио буенча чыгышы була. Тыңлагыз, микрофон алдында иптәш Молотов...
Радио. Советлар Союзы гражданнарына һәм гражданкаларына... Хәзерге Финляндия хөкүмәтенең безнең илебезгә карата дошманлык политикасы һәм дәүләтебезгә тыштан куркынычсызлыкны тәэмин итү бурычы безне ашыгыч чаралар күрергә мәҗбүр итә...

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук декорация. Бөтен балалар кайтканнар. Утырган җирләрендә дикъкать белән радио тыңлыйлар.

Радио. Ленинградка куркынычсызлыкны тәэмин итү бурычын уңышлы рәвештә хәл кылуыбыз СССР белән Финляндия арасындагы җимерелмәс дуслыкның нигезе булып хезмәт итәчәгенә шикләнмибез. (*Тышта музыка тавышлары*.)

Шәмсия. Нинди музыка ул?

Марат. Ирек мәйданына митингка баралар. (*Бөтенесе балкон тәрәзәсенә килеп карап торалар*.)

Таһир. Ягез, балалар, кайсыгыз минем белән бара?

Солтан. Кая, әткәй?

Таһир. Мин сезнең берегезне абыегыз урынына Кызыл Армиягә бирергә уйлыйм. Совет иленең дошманнары минем бер улымны үтерсәләр дә, минем әле яңадан өч улым бар. Алар үлә икән, үзем барырмын...

Шәмсия. Карт юләр, син нишлисең? Бер баланың каны да суынып бетмәгән, инде икенчеләрен котыртасыңмы?

Таһир. Юк, Шәмсия, котыртмыйм. Совет иленең һәрбер намуслы карты эшләргә тиешле ата буларак бурычымны гына үтим. Ягез, улларым, ни дисез?

Солтан. Рәхмәт, әткәй... Мин әле күкрәгемдә кайнаган ачу утларымны сезгә белдерергә кыймый тора идем. Син аны миннән элек әйтеп ташладың. Әйе, абый урынына мин барам.

Шәүкәт. Патриотик теләкләр күрсәтүеңне, әткәй, мин дә котлыйм. Ләкин Солтан абыйга караганда минем китүем артыграк булыр. Чөнки аның хатыны, баласы бар. Шуның өстенә ул җаваплы эшче.

Марат. Дөрес, әткәй, минемчә дә Солтан абыйны җибәрү урынлы түгел. Ул инженер кеше, бөтен бер заводның язмышы аңа тапшырылган. Шулай ук, Шәүкәт абый, сиңа да китәргә ярамый, синең институтың бар. Монда безнең семьядан иң кулай кеше мин булып чыктым. Шулай булгач, әткәй, миңа рөхсәт итегез.

Таһир. Әй, куй әле, куй, үз эшең булмаганга кысылма.

Гөлшат. Шәйхаттар абый урынына барган кеше аның урынын алыштырырлык булырга тиеш. Солтан абыйның китүен мин дә урынлы саныйм. Чөнки ул, бердән, таза, нык кеше. Икенчедән, белеме белән дә запастагы танк командиры.

Таһир. Дөрес, кызым. Әйдә, улым Солтангәрәй, киттек.

Солтан. Әйдә, әткәй.

Китәләр.

Шәүкәт. Марат, әйдә әле минем белән. (*Бүлмәгә узалар*.)

Шәмсия. Бу нинди җиңел кеше булды соң? Бернәрсә эшләргә уйласа, үтерсәң дә ул эшеннән кайтара алмыйсың.

Гөлшат. Син, әнкәй, үз-үзеңне бетермә. Бер Солтан абый гына түгел, меңләгән егетләр үз теләкләре белән барып язылалар. Әнә күрәсеңме, урамда күпме халык ташкыны... алар дошманнарга ачы нәфрәт, Ватаныбызга кайнар мәхәббәт белдерергә чыкканнар. Мин әле, кыз була торып та, үч алу тойгыларыма ия була алмыйча калтыранам... Изге Ватанымның данлы патриоты булган туганымның аккан каннары бәрабәренә үч алырга юллар эзләнәм. Син, әнкәй, тынычлан, һәрбер сугышка киткән кеше үлә дигән сүз түгел.

Шәмсия. Анысы шулаен шулай да, кызым, ана өчен авыр бит... Ярый, еламыйм, әйдә барсын, ир кеше бурычын үтәсен.

Гөлшат. Менә шулай. Син нәрсәдер эшли идең бугай?

Шәмсия. Токмач баса идем... (*Бүлмәгә китә. Телефон шалтырый*.)

Гөлшат. Тыңлыйм. Гөлшат Таймасова. Ничек, паспорт белән военный билетымны алып килергә дисезме? Яхшы.

Ашыгып Искәндәр керә.

Искәндәр. Гөлшат, мин хәзер генә урамда Таһир абый белән Солтанны очраттым. Авыр кайгыгызны уртаклашырга килдем.

Гөлшат. Рәхмәт, Искәндәр.

Искәндәр. Бу, Гөлшат, сезнең өчен генә түгел, бәлки, бөтен халкыбыз өчен зур кайгы. Ләкин, Гөлшат, борчылма, бездәге патриотлык хисләре бер Финляндия бандаларын гына түгел, хәтта бөтен дөнья буржуазиясен тар-мар итәргә дә җитәрлек. Без алардан Шәйхаттар үчен алырбыз, без — меңләгән, йөз меңләгән совет яшьләре — яхшы атларга, корыч танкларга, җитез самолетларга утырырбыз да совет кешеләренең нахакка аккан каннарын дауларбыз. Мин хәзер военкоматка барам да үз теләгем белән фронтка җибәрүне сорыйм.

Гөлшат. Сез үз теләгегез белән фронтка китәсез?

Искәндәр. Башкача мөмкинме соң, Гөлшат? Ватаныбыз шундый авыр минутлар кичергәндә, нинди генә совет яшьләре читтә калырга риза булыр икән!

Гөлшат. Рәхмәт, Искәндәр, чын күңелемнән котлыйм. Әйдә киттек алайса.

Искәндәр. Кая?

Гөлшат. Мин дә шунда, военкоматка барам.

Искәндәр. Мин, Гөлшат, хәзер үк бара алмыйм әле. Чөнки клиникада бик мөһим эшем бар. Шулай да чатка кадәр озата алам.

Китәләр. Марат белән Шәүкәт бүлмәдән чыга.

Шәүкәт. Шулай итеп, Марат, союз?
Марат. Союз, Шәүкәт абый.
Шәүкәт. Мин киттем.
Марат. Ярый, бар.

Шәүкәт китә. Марат эзләнергә керешә. Шәмсия керә.

Әнкәй, минем паспортым кайда икән?
Шәмсия. Язу өстәле астындадыр.
Марат. Карадым, анда юк.
Шәмсия. Яхшылап кара, кирәкле язулар шунда саклана ич.
Марат. Юк инде, юк. Бөтен җирне актарып чыктым. Кая, эзләп кенә бир инде.
Шәмсия. Эч пошкан чакта борчып йөрмә әле, кирәк булса, үзең эзләп ал. Тукта әле, сиңа нәрсәгә ул паспорт?
Марат. Милициягә барып, специальностемны шофер дип яздырып кайтам.
Шәмсия. Кая гына куйдым икән соң? И, комод тартмасындадыр. (*Кереп китәләр*.)

Бераздан, кулына паспорт тотып, Марат чыга. Тышкы ишеккә китә.
Башын тотып, Кәнҗебикә керә.

Кәнҗебикә. Алла, Алла, күземнән утлар күренде... Сукыр чебен шикелле кая бара торгандыр?

Шәмсия чыга.

Әй халык, әй халык, каян җыелгандыр шулкадәр халык. Милицияләр урамнан йөртмиләр, әллә кайлардан, Кабан күлләре аша әйләнеп кайттым. Безнең кызылармеецларыбызны үтергәннәр диме, апа?
Шәмсия. Әйе, Кәнҗебикә, үтергәннәр. Шулар арасында безнең Шәйхаттар да...
Кәнҗебикә. Шәйхаттар да үлгән дисеңме?!
Шәмсия. Әйе, Кәнҗебикә, үлгән. Аларның үлеменә кайгы белдереп, бөтен шәһәр халкы урамга чыккан.
Кәнҗебикә. Алай булгач, сугыш була икән, апа?
Шәмсия. Булыр, Кәнҗебикә, бик каты сугыш булыр. Таһир җизнәң Шәйхаттар урынына Солтангәрәйне илтергә китте.
Кәнҗебикә. Әй Ходаем, Закирҗанымны гына алмасалар ярар иде.
Шәмсия. Синең Закирҗаның карт инде, нишләп аны алсыннар?
Кәнҗебикә. Карт дип тормаслар, әнә герман сугышында илле яшькә кадәр алдылар. Безнеке дә нәкъ илленең өстендә. Кая, әйберләремне алыйм да тизрәк китим, апа.
Шәмсия. Самавыр кайнаган, чәй эчәр идең.
Кәнҗебикә. Юк, юк, Закирҗанымны күрми калыр хәлем юк.

Таһир керә.

Исәнме, җизни, хуш, сау бул... (*Китә*.)
Таһир. Ни булган аңа?
Шәмсия. Сугыш була, Закирҗанымны күрми калам, ди. Солтангәрәй кайда?
Таһир. Кадрия килен янына кереп калды.
Шәмсия. Соң ничек, яздырдыңмы?
Таһир. Әйе, Шәмсия, язылырга дип меңләгән халык килгән. Ләкин һәрбер теләгән кешене алмыйлар. Мин дежурныйга телеграмманы күрсәткән идем, кереп китте дә комиссарны алып чыккан. Комиссар әйтә: «Таһир Муталлипович, кабинетка рәхим ит»,— ди. Кердек. «Правда» газетасының корреспонденты башта үземне, аннан Солтангәрәй белән икебезне карточкага төшереп алды.

Солтан белән Кадрия керә.

Шәмсия. Шулай итеп, улым, син дә китәсеңме инде?
Солтан. Әйе, әнкәй, хәзерләнеп торырга куштылар.
Шәмсия. И бала, бала, син дә кайтмассың инде.
Солтан. Сөйләмә, әнкәй, менә күр дә тор, таң чулпаны, якты йолдыз шикелле кайтып килербез.
Таһир. Мин дә шулай дим шул. Әйдә, әйберләрен караштырыйк. (*Китәләр*.)
Кадрия. Солтан, син бу адымың белән минем тормышымны җимереп, тәмле хыялларымны җилгә очырдың. Ике арадагы чын мәхәббәтебез хөрмәтенә, Рөстәмне ятим итмәү хакына син язылмаска тиеш идең.

Солтан. Ватан язмышы хәл ителә торган чакларда шәхси тормыш тынычлыгына чумып кала торган булсак, ике арадагы коры мәхәббәтебезнең нинди әһәмияте калыр иде икән?! Шәһәр өстенә дошман самолетлары килеп берничә бомба ташлау белән, безнең мәхәббәтебез көлгә әйләнеп очачак. Ватан язмышы җылы өйләрдә хәл кылынмаган кебек, аерым шәхесләр тормышы да өйдә чишелми. Аларны чишә торган көч, Кадрия, әнә анда, фронтта.

Кадрия. Аңлыйм, Солтан, барысын да аңлыйм, ләкин нишлим, мин бит сине өзелеп яратам.

Солтан. Мин сине яратмыйммы?

Кадрия. Әлбәттә, яратасың. Менә шуның өчен дә мин сине бер генә минутка да җибәрәсем килми иде. Ярый, хәерле булсын, бар.

Солтан. Менә шулай.

Кадрия. Солтан, мине гафу ит.

Солтан. Ни өчен?

Кадрия. Мин бая, монда кайтканда, ачу белән каты сүзләр әйтеп ташладым. Кичер мине.

Солтан. Әлбәттә, кичерәм. Әйдә, әйберләрне җыештырыйк. (*Китәләр*.)

Таһир чыга. Телефонга бара.

Таһир. 40 нчы завод парткомын бирегез. Александр Петрович, бу сезме? Менә нәрсә. Көтелмәгән авыр кайгы аркасында, мин бүген агитаторлар җыелышына бара алмыйм. Өлкән улымны ак финнар үтергән... Нишлисең, авыр булса да түзәргә туры килә, ярый, хуш, сау булыгыз...

Шәмсия чыга.

Шәмсия. Атасы, Шәйхаттарны күмәргә барсак, ничек булыр икән?

Таһир. Бик ерак бит, Шәмсия. Алар военный кешеләр, без барганчы көтеп тормаслар.

Шәүкәт чыга.

Шәмсия. Улым Шәүкәт, дәресеңә нигә бармыйсың?

Таһир. Бүген комсомол собраниесе үткәрәм дигән идең, кара аны, соңга каласың түгелме?

Шәүкәт. Мин, әткәй, бүген мәктәпкә бармаска булдым.

Таһир. Ни өчен?

Шәүкәт. Мин китәм.

Шәмсия. Китәсең?

Таһир. Кая?

Шәүкәт. Фронтка.

Таһир. Фронтка?..

Шәүкәт. Әйе, әткәй, Шәйхаттар абыйның үчен алыр өчен язылып кайттым.

Таһир. Тукта әле, улым, чынлап сөйлисеңме?

Шәүкәт. Дөрес, әткәй, без бүген китәбез.

Таһир. Ничек инде ул безгә әйтми-нитми язылырга булдың? Мин синең атаң, минем рөхсәтемнән башка ул нинди башбаштаклык була ди?

Шәүкәт. Дөрес, әткәй, сез миңа ата, ләкин минем үз гражданлык хокукым да бар.

Таһир. Безнең семьядан җиткән иде инде. Шәйхаттар абыең, мәрхүм, үз Ватанын саклауда җан бирде, аның урынын алмаштырырга Солтан абыең үз теләге белән язылды.

Шәүкәт. Алар үзләре өчен, мин үзем өчен. Һәркем изге гражданлык бурычын үтәргә тиеш.

Шәмсия. Сезнең урыныгызга кыз балалар тудырган булсам, үземә файдалары тигән булыр иде. Бөтенегез дә сугыш чукмары булып бетәрсез микәнни?

Гөлшат, Маһирә, Шамил керә.

Маһирә. Исәнме, Шәмсия апа!

Шәмсия. Ярыйсы шунда.

Шамил. Саумы, Таһир абзый!

Таһир. Беркөе генә.

Шәүкәт. Шамил, син ни өчен күңелсез?

Маһирә. Аны җибәрмиләр.

Шәүкәт. Нишләп?

Шамил. Кирәк булгач, әйтербез, хәзергә без сезне аэродромга инструктор итеп күтәрергә торабыз, диләр. Шулкадәр китәсем килгән иде, булмады.

Шәүкәт. Үз теләгеңне аңлатырга, яхшылап сорарга иде.

Шамил. Сорадым, Шәүкәт, ике тапкыр начальникка кердем. Берничә тапкыр секретарьга әйтеп карадым. Беләсез, военный кешеләр кабатларга яратмыйлар.

Гөлшат. Әнкәй, минем әйберләремне хәзерләсәң иде.
Шәмсия. Нинди әйберләреңне?
Гөлшат. Юл өчен кирәк-яракларны.
Шәмсия. Кая барасың?
Гөлшат. Мине дә, әнкәй, фронтка җибәрәләр.
Шәмсия. Кайчан?
Гөлшат. Бүген кичкә җыенып килергә куштылар.
Шәмсия. Ярабби, нишлим инде мин сезнең белән, нишлим?

Марат керә.

Марат. Сезгә ни булды? Әнкәй, нигә елыйсың?
Шәмсия. Еламый нишлим? Әнә Шәүкәт абыең сугышка китәргә язылып кайткан. Гөлшат апаңны да җибәрәләр.
Марат. Аның өчен еларга ярамый. Рәхмәт, Шәүкәт абый, чын күңелемнән котлыйм.
Шәмсия. Сиңа нәрсә? Үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын дигәндәй, сиңа диңгез тубыктан.
Марат. Шундый батыр уллар, уңган кызлар үстерүегез белән мактанырга кирәк иде. Әткәй, нигә инде син дә уйга чумып эндәшмичә утырасың? Әйдә әле, бер партия шахмат уйнап җибәрик.
Таһир. Кит әле, кит, эч пошкан чакта...
Марат. Менә инде рәхмәт әйтеп аркамнан сөярләр дип кайтсам, бөтенесе борыннарын салганнар.
Таһир. Тукта әле, тукта, ни өчен синең аркаңнан сөяргә?
Марат. Мин дә фронтка китәргә язылдым.
Шәмсия. Ә?.. Син дә язылдың?
Марат. Әйе, әнкәй, язылдым.
Шәмсия. Нишлим мин сезнең белән, нишлим?.. Нигә телең йоттың, нигә эндәшмисең шуларга?!
Таһир. Монда, Шәмсия, эндәшерлек урын калмады. Тик минем бер генә теләгем бар. Өчесе бергә Шәйхаттар абыйлары танкысына утырсыннар да дошманнарны турап салсыннар!..

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Таймасовлар квартирасы. Вакыт кич. Пәрдә ачылганда, Кадрия язып утыра.

Кадрия. Дөрес, Солтан, эш кенә, кешеләрнең дөньяга карашларын үзгәртеп, әйләнә-тирәдәге вакыйгаларны дөрес аңларга ярдәм итә икән. Хәзер мин, синең елак Кадрияң, чәчү беткәнче өч айга командировкага китәм. Хатны шунда язарсың. Рөстәм хәзер матур итеп сөйләшә башлады. Ул хәзер яхшы итеп ашый, тәмле итеп йоклый.

Шәмсия керә.

Ярый, әнкәй, миңа вокзалга төшәргә вакыт.
Шәмсия. Иртә түгелме соң әле?
Кадрия. Түгел инде. Син, әнкәй, зинһар өчен, Рөстәмне яхшы кара, авырый күрмәсен.
Шәмсия. Әй, килен, мин аны сиңа караганда да яратарак төшәм. Ул булмаса, мин әллә нәрсә эшләгән булыр идем, ярый әле ул бар. Минем белән бертуктамый сөйләшә ул, төрле әйберләр сораша. Аның белән мин атасының, абыйларының кайгыларын онытам. Син, килен, тынычлап кит. Беләсең ич, без аны бабасы белән өрмәгән җиргә дә утыртмыйбыз.
Кадрия. Күкрәгемә кысып бер сөйим дә китим.
Шәмсия. Син аны, килен, уятма инде, ул рәхәтләнеп йоклый.
Кадрия. Ярый алайса, Солтаннан хат килүгә миңа хәбәр итәрсез.
Шәмсия. Ярый, килен, ярый. Үзең дә шалтырата торырсың. (*Озата чыга*.)

Кәнҗебикә белән Шәмсия керә.

Кәнҗебикә. Исән тордыгызмы, апа?
Шәмсия. Бер көйгә генә.
Кәнҗебикә. Җизни өйдәме?
Шәмсия. Юк, әле эштән кайтмаган. Авылдан килдеңме?
Кәнҗебикә. Юк, апа, Мәскәүдән товар белән кайтып килешем.

Шәмсия. Хатын башың белән ничек курыкмый йөрисең?

Кәнҗебикә. Сөйләмә инде, апа, кайчагында үзем дә аптырыйм. Элек вакытта ялгыз башым күрше авылга чыгарга курка идем. Хәзер атна саен Мәскәү юлына кырпак төшермим. Бу товарларны сатып бетерәм дә теге пуляк ягына китәм әле, анда товар очсыз, ди. Балалардан хәбәр киләме?

Шәмсия. Килгәли.

Кәнҗебикә. Ир балалар ир бала инде, ул Гөлшатка анда ни калган икән?

Шәмсия. Доктор кеше бит.

Кәнҗебикә. Булса да инде.

Шәмсия. Үзем дә аптырыйм. Өй тулы балалар иде, карлыгач балалары төсле очтылар да киттеләр. Тышта җил булса да, буран булса да, алар турында уйланам, алар турында кайгырам.

Кәнҗебикә. Кайгырмый ни? Кышы да нинди суык, каһәрле кыш булды бит. Сиңа гына сер итеп сөйлим, апа, иншалла, кешегә чыгармассың. Бу суыкларны да шул финнар җибәрә, ди.

Шәмсия. Ничек финнар җибәрә?

Кәнҗебикә. Безнең кияүләрнең җизнәсенең кодасы фронттан кайткан кызылармеецның апасының иреннән ишеткән. Шул әйтә, ди, Финляндия дигән җирнең түбәсе күккә тигән бик биек таулары бар икән, шул тауларның башына коточкыч суык җибәрә торган иләмсез станцалар салганнар, ди. Менә шул станцалар зур трубалары аша безгә таба суык җибәреп торалар икән.

Шәмсия. Куй, тузга язмаганны сөйләмә, безнең Совет илен бик зур диләр бит, ничек итеп машина көче белән салкынайтырлар икән.

Кәнҗебикә. Ник салкынайтмасыннар? Әнә күптән түгел генә сезнең шәһәрдә дә холодильник дигән завод салганнар ич. Шундагы машина көче белән берничә сәгать эчендә әллә никадәр боз таулары катырып куялар, ди. Шулай булгач, ышанмый нишлисең? Аннан, апа, сиңа гына сер итеп сөйлим, зинһар, кешегә чыгармассың. Шул безнең кияүләрнең җизнәсенең кодасы фронттан кайткан кызылармеецның апасының иреннән ишеткән. Фин солдатлары шулкадәр яхшы киенәләр, ди, һәрбер солдатның өстендә төлке тамагыннан тегелгән озын тун икән. Аркаларына электр машинасы куелган, ди. Шул машина электрик чыбыклары аша солдатның бөтен тәненә җылы җибәреп тора икән. Шул ук машина кирәк чагында солдатның баш очына беркетелгән котелок эчендә аш та пешереп куя икән.

Бүлмәдән Искәндәр чыга.

Искәндәр. Шәмсия апа, мине сорап шалтыратучы булса, әйтерсең, мин кинога барам.

Шәмсия. Ярый, әйтермен. (*Искәндәр китә.*)

Кәнҗебикә. Бу сездә торамыни?

Шәмсия. Сөйләмә инде, балалар киткәч, бер-ике көнгә генә дип кергән иде, чыгара алмыйбыз. Йә, шуннан соң?

Кәнҗебикә. Шуннан шул, безнең кияүләрнең җизнәсенең кодасы фронттан кайткан кызылармеецның апасының иреннән ишеткән. Шул, фин солдатлары эчтән ядрә үткәрми торган резина күлмәк кияләр икән. Шул каһәрләргә никадәр атсаң да, үтереп булмый, ди. Безнең командирлар, аптырагач, туп ядрәсе белән ата башлаганнар. Барыбер бернәрсә дә эшләтеп булмый, ди. Туп ядрәсе тиюгә, йомгак булып һавага очып китә икән дә бераздан дөп итеп төшеп утыра икән.

Шәмсия. Алар нинди кешеләр икән соң?

Кәнҗебикә. Алар, апа, Алып кадәрле зур гәүдәле, тубал кадәрле зур башлы, чәй тәлинкәсе кадәр зур күзле кешеләр икән. Уһу... сәгать унбер дә булган. Апа, берәр җиргә башым төртим әле. Әйберләремне урламасыннар дип, багунда йокламаган идем.

Шәмсия. Әнә бар, Гөлшат бүлмәсендәге диванга ятырсың.

Кәнҗебикә. Апа, мин килгәнне җизнигә белдермәсәң дә ярар, аның холкын беләсең, йә куып чыгарыр. (*Әйберләрен алып, бүлмәгә китә.*)

Ишектә звонок. Шәмсия барып ача. Таһир керә.

Таһир. Балалардан хәбәр юкмы?

Шәмсия. Юк, атасы. Шул турыда уйланып йөри торгач, чак-чак кына машина астында калмадым.

Таһир. Нишләп?

Шәмсия. Александровларның кызыннан хат юкмы икән дип бара идем. Бауман урамы буйлап уйга чумып бара торгач, урам аша чыгарга булганмын. Тротуарда кычкырышкан тавышка әйләнеп карасам, дөнья кадәр машина өстемә килә. Куркудан егылдым... Шуннан мине күтәреп алганнар да Татиздат алдына салганнар. Аңыма килгәндә ишетәм: бөтен җыелган халык шоферга рәхмәт әйтә. Бичара егет, мине таптатмас өчен, машинасын фонарь баганасына бәреп ваттырган. Шулай итеп, үлемнән калдым.

Таһир. Байгыш шикелле йөрмиләр аны.

Шәмсия. Анысы да монысы, карт, фронтта эшләр бик мөшкел икән.

Таһир. Кем әйтә?

Шәмсия. Кәнҗебикә сөйләде. Аларның кияүләренең җизнәсе кайткан, әллә нинди кеше ышанмаслык машиналары бар, дип әйтә, ди.

Таһир. Ышанма шул Кәнҗебикә гайбәтенә.

Шәмсия. Нишләп гайбәт булсын. Халык авызына кергән сүз буш булмый ул.

Таһир. Халык авызыннан чыккан һәрбер сүзне дә дөрес дип санарга ярамый. Бигрәк тә аны Кәнҗебикә кебек хатыннар сөйләсә. Ул нишләп йөри?

Шәмсия. Мәскәүдән кайтып килә.

Таһир. Син, Шәмсия, ул спекулянтканы өйгә кертүдән тыясыңмы инде, юкмы?

Шәмсия. Акрын, теге якта йоклый ул.

Таһир. Әле син аны кунарга да керттеңме?

Шәмсия. Керсә, чит кеше түгел лә, үз туганым.

Таһир. Андый туганнарыңның булуына караганда булмавы артыграк. Хәзер генә бит — туган, революциягә кадәр сәлам дә бирмиләр иде. Менә нәрсә, Шәмсия, бүген тимим, йокласын, әмма бүгеннән соң аяк басасы булмасын. Җизнәң кертергә кушмады дип тот та әйт. Кайда, чәең бармы?

Шәмсия. Куйдым, хәзер кайнап чыгар. (*Таһир җиңен сызганып юынырга китә. Ишектә звонок.*) Теге Искәндәр имгәк кайтты бугай. (*Барып ача.*)

Гаскәри киемнән Гөлшат керә.

Гөлшат. Әнкәй, исәнме!

Шәмсия. Саумы, балам!

Гөлшат. Әткәй кайда?

Шәмсия. Теге якта, юына.

Сөртенеп Таһир керә.

Гөлшат. Нихәл, әткәй, саумы!

Таһир. Исәнме, кызым, сау кайттыңмы?

Шәмсия. И бала, бала, сине күрер көнем дә бар икән.

Таһир. Әйдә, чишен, кызым, өстеңне сал. (*Чишендерәләр.*)

Шәмсия. Сөйлә, кызым, абыйларыңны күрдеңме?

Гөлшат. Ленинградка кадәр бер эшелонда барган идек, шуннан соң мин аларны күрмәдем.

Таһир. Син ничек, кызым, бөтенләйгә кайттыңмы?

Гөлшат. Юк, әткәй, мин берничә яралы командирны китердем.

Таһир. Йә, кызым, фронтта эшләр ничек?

Гөлшат. Яхшы, әткәй, тау-ташларны җимереп, алга барабыз.

Шәмсия. Ә безнең монда әллә ниләр сөйлиләр.

Таһир. Куй әле шул Кәнҗебикә гайбәтен.

Гөлшат. Дөрес, әткәй, Финляндия фронты безнең өчен көтелмәгән каршылыклар, табигый уңайсызлыклар китереп чыгарды. Ләкин безнең данлыклы Кызыл Армиябез каршында, халкыбызның үз Ватанына булган чиксез мәхәббәте алдында 45әр градуслы салкыннар, башка табигый уңайсызлыклар да чүп булып кына калдылар. Бөтен көнбатыш инженерлары кулы белән салынган тимер-бетон ныгытмалары, көлгә әйләнеп, күккә очалар. Финляндия өстендә очкан самолет тавышлары, меңләгән корыч танклар авазы, бөтен Скандинавия ярыматавын тетрәтеп, Европа илләренә барып ишетелә. Мин башта фронтта идем. Өч-дүрт җиреннән яраланган кызылармеецлар, командирлар, операция өстәленнән башын күтәрүгә, сугышка җибәрүне, Ватаныбызның язмышы белән үз тормышын алыштыруны сорыйлар.

Таһир. Менә ишеттеңме? Әллә нинди кешенең сүзенә ышанып, дошман тегермәненә су коеп йөрисең.

Шәмсия. Чын иттереп сөйләгәч, ышанмый нишлисең?

Таһир. Ышан, ышан, андый халык сиңа әллә нәрсәләр дә сөйләр.

Шәмсия. Ярый, минем белән булышып утырма. Әнә бар, утын ярып кер. Иртә белән Гөлшатның йокыдан торуына мич ашы пешереп җибәрербез.

Таһир. Синең шул булыр инде, рәхәтләнеп сөйләшергә дә бирмисең.

Шәмсия. Сөйләшерсең әле, төн озын. Кызым, юынып алмыйсыңмы?

Гөлшат. Бик яхшы булыр иде, әнкәй.

Шәмсия. Мин алайса ванна хәзерлим. Аннан чәй эчәрбез. (*Китә.*)

Гөлшат. Әткәй, әнкәй алдында әйтергә кыймадым. Безнең өчен кайгылы хәбәр бар.

Таһир. Нинди хәбәр ул, кызым?

Гөлшат. Син, әлбәттә, аек акыл белән кабул итәрсең. Безнең Шәүкәт белән Солтан абыйлар каты яраланганнар...

Таһир. Каты яраланганнар?..

Гөлшат. Әйе, әткәй. Бүгенгә әнкәйгә белдермә, җаен туры китереп әйтерсең.

Таһир. Кемнән ишеттең, кызым?
Гөлшат. Ленинградта алар белән бер частьта хезмәт итүче командирны очраттым, шул сөйләде.
Таһир. Ә соң Марат?
Гөлшат. Ул исән-сау, син кайгырма, әткәй. Аларның батырлыклары турында бөтен фронт газеталары мактап язалар. Менә миндә Ленинград газетасында басылган «Өч туган Таймасовлар экипажы» дигән зур мәкалә бар, портретларын да басканнар. (*Газета бирә.*)
Таһир. Әй балакайлар, балакайлар...
Гөлшат. Син үзең уйлап кара, әткәй, ак финнарга плен калып, унике сәгать буена сугышканнар. Дошманның берничә дотын җимереп, барлык тере көчен кырганнар. Марат, бер кулы яралы көенчә, кыш көне агымсуны йөзеп чыккан да, яланөс, яланаяк кар өстеннән барып, боевой заданиесен үзебезнекеләргә тапшырган. Шәүкәт белән Солтан абыйны коткарган. Шунда ук, икенче машинага утырып, дошманның ерак тылына кергән, кеше ышанмаслык могҗизалар күрсәткән.

Шәмсия керә.

Шәмсия. Син утын ярырга чыкмадыңмы әле? Бар инде, бар, газетаңны соңыннан укырсың.

Таһир китә.

Кызым, ванна булды.
Гөлшат. Ярый, әнкәй.
Шәмсия. Бар, кызым, син юынганчы, мин камыр изеп җибәрим.
Гөлшат. Әнкәй, Шамил шәһәрдәме?
Шәмсия. Шәһәрдә, кызым, шәһәрдә. Әле бүген генә Гөлшаттан хәбәр юкмы дип шалтыраткан иде. Ул бит хәзер зур кеше булды. Яшь очучыларны өйрәтә.
Гөлшат. Шалтыратыйм әле.
Шәмсия. Шалтырат, кызым, шалтырат. (*Искәндәр бүлмәсенә күрсәтеп.*) Бу каһәр төшкән белән бәйләнә күрмә, бик начар егет булып чыкты. Аның елгыларга мобилизация булган иде, авыруга сабышып, доктордан әллә нинди язулар алып, сугыштан качып калды. (*Китә.*)
Гөлшат (*телефонда*). 44-47, миңа Шамил кирәк иде. Шамил, бу синме? Таны, кем соң? Әйе, Гөлшат, күптән түгел генә самолетта кайтып төштем.

Искәндәр керә.

Искәндәр. Мин кемне күрәм! Гөлшат?! (*Йөгереп бара, Гөлшат әһәмият бирми генә сөйләвендә дәвам итә.*)
Гөлшат. Әйе, хатларыңны алдым, бик рәхмәт.
Искәндәр. Гөлшат, телефоныңны куй инде.
Гөлшат. Мин иртәгә китәм, вакытың булса кер, яме? Мин дә сине сагындым... Хуш хәзергә, ярый...
Искәндәр. Гөлшат, нинди язмыш сине монда китереп ташлады? Берәр йомыш белән кайттыңмы?
Гөлшат. Билгеле, качып түгел.
Искәндәр. Ничә тапкыр хат яздым, берсенә дә җавап алмадым.
Гөлшат. Хат язарга вакыт булмады.
Искәндәр. Йә, Гөлшат, финнарны бик каты кырабызмы?
Гөлшат. Төрле чак була.
Искәндәр. Их, җибәрмәделәр бит, шулкадәр китәсем килгән иде, булмады, берничә тапкыр гаризалар биреп карадым, юк, алмыйлар. Имеш, сездә йөрәк авыруы, сугышка ярамыйсыз, диләр.
Гөлшат. Ләкин мин сездә андый авыру билгеләре күрмим.
Искәндәр. Әллә ышанмыйсызмы? Менә документларым янымда...
Гөлшат. Кирәкми, мин сезгә документсыз да ышанам.
Искәндәр. Билгеле, шулай, без бер-беребезгә ышанырга тиеш. Шулай, Гөлшат, кайчан бу сугыш бетәр икән дә, кайчан безнең тантаналы туй көннәребез җитәр икән?
Гөлшат. Болай булгач, бераз кичектереп торырга туры килер.
Искәндәр. Кайчанга кадәр?
Гөлшат. Синең йөрәгең төзәлгәнчегә кадәр.
Искәндәр. Гөлшат, мин сине аңламыйм.
Гөлшат. Ә мин ачыктан-ачык аңлыйм. Кызыл авыз, шкурник син... (*Китә.*)

Искәндәр аптырап кала, бүлмәсенә кереп китә. Утын күтәреп, Таһир керә. Бүлмәдән Шәмсия чыга.

Шәмсия. Синең нишләп сөмсерең коелган?
Таһир. Утын ярганда, балта сабы белән теземә бәрдем.
Шәмсия. Карап эшлиләр аны.

Таһир. Чәең булдымы инде?
Шәмсия. Булды, теге якка хәзерләдем. Тик Гөлшат ваннадан чыкканны көтик инде.
Таһир. Ярый алайса, минем нәрсәгәдер кәефем юк.
Шәмсия. Бар алайса, бераз ятып тор.
Таһир. Мондагы утларны сүндерерсең, әрәмгә янмасын.
Шәмсия. Бар, бар, үзем карармын.

Таһир китә. Шәмсия утларны сүндерә. Бүлмәгә кереп барганда,
телефон шалтырый.

Әйе, без булабыз. Безгә киләсез? Без яттык инде. Сез кем соң? Совет председателе дисезме? Өйдә, өйдә. Атасы, кил әле.
Таһир (*бүлмәдән, башын сузып*). Кем ул?
Шәмсия. Сине сорыйлар. Ниндидер совет председателе, Таһир абзый өйдәме, хәзер сезгә барабыз, ди.
Таһир. Мондый вакытсыз чакта нинди председатель йөрсен, ди.
Шәмсия. Әнә бар, үзең сөйләш.
Таһир (*трубканы алып*). Әйе, Таһир Таймасов. Исәнмесез! Бу кем? Верховный Совет председателе? Ничек, минем улларымны дисезме? Хуш, әйе. Нишләп инде ул алай? Юк, мин алай әйтергә теләмәгән идем, чынлап та бу дөресме дип соравым иде. Обком секретаре белән киләсез? Рәхим итегез. Мондый шатлыклы чакта нинди йокы ди ул. Хәзергә хушыгыз.
Шәмсия. Нәрсә бар?
Таһир. Шатлык, Шәмсия, безнең Маратка Советлар Союзы Герое исеме бирелгән.
Шәмсия. Ә соң Солтангәрәй белән Шәүкәткә?.. Бернәрсә дә юкмыни?
Таһир. Алар Кызыл Байрак орденнары алганнар. (*Сүз таба алмый карашып торалар.*) Тукта әле, Шәмсия, нәрсә булды бу?
Шәмсия. Белмим, атасы, төш түгелдер бит?
Таһир. Юк, Шәмсия, өн бу, өн!.. Бар, син Гөлшатка әйт. Өстәлне бу якка хәзерлә. Булган сыйларыңны куй. Обком секретаре белән Верховный Совет председателе котларга килә, алар янына күршеләрне чакырам...

Таһир тышка, Шәмсия кухняга китә. Артта Таһирның «Әй, күршеләр, нишләп йоклап ятасыз, торыгыз...» дип кычкырып йөргәне ишетелә. Бераздан йөгереп өйгә керә. Ачык ишегалдында йокыдан уянган күршеләр күренә. Бүлмәләрдән Шәмсия, Гөлшат, Кәнҗебикә, Искәндәр чыга. Аптырап карап торалар.
Әйдәгез өйгә, өйгә керегез, түрдән узыгыз, Таймасовларның шатлыгын уртаклашыгыз...

Машина тавышы.

Шәмсия. Бар, кунакларны каршыла.

Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Таймасовлар квартирасы. Май аеның беренче көннәре. Тышта кояш яктысы. Киереп ачылган тәрәзәләр аша Казан шәһәренең тау як өлеше, Кремль башнялары күренә. Таһир белән Шәмсия, бүлмәдән чыгып, балконга узалар.
Шәмсия. Кара әле, атасы, никадәр халык...
Таһир. Әйе, Шәмсия, алар җиңеп кайтучы Казан егетләрен каршыларга вокзалга баралар. Ул егетләр арасында безнең улларыбыз булу нинди зур шатлык. Бире кил әле. Безгә хәзерләнергә кирәк булыр.
Шәмсия. Аш-су хәзерләнгән, калганнарын нарпит кешеләре карыйлар.
Таһир. Юк, мин ул турыда әйтмим. Мин — герой атасы. Син — аның анасы. Шулай булгач, кунаклар алдында ни дә булса сөйләргә туры килер.
Шәмсия. Кирәк булса, сөйләрсең.
Таһир. Мин сөйләрмен, менә син нишләрсең икән?
Шәмсия. Юк, юк, миннән булмый ул. Гомеремдә бер тапкыр жакт собраниесендә сөйләргә булып сүз алган идем, әллә ниләр бутап бетердем. Миннән булмый ул.
Таһир. Булмый дип ярамый, ни булса да сөйләргә кирәк. Син бит бер геройның, ике орденоносецның анасы.
Шәмсия. Яңадан бер герой тудырып үстерергә дисәләр, өстемә алам, әмма сөйләргә дисәләр, булмый ул.

Искәндәр керә.

Әнә, теге кайтты, яхшылап сөйләш.

Таһир. Кара әле, Искәндәр, малайларга урын кирәк, син бүлмәне бушатасыңмы, юкмы?

Искәндәр. Юкка гына, Таһир абзый, минем киңәшне тотмыйсың. Бер улың герой булды, икесе орден алды, шәһәр советына барып сорасаң, миңа берәр бүлмә табып бирерләр иде инде.

Таһир. Әһә, алай икән! Болай үзеңдә акыл юк түгел, мин әйтәм, биш-алты ай квартирамда буш тотыйм да, җитмәсә тагы үзеңә бүлмә дә алып бирим икән.

Искәндәр. Бирмәсәң, мин чыкмыйм, шул гына.

Таһир. Яхшылап әйткәнне белмәсәң, мин сине, энекәем, чыгарырмын.

Искәндәр. Хәлеңнән килсә карарсың. Урамга куып чыгарырга хакың юк.

Таһир. Хакым юкмы? (*Телефонга барып.*) Милиция начальнигын бирегез.

Искәндәр. Ярый инде, шалтыратма, чыгам, дидем бит. (*Бүлмәсенә кереп китә.*)

Шәмсия. Бу кадәр оятсыз кеше булыр икән. Гөлшат өчен үчегә ул.

Таһир. Төче телле кешедән өметеңне өз, диләр иде, бик дөрес икән. Тәмам канга тоз салды бит, сорыкорт.

Гөлшат керә.

Гөлшат. Әткәй, ишетәсезме?

Таһир. Әйе, кызым, ишетәбез.

Гөлшат. Казан егетләренә багышлап, «Геройлар маршы» дигән көй язганнар.

Арттан җырлап узалар.

Батырлык белән геройлар кайта,
Җиңү бәйрәме илне балкыта;
Алар шатлыгы — безнең шатлык ул,
Алар данлыгы — безнең данлык ул.
Әйдәгез, дуслар, урам яңратыйк.
Җырлыйк бергә, дөнья шаулатыйк.
Геройлар төсле, чын намус белән,
Уңышлар өчен бергә даулашыйк.

Шәмсия. Шундый шатлыклы көннәребездә бәбкәем Шәйхаттар гына юк.

Таһир. Әйе. Шәмсия, арыслandaй баланы югалту безнең өчен зур кайгы. Нишлисең, зур көрәшләр корбансыз булмаган кебек, зур сугышлар да үлемсез булмыйлар. Без аның исемен, үзебез үлгәнчегә кадәр, телләребездән төшермәбез. Һәр ел саен кабере өстенә барып, дошманнарга каршы йөрәгебездә ачу утлары сакларбыз. (*Сәгатьне карап.*) Барырга вакыт җитә, әйдәгез, өс-башларны алыштырыйк. (*Кереп китәләр.*)

Очучылар киеменнән Шамил керә, чемоданнар күтәреп, бүлмәдән Искәндәр чыга.

Шамил. Исәнмесез! Кая болай?

Искәндәр. Күченәм.

Шамил. Не везет сезгә, күченәсез дә күченәсез.

Искәндәр. Без шулай инде. Сөтнең каймагын җыябыз да сыегын башкаларга калдырабыз.

Шамил. Ничек, ничек дидең?

Искәндәр. Ярый, сау бул.

Шамил. Юк, китми тор. Гөлшат, Гөлшат...

Гөлшат чыга.

Гөлшат. Нәрсә, Шамил?

Шамил. Менә бу сезнең намуска тап төшерә торган сүзләр сөйли.

Искәндәр. Ышанмагыз, Гөлшат, ялганлый ул.

Шамил. Ах, оятсыз, хәзер генә «сөтнең каймагын җыябыз да сыегын башкаларга калдырабыз» дип әйттең бит.

Искәндәр. Валлаһи, честное слово, әйткәнем юк, ышаныгыз миңа.

Гөлшат. Әйе, сиңа «ышанырга ярый», чөнки син пошляк!

Искәндәр. Нәрсә?

Гөлшат. Күзеңнән ут күрсәтмәс борын чыгып киткән бул, вон!.. (*Искәндәр китә.*) Бу кадәр түбән, бу кадәр оятсыз кеше булыр икән. Ничек итеп мин шундый кабахәтне башта таный алмадым...

Шамил. Ярый, Гөлшат, калдыр аны. Мин сиңа үз турымда бер хәбәр әйтергә кердем.

Гөлшат. Нинди хәбәр ул?

Шамил. Мине Ерак Көнчыгышка җибәрәләр.

Гөлшат. Кайчан?

Шамил. Мәскәүдән җавап көтәм, бәлки, бүген үк булыр.
Гөлшат. Кызганыч.
Шамил. Минме?
Гөлшат. Юк, китүеңне әйтәм.
Шамил. Киресенчә, Ерак Көнчыгышка китүне мин үземә дәрәҗә дип саныйм. Чөнки миңа анда китү тәҗрибәмне арттырырга, очучылык техникамны күтәрергә ярдәм итәчәк. (*Сүз таба алмый.*) Гөлшат, әллә бергә китәбезме?
Гөлшат. Бик ерак шул.
Шамил. Булса соң? Ерак Көнчыгыш үз Ватаныбыз, үз җиребез бит.
Гөлшат. Анысы шулай. Ләкин клиникада зур профессор кул астында тагын да бераз эшлисем килә иде.
Шамил. Ярый, хәерле булсын. Китеп барсам, хуш, сау бул.
Гөлшат. Тукта инде, нигә ашыгасың?
Шамил. Аэродромда яңа тип машина сыныйсым бар.
Гөлшат. Предложениең шуның белән беттеме?
Шамил. Барлыгы шунда инде. Мин алай матур итеп боргалап-сыргалап сөйли белмим. Ләкин, Гөлшат, минем мәхәббәтем керсез, риясыз, саф йөрәктән булачак. Йә, әйт инде, ризамы?
Гөлшат. Ярый, Шамил, мин синең белән Ерак Көнчыгышка гына түгел, әллә кайларга да китәргә риза. (*Үбешәләр.*)

Кәгазь, карандаш тотып, Таһир чыга. Гөлшатны күреп борыла да ишеккә карап кычкыра.

Таһир. Рөстәмне минем янга чыгармагыз, доклад хәзерлим.

Гөлшат белән Шамил китәләр. Таһир язу өстәле янына утыра.

Ничек башларга икән? (*Ораторларча.*) Иптәшләр... Бөтен дөнья буржуазиясе... (*Туктый.*) Юк, ярамый, андый зур мәсьәләләргә кереп буталырсың да очына чыга алмыйча аптырап бетәрсең. Ни дә булса гади генә сүзләр табарга иде.

Кәнҗебикә керә.

Кәнҗебикә. Нихәл, җизни, арумы?
Таһир. Ару, ару, бик ару. Бу арада күренмәдең, кай тирәләрдә йөрдең?
Кәнҗебикә. Сөйләмә инде, җизни, таш капчыкта яттым бит.
Таһир. Нишләп?
Кәнҗебикә. Товар белән яптылар. Көчкә иллалла судка кадәр генә дип чыгардылар.
Таһир. Бик яхшы иткәннәр икән, балдыз. Сорыкорт булып яшәргә ярамаганны аңларга вакыт инде.
Кәнҗебикә. Үзем дә тәүбә иттем инде, җизни. Колхозга кайтып җиң сызганып эшләргә булдым.
Таһир. Акылга утырткannар, күрәсең?
Кәнҗебикә. Утырдым, җизни, бик нык утырдым. Апа кая соң?
Таһир. Теге якта. Үзеңнең болай бәхет юк түгел, төенче эт шикелле әллә каян иснәнеп сизәсең дә бәйрәм көннәрендә киләсең дә чыгасың.
Кәнҗебикә. Нинди бәйрәм тагы?
Таһир. Бүген малайлар кайта, кунаклар җыябыз. Хөкүмәт кешеләрен чакырабыз.
Кәнҗебикә. Шулаймыни? Кара әле, җизни, атбакат дигәннәрен ялласам?..
Таһир. Бар, бар, миңа уңайсызлама, күрәсең ич, доклад хәзерлим.
Кәнҗебикә китә.

(*Яңадан хәзерләргә керешә.*) Иптәшләр... Мин Николай патша заманында... (*Туктый.*) Болай ярамый, мондый сүзләрне һәрбер речь сөйләүче телгә ала. Ни дә булса кеше сөйләмәгән сүзләр табарга иде.
Шәмсия керә.

Шәмсия. Атасы, өстәлгә аракы куярбыз микән?
Таһир. Куй, куй, әчесеннән, төчесеннән мул итеп куй.
Шәмсия. Андый зур кунаклар эчәрләр микән соң?
Таһир. Ә-ә... Менә шундый мәҗлесләрдә әзрәк җибәргәлиләр.
Шәмсия. Аннан соң?
Таһир. Бар инде, бар, мине эштән бүләсең.

Шәмсия китә.

Әгәр дә Тукай кордашның сүзләре белән башласам.

Сания керә.

Сания. Саумы, Таһир абзый!
Таһир. Сау, сау.
Сания. Гөлшат апа өйдәме?
Таһир. Өйдә, өйдә, әнә теге якта. (*Аңа карамыйча, кире якка күрсәтә.*)

Сания китә.

Иптәшләр, мин сүземне бөек шагыйребез Габдулла Тукайның сүзләре белән башларга уйлыйм. Ул иске Россия халкының тормышын болай дип язган иде:

Көзге төн, мин йоклый алмыйм, өй түрендә җил елый;
Җил еламый, ач үлемнең куркусыннан ил елый.

Тукта әле, бүгенге шатлыклы көндә нигә мондый күңелсез шигырь укырга кирәк?

Шәмсия керә.

Шәмсия. Атасы, Марат апасының диванында йоклап йөри иде. Хәзер кая салырбыз икән?
Таһир. Чыннан да, яхшы караватЮ юк. Кичә әйткән булсаң, чыгып алган булыр идек, хәзер өлгерә алмыйбыз.
Шәмсия. Ярый инде, булмаса, иске урынында гына йоклар.
Таһир. Куй, юләр. Ул хәзер синең йомыштан йомышка чабып йөри торган Маратың түгел, Советлар Союзы Герое. Зур караватны бирергә туры килер.
Шәмсия. Ә үзебез кайда ятабыз ди?
Таһир. Без геройлар түгел, бер-ике көнгә идәндә дә ятырбыз.
Шәмсия. Аннан тагы?
Таһир. Ну билләһи... Тавык тары чүпләгәндәй, сүзең бетмәде. Бар инде, бар, башны чуалтасың.

Шофер керә.

Шофер. Таһир абзый, сезне алырга Совнаркомнан җибәргәннәр иде, озакламый поезд килә, ди.
Таһир. Шулаймы? Без хәзер.

Шофер китә.

Шәмсия. Соң, ничек, речең булдымы?
Таһир. Юк, Шәмсия, булмады, нәрсә булса да сөйләрмен инде, үз кешеләр, гаеп итмәсләр. Әйдә, өстеңә ки. (*Китәләр.*)

Сания белән Гөлшат чыга.

Сания. Гөлшат апа, ничек итеп Марат күзенә күреним инде?
Гөлшат. Нигә, Сания?
Сания. Соң бит теге вакытны мин аңардан көлгән идем. Син яшь малай, сабагыңны укы, дип хурлаган идем. Мин аны хәзер шулкадәр сөям, шулкадәр яратам... Төннәр буе йокламый чыгам. Әгәр дә ул минем шикелле үк: «Әй, син, яшь кыз бала, минем арттан йөрмә, әнә сабагыңны кара»,— дип җавап кайтарса, мин нишләрмен?..
Гөлшат. Марат алай эшләмәс, ул бик акыллы, яхшы күңелле бала. Ярый, мин җайлап кына әйтермен.

Юл киеменнән Кадрия керә.

Кадрия. Гөлшат?..
Гөлшат. Кадрия апа... (*Кочаклашып үбешәләр.*) Синең өчен борчылып тора идем. Ярый әле, кайтып өлгердең.
Кадрия. Син мине белсәң иде, Гөлшат... Кичә сездән Солтан кайта дигән телеграмманы алгач, төн буенча йокламый чыктым. Бүген таңнан, исполком председателен уятып, машина алдым, юлда шофер белән талашып беттем.
Гөлшат. Ни өчен?
Кадрия. Акрын китергән кебек тоела.
Гөлшат. Әйдә, Кадрия апа, каршыларга барабыз.
Кадрия. Мин юынмаган, киенмәгән дә.
Гөлшат. Ярар инде, гаепләмәс.
Кадрия. Юк, юк, бу көенчә аның күзенә күренер хәлем юк. Сез барыгыз, мин монда гына каршылармын.

Таһир белән Шәмсия киенеп чыга.

Таһир. Бәлеш... Кадрия килен дә кайтып өлгергән.
Кадрия. Саумы, әткәй! Исәнме, әнкәй!
Шәмсия. Бик яхшы, килен, әйдә, каршыларга барабыз.
Кадрия. Юк, әнкәй, мин монда гына каршылыйм инде. Минем Рөстәмем кая соң?
Шәмсия. Кунаклар киләсе булганга, кодаларга җибәргән идем.
Таһир. Әйдә, киттек, соңга калабыз.

Китәләр. Кадрия бүлмәгә уза. Хәзерләүче хатын-кызлар чыга.
Өстәлләрне кушып куялар. Киемнәрен үзгәртеп, Кәнҗәбикә керә.

Кәнҗәбикә. Ипләбрәк, аякларын сындырасыз. (*Урындыкларны рәтләп куялар.*) Юньләп куегыз, кулыгыз черемәгәндер бит.
Хатын. Абыстай, монда тыкшынып йөрмә әле, үз өеңдә хуҗа булырсың.
Кәнҗәбикә. Яхшылап эшләгез, миннән киткәнче, иясенә җиткәнче димәгез. (*Ашъяулыклар җәяләр, ашамлыклар кертеп куялар.*)
Маһирә керә.

Маһирә. Гөлшат өйдәме?
Кәнҗәбикә. Юк, бакзалга киттеләр. (*Китә.*)
Маһирә. Нишлим инде, соңга калдым бит. (*Телефон трубкасын алып.*) Вокзалны бирегез. Справочная, сөеклем, кырык алтынчы поезд тиз киләме? Нәрсә? Килде дисезме?

Кадрия керә.

Кадрия. Маһирә җаным...
Маһирә. Кадрия апа...
Кадрия. Нигә каршыларга бармадың?
Маһирә. Үч иткәндәй, бүген безнең балалар спектакле иде. Менә гримымны да сөртмәдем, монда йөгердем. Ләкин өлгерә алмадым.
Артта оркестр тавышы.

Кадрия. Әнә кайталар, әйдә балконга.

Балконга узалар. Кулларына чәчәкләр тотып, күп санда кызлар керә, оркестр якыная. Урамда шау-шу, «ура» тавышлары, йөгереп, Сания керә.

Сания. Кадрия апа, нишләп монда торасың, әйдә, ичмасам, баскыч төбендә каршы ал.
Кадрия. Кирәкми, Сания, халык алдында оялам.
Сания. Әй, нәрсәгә оялырга, чит кеше түгел лә, үз ирең ич, әйдә. (*Өстерәп китә.*)
Маһирә. Әйдәгез, кызлар, залда каршылыйбыз.

Залга чыгып тезеләләр. Зур итеп ишек ачыла, Таһир белән Шәмсия керә.

Таһир. Шәмсия, күрәсеңме, күпме кызлар җыелган?
Шәмсия. Әйдә, әйдә, телеңә салынма, әнә кунакларны каршыла.
Кунаклар керә.

Таһир. Әйдәгез, кунаклар, рәхим итегез, түрдән узыгыз.

Сания керә.

Сания. Керәләр, керәләр!..

Сәхнәдәге бөтен халык аягүрә басып кул чаба. Солтан, Шәүкәт, Марат керә, алар артында Гөлшат, Кадрия күренә, кызлар чәчәкләр ташлыйлар.

Пәрдә.

# ИЗГЕ ӘМАНӘТ

*Драма биш пәрдәдә, ун күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Гыйният Галимҗанов — күмер остасы.
Латыйфа — аның хатыны.
Фуат — аларның улы, шахта мөдире.
Наҗия — аларның кызы.

Хәзинә — Гыйниятнең анасы.
Әбузәр — шахтада хуҗалык мөдире.
Заһидә — аның хатыны.
Әсфан — Заһидәнең энесе.
Асия — Әбузәрнең сеңлесе, Фуатның хатыны.
Лидия — телеграфистка.
Мартынов — электротехник.
Остап — стахановчы.
Апанас — кортчы карт.
Шәйхи — шахтер.
Сахибә — аның хатыны.
Сабирҗан
Хәйрулла
Каюм
Һуберт — комендант.
Розенбах — комендант ярдәмчесе.
Һерман — немец докторы.
Ганс — немец солдаты.
Врач — урта яшьтәге хатын.
Һольцман — элекке шахта хуҗасы.
Петроччио — итальян солдаты.
Лазареску — румын солдаты.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галимҗановлар квартирасы, төрле якка китә торган ишекләр. Пәрдә ачылганда, дөм караңгы. Бер читтә, абажурлы өстәл лампасының яктысы астында, Наҗиянең пианинода уйнап-җырлап утырганы күренә.

Наҗия. Яз көнендә ап-ак чәчәк аткан
Агачларга туеп бакмадым.
Ул агачлар инде җимеш бирде,
Тик син, бәгърем, һаман кайтмадың.
Шомлы, салкын көзнең кичләрендә
Еракта шул миннән син, иркәм.
Киткән юлларыңнан күзем алмый,
Көтәм сине зарыгып кич, иртән.

Латыйфа керә.

Латыйфа. Кызым, нигә ятмыйсың инде?
Наҗия. Абыйны көтәм.
Латыйфа. Ул кайтмый торгандыр, кызым, кабинетында гына йокларга булгандыр.
Наҗия. Көтим әле, барыбер йоклыйсым да килми.
Латыйфа. Асия килен дә юкмы әле?
Наҗия. Яңа гына кайтып керде.
Латыйфа. Сәгать икенче инде, кайда йөрде икән?
Наҗия. Кодаларда булгандыр.

Латыйфа. Юк, кызым, анда түгелдер. Абыең белән бүген бик каты талашты... Ичмасам, аерылышсыннар иде. Абыеңны бетерә бит. Бичара бала көне-төне шахтада, фронт өчен тырыша. Ә монысы киенә дә ясана.

Ишектә звонок тавышы.

Әнә абыең кайтты, бар, ишек ач.

Латыйфа бүлмәгә, Наҗия ишек ачарга чыгып китә. Бераздан Фуат белән әйләнеп керә.

Наҗия. Абый, ашыйсың киләме?
Фуат. Юк, сеңлем. Бер стакан чәй булса, эчәр идем.
Наҗия. Хәзер, абый. (*Китә. Шунда ук стакан белән чәй кертеп куя.*)
Фуат. Әтинең хәле ничек?
Наҗия. Ярыйсы, гипска салгач, йокыга китте.

Фуат. Әйе... Һәр көнне иң яхшы шахтерларны фронтка бирәбез, шуның өстенә аның да шахтада булмавы бик нык сизелә... Теге йоклыймы?

Нажия. Юктыр әле, яңа гына кайтып керде...
Фуат. Кайда булган?
Нажия. Кем белә аны... (*Сүз табалмый торалар.*)
Фуат. Нажия, берәр көй уйна әле.
Нажия. Соң бит инде, абый.
Фуат. Кемгә ничек бит. Әйдә, уйна әле...

Нажия уйнарга керешә. Яртылаш чишенгән хәлдә, бүлмәдән Асия чыга.

Асия. Җитәрегез! Йокларга бирмисез...
Нажия чыгып китә.

Фуат. Кайда йөрдең?
Асия. Минем кайда йөрүемне йокларга ятканда сорамыйлар.
Фуат. Башка чакта минем вакытым юклыгын син бит беләсең.
Асия. Шулай да «үзгәләргә» табасың.
Фуат. Ничек инде ул «үзгәләргә»?
Асия. Бүген ниндидер бер ханым белән машинада кататься итеп йөргәнеңне күргәннәр.
Фуат. Беренчедән, «ниндидер» түгел, яңа килгән белгеч, икенчедән, кататься итеп йөрмәдек, Рудоуправлениегә эш белән бардык.
Асия. Сез ирләрнең шулай инде, кайсы монтажницагыз, кайсы чертежницагыз була...
Фуат. Үз гаебеңне аклар өчен, юк сәбәпләрне сылтау итәсеңме? Ләкин алар миңа ябышмый. Син миңа шуны әйт, кемдә булдың?
Асия. Һәрбер адымга рөхсәт алырга, кайту белән отчет бирә барырга сорамыйсыңмы тагын?
Фуат. Мин сиңа андый таләпләрне куйганым юк шикелле, шулай да мин хатынымның кайда йөргәнен белергә тиеш!..

Ишектә Латыйфа күренә.

Латыйфа. Улым, акрын, атаңны уятасың. Ятыгыз инде, вакыт бик соң бит... (*Китә.*)
Фуат. Их, Асия... Ватан күген каплап алган кара болыт пәрдәләре сиңа бер дә тәэсир итмиләрмени?
Асия. Кирәкми, мораль укыма! (*Бернәрсә булмагандай елмаеп.*) Әйдә, дуслашыйк. (*Кул бирә.*)
Фуат. Син бит әле миңа кайда булуыңны әйтмәдең.
Асия. Серафима Петровналарда идем, ул бүген хатын-кызлар җыйган иде, шунда бераз патефон уйнаттык, җырладык, биедек...
Фуат. Серафима бик иртә башлаган, ире киткәнгә өч ай да тулмаган, хатын-кыз мәҗлесләре оештырырга керешкән. Моннан соң андый компанияләргә йөрисе булма!..
Асия. Кая, миңа бер тәмәке бир әле.
Фуат. Син бит миңа «беркайчан да тартмыйм» дип сүз бирдең.
Асия. Тартмыйм ич инде, күптән ташладым, дуслашуыбыз хөрмәтенә берничә генә суырам.

Еракта тревогалы гудок тавышы. Латыйфа, Нажия чыга.

Нажия. Бу нәрсә? Һава тревогасымы?
Фуат. Юк, Нажия, бу ниндидер башка тревога!..
Латыйфадан башкалар аннан-моннан киенеп чыгып китәләр.

Латыйфа. Тагын нәрсә генә бар икән. (*Тәрәзәдән карап.*) Әйе, бертуктаусыз атлы арбалар, йөкле машиналарның кире якка агылуы юкка түгелдер... (*Өйдә тынлык. Үзен кая куярга белми.*) Нишлим инде, ятсам, күзне йокы алмас, ятмасам, эшкә кул бармый. Шундый төнне әнкәй дә китеп югалды.

Еракта самолетлар тавышы, зениткалар авазы.

Әнә, төнге юлбасарлар килделәр!..

Култык таягыннан ишектә Гыйният күренә.

Нигә тордың?.. Нигә урыныңнан кузгалдың? Мин сине уятмаска булган идем. Әйдә, алайса тышка чыгыйк.
Гыйният. Кирәкми, Латыйфа, беркая да чыкмыйбыз. Утны сүндер.

Дошман самолетлары якыная, зениткалар көчле ут ача, сызгырып төшкән бомба шартлавы ишетелә.

Латыйфа. Гыйният, мин куркам...
Гыйният. Курыкма, Латыйфа, кил минем яныма.

Латыйфа Гыйният янына елыша. Тышта дәһшәт дәвам итә.

Латыйфа. Балалар ни хәлдә икән?

Гыйният. Алар өчен кайгырма инде... Тик менә әнкәй кая соң? Әллә йоклап ятамы?

Латыйфа. Күрше Фатыйма ирен күрергә Харьковка китте, аның балалары янына кунарга кергән иде...

Гыйният. Киттеләр бугай?..

Латыйфа. Әйе, олактылар, ахры.

Гыйният тәрәзә каплавычын ача, өй эченә яктылык төшә.

Әнекәем!.. Бу кайсы төш яна?..

Гыйният. Олы урам тирәсе...

Латыйфа. Күпме йортлар җимерелеп, нинди бәндәләр һәлак булды икән?..

Гыйният. Әйе, коточкыч хәлләр... Кеше көче белән төзелгән күпме байлыклар, күпме җиһазлар кырыла, күпме бәндәләрнең җаны кыела. Күпме ятим сабыйларның күз яше коела... Юлбасарлар төсле кара төндә киләләр дә анасының җылы кочагында йоклап яткан сабыйлар өстенә бомба ташлыйлар...

Хәзинә кайтып керә.

Хәзинә. Күрдегезме, күрдегезме, тагын шәһәрнең астын өскә айкады?! Нигә соң безнекеләр явызларның каршыларына чыкмыйлар да тирес кортларыдай үрмәләгән «кабан дуңгызлары»ның борыннарына сукмыйлар?!

Гыйният. Сугыш серен безгә аңлау кыен эш ул, әнкәй, күрәсең, ул көн әле килеп җитмәгән.

Хәзинә. Вакыт инде, улым, юлын буарга, вакыт инде каны белән авыз-борынын юарга!..

Ашыгыч хәлдә Наҗия кайтып керә.

Латыйфа. Кызым, ни бар анда, нигә гудок кычкырткан?

Наҗия. Немецлар фронтны өзгәннәр. Бөтен организацияләргә күчәргә приказ бирелде. Теләгән кешеләргә шәһәрдән чыгарга кушалар.

Латыйфа. Шәһәрдән чыгарга?..

Гыйният. Кая?

Наҗия. Көнчыгышка. Озакламый Фуат абый машина белән кайтырга булды, җыенып торырга кушты.

Хәзинә. Мин сезгә әйтә килдем, тыныч чакта күчегез, дидем, тыңламадыгыз.

Наҗия. Дәү әни, әткәйнең кәефе юк.

Хәзинә. Әйдә, улым, әйдә, урыныңа кереп ят.

Гыйниятне җитәкләп китә.

Наҗия. Әнкәй, катып торма инде, әйберләрне җыйнарга кирәк.

Латыйфа. Тукта әле, кызым, бәлки, дөрес түгелдер.

Наҗия. Дөрес, әнкәй, әйтәм бит, мине Фуат абый җибәрде. «Тиздән кайтырмын, хәзер булып торыгыз» диде.

Латыйфа. Гомер иткән җиребезме, сезне тудырып үстергән нигезебезне ничек ташлап китәрбез икән?

Наҗия. Бер бездә генә түгел бит, бөтен ил белән. Әйдә, әни, җыенйык инде.

Латыйфа. Әйдә, әйдә!.. Башта иләк-чиләкләрне зур сандыкка тутырыйк.

Наҗия. Юк, әнкәй, аларның берсен дә алмыйбыз. Андый вак-төяк әйбер барган җирдә дә табылыр.

Латыйфа. Юк, юк, инәмне дә калдырмыйм. Гомерем буена бөртекләп җыйган әйберләрем белән нимеч калдыкларын кинәндерер хәлем юк.

Наҗия. Ул турыда уйлап та карама. Бөтен шәһәр китә бит. Барыбыз да иләк-чиләкләр төяп йөри башласак, нәрсә булыр иде.

Латыйфа. Алай булса, мин китмим, шул гына.

Наҗия. Ярый, китмәсәң, шунда калырсың. (*Кайбер әйберләрне алып китә.*)

Еракта бик каты шартлау тавышы ишетелә. Асия кайтып керә.

Латыйфа. Килен, әллә тагын килделәрме?

Асия. Юк, әнкәй. Шахтаны шартлаттылар!.. Наҗия җыенырга әйткәндер бит?

Латыйфа. Әйтте дә...

Асия. Әйткәч, ни карап торасың? Әйдә, әйберләрне алгала.

Латыйфа. Ничек инде алгала? Ә бу җиһазлар?

Асия. Алар бар да кала инде.

Латыйфа. Туктагыз әле. Сез акылдан яздыгызмы йә мин тилерәмме? Ничек итеп бу әйберләрне калдырырга да ничек итеп аларсыз яшәргә? Юк, юк, мин өй җиһазларымнан аерылмыйм.

Асия. Аерылмасаң, немецларга калырсың.

Латыйфа. Нигә сез мине шул нимеч калдыклары белән өркетәсез. Курыкмыйм мин нимечтән!..

Гайрәтләнеп китә. Асия ишектәге штораларны ала. Әбузәр керә.

Әбузәр. Җыенасызмы?

Асия. Әйе, дәдәй, җыенабыз. Сез өлгердегез дәмени?

Әбузәр. Мин кайтканда, җиңгәң җыенып маташа иде дә, туктаттым әле.

Асия. Нигә, китмәскә диган хәбәр бармы әллә?

Әбузәр. Андый хәбәр ишетелми ишетелүен дә... Әй, сеңлем, Донбассны биргәч, бетте инде...

Асия. Ни әйтергә телисеңдер, дәдәй, төшенмим.

Әбузәр. Дәдәңне төшенергә вакыт иде, сеңлем. Без бит синең белән столичный вокзалларда, патша поездларында ресторан тоткан Әбуталип Әбушахманов балалары. Шулай булгач, сиңа да качак булып йөрүнең нигә кирәге бар?

Асия. Юк, юк, бу мөмкин түгел. (*Китә.*)

Әбузәр. Мөмкин! Галимҗановлар белән араңны өзәргә бик вакыт.

Асия артыннан кереп китә. Наҗия чыга. Үзен кая куярга белми аптырап йөри.

Наҗия. Нигә бу абый кайтмый икән? Тизрәк китәсе иде... (*Күкрәктәге рух белән җырлый.*)

Хуш, исән бул, туган җирем,
Китәм синнән еракка.
Киткән кошлар кайткан кебек,
Без кайтырбыз бу якка.
Гөрләп торган шат яшьлегем
Үтте синең бишектә.
Яшь баладай иркәләвең
Оныталмам ничек тә.
Оныталмам йомшак җилең,
Серле зәңгәр төннәрең,
Оныта алмам беренче кат
Янып сөйгән көннәрем.

Танкистлар киеменнән Әсфан керә.

Әсфан. Сәлам гүзәл җырчыга!

Наҗия. Бу кем? Әсфан!

Әсфан. Наҗия... (*Кочагына ала.*)

Наҗия. Җибәр, Әсфан, чыгарлар.

Әсфан. Чыксыннар, сугышчыны гафу итәрләр.

Наҗия. Син ничек, озакка кайттыңмы?

Әсфан. Бик азга, берничә генә сәгатькә...

Наҗия. Аннан?

Әсфан. Машина алам да тагын фронтка. Сез дә китәргә җыенасыз, ахры?

Наҗия. Абыйның машина белән кайтканын гына көтәбез.

Әсфан. Ул әле тиз кайтмас, мин аның яныннан килдем. Ул анда шахтаның кыйммәтле машиналарын вагоннарга төятә.

Наҗия. Ә без аны монда түземсезлек белән көтәбез. Шулай диң, Әсфан, минем консерватория бетереп җырчы булу өметем, синең тау инженерлыгына ирешү теләкләрең тәмле төштәй генә булып калдылармыни?

Әсфан. Зарар юк, Наҗия. Масайган дошман тиздән безнең көчебезнең гайрәтен татыячак. Тынычлык сөюче халкыбызның канлы яше өчен безнең алда җавап бирәчәк. Гыйният абыйның аягына нәрсә булды соң?

Наҗия. Өченче көн немец самолетлары шәһәргә килделәр, электростанция тирәсенә берничә бомба ташладылар. Әткәй шул чагында станция түбәсендә дежур булган, көчле шартлау дулкыны аны җиргә бәреп төшергән.

Әсфан. Кызганыч... Безнең җизни сездә бугай, аның белән күрешергә дә, миңа китәргә вакыт.

Наҗия. Тукта инде, сөйләшик әле, бәлки, безгә яңадан күрешергә дә туры килмәс.

Әсфан. Нигә алай уйлыйсың?

Наҗия. Мин китәмен тылга, еракка, син каласың монда — фронтта. Безнең язмыш белән нәрсә булмаска мөмкин, бигрәк тә синең белән...

Әсфан. Минем өчен кайгырма. Миңа бик күп каты сугышларда, дәһшәтле атакаларда, дөрләп янган танк эчләрендә калырга туры килде. Ләкин Ватаныма, сиңа булган мәхәббәтем һәрвакытта мине саклады. Шундый авыр минутлар кичергән чакларымда күз алдыма килеп баса идең дә котылгысыз үлемне җиңәргә көч бирә идең. Моннан соң да син минем йөрәгемдә җиңү символы булып торырсың. Ярый, Наҗия, хуш... барып җитү белән миңа хат язарсың.

Күрешәләр, икесе ике бүлмәгә кереп китә. Гыйният белән Хәзинә чыга.

Хәзинә. Кил әле, улым. Латыйфа киленнең әйберләре өчен өзгәләнүе бик хаклы, мин дә җиһазларны кызганам. Әллә, мин әйтәм, Аллага тапшырып, өйдә мин калыйм микән?

Гыйният. Юк, юк, әнкәй, беребезгә дә калырга ярамый.

Хәзинә. Хак язганын күрермен, киленгә әйтеп тынычландырыйм әле. (*Китә.*)

Гыйният (*пианино өстендәге китапны алып*). Габдулла Тукай... Дошманнарга калмасын... (*Кесәсенә сала.*)

Фуат кайтып керә.

Улым, китәбезме?

Фуат. Сабыр, әткәй, минем сиңа сүзем бар...

Ишектә Әбузәр күренә. Штора артына яшеренә.

Гыйният. Ул нинди сүз, улым?

Фуат. Мин сиңа капиталь шахтасының генераль планын һәм яңа ачылган антрацит участогының чертежларын калдырам.

Гыйният. Нигә миңа, нигә үзеңдә сакламыйсың?

Фуат. Мин хәзер үк сугышка китәм.

Гыйният. Сугышка?

Фуат. Ул чертеж, планнар теләсә нинди шартларда да дошман кулына төшмәскә тиеш. Әгәр дә инде сакларга мөмкин булмаса — яндырырсың.

Әбузәр (*яшеренгән җиреннән чыгып*). Күрми дә торабыз, кияү кайткан икән.

Фуат. Син нишләп монда?

Әбузәр. Асиянең әйберләрен җыешырга, кодаларга булышырга кергән идем.

Фуат. Алар синең ярдәмеңнән башка да җыенырлар иде, сиңа бит бөтен складларыңны яндырырга, булган эш коралларын юк итәргә кушылган иде.

Әбузәр. Син борчылма, кияү, хәзер эшлибез аны, хәзер эшлибез.

Китәргә җыена. Бүлмәләрдән Наҗия, Латыйфа, Хәзинә, Асия, Әсфан чыга.

Латыйфа. Улым, без җыенып бетердек.

Наҗия. Абый, әйберләрне машинага ташыргамы?

Фуат. Кирәкми, Наҗия, ташымагыз. Мин сезгә бик күңелсез хәбәр китердем. Немецлар безнең чигенү юлыбызны кистеләр!..

Латыйфа. Харап булдык!

Хәзинә. Әсиргә калдыкмы?

Әбузәр. Немецка кол булдык?

Гыйният. Шауламагыз!.. Улым, хәлләр болай булгач, безгә нишләргә соң?

Фуат. Корал тотарга сәләтле кешеләр хәзер үк Ирек мәйданына җыела, ничек кенә булса да, дошман боҗрасын өзәргә тырышабыз.

Гыйният. Өзә алмасагыз?..

Фуат. Донбасс туфрагы өчен башыбызны куярбыз! Әсфан, әйдә, без киттек. Хуш, сау булыгыз!..

Исәнләшәләр, саубуллашалар. Китүчеләрне озата чыгалар.
Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Галимҗановлар квартирасы. Пәрдә ачылганда, кулына китап тотып, Хәзинә көйләп утыра. Асия кайтып керә.

Асия. Әткәйләр өйдә юкмы әллә?

Хәзинә. Юк шул... Үзем дә шул турыда ут йотып утырам... Иртән, полицайлар килеп, Наҗия белән икесен бергә алып киткәннәр иде, шуннан бирле кайтканнары юк... Син кичә тагын өйдә булмадың, кайда идең?

Асия. Караңгыда сезне уятып борчыйсым килмәде, абыйларга кереп кундым. Мин, гомумән инде, дәү әни, сездән китәм.

Хәзинә. Китәсең, кая?

Асия. Башка квартирага күчәм.

Хәзинә. Бездә урын тармыни?

Асия. Киресенчә, сездә шундый киң, шундый иркенлек... Җил-давылдан тынып калган дала шикелле, кайтып керсәң, җанны кая куярга урын тапмыйсың.

Хәзинә. Бу дөньялар һаман шулай бармас бит, үзгәрер әле. Сугыш бетәр, Фуатың кайтыр...

Асия. Юк, ул кайтмас инде.

Хәзинә. Каян беләсең?

Асия. Алар отрядыннан беркем дә калмаган.

Хәзинә. Кем әйтә?

Асия. Бар да шулай дип сөйлиләр.

Ганс керә.

Ганс. Капитан әфәнде сезне алырга җибәрде.

Хәзинә. Бу нинди мәхәббәтсез кеше?

Асия. Мине алырга килгән. Хуш, сау бул, дәү әни, әткәй белән Наҗиягә әйтерсең. Мине гаепләмәсеннәр. Һәркем дөньяда үзенчә уйларга, үзенчә торырга тырыша бит.

Ганс (*ironияле көлү белән*). Исән бул, матка!

Китәләр.

Хәзинә (*тәрәзәдән карап кала*). Әйе, тормышның асты өскә айкала, кешеләр, су өстендә йөзгән йомычкадай, төрле якка чайкала... (*Себерке алып идәнне себерә.*)

Наҗия (*кайгылы хәлдә кайтып керә*). Нинди хурлык, нинди түбәнлек...

Хәзинә. Тукта, кызым, сиңа ни булды?

Наҗия. Биржада...

Хәзинә. Соң?

Наҗия. Бөтен шәһәрдән җыелган кызларны залга чыгарып тезделәр дә сәламәтлегебезне барлау хәйләсе астында чишендереп карадылар...

Хәзинә. Мәккә кяферләре икән... Шуннан?

Наҗия. Шуннан, төрлебезне төрле исемлеккә язып, мине бойнядa эшләргә билгеләделәр.

Хәзинә. Риза булмаска иде.

Наҗия. Риза булмый нишлисең?! Шунда ук конвой белән лагерьга йә Германиягә озаталар.

Хәзинә. Бу нинди законсыз, миһербансыз кешеләр икән. Атаң кайда калды соң, нигә кайтмады?

Наҗия. Без бит бергә булмадык, аны бүген комендатурага алып киттеләр.

Хәзинә. Тагын ниләр күрәсебез бар икән... Синең ашыйсың килә торгандыр, хәзер чәй куям. (*Кухня ягына китә.*)

Наҗия (*битен кулы белән каплап, ишекле-түрле йөри*). Нишләргә, нишләргә соң миңа?..

Лида керә, Наҗия аңа ташлана.

Лидочка, бу син?!

Лида. Әйе, Надя, мин...

Кочаклашып үбешәләр.

Наҗия. Сөйлә тизрәк, син каян?

Лида. Киевтан.

Наҗия. Күптәнме?

Лида. Яңа гына.

Наҗия. Берәр эш беләнме?

Лида. Юк, торырга кайттым.

Наҗия. Торырга? Без моннан ничек качарга белмибез, син торырга дисең.

Лида. Зарар юк, акрынлап торырбыз әле. Тормыш бит ул үзе өйрәтә. Йә, сездә ниләр бар?

Наҗия. Әтине һәр көнне биржага чакырып эшкә чыгарга кысалар иде, бүген комендатурага алып киттеләр... Абый хәбәрсез югалды... Әнкәйне үтерделәр...

Лида. Нәрсә өчен?

Наҗия. Безнең күршедә эсесчылар тора. Моннан биш-алты көн элек абзарыбызда сыерыбызны суеп ятканда өсләренә барып кергән. Эндәшмәскә кирәк иде аңар. Каравыл салып халык җыярга теләгән. Шул чагында капка төбендә атып үтерделәр. Син беләсеңме, Лида, мине бойнядa эшләргә куйдылар...

Лида. Елама, Надя, синең ул зарлы нәфрәтләреңне күз яшьләре баса алмас. Мин беләм, син хискә бирелүчән шагыйрә йөрәкле кыз, ләкин оккупация шартларында кичергән тормышыбыз хис белән түгел, акыл белән яшәүне таләп итә. Йөрәкләребездә кайнаган ачы нәфрәт тойгыларын көрәшкә файдаланыйк. Безнең мәктәптә бергә укыган иптәшләрдән биредә кемнәр бар?

Наҗия. Малайлардан беркем дә күренми. Катя Сорокина биржада күчерүче булып хезмәт итә. Аня Сидоренконы аттылар.

Лида. Ни өчен?
Наҗия. Яралы командирны яшереп асраган.
Лида. Тагын?
Наҗия. Луиза Янчевская румын офицерына кияүгә чыкты.

Гыйният кайтып керә.

Лида. Исәнмесез, Гыйният Галимҗанович!
Гыйният. Лидочка... Син укуда идең түгелме?
Лида. Әйе, шулай идем.
Гыйният. Димәк, син дә китә алмадың?
Лида. Юк, мине бередә эшләргә калдырдылар.
Гыйният. Бередә эшләргә?

Әбузәр керә.

Әбузәр. Исәнмесез!
Наҗия. Лида, әйдә, урамда йөреп керәбез.
Лида. Хәзергә хушыгыз.

Наҗия белән китәләр.

Әбузәр. Йә, кода, ни эшләр бетереп ятасыз?
Гыйният. Эшләр беткән, көлтә җыясы гына калды. Үзеңне котларга кирәк. Дәрәҗәгә менгәнсең икән.
Әбузәр. Нинди дәрәҗә?
Гыйният. Шәһәр идарәсенә тылмач булып кергәнсең түгелме?
Әбузәр. И кода, син аны куй әле, Әсфан яныннан бер кеше качып кайткан.
Гыйният. Ул исән?
Әбузәр. Әйе, исән, пленга эләккән. Харьков янындагы лагерьда ята икән. Егетнең тормышы авыр, ди... Апасы, мескен, башын да күтәрми, елый да елый... Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, үземне бүген комендатурага чакырдылар.
Гыйният. Нәрсәгә?
Әбузәр. Фуат кияүнең сиңа биреп калдырган чертежларын сорыйлар.
Гыйният. Аның миңа чертеж калдырганын каян беләсең?
Әбузәр. Комендатурада шулай диделәр. Сез, имеш, кардәшләр икәнсез, бергә ашап, бергә эчкәнсез, әйтегез, юкса икегезне дә кулга алабыз, диләр. Нинди чертежлар иде соң ул, кода?
Гыйният. Белмим, минем андый чертежларны күргәнем юк.
Әбузәр. Алай булгач, нигә миннән сорыйлар?
Гыйният (*үз-үзенә*). «Ярык юк димә бүрәнә өстендә, бүре юк димә бүрегең астында» икән.
Әбузәр *(аңламыйча)*. Ни дисең, кода?
Гыйният. Мин сине тылмач булып хезмәт итәсең икән дип ишеткән идем. Ләкин синең әле шпионлык һөнәрең дә бар икән.
Әбузәр. Мин шпион? Йа Алла!.. Кешеләргә яхшылык итим дисәң, яманлык булып кайта икән. Мин бит аны сезне кызганудан гына әйткән идем.
Гыйният. Сиңа үз-үзеңне кызганырга иде, юкса үлгән чагыңда авызыңа су салучың да табылмас. Бар, безнең өйгә аяк басасы булма!..

Хәзинә керә.

Әбузәр. Юк, басарбыз әле!.. (*Китә.*)
Хәзинә. Нигә җикеренә ул?
Гыйният. Фуат китәр алдыннан миңа әманәт итеп шахтаның генераль планын, антрацит участогының чертежларын калдырган иде. Ул аны ничектер сизгән. Шуны миннән юмалап алмакчы була. (*Яшергән җиреннән алып.*) Дөнья хәлен, әнкәй, белмәссең, минем белән әллә нәрсә булырга мөмкин, мин аларны сиңа тапшырам. Хәзер үк утка янмаслык, суга чыланмаслык җиргә урнаштыр.
Хәзинә. Ярый, улым, ярый, урнаштырырмын. Нигә чакырганнар?
Гыйният. Иртәгәдән эшкә чыгарга приказ бирделәр.
Хәзинә. Соң, нишлисең?
Гыйният. Чыкмыйм, теләсә нишләсеннәр, чыкмыйм.

Остап керә. Хәзинә китә.

Әйдә, Остап Тимофеевич, бу көннәрдә күренмәдең, кайда идең?
Остап. Киров шахтасына кызымның хәлен белергә барган идем.
Гыйният. Соң, анда ниләр бар?

Остап. Точно бездәгечә, бөтен халык кайгы-хәсрәткә күмелгән... Килеп кергән көнне үк җиде кешене асканнар. Шулар арасында минем кияү дә булган... Чирле кызым өч бала белән ятим калган. Шуларны үз яныма кайтардым. Синең үз хәлең ничек соң?

Гыйният. Һаман искечә, һәр көнне биржага чакырып эшкә кушалар иде, бүген комендатурада шахтаны торгызырга приказ бирделәр.

Остап. Димәк, эшкә чыгасың?

Гыйният. Юк, мин бүген төнлә качам.

Остап. Кая?

Гыйният. Партизаннар отрядына. Миңа монда яшәргә калмады.

Остап. Ансы точно. Сиңа улың янына китәргә кирәк.

Гыйният. Ул исән?

Остап. Точно, менә сиңа аннан хат. (*Хат бирә.*)

Гыйният. Остап Тимофеевич!.. (*Кочаклап үбә.*) Моның өчен мин сиңа нинди генә сөенче бүләге бирим икән?

Остап. Берни дә кирәкми, анысы соңыннан.

Гыйният. Юк, юк, хәзер үк бирәм. Шатлык көненә дип саклап килгән сыем бар иде, шуны эчик әле... (*Аракы чыгара. Чашкаларга сала.*) Әйдә, тот, киләчәк җиңүебез өчен...

Остап. Точно!..

Эчәләр. Кулына чемодан тотып, таза гәүдәле, урта яшьтәге Мартынов керә.

Мартынов. Миңа Галимҗанов кирәк иде.

Гыйният. Мин булам.

Мартынов. Мине сезгә квартирага җибәрделәр.

Гыйният. Гафу итегез, без кеше кертмибез.

Мартынов. Мин вакытлыча, квартира тапканчы гына сездә торырмын. Менә минем шәһәр идарәсеннән язылган кәгазем һәм квартальныйдан бирелгән ордерым. (*Кәгазьләр бирә.*) Йә, ни дисез?

Гыйният. Ярый инде, керерсез... Чишенегез.

Мартынов әйберләрен куеп чишенә. Чемоданын ачып сөлге ала. Гыйният белән Остап һәрбер хәрәкәтен дикъкать белән карап торалар.

Остап (*дорфа рәвештә*). Син кем буласың?

Мартынов. Күрәсез бит — эшче.

Остап. Профессия ягыннан дим.

Мартынов. Электротехник.

Остап. Эш эзләп килдеңме?

Мартынов. Юк, электростанциягезне торгызырга җибәрделәр.

Остап. Син немецмыни?

Мартынов. Юк, саф рус.

Остап. Ялганлыйсың! Саф рус немецка эшләмәс, точно.

Мартынов. Сиңа, карт кеше, бераз гына телеңне тыя төшкәндә яхшырак булыр иде.

Остап. Тел бит ул сөйләргә яралган.

Мартынов. Анысы шулай, ләкин сәгать теле шикелле бертуктамый болгап тору ярамый.

Остап. Нәрсә була?

Мартынов. Кызган тимергә йә кислотага тидерүең бар.

Остап. Өркетмә, курка торганнардан түгел, точно!..

Мартынов. Хуҗа әфәнде, мин юынып алмакчы идем.

Гыйният. Кухняда, ишектән чыккач, уң якта.

Мартынов. Рәхмәт. (*Китә.*)

Остап. Ишеттеңме нәрсә ди?.. Безгә хәзер немецка эшләү түгел, булганны ватарга, җимерергә иде, ә ул электростанция торгызырга килгән.

Гыйният. Әйе, Остап Тимофеевич, кем дус, кем дошман икәнен күрә алмаганбыз шул. Әнә минем кода, совет заманында песи кебек аяк очы белән генә йөргән кеше, немец килү белән нишләде? Аждаһага әйләнде.

Остап. Кая, тагын берне сал әле! (*Өстәлгә сугып.*) Мин аның тетмәсен тетәм, точно.

Гыйният. Кодаңныңмы?

Остап. Түгел, менә бу яңа килгән кешенең.

Гыйният. Кирәкми, Остап Тимофеевич, бәлагә калырсың. Шайтан белсен, ул нинди кешедер. Әйдә, тот әле.

Эчәләр.

Шуннан, Фуат кайсы шәһәрдә икән?

Остап. Мин анысын ачык әйтә алмыйм, хат китерүче, Мариупольдән, ди. Апанас Архипыч мине аның белән таныштырырга булды.

Мартынов сөлге белән сөртенеп керә.

Гыйният. Гафу итегез, иптәш... Әй, юк, әфәндем... сез кай шәһәрдән буласыз?

Мартынов. Харьковтан.

Гыйният. Сезнең анда тормышлар ничек соң?

Мартынов. Бер көе генә.

Гыйният. Сез үзегез генә килдегезме, әллә?..

Мартынов. Команда белән. Мин үткән төнне йоклый алмаган идем, берәр җирдә урын булмасмы?

Гыйният. Менә шунда диванга ятыгыз.

Мартынов урын хәзерләп ята.

Фронтта ниләр бар икән?

Мартынов. Сугышалар...

Гыйният. Бик каты микән?

Мартынов. Әйе...

Гыйният. Кызыллар һаман чигенәләр микән?

Мартынов. Әйе...

Гыйният. Сез, зур шәһәрдән килгән кеше, миңа шуны әйтегез әле...

Мартынов гырылдап йокыга китә.

Остап. Йоклады... Бу кеше гамьсез, кайгысыз кеше, точно. Без монда төннәр буе йокламыйча ил кайгысын баштан кичерәбез. Ә ул көпә-көндез ятты да гырылдап йокыга да китте...

Берничә солдат ияртеп, Розенбах керә.

Розенбах. Бу нинди кеше?

Гыйният. Минем күршем.

Розенбах. Алыгыз!..

Остапны кухняга таба алып китәләр.

Бусы кем?

Гыйният. Белмим, яңа гына шәһәр идарәсеннән квартирага керттеләр.

Розенбах. Уятыгыз!

Солдатлар Мартыновны көч-хәл белән уяталар.

Документ!..

Мартынов кәгазь чыгарып бирә. Розенбах аерым дикъкать белән карап.

Господин Мартынов, электротехник?

Мартынов. Әйе.

Розенбах. Бик яхшы. (*Гыйниятка.*) Синдә капиталь шахтасының генераль планы, антрацит участогының чертежлары бар икән, без шуны алырга килдек.

Гыйният. Миндә бернинди дә план, чертежлар юк.

Розенбах. Ә ни өчен синең улың?..

Гыйният. Нәрсә минем улым?

Розенбах. Башкача сөйли.

Гыйният. Ничек башкача?

Розенбах. Мин үз кулым белән әткәйгә биреп калдырдым, ди.

Гыйният. Ул сездә?

Розенбах. Әйе, безнең кулда. Тотылдың? Ха-ха-ха!

Гыйният. Юк, аның миңа берни дә биреп калдырганы юк.

Розенбах. Бар, без аны табарбыз. Башлагыз!..

Хәзинә белән Нәҗия керә. Тентергә ябышалар. Шкаф, этажеркалардагы китапларны идәнгә ташлыйлар. Җиһазларны туздыралар, туры килгән затлы әйберләрне кесәләренә салалар. Күрше бүлмәләргә кереп китәләр. Савыт-сабаларны ваталар. Нәрсәләрнедер аударалар. Кирәкле әйберләрен таба алмау ачуыннан тагын да зәһәрләнәләр. Гыйният белән Остапны алып китәләр. Тышта машина тавышы ишетелә.

Нәҗия. Дәү әни, инде нишлибез? Әткәйне дә алып киттеләр.

Хәзинә. Әйе, кызым, хәйран йортыбызны вәйран иттеләр.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шәһәр читендә, урман эчендә, умартачылык хуҗалыгының өендә бара. Тыштан кергәч, уң якта кортлар кышлый торган омшаник. Сулда кортчы Апанасның торак бүлмәсе. Өй эчендә төрле кисмәк, умарта кысалары өелеп куелган. Стенага челтәр һәм төтәткечләр эленгән. Пәрдә ачылганда, Апанас карт рамалар төзәтеп утыра. Аның янында Фуат, кулында җамаяк белән ачы бал.

Апанас. Корт анасы илне аерыр көнне иртә үк «тию, тию, тию» дип җырларга керешә.

Фуат. Кара син аны, алар да җырлыйлар диген.

Апанас. Нинди генә әле... Без эчеп җырлыйбыз, алар аек баштан шундый матур итеп җырлыйлар, тыңлап торсаң, исең китәрлек була. Тагын берне биримме?

Фуат. Юк, юк, болай да изрәдем.

Апанас. Изрәрсең, ул бит үзе дә бала кортлар балыннан.

Фуат. Аның да аермасы бармыни?

Апанас. Бар шул, әйтәм бит, кортлар, картая барган саен, бал җыю сәләтләрен киметәләр. Балның сыйфатын төшерәләр. Ничек булса да еракка очмыйча, якын-тирәдәге икмәктән генә җыярга тырышалар. Беләсез инде, икмәк балы турталы, балавызлы була. Бала кортлар балы икенче инде, аның тәме дә, ләззәте дә башкача була.

Фуатка күзе төшеп.

Менә сиңа кирәк булса... Бу чыннан да эрегән, Фуат Гыйниятович, Фуат Гыйниятович!..

Фуат (*сискәнеп*). Ә, нәрсә бар?

Апанас. Бернәрсә дә юк. Нишләп алай утырган җирдә йоклыйсыз? Әллә авырыйсызмы?

Фуат. Сез мине гафу итегез, Панас Архипыч. Мин өч төн инде керфек тә какмаган.

Апанас. Алай булгач, нигә миңа әйтмисез? Барыгыз, бүлмәгә кереп ял итегез. Иптәш Батько килгәч, үзем уятырмын.

Фуат бүлмәгә кереп китә. Омшаниктан Лида йөгереп чыга.

Лида. Апанас Архипыч, ишетәсеңме, сөйли бит!

Апанас. Каян ул?

Лида. Мәскәүдән.

Апанас. Мәскәүдән?

Лида. Әйе, Мәскәүдән «Иван Сусанин» операсын бирәләр.

Апанас. Димәк, кызым, Мәскәү бар, Мәскәү яши?

Лида. Әйе, Апанас Архипыч, Мәскәү әүвәлгечә мәгърур рәвештә җыр, музыка белән яши. Их, передатчигыбыз да булса иде. Без аларга монда ниләр булганын, халкыбызның немецлардан ниләр күргәнен белдереп торыр идек.

Апанас. Булыр әле, кызым, булыр. Хәзергә монысы да безнең өчен зур уңыш. Һәр көнне Мәскәү хәбәрләрен, фронт хәлләрен ишетеп торырбыз. Кемдер килә, бар, туктат!

Лида китә. Наҗия керә.

Наҗия. Исәнме, бабай?

Апанас. Исәнме, кызым, җылынырга кердеңме?

Наҗия. Юк, миңа Галимҗанов кирәк иде.

Апанас. Нинди Галимҗанов?..

Наҗия. Шикләнмә, бабай, мин аның сеңлесе. Мине бирегә кочегар җибәрде. Менә таныгым. (*Билге күрсәтә.*)

Апанас. Барыгыз, бүлмәгә керегез.

Наҗия бүлмәгә уза. Ашыгып Остап керә.

Остап. Панас Архипыч, шикле кеше бар.

Апанас. Кайда ул?

Остап (*тәрәзәдән күрсәтеп*). Сезнең койма буенда гөмбә җыеп йөри иде, әнә урманга кереп бара. Мин килгәнне күргәч, тайды, точно.

Апанас. Син аның шикле кеше икәнен каян беләсең?

Остап. Беркөнне Галимҗановларга квартирага төшкән иде. Шунда немецларга электростанция торгызырга килгәнлеген үз авызыннан сөйләде.

Апанас. Шулаймыни?

Остап. Точно. Аңардан сак булырга кирәк.

Апанас. Әйдә, утыр.
Остап. Бу мине чакырган кешең кайда соң?
Апанас. Бераз көт, килер. Бал эчәсеңме?
Остап. Бик рәхәтләнеп. (*Апанас бал салып бирә.*) Ул соң, берәр җирдә эшлиме?
Апанас. Кемне әйтәсең?
Остап. Теге, мине чакырган кешең, дим.
Апанас. Синнән яшереп булмый инде, Остап Тимофеевич, ул партия вәкиле. Олы җирдән килгән. Безнең арада эшләргә җибәрелгән.
Остап. Олы җирдән? Алай булгач, мине каян белә икән ул?
Апанас. Ник белмәсен? Син бит заманында бөтен Донбассны шаулаткан стахановчы Остап Бондаренко.
Остап. Анысы точно.
Апанас. Мин хәзер, Остап Тимофеевич. (*Омшаникка кереп китә.*)
Зур корзина тотып, Мартынов керә.

Мартынов (*өсләрен каккалап*). Исәнмесез!
Остап. Саумы. Гөмбә җыярга килдеңме?
Мартынов. Исәп шулай иде дә, бер дә табылмый икән.
Остап. Өй тирәсендә үсми бит ул, точно. Эчкәрәк керергә иде.
Мартынов. Коеп яңгыр яуганда чыланасым килмәде.
Остап. Курыктым диген, ха-ха-ха...
Мартынов. Нигә куркырга? Бүреләр юктыр бит.
Остап. Болай күренүен күренмиләр дә, ни өчендер синең кебекләр куркалар. Урманда түгел, урамда да юл уртасыннан гына йөриләр, точно. Хуҗаларың бик тиз туйдырмый башлаган.
Мартынов. Каян беләсең?
Остап. Шундый коеп яуган яңгыр астында гөмбә җыеп йөрмәс идең, точно.
Мартынов. Һи-һи-һи... Тартасыңмы? (*Папирос тәкъдим итә.*)
Остап. Үземнеке бар. (*Янчык чыгарып, тәмәке төрә башлый.*)
Мартынов. Син һаман үзгәрмисең икән.
Остап. Бөкрене кабер генә төзәтә, диләр бит, точно. Без күмерчеләр шулай инде. Штрекны турыдан-туры ярырга өйрәнгән, точно!
Омшаниктан Апанас чыга.

Апанас. Остап Тимофеевич, таныштыгызмы?
Остап. Кем белән?
Апанас. Сезне чакырткан иптәш шул инде.
Остап. Шул?..
Апанас. Үзең әйткәндәй, точно. (*Тышка чыгып китә.*)
Остап. Сез мине гафу итегез.
Мартынов. Зарар юк, андый ялгышулар була ул. Йә, Остап Тимофеевич, нишләп торасыз?
Остап. Ничек дип әйтергә... Исемегезне белмим.
Мартынов. Ул кадәресе кирәкми. Иптәш кочегар дип кенә йөртегез.
Остап. Башта куркытып, соңыннан хәйлә юллары белән дә эшләтергә карагаңнар иде дә, булдыра алмадылар. Мин картайган инде, пенсионер кеше дип эшкә чыкмадым.
Мартынов. Анысы өчен рәхмәт, тик менә сез алар белән талашып, алар яклы кешеләрне сүгеп йөрисез.
Остап. Безнең өстән хуҗалык итүләренә йөрәгем әрни. Урамда күрүгә бугазларына ябышасы килә, точно.
Мартынов. Вакыты килер, ябышырбыз! Коры сүгенү, бугаз киереп кычкыру белән генә аларны җиңеп булмас. Безгә хәзер астыртын рәвештә ватарга, астыртын рәвештә җимерергә, җае туры килү белән һәрбер фашистны тончыктыра барырга кирәк. Безнең Батько сезгә дә, ялгыз бунтарьлык, коры протест ясап йөрүегезне ташлап, эшкә урнашуыгызны таләп итә.
Остап. Кая, шахтагамы?
Мартынов. Юк, тимер юлда бик уңайлы урын бар, ди.
Остап. Мин бит күмер остасы, андый җирдә эшләгәнем юк.
Мартынов. Батько кушкач, өйрәнерсең. Менә минем дә гөмбә җыеп йөргәнем юк иде.
Остап. Анысы точно, хи-хи-хи... Шулай да ул Батько миңа нindирәк эшкә керергә куша соң?
Мартынов. Носильщик булып керергә, ди. Эш авыр түгел. Килгән кешеләрне каршыларга, киткәннәрен озатып калырга, һәм нинди поезд, нинди эшелоннарның фронтка озатылуын күзәтеп торырга, ди.
Остап. Эшсез йөрүдән үзем дә туйган идем, точно. Әйдә, барам, ул Батьконы миңа ничек күрергә соң?
Мартынов. Сез аны хәзергә күрә алмассыз, чөнки ул шәһәрдә юк. Кемгә барып мөрәҗәгать итәргә икәнен миңа әйтеп калдырды. Хәзергә барыгыз, омшаникка керә торыгыз.

Остап кереп китә. Бүлмәдән Нажия чыга.

Йә, кызым, күрдегезме?

Нажия. Әйе, Максим Савельевич, рәхмәт сезгә.

Мартынов. Ни өчен?

Нажия. Аны бит бирегә сез кайтарттыгыз.

Мартынов. Ул кечкенә мәсьәлә. Бире килегез әле. Немецлар шәһәрдәге эшкә яраклы кешеләрнең исемлеген алдылар. Димәк, алар халыкны көчләп эшкә кушарга, Германиягә каторгага куарга уйлыйлар. Сезнең биржада таныш кызларыгыз бар бугай?

Нажия. Әйе, ике иптәш кызым күчерүче булып хезмәт итә.

Мартынов. Сез алар белән иптәшләрчә генә сөйләшегез әле. Бәлки, алар әнә шул шомлы исемлекне юк итешүдә безгә булышырлар.

Нажия. Минемчә, алар каршы килмәсләр, чөнки берсенең абыйлары армиядә, икенчесе комсомолка иде.

Мартынов. Шулай да саклык белән... Нәтиҗәсен миңа әйтерсез. Абыең ял итәме?

Нажия. Юк, нәрсәдер язарга утырды.

Мартынов бүлмәгә, Нажия омшаникка кереп китә. Берничә хатын-кыз һәм ирләр ияртеп, Апанас керә.

Апанас. Әйдәгез, иптәшләр. Менә монда омшаникка узыгыз. (*Килгән кешеләрне кертеп җибәрә дә үзе тагын тышка чыгып китә.*)

Нажия белән Лида чыга.

Нажия. Лидочка, бәгырем, Әсфан кайткан, бүген иртән записка белән өйләренә чакырган иде. Үзе авыру икән. «Йөри дә алмыйм» дип яза.

Лида. Син бит аны пленда дигән идең? Ничек җибәргәннәр?

Нажия. Бөтен бәла дә шунда, көне буе үзем белән тартыштым, күңелем бармаска куша. Ә йөрәгем аның янына омтыла... Киңәш бир, нишлим икән?

Лида. Барырга кирәк. Ләкин яхшылап сына. Читләтеп сораштыр. Бәлки, аның гаебе булмагандыр.

Мартынов белән Фуатның чыкканын күреп, омшаникка кереп китәләр.

Мартынов. Немецлар бөтен көчләре белән атагызга калдырган планны табарга, сез мөдирлек иткән капиталь шахтасын торгызырга, антрацит участогын ачарга тырышалар. Чөнки аларга күмер кирәк. Без менә шул күмерне бирмәскә тиеш. Аннан, сез Горлопанов дигән инженерны беләсезме?

Фуат. Әйе, бик яхшы беләм. Рудоуправлениедә эшли иде. Хәзер кайда икән?

Мартынов. Кулга алдылар. Ләкин үз шкурасын саклау теләге белән, кайбер шахталарны торгызырга мөмкинлеген күрсәтеп, проект төзеп бирергә булган.

Фуат. Димәк, аны чыгарганнар.

Мартынов. Хәзергә юк әле. Проект өстендә эшли, ди. Төзеп бетерүгә, әлбәттә, чыгарачаклар. Менә шул проектны кулга төшерү кебек җаваплы заданиене дә Батько сезгә йөкләде.

Лида керә.

Лида. Иптәш кочегар, чакырылган кешеләр килеп бетте.

Мартынов. Хәзер башлыйбыз. Галимҗанов, керә торыгыз.

Фуат китә.

Лидочка, немецлар бүген үзләренең газеталары аша: «Мәскәү шәһәре камалган, сугыш урамнарда бара»,— дип ялган тараталар. Иптәш Батько Мәскәү шәһәренең камалмавын һәм анда бервакытта да дошман солдатының аяк баса алмавын безгә бүген үк халыкка аңлатырга куша.

Лида. Язып бирсен иде, мин аны кулдан күчертеп таратыр идем.

Мартынов. Аның материалы язылган, басып яталар, ди. Озакламый аларны миңа китерерләр. Төнлә белән шәһәргә таратырсыз. Аннан, Лидочка, Батько сезгә ничек кенә булса да комендатура тирәсенә элемтә эшенә урнашырга куша.

Лида. Гестапога?

Мартынов. Әйе, гестапога...

Лида. Яхшы, иптәш кочегар. (*Омшаникка кереп китә.*)

Берничә кеше ияртеп, Апанас керә. Аларны омшаникка озата.

Мартынов. Панас Архипыч! Моннан ерак түгел җирдә Батьконың күмелгән кораллары бар икән, кар төшкәнче шуларны бирегә китерәсе иде, транспорт табып булмасмы?

Апанас. Ничә олау кирәк булыр икән?

Мартынов. Ике фургон булса, җитә.

Апанас. Алай гына булса табылыр, крестьяннарны кушарбыз.

Мартынов. Китерерләр дисеңме?

Апанас. Китерерләр! Күрәсең бит, тышта бозлы яңгыр явуына карамастан, күпме халык җыелды.

Мартынов. Әйе, Панас Архипыч, безнең халык — алтын халык. Без әле ул халыкның ярдәме белән шундый эшләр эшләрбез... Немец фашистлары нигә туганнарына үкенерләр.

Апанас. Машина тавышы!

Мартынов кереп китә. Әбузәр керә.

Әбузәр. Апанас Архипыч, балта, көрәк кебек коралларыңны бир әле.

Апанас. Нәрсәгә ул?

Әбузәр. Хуҗалар белән «Артем» шахтасыннан кайтып килә идек, сезнең турыдагы бәләкәй күпер җимерелеп, машинабыз пычракка батты.

Апанас. Карап йөрергә иде.

Әбузәр. Шоферлар мондагы кешеләр түгел. Безнең юлларда йөри белмиләр.

Апанас. Көрәкләр өйалдында, чоланда.

Әбузәр. Синең өй бик җылы икән, анда минем хуҗалар туңа, машиналарны чыгарганчы кертеп торыйм әле.

Апанас. Белмим шул, андый кешеләргә минем өем ошамас бит.

Китәләр. Мартынов чыгып тәрәзәдән карый. Апанас керә.

Эшләр начар, нишлибез?

Мартынов. Каушама, Апанас Архипыч. Ничә кеше?

Апанас. Эт көтүе кадәр: ике автобус, бер җиңел машина.

Мартынов. Димәк, алар «Артем» шахтасына карательный отряд белән барганнар. Син хәзер безнең өстән бикләп ал. Ачы балың булса, кызганма, сыйла үзләрен.

Кереп китә. Апанас зур йозак белән бикләп ала. Һуберт, Ганс, Әбузәр керә.

Һуберт. Туры юлдан алып кайтам дип сазга батырдыгыз. Шайтан белсен, без аннан ничек чыгарбыз.

Әбузәр. Нишлим соң, капитан әфәнде, теләгем яхшылыкта, тизрәк шәһәргә алып кайту иде, яңгыр яуды бит.

Апанас. Капитан әфәнде, сез бик туңгансыз, бәлки, теге бүлмәгә кереп бал эчәрсез. Җылынырсыз.

Һуберт. Ул бүлмәдә бал бармы?

Апанас. Сезнең кебек кадерле кунаклар өчен табарга була.

Кереп китәләр. Ганс бу якта кала, төрле җирдән карана. Чөйдә эленеп торган ак күлмәкне алып куенына яшерә. Күзе омшаниктагы йозакка төшә. Кесәсеннән зур бәйләм белән ачкычлар чыгара. Ача башлый. Бүлмәдән Апанас чыга.

Апанас. Солдат! Син анда ни эшлисең?

Ганс. Кемнәр бар анда?

Апанас. Беркем дә юк. Кортлар шаулаша торгандыр.

Ганс. Әй, хохол, эшегез капут бит. Большевикларыгыз Мәскәүдән качкан...

Апанас. Ай-һай, булыр микән!

Ганс. Менә газетага язганнар. Ха-ха-ха!.. Инде нишлисез?

Апанас. Нишлик? Сезнең үкчәгезне кашырбыз.

Һуберт, Әбузәр чыга.

Һуберт. Ганс! Белеп кил, машиналар тизме саздан чыгарлар.

Ганс китә.

Әбузәр. Панас агай, капитан әфәнде сезнең хуҗалык белән танышырга тели.

Апанас. Рәхим итсеннәр, танышсыннар.

Һуберт. Ничә баш умартаң бар?

Апанас. Йөз кырык.

Әбузәр. Өч йөз илле иде бит, калганнары кая?

Апанас. Язлыкта колхозларга өләштек.

Һуберт. Колхоз? Колхоз капут. Ха-ха-ха... Күпме балың бар?

Апанас. Бер килограмм да юк.

Әбузәр. Быелгы урожай кая?

Апанас. Кая булсын? Солдатлар килделәр дә алдылар, килделәр дә алдылар. Син үзең дә шактый ук ташыдың.

Һуберт. Димәк, синең балың юк?

Апанас. Әйтәм бит, юк, капитан әфәнде.
Әбузәр. Идән астында кисмәк-кисмәк нинди баллар ул?
Апанас. Кортларның кышлык азыгы.
Һуберт. Кортлар азыксыз да яшәрләр. Безгә бал кирәк. Без аларны алабыз.
Апанас. Алай эшләү дөрес булмас бит, капитан әфәнде.
Һуберт. Күп сөйләнмә!

Ганс керә.

Ганс. Капитан әфәнде, машиналар саздан чыгарылды. Сезне көтәләр.
Һуберт. Яхшы. Барыгыз, балларны минем машинага ташыгыз!
Ганс белән Әбузәр бүлмәгә кереп китәләр.
Әй, хохол! Кортчылык хуҗалыгың бүгеннән безнең мәхкәмә карамагына алына.
Апанас. Бик яхшы, капитан әфәнде. Барып баш иярлек бер хуҗам булыр. Юкса, барганы да, кайтканы да бал сорый.

Зур кисмәкләр күтәреп, Әбузәр белән Ганс чыга.

Һуберт. Иртәгә Әбузәр әфәнде белән бөтен хуҗалыкның исемлеген төзеп миңа китерерсең!

Китәләр. Апанас озата чыга. Машина тавышлары ишетелә. Апанас әйләнеп керә. Омшаник ишегеннән Мартынов һәм башкалар чыга.

Мартынов. Киттеләрме?
Апанас. Әйе, киттеләр. Ләкин кортларымны кышлык азыктан мәхрүм иттеләр...
Мартынов. Шаулама, Апанас Архипыч, кортларыңа азык табарбыз. Безнең өчен бу яхшы булды. Иртәгә үк капка башына «Шәһәр коменданты карамагындагы кортчылык хуҗалыгы» дип, зур вывеска язып куярбыз.

Лида йөгереп чыга.

Лида. Иптәшләр, Максим Савельевич, приемник эшли, Мәскәү сөйли!..

Бөтенесе баскан урыннарында тынып калалар. Омшаник эченнән тонык кына булып радио аша көчле кул чабу тавышлары ишетелә.
Ут сүнә.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Матур итеп җиһазланган, төрле мебельләр белән бизәлгән Әбузәр квартирасы. Пәрдә ачылганда, Әбузәр җыйналган халыкка сөйләп маташа. Коридорда
полицейский йөреп тора.

Әбузәр. Озын сүзнең кыскасы шул, җәмәгать, без татар шахтерлары иртәгәдән эшкә чыгарга тиеш. Кемгә сүз бирим? Ягез, картлар, сөйләгез! Әллә телегезне йоттыгызмы? Нигә эндәшмисез?
Шәйхи. Минем бер соравым бар.
Әбузәр. Рәхим ит, Шәйхи абзый, нинди сорау ул?
Шәйхи. Бу нәрсә, җыелышмы, куркытып сорау алумы, дим?
Әбузәр. Юк, Шәйхи абзый, бу җыелыш та, сорау алу да түгел. Бу агай-энеләрчә аңлашу. Үзара киңәшү генә.
Шәйхи. Алай булгач, нигә безне монда корал көче белән җыйдылар?
Әбузәр. Ике тапкыр игълан итеп килмәгәч, полиция аркылы чакырырга булдык, шул гына.
Шәйхи. Алай икән... Эшкә чыгу турында мин шуны әйтер идем: башка халыклардан аерылып, бер без генә эшләп йөрү килешеп бетәр микән, дим?
Әбузәр. Ник килешмәсен. Германия дәүләтенең бездән көткәне дә шул гына. Юкса «сезнең Казан татарлары безгә каршы кабахәт рәвештә сугышалар» дип зарланалар.
Шәйхи. Алай икән...
Әбузәр. Димәк, иртәгәдән эшкә чыгарга сүз бирәбез?
Шәйхи. Юк әле, энем Әбузәр, борчак куыргандай, эшне алай куырмыйк дигәндәй. Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар, дигән бабайлар. Без дә аерылмыйк.
Әбузәр. Димәк, чыкмыйсың?
Шәйхи. Башкалар ни әйтер, анда минем эшем юк, әмма мин үзем авыру кеше, картлыгым да бар, эшләп йөри алмам шул.
Әбузәр. Сабирҗан абзый, син ни дисең?
Сабирҗан. Мин авылга, крестьян арасына тимерче булып китәргә йөрим.
Әбузәр. Хәйрулла абзый, син?
Хәйрулла. Без толчукта, малай белән аяк киеме төзәтү кәсебенә керешмәкче идек.

Әбузәр. Ә син, Каюм абзый?
Каюм. Мин китәм әле...
Әбузәр. Нәрсә китәсең?!
Каюм. Яхшырак эш табылганны китәм.
Әбузәр. Ярый!.. Начарлык булса, миңа үпкәләмәссез. Шуның белән эш тәмам!..

Шәйхидән башкалар китәләр.

Шәйхи. Кеше югында үзеңә генә бер сүз әйтим әле. Син бит, энем, тукран хәленә төшкәнсең.
Әбузәр. Нинди тукран?
Шәйхи. Ишеткәнең юкмы? Бер тукран сумалага кунган, ди, ул каһәр суккан кош тик торучан түгел бит, бертуктаусыз чокынырга ярата. Шул, кунган сумаласын чокыйм дигән икән, борыны ябышкан, борынын алыйм дигән икән, койрыгы ябышкан, шулай итеп ычкына алмыйча тәки ябышып үлгән, ди. Синең хәл дә шуның шикелле.
Әбузәр. Аңлатып әйт, төшенмим.
Шәйхи. Төшенерсең әле. Ярый, энем, хуш, сау бул хәзергә. (*Китә.*)
Заһидә керә.

Заһидә. Нәрсә диләр?
Әбузәр. Әй, ул чукынган халык белән эшләп буламы. Руслардан башка чыкмыйбыз, диләр...
Заһидә. Ташларга иде, атасы. Бу кыланышың миңа да ошамый.
Әбузәр. Әсфан тордымы?
Заһидә. Юк әле, йоклый да йоклый. Әйтерсең гомерендә йокы күрмәгән.
Әбузәр. Бар, син кач, теге убырлы карчык килә.
Заһидә. Хәзинә кодагыймы?
Әбузәр. Шул инде, шул. Бар, бүлмәгә кер.
Заһидә. Кара әле, сиңа әйтәм...
Әбузәр. Бар, диләр сиңа!.. Әсфанны да бу якка чыгарма.

Заһидә китә. Хәзинә керә.

Хәзинә. Керергә ярыймы?
Әбузәр. Ул ни дигән сүз, кодагый? Әйдә, рәхим ит.
Хәзинә. Хуш, тереклек бирсен. (*Дога кылалар.*)
Әбузәр. Амин, шулай булсын.
Хәзинә. Оныттыгыз, кода, оныттыгыз. Хәлебезне дә килеп белмисез.
Әбузәр. Бушый алмыйм бит, кодагый.
Хәзинә. Син бушамасаң, башкаларга мөмкин иде, Латыйфа кодагыегыз үлеп тә килмәдегез. Әсфан кайткан икән, ул да килеп күренгәне юк.
Әбузәр. И кодагый, син аны куй инде, ул малай коры сөяккә калган бит.
Хәзинә. Авырыймыни?
Әбузәр. Ачка киселгән, кайтып кергәннән бирле башын да күтәргәне юк.
Хәзинә. Алай икән, Заһидә кодагый кая соң?
Әбузәр. Ул, ни, кодагый... Ерак базарга Әсфанга азык алырга киткән иде. Менә нәрсә, кодагый: синең үтенүең буенча мин Гыйният кода турында хуҗалар белән сөйләштем. Болай үзе исән-сау икән. Ләкин бөтенләй юк әйбер өчен утыра, диләр.
Хәзинә. Нинди әйбер өчен?
Әбузәр. Сезнең өйдә Фуат кияү калдырып киткән нindидер чертеж кәгазьләре булырга кирәк. Хуҗалар шуның кайдалыгын сорыйлар икән. Ә ул киреләнеп әйтми, ди.
Хәзинә. Белмим шул, безнең өйдә андый кәгазьләрнең бер дә күренгәне юк.
Әбузәр. Бар. Мин аны бик яхшы беләм. Фуат кияү китәр алдыннан минем алдымда Гыйният кодага тапшырды. Шуны эзләп табарга да коданы коткарырга кирәк.
Хәзинә. Юк бит, юк. Булган тәкъдирдә дә, син әйткәнчә эшләү әманәткә хыянәт итү була бит, хыянәт итү бик зур гөнаһ санала.
Әбузәр. Бернинди дә гөнаһ түгел. Казна әйберен яшереп кулда асрау — менә бу хыянәт инде. Шуның белән син улыңны үлемнән коткарасың бит.
Хәзинә. Аның өчен аңар үлем булырмы?
Әбузәр. Әлбәттә, ул кәгазьләр немецлар өчен әллә нинди әһәмиятле булмаса да, Гыйният коданың аларга карата яхшы теләктә булмавын күрсәтә. Ничек кенә булса да табарга кирәк. Кода харап була бит.
Хәзинә. Булмаганны каян табасың?
Әбузәр. Алай булса, менә нәрсә, кодагый, иртәгә Нәҗия өйдә югында мин сезгә барыйм әле, икәүләп бик әйбәтләп, бөтен җирегездән җентекләп эзләсәк, иншалла, табарбыз.

Хәзинә. И Алла... (*Урыныннан торып, Әбузәр каршына килә дә нәфрәт белән.*) Юкка гына анаң мәрхүмә син әбуҗаһилне тудырган... (*Китә.*)

Әбузәр. Заһидә, Заһидә, дим!

Заһидә керә.

Заһидә. Нигә шулкадәр акырасың?

Әбузәр. Мин тиз кайта алмам. Итальян базарына барам.

Әбузәр китә. Әсфан керә.

Заһидә. Нигә тордың, йокларга иде әле.

Әсфан. Җизнинең тавышына уяндым...

Заһидә. Синең инде карының ачкандыр.

Әсфан. Юк әле, апа, ашап кына яттым бит. Кил минем яныма утыр, мин бит сине шулкадәр сагындым...

Заһидә. Син мине белсәң иде, пленда — лагерьда дигән хәбәреңне ишеткәч, еладым да еладым...

Әсфан. Нажияне күрәсеңме?

Заһидә. Юк шул... Үзләре килмиләр, барып хәлләрен белим дисәң, җизнәң җибәрми.

Әсфан. Нигә кычкыра иде ул?

Заһидә. Сорама, җизнәң синең әллә нишләде...

Әсфан. Мин дә аңардан моны көтмәгән идем... Бая, картлар белән сөйләшкәнен ишеткәч, чәчләрем үрә торды...

Заһидә. Мин ерак базарга барып кайтыйм әле, сиңа кесәл пешерергә алма, җимеш булмасмы. (*Китә.*)

Әсфан үзен кая куярга белми йөренә. Китап алып укый.

Әсфан. Мин сыйныфның бөек көрәшенә
Артык айнык килеш карадым.
Һәрбер юлым, һәрбер хисем өчен,
Мин үземне мәсьүл санадым!

Нажия керә.

Нажия, бу синме?

Нажия. Өйдә үзең генәме?

Әсфан. Әйе, әйдә, утыр. Минем запискамны алдыңмы?

Нажия. Алдым.

Әсфан. Нигә килмәдең?

Нажия. Вакытым булмады.

Әсфан. Их, Нажия... Син дә мине оныткач...

Нажия. Заманасы шундый бит.

Әсфан. Тукта әле, Нажия, нигә син тәрәзәдән каранасың?

Нажия. Урамда квартальный полицейскием калган иде, китеп бармасын, дим. Син соң пленнан ничек котылдың?

Әсфан. Җизни мондагы начальстволар аша эш йөртеп кайтартты.

Нажия. Әйе, немецлар каршында аның дәрәҗәсе бар.

Әсфан. Ләкин мин аның андый дәрәҗәгә ирешүен көтмәгән идем.

Нажия. Нигә, начар түгел бит? Менә сине кайтартты...

Әсфан. Әйе, кайтартты... Шулай да, Нажия, син нигәдер бик салкын.

Нажия. Әнә шул квартальныем өчен борчылам.

Әсфан. Син, бәлки, миңа шикләнеп карый торгансыңдыр, ышан, Нажия, минем намусым кар шикелле ак, сөт шикелле пакь.

Нажия. Нишләп син пленга эләктең?

Әсфан. Фуат абый белән, сезнең яннан чыгып киткәч, штабка бардык, әлбәттә, дошман боҗрасын өзү вазифасы безнең танкистларга йөкләнде. Без йөздән артык машина белән кара болыт төсле ябырылган немец сафларына ташландык!.. Менә шул коточкыч сугышта машинам, минага эләгеп, сафтан чыккан, үзем контузия алганмын. Аңыма килгәндә, кул-аягым бәйләүле хәлдә немецлар арасында ята идем, шул көенчә мине лагерьга озаттылар.

Нажия. Шулай да син бик ябыккансың, үзгәргәнсең...

Әсфан. Үзгәрерсең... Сез бит минем анданиләр күргәнемне белмисез. Атналар буе бер локма капмаган хәлдә җир казый идек. Коеп яуган көзге яңгыр астында, ачык һавада куна идек. Җылынырга теләп ут ягыйм дисәң, яктырмыйлар иде. Шуннан барың бергә укмашып, юеш җиргә ятасың. Иртә белән йә катыра, йә кырау төшкән була. Команда булуга, тагын сикереп торасың. Шунда инде, кичә генә синең белән бергә эшләп йөргән иптәшләреңнең төн чыкканчы үлеп калганын күрәсең.

Нажия. Әсфан, мин сине квартальный белән таныштырыйм әле.
Әсфан. Кирәкми, мин ул итче немецларны күралмыйм.
Нажия. Син аның итче икәнең каян беләсең? Ул бик кызыклы квартальный. (*Китә.*)
Әсфан. Әйе, кызыклыдыр шул...

Немец полицее киеменнән Фуат белән Нажия керә.

Фуат абый!..
Фуат. Акрын, Әсфан...
Әсфан. Нажия, нигә инде аны башта ук шулай димәдең?
Нажия. Сине сыныйсым килде.
Фуат. Нажия, сиңа китәргә вакыт...
Әсфан. Юк, юк, мин аны җибәрмим.
Фуат. Әсфан, Нажияне тотарга ярамый. Аның җитди эше бар.
Нажия. Ярый, Әсфан, күрешербез әле, хуш, абый...
Фуат. Хуш, Нажия, каушама...

Нажия китә.

Әсфан. Шулай диң, Фуат абый.
Фуат. Әйе, Әсфан, шулай.
Әсфан. Син соң ничек монда?
Фуат. Асияне күрергә кердем.
Әсфан. Ул бит өйдә юк, командировкада.
Фуат. Шулаймыни? Йә, Әсфан, киләчәктә нишләргә уйлыйсың?
Әсфан. Бераз хәл җыеп аякка басу белән, фронт аша үзебезнекеләр ягына йә партизаннар арасына китәргә тора идем, менә син нинди киңәш бирерсең.
Фуат. Фронт аша кичү бик катлаулы эш. Минемчә, сиңа монда берәр эшкә керүдән дә яхшысы булмас.
Әсфан. Немецларга? Һичбер вакытта!.. Мин алардан күргән газапларның үчен алырга тиеш.
Фуат. Бигрәк тә яхшы, монда эшләсәң, андый теләгеңә тизрәк ирешерсең. Менә, мәсәлән, җирле халыктан полиция отрядлары төзиләр, тот та шунда кер.
Әсфан. Үз кешеләребезне камап йөрергә, дар агачларында муенчак кигезеп торыргамы?
Фуат. Полиция хезмәте ул гына түгел, әйтик: конвойный команда, төрмә надзирателе булырга ярый. Бигрәк тә синең шоферлык эшендә тәҗрибәң бар. Комендатура тирәсенә керергә кара. Җизнәң сиңа ярдәм итәр.
Әсфан. Кирәкми миңа аның ярдәме!.. Сез бит аның кем икәнен белмисез.
Фуат. Беләбез, ниләр эшләгәнен дә күреп торабыз.
Әсфан. Фуат абый, Асия апа кайтты!..
Фуат. Син бар, бүлмәгә кер.
Әсфан. Ялгышмыйсыңмы?.. Ул бит әүвәлге Асия түгел...
Фуат. Миңа аның белән сөйләшергә кирәк, бар.

Әсфан китә. Асия керә.

Асия. Бу кем?
Фуат. Әллә танымыйсыңмы?
Асия. Боже мой, син ничек монда?!
Фуат. Сине күрергә кайттым, әйдә, күрешик.
Асия. Килмә, килмә, мин синнән куркам.
Фуат. Курыкма, мин аю түгел, ашамам.
Асия. Нигә кайттың, сине монда тотарлар.
Фуат. Әйтәм бит, сине сагындым.
Асия. Сагынсаң, өч ай эчендә берәр хәбәр итәр идең.
Фуат. Туры килмәгәндер. Кем булып эшлисең?
Асия. Әйткәннәрдер инде. Комендатурада тылмачлык итәм.
Фуат. Бик яхшы түлиләр, ахры. Иң соңгы модада киенгәнсең. Күлмәк тезгә дә җитмәгән. Ул бизәнү, ул чәчләрне көязләү дисеңме, чын-чыннан шансонетка булгансың.
Асия. Җитәр! Мин үземнең намусыма кагылырга юл куймам.
Фуат. Намус турында сөйләргә ничек син оялмыйсың, фахишә!
Асия. Нәрсә?..
Фуат. Син бит иң кабахәт бер фашистка түшәк җәймәсе булгансың.
Асия. Әй, кем бар анда... ярдәм итегез!.. (*Ишеккә таба бара, Фуат, кулыннан тотып, граната күрсәтә.*)

Фуат. Тыныңны чыгарасы булма, елан!..
Асия. Фуат, тимә, үтермә...
Фуат. Дөньяда яшисең килсә, бүген үк миңа Горлопанов төзегән проектларны алып бир!..

Машина тавышы, икесе ике җиргә китеп басалар, Һуберт керә.

Һуберт. Син ни өчендер борчылган?
Асия. Мин... ни, капитан әфәнде, аңар әһәмият бирмәгез.
Һуберт. Бу нинди кеше?
Асия. Ул безнең квартальный, төнге каравыл акчасын сорарга кергән.
Һуберт. Сине тылмач итеп, срочно төрмәгә сорыйлар, минем машинама утырып хәзер үк китегез, кайтышлый господин Горлопановны алып килерсез. Өйдә бүлмәгә, мин сиңа язу бирермен.
Асия. Сез керә торыгыз, мин бу әфәндегә акча биреп озатыйм.
Һуберт. Яхшы. (*Кереп китә.*)
Асия. Фуат, кит! Хәзер үк моннан кит, үзеңне дә, безне дә харап итәсең.
Фуат. Сине кайда җибәрә ул?
Асия. Бер җиргә шунда...
Фуат. Ялганлама, дөресен әйт!..
Асия. Төрмәгә, проект белән Горлопановны алырга.
Һуберт (арттан кычкыра). Ася, мин сине көтәм...
Асия. Мин хәзер, Генрих! Бар инде, бар, монда хәзер каравыллар куела. (*Һуберт янына кереп китә.*)

Бүлмәдән Әсфан чыга.

Әсфан. Асия апа кая?
Фуат. Бүлмәдә, Һуберт янында. Мин китәм, бая әйткәннәрне онытма, бүген үк чарасын күрергә тырыш. (*Китә.*)

Өс-башлары тәртипсез хәлдә, бүлмәдән Асия чыга.

Асия. Ул кая, киттеме?
Әсфан. Әйе, китте.
Асия. Боже мой, өрәк булып нигә минем арттан йөри ул?

Әбузәр керә. Асия чыгып китә.

Әбузәр. Ни булган аңар?
Әсфан. Немецы кайткан.
Әбузәр. Һуберт әфәндеме? (*Бүлмәгә таба бара башлый.*)
Әсфан. Җизни, минем сиңа бер киңәшем бар иде.
Әбузәр. Сөйлә, каениш, нинди киңәш ул?
Әсфан. Шундый каты сугыш вакытында минем кебек яшь егетнең эшсез өйдә ятуын хуҗалар ошатып бетермәс. Миңа нәрсә белән булса да шөгыльләнергә туры килер.
Әбузәр. Әйе, син, каениш, бераз хәл алу белән сәүдәгә керешерсең.
Әсфан. Белмим шул, җизни, андый эшкә миндә бер дә сәләтлек күренми.
Әбузәр. Өйрәнерсең, башта мин сиңа станциядә буфет ачып бирермен. Гомумән, сәүдә эшенә ныклап керешергә кирәк. Сугыш бетү белән, ул эш бик нык тәрәккый итәчәк. Син үзең нинди эш теләр идең соң?
Әсфан. Мин шул, үземнең шоферлык хезмәтенә урнашып булмасмы, дим. Хуҗалар белән сөйләшеп карасаң икән, бәлки, алар мине үз яннарына алырлар.

Һуберт күренә. Әсфан китә. Ишектә тыңлап тора.

Һуберт. Ә... Әбузәр, нинди яңалыклар?..
Әбузәр. Мин бүген карт шахтерларны җыеп сөйләштем. Ләкин «без руслардан аерылмыйбыз» диләр.
Һуберт. Ә план, чертежлар нишләде?
Әбузәр. Минемчә, ул план, чертежларны Гыйният үзе каядыр яшергән. Сез аның белән йомшак мөгамәлә итәсез, ныграк кыссагыз әйтер иде.

Әбузәр китә, Розенбах керә.

Розенбах. Капитан әфәнде, рөхсәт итегез!
Һуберт. Керегез. Капка төбендә нинди ханым ул?
Розенбах. Лида исемле минем бер таныш кызым.

Һуберт. Нишләп ул сезнең белән йөри?
Розенбах. Эш сорап мөрәҗәгать иткән иде, сезнең белән таныштырырга булдым.
Һуберт. Юк эш белән шөгыльләнмисезме, обер-лейтенант?
Розенбах. Тыныч булыгыз, капитан әфәнде, ул ышанычлы кыз. Сөйләшеп карасагыз иде.
Һуберт. Җибәрегез.

Розенбах китә, Лида белән кире керә.

Лида. Исәнмесез, капитан әфәнде!
Һуберт. Исәнме. Ни кирәк?
Лида. Мин обер-лейтенант әфәндегә эш сорап килгән идем. Ни өчендер ул сезнең белән таныштырырга булды.
Һуберт. Эш кирәк булса, хезмәт биржасына барыгыз.
Лида. Мин сезнең каршыгызда нинди дә булса игътибарга лаеклы кеше. Минем токымым дворян нәселеннән! Әтием Идел буендагы шәһәрләрнең берсендә зур промышленник булган. Гражданнар сугышында Врангель армиясендә офицер булып хезмәт иткән. Россия варварларына каршы оештырылган коалицион поход җимерелгәч, Донбасс шахталарының берсендә гади хисапчы булып хезмәт итәргә мәҗбүр булган. Безнең анда мануфактура фабрикабыз, авылда утарыбыз, шәһәрдә берничә йортыбыз калган. Менә документларым.
Һуберт. Ә ни өчен сезнең фамилиягез ике этажлы.
Лида. Безнең элекке фамилиябез Мошковскийлар булган. Мәрхүм әтиебез үзенә шик тудырмас өчен Машко дип украинлаштырган. Ләкин бичараны... шахты эшендә гаепләп аттылар...
Һуберт. Нинди уку дәрәҗәгез һәм специальностегыз бар?
Лида. Унынчы классны бетергәннән соң элемтәчеләр мәктәбенә мобилизовать иткәннәр иде, качтым!.. Ха-ха-ха!
Һуберт. Комсомолда тордыгызмы?
Лида. Аллам сакласын, якын да бармадым.
Һуберт. Мин сезне алу-алмау турында хәзергә бер сүз дә әйтә алмыйм. Шулай да обер-лейтенант аша минем җавабымны ишетерсез.
Лида. Хушыгыз, капитан әфәнде.
Һуберт. Хушыгыз.

Лида китә.

Сез хаклы, обер-лейтенант, чыннан да күз төшәрлек кызны тапкансыз. Үзе нәфис, үзе мөлаем...
Розенбах. Ул ягыннан бигрәк, капитан әфәнде, мине ул кызның перспективасы кызыктыра.
Һуберт. Әйе, Россия шартларында алпавыт утарына, мануфактура фабрикасына һәм берничә йортка хуҗа булу начар перспектива түгел. Шулай да күзәтергә кирәк. Манипуляция булмасын.
Розенбах. Әлбәттә.

Ганс керә.

Ганс. Капитан әфәнде, доложить итәргә рөхсәт итегез. Төрмә белән шәһәр арасында машинагызга һөҗүм иткәннәр.
Һуберт. Ничек? Һөҗүм иткәннәр?
Ганс. Горлопанов белән шоферыгызны үтергәннәр. Асия Абушахмановнаны каты яралаганнар.
Һуберт. Ә проект, проект нишләгән?
Ганс. Алып качканнар.

Артта янгынчылар үтеп киткән машина, быргы тавышлары ишетелә.

Һуберт. Бу нәрсә тагын?
Ганс. Хезмәт биржасы яна.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Немец комендатурасында допрос алу, җәзалау бүлмәсе. Төрле якка китә торган тәрәзәләрдә тимер челтәрләр. Пәрдә ачылганда, Розенбах телефонда сөйли.

Розенбах. Да, кадерле бургомистр, шәһәр управасының эшендә абсолют хәрәкәтсезлек. Электростанциягез нормаль эшләми, биржаны яндырдыгыз, урамнарга воззваниеләр ябыштыралар. Безгә булган лояль карашыгыз һәрбер эшегездә импонировать итәргә тиеш!

Лида керә.

Лида. Обер-лейтенант әфәнде, мин сезгә бер үтенеч белән кергән идем.
Розенбах. Сөйләгез, нинди үтенеч ул?
Лида. Бүген безнең чиркәүдә кечке молебен була. Әнкәй чиркәүгә барырбыз дигән иде.
Розенбах. Ха-ха-ха! Аллага ышанасыз?
Лида. Билгеле, мин дин йолаларын бик нык тотарга тырышам.
Розенбах. Күрәсе иде, сез ничек гыйбадәт кыласыз икән?
Лида. Башкалар ничек булса, мин дә шулайдыр.
Розенбах. Юк, алай гына түгелдер, чөнки сезнең һәрбер хәрәкәтегез грациоз гүзәллеккә бәйләнгән... (*Тотына*.)
Лида. Эрнст, җибәрегез. (*Ычкынып китә*.) Бу турыда мин сезгә ничә тапкыр кисәтү ясадым.
Розенбах. Мине дә чиркәүгә алып барыгыз.
Лида. Кирәкми, мин гыйбадәт кылганда бөтен рухым белән бирелүчән... Сез мине саташтырырсыз.
Розенбах. Мин читтән генә карап торырмын.
Лида. Юк, Эрнст, мин сезнең анда булуыгызны теләмим.
Розенбах. Сез, гомумән, минем тәкъдимнәремне кире кагасыз. Минем белән рестораннарга да, театр-киноларга да йөрмисез. Шулай ук никах тантанабызны да кичектерә барасыз.

Җитез адымнар белән Һуберт керә.

Һуберт. Обер-лейтенант, минем янга, бүлмәгә!

Китәләр. Шоферлар киеменнән, кулына планшет тотып, Әсфан керә.

Лида (*аерым саклык һәм дикъкать белән каршына килеп*). Әсфан, Батькодан задание...
Әсфан. Нинди задание?
Лида. Фуат Галимҗановны коткарырга!
Әсфан. Галимҗановны? Аңар ни булган?
Лида. Кичә, төрмәдәге иптәшләрне качыруга алып барган эше уңышсызлыкка очрап, шәһәрдән качкан иде, ләкин ерак китә алмаган, Свердлов шахтасында тотылган. Бүген аны монда китерәләр. Озакламый поезд килә. Һәммәбезгә станциядә булырга кушылды.
Әсфан. Охранасы?
Лида. Күп түгел, ике генә кеше. Төн караңгы, отлично итеп башкарырбыз. Аннан Нәҗияне күрергә кирәк, станция тирәсеннән абыйсына квартира табып кую аңар кушылды.
Әсфан. Аны бүген күрергә мөмкин түгел, чөнки ул төнге сменада.
Лида. Анысы начар икән... Ярый, син тизрәк төшәргә тырыш.

Розенбах бүлмәдән чыга.

Розенбах. Әле сез китмәдегез?
Лида. Ачык итеп әйтмәдегез бит, обер-лейтенант әфәнде.
Розенбах. Барыгыз, минем өчен дә гыйбадәт кылыгыз.

Лиданы озатып китә. Һуберт чыга.

Әсфан. Капитан әфәнде, машинада планшетыгызны калдыргансыз.
Һуберт. Шулаймыни, рәхмәт сезгә.
Әсфан. Капитан әфәнде, минем апам кисәктән бик җитди авырган, барасы җирегез булмаса, миңа өйгә кайтып килергә рөхсәт итсәгез иде.
Һуберт. Барыгыз, мин бүген беркая да барырга җыенмыйм.
Әсфан. Машина кирәк булса, ачкычларын дежурныйга калдырам. (*Китә*.)
Һуберт планшетын алып тикшереп карый. Розенбах керә.

Розенбах. Капитан әфәнде, урамнарга тагын Совет информбюросының сводкасын ябыштырганнар. (*Кәгазь бирә*.)
Һуберт. Тагын шул Батько?
Розенбах. Әйе, капитан әфәнде, крестьяннарга өндәү яза — Батько, шәһәр халкына приказ яза — Батько, ләкин кем ул Батько? Анысы безгә билгесез.
Һуберт. Галимҗановның тотылуы, бәлки, аның кем икәнен ачарга ярдәм итәр. Миңа Асия Абушахмановнаны җибәрегез.

Розенбах китә. Асия керә.

Сөйлә, мин тыңлыйм.

Асия. Мин тәмам терелдем, ярам төзәлде. Клиникада мине бик яхшы дәваладылар. Әлбәттә, сезнең миңа күрсәткән ихтирамыгыз аркасында. Аның өчен мин сезгә бурычлы.

Һуберт. Аңар кадәр дә минем ихтирамым сиңа начар түгел иде, ләкин синең ниндидер «билгесез» кеше тарафыннан яралануың миңа ошамый.

Асия. Капитан әфәнде, андый күңелсез вакыйганы искә төшермик.

Һуберт. Зарар юк, минем ул «билгесез» кешене беләсем килә.

Асия. Генрих, кирәкми, ул турыда сөйләмик.

Һуберт. Урыныңа утыр! Мин синең квартираңда түгел, сөйлә, ничек сезгә һөҗүм иттеләр?

Асия. Ул турыда мин сезгә берничә кат сөйләгән идем.

Һуберт. Тагын сөйлә!

Асия. Төрмә белән шәһәр арасында безнең машинаның камерасына аттылар. Шофер машинаны туктатып чыгарга өлгермәде — Горлопановка, аннан миңа аттылар. Калганын мин хәтерләмим.

Һуберт. Иреңне кайда күрдең?

Асия. Нинди иремне?..

Һуберт. Минемчә, синең законлы ирең бер генә: Фуат Галимҗанов.

Асия. Мин аны күргәнем юк.

Һуберт. Ялган сөйлисең, син аның белән күрешкәнсең.

Асия. Ышаныгыз, капитан әфәнде.

Һуберт. Сиңа хәзер аны яшерүдән файда юк. Очрашуыгызның ничек булганын сөйләп биргәндә генә үз гаебеңне җиңеләйтә аласың.

Асия. Ничек? Мин гаепләнүчеме?

Һуберт. Әлбәттә, син партизан ирең белән элемтә тотуда гаепләнәсең. Андый кешеләргә карата булган хөкем карарларыбыз сиңа билгеле: йә атабыз, йә базар мәйданына чыгарып асабыз!

Асия. Ах! Мин аның белән бернинди дә элемтә тотмадым һәм киткәннән бирле күргәнем дә юк иде. Ләкин, бәхетсезлеккә каршы, дөрес, мин аны Әбузәр абыйларда очраттым. Ул миннән Горлопанов төзегән проектны сорап тора иде. Өстебезгә сез килеп кердегез, мин ут белән су арасында калдым. Аптырагач, - мин аны квартальный дип атарга мәҗбүр булдым.

Һуберт. Ни өчен шунда миңа белдермәдең?

Асия. Сезне үтерүеннән курыктым, чөнки аның кулында гранатасы бар иде.

Кисәктән ут сүнә, караңгыда калалар. Розенбах керә.

Һуберт. Бу нәрсә тагын, бездә генәме?

Розенбах. Юк, капитан әфәнде, бөтен шәһәрдә берьюлы сүнде.

Һуберт. Барыгыз, белеп килегез.

Розенбах. Тыңлыйм, капитан әфәнде. (*Китә.*)

Һуберт. Мин сине Германиягә озатам.

Асия. Лагерьга?

Һуберт. Анысын баргач әйтерләр.

Асия. Генрих, аз гына булса да кызганыгыз.

Һуберт. Алладан сорагыз, без кешеләрне кызганмыйбыз.

Асия. Кичерегез, гафу итегез, мин аны тотып бирергә сүз бирәм.

Һуберт. Ул синең ярдәмеңнән башка да тотылган инде!

Тибеп подвалга төшерә. Розенбах керә.

Розенбах. Электростанциядә авария. Бүген ут булмас, диләр.

Һуберт. Тагын саботаж, тагын диверсия?

Розенбах. Әйе, капитан әфәнде, бу очраклы хәл булмаска тиеш. Хәзер генә вокзалдан хәбәр иттеләр, анда зур инцидент булган.

Һуберт. Нинди инцидент?

Розенбах. Фуат Галимҗановны поездан төшереп вокзал комендатурасына алып кергәндә, пычак-кинжаллар белән коралланган кешеләр шайкасы безнең охранага ташланганнар.

Һуберт. Охранага ташланганнар?

Розенбах. Әйе, капитан әфәнде. Охранникларның икесе дә үтерелгән.

Һуберт. Ә Галимҗанов?

Розенбах. Ул качырылган.

Һуберт. Качырылган? Вокзал охранасы, жандармнар ни караган?

Розенбах. Алар вакытында килеп өлгермәгәннәр. Шулай да аларның тырышлыгы белән һөҗүм итүчеләрнең берсе яраланып тотылган.

Һуберт. Аһа, тотылган? Димәк, кем икәне дә танылган?

Розенбах. Ул үзе кыз кеше, исем, фамилиясен һәм иптәшләрен әйтүдән баш тарткан. Озакламый аны монда китерәчәкләр. Аннан, капитан әфәнде, инцидент булган җирдән менә бу әйбер табылган.

Һуберт. Кулъяулыгы?

Розенбах. Әйе, капитан әфәнде, хатын-кыз кулъяулыгы. Монограммасы да бар.

Һуберт. Н. Г. Г., майлы кул белән керләнгән. Машинада эшләүче булырга кирәк.

Розенбах. Һичшиксез, аңардан бензин исе аңкып тора.

Һуберт. Хәзер үк адрес өстәленә мөрәҗәгать итеп монограммага туры килгән хатын-кызларның исемлеген алыгыз. Гыйният Галимҗановны кертегез.

Розенбах китә. Хадимә, кереп, шәмнәргә ут кабыза. Гыйниятне кертәләр.

Йә, хәлең ничек?

Гыйният. Губернаторларча.

Һуберт. Ха-ха-ха. Һаман шаярасың?

Гыйният. Нишлим? Еласам, барыбер кызганмассыз.

Һуберт. Елап кара, бәлки, кызганырбыз.

Гыйният. Булмас, сезнең йөрәк таштан яралган.

Һуберт. Беләсеңме мин сине нигә чакырттым?

Гыйният. План, чертежлар турындадыр.

Һуберт. Юк, бөтенләй икенче мәсьәлә турында. Син соңгы көннәрдә бик ябыктың. Синдә нинди дә булса авыру булырга кирәк.

Гыйният. Миндә бернинди дә авыру юк, мин бары тик ачка киселгән.

Һуберт. Шулай да мин сине компетентлы медицина белгеченнән каратырга булдым.

Трубка тартып, песи адымы белән Һерман керә.

Менә, ул үзе дә килде. Доктор! Безнең бу гаепләнүчебез көннән-көн ябыга. Сез, аны карап, үзегезнең гадел заключениегезне бирсәгез иде.

Һерман (*Гыйниятне караган булып*). Үпкәләре сау-сәламәт. Йөрәге сирәк кешеләрдә очрый торган таза йөрәк. Азык матдәләренең төре җитмәү аркасында организмы йомшарган, билгеле дәрәҗәдә суставларына зәгыйфьлек китергән. Шуны компенсировать итәр өчен һәр көнне мәгълүм дозада укол кабул итәргә тиеш. Сез шуңар ризамы?

Һуберт. Доктор, башлагыз!

Һерман процедурага керешә, телефон шалтырый.

Капитан Һуберт сөйли. Хәрби комендант Гильбах? Исәнмесез, капитан! Шәһәр читендә патрульдә йөрүче итальян солдатларының коралларын алганнар? Капитан әфәнде, ул итальян макарончыларын андый җаваплы постларга куймаска, дип, сезгә әйтелгән иде. Кеше җитми дип, ул лодзараннарга ышанырга ярамаганны бик яхшы беләсез.

Һерман. Йоклады, уяну белән хәрәкәт итәрсез.

Һуберт. Доктор, безнең подвалда авыру балалы бер хатын утыра. Баласы, дуңгыз шикелле чинап, безнең тынычлыкны боза, берәр медицина ярдәме күрсәтсәгез иде...

Һерман. Бүген үкме?

Һуберт. Хәтта хәзер үк.

Һерман. Фамилиясе?

Һуберт. Александрова. Аннан тиф белән авыручыларның да кайберләре сезнең ярдәмегезгә мохтаҗлар... Алар турында да берәр чара күрегез, без бит больница да, клиника да түгел.

Һерман китә. Розенбах керә.

Розенбах. Капитан әфәнде, адрес өстәленнән яулыктагы монограммага туры килгән хатын-кызларның исемлеген бирделәр. Беренче: Наталья Григорьевна Горбачева — тимер юлында кассирша. Икенче: Надежда Герасимовна Гордеенко — банкта уборщица, өченче: Наҗия Гыйниятовна Галимҗанова — бойняда эшләүче.

Һуберт. Һәммәсен дә алып килергә!

Гыйният (*уянып*). Су бирегез.

Розенбах китә.

Һуберт. Уяндың?

Гыйният. Минем эчәсем килә.

Һуберт. Шундый рәхәт йокы белән йокладың...

Гыйният. Мин сусадым...

Һуберт. Син үткән төнне йоклый алмагансың, ахры?

Гыйният. Минем тамагым кипте, эчәсем килә.

Һуберт. Эчәсең килә? Ләкин доктор әфәнде үзеннән башка бернәрсә дә бирмәскә кушты, көт, ул хәзер килер. Син йоклаган арада, мин диванга ятып торган идем, йокыга киткәнмен. Гаҗәеп бер төш күрдем. Сезнең халык төшкә ышана бугай. Бәлки, син аны миңа юрап бирерсең?

Гыйният. Минем эчәсем килә.

Һуберт. Әйтәм бит: доктор әфәнде үзеннән башка бирергә кушмады. Тыңла, мин сиңа төшемне сөйлим. Җәй көне икән, дим, мин бик матур бер юл белән барам, ләкин барган саен юлым бетә, тарая бара, ахыр чиктә тар сукмакка, аннан очсыз-кырыйсыз сахрага әйләнде. Анда инде агач, үсемлекләр дә күренми, бөтен җирдә эссе ком гына. Шулай итеп, берьялгызым сахра буйлатып барам...

Гыйният. Су бирегез, су!

Һуберт. Менә бервакытны сәмум җиле исә башлады, әйтерсең лә Ходаем җиде тәмуг утын минем өскә китереп ташлады. Хәлем бетте, көчем китте, мин егылдым җиргә йөзтүбән. Аңга килеп күземне ачсам, авыз кипкән, тел әйләнми, үз сулышым үземә ут кебек.

Гыйният. Су бирегез, мин үләм.

Һуберт. Син түземсез кеше икәнсең, сөйләп бетергәнне көт.

Гыйният. Кирәкми, күрәсез бит, мин янам.

Һуберт. Нишлим соң, доктор әфәнде кушмагач. Аннан, монда су да юк. (*Флягасыннан, тавышлатып, стаканга су сала.*)

Гыйният. Әнә шул судан бирегез.

Һуберт. Бу су түгел, лимонад.

Гыйният. Агу булса да бирегез. Бер генә йотым эчерегез. Мин сезгә чертежларның кайдалыгын әйтәм.

Һуберт. Әһә, әйтәсең?

Гыйният. Әйтәм, тик, зинһар өчен, бирегез.

Һуберт. Әүвәле әйт.

Гыйният. Күрәсез бит, минем хәлем юк, аның кайдалыгын сөйләп бирер өчен башта миңа көч кирәк.

Һуберт. Мә, эч. (*Лимонадлы стаканны бирә.*)

Гыйният йотлыгып эчә.

Гыйният. Мөмкин булса, тагын берне бирегез.

Һуберт тагын бирә.

Менә шулай, инде хәзер мин сөйли алам... Тыңла син, фашист!.. Кайчан булса да бер көн килер — бу газап чигүләребезнең җәзасын күрерсез, суд залларында, оятсыз күзләрегезне ялтыратып, кеше үтерүчеләр булып утырырсыз. Шул чагында сезгә балаларын җуйган картлар «Үлем!» диярләр, аталарын җуйган балалар «Үлем!» диярләр, ирләрен җуйган хатын-кызлар «Үлем сезгә!!!» дип кычкырырлар.

Һуберт. Җитәр, татар көчеге!.. (*Бөтен көченә суга.*)

Гыйният егыла. Звонок бирә, сакчы керә.

Алыгыз!

Гыйниятне өстерәп китәләр. Розенбах керә.

Розенбах. Капитан әфәнде, коточкыч хәбәрләр! Мәскәү янында безнең гаскәрләр һәлакәткә очраган!

Һуберт. Нинди һәлакәткә?

Розенбах. Руслар каты һөҗүмгә күчкәннәр, бер-бер артлы бик күп шәһәрләрне алганнар. Безнекеләр тәртипсез рәвештә чигенәләр.

Һуберт. Юк, моның булуы мөмкин түгел, мондый ялганны кем тарата?..

Розенбах. Ышаныгыз, капитан әфәнде, бөтен Англия һәм Америка радиостанцияләре бирәләр.

Һуберт. Обер-лейтенант! Тоткыннар исемлеген бирегез.

Розенбах. Григорий Захаров — партизан.

Һуберт. Атарга!

Розенбах. Мария Савчук — билгесез профессия кешесе.

Һуберт. Исле газга бирергә.

Розенбах. Екатерина Харламова — медицина хезмәткәре.

Һуберт. Циклон аша үткәрергә!

Розенбах. Исак Драверт — ялган документ ясаучы.

Һуберт. Асарга!

Розенбах. Гыйният Галимҗанов.

Һуберт. Овчаркага биреп талатырга!

Аягы яралы хәлдә Лиданы җитәкләп кертәләр.

Мошковская?!
Розенбах. Ул кыз син идең?..
Лида. Әйе, мин идем!..

Ут сүнә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук комендатура, пәрдә ачылганда, Лида, бер ноктага карап, күңелдән шигырь укып утыра.

Лида. Карлар улы славяннар,
Кайгы сездән китәчәк,
Бар тираннар беткән кебек,
Бу тиран да бетәчәк.

Һуберт керә.

Һуберт. Йә, промышленник кызы, уйладыңмы?
Лида. Уйладым.
Һуберт. Нинди карар?
Лида. Актык сулышыма кадәр бирешмәскә булдым.
Һуберт. Руска хас кирелекне дәвам иттерәсең?
Лида. Бу кирелек түгел, батырлык ул! Бөтен Европаны талап җыйган корал белән, яшел аждаһа, соры бүреләр, чуар юлбарыс сурәтләре төшерелгән танк, пушка, машиналар белән котыбызны алып, тез чүктерергә теләгән идегез, ләкин булдыра алмадыгыз.
Һуберт. Мин соңгы тапкыр сорыйм, туры җавап бир: кемнәр иде синең иптәшләрең?
Лида. Мин сезгә башта ук әйттем: ул турыда бернинди дә сорау бирмәгез, мин Фуат Галимҗановны коткарырга катнаштым, мине газаплау, асу, кисү өчен сезгә җитәрлек материал бит. Әмма ничек һәм кемнәр белән башкаруым, ансын инде ишетә алмассыз.
Һуберт. Алыгыз!

Лиданы алып китәләр. Розенбах керә.

Розенбах. Наҗия Галимҗанованы китерделәр.
Һуберт. Кертегез!

Розенбах китә. Наҗия керә.

Син миңа бүген нәрсә эшләвең, кайларда булуың турында сөйләп бир.
Наҗия. Мин бүген, төнге сменада эшлисе булганга, көне буе өйдә булдым. Кичке алтыда эшкә киттем. Конторага чакырдылар, барсам — полицейский көтеп утыра иде, ул мине үзе белән монда алып килде.
Һуберт. Алтыдан соң бер җирдә дә булмадың?
Наҗия. Юк, чөнки ул мөмкин дә түгел, бездә хәрби охрана, администрация рөхсәтеннән башка капка төбенә дә килә алмыйбыз.
Һуберт. Син берәр әйбер югалтмадыңмы?
Наҗия. Безнең өйдән югалган әйберләр күп, бездә сезнең солдатлар тора...
Һуберт (*бүлдереп*). Юк, мин ул турыда әйтмим. Синең шәхси әйберең турында сүз бара.
Наҗия. Андый әйбер югалтканым юк.
Һуберт. Уйлап кара.
Наҗия. Һич хәтерләмим, нәрсә булыр икән ул?
Һуберт. Яулык.
Наҗия. Нинди яулык?
Һуберт. Кулъяулыгы.
Наҗия. Минеке икәнен каян беләсез?
Һуберт. Чөнки аңар синең монограммаң язылган. Менә ул! Таныйсыңмы?
Наҗия. Таныйм.
Һуберт. Димәк, синеке?
Наҗия. Әйе, минеке.
Һуберт. Син аны кемгә биргән идең?
Наҗия. Беркемгә дә бирмәдем.
Һуберт. Дөресен сөйлә, син аны бойняда ит урлап тотылучы румын солдатына бүләк иткәнсең.
Наҗия. Бу — акылга сыймый торган уйдырма!

Һуберт. Ләкин, аның әйтүенә караганда, син аның белән бик якын бәйләнештә булгансың. Хәтта аның белән Румыниягә качып китәргә йөргәнсең.

Нәҗия. Бар да ялган. Мин, гомумән, румыннар белән бернинди дә бәйләнештә булганым һәм яулык та бүләк иткәнем юк. Минем сүзләремнең дөреслеген Әсфан Абдрахманов раслар. Чөнки мин ул яулыкны аңар бүләк иткән идем.

Розенбах керә.

Розенбах. Капитан әфәнде, көткән кешегез кайтты.
Һуберт. Яхшы. Бу кызны алыгыз.

Розенбах белән Нәҗия китә. Әсфан керә.

Әсфан. Капитан әфәнде, мине сорагансыз икән.
Һуберт. Нигә бик озак йөрдең?
Әсфан. Урамда облавага эләктем.
Һуберт. Яулыгыңны төшереп калдыргансың. Мә, ал! (*Өстәлгә ташлый.*)
Әсфан. Юк, капитан әфәнде, бу минем яулыгым түгел.
Һуберт. Синеке, ал!
Әсфан. Әйтәм бит, капитан әфәнде, минем мондый яулыгым булганы юк.
Һуберт. Ялган! Мин синнән әйттерермен... Тиреңне тунармын...
Әсфан. Минем беркемнән дә мондый яулык алганым юк.

Һуберт звонок бирә. Нәҗия белән Розенбах керә.

Һуберт. Галимҗанова, Абдурахмановка син биргән яулыкны таны, үз алдында расла.
Әсфан. Юк, мин аны үзем раслыйм!.. (*Револьвердан ата.*)

Һуберт егыла.

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәйхи карт өе; бу йорт станция тирәсендә булганга, һәрвакыт паровоз тавышы, үтеп киткән поезд авазлары ишетелеп тора. Вакыт кич. Шәйхи карт,
көйләп, аяк киеме төзәтеп утыра.

Шәйхи. Заманалар авыр, михнәтләр күп,
Дуслар кирәк дөнья күтәргә...

Остап керә.

Остап. Исәнмесез!
Шәйхи. Исәнме, Остап Тимофеевич, әйдә, утыр.
Остап. Рәхмәт, мин сиңа бик ашыгыч бер йомыш белән кергән идем.
Шәйхи. Сөйлә, Остап Тимофеевич, нинди йомыш ул?
Остап. Без бүген бер иптәшебезне жандарм кулыннан коткардык. Менә шуны берничә генә сәгатькә сездә тотып булмасмы?
Шәйхи. Кем соң ул?
Остап. Галимҗанов.
Шәйхи. Гыйниятме?
Остап. Түгел, Фуаты. Аның тормышы куркыныч астында.
Шәйхи. Хәзер кайда соң ул?
Остап. Моннан ерак түгел. Маркеловларның өй түбәсендә.
Шәйхи. Бар, бакча артлатып кына кертегез.

Остап китә. Бүлмәдән Сахибә чыга.

Сахибә. Кем бар иде?
Шәйхи. Остап Тимофеевич Бондаренко.
Сахибә. Беркөн урамда күргән идем, бик йолкышланган.
Шәйхи. Йолкышланырсың, ул бит хәзер стахановчы Бондаренко түгел, вокзалда носильщик.
Сахибә. Нишләп йөри?
Шәйхи. «Бик әйбәт пассажирым бар, квартирага кертмәссезме?» дип сорый.

Сахибә. Кеше җибәрергә ярамаганны белә торгандыр бит.
Шәйхи. Белә дә, пассажиры бик әйбәт кеше икән, мин китерергә куштым.
Сахибә. Китерергә куштың? Юк, юк, кертмим. Бусагамнан да атлатмыйм.
Шәйхи. Ярый инде, дулама, кунар да чыгар, өең ашалмас.
Сахибә. Квартальныйлар белеп, штраф салсалар?..
Шәйхи. Түләрбез, андый кеше өчен жәл түгел. Ерак җирдән килгән кеше булса, ашыйсы-эчәсе килер. Самавыр куеп җибәр.
Сахибә. Суым да, күмерем дә юк!
Шәйхи. Табарсың әле. (*Тәрәзә чиертәләр.*) Әнә килделәр!.. (*Чыгып китә.*)

Бераздан өс-башлары тәртипсез хәлдә Фуат керә.

Сахибә. Тукта, тукта, таныш кеше түгелме?
Фуат. Исәнме, Сахибә апа!
Сахибә. Син ничек монда?
Фуат. Кунакка кайттым, шәһәрегездә төнлә йөртмиләр икән. Сездә кунып чыгарга булдым.
Сахибә. Бик әйбәт иткәнсең. Безнең Хөснулла да синең кебек югалды бит. Йөргән җирләреңдә күрмәдеңме?
Фуат. Юк шул, Сахибәттәй, ул бит армиядә иде. Үзебезнекеләр ягындадыр.
Шәйхи керә.

Сахибә. Һи, карт юләр, карт юләр, Фуат дисәң ни була иде.
Шәйхи. Сине чәпчетәсем килде. Хи-хи-хи. Самавыр куй, дисәм, күмерем юк, дисең инде.
Сахибә. Фуат кебек кунак өчен самавырын да куярмын, сый-хөрмәтен дә табармын. (*Китә.*)
Фуат. Шәйхи абый, син мине гафу ит инде, тыныч тормышыңны борчыдым.
Шәйхи. Юкны сөйләмә, энем, мин бит совет кешесе, күбрәген дә эшлисе иде дә...
Фуат. Монысы өчен дә бик зур рәхмәт. Бигрәк тә теге вакытны Әбузәр оештырган кара ниятле собраниене җимерүең беркайчан да онытылмас.
Шәйхи. Әйе, кызыклы собрание иде ул. Шуннан соң Әбузәргә аю мае сөрткәндәй булды. Эшкә димләп йөрүне теленә дә алмый башлады.

Ишек шакыйлар.

Син бар теге якка. Хәвеф-хәтәр булса, тамак кырырмын. Тәрәзә аша бакчага төшәрсең.

Фуатны бүлмәгә кертеп җибәрә. Тышка чыгып китә. Кызмача-исерек
Әбузәр белән керә.

Энем, Әбузәр, нишләп болай вакытсыз?
Әбузәр. Станциягә төшкән идем, ике кешенең артымнан күзәтеп йөргәнен сиздем, аптырагач буфетка да кереп утырып карадым, югалгандай булганнар иде, кайтырга чыксам, тагын артымнан килә башладылар.
Шәйхи. Шүрләдем, диген, хи-хи-хи...
Әбузәр. Шүрләрсең. Хәзер бит кеше үтерүне бернигә дә күрмиләр.
Шәйхи. Анысы дөрес, кешеләр бозылды... Һәр көнне талаулар, чишендерүләр булып тора. Әле бүген станциядә ике жандармны үтереп...
Әбузәр. Ишеттем лә!.. Кайтасы җир ерак, вакыт та бик соң, мин сездә генә кунып китим инде.
Шәйхи. Юк, энем Әбузәр, кеше кертергә кушмыйлар бит, приказ белән тыялар.
Әбузәр. Мин бит килмешәк түгел, шушы җирнең кешесе. Аннан минем шәһәр комендантыннан бирелгән «Теләсә кайда, теләсә нинди сәгатьтә йөри ала» дигән документым бар.
Шәйхи. Бардыр, юк димим. Ләкин безнең квартальный бик усал кеше. Сине кундырып үз башыма бәла алыр хәлем юк.
Әбузәр. Алай... Нишләргә инде?.. Син бервакытны өеңне сатарга йөргән идең, кире уйладың, ахры.
Шәйхи. Алучы булса, хәзер дә сатар идем, юк бит ул.
Әбузәр. Комиссионный хакына килешә алсак, мин сиңа алучы табам. Теге ягын карыйм әле, ничә тәрәзәсе бар икән.
Шәйхи (*аркылы төшеп*). Син, энем, анда кермә инде. Сахибәттәң чишенеп яткан, каты авырый ул.
Әбузәр. Бүген генә урамда күрдем, бернәрсәсе юк иде.
Шәйхи. Аның бит баш өянәге бар. Кисәктән генә егыла да авырый башлый. Нишләрбез икән, энем, мин ятарга җыена идем.
Әбузәр. Өлгерерсең әле, төн озын.
Шәйхи. Син алай дисең дә бит, таңнан аяк киемнәре белән базарга чыгасым бар. Син, энем, кит инде, мин ишекне бикләп ятыйм.
Әбузәр. Юк, мин беркая да китмим. Менә шунда ятам да йоклыйм. (*Киемнәрен салып урын хәзерли.*)

Шәйхи. Кара әле, энем Әбузәр... Мин квартальныйны... (*Китә башлый.*)

Әбузәр. Ярый инде, ярый, каныма тоз салма. Китәм, дидем бит. (*Китә.*)

Шәйхи озатып керә. Бүлмәдән Фуат чыга.

Фуат. Киттеме?

Шәйхи. Әйе, көчкә озаттым. Эт шикелле бәйләнде бит, әллә сизенде микән?

Фуат. Юктыр. Андыйларны һәр көнне чүпләп торалар. Чыннан да куркуыннан кергәндер. (*Тәрәзә чиертәләр.*) Тагын кем бар икән?

Шәйхи. Бусы үз кеше. (*Чыгып китә.*)

Калын итеп киенгән Мартынов белән Остап керә.

Фуат. Максим Савельевич! Сез ничек монда?

Мартынов. Хәлеңне белергә килдем. Йә, үзеңне ничек хис итәсең?

Фуат. Болай яхшы. Минем турыда аталарча кайгыртучанлык күрсәтеп, дошман тырнагыннан тартып алуыгызга бик зур рәхмәт. Мин бит дөньяда яшәү өметемне өзгән идем. Сез миңа яңадан тормыш бирдегез. Бүгеннән башланган икенче гомеремнең киләчәге сезнең ихтыярыгызда булачак. Тик Лида кызганыч... Минем өчен япь-яшь кыз баланың гомере чикләнде. Беренче булып охранага ул бит ташланды. Ләкин качып өлгерә алмады. Жандарм пулясыннан яраланды...

Мартынов. Әйе, батыр йөрәкле кыз иде. Ләкин мин аның үзенә катнашырга кушмаган идем, бары тик аның аша тиешле иптәшләргә хәбәр итәргә генә теләгән идем, ә ул түзмәгән, иң җаваплы, авыр эшкә үзе алынган... Без бүген немецларның көньяк командованиесенең оператив сугыш планын кулга төшердек. Менә шул планны үзебезнекеләргә илтеп җиткерүне Батько сиңа тапшырды.

Фуат. Мин, әлбәттә, аны үтәрмен, тик план, чертежларны табу заданиесе минем өстә кала бит.

Мартынов. Бу задание аннан да әһәмиятлерәк, икенчедән, сине монда артык тотарга да ярамый. Чөнки Нажия белән Әсфанны да кулга алдылар.

Фуат. Кайчан?

Мартынов. Моннан берничә сәгать элек.

Күке тавышы.

Остап. Бу безгә, китәргә вакыт.

Мартынов. Син хәзер фронт ягына китә торган поездда кочегар булып юлга чыгасың. Ул киемнәрне сал, менә боларны киярсең.

Фуат чишенеп киенә.

Валуйкага җиткәч, Роман Дорофеевич дигән кешене эзләп табарсың. Ул сине фронт аша озатыр. Менә документларың.

Фуат. Максим Савельевич, әгәр дә сезгә әткәй белән хәбәрләшергә мөмкин булса, сәламемне аңар ирештерегез, ул мине кичерсен. Тапшырган әманәтемне намус белән саклау түземлеге алдында баш иям.

Мартынов. Үзебезнекеләргә барып җитү белән немецларга күмер бирмәү эшенең уңышлы үтәлеп баруын, яшерен организациянең көннән-көн үсүен, радиостанция, типография, корал базасының оештырылуын телдән сөйләрсең. Менә бу сандык ике катлы. Астында немец командованиесенең планы булыр. (*Ачып күрсәтә.*)

Остап. Фонареңны кулыңа тот. Кара, син чын-чыннан кочегарга әйләндең, точно.

Фуат. Болай ярыйсы бугай, тик бит-кул гына аграк түгелме?

Остап. Аларны юлда буярбыз.

Китәләр, Шәйхи озатып керә. Бүлмәдән Сахибә чыга.

Сахибә. Әйдәгез, самавырым кайнады. Бәлеш, кунак кайда?

Шәйхи. Китте.

Сахибә. Нишләп китте? Ул бит кунарга кердем дигән иде.

Шәйхи. Шулай дигән иде дә, ни өчендер китәргә булды.

Сахибә. Җибәрмәскә иде. Аның өчен сөткә тәбә куырдым. Самавыр кайнаттым.

Шәйхи. Әй, карчык, карчык, дөнья хикмәтләрен аңлауда син артта шул. Беләсеңме кем ул? Бая вокзалда жандармнар кулыннан коткарылган кеше турында сөйләгән идең бит? Шул кеше Фуат булган. Хәзер аңарда ашау кайгысы түгел.

Сахибә. Кунакка кайттым дигән була, белмәгәнгә салышып, мондагы хәлләрне сораша. Үзе әнә нинди хәлдә икән. Мескеннәр, бөтен семьялары белән җәфа чигәләр. Кем белә, бәлки, безнең Хөснулла да шулай йөри торгандыр... Яңадан тотылмаса ярар иде.

Шәйхи. Тотылмас, утны-суны кичкән егет ул. Аның монда киемнәре калды. Иртәгә әбисенә илтеп бирерсең, тик кара аны, күзеңне ачып йөр, аларда солдатлар тора.

Сахибә (*иснәп*). Ятарга кирәк.
Шәйхи. Син бар, мин утырам әле.

Сахибә китә, Шәйхи эшләргә утыра. Тәрәзә чиертәләр, чыгып китә.
Остап белән керәләр.

Йә, ничек?
Остап. Илтеп тапшырдым, озакламый китәргә тиешләр. Ләкин облава булмаса ярар иде, команда белән жандармнар килделәр.
Шәйхи. Юкка ашыккансыз, бер-ике көн бездә дә торырга була иде.
Остап. Ничего, аларның бүген күзләре тонган чак. Безнекеләр бит бәргәннәр.
Шәйхи. Ничек?
Остап. Һөҗүмгә күчкәннәр. Немецлар бөтен фронт буйлап качалар, точно.
Шәйхи. Авызыңа бал да май, каян ишеттең?
Остап. Менә мә, укырсың, соңыннан башкаларга бирерсең.
Шәйхи. Тимофеевич, утыр әле... Кайнаган самавыр бар. Чәй эчеп җибәрик.
Остап. Вакытым юк, мин хәзер китәм. Исән-сау котылуларын белдереп, безнең турыдан узганда сызгыртып китәргә булганнар иде. Мин шуны гына көтәм. (*Шәйхи картның төзәткән аяк киемнәренә күзе төшеп.*) Кара, Шафееч, син бик әйбәт эшли башлагансың, точно.
Шәйхи. Башыңа төшсә, башмакчы буласың, диләр бит. Шуның шикелле, мин дә өйрәндем. Теләсәң, әйдә, сине дә компаниягә алам.
Остап. Юк, мин бу профессиямне немецлар китми ташламыйм.
Шәйхи. Файдалыракмы?
Остап. Эш анда түгел, Шафееч, мин хәзер носильщик, теләгән җиремә керә алам, теләгән кешемне күрә алам, теләгән чагымда шәһәрдә йөри алам, точно. Нигә болар китмиләр икән?
Шәйхи. Эшләре бетмәгәндер, тимерьюлчыларның хезмәте шундый бит. Китәргә дигәч тә, анысын алырга, монысын салырга, төрле җиргә кул куярга кирәк.
Остап. Шулай да озакладылар. Әллә барып килергәме икән?
Шәйхи. Әнә поезд килә!..
Сүзсез катып калалар. Көчле сызгыртып үтеп киткән поезд тавышы ишетелә.

Остап. Шафееч, китте бит!
Шәйхи. Аллага шөкер, котылды...
Остап. Точно!

Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Элекке Галимҗановлар квартирасы. Солдат казармасына әйләндерелгән, тәрәзәләре ватылган, мебельләре җимерелгән. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә беркем дә юк,
бераздан Хәзинә белән врач чыга.

Хәзинә. Шулай ук ул бала терелмәс микәнни?
Врач. Хәзергә әйтүе кыен, аның өчен стационар дәвалау кирәк. Менә шушы рецепт белән дару эчереп торыгыз. Ләкин ялгыз калдырудан сакланыгыз.
Хәзинә. Минем бит беркемем дә юк. Атасы төрмәдә, абыйсы...
Врач. Әйе, әйе, бик яхшы беләм. Фуат Гыйниятович минем танышым иде. Мине монда иптәш Мартынов җибәрде... Зинһар өчен, немецларга белдерә күрмәгез, алар мондый авыруны, бигрәк тә безнең кешеләрне тотмыйлар. Карета таба алсак, бүген килеп алырбыз. Хәзергә хушыгыз.

Хәзинә озата чыга. Заһидә белән керә.

Хәзинә. Доктор әйтә, «карета таба алсак, килеп алырбыз» ди.
Заһидә. Дөрес булыр микәнни?
Хәзинә. Шулай инде, кодагый, баланы харап иттеләр. Аны бит ундүрт ай буена ничек кенә газаплаганнар? Мондагы иптәшләрен әйттерергә теләгәннәр.
Заһидә. Солдатларың кайда?
Хәзинә. Бая мин югында киткәннәр. Урын-җирләрен дә алганнар. Бөтенләйгә олагырга йөриләр, ахры. Безнекеләр Сталинградта немецларны бик каты тукмаганнар, ди.
Заһидә. Шулайдыр, урам аша чыгарлык түгел. Шәһәргә машиналар тулган.
Хәзинә. Үз хәлең ничек?

Заһидә. Бүген тагын йоклый алмадым. Тәрәзә төбенә таяндым да Әсфанны аскан базар мәйданына карап төн уздырдым. Һаман шунда асылынып тора шикелле. Хәзер инде елый да алмыйм. Кайчагында сөйли торган сүземне онытам. Нәҗия кебек, мин дә акылдан язмасам ярар иде.

Хәзинә. Юкны сөйләмә, кодагый, авыр булса да түз, онытырга тырыш.

Заһидә. Әй, кодагый, ничек аны онытырга? Үз үлеме белән үлгән булса, «үлмәктән калмак юк» дияр идең дә, әкренләп онытыр идең. Бигрәк үкенечле үлем булды бит.

Хәзинә. Җизнәсе нишли?

Заһидә. Нишләсен? Эчә дә, чалган үгез кебек гырылдап йоклый. Бернәрсә сорасаң, акыра, бакыра. Картайгач, юк гадәткә өйрәнде. Кулы белән уйный башлады.

Хәзинә. Ялгыз агач өй булмас, ялгыз егет би булмас, дигән бабайлар. Бик дөрес.

Заһидә. Асия турында хәбәр бар.

Хәзинә. Нишләп тора икән?

Заһидә. Дриздинин дигән шәһәрдә асылынып үлгән.

Хәзинә. Бик әйбәт булган, бер себерке кимегән.

Җырлап, бүлмәдән Нәҗия чыга.

Нәҗия. Ак күгәрчен, күк күгәрчен
Гел уйнарга ярата;
Күктә гизеп, күктә йөзеп,
Бар шатлыгын тарата.

Тәрәзәгә йөгереп бара.

Нәҗия. Әсфан!.. Бу синме?.. Әйдә, әйдә, өйгә кер. Нигә миңа эндәшмисең? Үпкәң зур шул миңа... Синең үлемеңә мин генә сәбәпче булдым... Ах, Розенбах!.. Килмә, килмә каршыма, син җиттең бит минем башыма. Коткарыгыз, коткарыгыз, ярдәм итегез. Ул мине алырга килә.

Хәзинә. Чү, кызым, сабыр ит.

Нәҗия. Дәү әни, ул кабахәт немец мине үз янына чакыра.

Хәзинә. Син бармадыңмы?

Нәҗия. Куып җибәрдем.

Хәзинә. Бик яхшы иткәнсең, кызым.

Нәҗия. Дәү әни, яңадан килер микән?

Хәзинә. Юк, кызым, килмәс инде.

Нәҗия. Килсен иде, мин бит аны сагындым.

Хәзинә. Кемне әйтәсең, кызым?

Нәҗия. Әсфанны.

Хәзинә. Ә... килер, кызым, килер. Эше бетмәгәндер.

Нәҗия. Дәү әни, Казанга кайчан барасың?

Хәзинә. Тиздән, кызым, тиздән. Үзебезнекеләр килгәч тә барам.

Нәҗия. Күрәсең бик киләме?

Хәзинә. Килми ни. Минем анда ике кызым, бер улым бар.

Нәҗия. Барганда мине дә үзең белән алырсың, яме? Мин анда концерт бирермен. Беренче итеп «Кульяулыгым» көен җырлармын.

Кульяулыгым минем, ай, бар иде,
Бизәкләре зәңгәр, ал иде;
Аллы-зәңгәр чәчәк бәйләменә
Алыштырмас гүзәл пар иде.
Җырларымның иң моңлысын җырлап,
Син дустыма чиктем яулыкны,
Чын мәхәббәт, татлы хисләремне
Калдырамын, бәгърем, сагынып.

Үксеп еларга керешә.

Хәзинә. Елама, кызым, елама, әйдә бүлмәгә. (*Җитәкләп китә башлый.*)

Заһидә. Кодагый, Гыйниятулла кода кайта түгелме?

Хәзинә. Кая?

Заһидә. Әнә капкадан кереп килә.

Хәзинә. Әйе, ул бугай. Мәле, кодагый, Нәҗияне бүлмәгә озат. (*Хәзинә тышка чыгып китә.*)

Заһидә белән Нәҗия бүлмәгә уза. Гыйният белән Хәзинә керә.

Хәзинә. Әйдә, бәбкәем, әйдә, Гыйниятуллам.

Гыйният. Тукта, әнкәй, башым әйләнә...

Хәзинә. Менә, балам, шунда утыр.

Гыйният. Әнкәй, Наҗия кайттымы?..

Хәзинә. Кайтты, улым, кайтты.

Гыйният. Кая соң ул, күренми?..

Хәзинә. Күршеләргә кергән иде. (*Заһидә бүлмәдән чыга*.)

Гыйният. Бу кем, кодагый түгелме?

Заһидә. Әйе, кода, мин. Исән кайттыңмы?

Гыйният. Менә, күргәнегезчә. Үзегез нишләп торасыз?

Заһидә. Сорама, кода, безнең Әсфанны астылар...

Гыйният. Ишеттем, авыр кайгыгызны уртаклашам. Елама, кодагый. Батырларча үлгән ул, рәхмәт аңар. Әнкәй, син нигә сөйләмисең. Минем кайтуым сиңа шатлык түгелме?

Хәзинә. Шатлык, улым, шатлык, ләкин минем башым эшләми. Өнемме соң бу, әллә төшемме?

Гыйният. Өн, әнкәй, өн. Гыйниятуллаң янында! Син мине көтмәгән идең инде.

Хәзинә. Шулай иде шул, анда кергән кешеләрнең берсе дә кайтмый иде, сине ничек чыгардылар соң?

Гыйният. Монда җыясы ризыгым булгандыр.

Наҗиянең елаганы ишетелә.

Кем бар анда, нигә елый ул?

Хәзинә. Әй, улым, безнең өйдә тагын фаҗига!.. Наҗия акылдан язды.

Гыйният. Кызым, Наҗия!.. (*Бүлмәгә кереп китә*.)

Заһидә. Әйтмәскә иде, кодагый.

Хәзинә. Ничек яшерим? Ул бит барыбер күрер иде. Ичмасам, больницага урнаштыра алмадык. Күзе белән күрмәсә, ул кадәр булмас иде.

Заһидә. Ярый, кодагый, мин кайтыйм инде.

Хәзинә. Утыр әле.

Заһидә. Башым авырта башлады. (*Китә*.)

Бүлмәдән Гыйният чыга. Ишек яңагына сөялә.

Гыйният. Әнкәй, ул мине танымый, бала атасын танымый...

Хәзинә. Әйе, улым, ул хәзер бернәрсә дә аңламый.

Остап керә.

Гыйният. Һу!.. Остап Тимофеевич, әйдә, түрдән уз.

Остап. Узмыйм. Мин синнән бернәрсә турында гына сорарга килдем. Немец этләренә эшләргә сүз биргәнсең, диләр, шул сүз дөресме?

Гыйният. Әйе, Остап Тимофеевич, дөрес.

Остап. Син, Галимҗанов, эшләргә булдың?

Гыйният. Үзем генә түгел, сезнең кебек карт шахтерлар белән бергәләп эшләргә булдым.

Остап. Аз гына намусы булган кеше немецка эшләмәс. Их, Гыйният, без синнән моны көтмәгән идек. Кырык ел бәйрәм ашларыбызга йөрештек. Кырык ел шатлык, кайгыларыбызны бергә бүлештек.

Гыйният. Остап Тимофеевич...

Остап. Аңламыйм мин сине, Гыйният, аңламыйм!..

Пәрдә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шахта эче — рудничный двор. Төрле якка китә торган вагонетка юллары. Арткы планның бер ягында водопровод будкасы, икенче якта электротрансформатор, уртада клеть. Бер читтә телефон будкасы. Ара-тирә әйбер күтәреп узалар. Еракта тимер-томыр тавышы, вагонеткалар авазы ишетелә. Пәрдә ачылганда,

Лазареску белән Петроччио сакта тора.

Петроччио. Күңелсез, дустым Лазареску, күңелсез. Әгәр дә монда төнгә калырга туры килсә, акылдан шашарсың.

Лазареску. Без инде Россия белән чиктәш халык, русларны җиңгәннән соң, безгә өлеш тиячәк. Менә мин сезне аңламыйм. Өч-дүрт дәүләт аша монда килеп, нигә сугышып йөри торгансыздыр.

Петроччио. Без, билгеле, бөек империя өчен сугышабыз. Муссолини белән Гитлер бөтен илләрне үзләренә буйсындырачаклар. Димәк, без, итальян сугышчылары да, табыштан, бәлки, мәхрүм булмабыз. Ә сез менә ни өчен сугышасыз? Сезгә бит барыбер бернинди өлеш тимәячәк.

Лазареску. Ә син үзең, Петроччио, рус җиренә килеп искиткеч баедыңмы? Ефрейтордан бүген ничә тапкыр йодрык алдың?

Петроччио (*кулын селтәп*). Безнең кебек гади солдатларга шул инде ул. Туйдырды! Дөресен әйткәндә, Лазареску, бу җирдән башыңны тереләй алып китә алсаң, шуны зур бәхетең дип санарга кирәк. Белмим, ни белән бетәр бу сугыш. Хәтта бирердә, тылда да, һәр минутта җаныңны алганнарын көтеп кенә тор.

Ганс керә.

Ганс. Нәрсә бирердә такылдашасыз? Барыгыз урыннарыгызга!

Лазареску белән Петроччио китәләр. Гыйният керә. Телефонга бара.

Гыйният. Диффузорны бирегез. Остап Тимофеевичмы? Галимҗанов сөйли. Минем янга төшегез. Әйе, хәзер үк. (*Трубканы куя.*)

Ганс китә. Остап керә.

Остап. Нәрсә бар?

Гыйният. Хәзер генә мине комендант чакырган иде, Германиядән хуҗа килгән, бүген миннән шахтаны кабул итү тантанасы була, ди. Сиңа ничек кенә булса да «кочегар»ны күрергә, безгә нишләргә икәнен белергә кирәк. Моннан да уңайлы чакның булуы мөмкин түгел, чөнки шәһәрдәге бөтен начальство монда булачак.

Остап. Ярый, мин киттем. (*Китә.*)

Хәзинә керә.

Хәзинә. Менә ул кая икән.

Гыйният. Әнкәй, син нишләп килергә булдың?

Хәзинә. Бер атнадан бирле кайтканың юк, сагындым, ашарга китердем. Әйдә, улым, җылы көйгә ашап ал.

Гыйният. Син, әнкәй, юкка минем өчен мәшәкатьләнеп йөрисең. Мине монда бик яхшы сыйлыйлар.

Хәзинә. Дөресен әйткәндә, улым, мин сиңа икенче эш белән килдем. Кичә безнең шәһәрдә бик зур вакыйга булды.

Ганс керә.

Нихәл син, сыбызгы.

Ганс. А, матка, сәлам!

Хәзинә. Син нишләп монда?

Ганс. Күрәсез, шахта саклыйбыз.

Хәзинә. Әллә кичәге пух-пухтан куркып төштегезме дигән идем.

Ганс. Безнеке пух-пухтан курыкмаган. (*Узып китә.*)

Гыйният. Шуннан, әнкәй?

Хәзинә. Нәрсә турында сөйли идем әле, улым?

Гыйният. Шәһәрдә булган ниндидер бер вакыйга турында.

Хәзинә. Әйе, төнге сәгать икеләрдә үзебезнекеләр килделәр. Берничә сәгать буена вокзал тирәсендә дөп тә дөп, дөп тә дөп итеп торды. Шулкадәр шатландык инде.

Гыйният. Әйе, яхшы шатлык... Ярый әле яныгызга төшмәгән.

Хәзинә. Яңадан килмәсләрме дип яктырганчы сакладык, ләкин килмәделәр. Вокзалның бернәрсәсе калмаган, диләр. Бүген анда таба беркемне дә җибәрмиләр. Аннан бүген Шәйхи карт килгән иде. Ул әйтә: «Тиздән үзебезнекеләр килер, улы Фуат кайтыр, Гыйниятка әйт: эшләмәсен шуларга»,— ди. Чынлап та, улым, әле соң түгел, ташла син бу эшеңне.

Гыйният. Сез мине аңламыйсыз, әнкәй...

Хәзинә. Аңлыйбыз, бик яхшы аңлыйбыз. Төрмәдә сиңа авыр булгандыр, шуңар күрә вәгъдә биргәнсең. Хәзер берәр хәйлә тап, авыруга сабыш. Кара инде кыяфәтеңә, кырынмаган, атна буена юынмаган. Кабердән чыккан әрвахка охшыйсың.

Гыйният. Алган эшемне ахырына кадәр җиткерим. Аннан кырынырмын да, юынырмын да.

Хәзинә. Белмим, улым, белмим. Бу эшеңнең ахыры ни белән бетәр.

Остап керә.

Гыйният. Йә, ничек?

Остап. Күрдем. Башларга куша. «Ләкин үзен саклап калу өчен кирәк булган чаралар күрелгәнме?» ди.

Гыйният. Әйе, күрелгән. Газ дулкыны үтеп киткәнче чандагы суга чумам. Аннан иске шахта авызына киләм. Калганы сезнең иректә.

Остап. Ул турыда кайгырма. Бөтен нәрсә җайлап куелган.

Әбузәр керә.

Гыйният. Син бар урыныңа, бер генә минутка да телефоннан китмисең. Мин сиңа «зыбак», ягъни кабыз дип сигнал бирермен. (*Әбузәрне күреп, сүзне икенчегә бора.*) Вентиляциягез эшләми, газны начар куасыз.

Остап. Бездән эш сорарга беләсез, ләкин техника куркынычсызлыгын тәэмин итмисез! Әйдә әле, мин сиңа күрсәтим.

Гыйният. Күрмичә дә бик яхшы беләм.

Остап. Юк, штейгер әфәнде, син башта барып кара. Аннан мине ачуланырсың.

Китәләр.

Әбузәр. Нәрсә турында болар сөйлиләр? «Зыбак» — бу ни дигән сүз икән? Немецча да андый сүзне хәтерләмим, русча да ишеткәнем юк. Татарча да?! «Зыбак», «Тозак», «Йозак»... Һичбер нәрсә төшенмим. Шулай да Остап Бондаренко белән серләшеп йөрүе нәрсәгәдер бәйләнгән, әйе, әйе, бу юкка түгел. (*Чан артына яшеренә.*)

Гыйният керә.

Гыйният. Ярый, эш бетте бугай, калды фәкать нәтиҗә...

Һольцман, Розенбах, Һерман, Ганс һәм башкалар керә.

Розенбах. Таныш булыгыз, безнең намуслы штейгерыбыз Гыйният әфәнде Галимҗанов.

Һольцман. А...

Гыйният. Мин сезне хәтерлим. Безнең әүвәлге хуҗабыз Һольцман әфәнде.

Һольцман. Аһа, ул мине онытмаган.

Гыйният. Сезне онытырга ярыймы соң?..

Розенбах. Әфәнделәр! Сезнең алдыгызда Гыйният әфәнде Галимҗанов. Башта ул да руслар шикелле үк безгә каршылык күрсәтте, ләкин кешеләрне дөрес тәрбия итү методыбыз аңар үз хатасын танырга мәҗбүр итте. Ул хәзер безнең кеше. Гыйният әфәнде! Бөек Германия исеменнән рәхмәт әйтеп кулыгызны кысарга рөхсәт итегез.

Һольцман. Гыйният әфәнде, бәлки, сез дә бер-ике сүз әйтерсез.

Гыйният. Мин сүз сөйли белмим. Германия дәүләтенә ни дәрәҗәдә бирелгәнемне эшем белән күрсәтергә тырышырмын.

Розенбах. Алай булса, әйдәгез, безне антрацит участогы белән таныштырырсыз.

Гыйният. Сез бара торыгыз, мин диффузорга хәбәр итим. Бүген газны начар куалар.

Немецлар продолга кереп китәләр. Гыйният телефонга бара. Чан артыннан Әбузәр чыга.

Әбузәр. Син кая?

Гыйният. Диффузорга хәбәр итим, шахтада газ күбәйде.

Әбузәр. Син бар хуҗалар янына, мин үзем әйтермен.

Гыйният. Ә син нигә монда, нигә эшеңдә түгел?

Әбузәр. Синең нишләргә теләвеңне беләсем килә. (*Гыйният кисәктән әйбер белән суга, Әбузәр егыла. Трубканы алып кычкыра.*)

Гыйният. Диффузор!.. Остап Тимофеевич, «Зыбак, зыбак, зыбак»!!!

Гыйният чанга чумарга бара, Әбузәр, торып, аңа ябыша. Ике арада көрәш китә.

Әбузәр. Әй, халык, хыянәт, сакланыгыз, газ килә!..

Ерактан шаулап газ килгәне ишетелә. Шашкан кыяфәттә немецлар йөгереп чыга.

Гыйният. Качмагыз, барыбер котыла алмассыз!..

Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук шахта төзелеше. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә дөм караңгы, еракта оркестр белән уйналган матәм маршы ишетелә. Бераздан Шәйхи белән Остапның кармаланып килгәне күренә. Шәйхи кулында шахтерлар лампасы, Остап кулында телефон аппараты.

Остап. Шафееч, син кайда?
Шәйхи. Биредә! Әйдә тизрәк.
Остап. Күрмим, бернәрсә дә күрмим, точно.
Шәйхи. Әллә синдә тавык күзе инде.
Остап. Булыр да. Ике ел немец шулпасы эчтек бит. Тавык күзен ит ашамаудан була, диләр. Көч тә, гайрәт тә бар икән үзебездә. Немецның мактаулы техникасын лепёшкага әйләндерделәр, точно.
Шәйхи. Без ниндидер бушлыкка килеп чыктык.
Остап. Бу рудничный двор булырга кирәк, точно.
Шәйхи. Әйе, менә электр будкасы.
Остап. Менә кран, точно. Ул чан тирәсендәрәк булырга тиеш.
Шәйхи. Тукта. Аяк астында нидер бар. Әйе, менә алар.
Остап. Бусы кем?
Шәйхи. Әбузәр хаин.
Остап. Димәк, Гыйнияткә чанга чумарга ул ирек бирмәгән.
Шәйхи. Өскә хәбәр ит, төшсеннәр.
Остап. Алло, алло, рудничный двор. Мәетне таптык. Прожекторлар белән төшегез.
Шәйхи. Их, Гыйният, Гыйният! Бу көннәрне күрү сиңа насыйп булмады.
Остап. Бездә аның эше калды, даны калды, Шафееч!

Прожекторлар белән керәләр, сәхнә яктыра, халык җыела.

Шәйхи. Юл бирегез, майор килә!
Халык ике якка аерыла. Фуат белән Мартынов һәм гаскәрләр керә.

Остап. Фуат Гыйниятович, менә ул!
Фуат. Максим Савельевич, бу фаҗига нишләп болай булды соң? Ул үлемгә үзе теләп бардымы?
Мартынов. Төрмәдән чыкканда, чынлап та, ул шундый теләктә иде. Немецлар белән бергә үзен дә һәлак итү уенда иде. Мин аңар андый адымны атларга ярамаганны, дошманнан үчне алып та, исән калырга мөмкинлеген өйрәттем. Ул минем тәкъдимгә күнде. Ярдәмгә Остап Тимофеевичны бирдек. Алар икәүләп эшкә керештеләр. Без аның исән калуы өчен бөтен чараларны булдырган идек. Күрәсең, планыбызны Әбузәр хаин сизеп алган да аңар чанга чумарга ирек бирмәгән. Шулай итеп, меңгә якын фашист һәм хаиннар белән үзе дә һәлак булган.
Фуат. Их, әткәй, әткәй! Күпме газап, авырлыклар күрдең син...
Остап. Юл бирегез, анасы килә!..

Үзен мәгърур рәвештә тотып, вәкарь белән атлап, Хәзинә керә. Гыйният янына тезләнә.

Хәзинә. И улым, улым...
Андый яшерен-изге уең булгач,
Ник соң аны миңа әйтмәдең?..
Бирер идем сүзсез фатихамны,
Ачкан булсаң миңа теләгең...
Улым Фуат!
Мә, ал әманәтең,
Изге санап аны саклadык
(*план, чертежларны тапшыра*),
Илгә булган тирән мәхәббәтне
Зур корбаннар биреп аклaдык.
Сорыйм синнән шулар хөрмәтенә,
Минем алда хәзер тез чүгеп,
Сүзеңне бир, бәбкәм, үч алырга...
Фуат. Һәлак булган атам һәм анамның
Үлемнәре белән ант итәм:
Туган илем, бөек халкым өчен
Үч алырга тагын мин китәм.

Гыйниятнең гәүдәсен носилкага салып күтәреп китәләр. Музыка көчәйгәннән-көчәя бара.

Пәрдә.

# ЧЫН МӘХӘББӘТ

*Драма ун күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Гөләндәм.
Дәүран — аның ире, инженер.
Һарун — яшь инженер.
Самойлов — очучы.
Коновалов — цех начальнигы, соңыннан завод директоры.
Клавдия — аның хатыны, врач.
Акулина — Коноваловның анасы.
Гөлҗиһан — Гөләндәмнең апасы.
Хәсәнша — пенсионер карт.
Мидхәт — ОРС начальнигы.
Бәрбәрия — сәүдә хезмәткәре.
Поподияс — медицина докторы.
Хәмидә — албан кызы, фельдшерица.
Любица — каратаулы кызы, фельдшерица.
Карт — колхозчы.
Ирина — директорның секретаре.
I солдат
II солдат

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Матур итеп җиһазландырылган зур бүлмә. Бер читтә язу өстәле, аның өстендә телефон. Янәшә бүлмәләргә китә торган берничә ишек. Урамда, тынлы оркестрда марш уйнап, гаскәрләрнең үтеп киткәне ишетелә. Оркестр әкренләп ерагая. Сәхнәдә Гөлҗиһан үзе генә. Ул гаскәрләрнең узып киткәнен тәрәзәдән
карап кала да, бүлмә ишеген ачып, кемгәдер эндәшә.

Гөлҗиһан. Гөләндәм, тор инде, нәнәчем, тор!

Бүлмәдән арыган кыяфәттә Гөләндәм чыга.

Гөлҗиһан. Кайтканыңны ишетми калдым. Эш күп булган, ахры.

Гөләндәм. Төн буе яралыларны ташыдык. Кыямәт анда. Иртәнге биштә генә җибәрделәр.

Гөлҗиһан. Синең эшеңмени ул, нәнәчем. Син бит врач та, медсестра да түгел. Нишләп әле ул госпиталь дигәннәренә барып эләктең?

Гөләндәм. Хәзерге вакытта врачлар да, медсестралар да җитешми. «Эшләми утырасың» диделәр дә, чакырдылар. Бармый буламы?..

Гөлҗиһан. Ник булмасын? Минем яшь балам бар, дияргә иде. Өйдә утырып булмый дисәң, юньлерәк эш табарга була бит.

Гөләндәм. Нинди эш? Яшь балам бар дип, очучылар мәктәбенең ахыргы курсыннан киткән идем. Шунда кайту турында гына уйланам.

Гөлҗиһан. Авызыңнан җил алсын! Очучы булу турында уйлыйсы да юк. Сугыш булганчы, күкрәккә сугып, «мин — очучы» дип борын күтәреп йөрергә була иде. Хәзер бөтенләй башка хәл. Һәркем үзе турында кайгырта торган вакыт.

Гөләндәм. Юкка син алай...

Гөлҗиһан. «Юкка» булмый ни... Әнә домуправ урыны бушаган, ди. Әхмәтне армиягә алганнар. Аның урынына кеше эзләтәләр икән.

Гөләндәм. Минем эш түгел ул, туганым апа.

Гөлҗиһан. Йә, бар, салкын су белән юынып ал. Башың ачылыр. Югыйсә иснисең дә иснисең. Йокың туймаган. Белгән булсам, уятмаган булыр идем.

Гөләндәм сөлге тотып китә. Гөлҗиһан урын җыештыра. Кулына кәгазь, карандаш тотып, Хәсәнша керә.

Хәсәнша. Күршеләр өйдәме?

Гөлҗиһан. Өйдә, өйдә, Хәсәнша абзый, өйдә. Нинди кәгазьләр тотып йөрисең?

Хәсәнша. Ремонт сезоны бит, фатирчыларның теләкләрен җыярга кушканнар иде.

Гөлҗиһан. Син кем соң?

Хәсәнша. Кичә райсоветта йорт мөдире итеп куйдылар.

Гөлҗиһан. Шулаймыни?

Хәсәнша. Шулайрак. Итәк-җиңнәрегезне җыеп йөрегез, коры тотармын!

Гөлҗиһан. Син бит заводта эшли идең.

Хәсәнша. Шулай идем дә, сугыш башланыр алдыннан гына пенсиягә чыккан идем бит.

Гөлҗиһан. Бик тынгысыз хезмәткә алынгансың икән.

Хәсәнша. Эшнең инде, Гөлҗиһан, аның кайсы да шулай. Кичә райсовет председателе чакырып алды да: «Управляющийларны урыннарында тота алмыйбыз, куйган берсен армиягә алып торалар. Ул яктан син өлкән яшьтәге кеше, үзең райсовет депутаты, алын инде»,— дип сорагач, каршы килмәдем. Эшсез тора алмыйм, шабаш! Нишлисең бит, өйдә күңелсез... Малайлар өчесе бер көнне сугышка киттеләр. Фронтта да эшләр бик шәптән түгел. Һәр көнне сәгать алтыдан торып радио тыңлыйм-тыңлыйм да, күңел юатырлык хәбәр булмагач, утынлыкка чыгып әйбер ясыйм. Карчыкның бөтен савыт-сабаларын, кухня коралларын механикалаштырып бетердем. Шулай да күңел тынычлана алмады. Менә нәрсә, Гөлҗиһан, алдан әйтеп куям: син, күрше, теге шапшак якларыңны ташла инде.

Гөлҗиһан. Нинди шапшак?

Хәсәнша. Бүген иртән помой чиләгеңне нәкъ ишегалды уртасына томырдың.

Гөлҗиһан. Кем әйтә?

Хәсәнша. Менә мин әйтәм. Тәрәзәдән карап тордым.

Гөлҗиһан. Помой түгел бит ул, кашыгаяк юган су гына.

Хәсәнша. Теләсә ни булсын, ишегалдына түгәргә ярамый.

Гөлҗиһан. Ярый инде, инәдән дөя ясама.

Хәсәнша. Ясамыйча ярамый. «Торак йортларында абсолют чисталыкны булдырырга» дип, Молотов районын ярышка чакырдык, үзебез шуңа каршы барабыз. Ремонт турында бернинди дә теләгегез юк дисең алайса.

Гөлҗиһан. Бар, бар, ник булмасын? Утын чоланыбызның түбәсеннән су ага, тәрәзәләрнең замазкасы коелган. Кухня ишегенең бикләре начар. Аннан менә бу тәрәзәнең форточкасы...

Хәсәнша. Андый вак-төякләрне үзегез эшләгез, хөкүмәткә салынмагыз. Без бит зур ремонтлар турында материаллар җыябыз. Шулай да утын чоланыгызның түбәсен каратырмын. (*Китә.*)

Сөлге белән сөртенеп, Гөләндәм керә.

Гөлҗиһан. Мин базарга барам. Кая, акчаңны бир әле.

Гөләндәм (*акча бирә*). Нәрсәләр алырга җыенасың, туганым апа?

Гөлҗиһан. Нәрсә дип, шул: бер кадак май. Аннан җимеш тә яшелчә...

Гөләндәм. Ит алмыйсыңмыни? Дәүран итле токмач ашы ярата бит.

Гөлҗиһан. Шул Дәүран да Дәүран... Бетмәгән Дәүран булды инде.

Гөләндәм. Ир кешене ашсыз тотып булмый бит, туганым апа.

Гөлҗиһан. Заводта ашый ич. Аннан, нәнәчем, ир дип алай бик өзгәләнмә. Аларны никадәр иркәләсәң, шулкадәр назлана баралар. Аннан соң, беләсең килә икән, бәяләр үсканнән-үсә бара. Ул эвакуированный дигәннәре сатулашып та тормый, алам дигән әйбереңне биш бәя биреп кулыңнан тартып алалар... Әлегәчә шулай. Акчалары беткәч нишләр? Әмма ул халыкның чутлашып тормавы аркасында бәяләр югарыга сикерә. Ахыры ни булыр... Әйдә, Дәүраныңа итле аш дисең икән, акчаңны арттыр.

Гөләндәм акча бирә. Бәрбәрия килеп керә.

Бәрбәрия. Исәннәрмесез!

Гөлҗиһан. Сөбханалла, сине танырлык та түгел, Бәрбәрия. Шулкадәр киенгәнсең.

Бәрбәрия. Киенгән дип, әллә ни түгел инде, хи-хи-хи.

Гөләндәм. Апа, соңга каласың, базарыңа бар инде.

Гөлҗиһан китә.

Бәрбәрия, иреңнән хәбәр киләме?

Бәрбәрия. Юлдан гына бер хат язган иде, шуннан бирле юк. Беткәндер инде ул бичара. Анда каты сугышлар булган, ди... Гөләндәм, син миңа биш кенә мең сум акча биреп тор әле.

Гөләндәм. Биш мең?!

Бәрбәрия. Комиссионкага бик шәп пальто куйганнар, янымда акчам җитешми, өйгә кайтсам, бик ерак, әйләнеп килгәнче сатып куюлары бар.

Гөләндәм. Әле генә котик манто алдың түгелме?

Бәрбәрия. Алсам? Иш янына куш сыя ул. Ансының тегелешен яратмыйм.

Гөләндәм. Монсына күпме сорыйлар?

Бәрбәрия. Мөф инде мөф. Ундүрт кенә мең. Эстониядән килгән кешеләр куйганнар.

Гөләндәм. Син соң хәзер кайда хезмәт итәсең?

Бәрбәрия. Шул иске урынымда — кибеттә. Кая, биреп тор инде.

Гөләндәм. Минем андый акчам юк. Аннан, уйлап җиткерденме соң: хәзер андый киемнәр белән көйләнә торган вакыт түгел кебек...

Бәрбәрия. Ярый, хәерле булсын. Башка кешегә барырмын инде, хушыгыз. (*Китә.*)

Телефон шалтырый.

Гөләндәм (*трубканы алып*). Алло, әйе, Арслановлар квартирасы. Ул өйдә юк, заводта. Бу каян? Военкоматтан? Нәрсәгә? Мин аның хатыны, нигә соравыгызны беләсем килә. Яхшы. Кайтып кергәч үк әйтермен. Әшулай да, нишләп бу хәтле срочно?.. Менә сиңа, аңлатмый-нитми, сөйләшүне өзгән була. (*Телефон трубкасын куя.*) Ниндидер җитди мәсьәлә, күрәсең...

Дәүран кайтып керә.

Әле генә сиңа военкоматтан шалтыратканнар иде. Дәүран, син нишләп вакытсыз?

Дәүран. Шәһәргә чыккан идем.

Гөләндәм. Борчылгансыңмы дим?

Дәүран. Юк, Гөләндәм, борчылмадым. Болай гына ул.

Гөләндәм. Юк, болай гына түгел. Яшермә, әйт: ни булды сиңа? Военкоматтан да юкка гына түгелдер.

Дәүран. Беләсең бит, Москвадан күчеп килә торган гигант заводны каршыларга җыенабыз. Эшчеләренә торак йортлары табу, станокларына урын хәзерләү бар да миңа йөкләнгән. Менә хәзер дә шул турыда шәһәр советында үткәрелгән киңәшмәдән килешем.

Гөләндәм. Киңәшмәләр һәр көнне булып тора. Шулай да, ни булды? Син бүген бөтенләй башка.

Дәүран. Ә син... Тукта, алдыма бас әле. (*Әсәрләнеп карый.*) Син бүген миңа тагын да матуррак, сөйкемлерәк булып күренәсең...

Гөләндәм. Тукта әле. Сиңа ни булды? Синнән андый сүзләрне күптән инде ишеткәнем юк иде кебек... Йә, әйт. (*Дәүранга сыена.*) Әйтәсеңме?..

Дәүран (*җитди бер хәбәр әйтергә теләп*). Мин...

Гөләндәм. Нәрсә син?

Дәүран (*сүзне икенчегә борып*). Әйтергә онытып торам икән, кайтышлый фотографиягә кергән идем, беркөн төшкән фотобыз өлгергән.

Гөләндәм. Өлгергән? Кая, бир.

Дәүран. Хәзер күрсәтәм. (*Карточкалар чыгара.*) Кара, Гөләндәм, син нинди матур, нинди сөйкемле булып төшкәнсең.

Гөләндәм. Син дә бик матур чыккансың. Ләкин, Дәүран, ничек кенә булмасын, фото фото инде ул, кешенең бит эчке дөньясы, җан-рухы, мәхәббәт, нәфрәт тойгылары бар. Менә инде аларны берннди дә аппарат объективы ала алмый.

Дәүран. Анысы дөрес, Гөләндәм. Шулай да мин синең бу карточкаңа карармын да үземә җан азыгы, илһам алырмын.

Гөләндәм. Тукта әле, ни өчен минем фотокарточкама карарга? Мин үзем синең яныңда бит.

Дәүран. Юк, мин эштә — заводта кунып калган чакларымда, дим.

Гөләндәм. Юк, Дәүран, син нигәдер бүген серле сүзләр сөйлисең, тавышың, интонацияләрең дә үзгәргән. Сиңа ни булды?

Дәүран. Әйтәм бит, берни дә булганы юк. (*Телефон шалтырый, барып трубканы ала.*) Дәүран Арсланов. Военкоматтан? Әйе, мин беләмен. (*Сәгатенә карый.*) Ике сәгать вакытым бар. Әйберләремне җыям да тиешле сәгатьтә вокзалда булырмын. Хушыгыз.

Гөләндәм. Дәүран, син кая, командировкага китәсеңме?

Дәүран. Юк, Гөләндәм, фронтка...

Гөләндәм. Фронтка?..

Дәүран. Әйе, фронтка...

Гөләндәм. Үзең теләпме?

Дәүран. Үзем теләп гариза биргәндә җибәрмәгәннәр иде. Хәзер инженер буларак, спецзадание белән.

Гөләндәм. Ничек инде ул алай? Син бит завод өчен кирәкле кеше.

Дәүран. Фронтка алынучыларның берсе дә артык түгел, барысы да үз урыннарында кирәкле кешеләр.

Гөләндәм. Соң бит синең бронең бар.

Дәүран. Мине моңа кадәр биредә тотулары өчен дә син рәхмәт әйтергә тиеш. Чөнки мин партия члены, инженер булу белән бергә, запастагы командир да. Минем кебекләр сугышның беренче көнендә үк инде китеп беттеләр.

Гөләндәм. Юк, юк, бу мөмкин түгел! Ул чагында мин акылдан шашармын. Минем өчен бу дөньяда улыбыз Наил белән синнән дә кадерле кешем юк.

Дәүран. Их, Гөләндәм! Утыр әле. (*Гөләндәмне янәшә утырта.*) Кабарынкы сүзләр әйтергә теләмәс идем дә, нишлисең, заманыбыз куша. Үзең беләсең, Ватаныбыз куркыныч астында. Уйлап карасаң, дошманның Смоленскига килеп җитәчәге кайсыбызның башына килгән? Ә Смоленскины да калдырсак?.. Ләкин эшләр шуңа таба бара. Димәк, зур хаталар ясаганбыз. Ләкин алар турында сүз алып бару соң инде... Мәсьәлә шулай тора. Ватаныбыз куркыныч астында булганда, бар көчебезне бер йодрыкка тупларга тиешбез. Барлык халкыбыз иреклеге кыл өстендә торганда, мин, читтә посып калсам, чын ир булыр идемме, Гөләндәм?

Гөләндәм. Мин сине аңлыйм. Ләкин син миңа шунысын әйт: бу хәлдә мин нишләргә тиеш?

Дәүран. Син өйдә каласың, Гөләндәм, һәм мине көтәсең, акчаны аттестат белән ала торырсың. Ә мин җиңү белән кайтачакмын.

Гөләндәм (*уйга калып*). Әйе, мин калачакмын. Аш пешерү, күлмәк-ыштан юу, бала үстерү...

Дәүран. Һәр гаиләнең үз төбәге була. Элекке йолалар буенча әйткәндә, ыруның учагы... Сугыш күпме дәвам итәчәк — белгән юк. Кыска вакытта гына бетмәс ул. Әгәр дә син, Гөләндәм, улыбыз Наил белән мине көтеп алсагыз, бу үзе зур батырлык булыр иде...

Телефон шалтырый, Дәүран трубканы ала.

Дәүран. Бу кем, Сәҗидәме? Дәүран абыең. Мин үзем дә сезгә шалтыратырга тора идем әле. Әтиең эштәме, әниең дә өйдә юк? Әбиеңне чакыр әле. Нихәл, әнкәй, исәнме! Дәүраның сөйли. Менә нәрсә әнкәй: мин ашыгыч рәвештә армиягә китәм, янына бара алмавым өчен гафу ит. Килеп өлгерә алмассың. Син, булмаса, әнкәй, Сәҗидә белән вокзалга гына чык. Шунда сөйләшербез. Йә инде, әни, җылама... хуш хәзергә, хуш, әни... (*Трубканы куя да Гөләндәм янына килә.*) Их, Гөләндәм... Наилдән, синнән аерылып китүе миңа җиңел дип уйлыйсыңмы әллә? Сез бит минем бәхетем дә, рәхәтем дә һәм чын мәхәббәтем дә. Мин әнә шул бәхетебезгә кул сузучы явыз дошман белән көрәшкә китәм...

Гөләндәм. Сугыш — уен түгел. Анда кан коела, яшәү гомерләре киселә...

Дәүран. Ләкин син миңа ышан һәм вәгъдә бир... Кара инде җебеп тә төште... Йә, сөрт күзләреңне. (*Иркәли.*) Көт мине. Мин кайтачакмын!

Гөләндәм. Хәтереңне калдырган булсам, кичер мине, Дәүран, гафу ит.

Дәүран. Безнең арабызда кичермәслек берни дә булганы юк. Син ул сүзләрне мине өзелеп сөюдән, миннән аерылуның авырлыгыннан гына әйтәсең. Ярый, син миңа әйберләр әзерлә. Мин балалар бакчасына кереп Наил белән күрешеп чыгыйм.

Гөләндәм. Ярый, ләкин алар Черек Күл бакчасына китмәделәр микән? Күреп кайтырга тырыш.

Дәүран китә. Гөләндәм уйланып йөри. Комод ящигыннан күлмәк-ыштан, сөлге, кульяулыклар алып өстәлгә куя. Гөлҗиһан базардан кайтып керә.

Гөлҗиһан. Әй халык базарда, әй халык, умарта корты төсле гөжләп тора. Тукта, сиңа ни булды?

Гөләндәм. Апа, Дәүранның җылы оекбашлары бар иде, кайда икән?

Гөлҗиһан. Теге якта зур сандыкта. Нигә кирәк булды әле.

Гөләндәм. Ул бит китә.

Гөлҗиһан. Китә? Кая?

Гөләндәм. Фронтка.

Гөлҗиһан. Сугышка? Аны алмыйлар, дигән идең бит.

Гөләндәм. Шулай дигән идем дә, кирәк булгач алганнар. Син әйберләрен әзерләп бир инде.

Гөлҗиһан. Нәрсәләр салырга соң?

Гөләндәм. Менә бельелары, сабын белән теш порошогы сал. Күп кенә итеп ашарга куй.

Гөлҗиһан. Тагын?

Гөләндәм. Белмим, белмим, минем башым әйләнде инде. Үзең белеп карый күр.

Гөлҗиһан бельеларны алып китә. Әйберләр күтәреп, Мидхәт керә.

Мидхәт, әллә син дәме?

Мидхәт. Безгә кая инде ул бәхет. Дәүранны озатырга килдем. Үзе кайда соң?

Гөләндәм. Хәзер кайтыр. Балалар бакчасына Наил белән күрешергә киткән иде.

Мидхәт. Бүген үк китәргәме?

Гөләндәм. Хәтта хәзер үк вокзалга төшәргә, диләр.

Мидхәт. Ни өчен алай бик капыл икән?

Гөләндәм. Белмим, Мидхәт, белмим... Ансыз мин нишләрмен? Юк, башыма да китерә алмыйм.

Мидхәт. Әйе, җиңел түгелдер... Мин килгән саен сезнең татулык нигезенә корылган тормышыгызга сокланып китә идем. Дәүранны озату сиңа гына түгел, миңа да бик авыр, Гөләндәм. Чөнки ул минем иптәшем, иң якын дусларымның берсе иде. Нишлисең, сугыш, рәхимсез сугыш... Син борчылма, Гөләндәм. Дәүранның дуслары — без — сине ташламабыз. Үз арабызга алырбыз, кирәк булганда ярдәмебезне дә кызганмабыз. Кая, кадерле кешебезне озату уңае белән өстәл хәзерләргә кирәк иде бит.

Гөләндәм. Чыннан да, мин кибеткә чыгып керим әле.

Мидхәт. Мәшәкатьләнмә, якын дустым хөрмәтенә үзем китердем. Тик менә бу консервыларны...

Гөләндәм. Апа янына чыгып ачыгыз.

Әйберләрен күтәреп, Мидхәт китә. Гөләндәм өстәлгә зур ашъяулык җәя. Дәүран кайтып керә.

Күрдеңме?

Дәүран. Әйе, күрдем, комда уйныйлар иде, мине күрүгә: «Әти, әллә син дә сугышка китәсеңме? Бүген Валерийның да әтисе киткән»,— ди. Әйе, улым, китәм, дигән идем, муенымнан кысып кочты да: «Бар, әти, фашистларны кыйна»,— ди. Ә үзенең күзләреннән яшь ага.

Гөләндәм. Ул бит искиткеч акыллы бала. Минем хәзер бердәнбер юанычым шул инде. Син югында аңар карармын да синең юклыгыңны онытырга тырышырмын... Чөнки ул синең копияң. Төсе-бите, авыз-борыннары, хәтта бөтен кыланышларына кадәр сиңа охшаган.

Дәүран. Менә нәрсә, Гөләндәм, минем сиңа берничә сүзем бар. (*Утыралар.*) Наил хәзер зур инде, минемчә, сиңа эшкә керергә кирәк. Заводтагылар белән сөйләштем. Урнашырга ярдәм итәчәкләр.

Гөләндәм. Мин үзем дә бу турыда уйлана башладым инде.

Һарун керә.

Һарун. Исәнмесез, Гөләндәм.

Гөләндәм. Әйдә, Һарун. Сез сөйләшә торыгыз, мин хәзер. (*Китә.*)

Дәүран. Менә нәрсә, Һарун. Мин сиңа цехыбызны яңабаштан үзгәртеп кору турындагы планымны сөйләгән идем. Проектны тормышка ашыру сиңа йөкләнәчәк.

Һарун. Ышанычың өчен рәхмәт, Дәүран абый, мин аны эшләячәкмен. Ләкин бит минем дә китеп баруым бик мөмкин.

Дәүран. Китсәң, үзең ышанган башка бер иптәшкә калдырырсың. Проект, нигездә, әзер. Кайбер детальләрен генә карыйсы калды. (*Футляр бирә.*)

Һарун. Мин аны икебезнең исемнән игълан итәрмен.

Дәүран. Анысы синең эш. Бу турыда партия оешмасы да белә. Ярдәм кирәк булганда, аларга мөрәҗәгать итәрсең.

Тәлинкәләргә салынган ашау-эчү әйберләре күтәреп, Мидхәт, Гөләндәм,
Гөлҗиһан керә.

Һарун. Хуҗалык кешесенең эше хуҗаларча шул.

Мидхәт. Әйдәгез, дусларым, өстәлгә. Якын дустыбызны сугышка озату уңае белән йөрәкләребездәге әрнү, сыкрау хисләребезне басыйк. Кем белә, бәлки, безнең бик күпләребезне ачы язмыш тартып алачак...

Дәүран. Мидхәт, мин үләргә китмим, миңа җеназа укыма.

Мидхәт. Юк, мин киресенчә...

Дәүран (*бүлдереп*). Дуслар! Мин киләчәк тантанабыз өчен, кешеләребезнең күңел аклыгы өчен, барыннан да бигрәк Ватаныбызга булган мәхәббәтебезнең сафлыгы өчен тәкъдим итәм!

Ут сүнә.

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Арслановларның квартирасы. Пәрдә ачылганда, Бәрбәрия белән Гөлҗиһан төеннәр күтәреп керәләр.

Бәрбәрия. Гөлҗиһан апа, зинһар, саклык белән, анда савыт-сабалар.

Гөлҗиһан. Әйдә, әйдә, тавыкны йомырка өйрәтми, атлавыңны бел.

Кереп китәләр дә кире чыгалар.

Бәрбәрия. Аллага шөкер, ташып бетердек бит, Гөлҗиһан. Әйберләрең бик күп икән. Тормыш булгач, бар да кирәк бит. Гөлҗиһан апа, синнән бернәрсә сорыйм әле, шушы уңганлыгың белән нигә иргә чыкмыйсың?

Гөлҗиһан. Ай Алла, иске авыздан яңа сүз дигәндәй, нигә алай сорыйсың?

Бәрбәрия. Син гаҗәп яхшы күңелле, барчага изге теләкле кеше икәнсең.

Гөлҗиһан. Менә шуның аркасында бүгенге көнгә калдым да. Беренче ирем мал табучы сәүдәгәр кеше иде. Ул үлгәч, юләрләнеп бер яшь кияүгә тап булдым. Шул ристан берничә ел эчендә бөтен байлыгымны таратып бетерде. Хәзер мине кем алсын.

Мидхәт керә.

Мидхәт. Гөлҗиһан апа, мин синең Ташкентка китүеңне хәл иттем. Очарга курыкмыйсыңмы?

Гөлҗиһан. Ярапландамы? Юк, юк. Үлсәм дә утырмыйм.

Мидхәт. Башкача мөмкин түгел. Поездларда хәзер бик тикшереп, аерым әһәмияткә ия булган командировкалар белән генә йөртәләр.

Бәрбәрия. Самолетка эләгү — бик зур бәхет инде ул. Тиз дә, мәшәкатьсез дә.

Гөлҗиһан. Бик куркыныч бит.

Мидхәт. Берни дә түгел. Транспорт самолеты, бездән детальләр алып китәләр. Менә шушы кәгазь белән площадка начальнигына барырсың.

Гөлҗиһан. Юк, юк. Миннән булмый ул.

Бәрбәрия. Киреләнмә, окоп эшенә җибәрсәләр, үкенерсең. Хәзер китсәң, кичкә анда буласың.

Гөлҗиһан. Нишлим инде, нишлим...

Бәрбәрия. Уйлап торасы юк, тизрәк моннан ычкынасың гына калды.

Гөлҗиһан. Ярый, Аллага тапшырдым, үлә калсам, бәхил булыгыз. Анда йөргән кешеләр ачы нәрсә ашыйлар бугай, базарга чыгып лимон белән әлван кагы алып кайтыйм әле.

Мидхәт. Озак йөрмә, берничә сәгатьтән очасыз.

Гөлҗиһан китә.

Йә ничек, сөйләштеңме?

Бәрбәрия. Юк әле, баласы артыннан йөри бит. Тәмле тамагын да озатыйк. Аннан беркая да китә алмас. Әнә үзе кайтып килә. (*Бүлмәсенә кереп китә.*)

Кайгылы хәлдә Гөләндәм кайтып керә.

Мидхәт. Гөләндәм, борчуыңны уртаклашырга кердем. Балаң авырый икән.

Гөләндәм. Әйе, аңарда скарлатина. Инфекционный клиникага салдылар... Унбиш көн инде ул анда ята... Һәр көнне мин аны күрергә барам, ләкин кертмиләр...

Мидхәт. Кызганыч... Нинди зирәк бала иде. Сезнең утын мәсьәләгез ничек?

Гөләндәм. Шәптән түгел иде, рәтләнде инде. Заводтан да, военкоматтан да китерделәр.

Артта Хәсәнша тавышы.

Хәсәнша. Кайсы тагын коридорда утын ярган? Чүбегезне нигә монда өясез? (*Өйгә кереп.*) Әйтәсең, әйтәсең, колакларына тамга итеп киртлисең, юк, тыңламыйлар. Саумы, Гөләндәм!

Гөләндәм. Әйдә, Хәсәнша абзый, утыр.

Хәсәнша. Юк, сеңлем, утырып тормыйм. Кулыңны куеп менә шушы кәгазьне алып кал әле.

Гөләндәм. Нинди кәгазь соң ул?

Хәсәнша. Апаң Гөлҗиһанга, шәһәр өчен утын әзерләргә урманга барырга.

Гөләндәм. Нигә соң үзенә бирмисең?

Хәсәнша. Кичә әйткән идем, якын да килми. Шуннан соң инде райсоветка барып менә шушы язуны китерергә туры килде.

Мидхәт. Кара әле, абый кеше, шуны җайларга була бит.

Хәсәнша. Ничек җайлыйсың? Безнең йорт идарәсеннән унбиш кеше сорыйлар.

Мидхәт. Балалары авырый, үзе сау түгел дияргә була.

Хәсәнша. Ә соң минем вөҗданым?

Мидхәт. Син дә вөҗдан турында сөйләгән буласың тагын.

Хәсәнша. Нигә сөйләмәскә? Минем өч улым сугышта кан түгә, киленнәрем госпитальдә, кызым элемтә эшендә. Үзем пенсионер башым белән менә бу хезмәттә. Дошманны җиңү өчен барыбыз да эшләргә тиеш.

Мидхәт. Эшлисең икән, бик яхшы. Нигә аның өчен башкаларны борчырга.

Гөләндәм. Мидхәт, бу турыда син хаклы түгел.

Хәсәнша. Әйе, әйе, хаклы түгел шул. Син монда кем?

Мидхәт. Минем кемлегемне тикшерү синең вазифаңа керми торгандыр.

Хәсәнша. Нигә кермәсен? Мин райсовет депутаты, мин йорт идарәсенең мөдире. Үз йортыма кергән-чыккан кешеләрне барлап тору — минем эш. Тап-таза башың белән сугышка бармыйча нишләп монда адвокат булып йөрисең? Документың бармы?.. Документ, дим!.. (*Кулын сузып каршына бара.*)

Гөләндәм. Хәсәнша абзый, кирәкми. Повесткаңны апага бирермен. Ләкин ул минем сүзне тыңлар микән?

Хәсәнша. Эшләр болайга киткәч, тыңламый хәле юк. Яхшы чакта райсоветка барып күренсен. Аннан, Гөләндәм, мин синең бер бүлмәңне артык саныйм. Шуны эвакуация белән килгән иптәшләргә бирсәк, ничек карарсың икән?

Гөләндәм. Дөрес, Хәсәнша абзый, безнең артык бүлмәбез бар иде, ләкин без аны бирдек инде.

Хәсәнша. Кемгә?

Гөләндәм. Бәрбәрия исемле танышыбызны кертергә булдык.

Хәсәнша. Нигә миңа әйтмәдегез?

Гөләндәм. Апа миңа сезнең белән сөйләштем дигән иде.

Хәсәнша. Күргәнем дә юк.

Гөләндәм. Кулында ордеры да булгач, мин аны сезнең белән аңлашып эшләгәндер дип уйлаган идем.

Хәсәнша. Җыбыткы син, кызым, җыбыткы!.. Нигә шул апаңа тезгенеңне бирәсең?

Гөләндәм. Беләсең бит, Хәсәнша абзый, минем борчулы чагым... Иремнән хәбәр юк, балам каты авырый...

Хәсәнша. Ул кешегез өйдәме әле?
Гөләндәм. Өйдә бугай. Бәрбәрия, бире чык әле.

Бәрбәрия чыга.

Бәрбәрия. Нәрсә бар?
Хәсәнша. Ордерыңны күрсәт әле!
Бәрбәрия (*эре генә*). Рәхим итегез.
Хәсәнша. Мин бу ордерны танымыйм, ялган бу!
Бәрбәрия. Нишләп ялган? Шәһәр советының торак идарәсеннән бирелгән.
Хәсәнша. Ансы шулай. Ләкин бу йорт — райсовет йорты. Бушатыгыз бүлмәне. Мин анда хәзер Мәскәүдән килгән зур кешене китерәм.
Бәрбәрия. Юк әле, абзыкаем, китермичәрәк тор. Мине бирегә син кертмәдең, син чыгара да алмассың.
Хәсәнша. Чыгарырга калгач, сеңлем, чыгарырбыз инде аны. Синең шикелле итәк астыннан эш йөртүчеләрне йолкып атабыз.
Бәрбәрия. Кулыңны гына тидереп кара. Мин кызылармеец семьясы, ирем анда кан түгә! Миңа кагылырга хакың юк! Аңлыйсыңмы, хакың юк! (*Җикеренеп бара*.)
Гөләндәм. Бәрбәрия, тавыш чыгарма. Барыгыз райсоветка, кайсыгыз хаклы икәнен шунда әйтерләр.
Бәрбәрия. Барам, бик барам. Ник бармаска? Райсоветына да, шәһәр советына да, Верховный советына да барам! (*Бүлмәсенә кереп китә*.)
Хәсәнша. Койрыгыңа баскач, бармый нишләрсең.

Киенеп, Бәрбәрия чыга.

Бәрбәрия. Әйдә, картлач, киттек.
Хәсәнша. Әйдә, кәнтәй, шулай иттек.

Китәләр.

Мидхәт. Исеңдәме, Гөләндәм, бервакытны без, кызлар, егетләр, җыйналып, Идел аръягындагы атауга пикникка чыккан идек. Шунда мин сине Москва студенты Дәүран белән таныштырган идем.
Гөләндәм. Әйе, исемдә. Соңыннан син исереп тавыш чыгардың.
Мидхәт. Башкача минем чыдарлыгым калмады. Чөнки син бөтен килешең белән аңар табындың.
Гөләндәм. Мин генә түгел, башка кызлар да аны үзләренә каратырга тырышканнар иде. Ләкин ул нишләптер берсенә дә күңел бирмәде. Бары тик минем янда гына көнен уздырды.
Мидхәт. Сезнең күңелдә ул һаман да шулай сакланамы?
Гөләндәм. Тагын да көчлерәк, ул әле минем янымда булганда, аңа булган мәхәббәтемнең ни дәрәҗәдә көчле икәнен сизми йөргәнмен. Аерылышу миңа сүз белән тәэсир итә алмаслык чын мәхәббәтне аңлатты.
Мидхәт. Сез бигрәк инде, фанатикларча.
Гөләндәм. Ул чыннан да шулай. Гаилә драмаларының бик күбесе кешеләрнең бер-береннән аерылып тору вакытларында башлана торган була.
Мидхәт. Мәхәббәт хисе мәңге түгел ул.
Гөләндәм. Дөрес. Сүнәр-сүнмәс янган учак төсле пыскып торган мәхәббәтләр андый вакытларда әкренләп сүнәләр. Ә инде чын мәхәббәт аерылышу шартларында да, борынгы әкиятләрдәге кебек, мөкатдәс хискә әйләнә икән.
Мидхәт. Бәлки, шулайдыр да, ләкин күптән үлгән кеше белән нигә үзеңне юатырга?
Гөләндәм. Ничек үлгән?
Мидхәт. Шулай, исән булса, берәр хәбәре килер иде. Аның белән киткән кешеләр бар да кырылып беткәннәр.
Гөләндәм. Һәрбер хәбәре булмаган кеше үлгән дигән сүз түгел. Сугыш вакытында төрле хәлләр булырга мөмкин.
Мидхәт. Кеше шулай сөйли бит.
Гөләндәм. Теләгән кадәр сөйләсеннәр, мин аларга ышанмыйм. Ул минем мәхәббәтем, чын мәхәббәт үләргә тиеш түгел. Менә бүген тышта кырык ике градус салкын, мин фәкать аның турында уйлыйм. Шундый каты суыкта, кырда, яланда ятуын күз алдыма китереп әрним, сызланам...
Мидхәт. Ярый, Гөләндәм, хушыгыз. Иртәгә театрга билет алсам, барырсызмы?
Гөләндәм. Юк, бара алмам. Чөнки мин бит кичләрен госпитальгә йөрим.
Мидхәт. Анда сезгә ни калган?
Гөләндәм. Яралыларга китаплар укыйм. Шуның белән күбесен юатам.

Мидхәт китә. Гөлҗиһан кайтып керә.

Гөләндәм. Апа, сиңа урман эшенә барырга повестка китерделәр.
Гөлҗиһан. Башка эшләре булмаса, әйдә ташый бирсеннәр.

Гөләндәм. Туганым апа, син бу мәсьәләгә алай җиңел генә карама. Бу бит уен эш түгел. Хәзер сугыш вакыты, җавапка тартып куюлары бар.

Гөлҗиһан. Койрыгымны тотарлар. Берничә сәгатьтән мин монда булмыйм инде.

Гөләндәм. Кайда буласың соң?

Гөлҗиһан. Самолетта очам. Ташкентка, Гөлбану апаларга.

Гөләндәм. Ә билет, акча?

Гөлҗиһан. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын, дигән бабайлар. Поездга гына түгел, самолетка урын алып бирделәр. Менә ул! (*Кәгазь күрсәтә.*)

Гөләндәм. Бу нәрсә була инде?

Гөлҗиһан. Ә мин монда нишлим? Буш фатирыңны саклап ятыйммы? Анда тормыш, ди. Өрек-җимеш, кавын-карбызны урамда саталар икән. Шуның өстенә бүген «Мәскәү куркыныч астында» дип, радиодан игълан иткәннәр.

Гөләндәм. Ай-һай, апа, дөрес эшлисең микән? (*Бүлмәсенә кереп китә.*)

Бәрбәрия кайтып керә.

Бәрбәрия. Гөлҗиһан апа, минем эшләр начар бит.

Гөлҗиһан. Әллә ирең кайттымы?

Бәрбәрия. Ордерың дөрес түгел, диләр. Ул гына да түгел, кемдер әләкләргә өлгергән. Начальник дигәннәре, үз квартираңа акчага кеше кертеп, яңа җиргә ордер маташтырып йөрисең, дигән була. Имеш, бүлмәне бушатмасам, җавапка тартачаклар.

Гөлҗиһан. Менә сиңа!..

Бәрбәрия. Кая, акчаларымны бир.

Гөлҗиһан. Мин бит сиңа ордер сатмадым. Ул якларын үзем карыйм, дидең бит.

Бәрбәрия. Шулай дигән идем дә, теге жулик малай алдады. Председательдән кул куйдырмаган. Мин инде бөтенесен дә сорамыйм, яртысын бирсәң, риза.

Гөлҗиһан. Яртысын түгел, чиреген дә бирә алмыйм. Мин аларны тотып бетердем инде. Летчикларга күчтәнәч алдым.

Бәрбәрия. Димәк, бирмисең?

Гөлҗиһан. Тукта әле, мин синнән кайчан акча алдым соң?

Бәрбәрия. Әллә танар идеңме?

Гөлҗиһан. Шаһитларың бармы соң?

Бәрбәрия. Шаһитым булмаса, синең оятың булырга тиеш.

Гөлҗиһан. Мондый чакта оят — юк сүз ул.

Бәрбәрия. Имансыз икәнсең.

Гөлҗиһан. Әйдә, әйдә, театр уйнап маташма! Күкрәк көчең белән тапкан мал түгел әле ул. Минем кебек ятим кешегә хәрәм байлыгыңнан садака булыр.

Бәрбәрия. Тамагыңа таш булып кадалсын.

Гөлҗиһан. Каргышың казык башына. (*Бүлмәсенә кереп китә.*)

Әйберләр күтәргән Коновалов, Клавдия, Акулиналарны ияртеп, Хәсәнша керә.

Хәсәнша. Үзе өйдәме?

Гөләндәм. Өйдә, Хәсәнша абзый.

Хәсәнша. Иптәшләр, менә шушы бүлмә сезнеке булыр. (*Ишек шакый.*)

Бәрбәрия чыга.

Хәсәнша. Әйберләрегезне җыеп бетердегезме?

Бәрбәрия. Уйлаганым да юк.

Хәсәнша. Ничек уйлаганың юк? Сиңа бит райсоветта бушатырга куштылар.

Бәрбәрия. Бүлмә бирегез, бушатам.

Хәсәнша. Яхшылыкта бушат. Усаллыкка калса, милиция белән чыгарырмын.

Бәрбәрия. Кагылып кына карагыз! Мин эшче-крестьян Кызыл Армиясенең командиры хатыны. (*Шалт итеп ишеген яба да эчтән бикләп куя.*)

Хәсәнша. Юк, бикләнеп котыла алмассың, мин синең ишегеңне чәлпәрәмә китереп керермен!

Гөләндәм. Хәсәнша абзый, алай ярамас, ул чыннан да командир хатыны бит.

Хәсәнша. Ә моңа хәтле кайда яшәгән?

Гөләндәм. Анысын мин белмим.

Хәсәнша. Белмисең шул. Ә мин беләм: хәрәмсез түгел бу эш. Яхшылап әйткәнне белми икән, утыртам мин аны. Шабаш.

Гөләндәм. Алай ук ярамас, Хәсәнша абзый.

Хәсәнша. Дәүләт приказына буйсынмаска ярыймы?

Гөләндәм. Алай да ярамый.
Хәсәнша. Шулай булгач, нишлибез?
Гөләндәм. Кунакларны менә бу бүлмәгә кертегез.
Хәсәнша (аптырап). Ә үзегез?
Гөләндәм. Үзем менә шушы бүлмәдә дә торырмын.
Коновалов. Рәхмәт сезгә, ханым, бик зур рәхмәт.
Акулина (*Гөләндәмнең аркасыннан сөеп*). Яхшы күңелле кеше икәнсез...

Коноваловлар әйберләре белән Гөләндәм күрсәткән бүлмәгә кереп китәләр. Әйберләрен күтәреп, Гөлҗиһан чыга.

Хәсәнша. Син, кодача, кая барырга җыендың әле?
Гөлҗиһан. Синең эшең түгел ул. Дүрт ягым — кыйбла. Кая телим, шунда барам.
Хәсәнша. Шулай микән? Ә урман эшенә кем барыр?
Гөлҗиһан. Барды ди, бармый ни. Шундый суыкта урман кисеп йөрдем ди. Кирәк булса, үзең бар. Ә минем самолетка билетым бар инде.
Хәсәнша. Күрсәт әле билетыңны.
Гөлҗиһан. Мә! Күңелең булдымы инде?
Хәсәнша. Син дезертир! Әгәр дә качасың икән, үзеңне суд эзләп табар. Һәм сугыш вакыты законы белән зинданга рәхим итәсең инде.
Гөлҗиһан. Имансыз икәнсең. (*Җылый.*) Мин ялгыз хатынны җылатып сиңа ни файда?
Хәсәнша. Миңа файда юк. Зату сиңа җегәнлек табыла дигән сүз.
Гөләндәм. Апа, дим, бәлки, карышмассың? Кешеләрчә булыйк инде.
Гөлҗиһан. Каравыл! Таладылар. Кемгә җәвит итим?

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шул ук Арслановлар квартирасында бара. Пәрдә ачылганда,
Гөләндәм белән Акулина сөйләшеп утыралар.

Акулина. Очучылар мәктәбенә кайтырга теләвең бик әйбәт. Күп тә үтмәс, чын белгеч булачаксың. Хәзерге вакытта очучылар фронтта гына түгел, тылда да бик кирәкле кешеләр.
Гөләндәм. Алырлармы әле. Ничә ел узды. Белемнәрең искергән дип әйтүләре бар.
Акулина. Шөбһәләнмә. Синең кебекләрне дә алмагач, ни була ди ул...
Гөләндәм. Наилне дә сирәк күрәчәкмен булып чыга...
Акулина. Ә балаң өчен кайгырма, ул үсәр. Әбисе аны синнән дә яхшырак карар. Әбиләргә баланың баласы тагын да якынрак була ул.

Бер кулына әйберләр, икенчесе белән песи кочып, Бәрбәрия кайтып керә.

Бәрбәрия. Мырлавыгым, мырлавыгым минем, кара ничек туңган ул. Гөләндәм, нигә инде минем мырлавыгымны карамадың.
Гөләндәм. Өйдә юк идем, яңа гына кайтып кердем.
Акулина. Кычкырып йөдәткәч, песиегезне мин чыгарган идем.
Бәрбәрия. Билгеле сездер, башка кем булсын. Тышта шулкадәр суык, ярый әле туңып үлмәгән. Әйдә, мырлавыгым, сөт белән күмәч бирермен.

Бүлмәсенә кереп китә.

Акулина. Берәүгә песи дә кадерле. Ә күпме халык үлем астында.
Клавдия кайтып керә.

Әнә килен дә кайтты. (*Китә.*)
Гөләндәм. Клавдия Петровна, менә мич янына килегез. Һаман суытамы?
Клавдия. Бик әче җил чыккан.
Гөләндәм. Сез бик арыгансыз, ахры.
Клавдия. Көне буе операция өстәле янында басып тору шутка түгел ул. Җеп өзәрлек тә хәлем юк.
Гөләндәм. Авырулар һаман киләме?
Клавдия. Москва астындагы хәлләр килүчеләрнең санын тагын да күбәйтте.
Гөләндәм. Москва дигәннән, сезгә хатлар бар иде. (*Хатлар бирә.*)

Ишектә Акулина күренә.

Акулина. Килен, күгәрченем, чәй әзерләдем.

Клавдия белән китәләр. Ирләр киеменнән бусагада Гөлҗиһан күренә.

Гөләндәм. Әнекәем лә, апа түгелме?
Гөлҗиһан. Мин инде, мин.
Гөләндәм. Әйдә, чишен тизрәк.
Гөлҗиһан. Юк, Гөләндәм, чишенеп тормыйм. Шәһәргә җиде эшелон утын китердем, шуны бушаттырам. Наил кая, йоклыймы?
Гөләндәм. Юк, әбисендә, ул гомумән хәзер анда торачак.
Гөлҗиһан. Бик әйбәт булган. Син аны иркәләп боза идең.
Гөләндәм. Соң ничек, апа, бик авыр түгелме?
Гөлҗиһан. Башта җиңел булмады. Хәзер күнектем инде.
Гөләндәм. Ябыккансыңмы дим.
Гөлҗиһан. Юк, бераз артык-портыклар гына төшеп калгандыр.
Гөләндәм. Ашау-эчү якларыгыз ничек?
Гөлҗиһан. Сорама инде. Сугыш барысын юа.
Гөләндәм. Димәк, син анда баруыңа үкенмисең?
Гөлҗиһан. Мондый заманда үкенәләр димени. Анда җиңелдән түгел, нәнәчем. Ләкин ударный эшләү үзе бер илһам өсти торган нәрсә икән.
Гөләндәм. Тукта әле, апа, син бит үзгәреп кайткансың.
Гөлҗиһан. Моннан ничек киткәнемне беләсең. Әфсен укып өшкергәндәй, үземне үзгәрттеләр, нәнәчем.
Гөләндәм. Рәхмәт апа, синең өчен кайгырып тора идем.
Гөлҗиһан. Бәрбәрия һаман монда торамы?
Гөләндәм. Биредә. Чыгарга кушкан идем, бүлмә табалмый әле.
Гөлҗиһан. Мин аңар бүлмә табармын... Ләкин рәшәткәлесен... Беренчедән, аның иреннән калган үз фатиры бар икән. Анда ул акча түләтеп кешеләр тота, ди. Икенчедән, беләсеңме, алар ни өчен синең яныңа сырышып йөриләр?
Гөләндәм. Бераз төшенә башладым.
Гөлҗиһан. Хәзергә хуш, нәнәчем, тышта иптәшләрем көтәләр.
Гөләндәм. Кунарга кайтырсың бит.
Гөлҗиһан. Утыннарны бушатып бетерсәләр, кайтырмын. (*Йөгереп китә.*)

Бәрбәрия чыга.

Бәрбәрия. Менә нәрсә, Гөләндәм, минем бүген туган көнем бит, кунаклар чакырдым. Бераз утырып алабыз, яме?
Гөләндәм. Тәбрик итәм. Матурланып киткәнсең. Чәчеңне кайчан буяттың?
Бәрбәрия. Әле яңа гына, Ленинградтан бик шәп осталар килгән. Сипкелемне дә бетерергә булдылар. Чәчем килешәме?
Гөләндәм. Дөресен әйткәндә, юк. Кара күзгә сары чәч табигый түгел кебек.
Бәрбәрия. Сиңа ошамас инде. Без синең кебек чибәр түгел шул.

Әйберләр тотып, Мидхәт керә.

Әнә Мидхәт абый килеп җитте.
Мидхәт. Туган көнегез белән тәбрик итәм, Бәрбәрия.
Бәрбәрия. Рәхмәт, Мидхәт абый. Әйдәгез бүлмәгә.
Мидхәт. Гөләндәм, мин беркөн әйткән мәсьәләне хәл кылдым. Сине бүгеннән безнең ОРСка кассирша итеп билгеләдек. Менә приказы.
Гөләндәм. Рәхмәт, мин икенче бер җиргә гариза биргән идем инде. Алсалар, анда керәм.
Мидхәт. Ул бит әле алсалар. Алмасалар?
Гөләндәм. Алмасалар, шоферлар мәктәбенә китәрмен.
Мидхәт. Ә мин, сезгә ышанып, өч ел эшләгән кешемне чыгардым.
Гөләндәм. Менә монысы юкка, мин бит сездән эш сорамаган идем.

Бар да ак фетр кигән парлы кунаклар керә.

Бәрбәрия. Әнә кунакларым да килделәр. Әйдәгез, рәхим итегез!

Гөләндәм белән Бәрбәриядән башкалар кереп китәләр.

Гөләндәм, әйдә инде.
Гөләндәм. Рәхмәт, Бәрбәрия, мин кермим...
Бәрбәрия. Ят кешеләр юк бит... Җизниләр дә кодалар гына.
Гөләндәм. Миңа киләсе кеше бар.

Самойлов керә.

Бәрбәрия. Шул сукырыңмы? Тапкансың икән. (*Китә.*)

Гөләндәм. А... Виктор Игнатьевич, әйдәгез, рәхим итегез. Өстегезне салыгыз. Мин хәзер чәй куям.

Самойлов чишенә, Гөләндәм электр чәйнеге куя.

Утырыгыз. Бу арада күренмәдегез. Витя, нигәдер сез күңелсез.

Самойлов. Военкоматтан кайтып килешем. Фронтка сорап биргән рапортыма Москвадан җавап җибәргәннәр.

Гөләндәм. Соравыгызны кире какканнармы?

Самойлов. Юк, кагуын какмаганнар, гаризамны канәгатьләндергәннәр. Ләкин фронтка түгел, тылда яшьләрне өйрәтү эшенә билгеләгәннәр.

Гөләндәм. Шулай булгач, нигә күңелсезләнергә?

Самойлов. Их, белсәгез иде. Йөрәгем яна. Анда минем хатыным калды, балаларым... Хәзер инде башымда бер генә уй — үч алу.

Гөләндәм. Мин сезне аңлыйм, әлбәттә. Семья турында хәбәр бармы әллә?

Самойлов. Шул шәһәрдән котылып кайткан танышымны очраттым. Хатынымны, әйтергә дә авыр (*үзен кулга алалмыйча тора*), атканнар, баламны каядыр озатканнар.

Гөләндәм. Коточкыч хәл...

Самойлов. Нindидер формаль кагыйдәләргә таянып, мине фронтта булудан тыялар. Имеш, бер күзем юк. Ләкин алар миндә чикләнмәгән көч барлыгын исәпкә алмыйлар. Мин бит бер күзем белән дә кайбер күзле бүкәннәрнең унысы кадәр сугыша алам.

Телефон шалтырый.

Гөләндәм. Әйе, Гөләндәм Арсланова телефонда. Ничек, хәзер үк килергә? Гаризамны карыйсыз? Карагыз әле, иптәш... Өзделәр.

Самойлов. Кем ул?

Гөләндәм. Авиация мәктәбеннән. «Биргән гаризагызны карыйбыз, хәзер үк килеп җитегез» диләр.

Самойлов. Әйдә, алайса, киттек.

Гөләндәм. Юк, Витя, бу килеш уңайсыз, мин хәзерләнмәгән.

Самойлов. Берни дә түгел, анда сине белүчеләр бар, үзем сөйләшермен. Әйдә, киен.

Гөләндәм. Мин куркам.

Самойлов. Менә бусы инде һич килешми, очучылар өчен ят гадәт. (*Киемнәрен кидерә башлый.*)

Гөләндәм. Кара әле, Витя...

Самойлов. Икеләнмә. Берничә сорау бирерләр, шул гына. Әйдә, киттек. (*Алып китә.*)

Клавдия Петровна чыга, телефонга бара.

Клавдия. Промрайонны бирегез. ... нчы завод белән тоташтырыгыз. Цех начальнигы Коноваловны бирегез. Кадерлем, Иван Кузьмич кабинетындамы? Ничек? Кайтып китте, дисезме? Күптәнме?

Ишектә Коновалов күренә.

Бүген дә кайтмыйсыңмы әллә дип борчылып тора идем.

Коновалов. Син нәрсә, еладыңмы әллә?

Клавдия. Хәлләр әйбәттән түгел, Ваня, Москвадан Петр Карпичлардан хат алдым.

Коновалов. Нәрсә язалар?

Клавдия. Һәр көнне берничә тапкыр һава тревогасы, балалар белән метрода кунабыз, дигәннәр...

Коновалов. Тагын нинди хәбәрең бар? Йә, күрәм бит инде. Әйт. Елавың юкка булмас.

Клавдия. Аннан, Ваня (*әйтергә кыймый тора*), син мине гафу ит... Мондый арыган чагыңда әйтергә тиеш булмасам да, яшереп кала алмыйм... Безнең Валентин катлаулы операцияне күтәрә алмаган...

Коновалов. Их, Валя, Валя... Улым!..

Клавдия. Бер генә баласыз да калырбыз микәнни? Ах, авыр, Ваня...

Коновалов. Авыр, бик авыр, Клавдюша... Немец фашистлары кешегә нинди фаҗигаләр китерде... Үлгән баласы турында утырып еларга атаның яше юк... Әйе, яшем юк... Чөнки аны йөрәкләребездә кайнап янган ачу, нәфрәт ялкыннары киптергән... Ләкин килер бер көн, ул балаларның үчен алырбыз. Шуның өчен дә безнең халык, бугазларына тыгылган яшьләрен кире йотып, бер урынына бишне, биш урынына егерме биш өлеш итеп эшләп чыгарырга тырыша.

Клавдия (*елап*). Унтугызны да тутырырга өлгермәде бит әле ул. Яшьлекнең матурлыгын да белә алмый калды сабыем.

Коновалов. Бер бөтен буын диярлек аңардан мәхрүм булачак. Авыр, иң авыр көннәр кичерәбез, Клавдюша.

Клавдия. Син каты арыгансың. Эштә дә күңелсезлекләр бар, ахры?

Коновалов. Бүген мине обком секретаре чакырган иде. «Завод белән җитәкчелек итү эшенә сезнең кандидатурагызны күрсәтергә телибез, ни дисез» ди.

Клавдия. Директорлыкка? Син ни дидең?

Коновалов. Нәрсә дим? Мин партия солдаты, ни кушсалар, шуны үтәргә тиеш.
Клавдия. Ярый алайса, мин ашарга әзерләтим. Син биредә генә утыр инде. (*Китә.*)

Коновалов кесәсеннән газеталар чыгарып укырга керешә.
Бәрбәрия бүлмәсендә уен-җыр башлана.

Коновалов. Москва... Москва... Анда минем ата-анамның сөякләре күмелгән... Анда минем бердәнбер балам...

Хәсәнша керә.

Хәсәнша. Саумы, Иван Кузьмич.

Коновалов. Исәнме, Хәсәнша Сафиевич, карчыгың үлгән икән, авыр кайгыңны уртаклашам... Нинди авыру иде соң аңарда?

Хәсәнша. Ул электән дә чирләшкәрәк кеше иде. Малайлар китү белән, язгы боздай көннән-көн сыза барды. Больницага да салып карадым, рәтләнә алмады...

Коновалов. Аналарга авыр шул...

Хәсәнша. Аналарга гына түгел, Иван Кузьмич, аталарга да бик авыр... Сугышка кадәр безнең өй эче гөрләп тора иде, хәзер берүзем калдым... Сөйләшергә кеше юк... Аңлыйсызмы, Иван Кузьмич, кеше юк... Карчыкны күмеп кайткач, телсез кеше шикелле берүзем уйланып утырдым-утырдым да шомлана башладым. Юк, мин әйтәм, болай яшәргә ярамый, дим. Чыгып киттем дә, райсоветка барып, йорт идарәсеннән төшеп кайттым. Шабаш!

Коновалов. Менә анысын юкка эшләгәнсең. Безнең йортка син яхшы хуҗа идең.

Хәсәнша. Хатын-кыз белән талашып йөрү минем холыктагы кешенең эше түгел ул. Мине элекке урыныма да чакыралар, анда барырга теләмим. Сез мине үзегезгә алыгыз. Минем кулдан әле эш килә. Мин тимерче, мин калайчы, мин слесарь, мин токарь да була алам.

Коновалов. Ярый, тиешле кешеләр белән сөйләшермен. Сезнең кебек һөнәр остасы безгә бик кирәк.

Хәсәнша. Рәхмәт, Иван Кузьмич. Юкса мин ничек итеп ялгыз башым көн күрим? Заводта кеше арасында кайгым онытылыр. Эшләгән эшем кеше күзенә күренер.

Коновалов. Иртәгә иртүк документларыңны алып миңа керерсең, заводка бергә китәрбез.

Хәсәнша. Рәхмәт сезгә, Иван Кузьмич, хәзергә хушыгыз. (*Китә.*)

Клавдия керә.

Клавдия. Әйдә, Ваня, үз бүлмәбезгә.

Һарун керә.

Һарун. Хәерле кич.

Коновалов. Клавдия, таныш бул, минем ярдәмчем Һарун Юсупович Ахмеров.

Клавдия. Сезне үз өебездә күрүгә мин бик шат. Иван Кузьмич теленнән төшми торган Һарун Юсупович сез икәнсез алайса?

Һарун. Үзең турында мактау сүзе ишетү күңелне җылыта, әлбәттә. Ләкин мин үземне андый шәрәфкә лаеклы дип санамыйм.

Клавдия. Сез, Һарун Юсупович, тыйнаклык күрсәтеп маташмагыз. Безнең Иван Кузьмич кешеләрне таный ул.

Гөләндәм кайтып керә.

Клавдия. Гөләндәм Ахметовна, сез кайдадыр йөреп кайттыгыз.

Гөләндәм. Мине чакырып алганнар иде, шатлык белән кайтып килешем. Бүгеннән мине очучылар мәктәбенә ахыргы курска укучы итеп алдылар. Язын диплом алам. Аннан мин — һавада.

Коновалов. Рәхмәт, Гөләндәм Ахметовна, рәхмәт сезгә.

Клавдия. Чын күңелдән тәбрик итәбез.

Һарун. Бу адымың белән котлыйм, Гөләндәм. Юкса сез дә (*Бәрбәрия бүлмәсенә күрсәтеп*) алар белән утырасыз икән дип борчылган идем.

Клавдия. Әйдәгез, кунакларым, өстәлгә. Алдан хәзерләнмәгәч, әллә нинди сыебыз юк. Татарчалап әйткәндә, «Такта чәй дә якты чырай» булыр.

Кереп китәләр. Гөлҗиһан кайтып керә. Өсләрен чишенә. Бәрбәрия бүлмәсендә булган уен-җырны тыңлап тора. Керергә теләп ишеккә таба бара, өстендәге киемнәренә күзе төшеп туктап кала. Комод янына килеп, күлмәк белән яулык ала да ширма артына кереп китә. Бәрбәрия белән Мидхәт чыга.

Бәрбәрия. Мидхәт абый, син кая?

Мидхәт. Кая булсын, китәм. Синең кодаларыңның нурлы йөзләрен карап утырыйммы? Кайчаннан бирле йөреп, шуны да кулга төшерә алмадың.

Бәрбәрия. Нишлим соң, ипкә килмәгәч.

Мидхәт. Ансы инде синең осталыгыңа бәйләнгән.

Гөлҗиһан (*ширма артыннан чыгып*). Кемне кулга төшерү турында сөйлисез?

Бәрбәрия. Гөлҗиһан апа, син каян?

Гөлҗиһан. Каймылдык белән кайгылдыктан! Гөләндәм турында сүз барамы? Ул булмас, безнең нәсел бервакытта да андый түбәнлеккә төшмәс!

Бәрбәрия. Нинди түбәнлек?

Гөлҗиһан. Җитәр сиңа, кәнтәй токымы!

Мидхәт. Тукта әле, Гөлҗиһан апа, мин сине төшенмим.

Гөлҗиһан. Мин барысын да төшендем, яу башлыгы, петрау тәкәсе!.. (*Каты кычкырып.*) Мин сезне кызган табада биетермен.

Бүлмәләрдән йөгереп чыгалар.

Гөләндәм. Нәрсә булды, нинди тавыш?

Мидхәт. Һичнәрсә белмибез, тотты да җикеренә башлады.

Артта Хәсәнша тавышы.

Хәсәнша. Иван Кузьмич, Иван Кузьмич! (*Сәхнәгә кереп.*) Зур уңыш белән котлыйм, немец гаскәрләрен тар-мар иткәннәр!

Коновалов. Каян алдың ул хәбәрне?

Хәсәнша. Әле генә радиодан әйттеләр. Москва янында безнекеләр һөҗүмгә күчкәннәр, бик күп шәһәрләрне алганнар.

Коновалов. Ниһаять, ниһаять, ул көнне күрергә ирештек!..

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Директорның кабул итү бүлмәсе. Һәр җирдә чисталык, стена буйлап диван, урындыклар тезеп куелган. Бер якта зур көзге. Тәрәзә төбендә гөлләр. Пәрдә ачылганда, Ирина Сергеевна көзге каршында төзәтенә. Тыштан керә торган ишек артында — коридорда — туктаусыз үтеп йөрүче кешеләрнең аяк тавышлары ишетелеп тора. Мидхәт керә.

Мидхәт. Исәнмесез, Ирина Сергеевна!

Ирина. Мидхәт Шакирович.

Мидхәт. Директор юкмы әллә?

Ирина. Биредә, Үзәк Комитет парторгы белән сөйләшеп утыралар. Аннан Һарун Юсуповичны кабул итәчәк. Сезне үзе чакыртып алырга булды.

Мидхәт. Нәрсә турында икәнен белмисезме?

Ирина. Нәрсә дип... Кичәге киңәшмәдә сезнең ОРС бүлеге турында да сүз булган икән. Шикаятьләр бар кебек.

Мидхәт. Гафу итегез, миндә сезнең өчен кечкенә генә бүләк бар иде. *(Матур гына тартмада әйбер бирә.)* Рәхим итегез.

Ирина. Ах, коробкасы нинди матур.

Мидхәт. Ә сез аны ачып, татып карагыз.

Ирина (*коробканы ачып, авызына конфет каба*). М-м... Шикарный әйбер. Магазиныгызга килдеме?

Мидхәт. Что сез?.. Москвада Наркоматта эшләүче дустым җибәргән. Нәкъ сезнең өчен сораткан идем.

Ирина. Рәхмәт.

Мидхәт. Минем сезнең өчен тагын бер бүләгем бар. (*Портфеленнән зур тартма чыгара.*) Менә, рәхим итегез.

Ирина. Бусы ни?

Мидхәт. Ачып карагач, белерсез...

Ирина (*коробканы ача*). Боже мой!.. Бу да миңамы?

Мидхәт. Әлбәттә.

Ирина. Шикарный әйбер.

Мидхәт. Махсус сезнең өчен сораткан идем.

Ирина. Рәхмәт.

Гөләндәм керә. Мидхәт сүзсез генә баш иеп чыгып китә.

Ирина. Әйбәт кеше дә инде.

Гөләндәм. Кем? Чумаринмы?

Ирина. Әйе, үзе укыган, үзе культуралы. Гафу итегез, директор чакыра.

Директор бүлмәсенә кереп китә. Самойлов керә.

Самойлов. Һу!.. Күктән эзләгәнем җирдән табылды... Тәбрик итәм, Гөләндәм, тәбрик итәм.
Гөләндәм. Нәрсә белән?
Самойлов. Мәктәп бетереп, очучы булуыгыз белән.
Гөләндәм. Аның өчен мин сезгә бурычлы. Кайчан килдегез?
Самойлов. Яңа гына. Корабльдән — балга дигән шикелле, аэродромнан — бирегә.
Гөләндәм. Үзегез генәме?
Самойлов. Команда белән. Мәктәп бетергән яшьләрне самолетлар алырга китердем.
Гөләндәм. Аннан?
Самойлов. Аннан алар белән үзем дә.
Гөләндәм. Ничек үзегез дә.
Самойлов. Фронтка.
Гөләндәм. Димәк, максатыгызга ирештегез? Рөхсәт иттеләр?
Самойлов. Әйе, ләкин очучы түгел, бортмеханик итеп билгеләделәр.
Гөләндәм. Бәхетле кеше икәнсез.
Самойлов. Ә сез бәхетсезме?
Гөләндәм. Әйе, бәхетсез. Мин дә фронтка җибәрүне сорап рапорт биргән идем, җавап юк. Әле менә директорга килүем дә шул турыда иде.
Самойлов. Ул гына булса зыянлы түгел. Сөйләгез, нинди зарларыгыз бар?
Гөләндәм. Шәһәрдән шәһәргә төрле йомышлар белән транспорт отрядында йөрү мине туйдырды. Минем очасым, еракларга очасым килә! Аннан инде, билгеле, йөрәк кайнаррак эшләргә талпына.

Кәгазьләр тотып, кабинеттан Ирина чыга.

Самойлов. Мин Москвадан. Перегончылар отрядының начальнигы Виктор Самойлов, директорга ашыгыч йомышлар белән.
Ирина. Яхшы, мин хәзер әйтермен. (*Кереп китә.*)
Самойлов. Сезнең биредә — җитәкчелектә — зур үзгәрешләр бар икән.
Гөләндәм. Әйе, яңа директор, партия оешмасының яңа оештыручысы килде.
Самойлов. Соң, ничек?
Гөләндәм. Эшне Москвача зурдан куйдылар. Бөтен җирдә энтузиазм күтәрелде.

Кабинеттан Ирина чыга.

Ирина. Иптәш Самойлов, сезне директор чакыра.
Самойлов (*Гөләндәмгә*). Гафу итегез, күрешербез әле.

Кабинетка кереп китә.

Ирина. Гөләндәм Ахметовна, иптәш директор сезне көттерүе өчен гафу үтенде. Хәзерге сәгатьләрдә ул сезне кабул итә алмый. Обкомнан шалтыраттылар. Фронт өчен самолет сатып алырга килгән колхозчылар белән беседасы булачак.
Гөләндәм. Яхшы, ул чагында мин бераздан әйләнеп килермен. (*Китә.*)

Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Директор кабинеты. Бөтен мебельләр аерым зәвык белән кызыл агачтан ясалган. Тәрәзәләргә ефәк шторалар эленгән. Стенага берничә самолет модельләре һәм түшәмгә кадәр тоташ итеп эшләнгән китаплар шкафы куелган. Өстәлдә берничә телефон аппараты. Зур тәрәзәләр аша яңа төзелеп килә торган шәһәр панорамасы күренә. Пәрдә ачылганда, беренче ранг инженеры чинында
Коновалов колхозчылар белән сөйләшеп утыра.

Коновалов. Шулай иптәшләр! Сезнең бу патриотлык адымыгыз, явыз дошманга каршы корыч стена булып күтәрелгән халкыбызда үз Ватаннарына булган мәхәббәт хисләрен тагын да арттырачак, фронтовикларыбызның сугышчан рухларын күтәрәчәк. Самолетның күпме торганын мин сезнең райком секретарегызга әйткән идем.
Карт. Ул якларын беләбез. Тиешле сумманы Дәүләт банкысындагы счетыгызга күчерергә дип, чекларыбызны да язып китердек. Менә алар. Тик безне сайлап җибәрүче колхозчыларның берничә теләкләре бар иде.
Коновалов. Әйтегез, иптәшләр, нинди теләкләр ул?
Карт. Беренчедән, без алачак самолетыбызның канат астына кайсы өлкәдән, нинди районнан икәнебезне әйтеп, «Яңа юл» колхозыннан фронтовикларыбызга бүләк» дип язуыгызны сораганнар иде.
Коновалов. Яхшы, иптәшләр, моны эшләргә мөмкин.

Карт. Аннан, безнең колхозчыларыбыз сатып ала торган самолетыбызны күреп, тикшереп алырга кушканнар иде.

Коновалов. Ул турыда шикләнмәгез, иптәшләр. Безнең продукциябезнең сыйфаты сезнең ышанычыгызны аклаячак.

Карт. Шулай да утырып йөреп алырга кушканнар иде. Үзегез бик яхшы беләсез, иптәш директор, бу бит бүләк багу мәҗлесенә куя торган бүләк кенә түгел, немец мәлгуньнәр белән сугышырга барачак машина. Шулай булгач, без аның йөрешен, ничек итеп очышын, машина частьларының һәрбер шөребен карап, тикшереп җибәрәсебез килә. Шуннан соң инде акча мәсьәләсен сөйләшергә мөмкин булыр. (*Акча документларын кесәсенә салып куя.*)

Коновалов. Яхшы, иптәшләр, моңар да күнәргә була. Менә шушы язу белән цех начальнигына барырсыз, ул сезгә төрле конструкциядәге самолетларны күрсәтер. Җаныгыз теләгәнен сайлап алырсыз. Һәм шунда кайчан утырып очарга икәнен дә әйтерләр.

Карт. Яхшы, иптәш директор, без канәгать.

Коновалов. Ә сезгә завод коллективы исеменнән зур рәхмәт. Хушыгыз, иптәшләр. (*Озата.)*

Ишектә Гөләндәм күренә.

Гөләндәм. Рөхсәтме?

Коновалов. Керегез. (*Урын күрсәтә.*) Утырыгыз, мин сезне тыңлыйм.

Гөләндәм. Фронтка җибәрүне сорап биргән рапортыма җавап алырга кердем.

Коновалов. Рапортыгызның Москвага җибәрелүе турында мин сезгә белдергән идем. Җавап килү белән хәбәр итәрбез.

Гөләндәм. Ул чагында мин сезгә икенче рапортымны тапшырам. (*Коноваловның алдына кәгазь куя.*)

Коновалов. Гөләндәм Ахметовна, дусларча сөйләшик әле. Ни өчен сез фронтка китәргә ашкынасыз? Анда ирләргә кыен, ә хатын-кызга мең кат кыенрак.

Гөләндәм. Югалган иремнең урынын алыштырасым килә. Мин бүген У-2 дә, иртәгә «Дуглас»та очам, берсекөнгә «Транспорт»ка утырам да Уралдан чимал китерәм. Анда-монда, перегончы булып, Москвага барам. Төрле шәһәрләргә аерым детальләр илтәм. Дошман яңадан һөҗүмгә күчкән, Дон елгасын кичеп, Иделгә, Сталинградка ыргыла. Минем менә шунда — лачын егетләр арасында буласым, Ватанга булган чын мәхәббәтемне күрсәтәсем килә.

Коновалов. Безнең транспорт отрядында хезмәт итүегез шул ук Ватаныбызга мәхәббәт күрсәтү дип саныйм.

Гөләндәм. Ансы шулай, Иван Кузьмич, мин сездән ялынып сорыйм: җибәрегез мине фронтка. Сезгә биредә кем булса да ярый бит.

Коновалов. Юк, Гөләндәм Ахметовна, безгә кем булса да ярамый, без үз заводыбызга гади эшчене дә, теләсә кемне дә алмыйбыз. Сезнең кебек очучыларга без мохтаҗ. Шулай булуга карамастан, мин сезнең соравыгызны үтәр дә идем, ләкин бит ул мәсьәлә миннән генә тормый. Рапортыгызны көне-сәгате белән Москвага җибәрдек.

Гөләндәм. Алай булгач, нигә соң җавап бирмиләр?

Коновалов. Сугышка омтылучылар бер сез генә түгел бит. Карап өлгерә алмыйлар, күрәсең. Мәгез, бу рапортыгызны алыгыз.

Гөләндәм. Чын күңелдән булган соравымны исегездә тоту өчен, мин ул рапортның сезнең алдыгызда торуын теләр идем.

Коновалов. Бер рапортыгыз бездә бар, монсын артык дип саныйм.

Гөләндәм. Иптәш беренче ранг инженеры...

Коновалов (*бүлдереп*). Иптәш кече лейтенант! Сезгә дусларча әйтәм. Түземлерәк булыгыз, көтик инде. Көтик.

Гөләндәм кәефсезләнеп чыгып барганда, Ирина керә.

Ирина. Мидхәт Шакирович Чумарин.

Коновалов. Керсен.

Ирина китә. Мидхәт керә.

Мидхәт. Чакыруыгыз буенча килдем, иптәш директор.

Коновалов. Утырыгыз. Менә нәрсә, Чумарин, сез безнең ышанычыбызны аклый алмадыгыз.

Мидхәт. Бәлки, сез, иптәш директор, кайбер гайбәтләрне сәбәп итеп ала торгансыздыр. Ләкин минем гаебем юк. Аннан безнең штат турында сезнең фикерегез бар икән, мин аның белән килешәм. Мин бүген ОРС буенча 30 процентка кыскарту ясадым.

Коновалов. Ул гына түгел. Гомумән, сезнең эшегездә тәртипсезлек, намуссызлык, хәтта угрылык фактлары да юк түгел. Бу турыда документаль материаллар җитәрлек. Бронегыз үзегез беләнме?

Мидхәт. Әйе, үзем белән. Рәхим итегез. (*Кәгазь бирә.*)

Коновалов. Менә шушы приказ буенча бөтен эшегезне Дәүләтгәрәевкә тапшырырсыз.

Мидхәт. Мине кая?

Коновалов. Ансы минем эш түгел. Әмма мин сезне заводта тота алмыйм.

Мидхәт китә. Ирина керә.

Ирина. ОРС системасында эшләүче хезмәткәрләр килгәннәр.

Коновалов. Ничек килгәннәр?

Ирина. Алар өчәүләп сезнең кабул итүегезне сорыйлар.

Коновалов. Бөтенесен дә кабул итә алмыйм. Берсе генә керсен.

Ирина китә. Бәрбәрия керә.

Бәрбәрия. Иптәш директор, сезнең кушуыгыз буенча булса кирәк, Мидхәт Чумарин безгә кыскарту ясады. Илебезнең фашист ерткычларына каршы алып барган рәхимсез сугыш елларында бөтен хезмәт ияләребез зур фидакарьлек чыгышлары ясыйлар. Танк колонналары, самолет эскадрильялары оештыралар. Бу патриотлык агымыннан без дә читтә кала алмыйбыз. Илебезгә булган кайнар мәхәббәтебезне күрсәтергә телибез.

Коновалов. Эш нәрсәдә соң, сузмый гына әйтегез.

Бәрбәрия. Без, менә шушы исемлек буенча кыскартылырга тиешле булган ОРС хезмәткәрләре, сугыш беткәнчегә кадәр хезмәт хакы алмыйча эшләргә сүз бирәбез. Тиешле булган хезмәт хакларыбызны оборона фондына бүләк итәбез.

Коновалов. Рәхмәт, иптәшләр. Иртәгәдән таралар цехына эшкә чыгарсыз. Бүген сезне участокларга беркетерләр.

Бәрбәрия. Ничек ул таралар цехына?

Коновалов. Шулай: сугыш беткәнчегә кадәр заводта эшләргә сүз бирәбез, дисез бит.

Бәрбәрия. Без бит ОРС системасында, дибез.

Коновалов. Шулаймыни?

Бәрбәрия. Шулай шул. Башкача ничек булсын.

Коновалов. Менә ул ничек? Ватаныбыз таләп иткән изге бурычларны үтәү нигезендә бик күп кенә пенсиягә чыккан картларыбыз яңадан производствога кайттылар. Меңләгән хатын-кызларыбыз фронтка киткән ирләренең станоклардагы урыннарын алыштырдылар. Хәтта яшүсмер балаларыбызга кадәр ата-агаларының урыннарына килеп бастылар. Бөтен ил, барлык халкыбыз бердәм көч булып явыз дошманны җиңәргә булыша.

Бәрбәрия. Без дә тик ятмыйбыз. Без дә булышабыз.

Коновалов. Дөрес. Сәүдә хезмәткәрләре арасында да намус белән эшләүче иптәшләребез күп. Ләкин безнең ОРС системасында эшләүче кайбер хезмәткәрләр дәүләт милкен үзләренеке дип буташтыра башладылар. Шуның өчен мин аларның артыкларын ярдәмче цехка чыгарам. Шунда тәрбия алырлар.

Бәрбәрия. Без мобилизованный түгел, көчләп кушарга хакыгыз юк.

Коновалов. Кирәк булганда, мәҗбүр итәргә дә хакыбыз бар. Барыгыз!

Бәрбәрия китә. Почта тотып, Ирина керә.

Ирина. Киңәшмәгә чакырылган кешеләр бар да килделәр. (*Директорга пакет тапшыра*.)

Коновалов. Керсеннәр. (*Пакетны ертып укый*.) Әһә, Гөләндәм Ахметовнага җавап язганнар. Чакырыгыз үзен.

Ирина китә.
Зур папка тотып, Һарун, технорук, партия вәкилләре, цех начальниклары, инженерлар керә.

Утырышыгыз, иптәшләр.

Барысы да утырышалар, тышта гайре табигый мотор тавышы ишетелә. Бөтен кеше дикъкатен шуңа юнәлтә. Коновалов, тынычсызланып, тәрәзәгә бара. Һавага
карап эзләнә. Өстәл янына килеп звонок бирә, Ирина керә.

Һавада нинди лихач ул?

Ирина. Гөләндәм Ахметовна, диләр.

Тыштагы мотор тавышы тагын да көчлерәк һәм якынрак булып ишетелә, һәммәсе дә йөгереп тәрәзәгә баралар.

Коновалов. Кара, кара, нишли ул?

Һарун. Үлем элмәге ясый. Коточкыч, коточкыч!..

Коновалов. Ярый, посадкага китте. Кыю кыз! Энергия үзендә, ә? Ләкин лихачлык кирәккән нәрсә түгел. Кисәтеп сөйләшү кирәк булыр. Ярар, бу мәсьәләне калдырып торыйк.

Иптәшләр! Киңәшмәне ачарга рөхсәт итегез. Көн тәртибендәге мәсьәлә һәммәбезгә дә билгеле. Иптәш Арсланов һәм иптәш Ахмеровлар төзегән проект безнең завод өчен берничә миллион сумлык экономия би-

рәчәк. Һәм тизләтәчәк. Проектның техник ягы Москва белгечләре тарафыннан каралып расланган һәм Оборона халык комиссариатыбыз тарафыннан тизлек белән тормышка ашырырга безгә кушылды. Без бүген аны ничек итеп үзләштерү турында сүз алып барырга тиешбез. Беренче сүзне проектның авторларының берсе Һарун Юсупович Ахмеровка бирәбез.

Һарун папкасын ачып өстәл янына килә. Ирина керә.

Ирина. Иван Кузьмич, Арсланова сезнең чакыру белән килеп җитте. Керсенме?

Коновалов (*уйланып торганнан соң*). Әйдә керсен әле. Гафу итегез, иптәшләр. Кечкенә генә сюрприз.

Ирина китә. Гаепле сыман кыяфәттә Гөләндәм керә.

Коновалов. Иптәш Арсланова, беренчедән, һавада күрсәткән лихачлыгыгыз өчен сезгә миннән җитди кисәтү... Ләкин, иптәшләр, Арслановане тәбрик итә алабыз. Фронтка җибәрүне сорап язган рапортына уңай җавап килде. Арыслан йөрәкле Арсланова! Мин сезне биредәге иптәшләр, гомумән завод коллективы исеменнән патриотик адымыгыз белән тәбрик итәм. (*Барысы да кул чабалар.*)

Кадерле Гөләндәм Ахметовна!

Сезгә бездән изге теләк: фашистларны тар-мар итүдә батырлык күрсәтеп, туган җирдә бәхетле очрашуыбыз язсын!

Рәхмәт сезгә. Инде китсәгез дә ярый. Сезнең патриотик адымыгызны без республика газеталарында да чагылдырачакбыз.

Гөләндәм. Рәхмәт, иптәшләр. Миңа китәргә рөхсәтме?

Коновалов. Рөхсәт.

Гөләндәм китә.

Иптәшләр, киңәшмәне дәвам итәбез.

Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Вакыйга Албания таулары арасында бара. Әйләнә-тирә субтропик агачлар белән уратылган. Артта биек-биек таулар күренә. Бер якта палаткадан корылган кыр госпитале, икенче якта тау казып ясалган тирән куыш. Аның эчендә учак янып тора. Вакыт төн. Тышта җил-давыллап бозлы яңгыр ява. Куыш эчендәге учак тирәсендә Хәмидә белән Любица һәм берничә кыз җырлап утыра.

Караңгы төндә ягылган учак,
Янар ул һаман, сүнмәс беркайчан.
Янар ул шулай Көнчыгышыннан
Иреклек таңы сызылып атканчы.
Күк йөзендәге кара болытлар
Еракка таралып читкә акканчы.

Поподияс керә.

Поподияс. Исәнмесез, кызларым!

Кызлар (*урыннарыннан сикереп торып*). Сезгә саулык телибез, ата!

Поподияс (*чыланган өсләрен салып, ут янына утыра*). Хәлегез ничек, кызларым?

Хәмидә. Ашарга юк, доктор әфәнде.

Поподияс. Крестьяннар китермәделәрмени?

Любица. Мондый көндә кем йөрсен? Ике тәүлектән бирле коя да коя... Бүген бер яралы атыбызны суйдырып ашаткан идек, авыруларда эч китү башланды... Җитмәсә тагын тозыбыз да юк...

Поподияс. Әйе, хәлебез шәптән түгел... Мин дә, өч көн буе йөреп, отряд штабын туры китерә алмадым. Михайлович бандаларының ярдәме белән немец, итальян фашистлары төрле яклап һөҗүм итәләр. Бөтен җирдә каты сугышлар бара.

Хәмидә. Иртәгә безнең авыруларга бирерлек бернинди азыгыбыз юк.

Поподияс. Азык мәсьәләсе чиккә җитте. Менә-менә самолеттан ташларга тиешләр. Шуның өстенә медикаментлар җитешмәве...

Любица. Әйе, без бүген авыруларның ярасын марганцовка белән генә бәйләдек.

Поподияс. Марковичның хәле ничек?

Любица. Бик авыр. Температурасы һич төшми.

Поподияс (*ут яныннан торып*). Ярый, мин аны хәзер карармын.

Хәмидә. Доктор әфәнде, фронтларда ниләр бар икән?

Поподияс. Кызыл Армия, Сталинград операциясен тәмам итеп, немецларны көнбатышка кысрыклый. Сугышлар Харьков астында бара. Ләкин союзниклар Италиядә һаман бер урында таптаналар. (*Куыштан чыгып палаткага кереп китә.*)

Носилкага салынган авыруны күтәреп, ике партизан керә.

Партизан. Авыру китердек, кабул итегез.
Хәмидә. Кайдан?
Партизан. Ядран буеннан.
Любица. Ни өчен сез аны үз тирәгездәге госпитальләрнең берсенә салмадыгыз.
Партизан. Бу әфәнде аеруча игътибарга лаеклы кеше икәнлеген искә алып, аны ерак тылга чыгарырга кушканнар иде.
Любица. Хәмидә, авыруның температурасы югары. Доктор әфәндене чакырып кил.

Хәмидә китә.

Партизан. Аның хәле болай ук түгел иде. Бөркет тавын кичкәндә, бозлы яңгырга очрадык, аяк асты тайгакка әйләнеп качырларыбыз берничә җирдә егылды. Менә аның документы һәм докторыгызга хат. Таң атканчы ял итәргә урыныгыз булмасмы?
Любица. Палаткада урнаштырырлар.

Партизаннар китә. Хәмидә керә.

Хәмидә. Йоклыймы?
Любица. Юк. Аңын югалткан.

Авыру ыңгыраша.

Хәмидә. Саташа.
Любица. Тсс. Йөзенә караганда безнең ил кешесенә охшамый. Рус булса кирәк. Хәрби формасы да шуны әйтеп тора.
Хәмидә (*кулындагы документны укып*). Дәүран... Арсланов. Исеменә, фамилиясенә караганда, рус түгел. Кем соң сез?
Дәүран (*аңына килеп*). Су...

Аны аңламыйлар.

Ich will trinken... Trinken. Пить...
Хәмидә. Ах, pie... Эчәргә су сорый ул.

Су эчерәләр.

Дәүран. Danke... Спасибо.
Хәмидә. «Рәхмәт» дип әйтергә тели. «Ju falenderoj» дип әйтегез. Ну, ju falenderoj.
Дәүран. Ju falenderoj...
Хәмидә. Яхшы, уңыш бар. Сез кем? Россия, СССР?
Дәүран. Кызыл Армия офицеры. Мин хәзер кайда?.. Wo ich?
Любица. Немецча сорый: мин кайда, ди.
Хәмидә. Албания. Partizane.
Дәүран. Аңладым. Verstandlich.
Хәмидә. Сез урысмы? (*Бармагы белән төртеп.*) Рус?
Дәүран. Мин — татар.
Хәмидә. Татар. О-о! Ләкин сез татарга охшамыйсыз. Алар җәенке битле, кысык күзле, кәкре аяклы булалар.
Дәүран. Nicht verstahen. Мин — татар.
Любица. Сез соң ничек безгә килеп эләктегез?.. Аңламый. Туктагыз. Ул тагын аңын югалтты. Нишлибез инде? Безнең телне ул аңламый. Без — аныкын.
Хәмидә. Бездә ул озак булачак әле. Өйрәтербез. Моны мин үз өстемә алам.

Поподияс керә.

Поподияс. Ярасы кай җирендә?
Любица. Бөерендә, доктор әфәнде.
Поподияс (*карап*). Канын бик күп югалткан. Ярасы бик житди... Операция ясарга иде, ләкин ул аны бу хәлендә күтәрә алачак түгел. Кан кирәк.
Любица. Безнең, доктор әфәнде, бер кубик та каныбыз юк.
Хәмидә. Әгәр дә, доктор әфәнде, минем канымны алсагыз?

Любица. Яисә минекен.
Поподияс. Мөмкин түгел. Чөнки сез икегез дә моннан өч кенә көн элек бирдегез.
Любица. Документлары буенча каны беренче группаныкы.

Кан алу приборлары алып, Хәмидә белән китәләр.

Поподияс (*пакетны ачып укый*). «Доктор әфәнде, бу авыру аерым әһәмияткә лаеклы кеше. Россиянең сугышчан гадел бер халыкның улы. Сез аның гомерен саклап калырга тырышыгыз. «Әнвәр Хуҗа». (*Документын укып.*) 2 нче батальон командиры Дәүран Усманович... Кай җирләрдән килеп, Албания азатлыгы өчен канын агызган. Бичара кеше, син берни белми йоклыйсың. Сиңа ярдәм күрсәтүдән гаҗиз калган доктор йөрәгенең әрнеп тибүен тоймыйсың...

Хәмидә белән Любица керә.

Хәмидә. Доктор әфәнде, кан булды!
Поподияс. Каян ул?
Хәмидә. Минем запасым бар иде.

Кан җибәрү процедурасын үткәрәләр.

Поподияс. Хәмидә, ярты сәгать саен температурасын үлчәп торырсыз. Хәле яхшыланса, иртә белән операция ясарбыз. Любица, әйдәгез минем белән. Бердәнбер таблеткам бар иде, аңына килгәч, бу әфәндегә бирерсез.

Китәләр. Хәмидә Дәүранның өстенә яба. Учакны көчәйтеп яга. Кулына саз алып учак янына утыра, әкрен генә уйнап җырларга керешә.

Хәмидә. Әдрән диңгез, гүзәл диңгез,
Күп яуларны күргән диңгез.
Тау батыры Искәндәргә
Җан дәвасын биргән диңгез.
Әдрән диңгез, даулы диңгез,
Тирәләре таулы диңгез.
Хәлен җуйган син бөркеткә
Шифа бирсен изге диңгез.

Хәле китеп ава, Любица керә.

Любица. Хәмидә, Хәмидә, сезгә ни булды?
Хәмидә. Хәлем китте...
Любица. Доктор әфәнде, доктор әфәнде! (*Чыгып йөгерә.*)

Поподияс белән әйләнеп керәләр.

Поподияс. Хәмидә, сезгә ни булды?
Хәмидә. Башым әйләнә...
Поподияс. Палаткага кертеп салыгыз!..

Хәмидәне алып китәләр.

Кисәктән генә ни булды аңа?
Любица. Доктор әфәнде, гафу итегез, Хәмидә үз канын алып җибәргән иде.
Поподияс. Их сезне... Әйттем бит мин сезгә, ярамый, дидем...
Дәүран күзен ачып хәрәкәтләнә.

Хәлегез ничек, авыру?
Дәүран. Әйбәт, доктор әфәнде, мин үземне хәзер яхшы хис итәм...
Поподияс. Операциягә!.. (*Җиңнәрен сызгана башлый.*)

Башкалар операция хәзерлеген күрәләр.
Ут сүнә.
ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук. Көз көне, шулай да көньяк кояшның рәхимле нурлары бөтен җирне яктырта. Агач, үсемлекләрдә дә яшеллек аңкып тора. Бер читтә, зур агач
күләгәсе астында, Дәүран кровате, аның янында Хәмидә.

Хәмидә. Бүген ноябрьнең уны. Сезнең безгә килеп төшүегезгә төгәл өч ай булды. Ярагыз төзәлә төште. Шул арада без сезнең белән ике телне дә үзләштерергә өлгердек. Мин — татар телен. Ә, ул мөселман теле бит әле! Ә сез — албан телен.

Дәүран. Сез менә дигән укытучы булып чыктыгыз. Хәзер без бер-беребезне аңлауда шактый алга баруга ирештек. Йә, сөйләвегезне дәвам иттерегез. Шулай, утыз тугызынчы елны...

Хәмидә. Утыз тугызынчы елны итальяннар Албанияне басып алганда, мин Тирана шәһәрендә акушеркалар мәктәбендә укый идем. Алар килеп керү белән, безнең мәктәпне яптылар. Мин авылга китеп шифаханәдә фельдшерица булып эшли башладым. Көннәрнең берендә бу авыл халкының Әнвәр Хуҗа хәрәкәтенә катнашканы сизелеп, бөтен халкы Италиягә эшкә сөрелде, авыллары яндырылды. Бу вакыйгадан соң мин, сәясәткә катнашмау максаты белән Далмациягә кайтып, үз авылымда торырга теләгән идем. Ләкин, өйгә кайту белән, мин хәйранга калдым... Усташыйлар тарафыннан оештырылган мөселманнар белән христианнар арасындагы милли суешуда атам белән анам ерткычларча үтерелгән... Шуннан мин кырык беренче елны Әнвәр Хуҗа армиясенә барып язылдым.

Дәүран. Нинди зур фаҗигаләр аша...

Хәмидә. Тагын каһвә биримме?

Дәүран. Рәхмәт, Хәмидә, артык теләмим.

Любица йөгереп керә.

Любица. Шатланыгыз, әфәндем, хәзер генә радиодан тыңладык, Кызыл Армия Киев шәһәрен алган. Немецларның тагын бер кат арка сөяген сындырган.

Дәүран. Любица кадерлем, кил яныма, үбим үзеңне!

Любица. Соңыннан, әфәндем, соңыннан. Авыруларга белдерергә ашыгам! (*Палаткага кереп китә*).

Дәүран. Күрәсе иде, хәзерге минутта минем илем, Москва, Казан нишлиләр икән?

Хәмидә. Сез Москвада булганыгыз бармы?

Дәүран. Булу түгел, мин анда дүрт ел укыдым.

Хәмидә. Бик матур диеп сөйлиләр, дөресме?

Дәүран. Москва ул, Хәмидә, гүзәллек, нәфислек үрнәге, прогрессив культура, сәнгать, әдәбият үзәге, хаклык, дөреслек канунының нигезе. Сугыш бетеп, дөньяда тынычлык урнашу белән, мин сезне кунакка чакырырмын, барырсызмы?

Хәмидә. Ул минем күптәнге теләгем һәм хыялым, беренче мөмкинлек булу белән, мин анда булачакмын. Сезгә сорау бирергә мөмкинме?

Дәүран. Рәхим итегез.

Хәмидә. Сез, хәлегез авыр чакларда «Гөләндәм, Гөләндәм» дип саташа идегез, кем ул Гөләндәм?

Дәүран. Хатыным.

Хәмидә. Сез өйләнгәнмени?

Дәүран. Күптән инде, җиде яшьлек улым да бар. Ул хәзер үскәндер, зур малай булгандыр.

Хәмидә. Хатыныгыз да инженермы?

Дәүран. Түгел... (*Сүз таба алмый.*) Педагог...

Хәмидә. Димәк, укыта?

Дәүран. Юк иде... Хәзер, әлбәттә, укыта торгандыр...

Хәмидә. Сез арыдыгыз, ахры. Бераз ял итеп алыгыз.

Дәүран. Юк, Хәмидә, армадым... Сезнең белән миңа шундый күңелле... Сез янымда торсагыз, туган илемне сагынып җирсүемне онытам... Сез, әлбәттә, кешегә үз иленнән аерылып торуның никадәр газап икәнен белмисез. Мин элек тә үз Ватанымны өзелеп сөючеләрнең берсе идем. Ләкин аңар булган мәхәббәтемнең ни дәрәҗәдә көчле булуын мин элек белми йөргәнмен. Мин хәзер аның җәйге йомшак җилләрен, ягымлы кояшы, җәелеп аккан Идел елгасын, хәтфә төсле яшел болыннарын гына түгел, хәтта мин аның рәхимсез кышкы суыкларын, зәһәрле бураннарын, айлар буена пыскып яуган күңелсез көзге яңгырларын да өзелеп сагындым...

Хәмидә. Тизрәк терелегез дә аннан илегезгә китәрсез.

Дәүран. Хәмидә, миңа беркөн җырлаган «Язгы кар суы» көегезне җырлагыз әле.

Хәмидә. Кирәкми, әфәндем, сез җыр-музыкадан соң күңелсезләнәсез, уйга чумасыз. Авыру өчен ул ярамый.

Дәүран. Сезнең ул җырыгыз миңа бик ошый. Аңарда дәрт, шатлык шулкадәр көчле яңгырыйлар... Аны тыңлаганнан соң, каядыр очасы, талпынасы, бөтен тавышка кычкырасы килә!..

Хәмидә (*үзе уйнап җырлый*).

Биек тә биек Динар тавыннан,
Динар тавыннан, ай, тавыннан
Ага ыргылып язгы кар суы,
Язгы кар суы, кар суы,
Түгел ул аккан язгы кар суы,

Язгы кар суы.
Безнең йөрәкнең әрнеп ярсуы,
Әрнеп ярсуы.
Әйләнеп тиздән ачу көченә,
Ачу көченә.
Тупланып гомум халык үченә,
Халык үченә.
Китәрбез ташып, ярлардан ашып,
Ярлардан ашып.
Киң далаларны үтәрбез басып,
Үтәрбез басып.

Поподияс керә.

Поподияс. Хәмидә, хезмәткәрләрне җыйнагыз, сүзем бар.

Хәмидә. Яхшы, доктор әфәнде. (*Китә.*)

Поподияс. Йә, авыру, хәлегез ничек?

Дәүран. Яхшы иде, доктор әфәнде, тик бүген тагын миндә температура.

Поподияс. Сез аңар борчылмагыз, ул үтәргә тиеш... Менә нәрсә, хөрмәтлем, миңа хәзер генә баш штабтан хәбәр иттеләр. Сезне биредән озатабыз.

Дәүран. Кая, доктор әфәнде?

Поподияс. Хәзергә отряд штабына. Аннан үз илегезгә — Россиягә җибәрерләр.

Дәүран. Аның өчен сезгә рәхмәт, доктор әфәнде.

Поподияс. Сезнең авыруыгызның хәзерге стадиясе электр көченнән файдалануны, минераль сулар белән дәвалауны сорый. Үзегезгә мәгълүм — кыр госпитале шартларында аларны булдырырга мөмкинлегебез юк. Икенчедән, терелгәннән соң да сезне яңадан армиягә кайтарырга мөмкин булмас дип санамыйм. Барыннан да бигрәк Совет медицинасы, дөньяда иң алдынгы медицина буларак, сезнең авыруыгызны дәвалауда яңа методлар да табуын өмет итәбез.

Хәмидә керә.

Хәмидә. Доктор әфәнде, хезмәткәрләр җыелды. Сезне көтәләр.

Поподияс. Яхшы, Хәмидә.

Күктә самолет тавышы. Бар да һавага карыйлар. Төрле яктан хезмәткәрләр, авырулар кереп тулалар.

Бу нинди самолет икән?

Любица. Бу безгә, доктор әфәнде. Әнә ул безнең өстә әйләнә.

Паподияс. Утыру урынын күрсәтеп сигнал бирегез, сигнал!

Дәүран белән Хәмидәдән башкалар чыгып китәләр.

Дәүран. Хәмидә, кадерлем, мине тәбрик итегез.

Хәмидә. Нәрсә белән?

Дәүран. Отряд штабына, аннан үз илемә китүем белән.

Хәмидә. Кем әйтте?

Дәүран. Хәзер генә доктор әфәнде сөйләде. Йә, тәбрик итегез инде.

Хәмидә. Гәрчә минем өчен газап булса дамы?

Дәүран. Ничек инде ул газап?

Хәмидә. Юк, мин алай әйтергә теләмәгән идем... Әгәр дә сез китсәгез, татар телен өйрәнү теләгем туктылып калачак димәкче идем...

Поподияс белән Гөләндәм керә.

Поподияс. Сез алып китәчәк авыру биредә, менә ул.

Дәүран белән Гөләндәм бер-берсенә озак кына карашып торалар.

Дәүран. Гөләндәм!..

Гөләндәм. Дәүран!..

Кочаклашалар. Дәүран, хәлсезләнеп, Гөләндәмнең кулына ава.

Дәүран бәгърем!

Поподияс. Урынына салыгыз!..

Дәүранны илтеп яткыралар.

Камфара бирегез, камфара!..

Ут сүнә.

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук җирдә. Дәүран аңына килгәннән соң Гөләндәм белән сөйләшүләренең дәвамы.

Дәүран. Син соң ничек, Гөләндәм, мине алырга белеп килдеңме?

Гөләндәм. Һич юк. Без истребительләр эскадрильясы, Албания армиясенә сугыш припаслары китерүче транспорт отрядын озатучы булып килгән идек. Үз илебезгә кире очарга торганда гына, бер яралы рус офицерының кайдадыр кыр госпиталендә ятуын һәм аны һичкичекмәстән үзебезгә алып китәргә кирәклеген хәбәр иттеләр. Моны ишетү белән, күңелем нидер сизенгән кебек, йөрәгем ярсып тибә башлады. Иптәшләр арасыннан беренче булып мин теләк белдердем. Алар миңа бара торган җиремнең тау-таш арасы булуын, утыру мәйданының юклыгын әйттеләр. Шулай да мин үз теләгемнән кайтмадым. Очарга рөхсәт сорадым. Менә бервакытны һавага күтәрелдек, очабыз... Ләкин озак та үтмәде, каршыбызга бер немец пираты килеп чыкты. Аннан икенчесе, аннан өченчесе... Ике арада каты һава сугышы китте... Берсен бәреп төшердек, калган икесен кыйнап качырдык... Менә, Дәүран, болар бар да синең өчен. Тау-таш араларында яраланып ятучы билгесез бер кешебезнең язмышы өчен шундый кыенлыкларны кичтек.

Дәүран. Рәхмәт, бәгърем. Мин синең турында һәрвакытта да иң югары фикердә идем. Карале, безнең бу очрашу бөтенләй өйдәгечә... Минем улым Наил ничек, үсәме?

Гөләндәм. Ул хәзер зур инде, быел укырга керде. Әбисе аны шулкадәр яхшы карый. Тик син, Дәүран, бик ябыккансың.

Дәүран. Син мине моннан биш-алты айлар элек күрсәң, бөтенләй танымас идең. Өч ай буена хәрәкәтсез йөзтүбән капланып яттым. Бары тик мәрхәмәтле доктор, кадерле Хәмидә, Любицалар ярдәме белән генә шушы хәлгә ирештем.

Гөләндәм. Нинди Хәмидә ул?

Дәүран. Албан кызы, ул мине шулкадәр карады, бала бишеге яныннан аерылмаган ана кебек минем янымнан китмәде.

Гөләндәм. Тизрәк китәсе иде. Бу Витя нигә килми соң?

Дәүран. Нинди Витя ул?

Гөләндәм. Бортмеханигым. Самолет янында калган иде. Без аның белән аэроклубта бергә укыдык. Безнең шәһәр егете. Син аны белергә тиеш.

Дәүран. Хәтерләмим.

Гөләндәм. Әсгать Сәлимов синең белән киткән идеме әле?

Дәүран. Юк, ул беренче көнне үк алынды. Нигә, әллә ул?

Гөләндәм. Ул хәзер Советлар Союзы Герое.

Дәүран. Менә ничек! Ә Мидхәт нишли? Һаман шул урынындамы?

Гөләндәм. О... Синең дустың Мидхәт... Мидхәт түгел, кара елан ул. Штрафнойга озаттылар.

Дәүран. Ни өчен?

Гөләндәм. Булды инде, сөйләрмен әле. Бу Витя нигә килми соң? Дәүран, син миңа ничек итеп монда килеп чыгуыңны сөйлә әле.

Дәүран. Аны сөйләү өчен, Гөләндәм, «Мең дә бер кичә» экиятләрендәге кебек күп төннәрне тасма итәргә кирәк. Немецларның тылында диверсион эшне җәелдерергә безне десант итеп төшерделәр. Без анда тимер юл челтәренең үзәк урыны булган Украина туфрагында шактый гына күперләрне җимердек... Бик күп тимер юлларны сафтан чыгардык. Билгеле, көннәрнең берендә безнең эзгә төштеләр. Шуннан без, Карпат таулары арасына кереп, җирле партизаннарга кушылдык. Ләкин безгә анда да озак яшәргә туры килмәде, немецлар безне төрле яклап чорнадылар. Көннән-көн кыса бардылар. Ахыр чиктә утлы боҗраны өзеп чыгудан башка чарабыз калмады. «Йә үлем, йә яшәү» дип, дошман сафларына ташландык. Шулай итеп, без бик күп иптәшләрне корбан итү бәрабәренә чолганыштан котылдык. Шуннан соң берничә иптәшем белән Славениягә, аннан Хорватиягә, аннан менә бу якка килеп чыктык.

Хәмидә керә.

Хәмидә. Әфәндем, сезгә соңгы мәртәбә перевязка ясарга кушканнар иде.

Дәүран. Гөләндәм, таныш бул, мине үлемнән алып калучы кешеләрнең берсе Хәмидә ханым шушы инде.

Гөләндәм. Минем иремә күрсәткән ярдәмегез өчен рәхмәт сезгә.

Дәүранны җитәкләп, палаткага кереп китәләр. Самойлов белән
Поподияс сөйләшеп керә.

Поподияс. Хәзерге көндә безнең армиябез, партизанлык стадиясеннән чыгып, регуляр армия булу дәрәҗәсенә иреште. Менә шуның өчен дә безнең командованиебез төрле җирләрдә мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт

иткән аерым отрядларны билгеле районнарга туплау белән бергә, тау-таш араларындагы вак госпитальләрне дә бер төбәккә җыярга приказ чыгарды. Шул приказны үтәү йөзеннән без иртәгедән Бөркет чокырларына күчәбез.

Самойлов. Шулай да бит аны үзегез белән алырга мөмкин.

Поподияс. Юк шул. Безнең бу походыбыз икешәр километрлы биек тауларны, ыргылып аккан тирән суларны җәяү кичүгә бәйләнгән. Мәсьәлә анда гына да түгел, бәлки, без аны күтәреп тә илтер идек, ләкин, бая әйткәнемчә, биредә дәваларга мөмкинлегебез юк. Шулай киңәшеп карагыз, бәлки, берәр чара табарсыз. (*Палаткага кереп китә.*)

Гөләндәм чыга.

Гөләндәм. Витя, нишләп син анда бик озак?

Самойлов. Бер цилиндрыбыз эшләми.

Гөләндәм. Бөтенләйгәме?

Самойлов. Әйе, бөтенләйгә...

Гөләндәм. Димәк, безнең самолетыбыз...

Самойлов. Әйе, иптәш өлкән лейтенант, гади тел белән әйткәндә, өч кешене күтәреп оча алмый.

Гөләндәм. Юк, юк, бу мөмкин түгел! Докторның әйтүе буенча ике-өч көн эчендә аңа операция ясалмаса, аның гомере үлем белән чикләнәчәк. Аңлыйсыңмы, Витя, үлем белән...

Самойлов. Дөрес. Доктор миңа барысын да сөйләде. Ләкин бит цилиндрның берсе эшләми. Шуның өстенә питотрубкабыз бозылган. Барометрда көтелгән бозлы яңгырларны ерып, дошман зонасы аша кичүне уйларга да ярамый.

Гөләндәм. Мотор хәрәкәтен мин йөрәгемнең тибеше шикелле сизәм. Питотрубкасыз да очар идем, тик менә цилиндр гына... Нишләргә соң, Витя, киңәш бир.

Самойлов. Минем киңәшем бер генә. Икебезнең берсе биредә калырга тиеш.

Гөләндәм. Биредә?

Самойлов. Әйе, биредә. Шуның белән авыруны үлемнән алып калырга мөмкин. Башкача безнең чарабыз юк.

Гөләндәм. Яхшы, мин калам. Сез очарсыз.

Самойлов. Бу мөмкин түгел. Чөнки сез самолетның командиры, постны ташларга хакыгыз юк.

Гөләндәм. Алай булгач, нишләргә соң?

Самойлов. Биредә калырга миңа рөхсәт итегез, иптәш өлкән лейтенант!

Гөләндәм. Витя, кадерлем. (*Кочаклап үбә.*)

Поподияс чыга.

Поподияс. Авыруны чыгарырга мөмкинме?

Самойлов. Әйе, доктор әфәнде, мөмкин.

Любица белән Хәмидә, Дәүранны җилкәләренә кочтырып,
палаткадан чыгалар.

Дәүран. Мин сезнең ихтыярыгызда, Гөләндәм.

Гөләндәм. Хәзер, Дәүран, очабыз. Хәмидә, сезне бер генә минутка мөмкинме?

Хәмидә. Рәхим итегез.

Гөләндәм. Минем иремә күрсәткән хөрмәтегезне йоларлык минем янымда бер әйберем дә юк. Албания таулары арасында очрашуыбызның истәлеге итеп фотокарточка калдырам. Без аны Дәүран белән сугышка кадәр төшкән идек.

Хәмидә. Рәхмәт сезгә! Минем өчен ул зур хатирә булачак...

Гөләндәм. Артында Казандагы адресым да язылган. Сугыштан соң, бәлки, хат та язарсыз.

Хәмидә. Әлбәттә, язармын. Сугыштан соң, бәлки, мин укырга да барып чыгармын.

Поподияс. Хәмидә, сез биредә авырулар янында калырсыз. Без кунакларны озата барабыз.

Хәмидә. Яхшы, доктор әфәнде.

Дәүран. Хуш, Хәмидә, сау бул, кадерлем. Тормышыңда зур бәхетләр, чиксез уңышлар телим...

Хәмидәдән башкалар китәләр. Хәмидә фотокарточкага карап тора. Артта самолетның кузгалып киткәне, әкренләп югарылык алганы, тора-бара бөтенләй
ишетелмәслек булып еракка очып киткәне ишетелә.

Хәмидә (*җырлый*).

Чыгар-чыкмас канатларын талпып,
Очып киттең бала кош кебек,
Үткән көннәрем, кичкән төннәрем
Калды фәкать күргән төш кебек.

Самойлов кереп тыңлап тора.

Тик шулкадәр ерак араларны
Ничек инде очып үтәрсез?
Бозлы яңгыр, яшен кырларыннан үтеп,
Сау-сәламәт барып җитәрсез?

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Москвада Коноваловлар квартирасының ашау-эчү бүлмәсе. Әйләнә-тирәдә төрле ишекләр. Артта гөмбәзләп салынган зур түгәрәк балкон. Аның тәрәзәләре аша Кремль башнялары күренеп тора. Еракта — кояш баеганнан соң күктә була торган матур кызыллык. Пәрдә күтәрелгәндә, сәхнәдә беркем дә юк. Ачык ишеге белән тамашачыларга карап торган бүлмә эчендә телефон шалтырый, эчке бүлмәләрнең берсеннән Акулина Мироновна чыга, телефонга бара.

Акулина. Тыңлыйм. Кем сөйли? Сергей Петрович, исәнмесез! Юк, юк, бернинди хәбәр юк. Үзем дә аптырадым инде. (*Ишектә звонок.*) Гафу итегез, шалтыраталар. (*Барып ача.*)

Полковник чинында Дәүран керә.

Дәүран. Гафу итегез, Акулина Мироновна сез буласызмы?
Акулина. Әйе, мин булам. Сезне кем диеп таныйм?
Дәүран. Дәүран Арсланов.
Акулина. Гөләндәм Ахметовнаның ире?
Дәүран. Әйе, нәкъ шул, үзе.
Акулина. Әйдәгез, рәхим итегез.
Дәүран. Әбекәй, сез мине кичерегез. Иван Кузьмичның адресын Наркоматтан бирделәр. Үзе Германиядә, командировкада икән. Бәлки, бүген кайтып җитәр, диделәр. Шуны ишеткәч, барыйм әле дим... Күрәм, кайтмаган әле... Бик күрәсе килгән иде.
Акулина. Шулай булмый ни. Санга санап килүегез өчен рәхмәт. Шатлыклы көнебезгә туры килдегез, минем Ванюшамны...
Дәүран. Әйе, Акулина Мироновна, аларның заводларын «Ленин» ордены белән, Иван Кузьмичны Социалистик Хезмәт Герое исеме белән бүләкләгәннәр. Шул уңайдан менә мине дә чакыртып кайтардылар.
Акулина. Ә сезне ни сәбәп белән?
Дәүран. Сугышка кадәр мин дә бит шул заводта инженер булып эшләдем. Фронтка киткәндә, бер проект төзеп калдырган идем, алар аны тормышка ашырганнар. Инде хәзер, завод коллективын бүләкләгәндә, мине дә онытмаганнар.
Акулина. Менә бәхет дигәнең төрле яклап килә диең. Фронтта да биргәннәр, монда кайтып та аласыз.
Дәүран. Кайчан кайтачагы турында хәбәр дә юкмы?
Акулина. Юк шул. Кичәдән бирле «кайчан кайта» дип телефоннан сорыйлар. Ни телеграмма бирми, ни шалтыратмый. Гафу итегез, Гөләндәм Ахметовна белән бер җирдә хезмәт итәсезме?
Дәүран. Бер фронтта идек. Частьларыбыз аерым булса да, еш кына очраша идек.
Акулина. Ә хәзер?
Дәүран. Аның белән, Акулина Мироновна, бик зур бәхетсезлек булды бит... Ул Берлинны штурмлау көнендә югалды... Шуннан бирле аны бөтен җирдән эзлиләр, ләкин исәнлеген дә, үле икәнен дә белмиләр.
Акулина. Берлинны алу көнендә дисезме?
Дәүран. Әйе, Акулина Мироновна, Берлинны алу көнендә, 2 нче майда. Сталинградтан башлап, бөтен каты сугышларны кичкән сугышчының дошман оясын туздырган көнне генә һәлак булуы бик зур үкенеч...
Акулина. Бәлки, исәндер әле. Ышанырга кирәк.
Дәүран. Мин үзем дә шулай дип өмет итә идем. Ләкин... Акулина Мироновна, Иван Кузьмичны күрмичә мин китә алмыйм. Сездә дә көтеп утырып булмый. Бәлки, мин кайбер әйберләрне сездә калдырып торыйм? Ни әйтерсез?
Акулина. Әйберләрегезне менә бу бүлмәгә урнаштырыгыз.
Дәүран. Рәхмәт. (*Кереп китә.*)
Акулина. Дөрес булса, нинди зур кайгы... Ул бит гади йорт хозяйкасыннан данлыклы очучы булу дәрәҗәсенә ирешкән хатын...

Ишектә звонок тавышы, барып ача. Яхшы киемнән Хәмидә күренә.

Хәмидә. Мөмкинме?
Акулина. Рәхим итегез.
Хәмидә. Борчуым өчен гафу итегез. Сез миңа Арслановларның кайда икәнен әйтә алмассызмы?
Акулина. Сез кем соң?
Хәмидә. Мин Албаниядән.

Акулина. Албаниядән? Сезгә нигә алар? (*Әйберләрен калдырып, чәчен тарап Дәүран чыга.*) Иптәш полковник, сезне сорыйлар.

Дәүран (*танып*). Кадерлем Хәмидә!.. (*Йөгереп барып күрешә.*) Рәхим итегез, утырыгыз.

Хәмидә. Рәхмәт.

Акулина китә.

Дәүран. Укырга килдегезме?

Хәмидә. Хәзергә посольствода тәрҗемәче булып эшлим. Көзгә, әлбәттә, укыячакмын. Мин бик шат, сез тәмам терелеп, сау-сәламәт кеше булгансыз.

Дәүран. Аның өчен мин сезгә, доктор Поподияска, кадерле Любицага, Самойловка бурычлы. Тик алар хәзер кайда?

Хәмидә. Доктор Поподияс белән Любицалар сау-сәламәтләр. Тирана шәһәрендә торалар. Тик Виктор гына...

Дәүран. Ничек Виктор гына?

Хәмидә. Ул юк инде... Сездән аерылып калганнан соң, беренче мөмкинлек булу белән, аны Россиягә озатырга теләгәннәр иде, ул китәргә риза булмады, сезнең командованиедән рөхсәт сорап, Албания штабында эшләргә калды. Ләкин хыянәтчеләр 1944 елның апрель аенда аны атып үтерделәр.

Дәүран. Их, Витя, Витя...

Хәмидә. Мин сезгә үтенеч белән. Сез бит Виктор белән бер шәһәрдән. Казан күпләргә таныш инде ул. Миңа Викторның анасын табасы иде. Ул бичара карчык улын көтә торгандыр... Ләкин аның бердәнбер улы — минем кадерле ирем юк инде... Сез ул карчыкның миңа адресын табып бирсәгез, мин аңар хат язар идем.

Дәүран. Үкенечкә каршы, Хәмидә, мин аның адресын белмим. Шулай да бер-ике көннән Казанда булачакмын. Шунда аны эзләп табармын.

Хәмидә. Ул чагында сез миңә бу фотоны да алсагыз иде. Ул аның миңа мәңгелек истәлеге итеп калдырган улының фотосы. Мин аның исемен дә Виктор дип куштырдым.

Дәүран. Нинди матур малай, Викторның анасын ничек кенә булса да табармын.

Хәмидә. Рәхмәт сезгә. Ханымыгыз да үзегез беләнме?

Дәүран. Юк шул, Хәмидә, ул инде мәңгегә минем белән була алмас.

Хәмидә. Ничек алай була алмас?

Дәүран. Берлинны алу көнендә ул югалды...

Хәмидә. Югалды?.. Шундый батыр очучы?

Дәүран. Әйе. Хәмидә шундый батыр очучы, ләкин эш анда гына да түгел. Без бер-беребез белән мәңге бергә булырга тиешле дип туганбыз.

Хәмидә. Мин сезне дә исемнән төшергәнем юк, Кызыл Армия офицеры Дәүран...

Дәүран. Ә мин сезне оныттым дип уйлыйсызмы? Сез җырлаган җырлар һаман күңелемдә:

Әдрән диңгез, гүзәл диңгез,
Күп яуларны күргән диңгез.
Тау батыры Искәндәргә
Җан дәвасын биргән диңгез...

Хәмидә. Хәтерегез яхшы икән.

Дәүран. Ә менә бу сүзләрне хәтерлисезме: дуслык — migesi, җыр — konge, ә кунак — мусафир. Бусы безнеңчә диярлек, чөнки гарәптән кергән сүз... Ә нинди бөек вакыйга якынлаша? Бөек Җиңү — madh fitore!

Хәмидә. Яхшы әйттегез. Мин сезгә Lumteri телим. Ә бусы нәрсә?

Дәүран. Сез миңа бәхет телисез. Мин дә сезгә шуны ук.

Тышта машина тавышы.

Хәмидә. Гафу итегез, мине иптәшләрем чакыралар. Хушыгыз.

Дәүран. Хәмидә, мин сезне озата чыгам.

Китәләр.Тышта ишек артында кемнәр беләндер очраша. Дусларча исәнләшәләр, көлешәләр. Клавдия керә.

Клавдия. Исәнме, әнкәй!

Акулина. Клавдия, голубушкам... Погоннар тагып җибәргән, танырлык та түгел. Кем диләр инде сиңа?

Клавдия. Медицина хезмәте майоры.

Акулина. Нигә телеграмма бирмәдегез, каршы алырга төшкән булыр идем.

Клавдия. Без бит, әнкәй, самолетта очып килдек. Аннан безнең кунакларыбыз да бар әле. Аларны кайсы бүлмәгә куярбыз икән?

Акулина. Бездә урын җитәрлек, кемнәр алар?

Клавдия. Һарун Юсупович белән Хәсәнша Сафиечлар. Тиздән алар монда булалар. Ә Ваня Германиядән кайттымы инде?

Акулина. Юк шул, голубушкам. Көтәбез инде үзен. Наркоматка шалтыраткан идем, бүген Москвада булачак, дип әйттеләр.

Клавдия. Йә, әнкәй, сөйлә, ничек торасың?

Акулина. Әйбәт, Клавдюша, тик ялгызыма күңелсез иде. Кайчан кайтасыз инде?

Клавдия. Болай булгач, кайтмабыз инде, әнкәй, синең үзеңә безнең янга күчәргә туры килер. Чөнки Ваняның заводы бөтенләйгә анда кала.

Акулина. Шундый квартирабызны ташлап, Москвадан күчәргәме?

Клавдия. Безнең хәзерге квартирабыз моннан да яхшырак. Үзебезгә генә аерым йорт салдылар. Ишегалдыбызда газоннар, аллеялар... Шуларны карарга кеше юк. Мин көне-төне госпитальдә, Ваня заводтан бушамый. Син бит гөлләр, чәчәкләр яратасың. Җиләк-җимеш, яшелчә үстерер идең.

Акулина. Менә аларны яратам да яратам инде! Шулар өчен генә риза булмасам, Москваны һич тә ташламас идем. Тамара язамы?

Клавдия. Әйе, атна саен хаты килеп тора.

Акулина. Болай булгач, Тамара кайтыр, барыбыз да бергә җыйналырбыз, тик балакаем Валентин гына...

Клавдия. Ул һич тә истән чыкмый, әни.

Акулина. Онытып торам икән. Сезнең чәй эчәсегез килә торгандыр. Самавыр кайнатыйм әле.

Клавдия. Юк, әнкәй, чәйнек кенә куй.

Шаулашып, Һарун, Хәсәнша, Дәүран килеп керәләр.

Һу-у! Кунаклар килде, кунаклар. Әйдәгез, узыгыз. Әйберләрегезне менә бу бүлмәгә куя торыгыз. (*Бүлмәгә кереп китә.*)

Дәүран. Мин күрәм, Хәсәнша абзый, син бөтенләй үзгәргәнсең. Без хәзер синең белән кардәшләр. Гөлҗиһанга өйләнүеңне күптән түгел генә белдем. Ай, бу дөнья! Әллә инде яшь хатын яшәрткән.

Хәсәнша. Юк, энем, авыр еллар мине үзгәртте. Мине генә түгел, бик күп кешеләрне яңадан тудырып, яңадан яшәртте. Менә син, бүгенге полковник Дәүран идеңме? Гөлҗиһан апаң, Иван Кузьмич, Һарун, әйтик... Шушы сугыш чорында бар да үзгәрделәр, бар да язгы кояш нуры белән тармакланган агач яфраклары шикелле яшәрделәр, парлакландылар... Тик менә Гөләндәм генә. Шулай ук дөрес булыр микәнни?

Почтальон керә. Клавдияне чакыралар. Ул, журналга имзасын куеп,
почтальонны озата. Телеграмма текстын укыганны барсы да аягүрә басып тыңлыйлар.

Клавдия. «Молния» дигән. Вылетаю из Берлина. Точка. С близким человеком... Точка. Меня встречать не надо. Точка. В одиннадцать ночи будем дома. Точка. Целую, Ваня.

Барсы да шатланып, гөрләшеп алалар.

Клавдия. Бернәрсә дә аңламыйм. Нишләп мин аны каршы алырга тиеш түгел икән? Беркайчан да андый гадәте булмый торган иде.

Һарун. Ул сезне борчырга гына теләмәгән. Димәк, аны алып кайтучылар да була. Наркоматта машина кытлыгы булганы юк, Клавдия Петровна.

Дәүран (*сәгатенә карап*). Унбергә хәтле 4 сәгать вакыт бар әле. Нишлибез?

Хәсәнша. Мин Мәскәү циркына барыр идем. Безнең Җәлал Хаҗи Морат көрәшә микән?

Акулина. Цирк ерак ул. Аннан кайтып өлгермисең.

Дәүран. Ә мин менә нәрсә уйлыйм. Иван Кузьмичның кайтуы барыбыз өчен дә бәйрәм. Әзерләник шуңа. Егетләрчә.

Һарун. Менә бу дөрес. Клавдия Петровнаның эше муеннан. Аңа ярдәм итик.

Дәүран. Хәсәнша абыйны Акулина җиңги янында дежур калдырабыз. Калганнарыбыз — ауга! Кем нәрсә таба. Килештекме?

Клавдия. Анысы инде, өйдә дә запаслар булырга тиеш. Дөрес, минем дә чыгып керәсем бар.

Һарун. Сүз көрәштереп торасы юк. Дәүран абый, без бергә барабыз. Киттек.

Хәсәнша. Ә мин кемнән ким?

Акулина. Сиңа, чыннан да, өйдә утырасы гына. Ничек кинода әйтәләр: «Москва — большой, Казань — маленький». Мәскәүдә адашып куюың да бар.

Акулина белән Хәсәншадан башкалар чыгып китәләр.
Ут сүнә.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук Коноваловлар квартирасында бара. Пәрдә ачылганда, Хәсәнша белән Акулина Мироновна хәзерләнеп куелган зур өстәлнең

бер читендә ашап-эчеп утыралар.

Хәсәнша. Әйе, ул еллар, чыннан да, авыр еллар иде шул...

Акулина. Авырлыксыз җиңеллек булмый ул, Сафиеч. Шул авырлык, кыенлыклар безне көрәшкә тупла-ды. Кая, чәркәңне бир әле.

Хәсәнша. Күп булмас микән?

Акулина. Әйдә, кыланма инде, теге елны бик шәп сала идең бит.

Хәсәнша. Ул бит ул елны. Анда, аракы түгел, әллә нәрсә дә эчәр идең. Кунак булсаң, тыйнак бул, диләр бит.

Акулина. Әйдә, әйдә тот.

Хәсәнша. Ярый инде алайса, аш булсын.

Акулина. Шулай булсын. Ашап эч әле. Менә консервыдан, балыктан җитеш.

Хәсәнша. Ашыйм, ашыйм, Мироновна, кыстама. Мин бит ят кеше түгел.

Акулина. Сезнең теге урам рәтләндеме инде?

Хәсәнша. Безнең шәһәр хәзер сез барындагыча түгел, күрсәгез, аны танымассыз. Ә инде киләчәге тагын да шәбрәк. Менә шуларны күреп үлсәм ярар иде.

Акулина. Күрерсең. Син әле җен кебек.

Хәсәнша. Син мине элегрәк күрсәң иде. Илле яшькә кадәр сабан туйларында мәйдан тота идем. Менә син шуны әйт, ни өчен кеше анадан камил акыллы булып тумый икән дә башка җан ияләре шикелле тизрәк үсеп җитлекми икән. Уйлап карасаң, кешенең ярты гомере әрәмгә китә бит. Егерме яшькә кадәр ул кем? Дөньяның ачысын да, төчесен дә белгәне юк әле. Ата-ана кулында үсү, җитлегү дәверен уздыра. Барыннан да бигрәк гомеренең өчтән бер өлешен йоклап үткәрә. Докторлар, профессорлар нигә менә шул турыда уйламыйлар икән. Кая, тагын берне сал әле.

Акулина. Юк, артык бирмим. Исердең, әллә ниләр сөйли башладың.

Хәсәнша. Минме исердем?

Акулина. Исерми ни. Телең тасма кебек озын, өзеләсе юк, ахры.

Хәсәнша. Чыннан да исердем бугай шул. Бераз ял итеп алыйм әле. Төнлә йокламаган идем. Кайтып ятырга да өлгермәдем, Москвага китәргә дип чакырып алдылар.

Акулина. Бар әнә, диванга ятып тор.

Хәсәнша. Андый-мондый хәл була калса, уятырсың. Мин йокыга катырак, бөергә төртерсең, кытыклы кеше мин.

Акулина. Бар инде, бар, күп сөйләүчән кеше икәнсең.

Хәсәнша. Бетте. Шабаш. Мендәре йомшак, нәкъ минем Гөлҗиһан кебек икән.

Акулина. Гөлҗиһаның төшеңә керсен.

Хәсәнша. Һии, Гөлҗиһан төшемә керсә, мин аны ычкындырмыйм инде. Шабаш.

Ишектән, әйберләр күтәреп, Клавдия керә.

Акулина. Голубушка. Арып беткәнсеңдер. Күпме әйбер алган!

Клавдия. Өстәлне хәзерли башлыйк. Барысы да әзер булсын.

Акулина. Урамда ничек?

Клавдия. Урамда — халык, элеккеге демонстрацияләрдән дә болайрак. Дүрт ел диярлек газап чиккән кешеләр Бөек Җиңү көне турында ишетәселәре килә. Урамнарда кешеләр репродукторлар тирәсенә җыелган да шатлыклы хәбәрне менә әйтерләр, менә әйтерләр дип тилмереп көтәләр.

Дәүран белән Һарун төргәкләр белән кайтып керәләр.

Һарун. Иптәшләр! Шатлыклы хәбәр. Бүген төнлә Берлинда фашистлар Германиясенең капитуляция актына кул кую булачак. (*Барысы да кул чабалар, шатланышалар.*) Куегыз барлык радиоларны, гел эшләп торсыннар. (*Радио энтузиазмлы совет маршларын тапшыра.*)

Дәүран (*сәгатенә карап*). Хәзер Иван Кузьмичны гына көтәсе калды.

Ишектә звонок. Барысы да сискәнеп аякка басалар. Тантаналы рәвештә Коновалов белән Гөләндәм килеп керәләр. Шау-шулы очрашу.

Коновалов (*кочакланышулардан котылганнан соң*). Мин Дәүранга көтелмәгән, ләкин шатлыклы сюрприз ясарга булдым. Ул Гөләндәмне югалтудан Мәҗнүн була язган иде. Юк, мин әйтәм, шатландырып, таптаза егет ясыйм үзен.

Клавдия. Телеграммада искә алынган «близкий человек», димәк, Гөләндәм булып чыкты.

Коновалов. Ул! Дәүран, хатыныңны, гүзәл Гөләндәмне, сау-сәламәт килеш үзеңә тапшырам.

Хәсәнша. Ә мин «близкий человек» дигәнне озын сыйраклы, ак чәчле немец кызын эләктереп кайтасың дип торам.

Акулина. Тавык төшенә тары керә, диләр. Нигә син минем кызымны җәберләргә булдың әле?

Хәсәнша. Шаяртып кына, Акулина Мироновна, шаяртып кына. Бүген — бәйрәм кичәсе. Оҗмахка керү белән бер.

Һарун. Уйлап карасаң, син, Гөләндәм, борынгы риваятьтәге феникс кош кебек, янып көлгә әверелгәннән соң яңадан гүзәл җисемеңә кайткан кеше.

Дәүран белән Гөләндәм бер-берсенә карап туялмыйча яратышалар.

Гөләндәм. Өнемме бу минем, төшемме?

Дәүран. Өн бу, Гөләндәм. Бу безнең шатлыклы өнебез. Сөйлә, бәгърем, кайда идең, нишләп югалдың?

Гөләндәм. Тукта, туйганчы бер карыйм әле... Мин бит Наил белән сине шулкадәр сагындым, Дәүран, шулкадәр сагындым...

Дәүран. Ә син мине белсәң иде, Гөләндәм... Синең югалу вакыйгаңны ишетү миңа зур газапка әйләнде. Юкка гына мине Мәҗнүн белән тиңләмиләр. Ләйләсез калган Мәҗнүн булдым мин.

Клавдия. Дуслар, барыгызны да өстәл янына сорыйбыз. (*Утырышалар.*)

Гөләндәм. Әйе, фашизмны тар-мар итү көнебездә, союзникларыбыз итеп саналган кешеләр тарафыннан күрсәткән әшәкелекне көтмәгән идем. Шул биш-алты көн эчендә мин анда ниләр генә күрмәдем...

Коновалов. Гөләндәм Ахметовна, сөйләп бирегез үзләренә.

Гөләндәм. Безнең гаскәр тарафыннан Берлин шәһәре камалу белән, немецлар әһәмиятле архив материалларын, хыянәтче фашист башлыкларын, шулай ук кыйммәтле дәүләт байлыкларын һавадан союзниклар ягына ташый башлыйлар. Командованиедан безгә бер генә немец самолетын да Берлиннан чыгармау заданиесе бирелде. Без, әлбәттә, аларның күтәрелгән берсен юк итә бардык. Шушы сугышларның берсендә минем машинамны сафтан чыгардылар, яна башладым. Ахырында парашют белән сикерүдән башка чарам калмады. Җил-давыллы көн иде, мине Көнбатыш Германиянең кечкенә бер шәһәрчеге тирәсенә илтеп төшерде. Күп тә үтмәде, минем янга Америка офицерлары килеп җиттеләр дә үзләре белән машинага утыртып шәһәргә алып киттеләр. Мин инде союзниклар кулына эләктем дип шатланган идем. Ләкин эш алай булып чыкмады. Мине бер замокның подвалына төшереп яптылар. Анда инде миннән һәр көнне, бишәр тапкыр анкета тутыртып, нинди максат белән зонага төшүемне сорарга керештеләр. Аңлыйсыңмы, Дәүран, һәр көнне разведчиклары кереп, кешеләрне каушата, хәтта саташтыра торган психик һәм психологик алымнар кулланып, миннән үзләре теләгән информация алырга, шантаж методлары белән үз якларына аударырга тырышып карадылар.

Дәүран. Әйе, ул союзникларның нинди «дус» булулары безгә мәгълүм инде. Безнең кулыбыз белән утлы күмер көрәргә уйлаганлыклары да бик ачык... Ләкин сиңа бик авыр булган анда. Үзең генә булдыңмы? Ничек котылдың?

Гөләндәм. Бөтен хикмәт тә шунда. Безнең бер совет разведчигы шулай ук америкалылар кулына эләгә. Ләкин бу разведчик, званиесе белән майор, хәйләләп тегеләрнең рациясе аркылы 1 нче Белоруссия фронты штабына хәбәр җиткерә. Безнең хәл маршал Жуковка барып җитә. Ул фронт штабы начальнигы генерал Малининга задание бирә: тегеләргә ультиматум ясап, безне җибәрүләрен таләп итәргә. Тегеләр, җинаятьтә тотылган кешеләр буларак, гафу үтенергә мәҗбүр булалар. Шулай без майор Кондратенко белән фронт штабына кайтарылдык.

Дәүран. Шуннан?

Гөләндәм. Тагын бер могҗиза. Руста ул «везение» дип атала. Иван Кузьмичка үзенең эшләре белән фронт штабында чакны берәү минем турыда сорау бирә. Сез шундый летчикны беләсезме? Ул да бит, янәсе, Казаннан... Мин уйлыйм, бу инде безнекеләрнең дә мине тикшерүләре булгандыр...

Менә калганын Иван Кузьмичтан белеп була инде. Ул минем җәбраилем булып чыга.

Коновалов. Дөресен әйткәндә, бу ситуациядә минем әллә ни казанышым юк. Чыннан да «Смерш» начальнигы миннән сорый: «Арсланова дигән очучыны беләсезме?» Ничек инде мин «белмим» дип әйтим... Хәзер инде эш сугышчан характеристика, гомумән, идеологик позициясе нindирәк дигән сорауга күчте бу. Менә шунда инде мин аңа «ничек үземә ышана торган булсам, шул дәрәҗәдә Гөләндәм Арслановага да ышанам» дидем. «Смерш» начальнигы канәгать булып калды кебек.

Ә Гөләндәмнең полк командиры белән сөйләшүе бик җайлы барды. Мин аңардан бер атнага увольнение сораган идем, Гөләндәм белән горурланып, риза булды. Менә шул.

Гөләндәм. Кадерле Иван Кузьмич, Сез булмасагыз, без бергәләп шушы җылы, туганнарча якын мәҗлестә утыра алыр идекме? Һич юк. Шунлыктан бүгенге онытылмаслык бәйрәмебез көнендә беренче тостны Иван Кузьмич хөрмәтенә күтәрүне тәкъдим итәм.

Барысы да, ризалык биреп, бокалларын күтәрәләр.

Коновалов. Дуслар! Шушы минутларда Берлинда Германиянең капитуляциясе турында актка кул кую процедурасы әзерләнә. Бик тантаналы рәвештә АКШ, Англия, Франция вәкилләрен аэродромда каршы алдылар инде. Фашистлар Германиясе исеменнән фельдмаршал Кейтель билгеләнгән. (*Барысы да «о-о», «кызык булачак бу», «ниһаять, алар безгә тезләрен чүгәчәкләр» дигән тавышлар белән хуплыйлар.*) Актка кул кую төнлә белән башкарылачак. Бу бөек тарихи миссия белән җитәкчелек итү хаклы рәвештә маршал Жуковка йөкләнгән.

Хәсәнша. Берлин халкы ничек, Берлин халкы?

Коновалов. Берлин шаулый. Ә безнең завод миссиясе тәмамланганга күрә, безгә өйгә очарга әйтелде. Капитуляция актын биредә радио аша дуслар белән бергә ишетү тагын да күңеллерәк булачак дип санадык. Әйдәгез, тагын берәрне салыйк. Бусы Бөек Җиңү бәйрәме хакына. Бүгенге төнне йокламыйбыз инде.

Клавдия. Әйдәгез балконга, салют карыйбыз!

Утларны сүндереп, артка узалар. Еракта төрле төстәге утлар ташкыны. Кремль тирәләреннән бөркелеп күккә менәләр дә, төрле гүзәл фигуралар ясап, Москва
өстенә сибеләләр.

Гөләндәм (*Дәүранның кочагына кереп*). Менә ул безнең Ватаныбызга булган мәхәббәтебезнең җимеше! Менә ул халкыбызның данлы җиңеше!..

Дәүран. Дүрт ел буена җилкәләребездә күтәреп килгән авыр сугыш йөкләрен бу көннән селкеп ташлыйбыз да, башларыбызны югары күтәреп, шул сугыш нәтиҗәсендә туган яраларыбызны төзәтә башлыйбыз.

Гөләндәм белән Дәүранга башкалар кереп кушыла. Спектакльнең соңгы күренешендә катнашучылар, кулга кул тотынып, сәхнәнең алгы өлешенә
(авансценага) чыгалар.

Коновалов. Дусларым! Берничә сәгатьтән без барыбыз да үзебезне кешелек тарихының бөек борылыш катнашчылары һәм шаһитлары дип хис итә башлаячакбыз. Безнең данлыклы кораллы көчләребез, илебез халкы кешелек дөньясын һәлакәттән алып калды. Моннан соң безнең киләчәк үз кулыбызда булачак.

Гөләндәм. Ә мин шуны беләсем килә. Кеше хәтере үзгәрүчән. Әйе, коточкыч гарасатны без үзебезгә буйсындыра алдык, аны җиңеп чыктык. Узар айлар, еллар. Данлыклы армиябезнең илебез халкына, башка халыкларга ирек яулап биргәнен Бөек Җиңү бәйрәме искә төшерер. Ә киләчәктә яшь буыннарыбыз шуны тәкъдир итә алырмы? Бүген канга батып сугышкан, ләкин еллар үтү нәтиҗәсендә картаеп, бөкрәеп беткән кешеләребез хурлыклы сәдакаларга гына дучар булып калмасмы?

Акулина. 40 нчы еллар яшь буыны тылда һәм фронтта үзен һәртөрле мактауга лаеклы күрсәтте. Ә киләчәк яшь буыннар бу принципларга иярерлек булырмы?

Клавдия. Кеше табигате каршылыклы. Кайберәүләрне ул гомер-гомердән яшәп килгән аумакайлыкка, дөресне ялган, ялганны хак сүз дип, күккә чөяргә өйрәтте. Бөек Җиңүебездән соң андый холыклар кабатланмасмы?

Һарун. Әйе, безнең Бөек Җиңүебез алдагы буыннар алдына җитди таләпләр куя.

Без союзникларыбызның нинди мәкерле уйларда яшәгәнен беләбез. Киләчәктә алар безнең дәүләтне, аның абруен аяк астына ташлап таптау өчен бөтен көчләрен куячаклар. Һәм безнең пакь күңелле кешеләребезне саташтыру юлында кулларында булган иң көчле коралны кулланачаклар. Ул корал — Алтын Бозау, ягъни Акча!

Акча кешеләрне капма-каршы ике якка аера, аларны бер-берсенә дошман итә, берәүләрен буең җитмәслек дәрәҗәдәге әфәнде ясаса, икенчеләрен колга әверелдерә.

Хәсәнша. Егетләр! Әгәр илебездә яңадан канечкечләр хакимлек итә башлый икән, валлаһи, дип әйтәм, гаделлек урнаштыру өчен беренче булып коралга ябышачакмын. Шабаш!

Дәүран. Бүген бездә бәйрәм. Күктәге йолдызларга карагыз! Алар безне шатлыклы мизгелләрдә коендыра. Ә иртәгесе турында нәрсә әйтә алабыз?

Киләчәк буыннарыбызга васыятебез шул: уяу булыгыз!

Иң алга Дәүран белән Гөләндәм чыга.

Пәрдә.

## АЛСУ ТАҢ

**(Мин-минлек корбаны)**

*Драма биш пәрдәдә, ун күренештә*

КАТНАШАЛАР:

Мортаза — «Алсу таң» колхозы председателе.
Халидә — аның хатыны. Авыл советы председателе.
Айтуганов — авыл хуҗалыгы институты аспиранты.
Шакирҗан — башта авыл советы, соңыннан тикшерү комиссиясе председателе.
Гамилә — аның хатыны.
Җәмилә — аларның кызлары. Авыл советы секретаре.
Нурулла — «Алсу таң» колхозының завхозы.
Фәрдәнә — аның кызы, бригадир.
Зиннур — терлекчелек фермасы мөдире.
Гозәир — бакчачы, умартачы карт.
Алмазия — колхозчы кыз.
Мәфтуха — тол хатын, Мортазаның апасы.
Әптәлим — гармунчы егет.
Моракаев — райисполком председателе.
Җамали — пожар сарае мөдире.
Майҗиян — колхозчы хатын.
Кузнецов — прораб.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Авыл советы канцеляриясе. Тыштан керү, председатель бүлмәсенә узу һәм клубка чыгу өчен ишек. Сәхнәдә секретарь өстәле. Берничә шкаф һәм урындыклар. Стенада телефон. Пәрдә ачылганда, Җәмилә, әкрен генә җырлап, эшләп утыра.
Ишекне киң ачып, җитез адымнар белән Мортаза керә.

Мортаза. Җәмилә, Халидә апаңнан берәр хәбәр юкмы?

Җәмилә. Юк, Мортаза абый, бернинди дә хәбәр юк.

Мортаза. Нишләп кенә тора икән? Аларның укулары берендә бетәргә тиеш иде, бүген инде унысы.

Җәмилә. Бигрәк тә сагынгансың инде, Мортаза абый.

Мортаза. Син яшь әле, Җәмилә, семья тормышының тәмен белмисең... Башка районга билгеләп куярлар дип борчылам... Шакирҗан абзый бүлмәсендәме?

Җәмилә. Юк. Ул бүген «Чулпан» поселогына киткән иде.

Мортаза. Алай булса, мин аның бүлмәсенә кереп утырыйм әле. Язасы әйберләрем бар иде.

Җәмилә. Бар, бар, анда тыныч, беркем дә юк. (*Мортаза китә башлый, телефон шалтырый, Җәмилә трубканы ала.*) Шакирҗанова тыңлый. Әйе, бәхетегезгә, биредә. Мортаза абый, сине сорыйлар.

Мортаза (*трубканы алып*). Сораган кешегез телефонда. Исәнмесез, иптәш Саттарова, эшләр болай ничего, кичә икмәк йөкләмәсен бетердек, хәзер натурплата өчен сугабыз. Семинарга бер кешене? Фәрдәнәне җибәрербез. Җидееллыкны бетергән. Әйе, партия кандидаты. Ярый, мин хәзер үк чакыртып әйтермен. Хушыгыз. (*Трубканы куя.*) Җәмилә, үскәнем, миңа Нурулла абзый белән Фәрдәнә кирәк иде. Чакырып килче!

Җәмилә. Ярый, Мортаза абый. Шуннан берьюлы өйгә кереп капкалап та алырмын. Син монда буласыңдыр бит әле?

Мортаза. Булам әле, булам. Әйтәм бит, язасы әйберләрем бар.

Җәмилә китә. Демобилизованный солдат киеменнән Зиннур керә.

Зиннур. Мортаза абый, мине сорап фермага баргансың икән.

Мортаза. Әйе, барган идем, көтүдә, диделәр. Утыр әле. Менә нәрсә, үскәнем, син анда нәрсә бутыйсың?

Зиннур. Ничек инде «бутыйм»?

Мортаза. Кичә үзегезнең ферма җыелышында, хатын-кызлар алдына чыгып, идарә турында лыгырдагансың.

Зиннур. «Лыгырдамадым», эштәге кимчелекләр турында сөйләдем. Нигә, ярамый әллә?

Мортаза. Ярый, бик ярый... Ләкин, энем, һәрнәрсәнең чиге, үлчәве бар. Беркөнне партия җыелышында сөйләдең, шул җиткән иде. «Безнең идарә ферма эшенә әһәмият бирми», — диюең политик яктан дөрес түгел.

Зиннур. Ә мин әйтәм, дөрес, дим. Һәм хәзер дә шуны кабатлыйм. Безнең ферма колхозга күпме табыш бирә. Ә шулай да электричество юк. Ул булмагач, водопровод кертеп булмый. Механизация үткәрә алмыйбыз.

Мортаза. Булыр әле, Москва шәһәре дә берьюлы төзелмәгән. Хәлдән килгәнне әле дә эшләп барабыз. Сугыштан соң йөз баш атка яңа абзарлар салдык. Ике автомашина алдык. Тимер ходлы арбалар кайтарттык. Быелтыр клуб җиткердек. Быел менә идарә йорты салып ятабыз. Шулай, энем, моннан ары алай сөйләнеп йөрисе булма! (*Бүлмәгә кереп китә.*)

Фәрдәнә керә.

Фәрдәнә. Зиннур, Мортаза абый бирedәме?

Зиннур. Бирedә...

Фәрдәнә. Нишләп болай күңелсез?

Зиннур. Мортаза абый белән сүзгә килештек. Кичәге чыгышым өчен ачулана.

Фәрдәнә. Син анда, чыннан да, катырак бәрелгәнсең, ахры, безнең әти дә дулап йөри.

Зиннур. Мин дөресен сөйләдем. Терлекчелек мәсьәләсендә иске карашлар белән яшәргә ярамый. Алар һаман да фермага доходлы статья итеп кенә карыйлар.

Фәрдәнә. Әйе, соңгы вакытта бер дә тәнкыйть яратмый башлады шул.

Зиннур. Үзегез гаепле. Булган кимчелекләрен әйтмичә узындыргансыз.

Фәрдәнә. Без нишли алабыз? Районда мактыйлар бит. Райисполком председателе Моракаев белән бер кашыктан ашыйлар.

Нурулла керә.

Зиннур. Исәнме, Нурулла абзый!

Нурулла (*ишетмәгәнгә салынып*). Кызым Фәрдәнә, Мортаза абыең мондамы?

Зиннур. Бирedә, Нурулла абзый, исәнме, дим.

Нурулла. Ишетмәдем. Колакка катылана башладым...

Зиннур. Сизәм, кичәге чыгышымны яратмагансың.

Нурулла. Нишләп яратмаска, бик яраттым... Тик, энем, хатын-кыз алдында чыгып әтәчләнгәнче, минем янга килеп: «Нурулла абзый, фермага бидоннар, чиләкләр алып кайта алмассыңмы?» — дип сорасаң, мөрәҗәгать итсәң, ягъни мәсәлән, каршы килер идемме? Һич юк, әлбәттә.

Зиннур. Алай, син дигәнчә «мөрәҗәгать» итәргә мин синнән бурычка товар сорамыйм. Син аны мин әйтмичә дә үзең алырга тиеш. Чөнки ул синең хезмәтең. Мин сиңа берничә тапкыр әйтеп карадым. Язып та бирдем, нәтиҗәсе булмады. Менә шуннан соң инде җыелышка чыгып әйтергә туры килде.

Нурулла. Юк инде, энем, сәнәктән көрәк булдың шул. Атаң мәрхүм дә шулай иде, җыен булдымы, лар-лар килеп тавыш күтәрә иде.

Зиннур. Без шулай инде, туры әйтергә яратабыз шул. (*Китә.*)

Нурулла. Ишеттеңме, атаң белән ничек сөйләшә? Ә син, кайчан карама, аның белән чыш та пыш!

Фәрдәнә. Куй инде, әти, юкны сөйләмә...

Нурулла. Бер дә юкны түгел, барын да күреп торам. Аның белән синең бер сүзең дә булмасын. Армиядән кайтканнан бирле миңа каныкты.

Бүлмәдән Мортаза чыга.

Мортаза. Менә нәрсә, Фәрдәнә, Казанга алдынгы бригадирлар семинарына бездән бер кеше сорыйлар, мин сине җибәрергә булдым.

Фәрдәнә. Рәхмәт, Мортаза абый.

Нурулла. Рәхмәтен рәхмәт тә, кызым, ни әйтер бит Кара Әхмәт дигәндәй, балаларны кем карар?

Мортаза. Озакка түгел бит, Нурулла абзый, бер генә айга.

Нурулла. Шулай да, иптәш Мортаза, безнең Фәрдәнәнең белеме болай да җитәрлек, җидееллык бетерде. Бездә әле барлы-юклы белем белән дә бригадир булып йөрүчеләр бар. Менә шуларны җибәрергә иде.

Мортаза. Бу семинарга укымышлы кешеләрне сорыйлар. Анда алган белемнәре белән мондагы бригадирларны да тәрбия итәрлек булсын, диләр.

Фәрдәнә. Китәм, Мортаза абый. Бер айга, әти, балалар янына Хупҗамал түтәйне алып кайтырсың. Кайчан юлга чыгарга?

Мортаза. Бүген үк китәргә. Эшләреңне Раушаниягә тапшырырсың.

Фәрдәнә. Мин алайса кайтып җыеныйм.

Мортаза. Бар, бар. Тик кара аны, анда матур егетләр күп булыр, кылдый-былдый буталма, сабагыңны яхшы укы.

Фәрдәнә. Кайгырма, Мортаза абый, «Алсу таң» йөзенә кызыллык китермәм. (*Китә.*)

Мортаза. Кызың бик әйбәт, Нурулла абзый...

Нурулла. Атасына охшаган.

Мортаза. Үзе уңган, үзе матур да... Мондый кызга өйләнгән егет бәхетле ир булыр...

Нурулла. Кыз әйбәт... Тик менә теге Зиннур аның артыннан чаба.

Мортаза. Чапса, әллә начар егетме?

Нурулла. Бик шәптән дә түгел шул. Кичә ферма җыелышында безне ничек тәнкыйтьләгән.

Мортаза. Күрәсең, яхшы иттереп эшли алмыйбыз әле. Чыннан да ул хаклы, фермага барып карап йөргән идем, савыт-сабалар бик тузган. Район сельпосына шалтыратып та карадым, андый товарлар хәзергә бездә юк, диләр. Сиңа да бүген шул савыт-сабаларны алырга Казанга китәргә туры килә.

Нурулла. Син кушкач, Казанына гына түгел, Мәскәвенә китәргә дә риза.

Мортаза. Аннан мин җәй көне киңәшмәгә баргач, Министрлар Советында, беренче мөмкинлек булу белән, легковой машина бирергә вәгъдә иткәннәр иде. Шуны кереп бел әле. Алып кайта алсаң, шәп булыр иде, мин әйтәм, ә?

Нурулла. Сөйләмә дә инде, иптәш Мортаза, бөтен районның борынына сугар идек. Буш вакытларда Моракаев кебек куян атарга чыгар идек.

Мортаза. Юк, мине ул кызыктырмый. Машинаның тәме башкада... Шофер янына утырасың да, башыңны артка ташлап, районга китәсең... Юлда әллә ничаклы авылларны үтәсең. Барсының да күзе сиңа төбәлгән була. «Алсу таң» председателе Шәфигуллин килә»,— дип, юл биреп калалар...

Нурулла. Шунда инде яныңда хатының да булса, бәлфәраз...

Мортаза. Хатын дигәннән, Нурулла абзый, минем Халидә кайтмый бит. Казанга барып җитү белән мәктәпләренә кереп бел әле, нишләп ята икән.

Мәфтуха керә.

Мәфтуха. Мортаза, четовод Миргалим, менә бу кәгазьләргә кул куйсын, ди, районга җибәрәсе бар, ди.

Мортаза (*кәгазьләрне карап*). Банкка поручениеләр икән, бераз көтеп тор, мин хәзер. (*Китә. Бүлмә ишегенә җиткәч, туктап.*) Апа, өйгә әйберләр кирәк дип аптырата идең, әнә Нурулла абзыйга куш, алып кайтыр. (*Кереп китә.*)

Мәфтуха. Нәрсә, Нурулла абзый, Казангамыни?

Нурулла. Әйе, Мәфтуха, фермага савыт-сабалар алырга барам. Сезгә нәрсә соң?

Мәфтуха. Безгә дә шул инде, зуррак кәчтрүл белән аш тәлинкәләре кирәк. Кеше килгәндә аш кашыкларыбыз да җитешми. Аннан чыбылдыкка матырҗа, үземә эрзин батинка, ит тартырга машинка. Патефонга инәләр. Пәлтәмә зур төймәләр.

Нурулла. Тукта, тукта, күпкә китте бу, язып алыйм әле.

Мәфтуха. Аннан әйбәт кенә кыл иләк, ике таба, пар чиләк, биш буй шпалир кирәк.

Нурулла. Бу әйберләр районда да тулып яталар.

Мәфтуха. Район район инде ул, Казанда сайлап алырга була. Зинһар, оныта күрмә инде. Кичә сезнең очка барган идем, өеңне бик шәп салгансың икән. Хөршидәң генә күрә алмады, мин әйтәм.

Нурулла. Әйе, көтмәгәндә үлеп китте шул...

Мәфтуха. Өйләнергә уйламыйсыңмы?

Нурулла. Балалар күп бит, Мәфтуха, дүрт үксезнең өстеннән кем килер икән.

Мәфтуха. Ник килмәсен? Фәрдәнәң җиткән кыз инде, аннан кечесе дә зур булган. Берәр акыллырак кеше туры килсә...

Нурулла. Ул турыда уйлаганым юк әле. Минем башта бүтән кайгы бар... Әнә шул өй турында бик күп сөйлиләр. Нурулла абзый ферма өчен чиләкләр алмый, бидоннар табып китерми, ә үз өенең түбәсен калай белән яптырды, дип әйтәләр, ди.

Мәфтуха. Кем?

Нурулла. Зиннур, әлбәттә.

Мәфтуха. Яптырсаң, урлап алмагансыңдыр ич.

Нурулла. Аллам сакласын. Егерме ел хуҗалык эшендә йөреп, бер тиенлек хыянәтем чыкканы юк.

Мәфтуха. Шулай булгач, нигә бәйләнә?

Нурулла. Нишлисең? Үзара тәнкыйть заманы диләр дә яралар да салалар. Ярый, аны калдырыйк әле. Синең йомыркаң белән маең булмасмы?

Мәфтуха. Булыр иде дә, син бик очсыз аласың.

Нурулла. Очсыз дип, базар бәясен бирермен инде. Казанга бару расходларын капларга миңа да бераз кирәк бит.

Бүлмәдән Мортаза чыга.

Мортаза. Менә, апа, Миргалимгә илтеп бир, хәзер үк районга җибәрсен.

Мәфтуха. Чәй куйсам, кайтырсың микән?

Мортаза. Юк әле. Монда эшләрем бар.

Нурулла белән Мәфтуха китә. Мортаза телефонга барып шалтырата.

Райисполком председателе Моракаевны бирегез. Җавап кайтармый? Ул чагында квартирын алыгыз. Ни хәл, Исмәгыйль, исәнме? Нишләп өйдә утырасың? Яңа гына кайтып кердең?

Ишекне әкрен генә ачып, Халидә керә, Мортазаның телефонда сөйләшүен тыңлап тора.

Эшләр әйбәт иде, малай, тик менә минем хатын Халидә кайтмый бит. Сездә районда күренмәдеме? Юк, дисең алайса? Сагындым шул, бик сагындым...

Халидә, аяк очлары белән генә килеп, Мортазаның күзләрен тота.

Җибәр әле, шаярма, күрәсең җитди мәсьәлә турында сөйләшәм. Кем бу, шәйтан алгыры?! (*Халидәнең кулларын күзеннән ычкындырып әйләнә*.) Халидә акыллым, бу син?! (*Кочагына ала*.)

Халидә. Кысма, кысма ул кадәр, үтерәсең...

Мортаза. Менә бит ул минем көткәнем.

Халидә. Җибәр, кеше килеп керүе бар. (*Ычкына*.)

Мортаза. Нигә телеграмма бирмәдең?! Районнан да шалтыратмадың.

Халидә. Искәрмәстән кайтып, кызык итәсем килде.

Мортаза. Яхшы кызык итү... Мин монда әллә ниләр уйлап бетердем. Йә, сөйлә, безгә билгеләделәрме?

Халидә. Юк шул, Мортаза, районда калдыралар.

Мортаза. Ә без сине үзебезгә кайтасың дип көтә идек...

Халидә. Мин үзем дә шулай дип тора идем дә, ләкин иптәш Дәүләтшин, райкомда пропаганда бүлегендә эшләрсең, ди. Димәк, минем районда эшләвем сиңа ошамый?

Мортаза. Ошый, бик ошый... Синең үсүең, дәрәҗәгә менүең минем өчен мәртәбә, конешно... Тик син безнең семья мәсьәләсен куярга тиеш идең.

Халидә. Куйдым. Иптәш Дәүләтшин сине дә районга алабыз, ди.

Мортаза. Мәшһүр хатынның ире итепме?

Халидә. Юк. Алар сиңа нинди дә булса хуҗалык эше бирерләр.

Мортаза. Берәр учреждениедән завхозлыкнымы? Рәхмәт! Мин авылдан китмим. Сиңа да рөхсәт бирмим. Хәзер үк Дәүләтшинның үзе белән сөйләшәм. (*Телефонга барып шалтырата башлый*.)

Халидә. Ха, ха, ха!.. Кирәкми, Мортаза, шалтыратма. Нәкъ син дигәнчә булды. Мине авыл советына председатель һәм партия оешмасына секретарь итеп тәкъдим итәргә булдылар.

Мортаза. Нигә соң аны башта ук шулай димәдең!

Халидә. Миңа булган мәхәббәтең сүрелмәдеме икән дип сынап карадым.

Мортаза. Юләр син, Халидә... Сиңа булган мәхәббәтем сүреләме соң? Минем белән бергә ул кабергә дә керәчәк. Димәк, без яңадан бергә... Мин колхоз председателе, син авыл советында, партоешмада, бөтен эш, бөтен власть бездә — Шәфигуллиннар кулында...

Халидә. Минем әле сайланасым бар.

Мортаза. Ул турыда сүз дә булырга мөмкин түгел. Барысы да сине көтә иде. Шакирҗан абзый, мин картайдым инде, эшли алмыйм, дип гариза биргән иде, Халидә кайтканчы гына чыдарсың әле дип калдырдылар.

Халидә. Эшләрең ничек бара соң?

Мортаза. Минем эшләрем кайчан начар булганы бар? Быел да икмәк тапшыруда беренче квитанцияне мин алган булсам, районда беренче булып тутыручы да мин булдым. *(Халидәне кочагына алып, тәрәзәгә таба бара.)* Әнә күрәсеңме? Нинди идарә йорты салдырам? Өске катында зур утырышлар залы, үземә кабинет. Секретарь алам, звонок куйдырам.

Халидә. Алары нигә?

Мортаза. Шәһәр культурасын, шәһәр техникасын үзләштерәбез. Аскы катында счетовод, завхоз, бригадирларга аерым бүлмәләр. Шәп бит, ә?

Халидә. Начар түгел, әлбәттә... Быел өлгерәме соң?

Мортаза. Өлгертәм. Материалларына иске идарә йортын сүттереп ташлаткан идем, менә күрәсеңме, үзем хәзер, йортсыз йомран булып, авыл советында эшләп утырам.

Халидә. Узган җәй кайтуымда гидростанция салу турында сүз кузгаткан идек, шул хакта берничә кат хатларым аша сорап карадым, җавап бирмәдең. Ул мәсьәлә нишләде соң?

Мортаза. Акча күп кирәк булгач, калдырып торырга булдык.

Халидә. Электричество булмагач, ферманы механизацияләү планыгыз да үтәлмәгәндер инде?

Мортаза. Билгеле, шулай.

Халидә. Клубыгыз ничек, эшлиме?

Мортаза. Юк әле. Быел иген бик үкереп уңды бит, куярга урын юк. Вакытлыча клубка тутырдык.

Халидә. Радиоузел да, ясле дә салынмаган.

Мортаза. Аларны инде киләсе елга дип торабыз, ләкин шатлыклы хәбәр дә бар: легковой машина алам!

Халидә. Беренче чиратта ул кирәк микән? Мин сине сынап-сынап торам да, Мортаза, гаҗәпләнәм. Син ничектер үзгәреп куйгансың кебек.

Мортаза. Тукта әле. Мин дә сине тыңлап торам-торам да прямо таңга калам. Сине анда үзгәртеп җибәргәннәр.

Шакирҗан, Зиннур һәм Җәмилә керә.

Зиннур. И... Халидә апа кайткан...

Шакирҗан. Исәнме, Халидә!

Халидә. Бик яхшы, Шакирҗан абзый, үзең нихәл соң?

Шакирҗан. Картларча, бер көе генә йөрибез шунда.

Җәмилә. Халидә апа, Мортаза абый сине сагынып үлә иде.

Халидә. Ай-һай, шулай микән?

Җәмилә. Ихлас әгәр шулай, һәр көнне: «Халидә апаңнан хәбәр юкмы»,— дип, миннән сораша иде.

Шакирҗан. Йә, Халидә, кайчан миннән эшне аласың?

Халидә. Белмим, Шакирҗан абзый, халык ни әйтер бит әле?

Шакирҗан. Ул турыда уйлап та карама, син бит инде бер кат сайланган кеше, безнең авыл советының депутаты.

Зиннур. Ул мәсьәлә инде, Халидә апа, райкомда да хәл кылынган.

Телефон шалтырый.

Мортаза (*трубканы алып*). Борма Тау авыл советы. Шакирҗан абзый, сине райком инструкторы Хәлилов сорый.

Шакирҗан (*трубканы Мортаза кулыннан алып*). Әйе, мин булам, иптәш Хәлилов. Исәнмесез! Ничек? Партиянең мөһим карарлары бар? Алай икән, бик әйбәт, иптәш Хәлилов, тыңларбыз. Хәзергә хушыгыз. (*Трубканы куя.*) Иптәшләр! Безгә хәзер бөтен партия членнарын, комсомолларны һәм агитаторларны җыярга кирәк булыр. Ярты сәгатьтән радио аша КПСС Үзәк Комитетының Сентябрь Пленумы карарлары турында информацион белдерү булачак!

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук — авыл советы канцеляриясендә бара. Пәрдә ачылганда, клубтан Җәмилә чыга. Тыштан, кызлар ияртеп, Алмазия керә.

Алмазия. Җәмилә, кече учакка ут капкандай, Мортаза абый безне нигә чакыртты икән?

Җәмилә. Клубны җыябыз, кызлар.

Алмазия. Артистлар киләмени?

Җәмилә. Юк, Алмазия, бүген безгә Сентябрь Пленумы карарлары турында доклад сөйләргә Казаннан бер иптәш килә, ди. Менә шул уңай белән клубны җыеп бизибез. Әйдәгез, кызлар, эшкә! (*Клубка кереп китәләр.*)

Чиләк тотып, тыштан Мәфтуха керә. Тирләрен сөртә-сөртә, клубтан Нурулла чыга.

Нурулла. Кая болай, Мәфтуха?

Мәфтуха. Менә Мортаза клуб идәнен юарга җибәрде.

Нурулла. Нишләп алай? Сине эшкә йөртми иде бит.

Мәфтуха. Халидә килен яңа закон чыгартты. Бөтен кешегә хәзер эшләргә, диләр бит.

Нурулла. Әйе, ул хатын хатын гына булмады. Безнең башка бәла булыр, ахры. Бер ай эчендә авылның астын өскә китерде. Менә мин бүген керфек тә какмаган. Төн буена клубтагы ашлыкларны амбарларга ташыттым. Кичә районда сельпода эшләүче Мөбарәкшаны күргән идем, райисполком сессиясендә колхозыгызны шундый итеп тәнкыйтьләде... Таң калып утырдык, ди.

Мәфтуха. Өйдә көне-төне сүзгә килүләре аз иде, инде анда барып та кеше көлдергән икән.

Нурулла. Электән дә алар шулай торалар идеме?

Мәфтуха. Кая ул... Бер-берсенә авыр сүз дә әйтешкәннәре юк иде. Халидә килен Казаннан кайту белән әллә нәрсә булды үзләренә. Мортаза үзе гаепле, укырга җибәрмә, дидем мин аңа, тыңламады. Безнең хатын-кызга ирек бирсәң, шулай була ул.

Нурулла. Анысы инде, Мәфтуха, Халидәгез электән дә бик коры хатын иде.

Мәфтуха. Шулай да алай бәйләнчек түгел иде.

Нурулла. Озын гомерле булыр, әнә үзе килә. (*Икесе ике якка китәләр.*)

Клубтан Җәмилә чыга. Тыштан Халидә керә.

Халидә. Җәмилә, син хәзер бөтен комсомолларыңа хәбәр ит, эшли торган җирләрендә халыкка бүгенге докладның әһәмияте турында аңлатсыннар һәм бөтен кешенең җыелышка килүен тәэмин итсеннәр. Аннан иртәгә мине райком бюросына доклад белән чакыралар. Менә шушы сораулар буенча миңа материаллар әзерләп куярсың. (*Урамда гармун тавышы.*) Бу кем, көпә-көндез урамда гармун уйнап йөри?

Җәмилә. Безнең авылда бер генә инде ул — Әптәлим. Кичә «Чулпан»нарга туйга киткән иде, хәзер шуннан кайтып килеше.

Халидә. Бар әле, Халидә апа чакыра, диң.

Җәмилә китә. Зиннур керә.

Зиннур. Халидә апа, мин хәзер генә идарәдә булдым, Мортаза абый анда счетовод, кладовщикларны җыеп алган да быелгы уңыш турында нәтиҗәләр ясата. Еллык фураждан, орлыктан калган ашлыкларны эш көннәренә бүлеп, бүгенге җыелышта игълан итәм, ди. Сез ул турыда беләсезме?

Халидә. Юк, аның миңа ул турыда берни дә әйткәне юк.

Зиннур. Быел да фермага механизация, водопровод кертү турында берни дә эшләмибезмени, дигән идем, күтәрелеп бәрелергә кереште.

Мортаза керә.

Мортаза. Кайчан гына карама, «әлмән белән сәлмән» кебек, сез бергә.

Халидә. Мортаза, бире кил әле.

Мортаза. Юк, серегезне бүлдермим, соңыннан!.. (*Клубка кереп китә.*)

Зиннур. Мин аның янына керим әле, чыннан да әллә ни уйлавы бар. (*Клубка кереп китә.*)

Култык астына гармун кыстырып, Әптәлим керә.

Әптәлим. Халидә җиңги, мине чакыргансың икән.

Халидә. Әйе, чакырдым. Менә нәрсә, Әптәлим. Син беркөн, читкә китәргә йөрим, берәр җиргә требование юкмы, дигән идең. Миңа бүген районнан кәгазьләр килде, берничә җиргә кешеләр сорыйлар.

Әптәлим. Хәзер партия йөз меңләгән белгечләрне шәһәрләрдән авылларга җибәреп торганда, кеше авылдан читкә китәме?!

Халидә. Бердән, син белгеч түгел, икенчедән, безнең колхозлар артык эш көчләрен моннан соң да шулай промышленностька биреп торырлар.

Әптәлим. Анысы шулай инде, конешно... Мин болай гына әйтүем. Күбрәк акча төшә торган эш булса, нигә китмәскә, җиңги.

Халидә. Менә күмер эшенә, Донбасска сорыйлар.

Әптәлим. Юк, җиңги, Донбассның һавасы бик эссе, миңа кызу ярамый.

Халидә. Анда теләмәсәң, Төньяк Уралга китәргә була.

Әптәлим. Анда, җиңги, бик суык.

Халидә. Ул чагында Кузбасска билгелим. Анда артык эссе дә, суык та түгел.

Әптәлим. Юк, җиңги, миңа Казан тирәсендәрәк булмасмы?

Халидә. Әптәлим! Син миңа боргалап-сыргалап сөйләмә. Мин синең эш көннәрең белән таныштым, бөтен ел буена нибарлыгы 57 эш көнең бар.

Әптәлим. Шулайдыр. Бездә бит, Үзәк Комитетның Сентябрь Пленумы карарларында әйтелгәнчә, кешеләрне дөрес файдаланмыйлар. Әйтик менә мине, гармунчы-музыкантны, кара эштә йөртмәкче булалар.

Халидә. Эшнең карасы-агы юк. Һәрбер хезмәт бездә намус эш санала. Моннан соң синең бу эшсезлегеңне Мортаза абыең да яклап кала алмас. Суксаң тимер өзәрлек башың белән, эшләмичә, туйдан туйга гармун уйнап йөрүеңә колхозчылар да түзеп тормаслар. Бу сиңа аңлашыламы?

Әптәлим. Әйе, аңлашыла, җиңги, бик нык аңлашыла...

Халидә. Аңлашылса — бар. Бүген үк үзеңә берәр эш сора.

Әптәлим китә. Ишектә Гозәир күренә.

Гозәир. Керергә ярыймы?

Халидә. Әйдәгез, Гозәир абзый, рәхим итегез. (*Урындык бирә.*)

Гозәир. Рәхмәт, кызым, миңа килергә кушкансың икән.

Халидә. Әйе, кушкан идем шул. Мин сезне, Гозәир абзый, «Беренче май» колхозына китәргә йөрисез икән дип ишеттем, шул сүз дөресме?

Гозәир. Кем әйтте?.. Кияүдәге кызым чакырган иде. (*Үпкәләп.*) Әйеме? Эе!

Халидә. Яшермичә сөйләгез, Гозәир абзый, бөтенләй алай түгел бит. Авыл советы председателе һәм партоешма секретаре буларак, мин эшнең дөресен белергә тиеш.

Гозәир. Ярый алайса, кызым, дөресен беләсең килсә, мин сиңа дөресен сөйлим. Тик үпкәләштән булмасын, әйеме? Эе. Үзегезгә мәгълүм, мин бөтен гомерем буена бакчачылык, умартачылык белән шөгыльләнеп килдем. Колхоз булгач, Борма Тау итәкләрен алма, чия бакчаларына әйләндерергә йөрдем. Ул чагында, төрле сылтаулар табып, аларны тормышка ашырмадылар. Сугыштан соң хөкүмәтнең Февраль карарлары чыккач, нишләргә икәнен күрсәтеп Мортазага язып та бирдем. Аның да нәтиҗәсе булмады. Менә тагын хөкүмәтнең авыл хуҗалыгын ишшу да үстерү, бакчачылык, умартачылыкны ишшу да яхшырту турында яңа карарлары булды. Шул уңай белән, ирең Мортазага барып, тагын бер кат сөйләп карадым. «Быел безнең расходлы елыбыз, идарә йорты салабыз, легковой машина алабыз»,— диде. Сүз көрәштереп тормадым, кайтып, карчык белән киңәштем дә китәргә булдым. Әйеме? Эе!

Халидә. Юк, Гозәир абзый, сезнең кебек алтын куллы кешеләрне авылдан җибәрергә ярыймы? Үзең әйткәндәй, хөкүмәтнең Сентябрь Пленумы карарларында, синең шикелле төрле сәбәпләр белән киткән кешеләрне хәзер киредән авылларга кайтару куела.

Гозәир. Монда мин нишлим? «Беренче май»чылар миңа биш гектар җирдә җиләк-җимеш, умартачылык хуҗалыклары оештырып бирергә вәгъдә итәләр. Аллага шөкер, тәҗрибәм бар. Ике тапкыр Мичурин бакчасында булдым, хатлар язышып тора идек. Бакчамдагы агачларым бар да аның бүләге. Әйеме? Эе!

Халидә. Менә нәрсә, Гозәир абзый, бу турыда мин идарә белән сөйләшеп, сиңа кирәк булган шартларны тудырырга тырышырмын.

Гозәир. Ай-һай, кызым, күңелеңә авыр алмасаң, шуны әйтер идем, ирең Мортаза бик тискәре кеше бит, тыңлар микән?

Халидә. Тыңлар, Гозәир абзый, тыңлатырбыз. Китү турында уйлап та карама.

Гозәир. Турысын әйткәндә, кызым, үзебезнең дә китәсебез килми иде. Шунда туган, шунда гомер иткән дигәндәй, безгә монда бар да якын бит. Ярый алайса, мин кайтып карчыкны шатландырыйм әле. Бигрәк тә аның китәсе килми иде.

Халидә. Бар, бар, Гозәир абзый, Гайнелхәят түтәйгә миннән сәлам әйт.

Гозәир. Буш чагыңда килеп чык, кызым, алма, чияләрнең хәзер мул чагы.

Халидә. Ярар, ярар, Гозәир абзый, барырмын.

Гозәир. Хуш, кызым.

Халидә. Хуш, Гозәир абзый, хуш!

Ишеккә озата бара. Клубтан Мортаза чыга.

Син нәрсә, Мортаза, уңыш бүләргә йөрисеңме?

Мортаза. Әйе, бүгенге җыелышта быелгы нәтиҗәләрне игълан итәргә уйлыйм.

Халидә. Нигә ул кадәр ашыгырга булдың соң?

Мортаза. Бердән, куярга урын юк, икенчедән, бозылуы бар, өченчедән, аны саклауга эш көннәре әрәмшәрәм итәсем килми. Әйдә, үз икмәкләрен үзләре сакласыннар.

Халидә. Ә соң идарәдә карадыгызмы?

Мортаза. Карамасак, кем каршы килер икән?

Халидә. Уңыш бүлү кебек политик мәсьәләне без башта партоешмада, аннан идарә утырышында карарга тиешбез...

Мортаза (*Халидәнең сүзен бүлеп кәгазь күрсәтә*). Менә нәтиҗәләре. Шәп бит, ә?!

Халидә. Әйе, начар түгел... Тик менә бүленми торган фондка аз калдыргансыз.

Мортаза. Устав буенча унбиш процент.

Халидә. Ләкин бит устав буенча унбиш процентттан да ким булмаган нормада диелгән. Егерме биш, хәтта утыз процентка кадәр калдырырга хакың бар. Беләсең, партиянең соңгы карарлары нигезендә эш планнарыбызда үзгәрешләр булачак. Ул үзгәрешләр бездән өстәмә расходлар чыгаруны таләп итәчәк. Аңла, Мортаза, беренче чиратта без дәүләт интересын күз алдында тотарга тиеш.

Мортаза. Дәүләт интересы турында син миңа акыл өйрәтмә, яме? Ун елдан бирле район күләмендә беренче булып икмәк йөкләмәсен кем үтәп килә? Мин — Мортаза! Колхозчыларга районда беренче булып хезмәт көненә кем уңыш бүлде? Мин! Урып-җыю, чәчү кампанияләрендә беренчелек кемнең кулында? Миндә — Шәфигуллинда, конешно!

Халидә. Синең ул уңышларыңны күмеп калырга беркем дә теләми. Ләкин соңгы елларда колхозның гомуми байлыгы нигә артмаган? Бүленми торган фонд нигә үсмәгән, фермага механизация кермәгән, гидростанция салу мәсьәләгез елдан елга кичектерелгән. Артта калган колхозчылар интересын тәэмин итү йөзеннән күбрәк уңыш өләшеп, шуның белән алар каршында үз авторитетыңны күтәреп килгәнсең. Без моңа хәзер ирек бирмәбез!

Мортаза. Кем соң ул «сез»?

Халидә. Партия членнары, комсомоллар һәм алдынгы колхозчылар.

Мортаза. Беләм мин монда эшнең нидә икәнен... Матур сүзләр белән минем күзләремне томалап, Зиннур малай белән сукыр тәкәле уйнарга телисең!..

Халидә. Их, Мортаза!..

Җәмилә белән шәһәрчә киенгән Фәрдәнә керә.

Фәрдәнә. Исәннәрмесез, иптәшләр!

Мортаза. Менә сиңа кучтәнәч!.. Гөлкәем, Фәрдәнәм кайткан!.. (*Каршы барып күрешә.*)

Фәрдәнә (*уңайсызланып*). Исәнме, Халидә апа!

Халидә. Бик әйбәт, Фәрдәнә, шәһәр икмәге килешкән сиңа.

Җәмилә. Чыннан да, Халидә апа, ул тагын да тазарып, тагын да матураеп кайткан.

Фәрдәнә. Кунак урынында гына сыйлап йөрткәч, тазардым шул.

Халидә. Йә, сөйлә, укуларың ничек барды соң?

Фәрдәнә. Бик әйбәт, Халидә апа. Мин хәзер бригадамның эшен ничек куярга икәнен беләм.

Мортаза. Анысы инде, Фәрдәнә, моңа кадәр дә синең бригадаң начар куелмаган иде.

Фәрдәнә. Дөрес, Мортаза абый, минем бригадамны алдынгы бригада итеп йөртә идегез. Ләкин ул сукыр кешенең кармаланып йөрүе шикелле генә булган. Мин хәзер, Сентябрь Пленумы карарларын үзләштереп, азмы-күпме булса да Мичурин хәзинәсеннән авыз итеп кайттым.

Мортаза. Кара, кара, ничек кенә сөйләп җибәрә!

Клубтан Шакирҗан белән Зиннур чыга.

Зиннур. Күрми дә торабыз, Фәрдәнә кайткан ич.

Шакирҗан. Нихәл, кызым Фәрдәнә, исән кайттыңмы?

Фәрдәнә. Абага чәчкәсе кебек, Шакирҗан абзый. Ягез, үзегездә ниләр бар?

Мортаза. Бөтен кыр эшләрен бетердек, уңыш бүләргә җыенабыз.

Җәмилә. Казаннан бүген авыл хуҗалыгы институтының аспиранты Айтуганов килә. Аны көтәбез.

Фәрдәнә. Ишеттем. Ул безнең авыл егете икән.

Зиннур. Безнең авыл егете? Кем улы?

Фәрдәнә. Атасының исеме Гәрәй, ди.

Мортаза. Шакирҗан абзый, кайсы Гәрәй икән ул?

Шакирҗан. Гәрәй, Гәрәй Айтуганов... Юк, кызым Фәрдәнә, безнең авылда андый кеше юк. Ялгыша торгансыңдыр.

Фәрдәнә. Юк, Шакирҗан абзый, ялгышмыйм. Мин кайтышлый районга кергән идем, шунда миңа инструктор Саттарова сөйләде.

Мортаза. Гаҗәп, кайсы Гәрәй улы булыр икән ул?

Шакирҗан. Бу теге революциягә кадәр читкә киткән Латыйп Гәрәевнең улы түгелме икән? Алай дисәң, алар фамилияләрен Уразманов дип йөртәләр иде.

Җәмилә. Әти, күпер башы Бәхтегәрәй абзыйларның теге Донбасста эшләүче абыйларының исеме ничек иде әле?

Шакирҗан. Җиһангәрәй.

Җәмилә. Менә шуның улы түгелме?

Шакирҗан. Юк, кызым, аларның балалары бар да кыз бала иде шикелле.

Мортаза. Таптым! Солтангәрәй малае!

Шакирҗан. Кайсы Солтангәрәй, алар бездә өчәү.

Мортаза. Москвада «Урак-чүкеч» заводында эшләүчеләр.

Шакирҗан. Юк, энем Мортаза, аларның фамилияләре Байтуганов.

Мортаза. Байтуганов белән Айтугановның аермасы аз инде.

Халидә. Чыннан да, Гәрәйләр белән авылыбыз тулган икән.

Мортаза. Әйтмә дә, безнең авылдан читкә китеп эшләүче Гәрәйләрдән генә дә бер МТС төзергә мөмкин. Менә кадрлар кайда ул! Алар арасында нинди генә профессия кешеләре юк. Үзәк Комитет карары буенча һәммәсен дә хәзер авылга сөреп кайтарырга иде.

Зиннур. Ул чагында, Мортаза абый, синең белән миңа рәт калмас иде.

Шакирҗан. Шулай да кайсы Гәрәй улы булыр икән ул?

Халидә. Ярый, Шакирҗан абзый, баш ватма, килгәч, үзеннән сорарбыз.

Җәмилә (*тәрәзәдән күреп*). Әнә ул килеп тә җитте!

Барысы да йөгерешеп чыгып китәләр. Бераздан Айтуганов белән шаулашып керәләр.

Халидә. Әйдәгез, иптәш Айтуганов, рәхим итегез!

Мортаза. Кая, өстегезне салдырыйм.

Айтуганов. Рәхмәт, мин үзем дә салырмын.

Халидә. Утырышыгыз, иптәшләр.

Мортаза. Җәмилә, бар әле, шул балаларны ку, аю күргәндәй тәрәзәгә менәләр.

Җәмилә китә. Барысы да тын калалар.

Халидә. Ягез, иптәшләр, кем дә булса сөйләсен иде.

Мортаза. Чыннан да, мин тугандай булды бу.

Зиннур. Ай-һай, Мортаза абый, син туганда, ярты авыл аякка баскандыр.

Озак пауза. Тыштан Җәмилә керә.

Шакирҗан. Иптәш Айтуганов, сезгә бер сорау бирергә буламы?
Айтуганов. Нигә булмасын, рәхим итегез.
Шакирҗан. Сезне, безнең авыл егете, диләр, шул сүз дөресме?
Айтуганов. Әйе, мин шушы «Борма тау» авылында туганмын.
Шакирҗан. Кем улы буласыз?
Айтуганов. Гәрәй улы.
Шакирҗан. Кайсы Гәрәй?
Айтуганов. Безнең әти көтүче булган, ахры.
Шакирҗан. Сәхибгәрәй улымы? Кил алайса, яңадан күрешик!

Кочагын җәеп бара. Бөтенесе дә аякка басалар. Айтугановны сырып алалар. Яңадан күрешәләр.

Шакирҗан. Утызынчы елны әтиең белән әниең, гөмбәдән агуланып, икесе бер көнне үлеп киттеләр. Мин ул чагында яңа гына оештырган колхоз председателе идем. Сезне, үз өемә алып, берничә атна карадым да, бу игезәк малайлар белән нишләргә дип, районга киттем. Анда миңа авылда туганнарыгыз, кардәш ыругларыгыз да булмагач, балалар йортына бирергә куштылар. Шуннан мин сезне шәһәргә илтеп тапшырдым. Шул чагында фамилиягезне дә мин кушкан идем.

Айтуганов. Ничек сез кушкан идегез?

Шакирҗан. Сезне шул балалар йортына яздырганда, яшь кенә бер рус кызы: «Фамилияләре ничек?» — ди. «Сәхибгәрәй улы»,— дим. «Юк, ул аларның аталарының исеме, син миңа фамилияләрен әйт»,— ди. Бәйләнде бит. Нишләргә, бабаңның исемен онытканмын. Шулай уйланып торганда, шул көннәрне генә үлеп киткән Айтуган карт кылт итеп исемә төште бит. Менә шулай аның исемен сезгә фамилия итеп яздырдым.

Айтуганов. Менә сиңа кирәк булса!.. Без чыннан да бабайның исеме Айтуган булган дип йөри идек.

Шакирҗан. Авылга кайткач, мин аны сорашып белдем дә, соң иде инде. Синең бабаңның исеме Асылгәрәй иде.

Зиннур. Тагын бер Гәрәй табылды.

Мортаза. Иван улы Иванов дигән шикелле Гәрәй улы Гәрәй Гәрәев булса, тагын да кызыграк буласы икән.

Шакирҗан. Икенчегез кайда соң, энем?

Айтуганов. Москвада, Хәрби академиядә укый.

Шакирҗан. Ә үзегез?

Айтуганов. Моннан ике ел элек авыл хуҗалыгы институтын бетергән идем, хәзер аспирантурада укыйм.

Шакирҗан. Менә бит ул безнең Совет заманы! Ятим балалардан нинди кешеләр чыккан!

Айтуганов. Аның өчен, күрәсең, Шакирҗан абзый, без сезгә бурычлы икәнбез, моңа кадәр шуны белми йөргәнбез.

Шакирҗан. Яшь идегез шул, дүрт яшь тә тулмаган иде.

Мортаза. Моңа чаклы нигә соң кайтмый тордыгыз?

Айтуганов. Шулай туры килде инде, авылда беркемебез дә булмагач, кайтмадык.

Җәмилә. Халидә апа, халык җыелып бетте диярлек, клубка узсак ничек булыр икән?

Халидә. Әйе, Җәмилә, узарбыз. Иптәш Айтуганов, әйдәгез, рәхим итегез.

Җәмиләдән башкалар барысы да клубка кереп китәләр.

Җәмилә. Безнең авылдан да менә нинди кеше чыккан бит!..

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шакирҗан картның өй эче, чиста итеп җыештырылган. Тәрәзәләргә ак пәрдәләр эленгән. Түрнең бер ягында гади диван. Икенче ягында тимер карават. Стенада сәгать, көзге. Пәрдә ачылганда, Гамилә өй җыештырып йөри. Шакирҗан белән Айтуганов кайтып керә.

Шакирҗан. Әйдә, энем, рәхим ит.
Айтуганов. Исәнмесез, апа!
Гамилә. Бик яхшы, улым, син шул Сәхибгәрәй абыйның улы буласыңмыни инде?
Айтуганов. Әйе, апа, шуларның берсе булам.

Гамилә. Сине күргәч, Хәкимҗан бәбкәм исемә төште... Ул сезне бик ярата иде, кая гына барса да ияртеп йөри иде...

Шакирҗан. Кая, Гамилә, ашың бармы, чәең буламы?
Гамилә. Ашым кайный әле, чәем өлгергән.

Айтуганов. Гамилә апа, без яңа гына Гозәир бабайдан чәй эчеп чыктык. Үзегезнең эчәсегез килмәсә, әзерләп мәшәкатьләнмәгез.

Гамилә. Ярый, улым, ярый, сабыр итәргә дә була. Безнең Хәкимҗаныбыз да чәйне...

Шакирҗан. Гамилә, син ашыңны кара инде.

Гамилә. Әйтәм бит, ашым кайный әле.

Шакирҗан. Токмачыңны баса тор. Кунакның вакыты юк. Бүген китәм, ди.

Гамилә. Ай Алла, нигә бик тиз?

Айтуганов. Минем сездән соң тагын берничә колхозда буласым бар әле. Шуңа күрә ашыгам.

Гамилә. Синең кебек кешенең укуы да, эше дә күптер шул. (*Китә.*)

Шакирҗан. Без ул бала турында анасы алдында ничек булса да сөйләшмәскә тырышабыз. Анасының йөрәге бик начар.

Айтуганов. Ул малаегызга ни булды соң?

Шакирҗан. Сталинград сугышларында үлде.

Айтуганов. Кызганыч... Сез миңа председатель турында сөйләргә булган идегез.

Шакирҗан. Әйе, ул үзе күрше авылдан, нык тормышлы кешенең баласы. Сугышка чаклы районның берничә колхозында эшләп, яхшы эше белән үзен таныткан иде. Шуңа күрә аны монда кирәкле кеше санап фронтка да җибәрмәделәр. Сугыш елларында безнең колхозның эше сүтелә башлагач, аны безгә китереп - куйдылар. Начар эшләмәде. Хәзер дә әйбәт алып бара. Авыл хуҗалыгын бөтен нечкәлекләре белән белә. Үзендә организаторлык сәләте дә бик көчле. Ләкин соңгы елларда масайды, киңәшләшеп эшләүне яратмый башлады.

Кулы камырлы килеш Гамилә чыга.

Гамилә. Бервакыт шулай әниең белән урманга җиләккә бардык. Ул курай уйнарга бик оста иде. Әллә каян гына бер көпшә кисәге табып алды да әй уйный бичара, әй уйный... Йөрәге сизенеп ашкынган икән, шуннан озак та үтмәде, икесе бер көнне үлделәр...

Айтуганов. Әнине мин бераз хәтерлим, тик әти генә истә калмаган.

Шакирҗан. Әтиең бик юаш кеше иде, хайваннарга да, бичара, «рәхмәт төшкерләре» дип кенә кычкыра иде.

Гамилә. Бервакытны минем Хәкимҗаным белән...

Шакирҗан. Гамилә, бар инде, кулыңдагы камырың ката бит!

Гамилә (*кулларына карап*). Чыннан да, онытып торам икән шул. (*Китә.*)

Айтуганов. Хатыны ничек соң, Шакирҗан абзый?

Шакирҗан. Хатыны аның шахтер кызы. Донбасста эшләгәндә, Мортаза өйләнеп кайткан иде. Күп еллар безнең авыл советында секретарь, аннан избач булып эшләде. Аннан инде Казанга партия мәктәбенә укырга китеп, быел аны бетереп кайтты. Акыллы, турылык сөюче хатын... Дөресен әйткәндә, Мортазаның бозылуы да ул югында башланды. Менә хәзер Халидә кайтып парторг булгач, никтер килешеп эшли алмыйлар. Үзәк Комитет карары буенча шәһәрләрдән авылларга агрономнар, зоотехниклар килә башлады, безнең авылга да җибәрерләр микән?

Айтуганов. Әйе, Шакирҗан абзый, җибәрерләр. Партия хәзер һәрбер колхозда агроном белән зоотехник булуны куя. Башта әле йомшаграк колхозларны ныгыталар. Сезнең колхоз бит район күләмендә алдынгы колхозлардан санала. Әйе, авылларга кадрлар кирәк. Шул уңай белән әле мине дә чак-чак кына җибәрми калдылар.

Шакирҗан. Агроном итепме?

Айтуганов. Райком секретаре итеп җибәрергә теләгәннәр иде, соңыннан аспирантураны бетергәнче сабыр итәргә булдылар.

Гамилә керә.

Гамилә. Атасы, безнең маллар япмаган.

Шакирҗан. Шушы вакытка кадәрме?

Гамилә. Эш белән мавыгып оныткanмын.

Шакирҗан. Их, сине... Гаеп итмә инде, энем, мин хәзер...

Гамилә. Шунда берьюлы токмач кабартырга коры-сары алып керергә дә онытма.

Шакирҗан китә.

Бу балалар кайда йөриләр икән дип, еш кына телгә ала идек. Балаң-чагаң ничәүләп?

Айтуганов. Мин бит әле, Гамилә апа, өйләнмәгән.

Гамилә. Нишләп алай? Яшең шактый бит инде.

Айтуганов. Вакыт тигәне юк әле, башта укуымны тәмам итәсем килде.

Җәмилә кайтып керә.

Гамилә. Кызым, кайда йөрисең?
Җәмилә. Комсомол җыелышы уздырдым, әни.
Гамилә. Кунак барында, андый җыелыш-мыелышларыңны калдырып торырга да була торгандыр. Әйдә, миңа булышырсың. (*Китә.*)
Айтуганов. Тышта һаман явамы, Җәмилә?
Җәмилә. Юк, аяза. Катырыр, ахры.
Айтуганов. Йә, Җәмилә, ни эшләр бетереп ятасыз?
Җәмилә. Безнең эшләр билгеле инде: язабыз, сызабыз, җыелышлар уздырабыз.

Гамилә керә.

Гамилә. Кызым, мин сиңа нәрсә дидем.
Җәмилә. Мин бик туңдым әле, әни, бераз җылынам.
Гамилә. Туңсаң, җылы якка кер. (*Тышка чыгып китә.*)
Айтуганов. Гафу итегез, Җәмилә, сез кайда укыдыгыз?
Җәмилә. Быел районда унъеллык мәктәпне бетердем.
Айтуганов. Тагын да укырга теләмәдегезме?
Җәмилә. Бик теләгән идем дә, медицина институтына гариза да җибәргән идем. Кинәт кенә әни авырып китте дә бара алмый калдым.
Айтуганов. Йә, Җәмилә, ни дә булса сөйләгез инде!
Җәмилә. Нәрсә генә сөйлим икән соң?!
Айтуганов. Нәрсә булса да ярый.
Җәмилә. Сез тыңларлык минем бернинди дә сүзем юк.
Айтуганов. Нигә алай дип уйлыйсыз?
Җәмилә. Чөнки безнең авыл тормышы һаман бертөсле.
Айтуганов. Юкка алай уйлыйсыз. Менә мин сездә бер генә көн булдым. Колхозчыларның тормышын, көнкүрешләрен күреп, үземә бик күп рухи азык алдым...

Чиләк тотып, Гамилә керә.

Гамилә. Кызым, юынырга су беткән, коедан гына алып кер инде... (*Җәмиләгә чиләк тоттырып китә.*)

Тыштан Халидә керә. Җәмилә китә.
Халидә. Саумысез!
Айтуганов. Әйдәгез, рәхим итегез.
Халидә. Йә, иптәш Айтуганов, кайларда булдыгыз?
Айтуганов. Озак кына фермагызда йөрдек. Тегермәнегездә булдык. Су буйларыгызны карадык. Гомумән, Шакирҗан абзый мине бөтен хуҗалыкларыгыз белән таныштырды. Аннан безне Гозәир бабай чәйгә алып керде. Төрле-төрле алма, чия белән сыйлады.
Халидә. Соң, ничек, карт үзе ошадымы?
Айтуганов. Әйе, агробиологиядән, агротехникадан шулчаклы белемле карт икән, исем китте инде. Әйе, чын-чынлап лаборатория. Барометр, термометр кебек приборлар, слесарьлык, столярлык станоклары бар. Төрле техника журналлары ала икән.
Халидә. Сез аның хуҗалыгында җәй көне булсагыз иде, аның бакчасында нинди генә агач, үлән юк. Шуның өстенә ул умартачы, ул балыкчы, ул җәнлекче дә. Сугыш елларында, Головатыйның чакыруы буенча, җиңү фондына сиксән мең сум акча керткән карт бит ул.
Айтуганов. Кара, ул турыда миңа берни дә әйтмәде.
Халидә. Ул, гомумән, үзе турында сөйли торган кеше түгел.
Айтуганов. Мин үзеннән сорарга уңайсызландым, кайда укыган соң ул?
Халидә. Беркайда да, бары тик солдат хезмәтендә генә русча укырга-язарга өйрәнгән.
Айтуганов. Чын-чыннан халык арасыннан чыккан талант икән.
Халидә. Без менә чак-чак кына шул кешесез калмадык. Сизеп өлгермәсәк, колхозыбызны ташлап китә иде.
Айтуганов. Нишләп?
Халидә. Сәбәбе шул: аңа монда җәмәгать хуҗалыгында эш шартлары тудырылмаган. Ул гына да түгел, үзенә кырын караучылар да бар.
Айтуганов. Менә ничек...
Халидә. Кызганычка каршы, шулай.

Мортаза, Зиннур, Фәрдәнә, Гозәир һәм Шакирҗан керәләр.

Шакирҗан. Әйдәгез, кунаклар, рәхим итегез!
Гозәир. Әссәламәгаләйкүм!
Шакирҗан. Әйдә, Гозәир абзый, түрдән уз!

Барысы да утырышалар.

Гозәир (*дога кылып*). Хуш, тереклек булсын!
Шакирҗан. Шулай булсын, Гозәир абзый. Фәрдәнә, патефонны куй әле, кунакларга күңеллерәк булыр.

Фәрдәнә патефонга пластинка куя башлый.

Мортаза. Кирәкми, Фәрдәнә, чинатма! Иптәш Айтуганов, сез инде безнең колхоз белән яхшылап таныштыгыз, һәр җирдә дәфтәрегезгә яза бардыгыз. Мин уйлыйм, начар яктан түгелдер, конешно. Бәлки, Казанга кайткач, яхшы якларыбызны күрсәтеп газетага да язарсыз.

Айтуганов. Уйлап карарга була... Мин сезнең фермагызны карадым һәм башка хуҗалыкларыгыз белән дә таныштык. Әйе, сезнең колхозыгыз бай һәм әйбәт колхоз икән.

Мортаза. Тырыштык инде, иптәш Айтуганов, тырыштык.

Айтуганов. Ләкин нишләмәк кирәк — кимчелекләр дә җитәрлек. Мәсәлән: партия XIX съездда һәм Сентябрь Пленумында кискен итеп терлекчелекне үстерү бурычын куйды. Механизациясез аны үстерергә мөмкин түгел. Механизация кертү өчен электрификация кирәк, электрификацияне булдыру өчен гидростанция салырга кирәк. Бу турыда сезгә уйлый башларга иде. Аны булдыру өчен сездә бөтен мөмкинлекләр бар.

Мортаза. Безнең елга андый-мондый елгалардан гына түгел шул, аны җиңәргә, ай-һай, күпме көч, күпме средство кирәк.

Айтуганов. Ул чагында күрше авыллар белән бергәләп салырга була. Алай эшләү средство ягыннан да, эш көчләре ягыннан да җиңеллек бирәчәк.

Мортаза. Ул эшне инде район җитәкчеләре кайгыртырга тиеш. Андый төзелеш әле безнең РИКнең бишьеллык планында күренми.

Айтуганов. РИК планында күренми икән, башка юл белән салырга була. Әнә Свердлов, Москва өлкәләренең колхозлары патриотик почин белән, халык планы нигезендә күптән инде тоташтан электрлаштылар.

Мортаза. Алар промышленность өлкәләре. Гидростанция салу өчен, әйтәм бит, күпме материал, күпме средство кирәк, Шакирҗан абзый, ә?

Айтуганов. Теләк булса, материалы да, средствосы да табылыр иде, Мортаза абый.

Мортаза. Теләк юк түгел. Үткән ел техниклар китертеп смета да төзетеп карадык. Нурулла абзый, ә? Әлеге дә баягы, итәк кыскарак.

Айтуганов. Аннан, авыл тирәләрегездә, су буйларыгызда, тау битләрегездә күпме җирләрегез әрәмгә ята. Нигә шул җирләрне җиләк-җимеш бакчаларына әйләндермәскә?! Шундый эш өчен янып-көеп йөргән Гозәир бабай кебек алтын куллы кешеләрегез дә бар. Өч-дүрт елдан йөз меңләгән табыш алыр идегез.

Мортаза. Сугыштан соң, бакча ясыйбыз дигән булып, алмагачлар утыртып караган идек тә, куян ашап бетерде, Гозәир абзый, ә?

Айтуганов. Анысы инде начар хуҗа булганлыктан, карамаганлыктан гына.

Мортаза. Ул каһәрләр безнең дисциплинага буйсынмыйлар шул, килгәнне әллә каян сизәләр дә, койрыкларын күтәреп, кырга чабалар, Гозәир абзый, ә?

Гозәир (*ачуы килеп сикереп тора*). Энем Мортаза, кәмит уйнама, әйеме? Эе! Атаң бирмәгән акылны бирәләр, тавык мие ашамаган булсаң, сөйләгәнгә колак сал! Әйеме? Эе!

Мортаза. Ай-һай! Бу нишләвең бу?

Гозәир. Базар кәмитендәге мәзәкче булып кылану сиңа килешми! Яхшымы-яманмы, син безнең председатель кешебез, әйеме? Эе!

Мортаза. Сыер дуласа, аттан яман, диләр иде, дөрес икән, Нурулла абзый, ә? Ничек җикеренә!

Гозәир. Җикеренми ни! Үз ялганыңа нигә миннән кул куйдырып торасың? Әллә мин сиңа Нурулла дип белдеңме? Кайчан бакча төзедең? Дөрес, бер елны үз милегең артына йөз төп алмагачы утырткан идек. Куяннар түгел, ихатасы булмагач, кәҗәләр кимереп бетерде. Әйеме? Эе!

Айтуганов. Партия карарларында яткын җирләрне, сазламык болыннарны эшкәртү бурычы куелды. Бу карарларны үтәү буенча нинди булса да эшләр алып барылуы әлегә күренми. Әйтик, суның аръягында малярия оясы булып күпме җирләрегез әрәмгә ята. Нигә аларны, киптереп, чәчү мәйданына әйләндермәскә?!

Гамилә бүлмәдән чыга.

Гамилә. Атасы, аш өстәлдә.
Шакирҗан. Әйдәгез, кунаклар, табынга рәхим итегез.

Мортазадан башкалар бүлмәгә кереп китәләр. Тыштан Мәфтуха керә.

Мәфтуха. Әйдәгез инде, Мортаза, кайчаннан бирле мунчага көтәм!
Мортаза. Безне монда мунча керттеләр инде, апа.
Мәфтуха. Парлапмы?
Мортаза. Һәм парлап та, һәм жарлап та чаптылар. Тәнең генә чыдасын!.. (*Чыгып китә.*)
Мәфтуха. Нәрсә ди бу, нәрсә ди? Һич сүзенең ата-анасы юк!

Пәрдә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шул ук Шакирҗан карт өендә бара. Пәрдә ачылганда, Җәмилә, җырлап, кулъяулыгы чигеп утыра.

Җәмилә. Сөеп җиккән туры атыңның
Дугалары талмы әллә?
Озын керфекле күзеңдә
Тылсымнарың бармы әллә?..

Бүлмә ишегеннән Айтуганов күренә.

Айтуганов. Җәмилә!..
Җәмилә (*сискәнеп*). Ә?..
Айтуганов. Ни булды сезгә?
Җәмилә (*чигә торган яулыгын яшереп*). Менә бармагыма инә белән чәнечтем...
Айтуганов. Карап тегәргә идегез.
Җәмилә. Көтмәгәндә кереп эндәшкәч...
Айтуганов. Ха-ха-ха... Шулай да сез, Җәмилә, чебен тимәс чер итәр икәнсез.
Җәмилә. Авырта ич. Кая, үзегезгә чәнчеп карыйм әле.
Айтуганов. Мәгез, мә, «эһ» тә димәм. (*Кулын сузып тора.*) Йә, нигә чәнечмисез?
Җәмилә (*ягымлы елмаеп*). Кызганам...
Айтуганов. Кызганасыз? Ха-ха-ха... Их, Җәмилә, үзегез врач булырга җыенасыз, үзегез инә белән чәнчергә дә кызганасыз.
Җәмилә. Мин бит сезне генә.
Айтуганов. Башкаларны кызганмыйсызмы?
Җәмилә. Ярый инде, Гәрәй абый...

Фәрдәнә бүлмәдән чыга.

Фәрдәнә. Җәмилә, Гамилә апа чакыра.

Җәмилә китә.

Гәрәй иптәш, безнең авылны яратмадыгыз, ахры.
Айтуганов. Нигә алай дип уйлыйсыз?
Фәрдәнә. Бик тиз китәсез.
Айтуганов. Юк. Мин авылны бик яраттым. Моңа кадәр кайтмый йөрүемә дә үкенәм. Бигрәк тә кешеләре әйбәтләр.
Фәрдәнә. Кызлары ничек соң?
Айтуганов. Кызлары да, егетләре дә әйбәт.
Фәрдәнә. Тагын да бер көн торсагыз, без сезгә «Галиябану» әсәрен уйнап күрсәтергә булган идек. Бүген өлгерә алмадык.
Айтуганов. Димәк, сез бригадир да, артистка да.
Фәрдәнә. Мин үзебезнең түгәрәк белән җитәкчелек итәм. Үткән ел Казанда үзешчән сәнгать смотрында икенче премияне алган идем. Озакламый миңа тагын Казанга барырга туры килә.
Айтуганов. Шул үзешчән сәнгать эше беләнме?
Фәрдәнә. Юк. Тәҗрибә кырыма сортлы орлыклар алырга барам. Шуларны табарга сез миңа ярдәм итсәгез иде.
Айтуганов. Бу өлкәдә минем белеш-танышларым күп, ярдәм итәрмен, мине күрми китмәссез.
Фәрдәнә. Сез анда кайсы урамда торасыз?
Айтуганов. Горький урамында.
Фәрдәнә. Бик әйбәт җирдә икән. Академия театры да якын.
Айтуганов. Менә адресым. (*Кәгазьгә язып бирә.*)

Зиннур керә.

Зиннур. Фәрдәнә, син бит иптәш Айтугановка ат эзләргә киткән идең.
Фәрдәнә. Минем атым да, кешем дә әзер. Хәзер алып киләм. (*Китә.*)

Зиннур. Иптәш Айтуганов, рәхмәт сезгә. Безнең теләкләрне әйттегез дә салдыгыз. Бу турыда без Мортаза абыйга бик күп әйтеп карадык, тыңламый иде. Моннан соң ул, бәлки, үзгәрер.

Айтуганов. Белмим шул, минем әйтүем белән генә булыр микән?

Зиннур. Моңа кадәр аның терәге — райисполком председателе Моракаев бар иде, анысының хәзер куыгы шиңәргә тора.

Айтуганов. Берәр гаебе бармыни?

Зиннур. Бик салырга ярата. Озак тотмаслар, чыгарырлар.

Җәмилә бүлмәдән чыга.

Җәмилә. Гәрәй абый, Зиннур абый, сезне чәйгә көтәләр.

Айтуганов. Әйе, берәр чынаяк эчәргә дә миңа китәргә вакыт.

Зиннур белән кереп китәләр. Җәмилә чигә торган яулыгын алып эшкә утыра. Уйланып җырлый.

Җәмилә. Ак ефәккә төшкән төрле бизәкләрем,
Түгел алар минем гади кул эшем.
Син кабызган, егет, көчле мәхәббәтнең
Тойгысыннан туган йөрәк тибешем.

Истә тотар өчен, зәңгәр җептән генә,
Бер читенә куйдым исемем билгесен.
Шуның белән сиңа бүләк итәм бүген
Яшьлек хисләремнең тәүге изгесен.

Чиккән кульяулыгын Айтугановның ишегалдында эленеп торган пальто кесәсенә илтеп сала. Кулына чыбыркы тотып, тыштан Әптәлим керә.

Әптәлим. Җәмилә, мине иптәш Айтугановны илтергә билгеләгәннәр иде.

Җәмилә. Хәзер мин аңа әйтермен. (*Бүлмәгә кереп китә.*)

Бераздан сәхнәгә, үзара сөйләшеп, Айтуганов, Халидә, Зиннур, Шакирҗан, Гамилә, Җәмилә, Нурулла, Гозәир карт чыга.

Айтуганов. Минемчә, сезгә проектның ике вариантын да күздә тотарга кирәк булыр. Кайсы сезнең өчен уңайлы, шунысын кабул итәрсез.

Халидә. Киңәшегез өчен рәхмәт. Безнең өчен, әлбәттә, дүрт авыл белән салу уңайлы.

Айтуганов. Ярый, Гамилә апа, хуш, сау булыгыз!

Гамилә. Башка сыебыз булмады инде, гаеп итә күрмәгез. Ашык-пошыграк булды шул. Кунган булсагыз, мунча ягып, коймак белән сыйлаган булыр идек.

Айтуганов. Болай да бик яхшы сыйладыгыз. Рәхмәт, Гамилә апа, Шакирҗан абзый, хуш, Җәмилә, исән бул!

Бөтенесе белән күрешеп китә. Гамиләдән башкалар озата чыгалар.
Гамилә кунак киткәннән соң өйдә була торган тәртипсезлекләрне рәтләп йөри.
Җәмилә керә.

Гамилә. Киттеләрме, кызым?

Җәмилә. Әйе, әни, киттеләр...

Гамилә. Нишләп, кызым, күзең кызарган?

Җәмилә. Чаналарындагы печәннәрен рәтләгән идем, чүп керде, ахры...

Шакирҗан белән Халидә керә.

Халидә. Җәмилә, бая сорарга онытканмын, теге материаллар әзерме?

Җәмилә. Хәзер, Халидә апа, язып бетердем. (*Китә.*)

Шакирҗан. Әйе, шулкадәр җирнең сазламыкта әрәм ятуын үзебез дә белә идек, ә шуны рәткә кертү турында беребезнең дә башына килмәгән.

Халидә. Бөтен бәла дә шунда, Шакирҗан абзый, без әле һаман да бүгенге көн белән яшибез. Киләчәк өчен кайгыртмыйбыз. Кемнеңдер безгә әйтүен көтәбез.

Мортаза керә.

Гамилә. Карткаем, утын гына кертеп бирче әле!

Шакирҗан белән Гамилә чыга.

Мортаза. Шулай диең, хатын... Минем белән көрәшергә көчең җитмәгәч, башкаларны куштым, диң.

Халидә. Ничек инде ул «башкаларны»?

Мортаза. Шулай. Айтуганов синең җырларыңны җырлады түгелме соң?

Халидә. Айтуганов кебек кеше дә минем сүзләремне кабатлаган икән, аларның дәреслегендә шигең калмаска тиеш иде. Ләкин мин синең өчен кызарып утырдым. Җитмәсә тагын, яшь бикәч шикелле үпкәләп, мәҗлес кадәр мәҗлесне ташлап киттең. Шуның белән үзеңнең культурасызлыгыңны күрсәттең.

Мортаза. Ә син бөтен кешене, хәтта Гозәир картны да, миңа каршы котырткансың.

Халидә. Ахмак икәнсең...

Мортаза. Нәрсә, нәрсә дидең?

Халидә. Кеше өендә акырма, кайткач җикеренерсең. (*Пауза.*) Менә нәрсә, бая сиңа райком секретаре Дәүләтшин шалтыраткан иде. Иртәгә «Тугай» колхозының икмәкләрен пристаньга илтешергә өмә оештырганнар. Бездән дә ярдәм сорыйлар.

Мортаза. Җитәр инде, мин аларга бик күп булыштым. Һәр ел саен орлык алып торалар. Ашлыкларын сугып бирәм, корма җибәрәм. Ә үзләреннән күзеңә кырып салырга бер ярдәм күрмәссең.

Халидә. Алардан ярдәм өмет итәргә безгә оят булмас микән? Алар бит өченче ел бөтен авыллары белән яндылар. Быел автомашиналары ватылган, ат көчләре аз. Мин иптәш Дәүләтшинга, ярдәм итәрбез, дидем.

Мортаза. Тукта әле, нигә син минем өчен вәгъдә бирәсең? Бу нәрсә, миңа приказмы? Минем өстән хатыным начальлек итә башладымыни инде? Менә нинди көнгә калдым бит!..

Халидә. Мин сиңа хатының булып түгел, партоешма секретаре, авыл советы председателе булып әйтәм. Риза түгелсең икән, ул вакытта, әйдә, мәсьәләне партия җыелышына куеп карыйк.

Мортаза. Куй, куй!.. Ул чагында мин дә синең белән тору-тормау мәсьәләсен куярмын!..

Кәгазьләр тотып, Җәмилә чыга.

Җәмилә. Менә, Халидә апа, язып бетердем.

Халидә. Рәхмәт, Җәмилә, хушыгыз! (*Китә.*)

Җәмилә бүлмәгә уза. Шакирҗан керә.

Шакирҗан. Энем Мортаза, сиңа киңәш итеп шуны әйтермен дигән идем: быел безнең бик бай елыбыз, иген әйбәт уңды. Шулай булуга карамастан, син бүленми торган фондка аз калдырырга җыенасың...

Мортаза. Ат азгыны тайга ияргәндәй, син дә аларга тагылдыңмыни? (*Ачуланып чыгып китә.*)

Тыштан, җилпуч күтәреп, Гамилә керә.

Гамилә. Мортазага ни булган, койрыгы көйгән мәче кебек чыгып бара. Чак-чак кына җилпучымны бәреп онымны түкмәде.

Гамилә бүлмәгә кереп китә дә җилпучын калдырып чыга.

Аш-су артыннан йөреп тыңлый алмадым, нәрсә турында бәхәсләштегез соң?

Шакирҗан. Безнең колхозның эшләрен азрак тәнкыйть итте.

Гамилә. Аннан ни зыян? Начальство түгел бит әле.

Шакирҗан. Начальство түгелен түгел, шулай да бик үтемле итеп әйтте.

Гамилә. Сиңа төбәп әйтелмәгән булса, зыян юк. Әйдә, ятыйк инде, Кадер кичәсе түгел.

Утны сүндерәләр. Күрше бүлмә ишеге аша бу якка ут шәүләсе төшеп бераз яктырта. Гамилә караватка, Шакирҗан диванга барып ята.

Гамилә (*тәрәзәдән карап*). Нигәдер Мортазалар ятмыйлар. Әллә инде үзләрендә кеше бар.

Шакирҗан. Әйе, бу егет, Гәрәйне әйтәм, барыбызның да йокысын ачты шул... Бервакытны шулай, Герман сугышында йөргәндә, Карпат таулары арасындагы бер авылга кунарга туктадык. Бүгенге кебек көз көне иде. Тездән пычрак ерып килгән солдатлар баш төртүгә йокыга киттеләр... Тик мин генә йоклый алмыйча ятам... Нигә дисәң, шул көнне генә әтинең үлүе турында өйдән хат алган идем. «Бичара карт... бөтен гомере буена нинди рәхәт күрде инде?!» — дим... Син тыңлыйсыңмы? (*Барып карый.*) Бәлеш, эреп тә киткән бу!

Арт бүлмәдән Җәмиләнең әкрен генә җырлаганы ишетелә:

Ай югары, ай югары,
Айга менәсем килә.
Айга менеп, түбән карап,
Сине күрәсем килә.

Шакирҗан. Гамилә, Гамилә, дим!

Гамилә (*уянып*). Нәрсә бар тагын?

Шакирҗан. Бу, Сәхибгәрәй абзый малайларын әйтәм, берсе Әхмәтгәрәй, икенчесе Мөхәмматгәрәй иде, бусы кайсы икән?

Гамилә. Әллә тагын?

Шакирҗан. Исеңдә түгелме?

Гамилә. Исемдә булса да, хәзер аларны кайдан беләсең? Икесе дә бертөсле, игезәк малайлар иде.

Шакирҗан. Әйе, егерме өч ел үткән шул, ярты гомер дигән сүз. Шулай да аларның кайсы Әхмәтгәрәй дә, кайсы Мөхәммәтгәрәй икән?

Гамилә. Юк белән башыңны катырма! Синең өчен кайсы булса да барыбер түгелмени?

Шакирҗан. Түгел шул. Менә бу бездә булганының кайсы икәнен беләсем килә.

Гамилә. Гәрәй инде.

Шакирҗан. Ул бит коры гына Гәрәй. Безнең татарда һәр кешенең исеменә нинди дә булса бер койрык тагыла. Менә шуны беләсем килә.

Гамилә. Ярый. Мине аптыратма, йоклыйсым килә.

Әйләнеп ята. Аргы бүлмәдә тагы Җәмилә җырлый:

> Алсу күлмәгем киямен,
> Башым түбән иямен.
> Алсу гөлләргә охшатып,
> Син гүзәлне сөямен.

Шакирҗан торып бүлмә ишегенә бара.

Шакирҗан. Кызым, кызым, Җәмилә, бире чык әле!

Җәмилә бу якка чыга.

Җәмилә. Син эндәштеңме, әти?

Шакирҗан. Нигә йокламыйсың, кызым?

Җәмилә. Минем, әти, язасы эшләрем бар иде.

Шакирҗан. Кызым, бу Айтуганов абыеңның исеме ничек әле?

Җәмилә. Гәрәй.

Шакирҗан. Тулысы белән?

Җәмилә. Ничек тулысы белән?

Шакирҗан. Мөхәммәтгәрәйме, әллә Әхмәтгәрәйме, дим.

Җәмилә. Мин анысын әйтә алмыйм, әти. Нигә сорыйсың?

Шакирҗан. Тулы исемен беләсем килә, һич тә таба алмыйм, шуны уйлап йокыга да китә алмыйм.

Җәмилә. Син, әти, йөзгә кадәр санап кара әле, бәлки, онытырсың.

Шакирҗан. Санау оныттырамы?

Җәмилә. Шулай диләр бит.

Шакирҗан. Ярый алайса, бар, кызым, йокла.

Җәмилә китә. Шакирҗан урынына барып ята. Санарга керешә.

Шакирҗан. Бер, ике, өч... ун... егерме... илле... сиксән... йөз... (*Торып утыра.*) Анасы, анасы, дим!

Гамилә (*тагын уянып*). Тагын шул Гәрәйләр турындамы?

Шакирҗан. Юк, аналары турында. Бик яшь иде, мин әйтәм, Сәхибгәрәй абзыйның ул икенче хатыны булды микәнни?

Гамилә. Ят инде, ят! Әнә этәч кычкыра.

Шакирҗан. Тукта, капкада кемдер бар.

Гамилә. Чыннан да син бүген Гәрәйләрең белән саташа башладың, ахры. Мондый чакта кем йөрсен?!

Шакирҗан. Әнә ишек шакыйлар. (*Ишеккә барып.*) Кем бар?!

Халидә (*тыштан*). Бу мин, Шакирҗан абзый.

Гамилә. Халидә түгелме? Нишләп йөри икән?

Шакирҗан чыгып китә. Чемодан тоткан Халидә белән керә.

Халидә. Вакытсыз чакта борчуым өчен гафу итегез.

Шакирҗан. Нәрсә, Халидә, әллә тагы берәр кунак килдеме?

Халидә. Юк, Шакирҗан абзый, мин үзем сезгә күчеп килдем.

Шакирҗан. Ничек күчеп килдең?

Халидә. Күрәсең, Мортаза белән безнең юллар бер түгел... Квартира тапканчы үз яныгызда торырга рөхсәт итсәгез иде?

Гамилә. Ул ни дигән сүз, әйдә, Халидә, рәхим ит!

Кулыннан әйберләрен алалар. Алгы бүлмәгә узалар.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга «Алсу таң» колхозының яңа җиткергән идарә йортының утырышлар залында бара. Уң якта — беренче планда зур балкон ишеге. Сулда «Парткабинет», «Идарә председателе» дип язылган табличкалы ишекләр. Артта — тыштан керү ишеге. Пәрдә ачылганда Борма Тау партоешмасының колхоз активы
белән үткәрелгән җыелышы.

Халидә. Зиннур тәкъдим иткән резолюция буенча кемгә сүз бирим, иптәшләр?

Җәмилә. Резолюция бик әйбәт язылган. Өстәмә итеп мин шуны әйтер идем: Гозәир бабайга, тәҗрибә эшләрен җәеп җибәрү өчен, хата-лаборатория, питомник, парник хуҗалыклары оештырып бирүне идарә алдына кисәтеп куярга.

Халидә. Бу дөрес һәм урынлы тәкъдим.

Шакирҗан. Минем бер өстәмәм бар: умартачылык хуҗалыгы турында һәр елны сөйләнеп киләбез, төрле тәкъдимнәр кертәбез. Ләкин безнең идарә шуны тормышка ашыруда сүлпәнлек күрсәтә.

Зиннур. «Сүлпәнлек күрсәтә» түгел, Шакирҗан абзый, бернәрсә дә эшләми дияргә кирәк.

Шакирҗан. Әйе, бернәрсә дә эшләми диеп әйтергә дә мөмкин булыр.

Халидә. Бу тәкъдимгә ни дисез?

Зиннур. Мәсьәләнең куелышы дөрес. Тик аны конкретлаштырырга гына кирәк. Ягъни: быел җәйгә егерме биш баштан да ким булмаган санда кортчылык хуҗалыгы оештырырга идарәне мәҗбүр итәргә дип языйк.

Халидә. Тагын да нинди тәкъдимнәр булыр?

Фәрдәнә. Башка тәкъдимнәр күренми, тавышка куярга кирәк.

Мортаза. Миңа да сүз бирегез әле?

Халидә. Рәхим итегез!

Мортаза. Җәмилә әйткәнчә, «резолюция бик әйбәт язылган», конешно: «Тәкъдим итәргә!», «Кисәтеп куярга!», «Идарәне мәҗбүр итәргә!» диелгән. Болар турында мин соңыннан әйтермен. Гидростанция салуга килгәндә, мин икеләнмим. Конешно, станцияне салабыз. Тик хәзер нинди станция салу турында гына сүз барырга тиеш. Ә инде резолюциягә Зиннур язган дүрт авыл белән бергәләп салу тәкъдиме дөрес түгел, хата тәкъдим.

Җамали. Правильно!

Мортаза. Үзегез уйлап карагыз, әгәр дә без станцияне дүрт авыл белән бергәләп салабыз икән, шул станция бирәчәк ике йөз киловатт энергияне дүрт авылга бүлеп карагыз әле, күпмешәр тия?

Җамали. Пучтяк, конешно!

Мортаза. Тавыклар көләрлек! Бу шул Карасу авылындагы гидростанция шикелле — ашлык сукса, өйләргә ут бирми; ут бирсә, бер барабанны да әйләндерә алмый торган җан көеге булыр иде. Безгә андый кәрлә станция кирәкми!

Җамали. Менә ват, дөрес!

Мортаза. Аннан, иптәшләр, шул ягын да уйлагыз, үз җиребезгә, үз суыбызга станция салып, ничек инде башка авылларны кинәндереп торыйк! Шул ук вакытта, үзебезгә туйганчы файдаланырлык уты да булмасын, имеш!

Җамали. Менә монысы ишшу да дөрес!

Мортаза. Менә шушы карашлардан чыгып, мин үзебезнең авыл өчен генә салырга дигән тәкъдим кертәм.

Фәрдәнә. Ә соң акча, средство ягы ничек, җитәрме?

Мортаза. Табарбыз. Үзебездә җитми икән, авыл хуҗалыгы банкысыннан озак сроклы ссуда сорарбыз.

Зиннур. Дүрт авыл белән салганда, эшче көчләре ягыннан җиңел булачак. Һәм тизрәк салырга мөмкинлек бирәчәк. Шул хакта уйладыгызмы?

Халидә. Аннан, үзебез өчен генә салабыз икән, ике йөз киловатт энергияне кая куярбыз да, ничек итеп аны рациональ файдалана алырбыз?

Мортаза. Тормыштан, политикадан артта каласыз, иптәш Халидә! Без хәзер социализм фазасыннан коммунизм фазасына кереп барабыз!

Җамали. Правильно!

Мортаза. Сентябрь Пленумы карарлары безгә җәмәгать хуҗалыкларын үстерүне бурыч итеп куйды түгелме? Гончар эшләү заводы салырбыз, такта яру, тугым тарту мастерскойлары оештырып җибәрербез. Шуның өчен мин резолюциядән «дүрт авыл белән бергәләп салу» дигән сүзләрне төшереп калдырырга тәкъдим итәм.

Халидә. Мин сезне аңлый алмыйм, иптәш Шәфигуллин. Сез, башта средство юклыкны сылтау итеп, гомумән, станция салуга каршы идегез. Хәзер инде средство һәм башка яклардан җиңеллек бирә торган, дүрт авыл белән салу тәкъдиме кертелгәч, аңа да каршы чыгасыз. Ярый, мин сезнең тәкъдимегезне тавышка куям. Иптәшләр! Резолюциядән «дүрт авыл белән бергәләп салу» дигән сүзләрне төшереп калдырырга дигән

кешеләр кулларын күтәрсеннәр! (*Мортаза белән Җамалидән башка беркем дә тавыш бирми.*) Димәк, ничек язылган булса, шулай кала. Сез башка пунктлар турында да нидер әйтергә булган идегез, иптәш Шәфигуллин?

Мортаза. Әйе. Аннан, иптәшләр, гидростанция салу кебек катлаулы эшкә тотынганда, сазламык киптерү, җиләк-җимеш бакчалары төзү кебек эшләр белән шөгыльләнү артык түгелме? Менә шул хакта яңадан бер кат уйлап карагыз әле.

Фәрдәнә. Яңадан уйлап-нитеп торасы юк, бик әйбәт уйланган. Җитәр инде, Мортаза абый! Моңа кадәр безнең идарә аны эшлибез дә, моны эшлибез дип, бик күп өметләндереп килде. Хәзер безгә Халидә апа докладында куелган мәсьәләләрне ничек итеп тизрәк тормышка ашыру турында гына уйларга кирәк.

Мортаза. Халидә апаң эшләмәс бит, мин дә эшләмәм, сезгә — колхозчыларга эшләргә туры киләчәк. Авырга килсә, миңа үпкәләмәссез.

Халидә. Иптәшләр! Зиннур тәкъдим иткән резолюция проектын Җәмилә, Шакирҗан абзыйлар керткән төзәтмәләр белән кабул итәргә дигән кешеләр кулларын күтәрә. (*Мортаза белән Җамалидән башкалар тавыш бирәләр.*) Ә сез, Шәфигуллин иптәш?

Мортаза. Мин каршы!

Җамали. Мин дә каршы!

Мортаза. Шуның белән бергә, бүгеннән башлап, колхоз председателе түгеллегемне дә белдерәм! (*Бөтен кеше аптырап кала.*)

Шакирҗан. Мортаза, син ни сөйлисең, акылыңдамы?

Мортаза. Әйе, әйе, Шакирҗан абзый, башкача мин эшли алмыйм.

Җамали (*елак тавыш белән.*) Җыйнаулашып бер кешегә каныккач, конешно, эшли алмый! Ни генә әйтсә дә гаепкә аласыз. Үз авылы өчен станция салу разе начар эш?

Зиннур. Берәү дә аны начар дигәне юк, Җамали абзый, дүрт авыл белән бергәләп салу безнең өчен уңайлырак һәм җиңелрәк, дибез.

Җамали. Уртак эшне эт җыймас дигән бабайлар. Күрше авыллар белән талашып, кырылышып бетәрбез, шул булыр.

Шакирҗан. Җамали, синең бу чыгышың «туй узгачтан дөмбергә» дигән кебегрәк булды. Тавышка кухганчы сөйләргә иде.

Җамали. Сөйләрбез әле, идарә җыелышы гына булсын, общий собранҗа гына булсын, икмәк ашаткан председателебезне кыерсытырга ирек бирмәбез! Сезгә нәрсә? Үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын дигәндәй, сез бит барыгыз да язу-сызу эшендә йөргән онтилигентлар! Колхоз эшен җилкәсендә тартып барган колхозчылар моңа риза булмас!..

Фәрдәнә. Син үзең соң нинди эш кырганың бар?! Озын кыш буена, карт аю кебек, пожар депосында йоклап чыгасың. Җәен пожар атлары белән урманнан утын, печән ташып, язгы өзеклеккә безгә үк биш бәядән сатып ятасың. Җитмәсә тагын шулар өчен һәр ел саен идарәдән оялмыйча биш йөз хезмәт көне аласың.

Халидә. Шуның белән, иптәшләр, җыелыш тәмам.

Халидә, Зиннур, Шакирҗан, Фәрдәнәләр парткабинетка кереп китәләр. Җәмилә белән Мортазадан башкалар таралалар.

Җәмилә. Мортаза абый, миңа калыргамы?

Мортаза. Мин синең белән нишлим?

Җәмилә. Безгә хәзер партия җыелышының карары буенча эш планы төзергә кирәк.

Мортаза. Зиннур белән Халидәләр төзегән план бар бит инде.

Җәмилә. Ул план түгел, резолюция генә.

Мортаза. Барыбер. Без хәзер синең белән шул резолюция буенча биергә тиеш!

Җәмилә. Аңламыйсыз, Мортаза абый, хәзер безгә...

Мортаза (*аның сүзен бүлеп*). Син миңа акыл өйрәтмә, яме! «Алсу таң» колхозын мин аякка бастырдым! Шулай ук синең кебек тәти кызларга ун классны белем алуга мөмкинлек тудыручы да мин булдым... Моннан соң да йөзем белән җиргә егылмам! Бар, кайтып йокла!

Җәмилә китә. Кабинеттан Фәрдәнә чыга.

Мортаза. Фәрдәнә, тукта әле!

Фәрдәнә. Нәрсә бар?

Мортаза. Халидә, Зиннурларның миңа каршы сөйләүләрен мин аңлыйм, тик менә синең аларга иярүең мине таңга калдырды.

Фәрдәнә. Нигә аңа таңга калырга? Мин бик туры сөйләдем.

Мортаза. Әйе, туры... Ләкин, рус әйтмешли: как дуга.

Фәрдәнә. Син бүген бездә булдыңмы?

Мортаза. Әйе, булдым.

Фәрдәнә. Әти белән нәрсә турында сөйләштегез?

Мортаза. Колхоз председателе белән завхоз авызында нинди сүз булсын, эш турында сөйләштек.

Фәрдәнә. Нигә яшерәсең? Үзеңә мине хатынлыкка кодалап баргансың ич!

Мортаза. Барсам?! Әллә ул начарлыкмы?

Фәрдәнә. Әти карашынча, билгеле, яхшылык. Үлеп-үлеп мине сиңа димлиләр. Аның өчен мин аны гаепләмим, чөнки ул иске кеше. Тик менә син, колхоз председателе, җитмәсә тагын коммунист башың белән, әтиемне күндереп, мине үзеңә алырга йөрисең. Ләкин бит татар кызларын байлык, авторитетка кызыгып озату заманнарын без хәзер иске китаплардан укып кына беләбез.

Кабинеттан Зиннур белән Шакирҗан чыга. Фәрдәнә белән Зиннур җитәкләшеп китәләр. Шакирҗан Мортаза янына килә.

Шакирҗан. Катырак бәрелгән булсам, үпкәләмә, Мортаза. Җитәкче булуның хикмәте «аны эшләргә дә, моны эшләргә» дип боерык биреп йөрү белән генә чикләнми. Башкаларның да сүзенә колак салырга кирәк. (*Китә.*)

Халидә чыга.

Халидә. Кайтырга вакыт, Мортаза.

Мортаза. Күрәсең ич, эшне яңа председательгә тапшырырга әзерләнеп утырам.

Халидә. Бу вакытта нинди эш? Сәгать бер тулган инде.

Мортаза. Шулай эшләп тә бит сүктегез.

Халидә. Сүкмәдек. Чын дөреслекне төшендерергә тырыштык. Син моны аңларга тиеш, Мортаза. Мин беләм, син аңлыйсың да. Ләкин тискәрелегеңә барасың. Син, бәлки, миңа килеп ялынырлар дип уйлыйсыңдыр? Юк, коллектив беркемнең дә капризына юл куймас. Бу турыда яхшылап уйла син, Мортаза. (*Китә.*)

Мортаза уйланып йөри, урамда гармун тавышы ишетелә.
Бераздан Әптәлим керә.

Әптәлим (*өсләрен каккалап*). Ну, буран!..

Мортаза. Һаман дулыймы?

Әптәлим. Котыра гына... Мортаза абый, тәмәкең бармы?

Мортаза. Үзеңнеке юкмыни?

Әптәлим. Бар иде дә... Клубта яшьләр тартып бетерде. (*Папирос кабызалар.*) Беркөнне мине Халидә җиңги чакырткан иде...

Мортаза. Соң, ничек, кыздырдымы?

Әптәлим. Ул алай ачуланмады, авыр сүз дә әйтмәде. Ә шулай да эредем дә төштем... Гомеремдә болай беркемнән дә шүрләгәнем юк иде. Мин хәзер эшкә чыгу-чыкмау турында түгел, моңа кадәр шуны аңламавыма газапланам... Синдә дә шундый хәл бугай, әле хәзер тәрәзәдән карап тордым да, кызганып, хәлеңне белергә кердем...

Мортаза. Рәхмәт...

Әптәлим. Мондагы утырыштан кайтышлый, Шакирҗан Җәмиләсе клубка кергән иде. «Яшьләр, уйнап-җырлап калыгыз, тиздән Сарысазны киптерергә керешәбез!» ди. Шунда идарә турында сүз чыккач, Сабирҗан Шамиле әйтә: «Безнең идарәдә хөкүмәт, партия куйган бурычларны тиешенчә аңламаучы кешеләр утыра, алыштырырга иде үзләрен»,— ди. Бу нәрсә инде, Мортаза абый, кая барма, синең турыңда сөйлиләр.

Мортаза. «Син монда бала-чага гайбәтен сөйләп йөрмә әле, яме!

Әптәлим. Бер дә гайбәт түгел, валлаһи, менә шулай. Шунда тыңлап утырдым-утырдым да түзмәдем. «Юк, мин әйтәм, Мортаза абыйны мин беркемгә дә алыштырмыйм!» — дидем.

Мортаза. Ай-һай, әйтә алдың микән?

Әптәлим. Әйттем, чатлатып әйттем. Эчемнән, конешно.

Мортаза. Минем монда эшләрем бар. Син бар, кайтып йоклавыңны бел.

Әптәлим. Юк әле, кайтмыйм. Фермада дежурда торучы кызлар янына барам. (*Китә.*)

Урамда үзе гармунда уйнап, үзе җырлаганы ишетелә. Нурулла керә.

Нурулла. Ай-яй!.. Буран... Әптәлим эшсезнең чыкканын көтеп, тешләрем тешкә тиеп бетте...

Мортаза. Йокламыйча, буранда нишләп йөрисең?

Нурулла. Сезнең өйдә Мәфтуха белән кайгырып утырдык та, кайтмагач, хәлеңне белергә килдем. Син мескенне бит...

Мортаза. Ярый, төче телләнми генә сөйлә, йомышың нидә соң?

Нурулла. Йомыш шул: калага сушилка өчен калайлар алырга барам. Менә Миргалимнән кәгазьләр яздырдым, кулыңны куйсаң, иртә намаздан китәм.

Мортаза. Ләкин бит хәзер мин председатель түгел.

Нурулла. Ничек түгел? Әллә төшерделәрме?

Мортаза. Үзем отказаться иттем.

Нурулла. Ни өчен?

Мортаза. Шулай кирәк булды, азат итегез.

Нурулла. Алай... Кемне куйдылар?

Мортаза. Анысы инде идарә эше. Иртәгә бөтен членнарны җыям да гаризамны каратам.

Нурулла. Алай булса юк, булмый ул. Синең китүеңә идарә членнары риза буламы?!

Мортаза. Булмый нишләсеннәр? Үзем теләмәгәч, көчләп тота алмаслар.

Нурулла. Анысы шулаен шулай да... Син китсәң, миңа да аякны киенергә туры килер... (*Пауза.*) Юк, моның булуы мөмкин түгел. Ул эшкә район да, колхозчылар да күнмәсләр. Әйдә, кайтыйк әле, сезнең өйдә бераз утырып алырбыз дип, мин кыстырып килгән идем. (*Түш кесәсендәге шешә башын күрсәтә.*)

Мортаза. Нигә аны әйтми торасың, әйдә, чыгар!

Нурулла. Монда ярар микән соң?

Мортаза. Нигә ярамасын, мин бик арыган идем.

Нурулла. Армый ни! Биш сәгатьләп утыргансыз бит. (*Өстәлдәге стаканга аракы салып бирә.*) Бик каты алыштыгыз, ахры?

Мортаза. Әйе, Халидә белән Зиннурларның сөйләвен мин аңлыйм, алар яңа кешеләр, эш күрсәтергә тырышалар. Шакирҗан картның да чыгышы миңа бик ачык, каян җил иссә, шунда ава торганрак кеше. Ә менә синең кызың Фәрдәнә...

Нурулла. Ул да сиңа каршы чыктымы?

Мортаза. Ничек кенә әле...

Нурулла. Ах, каһәр суккан бала... Никадәр әйтәм, никадәр өйрәтәм: «Үз эшеңне бел дә, агына да, карасына да катышма»,— дим. Юк, тыңламый. Ярый, кайгырма, җайлыйбыз аны. Бүген үзенә, Мортаза абыеңа димләми булмас, ахры, дигән идем, авызы бияләй кадәр ерылды...

Мортаза. Ялганлыйсың, карт төлке!.. Ул хакта да миңа бая шундый итеп әйтте ул... Гарьлегемнән нишләргә белмәдем.

Нурулла. Хатын-кызның шул инде, бервакытта да алар сиңа сөям, яратам дип әйтмәс, һаман боргаланыр-сыргаланыр, иһаһай да миһаһай килер. Әйтәм бит, ул турыда син борчылма, Фәрдәнә синеке! Тик бер шарт белән.

Мортаза. Нинди шарт?

Нурулла. Башма баш ясыйбыз. «Аршин мал алан»дагы кебек, син миңа Мәфтуха апаңны бирәсең, мин сиңа Фәрдәнәне...

Зур толып киеп Моракаев керә.

Мортаза. Иптәш Моракаев?..

Нурулла. Исмәгыйль иптәш, исәнме?

Мортаза. Әйдә, өстеңне сал. (*Нурулланы читкә алып.*) Нурулла абзый, бар син, апага әйт, ит пешерсен. Аннан, сельпо председателен уятып...

Нурулла. Менә миндә бар бит әле.

Мортаза. Юк. Аның үзенә бер бөтен кирәк. (*Нурулла китә.*) Иптәш Моракаев, нишләп болай вакытсыз?

Моракаев. Сезнең җыелышка дип килә идем, яшь ат, буранда адашып, түбән якка алып киткән.

Мортаза. Буран дигәннән, безнең монда да «Сафура бураны» булып алды әле.

Моракаев. Әйе, Шакирҗан абзый сөйләде. Мин аларга туктадым. Начар хатыннар комедиясе уйнап алгансың.

Мортаза. Бер дә алай түгел, иптәш Моракаев, алар мине дүрт авыл белән станция салырга көчлиләр. Күнә алмыйм, мине председательлектән бушатыгыз, дидем. Шул гына.

Моракаев. Коммунист түгел син, чүпрәк! Бәхетең, собраниегезгә килеп җитмәдем. Бу капризың өчен председательлегеңнән генә түгел, партиядән дә чыгарырга тәкъдим керткән булыр идем. Индивидуалист син, иске крестьян бунтарьлыгы белән җиңәргә уйлыйсың. Юк, брат, андый приемнар белән хәзер безне куркыта алмыйсың. Сиңа ялынып торырга утызынчы ел түгел, һәр көнне безгә шәһәрдән югары белем алган агрономнар, инженерлар килеп торалар. Иртәгә үк берсен китереп куярбыз, нишләрсең?

Мортаза. Үземә күрә берәр эш бирерсез әле, урамга чыгарып ташламассыз.

Моракаев. Әйе, мондый чыгышыңнан соң бирербез муен тамырыңа! Иртәгә үк мин сине райком бюросына куйдырам.

Мортаза. Туктале, сиңа ни булды?.. Бәлки, ялгышканмындыр. Ләкин барысы да шул хатын аркасында. Халидәгә, хатынга үч итеп эшләдем.

Моракаев. Ул сиңа хатын гына түгел, беренче чиратта, партоешма секретаре. Син моны аңларга тиеш идең.

Мортаза. Кызулык белән булды. Соңыннан мин аны үзем дә төшендем. Ләкин син моны инде райкомга җиткермәсәң дә була...

Моракаев. Утыр, хәзер үк гариза яз!

Мортаза. Райкомга?

Моракаев. Юк. Партоешма секретаре Халидә Шәфигуллинага. Бүгенге җыелышта ясаган тупас чыгышыңны танып, кичерүләрен сора.

Мортаза. Бәлки, миңа телем белән генә әйтсәм дә ярар.

Моракаев. Юк, ярамый. Чөнки бу — политик мәсьәлә.

Мортаза. Ярый, иртә белән өйдә язармын.

Моракаев. Өйдә түгел, хәзер, менә монда яз!

Мортаза. Соң бит әле алар аны бүген карамыйлар.

Моракаев. Беләм мин ир белән хатынның эшен. Юмалап берничә сүз әйтерсең дә ризаландырырсың. Бу — зур политик мәсьәлә. Шуның өчен ак өстенә кара белән язылып калынырга тиеш. Яз! (*Мортаза теләр-теләмәс кенә барып утыра да, телләрен чыгарып, гариза яза башлый. Моракаев папирос чыгарып кабыза, Мортазаны күзәтә.*) Ха-ха-ха!.. Азапланма, кирәкми, шаярдым гына.

Мортаза. Фу... Котымны алдың, Исмәгыйль... Бер бәкедән су эчкән үгезләр идек бит, ни генә булды икән моңа, дим.

Моракаев. Шүрләдең, ә?

Мортаза. Политикага китереп бәйләгәч, шүрләрсең. Сезнең кебекләр еш кына, инәдән дөя ясап, безнең братларны аяктан егып куялар.

Моракаев. Дусларча әйткәндә, синең ул чыгышың яхшы чыгыш булмаган. Аның белән син үзеңә булган каршылыкны тагын да көчәйттең. Но ничего, болай булгач, бар да җайланыр. Без бүген, райком секретаре иптәш Дәүләтшин белән киңәшеп, сезнең ул гидростанция салу мәсьәләгезне хәл иттек.

Мортаза. Хәл иттегез? Минемчәме?

Моракаев. Синеңчә дә, аларча да түгел. Безнеңчә. Район үзәге белән уртак станция итеп салабыз. Ягъни станция салу расходларының яртысын район хисабына алабыз. Шуның өчен сез, ике йөз киловатт энергиягезнең яртысын безнең район учреждениеләрен, мәктәп, клубларын яктыртырга бирерсез. Калган йөз киловаттан үзегез файдаланырсыз.

Мортаза. Менә бу фикер, менә бу эш булыр ичмасам. Рәхмәт, иптәш Моракаев, рәхмәт сезгә... Димәк, район белән уртак булгач, төзү материалларын, машина җиһазларын алырга да җиңел булачак. Тик менә эшче көчләре турында ничегрәк була инде? Шул хакта сөйләштегезме?

Моракаев. Сөйләштек. Власть үзебезнең кулда бит. Кирәк булган эшче көчләрен, ат-машиналарны да башка колхозлардан алырбыз.

Мортаза. Ләкин бу эшкә Халидәләр ничек карар икән?

Моракаев. Мин килү белән үк Шакирҗан абзыйның тел төбен тартып карадым. Ул риза. Минемчә, Халидә һәм башкалар да каршы килмәсләр. Чөнки бу план алар планына каршы килми ич. Иртәгә, бөтен партия членнарын чакырып, идарәнең киңәйтелгән утырышын җыярсың. Мин шунда чыгыш ясармын.

Мортаза. Яхшы, иптәш Моракаев, әйдәгез хәзер миңа, шунда бераз мөгәричләп алырбыз!

Китәргә җыеналар. Урамда гармун тавышы ишетелә.

Моракаев. Бу кем, бик матур итеп уйный?

Мортаза. Әптәлим. Теләсәгез, аны да үз яныбызга алырга була. (*Чыгып китәләр.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шул ук «Алсу таң» колхозының идарәсендә бара. Ачык тәрәзәләр аша ап-ак чәчәкләргә күмелгән шомырт агачлары күренә. Пәрдә ачылганда, Мәфтуха тәрәзәдән урамга карап кычкыра.

Мәфтуха. Зөфәр, усал малай, нигә аңа тиясең? Әниеңә әйтермен. (*Телефон шалтырый, трубканы ала.*) Әлләү-әлләү, дим. Әйе, «Алсу таң» колхозы. Нәстә? Кычкырыбрак әйт! Мортаза Сарысазда канаулар казыта. Халидәне белмим. Сельсоветындадыр. Җитен орлыклары килеп алырга? Ярый, Мортазага әйтермен. (*Трубканы, куя.*)

Юл киеменнән Нурулла керә.

Нурулла. Нихәл, Мәфтуха, арумы?

Мәфтуха. Шөкер әле, Нурулла абзый, үзең исән кайттыңмы?

Нурулла. Әлһәмделилләһи шөкер, монда нишлисең?

Мәфтуха. Менә балаларга нәнкә итеп куйганнар иде, идарәне җыештырып чыгыйм дип кердем.

Нурулла. Мөрәббияләре кая?

Мәфтуха. Барысы да эштә. Сарысазны киптерергә чыктылар. Ахырзаман анда, кыямәт!.. Билдән суга кереп эшлиләр.

Нурулла. Ә чәчү ни хәлдә?

Мәфтуха. Өченче көнне үк бетерделәр.
Нурулла. Бик коры тотканнар.
Мәфтуха. Мытыис машиналары убыр кебек, көне-төне чәчте. Бер атна була инде, Мортазаның юньләп йоклаганы да юк.

Артта мотоцикл тавышы.

Мәфтуха. Әнә Мортаза кайтты!

Яз кояшыннан пешкән, изүләрен чишкән, җиңнәрен сызганган хәлдә, җитез адымнар белән Мортаза килеп керә.

Мортаза. Һи!.. Нурулла абзый кайткан!.. Без сине анда әллә йортка кердеме дип тора идек.
Нурулла. Керерсең йортка! Әле заводка, әле сельэлектрога, әле авыл хуҗалыгы министрлыгына йөреп аякларым калмады.
Мортаза. Эшләр ничек соң?
Нурулла. Сельэлектро белән договор ясадык, хәзергә егерме биш тонна тимер-томыр, утыз биш тонна цемент алдык. Ленинградка турбиннарга заказлар бирдек. Проект чертежлары тәсдыйк иттереп, үзебез белән прорабны да алып кайттык.
Мортаза. Прорабны да? Кая ул? Кемдә?
Нурулла. Алар әле Моракаев, Айтугановлар белән пристаньда районнан машина көтеп калдылар. Мин күрше авылларга утырып кайттым.
Мортаза. Айтуганов, дисеңме? Ул нишләп йөри? Ялга кайтамы әллә?
Нурулла. Безнең райкомга аны секретарь итеп җибәргәннәр.
Мортаза. Секретарь итеп?
Нурулла. Бер пароходта кайттык. Үзе белдерми, эш белән киләм, дигән була. Миңа сер итеп Моракаев сөйләде.
Мәфтуха. Мортаза, районнан шалтыраттылар, җитен орлыклары килеп алырга куштылар.
Мортаза. Апа, халык эштән кайта башлады, балаларны аналарына тапшыр да өйгә йөгер. Бик әйбәтләп ашарга әзерлә, үзләрен чәйгә алып керербез. (*Мәфтуха китә.*) Бик күп нәрсә эшләп кайткансыз, Нурулла абзый, молодцы!
Нурулла. Иптәш Моракаевка рәхмәт инде, ул булмаса, тиз генә очына чыга алмас идем. Әмма шәп тә кеше икән! Кая гына барсак та, чират-фәлән көтеп тормый, мөгезсез сыер кебек, директорына да, министрына да барып керә. Бөтен җирдә тагын үзен беләләр.
Мортаза. Ул бит Казанда зур урыннарда эшләгән егет. Ниндидер гаепләре аркасында гына безгә төзәлергә җибәрелгән кеше.
Нурулла. Транспорт булса, иптәш Мортаза, материалларны мин ташый башлар идем. Алар анда яр буенда ачык һавада калдылар.
Мортаза. Хәзер, Нурулла абзый, табарбыз. (*Телефон трубкасын алып.*) Центральный, «Пламя революции»не бирегез. (*Тәрәзәдән кемнедер күреп.*) Фәйзерахман, бире кил әле! Нишләп синең сыерларың клевер басуына кергәннәр? «Бер генә сыер» имеш! Безнең басуда корма беткәнме? Бүгеннән соң күзеңне ачып йөрергә сабак булыр, мин сине өч хезмәт көне белән штрафлыйм. Бар, эшеңдә бул! (*Трубкага.*) Бу кем? Миңа Егоров кирәк иде. А... Коля, бу син үзеңмени? Сәлам! Шәфигуллин. Чәчүеңне бетергәч, барин булып канцеляриядә ятам, диең. Ха-ха-ха!.. Эш күп дисең алайса? Шулай да безнеке кебек түгелдер, парин. Бер генә минутка. (*Тәрәзәдән.*) Әй син, малай! Нигә атыңны куасың? Ялулыкка чапмыйсыңдыр бит?! Ташла чыбыгыңны, ташла, дим! (*Трубкага.*) Менә нәрсә, Коля: мин иртәгәдән станцияне салырга керешәм, син миңа материаллар ташырга автомашинаңны биреп тор инде. Үземнеке дә берсе эшли. Күп бит ул, алтмыш тонналап, бүген бирә алмыйсың, иртәгә? Алай да ярый. Рәхмәт, Коля, мин дә сине онытмам. Хәзергә хуш, парин! (*Трубканы куя.*) Нурулла абзый, Галиәхмәткә әйт, машинасын әзерләсен. Иртәгәдән ташый башларсыз.
Нурулла. Ярый, иптәш Мортаза. (*Китә.*)
Мортаза (*телефон трубкасын алып*). МТСны бирегез. Бу кем, Әхмәтшинмы? Исәнме, малай! Шәфигуллин. Син, нигә вәгъдәңдә тормадың, теге сазламык сөрә торган тракторларыңны җибәрмәдең? Ничек, юлда күпер ватылып су аша чыга алмый ятканнар? Сазламыкның кипкән җиреннән сөрә башларга мөмкин. Хәзергә утыз гектарлап әзер. Әһә! Әнә тавышлары ишетелә. Тракторларың киләләр, дим! Рәхмәт малай, хәзергә хуш! (*Трубканы куя.*)

Халидә керә.

Мортаза. Ишеттеңме, Халидә, иптәш Моракаев станцияне салу өчен бөтен материалларны алып кайткан, хәтта прорабын да...
Халидә. Шулаймыни? Бик әйбәт булган.
Мортаза. Аннан тагын бер яңалык, иптәш Айтугановны безнең райкомга секретарь итеп җибәргәннәр.
Халидә. Кем әйтә?
Мортаза. Нурулла абзый, бер пароходта кайтканнар. Озакламый моннан үтеп китәчәкләр, ди.

Халидә. Андый кешенең секретарь булып килүе яхшы эш.

Артта тракторлар тавышы.

Мортаза. Әнә сазламык сөрергә тракторлар да килеп җиттеләр. Эшне шәп алып барам бит, Халидә, ә?
Халидә. Мактанма, Мортаза.
Мортаза. Мактанырлыгым булгач, нигә мактанмаска?! Бер атна эчендә Сарысазны нишләттек? Актарып ташладык.
Халидә. Әйе, халыкка рәхмәт инде.
Мортаза. Мин сезгә үземнең нинди кеше икәнлегемне күрсәтермен әле! Шушы ике-өч ел эчендә районда гына түгел, бөтен республика күләмендә беренчелекне алырмын! Мин әле, мин!..
Халидә. Мин түгел, «без» диген.
Мортаза. Ярый инде, «без», конешно...
Халидә. Менә шушы алдынгылыкны кулыңнан ычкындырма инде, Мортаза.
Мортаза. Тырышырмын, Халидә. Тик «Пламя революции»дән җиңелеп куймасак ярар иде. Чөнки быел бездә бик катлаулы эшләр бара бит. Станция салабыз, сазламык киптерәбез, фермага механизация кертәбез.
Халидә. Ни генә булмасын, син артта калырга тиеш түгел, Мортаза. Беләсең, артта калганны кыйныйлар.
Мортаза. Юк инде, моннан соң кыйнатмам...
Халидә. Тукта әле, без нигә караңгыда утырабыз. (*Лампага ут кабыза.*)
Мортаза. Безнең тормыш, Халидә, һаман да шулай, Сак белән Сок шикелле дәвам итәр микәнни?
Халидә. Күрәсең, шулай инде... Бер кискән икмәк кире ябышмый, диләр түгелме?
Мортаза. Дөрес түгел ул. Без бит бер-беребезне яратыша идек. Тик безнең мәхәббәт эш аркасында гына бозылды. Уйлап карасаң, тавыклар көләрлек, эш аркасында семья җимерелсен, имеш!
Халидә. Бөтен хикмәт синең принципларыңда, Мортаза.
Мортаза. Дөрес, минем ялгышларым булды. Синең ярдәмеңдә мин аларны бетерергә тырышам. Моннан соң да мине ташлама, ничек эшләргә икәнен әйтеп тор, ләкин кеше югында әйт... Беләсеңме, Халидә, мин синсез яши алмыйм. Һәр көнне өйгә кайтып керү белән сине юксынам... Син булмагач, миңа дөньяның яме юк...
Халидә. Ә соң Фәрдәнә?
Мортаза. Әй, куй әле... Ул бит болай гына, ясалма мәхәббәт кенә иде. Аның артыннан йөргән булып, сине көнләштерергә теләгән идем.
Халидә. Ләкин үтмәде!
Мортаза. Әйе, үтмәде. Синең горурлыгың алдында җиңелдем... Син элек мине сөя идең бит, шулаймы?
Халидә. Әйе, сөя идем...
Мортаза. Ә хәзер?
Халидә. Кызганам...
Мортаза. Кызгану, конешно, шул сөю була инде. Әйдә, Халидә, кушылыйк... (*Барып тотына.*)
Халидә. Җибәр әле, кулларыңа ирек бирми генә сөйләргә була бит.

Артта «Победа» машинасы тавышы ишетелә.

Мортаза. Айтуганов, Моракаевлар килделәр!

Тышка чыгып китәләр. Бераздан, сөйләшә-сөйләшә, Мортаза белән Моракаев керә.

Моракаев. Договор буенча сельэлектрога тиешле булган суманы иртәгә үк җибәрегез. Менә документлары.
Мортаза. Ярый, ярый, иптәш Моракаев, җибәрербез.
Моракаев. Менә монысы инде Ленинградка, турбиннарга бирелгән заказларның копияләре. Боларның да акчаларын иртәгәдән калдырмыйча күчерегез. Чөнки ул организация белән шәләй-вәләй эш итәргә ярамый.
Мортаза. Конешно, шулай.
Моракаев. Аннан инде мин проектный бюродан чертежларны эшләтеп алдым. Менә счетлары, аларга да биш мең сум акча җибәрергә кирәк.
Мортаза. Соң бит без иртәгә сельэлектрога күчерәбез инде, монысы тагын нәрсәгә?
Моракаев. Анысы аның договор буенча, проект, сметаларны төзеп бирү өчен. Боларны мин частный рәвештә чертежницалардан эшләтеп алдым. Юкса үзең беләсең, проектный бюро кайчан аны эшләттерә дә, кайчан безгә җибәрә?! Ә мин аның өч-дүрт көн эчендә эшен бетереп алып кайттым.
Мортаза. Анысы бик әйбәт булган, конешно... Ләкин безнең идарә...
Моракаев. Ярый инде, вакчылланма. Сиңа ни әйтәләр, шуны эшлә! Менә монысы минем командировкага бару отчетым. Бу суманы миңа хәзер үк түлисез.
Мортаза. Командировка расходлары да безнең өстәнме?
Моракаев. Билгеле, ГЭС бит сезнеке.

Мортаза. Булса соң? Энергиянең яртысы сезгә биреләчәк бит. Шулай булгач, расходлар да уртак булырга тиеш.

Моракаев. Анысы шулай... Ләкин бу кварталда безнең РИКкә җибәрелгән акчалар мәктәпләр ремонтына тотылып беткәннәр. Счетыбызда хәзер бер тиен дә акча юк. Син кайгырма, алдагы кварталларда финанс министрлыгы безгә акча җибәрү белән барысын да исәпләшербез. Кая, счетоводыңа түләргә кушып резолюцияне сал!

Мортаза (*озак кына басып тора да яза*). Менә чек бирергә куштым.

Моракаев. Ун көн эчендә дөнья кадәр эш эшләп кайттым. Шулай да кашынып торасың. Иллә саран кеше дә инде син!

Мортаза. Саранланырсың. Җәмәгать акчасы бит ул.

Моракаев. Башка берәүне җибәргән булсак, бөтен җәй буена йөреп тә очына чыга алмас иде.

Мортаза. Анысы өчен рәхмәт инде, Нурулла абзый да үзеңә шаккаткан.

Моракаев. Әй, бу нәрсә! Заманында мин миллионнар белән эш иткән егет!.. Йә, сезнең монда эшләр ничек соң?

Мортаза. Әйбәт. Кирәк булган таш, агач материаллары җитәрлек итеп әзерләнде. Эш кораллары, терлек дирбияләре дә каралган. Иртәгәдән бөтен халыкны су буена чыгарабыз. Тик менә сез бирергә тиеш булган кеше, тарту көчләре кайчанрак килер икән?

Моракаев. Аннан эш тормас. Син менә үзең монда яхшы итеп оештыр. Уракка төшкәнче, буаның эшен бетерергә кирәк. Күзгә ут бирерлек булсын. Тегеләр кая соң?

Мортаза (*тәрәзәдән карап*). Идарә алдында Гозәир карт белән сөйләшеп торалар. Бу Айтуганов чыннан да инде безгә килдеме?

Моракаев. Чыннан да. Дәүләтшинның докладын бюрода тыңладылар да моны җибәрергә карар чыгардылар.

Мортаза. Бик каты кеше булмаса ярый инде.

Моракаев. Йомшак булырга охшамый... Пароходта бик күп мәсьәләләр буенча бәхәсләшеп кайттык. Чарланган егет.

Кузнецов, Шакирҗан, Зиннур керә.

Кузнецов. Авылыгызда бер җан иясе күренми.

Шакирҗан. Яңа гына Сарысаздан кайттылар. Бар да ашый, эчәләр.

Кузнецов. Без шунда утырырбыз микән?

Мортаза. Юк, минем кабинетка узарбыз. Монда хәзер наряд алырга кереп тулалар. Әйдәгез.

Кереп китәләр. Тыштан Айтуганов белән Халидә керә. Айтуганов кулындагы кожанын ишек янындагы чөйгә элеп куя.

Халидә. Шулай итеп, безнең райком секретаре булып килдем, диң.

Айтуганов. Юк әле, Халидә апа, башта сайланасы бар. Хәзергә район партконференциясенә тәкъдим генә керттеләр.

Халидә. Сезне биредә беләләр. Шатлана-шатлана сайлыйбыз инде. Булдыксыз җитәкчеләрдән бик туйган идек.

Айтуганов. Бу ГЭС мәсьәләгез нишләп алай булды соң?

Халидә. Әлеге дә баягы район җитәкчеләребезне күндерә алмадык. Нигә, әллә начармы, иптәш Айтуганов?

Айтуганов. Начарлыкка начар димим. Сугыштан соң гына төзелгән район үзәгенә ут кирәк, әлбәттә. Ләкин срогында салып өлгертергә эшче көчләрегез җитәр микән, дим?

Халидә. Әйдәгез, шул турыда хәзер прорабның эш планнары белән танышыйк.

Кереп китәләр. Тыштан Фәрдәнә кереп нидер язарга утыра. Спай киемнәр киеп Җәмилә керә.

Җәмилә. Фәрдәнә апа, иптәш Айтуганов килгән диме?

Фәрдәнә. Әйе, Җәмилә, килде.

Җәмилә. Кемгә төште икән?

Фәрдәнә. Белмим.

Җәмилә. Үзе кайда соң әле?

Фәрдәнә. Мортаза абый кабинетында.

Җәмилә. Ул соң ничек, берәр йомыш беләнме?

Фәрдәнә. Юк, уйнап йөри. Хи-хи-хи...

Җәмилә. Нигә көләсең?

Фәрдәнә. Балаларча сорашкач, көлми нишлим соң?

Җәмилә. Сорашуның ни гаебе бар?

Фәрдәнә. Яшереп маташма, Җәмилә, без бит кызлар, бер-беребезне аңлыйбыз. Ләкин юкка нәфесең сузып йөрисең. Ул хәзер безнең райком секретаре булачак бит. (*Кереп китә.*)

Җәмилә. Райком секретаре?

Урамда матур итеп гармун уйныйлар. Балкон ишеген ачып, Җәмилә тышка уза. Авызына папирос кабып, кабинеттан Айтуганов чыга. Кожан кесәсеннән

шырпы алып кабинетка кереп барганда, Җәмиләне күреп туктап кала.

Айтуганов. Исәнме, Җәмилә!

Җәмилә. Исәнмесез, Гәрәй абый!

Айтуганов. Нишләп болай биредә берүзегез генә моңаеп торасыз?

Җәмилә. Әнә яшьләр клуб алдында гармун уйнап җырлыйлар...

Айтуганов. Чыннан да, кем ул бик моңлы итеп уйный?

Җәмилә. Әптәлим.

Айтуганов. Теге вакытны мине илтә барган егетме?

Җәмилә. Шул үзе. Ул бит безнең оста гармунчы.

Айтуганов. Шулаймыни? Җәмилә, көз көне сездә булганнан соң, районга барып җиткәч, кесәмнән бер ал яулык килеп чыкты, сезнеке түгелме ул?

Җәмилә. Нишләп минем яулыгым сезнең кесәгезгә керсен?

Айтуганов. Ул турыда уйлап, мин үзем дә аптырап беттем. Посылка итеп җибәрергә дә теләгән идем, уңайсызландым. Бер почмагына аның «Җ. Ш.» диеп тә язылган.

Җәмилә. Дөньяда Җ. Ш. лар бер мин генә түгел бит.

Айтуганов. Анысы шулай, әлбәттә. Ләкин каян ул минем кесәмә килеп кергән икән? Мин аны бик кадерләп кенә сакладым. Хәтта ул хәзер дә минем янымда, менә ул.

Җәмилә. Юк... Минем мондый яулыгымның булганы юк... Башка берәр кызыгыз шаярып салгандыр...

Айтуганов. Ә мин аның сезнеке булуын теләгән идем...

Җәмилә. Аннан сезгә ни файда?

Айтуганов. Янган йөрәгемә зур дәва булыр дигән идем...

Җәмилә. Сезнең йөрәгегез янамы?

Айтуганов. Сездә булып киткәннән бирле дөрләп яна... Яна гына да түгел, хәтта көлгә әйләнеп бара...

Җәмилә. Бичара... Шундый авыру йөрәкле кешене нигә инде безгә секретарь итеп җибәрделәр икән?

Айтуганов. Эштә андый йомшаклык күрсәтмәс дип ышанганнардыр.

Җәмилә. Мин керим әле, туңа башладым...

Айтуганов. Туктагыз инде, тагы бераз торыйк әле... Суның аръягында нинди утлар ул? Балыкчылармы дим.

Җәмилә. Түгел. Тракторчылар сазламыкны сөрәләр.

Айтуганов. Авыл... Менә нинди матур бит ул безнең авыл... Яратам мин аның шушы җәйге тынлыгын... Гүзәл романтикасын... Кара инде, бер генә яфрак та селкенми... Әкрен генә күктә ай калка... Әрәмәсендә төрле кошлар сайрыйлар... Урамында яшьләр күңел ачып җырлыйлар... Ә инде басуларында мотор тавышлары яңгырый...

Кабинеттагылар барысы да бу якка чыгалар. Балконга узалар.

Мортаза (*урамдагы халыкка мөрәҗәгать итеп*). Иптәшләр! Эш планыбызда зур үзгәрешләр булу сәбәпле, бүген мин сезгә наряд бирә алмыйм. Хәзер кайтып йоклагыз. Иртәгә иртән гидростанцияне сала башлауга багышланган митингка килерсез. Кемгә кайда эшләргә икәнен шунда игълан итәрбез!

Пәрдә.

## ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга су буенда болынлыкта бара. Сәхнә аркылы вакытлы буа — перемычка салынган. Пәрдә ачылганда, кызу эш бара. Кайдадыр такта ярган, ат куган, автомашиналар йөргән авазлар ишетелә. Бер читтә зур казан асылган, аның тирәсендә Мәфтуха кайнаша. Култык астына төен кыстырып, Гамилә

үтеп бара.

Мәфтуха. Гамиләттәй, кая болай?

Гамилә. Районга Җәмилә кызым янына барам. Гәрәй кияү Казанга фленум дигәннәренә киткәч, үзләренә фатир биргәннәр. Шуны җыештырырга чакырып җибәргән.

Мәфтуха. Җәмиләнең бәхете бар икән, көтмәгәндә менә нинди иргә чыкты бит.

Гамилә. Тигез мәхәббәт бирсен инде, Мәфтуха, кияүдән бик уңдык. Көзгә Җәмиләне духторлар мәктәбенә укырга җибәрәм, безне үз янына алам, ди.

Мәфтуха. Сөйләмә инде, сөйләмә, сукыр бәхетегез бар икән.
Гамилә. Ярый, мин китим әле.
Мәфтуха. Нигә соң ат сорамадың?
Гамилә. Мондый кызу эш өстендә ничек сорыйсың. Ерак түгел ич. Әкренләп барырмын әле. (*Китә.*)

Тирләрен сөртә-сөртә, Фәрдәнә белән Зиннур керә.

Фәрдәнә. Уф, янам!
Мәфтуха. Кил, гөлкәем, әйрән эч. (*Чүлмәк бирә.*)
Фәрдәнә (*чүлмәктән әйрән эчеп*). Ах, нинди куе, салкын... Рәхмәт, Мәфтуха апа.
Мәфтуха. Мортаза абыеңа диеп китергән идем. Килегез әле, менә монда күләгәгә утырыгыз, йөрәк белән бөер турап бирермен. (*Казаннан ит соса башлый.*)
Зиннур. Мәфтуха апа, мәшәкатьләнмә, халык белән бергәләп ашарбыз.
Мәфтуха. Ярый алайса, бергәләп ашарсыз... Тик үзем яраткан кешеләремне сыйлыйсым килгән иде. Әле бая Гамилә апага да сөйләдем, безнең Зиннур белән Фәрдәнә шулчаклы пар килгәннәр... Ни өчен бергә кушылмыйча гомерләрен заяга уздырдылар икән, дим. Гомер дигәнең ике килми ул, кадерен белеп калыгыз... Үзегез укыганнар, үзегез уңганнар, үзегез тагын...
Фәрдәнә. Син бигрәк инде, Мәфтуха апа, безне зурладың.
Мәфтуха. Дөресе шулай булгач. Сезнең белән тиңләшерлек безнең авылда нинди яшьләр бар? Сез бит...
Зиннур. Мәфтуха апа, казан астың сүнгән түгелме?
Мәфтуха. Сүзгә мавыгып, чыннан да онытып куйганмын икән. (*Китә.*)
Зиннур. Бу Мәфтуха апага ни булган? Безнең турыда күпме гайбәт сатып йөргән кеше бүген үлеп-үлеп мактарга кereште.
Фәрдәнә. Аның сере бар. Әти аны алырга йөри. Монысы: «Фәрдәнәңне олактырмый чыкмыйм»,— дип әйтә икән. Менә шуның өчен ул мине тизрәк әти яныннан куарга тели.
Зиннур. Ә... Менә эш нәрсәдә икән?! Шулай да Мәфтуха апаның сүзләрендә дөреслек юк түгел. Кайчан инде туйны ясыйбыз?
Фәрдәнә. Көзгә.
Зиннур. Ни өчен көзгә?
Фәрдәнә. Туйның вакыты көз көне була.
Зиннур. Иске крестьян йоласын куасың. Оят түгелме сиңа? Әгәр дә аңарчы мин берәрсенә өйләнеп куйсам?
Фәрдәнә. Чынлап сөйсәң, көтәрсең әле. (*Йөгереп китә башлый.*)
Зиннур (*куып җитеп тотып ала*). Көтмәм! Сиңа үч итеп, тотам да өч балалы тол хатынга өйләнәм!.. (*Үбә.*)

Нурулла керә.

Нурулла. Тәбрик итәм, Зиннур иптәш, тәбрик итәм!

Фәрдәнә китә.

Зиннур. Нәрсә белән?
Нурулла. Кичә сине председатель урынбасары итеп сайлаганнар бит.
Зиннур. Ә-ә-ә...
Нурулла. Бик белеп эшләгәннәр, мин аны һәрвакытта әйтеп килә идем. Син бит безнең авылда иң акыллы, иң белемле...
Зиннур. Ярый, Нурулла абзый, салпы якка салам кыстырма. Сыймый ул. Иртәдән бирле кайда йөрдең?
Нурулла. Идел буена чуерташка барган идем.
Зиннур. Нишләп соң бик озак?
Нурулла. Идел ярыннан менгәндә, ике камерабыз да шартлады.
Зиннур. Шулай микән соң? Ә чумарага кайчан бардыгыз?
Нурулла. Нинди чумара?
Зиннур. Районга күчеп килә торган парикмахерның өй җиһазларын илтергә баргансың түгелме?

Нурулла дәшми. Китә. Утын күтәреп, Мәфтуха керә.

Мәфтуха. Нишләп син болай көзге чебеш кебек бөрештең?
Нурулла. Әнә Нәфыйк малае каныма тоз сала.
Мәфтуха. Юкка гына син аны яратмыйсың. Бик әйбәт егет ләбаса.
Нурулла. Әйбәт... Аның теленә эләккәнең юк әле.
Мәфтуха. Минемчә, ул сиңа Фәрдәнә турында сүз ишеттерүеңә бәйләнә. Тот та бир үзенә, өне тыгылсын.
Нурулла. Кызымны түгел, көчегемне дә бирмим мин аңа!..

Мәфтуха. Кара, песи кебек кенә йөрсәң дә гайрәт бар икән үзеңдә.

Нурулла. Минем гайрәтемне күргәнегез юк әле... Заманында карчыга иде Нурулла!.. Хәзер генә аның канатлары йолкынган...

Мәфтуха. Мортаза кайтты. (*Китә.*)

Күңелсез генә Мортаза керә.

Нурулла. Йә, иптәш Мортаза, районда эшләрең ничек булды соң?

Мортаза. Юлым уң булмады, Нурулла абзый.

Нурулла. Нишләп алай?

Мортаза. Айтуганов Казанда обком пленумында. Икенче секретарь язгы чәчү йомгаклары турында докладка әзерләнә. Башкалары инде бар да силос салу, печән чабу эше белән колхозларга киткәннәр. Райисполком председателе Моракаев эшләрен тапшырып ята.

Нурулла. Ничек, чыгаралармыни?

Мортаза. Күптән вакыт иде инде аңа. Учреждениедән учреждениегә кереп, кешеләр, автомашиналар сорап йөрдем. Юньләп сөйләшмиләр дә. Аптырагач, кайтышлый берничә колхозда булып карадым, алар да ярдәм итә алмыйлар.

Нурулла. Вакыты шундый чак шул, печән өлгергән, урып-җыю борын астында, башка эшләрнең дә килеп тыгылган чагы.

Мортаза. Моракаев мине шундый итеп утыртты... Жулик! Гомеремдә беркемнән дә болай алданганым юк иде... Станцияне салып кына өлгертим, бирермен мин аларга ут... Тотарлар кукиш! Нишләргә инде?.. Печән өлгергән. Кайбер колхозлар бүгенле-иртәгәле чыгалар. Ә мин, буаның эшен бетермичә, бер кешене дә моннан ала алмыйм. Силос планы тулмаган. Клуб, мәктәпләр өчен утын әзерләнмәгән. Иртәгәдән юл төзү эшенә ун ат, егерме кеше сорыйлар. Кыш көне кискән диләнке төпләрен өч көнлек срок эчендә әрчетергә кушалар. Гидростанция салу мине, Нурулла абзый, менә нинди хәлгә китереп терәде. Ятьмәгә эләккән балык кебек тыпырчынам, әмма ычкынырга әмәл юк.

Нурулла. Бер әмәл бар барын, тик син аңа ничек карарсың икән. Кичә идарә утырышында сине сүгүләрен тыңлап утырдым-утырдым да өйгә кайтып яткач, бер уйга килдем. Иртә белән аны сиңа тәкъдим итим дип әйтергә дә барган идем, районга чыгып киткәнсең.

Мортаза. Идарәдән соң мин ятмадым. Идел буена печән карарга киттем. Аннан инде районга. Нинди тәкъдим ул?

Нурулла. Беләсең, мин районнарда юл бүлеге мөдире булып эшләгәндә, бик күп күперләр, тегермәннәр салган кеше. Безнең суның тәүлек җыелышы иң явымлы елларда да егерме биш сантиметрдан артканы юк. Димәк, хәзерге көндә безнең вакытлы буаның өелгән балчыгы яңадан бер көрәк салмыйча да дүрт-биш тәүлек буена җыелган суны сыйдыра ала. Арыкны салучы балта осталары берсекөннән дә соңга калдырмыйча тәмам итәбез, диләр. Шулай булгач, нигә безгә яңадан ике-өч көнебезне вакытлы буаны күтәрү эшенә әрәм итәргә?

Мортаза. Чыннан да, Нурулла абзый, синең бу тәкъдимең бик акыллы тәкъдим бит. Ул чагында без, бүгеннән үк, моннан кешеләрне, атларны алып болынга чыгарыр идек. Һәм ике-өч көн эчендә башка бик күп эшләребезне дә төгәлләр идек. Мин бу тәкъдимне бүген үк идарәгә куеп тикшерәм.

Нурулла. Ләкин мин бу турыда прораб Кузнецов белән сөйләшеп караган идем дә, якын да килми.

Мортаза. Ни өчен?

Нурулла. Фән кушуы буенча туры килми, ди. Әнә үзе килә, әйбәтләп кенә сөйләшеп кара әле. Мин машинаны чуерташка җибәрим.

Китә. Кузнецов керә.

Кузнецов. Иптәш председатель, сез бүген бөтенләй югалдыгыз.

Мортаза. Эшче көчләре сорап районга барган идем.

Кузнецов. Соң ничек, бирделәрме?

Мортаза. Берәр атнадан вәгъдә итәләр... Ә миңа бүген кирәк.

Кузнецов. Әйе, быел сезгә авыргарак туры килде шул. Юкка сез дүрт авыл белән бергәләп салу вариантын кабул итмәгәнсез.

Мортаза. Бу турыда сөйләү хәзер соң инде. Иң дөресе, безгә бөтенләйгә тотынмаска кирәк булган. Ярый, буласы эш булган. Бу положениедән чыгу өчен безнең бер тәкъдимебез бар, сез шуңа ничек карарсыз икән?

Кузнецов. Әйтеп карагыз, нинди тәкъдим икән ул?..

Мортаза. Безнең тәҗрибәле картларыбыз, вакытлы буаны...

Кузнецов. Бу миңа таныш тәкъдим. Бая Нурулла Мутыгуллович сөйләгән иде. Ул эш мөмкин түгел. Чөнки проекттагы техник нормаларны бозарга ярамый. Дөрес, ул әйткәнчә, бүгенге көндә безнең ике метрга якын күтәрелгән буабыз бар. Ләкин су табигатьнең иң көчле стихиясе санала. Аңардан саклану чаралары үткәрмичә эш итәргә ярамый.

Мортаза. Димәк, булмый дисез алайса?

Кузнецов. Ул турыда хәтта уйларга да юк.

Алмазия керә.

Алмазия. Иптәш Кузнецов, сезгә телеграмма. (*Кәгазь бирә дә китә.*)

Мортаза. Каян?

Кузнецов. Казаннан, сельэлектродан. Ленинградтан турбиннар кайткан. Тизрәк килеп алырга кушалар. Икенче кат диелгән. Беренчесен минем алганым юк.

Мортаза. Анысы аның минем кесәдә, менә ул. Өченче көн алган идем.

Кузнецов. Ни өчен аны миңа бирмәдегез?

Мортаза. Буаның фундаментын салган көнегез иде. Бүленмәсен, дидем. Соңыннан оныткانмын.

Кузнецов. Монысын молния итеп биргәннәр.

Мортаза. Нигә ул кадәр ашыктыралар икән?

Кузнецов. Чөнки тимер юл вокзалында килгән товарларны вакытында алмасаң, һәрбер тәүлек өчен акча түләтәләр. Миңа ат әзерләгез.

Мортаза. Безнең машина Идел буена чуерташка китәргә тиеш, шуңа утырыгыз да китегез. Бәлки, кичке пароходка да өлгерерсез.

Кузнецов. Ярый алайса, мин кайтып әйберләремне алгалыйм.

Мортаза. Барыгыз, бар, тик, зинһар өчен, озак йөри күрмәгез.

Кузнецов. Юк, юк. Ике-өч көннән кайтып җитәрмен.

Мортаза. Алай-болай ярдәм кирәк булса, Айтуганов белән Халидәгә мөрәҗәгать итәрсез. Алар анда Казанда обком пленумында.

Кузнецов. Яхшы. Хушыгыз. (*Китә дә туктап кала.*) Теге мәсьәлә турында тагы бер кат әйтәм, куелган тәртипне үзгәртә күрмәгез.

Мортаза. Юк, юк. Бала түгел лә мин.

Кузнецов китә. Мортаза озатып кала. Нурулла керә.

Нурулла. Йә, ничек, сөйләштеңме?

Мортаза. Сөйләштем. Ярамый, ди.

Нурулла. Укыган кешеләрнең шул инде аларның. Үлсәң дә хәлеңә кермәсләр. Машинага утырып кая бара соң әле?

Мортаза. Казанга.

Нурулла. Казанга? Хатынын сагынганмыни?

Мортаза. Ленинградтан турбиннар кайткан, шуларны алырга китә.

Нурулла. Алай булганда бик әйбәт, булды гына. Буаны үз дигәнебезчә эшлибез.

Мортаза. Юк, Нурулла абзый, аның белән шаярырга ярамый.

Нурулла. Бернинди дә шаяру түгел. Мин Ык кебек елгаларда бишәр ташлы тегермәннәр җиткергән кеше.

Мәфтуха керә.

Мәфтуха. Мортаза, ашым өлгерде, вакыт күпме соң әле?

Мортаза (*сәгатенә карап*). Ашатырга, апа, бик вакыт.

Мәфтуха. Алай булса, чаң сугам.

Мортаза. Бар, бар, сук. (*Мәфтуха китә.*) Әйдә әле, Нурулла абзый, чыннан да синең ул теге тәкъдимең буенча картлар, идарә членнары белән киңәшеп карыйк.

Китәләр. Артта чаң тавышы ишетелә. Кызлар, егетләр йөгерешеп керәләр.

Кыз. Кызлар, әйдәгез, башта су кереп алабыз!

Әптәлим. Чыннан да, әйдәгез, кызлар!

Кыз. Тыкшынып йөрмә әле, кит безнең тирәдән!

Әптәлим. Яхшылыкта, кызлар, безне дә үзегез белән алыгыз, юкса суга төшкәч кенә киемнәрегезне җыеп алып китәрбез дә яр буенда, су аналары шикелле, тик бөрешеп утырырсыз. Егетләр, ә?

Кызлар, егетләр тарала башлыйлар. Алмазия керә.

Алмазия. Кызлар, егетләр, стена газетасы чыгардык. Укып китегез.

Әптәлим. Кая әле, кая, кемнәрне мактадыгыз икән? (*Кычкырып укый.*)

Минвалеев Әптәлим
Активлашты һәр эштә.

Күрдегезме, кызлар, абзагыз турында ничек язалар?!

Алмазия. Калганын укы, калганын, аннан мактанырсың.

Әптәлим (*карап*). Калганы кызык түгел икән. Әйдәгез, егетләр, тегермән артына коенырга төшәбез.
Алмазия. Тыңлагыз, үзем укыйм!

Минвалеев Әптәлим
Активлашты һәр эштә.
Тик хәзергә артта әле
Социалистик ярышта.

Яшьләр көлешә-көлешә китәләр. Мортаза, Зиннур, Шакирҗан, Фәрдәнә һәм башкалар керәләр.

Зиннур. Фәнни нигездә төзелгән проектны үзгәртергә беркемнең дә хакы юк.

Мортаза. Без дә фәнгә каршы килмибез һәм проектны үзгәртергә дә теләмибез. Без, бары тик практик яктан гына уңайлырак итеп эшләргә уйлыйбыз. Нурулла абзый, иптәшләргә сөйләп бир.

Нурулла. Әгәр дә без минем тәкъдим буенча эш итсәк, өч йөз хезмәт көненә, ике тәүлек вакытка, илле ат көченә экономия ясыйбыз.

Мортаза. Ә ул ике тәүлектә без ярты печән эшебезне тәмам итә алабыз. Өч йөз хезмәт көненә экономия ясау да уен эш түгел, иптәшләр.

Фәрдәнә. Безнең станция проектын төзүче инженер Малахов нәрсәгә булса да таянып эшләгәндер бит. Шуның өчен мин Зиннур иптәшнең фикеренә кушылам.

Мортаза. Малахов кебек яшь бер инженер төзегән проектны гына түгел, безнең новаторларыбыз академиклар төзегән нормаларны да җимерәләр, Шакирҗан абзый, ә?

Шакирҗан. Мин ни әйтергә дә аптырыйм. Нурулла сүзендә дә дөреслек бар. Үз гомерендә күп тегермәннәр салып, күзе чыккан кеше. Печәнгә чыгу да хәзер бик кирәк. Шулай да бу мәсьәләдә райком секретаре белән Халидә кайтуын көтәргә иде. Бер көн иртә, бер көн соң дигәндәй.

Мортаза. Юк, Шакирҗан абзый, үзең беләсең, печән эшендә бер көн түгел, аерым сәгатьләр дә бик зур роль уйный. Шулай итеп, мин хәзердән буа эшен туктатам! Аштан соң бөтен кешеләрне болынга — печән эшенә чыгарам. Андагы кешеләр белән җитәкчелек итүне, Зиннур энем, сиңа тапшырам.

Мәфтуха керә.

Мәфтуха. Мортаза, ашым салган, кайнар көйгә ашагыз инде!
Зиннур. Ләкин бит, Мортаза абый...
Мортаза. Әйдәгез, иптәшләр, сүз сөйләп торырга безнең вакытыбыз юк. Ашагыз да эшегездә булыгыз!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук су буенда — буа янында бара. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә Мәфтуха, көйләп, бияләй бәйләп утыра. Нурулла керә.

Нурулла. Мәфтуха, Мортаза кая?
Мәфтуха. Мытыеста.
Нурулла. Алай... Миңа ул бик кирәк иде.
Мәфтуха. Кирәк булса, көтәсең инде, төшкә кайтып җитәм, дигән иде.
Нурулла. Арыкны эшләүчеләр кайда?
Мәфтуха. Ашарга кайтып киттеләр.
Нурулла. Ә син нигә кайтмадың?
Мәфтуха. Мине суның артуын үлчәп торырга, эш коралларын сакларга калдырдылар.
Нурулла. Аулак икән алайса.
Мәфтуха. Өйдәме?
Нурулла. Юк, монда, синең яныңда, дим. (*Янына ук килеп утыра*.)
Мәфтуха. Ярар, ярар, елышмый гына тор әле. «Кыр — күз, урман — колак» дигәндәй.

Нурулла. Мортаза әмма үзеңне биетә, мин әйтәм. Әле клуб карата, әле балалар артыннан йөгертә, инде хәзер охранник итеп калдырган.

Мәфтуха. Бер дә ул калдырмады. Шакирҗан абзый «суны үлчәп торырга кеше юк» дигәч, үзем сорап алдым.

Нурулла. Юк инде, Мәфтуха, түремдә бикә булып кына утырасы урында, эштән эшкә йөрисең.

Мәфтуха. Синең ул балаларың утыртырлар түреңдә. Кичә малаеңа, Илдарханга, атың бик тирләгән, дигән идем, әйтмәгән сүзе калмады.

Нурулла. Өйдә ана булмауның нәтиҗәсе ул, Мәфтуха, менә шуларны тәрбия итәргә чакырам да бит, килмисең.

Мәфтуха. Ай-яй, ничек кыздыра...

Нурулла. Яңгыр гына булмаса ярар иде... Әйе, кызуларга китте шул.
Мәфтуха. Әйдә, Алла бирсен.
Нурулла. Бик кирәге бар!
Мәфтуха. Менә инде җүләр, яңгыр теләүгә шулай диләрме? Бәрәңгеләр сусаган, сабаннарга да кирәк бит әле.
Нурулла. Була гына күрмәсен. Безгә хәзер бер тамчысы да кирәкми. Беләсең, бөтен халык болында, печән эшендә...

Артта мотоцикл тавышы.

Мәфтуха. Әнә Мортаза кайтты.

Мортаза керә.

Мортаза. Йә, Нурулла абзый, болында ниләр бар?
Нурулла. Болында эшләр бик әйбәт, иптәш Мортаза. Ургычлар гөрләтеп эшлиләр. Унбер егет, җиде кыз чалгыда, кыр казлары кебек, пакус салып баралар. Узган-барган кешеләр болын башына туктыйлар да безнең яшьләрнең эшенә сокланып карап торалар. «Беренче май» председателе белән бергә кайттык. Ул да кешеләрен илтергә барган. «Хәйләкәр сезнең Мортаза, кичә миңа «бер-ике көн сабыр итәм әле» дигән иде, бүген килсәм, сезнекеләр чәүкәләр шикелле болынны сырып алганнар» ди.
Мортаза. Аның кебекләрне шулай итәләр аны, ул җыенганчы, безнекеләр бетереп тә куярлар әле, Нурулла абзый, ә?
Нурулла. Әлбәттә, иптәш Мортаза. Тик менә, кичке ашка итләре аз икән, хәзер үк бер хайванны суеп илтәсе иде. Зиннур әйтә: «Теге сөт бирми торган зур сыерны суегыз»,— ди.
Мортаза. Юк, ул ябык булыр. Иң симез кысыр сарыкларны сайлап суярсың. Бодай икмәге пешерт. Сөткатыкны, май-каймакны җәлләмә, ирләргә кич, яткanda, сөяк-санакларны йомшартырга йөзәр грамм рус ачысын да алып бар.
Нурулла. Син бигрәк тә юмартланып киттең, иптәш Мортаза.
Мортаза. Андый эшкә минем кайчан саранлашканым бар?
Нурулла. Шулай да бүген синең кәеф шәп!
Мортаза. Прорывтан чыктык бит, Нурулла абзый, буаның эше бетеп килә. Станция өчен машиналар, җиһазлар кайта. Әле хәзер МТС директоры белән сөйләшеп кайттым. Силос турарга тагын бер трактор, ике автомашина җибәрергә булды. Аннан менә өлкә газетасында безне күккә чөйгәннәр.
Нурулла. Станция турындамы?
Мортаза. Сазламык киптереп, җитен чәчүебезне пленумда обком секретаре мактап сөйләгән. Шулай булгач, нигә минем кәефем яхшы булмасын?!
Нурулла. Ул чагында эшләр башка, әлбәттә. Иптәш Мортаза, завод-фабрикаларда, гыйльми мәхкәмәләрдә яхшы тәкъдим керткән кешеләрне мактыйлар, бүләклиләр, газеталарга язалар. Миңа да бу тәкъдим өчен ни дә булса берәр нәрсә кирәктер инде, әлбәттә.
Мортаза. Әйе, әйе, Нурулла абзый, синең бу тәкъдимең өчен чыннан да берәр нәрсә эшләргә кирәк булыр. Станцияне срогыннан элек салып өлгертсәм, бәлки, миңа да (*күкрәгеннән орденга урын күрсәтеп*) тагын берне тагып куярлар, дим, Нурулла абзый, ә?
Нурулла. Бик мөмкин, иптәш Мортаза. Ярый, мин печәнчеләргә ит әзерлим әле.
Мортаза. Бар, бар, иң симез сарыкларны сайлап суй!

Машина тавышы.

Нурулла. Бу нинди машина?
Мортаза. Айтуганов белән Халидә Казаннан кайттылар.
Нурулла. Нишләп бик тиз? Гадәттә пленумда берәр атна булалар иде.

Чыгып китәләр. Бераздан Халидә белән Мортаза керә.

Мортаза. Айтуганов безгә туктап та тормады, яшь бикәчен сагынды микәнни?
Халидә. Эшләре күп аның. Беләсең, печән өсте, тиздән уракка. Аннан пленумда терлек азыгы мәсьәләсен кискен итеп куйдылар. Йә, синең монда эшләр ничек соң?
Мортаза. Эшләр әйбәт, иртәгә арыкны бетерәләр. Кичә Кузнецовны Казанга турбиннар алырга җибәрдек.
Халидә. Әйе, без аны күрдек.
Мортаза. Казандамы?
Халидә. Юк, Кама Тамагы пристаненда очраттык. Без килеп туктауга, алар кузгалып киттеләр. Тукта әле, синең монда эшчеләрең бик аз күренә.
Мортаза. Кичә балта осталарыннан башка бөтен халыкны мин моннан алып печәнгә чыгардым, силоска, утауга куштым.

Халидә. Шулаймыни? Ә соң ярдәмче буа эше нишли?

Мортаза. Күрәсең, метр ярым өйгән вакытлы буабыз бар. Төп арыкның эшен иртәгә бетерәләр. Шулай булгач, нигә монда эшче, ат көчләрен бушка тотарга? Хәзер бит һәрбер көне кадерле чак.

Халидә. Анысы шулай, көннәр артык кызуга китү аркасында, бөтен кыр эшләре бергә тыгылыр, ахры.

Мортаза. Йә, Казанда ниләр бар?

Халидә. Казан кайный... Әле анда, әле монда яңа йортлар салалар. Урамнарында газ трубалары үткәрәләр. Яңа порт өчен җир казу эшләре алып баралар. Кайтасы көнне үзәк магазиннарга кереп йөрдем дә, Казан бүләге итеп сиңа нәрсәдер аласым килде. Ләкин ни алырга белмим. Аптырагач (*портфеленнән украинча чиккән ирләр күлмәге чыгара*), менә шушы күлмәкне алдым. Әйбәтме?

Мортаза. Әйе, чигеше бик матур... Ләкин сиңа нигә ул? Ирең юк.

Халидә. Булыр әле, гомергә тол дүдәк булып йөрмәм бит...

Мортаза. Шулай да беләсе иде, кем өчен алдың икән син аны?

Халидә. Синең өчен, Мортаза... Председатель башың белән кара мүкәй булып йөрисең. Кара инде, якаларың каткан, кырынмаган... Үзеңне бераз гына тәртипкә кертергә иде.

Мортаза. Их, Халидә... Миндә аның кайгысы юк әле. Тизрәк печәнне җыеп аласы иде. Силос салынып бетмәгән. Урак җитә. Аннан көзгә гидростанцияне өлгертергә дип тырышам. Дөресен әйткәндә, Халидә, син киткәннән бирле, минем юньле тормыш күргәнем юк.

Халидә. Нигә, әллә Мәфтуха апа белән сүзгә килештегезме?

Мортаза. Әй, куй инде... Мин чыгып киттемме, Нуруллосы кереп утыра. Ни өйләнешмиләр, ни бер-берсеннән бизешмиләр. Карт мәхәббәт язгы бизгәк кебек була, диләр. Дөрес икән. Кайт, Халидә, өрмәгән җиргә дә утыртмам. Мин бит хәзер элекке Мортаза түгел.

Халидә. Синең миңа биргән сүзең бар, шуны үтәмичә, мин кайтмыйм.

Мортаза. Ярый алайса, кеше аяк эзе басылгач, үзем барырмын. Син чоланда ятасың бугай. Иплә кенә килермен дә чолан тәрәзәңне чиертермен.

Халидә. Йөри күрмә, безнең Шакирҗан абзыйларның эте бик усал, кичтән үк чылбырыннан ычкындырып куярмын.

Мортаза. Күлмәк өчен күпме акча бирергә?

Халидә. Бер тиен дә кирәкми, минем бүләгем итеп киярсең.

Ашыгып Гозәир керә.

Гозәир. Исәнмесез, оланнар!

Халидә. Әйдә, Гозәир абзый, бакчаң нишли, үсәме?

Гозәир. Үсә, кызым, ул турыда сөйләрмен әле. Тик мин сезгә бик күңелсез хәбәр китердем.

Мортаза. Нинди хәбәр ул, Гозәир абзый?

Гозәир. Барометр җил-давыллы яңгыр күрсәтә.

Халидә. Җил-давыллы яңгыр күрсәтә?..

Гозәир. Әйе, кызым. Иртә белән карап бакчага киттем, берни юк иде, төшкә кайтып карасам, күзем шар булды.

Мортаза. Көн бик аяз, Гозәир абзый, бәлки, булмас әле.

Гозәир. Юк, энем, явар. Ике-өч көннән бирле юкка кыздырмады ул. Күрәсеңме, карлыгачлар да юкка уйнамый. Димәк, тиздән яварга тиеш. Әнә күктә болытлар да куера башлады.

Халидә. Йә, Мортаза, нишлибез?

Мортаза. Хәзер халыкны җыям!

Чыгып китә. Артта тревога, чаң тавышы ишетелә.

Гозәир. Хәтәр генә булмаса ярар иде. Бәхетсезлеккә каршы, бүген авылда балта осталары белән карт-корылардан башка беркем дә юк. Башбаштаклык менә шулай була ул.

Халидә. Нинди башбаштаклык ул, Гозәир абзый?

Гозәир. Соң бит алар Кузнецовның планын үзгәрттеләр.

Халидә. Ничек үзгәрттеләр?

Гозәир. Шулай: ул аларга буадан бер кешене дә алырга ярамый дигән, ә болар тыңламаганнар, үз белдекләре белән эшләгәннәр.

Халидә. Тукта әле, Гозәир абзый, без Кузнецов белән юлда очраштык. Берни дә әйтмәде, бар да искечә, әйбәт бара, диде.

Гозәир. Шулай дигәндер. Чөнки алар аны ул авылдан чыгып китү белән үзгәрттеләр.

Мортаза керә. Сәхнә караңгылана башлый.

Халидә. Мортаза, нигә син Кузнецовның планын үзгәрттең?

Мортаза. Паникага бирелерлек берни дә юк.

Сәхнәгә төрле яклап халык кереп тула.

Мортаза. Иптәшләр! Җил-давыллы яңгыр килә. Димәк, айлар буе куйган көчебезнең юкка чыгу куркынычы бар. Безгә хәзер бер генә юл: ничек кенә булса да вакытлы буабызны күтәрергә, отводный каналның тамагын киңәйтергә, казылып бетмәгән кавыз юлын ачарга. Шакирҗан абзый! Син вакытлы буаны күтәрү эше белән җитәкчелек итәрсең! Хәзер үк бөтен балта осталарын, такта яручыларны шунда алып кит.

Шакирҗан белән балта осталары китәләр.

Гозәир абзый! Син отводный каналның тамагын киңәйтүчеләрне карап эшләтерсең.

Гозәир китә.

Апа, син хәзер утаучыларга йөгер, бөтен хатын-кызларны бирегә җыеп кайтырсың.

Мәфтуха китә.

Нурулла абзый! Син печәнчеләрне алып кил!

Нурулла китә.

Халидә акыллым! Син, авылга кайтып, пожар сараендагы, фермадагы кешеләрне һәм авылдагы бөтен карт-корыларны, бала-чагаларны оештырып монда төшәрсең. Мин үзем ерак басуга тракторчыларны алырга барам!

Чыгып китәләр. Сәхнә буш кала. Артта мотоцикл тавышы. Еракта беренче күк
күкрәү авазы ишетелә.
Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук, вакытлы буа янында бара. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә дөм караңгы. Җил-давыл белән көчле яңгыр ява. Шакирҗан карт кул астында эшләүчеләр тачкаларда балчык ташыйлар. Мәфтуха белән Нурулла пычкы чүбе
тутырылган капчыкларны буа өстенә өяләр.

Нурулла. Беттем, Мәфтуха, беттем! Мортазаны да, үземне дә бетердем.
Мәфтуха. Күп сөйләнмә, ташы инде тизрәк!
Нурулла. Мондый тәкъдимне башыма китергән зиһенемә нәләт төшсен бүгеннән!

Мортаза йөгереп керә, вакытлы буа өстенә менеп баса.

Мортаза. Капчыкларны, капчыкларны монда өегез, иптәшләр! (*Икенче якка мөрәҗәгать итеп.*) Абзыйлар, түтәйләр! Кавызны тизрәк казыгыз, кавызны! Отводный каналның тамагын киңрәк ачыгыз!

Яңгыр көчәйгәннән-көчәя бара. Бертуктаусыз яшьнәп торган яшен уты яктысында йөгерә-йөгерә эшләп йөргән кешеләрнең күләгәләре күренә. Артта шау-шу
күтәрелә. Шакирҗан йөгереп керә.

Шакирҗан. Мортаза, Мортаза, дим!
Мортаза. Нәрсә бар тагын?
Шакирҗан. Буаның бер җиреннән ера башлады!
Мортаза. Кай төштән?
Шакирҗан. Әнә уң як култыктан, багана төбеннән!
Мәфтуха. Умыра, умыра, астан умыра!
Шакирҗан. Китегез буадан, әнә ул селкенә!
Мәфтуха. Чык, Мортаза, чык, бетәсең!

Чытырдап сынган агачлар, улап аккан су тавышы ишетелә. Буа белән Мортаза үзе дә аска төшеп китә.

Бетте, Мортаза бетте!
Шакирҗан. Җәмәгать, бирегә, зинһар, тизрәк бирегә!
Мәфтуха. Нигә катып торасыз, нигә берәр чара күрмисез!
Нурулла. Әнә ул калыкты, өскә чыкты!
Шакирҗан. Ярга таба, Мортаза, ярга таба!
Нурулла. Кая, миңа бау бирегез, бау, кереп коткарыйм!

Өстендәге киемнәрен салып ташлый да ярдан сикерә. Гозәирдән башкалар су агымына таба чыгып китәләр. Яңгыр әкренләп туктый. Гозәир карт, яр
башыннан озак кына карап торганнан соң, алгы планга килеп уйлана.

Гозәир. Җилкәне юк тал каек,
Җилгә каршы бaралмас.
Калканы юк ир-егет
Яуга каршы торалмас
дигән бабайлар, бик дөрес!

Әкрен генә Шакирҗан керә.

Гозәир. Таптылармы, Шакирҗан?

Шакирҗан. Таптылар. Ләкин үлгән...

Гозәир. Үлгән?.. Шундый тиз арадамы? Ирекле хәрәкәт ясасыннар иде.

Шакирҗан. Ясаталар. Ләкин файдасы булмас, башы яньчелгән, бик каты бәрелгән. Карарлык түгел... Халидәсе кайда соң әле?

Гозәир. Кәнсәгә киткән иде, райкомнан шалтыратканнар.

Шакирҗан. Көтмәгәндә менә нинди хәлләр булып куйды бит, Гозәир абзый, ә?

Гозәир. Мин-минлек корбаны. Башка түгел, энем Шакирҗан.

Кояш чыга. Күктә салават күпере күтәрелә. Носилкага салынган Мортаза гәүдәсен күтәреп, сәхнә аша үтеп китәләр. Тыны кысылып, йөгереп,

Халидә килеп керә.

Халидә. Мортаза!.. Нишләдең син, Мортаза?!

Пәрдә.

## БИШЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнәнең беренче планында ишеге белән тамашачыларга каратып салган гидростанция тора. Артта су белән тулы киң буа. Аның арьягында терлекчелек фермасының абзарлары. Силос башнялары, алар өстеннән күрше авылларның панорамасы күренә. Вакыт кичкә таба. Пәрдә ачылганда, Әптәлим станция

түбәсендә җырлап нидер урнаштыра. Җирдә Алмазия аңа булыша.

Әптәлим. Судан алып электрның
Сүнмәс гүзәл яктысын
Һәр урынга, һәрбер өйгә
Кертик Ильич лампасын.

Алмазия. Электрның нурларын
Кабызабыз һәр өйдә.
Шәмдәл, сукыр лампаларны
Бирик инде музейга.

Әптәлим. Их, Алмазия, кеше бәйрәм итә, ә без синең белән эшләп йөрибез.

Алмазия. Тормыш шулай инде ул, Әптәлим, алар эшләгәндә, без укып яттык.

Артта гармун тавышы.

Әптәлим. Әнә күрше авыллардан вәкилләр дә килә башлады. Ай, шул гармунның тавышы өзә бит үзәкне... Шуны ишетсәм, чабарга әзерләнгән ат шикелле, йөрәк ярсырга керешә. Бигрәк тә әнә аның кебек белер-белмәс кеше уйнаса, кулыннан тартып алып, сызып җибәрәсем килә... Кара инде, кара, нигә урынсызга бакасын баса ул?

Алмазия. Ярый инде, дулама, бар кеше дә синең кебек оста түгел бит, өйрәнчек егеттәр.

Әптәлим. Бер ай тула инде, кулга гармун тоткан юк. Карлыгач шикелле, баганадан баганага кунып тик йөрим.

Станциядән Гозәир карт чыга.

Гозәир. Энем Гаптәлим, бик югары менгәнсең, кара аны, аякларың таймасын.

Әптәлим. Кайгырма, Гозәир бабай, минем аякларда хәзер корыч тырнаклар.

Гозәир. Нишлисең анда?

Әптәлим. Күк йөзенә тагын бер йолдыз өстим.

Гозәир. Нинди йолдыз?

Әптәлим. Безнең «Алсу таң» колхозында, коммунизм тормышы башлануын күрсәтеп, менә бу йолдыз караңгы төннәрдә янып торачак.

Станциядән Кузнецов чыга. Түбәдән Әптәлим төшә.

Кузнецов. Нихәл, Минвалеев, эшләр барамы?

Әптәлим. Мондагысын бетердек, иптәш начальник.

Кузнецов. Рәхмәт сезгә. Хәзер Гозәир бабайның хата-лабораториясенә барып, патроннар куярсыз, аннан радиоузелдагы эшегезне бетерерсез.

Алмазия. Аннан, иптәш начальник?

Кузнецов. Аннан инде бәйрәм итәрсез.

Әптәлим. Рәхмәт, иптәш Кузнецов. Әйдә, Гозәир бабай, киттек!

Китәләр. Халидә керә.

Халидә. Петр Данилыч, иптәш Айтуганов килде, ферманы карап йөри.

Кузнецов. Бик әйбәт, рәхим итсеннәр.

Халидә. Сезнең монда эшләр ничек соң, әзерме?

Кузнецов. Бөтен машиналарны куеп бетердек, хәзер проба ясап карыйбыз. (*Станциягә кереп китә.*)

Сабан туе бүләкләре бәйләгән колга күтәреп, Шакирҗан керә.

Халидә. Һу!.. Шакирҗан абзый, әллә инде авылдагы бөтен сөлге, тастымалны җыеп бетердең?

Шакирҗан. Байлык — көрлек галәмәте дигән сүз, Халидә, менә бер елда күпме кеше өйләнгән.

Халидә. Нурулла абзыйдан да алдыңмы?

Шакирҗан. Фәрдәнә өченме?

Халидә. Юк, ул бит үзе өйләнде.

Шакирҗан. Кемгә?

Халидә. Безнең Мәфтуха апага.

Шакирҗан. Кайчан?

Халидә. Кичә кич кияү керттем үзләрен.

Шакирҗан. Ах, карт төлке! Бүген үзен өч-дүрт тапкыр очраттым, берни дә әйтмәде. Әйтәм аны сакал-мыекларын кырдырган.

Халидә. Әнә үзе килә. (*Станциягә кереп китә.*)

Аркасына мылтык асып, Нурулла керә.

Нурулла. Шакирҗан кордаш, Халидә мондамы?

Шакирҗан. Биредә. Тукта әле, син ни диеп сакал-мыекларыңны кырдырдың?

Нурулла. Менә инде, иртәгә безнең Татарстанның утыз биш еллык бәйрәм көне бит. Әллә белмисеңме?

Шакирҗан. Шул гынамы?

Нурулла. Аннан иртәгә сабан туе.

Шакирҗан. Аннан?

Нурулла. Аннан гидростанция ачабыз.

Шакирҗан. Аннан?

Нурулла. Аннан бетте инде.

Шакирҗан. Юк әле, бетмәде. Сакал-мыекларыңны нигә кырдырдың?

Нурулла. Аһ Алла, әйттем бит инде, бу көннәрдә бездә өч төрле бәйрәм, дидем.

Шакирҗан. Дүртенчесе?

Нурулла. Дүртенчесен мин белмим.

Шакирҗан. Өйләнгәнсең бит, мут кеше! Шуның өчен синнән чүпләм башлы зур сөлге!

Нурулла. Өйләнүен дисбительно өйләндем. Ләкин бит әле без никах та укытмаган, загста да булмаган.

Шакирҗан. Ә шулай да кияү кереп өлгергән. Кая, чыгар сөлгеңне!

Нурулла (*башын кашып*). Бирми булмас, ахры. Ярый, сабан туе бүген түгел бит әле, иртәгә. Берараны кереп алырсыз.

Шакирҗан. Юк инде, яңадан сезнең очка кадәр барып мин йөрмәм, үзең китереп бир!

Фермага таба китә. Нурулла станциягә кереп югала. Айтуганов белән Зиннур керә.

Айтуганов (*станцияне карап*). Әйбәт, әйбәт, иптәш председатель. Димәк, районыбыз хәзер яртылаш электрлашты дигән сүз. Бу бик зур уңыш.

Зиннур. Үзебез генә булсак, өлгерә алмый идек, безне шефка алган завод коллективына, МТС эшчеләренә рәхмәт инде, алар безгә булышты.

Фәрдәнә керә.

Фәрдәнә. Иптәш Айтуганов килгән икән, исәнмесез!

Айтуганов. Килүен килдем, ләкин «үзе кунак чакырган, үзе баланга киткән» дигән шикелле булды бит, Фәрдәнә. Безнең фермадагы водопроводларны, механизацияләрне килеп карарга райком җитәкчеләренең вакытлары юк, дип, райком пленумында тәнкыйть иттең, килсәм, үзең юк.

Фәрдәнә. Гаеп итмәгез инде, иптәш Айтуганов, Зиннур әйткәндер, мин бүген Идел буенда терлекләр лагеренда идем, әйдәгез, ферманы күрсәтим.
Зиннур. Без инде карап өлгердек.
Айтуганов. Бик әйбәт булган, рәхмәт сезгә.

Станциядән Халидә чыга.

Халидә. Иптәш Айтуганов, әйдәгез, проба өчен хәзер турбиннарны җибәреп карыйлар.
Айтуганов. Яхшы. Тик минем сезгә бер сүзем бар иде. (*Читкә алып китә. Зиннур белән Фәрдәнә станциягә кереп югалалар.*) Менә нәрсә, иптәш Шәфигуллина, мин сезнең кандидатурагызны райисполком председательлегенә тәкъдим итеп Казанга җибәргән идем. Бүген җавап алдым. Сезне раслаганнар.
Халидә. Бик җаваплы урын бит, иптәш Айтуганов, эшли алырмын микән? Минем бер дә андый эштә тәҗрибәм юк.
Айтуганов. Тәҗрибә мәсьәләсенә килгәндә, берәү дә анадан тәҗрибә белән тумый бит. Эш ул кешеләрне үзе өйрәтә. Менә мин дә укыганда фән эшчесе булып лабораторияләрдә, тәҗрибә кырларында сортлы бодайлар үстерермен дигән идем. Ләкин обком авылларга җибәрде. Киңәш итеп мин сезгә шуны әйтер идем: кайда гына булганда да, нинди генә мәсьәләне хәл кылганда да, беренче чиратта, халык интересын, дәүләт интересын күз алдында тотыгыз. Эшегез һәрвакытта уңышлы булып чыгар.
Халидә. Киңәшегез өчен рәхмәт, иптәш Айтуганов. Ә инде бу ышанычыгызны мин намуслы эшем белән акларга тырышырмын.
Айтуганов. Әйдәгез, керик.

Станциягә кереп китәләр. Бераздан, кулын селтәп, Нурулла чыга. Киткән ягыннан Шакирҗан керә.

Шакирҗан. Йә, Нурулла, сөлге булдымы?
Нурулла. Әй, куй әле сөлгеңне!.. Әнә станция эшләми.
Шакирҗан. Нишләп?
Нурулла. Кем белә инде аны. Болай машиналары әйләнә. Тик уты гына юк.
Шакирҗан. Гаҗәп, эш нәрсәдә икән соң?
Нурулла. Нәрсәдә дип, машина белән сәгатьнең, хатын-кыз белән чыгымчы атның җаен табу кыен ул.
Шакирҗан. Синең сүзеңә ышанмыйм, кереп карыйм әле.

Шакирҗан станциягә кереп китә. Аның артыннан Нурулла кереп барганда, Мәфтуха килеп чыга. Нурулланы туктата.

Мәфтуха. Тукта әле, сиңа әйтәм!
Нурулла. Син нишләп монда йөрисең?
Мәфтуха. Станция җибәргәнне карарга килдем.
Нурулла. Бик иртәләгәнсең.
Мәфтуха. Балалар ашап-эчтеләр дә киенеп-ясанып урамга чыгып киттеләр. Иртә белән генә мунча ягып, коймак измәкче идем, син моннан ничәләрдә кайтырсың икән?
Нурулла. Кояш чыккач, алмашым килгәч.
Мәфтуха. Нигә инде алай бик соң?
Нурулла. Охранникларның тормышы шул инде, кеше эшләгәндә алар йоклыйлар, кеше йоклаганда...
Мәфтуха. Тоже йоклыйлар, диң.
Нурулла. Юк, миңа йокларга ярамый.
Мәфтуха. Карап торам-торам да мин, сиңа әйтәм, юкка гына син моңа кадәр майга, тузанга манчылып завхоз булып йөргәнсең. Охранник булу сиңа зрә дә килешә икән. Шушы мылтыгыңны аркаңа асып җибәргәч, Сәетбаттал Газига охшап куясың.
Нурулла. Зиннур кияүгә рәхмәт инде, ул мине бу дәрәҗәгә күтәрде.

Станциягә кереп китәләр. Сәхнә караңгылана. Әптәлим, Алмазия һәм
егетләр, кызлар, башка авыллардан килгән вәкилләр керәләр.

Әптәлим. Ягез әле, егетләр! Кызлар ди-ди кибә соң безнең җелекләр! (*Гармун уйнап җибәрә.*)

Яшьләр җырлап бииләр.

Кызлар. Борма тауның егетләре
Таштан юллар салалар.
Намуслы эш һәм хезмәттә
Орден, медаль алалар.
Егетләр. Борма тау авыл кызлары

Шомырт кара күзләре.
Балдан татлырак сүзләре,
Ай, кояштай йөзләре.

Кызлар. Борма тауның егетләре
Бар да кара кашлылар.
Буйга матур, эштә батыр,
Фәндә зирәк башлылар.

Егетләр. Борма тау авыл кызлары
Депутатка ярарлык.
Буй-сыннары һәйкәл кебек,
Сокланышып карарлык.

Станциядән Нурулла чыга.

Нурулла. Булды, егетләр, булды!

Әптәлим. Нәрсә булды?

Нурулла. Ут булды!

Әптәлим. Менә инде, иске авыздан яңа сүз дигәндәй, кем сиңа «булмый» дигәне бар?!

Нурулла. Юк иде шул, кайчаннан бирле җибәрә алмыйлар иде, Гәрәй иптәш возбудитель дигән нәмәкәйне боргалауга, ялт итеп кабынды!

Станциядән Айтуганов, Халидә, Зиннур, Шакирҗан, Фәрдәнә, Кузнецов, Мәфтухалар чыгалар. Төрле яклап картлар, карчыклар кереп тулалар.

Зиннур. Иптәшләр! Гидростанциябезне җибәрүгә багышланган митингны ачарга рөхсәт итегез. Сүз Халидә иптәш Шәфигуллинага бирелә.

Халидә. Иптәшләр! Кырык бишенче елның язында, безнең гаскәрләр Гитлер Германиясенең оясын утка тоткан көннәрдә, Халык Комиссарлары Советы авылларны электрлаштыру турында карар кабул иткән иде. Шушы ун ел вакыт эчендә безнең колхозларыбыз егерме меңләп гидростанция салдылар. Аларның көчен бергә җыйганда, ике миллион киловаттан артыграк. Икенче төрле итеп әйткәндә, дөнья йөзендә иң зур гидростанцияләрнең берсе саналган Днепрогэстан да өч мәртәбә көчлерәк. Димәк, Владимир Ильичның: «Коммунизм ул — совет власте плюс бөтен илне электрлаштыру»,— дигән хикмәтле сүзләре хәзер тормышка ашырылды! (*Кулы белән артка ишарә ясый.*)

Кузнецов (*станция ишеген ачып эчкә кычкыра*). Беренче рубильник!

Бөтен җирдә бердән ут кабынып китә. Җыелган халык «ура» кычкырып кул чаба.

Халидә. Искелекнең куркыныч символы булган караңгылык безнең илдә тиздән бетәчәк! Барлык авылларны да Ильич лампаларының ямьле нурлары яктыртачак!! (*Кулы белән тагын ишарә ясый.*)

Кузнецов. Рубильникларны!!

Горизонттагы авылларда да бер-бер артлы утлар кабына. Халык, тагын да шатланып, көчлерәк кул чаба. Әптәлим, алга чыгып, аерата дәрт белән марш уйнап җибәрә.

Пәрдә.

*1954*

## АВТОРДАН

**«Ялкын» («Фәрхиназ»)**

«Ялкын» («Фәрхиназ») драмасы 1878 елны элекке Казан губернасында булып узган «Мәңгәр», «Тигәнә» восстаниеләрен эченә ала.

Бу восстаниеләр авылларга пожар сарайлары салдырып чаң куйдыруга каршы дини мотив белән башлансалар да, асылда, милли изүгә, самодержавиенең рәхимсез кысуына, талавына чыдаша алмыйча күтәрелгән крестьян восстаниеләре булалар.

«Ялкын» драмасы ике кисәктән торырга тиеш дип уйланыла. Аның шушы беренче кисәге Татарстан республикасының XX еллык бәйрәменә багышлап язылган. Аңарда татар хезмәт иясе халкының патша Россиясендә, самодержавие изүе астында нинди авыр тормыш белән яшәвен, нинди фаҗигале, газаплы хәлләрне кичерүен җанландырып күрсәтү - бурыч итеп куелды. Драманың бу беренче кисәгендә восстаниенең башлануына сәбәп булган төп мотивлар гына бирелә.

*25 май, 1940 ел*

**«Кыю кызлар»**

«1939 елны язылды. Һәм шул елны Татар дәүләт академия һәм Башкорт дәүләт академия театрларында куелды. Бу әсәр, минем уйлавым буенча, татар халкының иске тормышын күрсәтү ягыннан энциклопедия булырга тиеш иде. Андагы типлар галереясы, халыкчанлык мотивлары, мәдрәсә тормышы, руханиларның пычрак яклары җитәрлек бирелгән. Иске татар тормышын хәзерге яшьләргә күрсәтү ягыннан әсәрнең кыйммәте хәзер дә бик зур. Әсәр, гомумән, җәмәгатьчелек тарафыннан яхшы бәя биреп каршыланды. Уфадагы постановканы күрмәдем. Әйтүләренә караганда, анда шәп барган, шулай ук Мәскәүдән килеп караган тәнкыйтьче Калашников зур бәя биргән, һәм шул ук фикерен «Искусство» газетасына да язып чыккан иде».

**«Башмагым»**

«1941 елның ноябрь ахырлары иде. Бөтен көнбатыш якларыннан Казанга эшелон-эшелон булып завод-фабрикалар күчеп киләләр. Немецлар Мәскәү янына килеп җиттеләр. Хәзерге Татар дәүләт академия театры эвакопунктка әйләндерелде. Татар театры Большой театрда атнага берничә спектакль бирә. Опера театры бөтенләй эшләми. Шәһәрдә күңелсез, кичләрен урамнарда ут юк, караңгы, йөреп булмый. Шундый төннәрнең берсендә Җәүдәт Фәйзи миңа килде. «Таҗи абый, болай булмый бит инде, халыкның күңелен күтәреп аласы иде», — ди. «Нәрсә белән?» — «Менә миндә «Башмагым» дигән бер әсәр бар. Әгәр дә син шуннан миңа либретто язып бирсәң, мин музыкаль комедия язар идем»,— ди.

Мин «Башмагым» әсәренең иске вариантын (Хәбибулла Ибраһимовның шушы исемдә проза жанрында язылган пьесасы күздә тотыла.— *К.Г.*) белә идем, язарга вәгъдә бирдем, һәм тиз арада эшләп тә бетердем. 1942 елның февраль аенда Опера театры тарафыннан куелды. Шуннан бирле өзлексез рәвештә бара»...

**«Таймасовлар» («Патриотлар»)**

«1941 елны Мәскәүдә булачак Татар сәнгате декадасы өчен махсус заказ белән язылды.

Беренче мәртәбә 1941 елның 28 августында Татар дәүләт академия театрында куелды. «Кызыл Татарстан» газетасында Г.Кутуйның мактап язган мәкаләсе басылды. Әсәр бөтен сугыш еллары буена уйналып килде».

**«Изге әманәт»**

(Әсәр Донбасс татарларының немецлар оккупациясе чорында Ватаныбызга карата тугрылыгын чагылдыруга багышланган. Донбасстагы татар шахтерларының оккупация дәверендәге тормышын өйрәнү максаты белән Т.Гыйззәт 1943 елның җәендә Донбасс шәһәрләренә махсус сәяхәт кыла.— *К.Г.*)

«Изге әманәт» 1944 елны язылды. Язылып бетү белән Язучылар союзында укыганда, Кави Нәҗми, Гази Кашшаф, Мирсәй Әмир, Гомәр Бәшир, Дәрҗия Аппакова һәм башка иптәшләр катнаштылар. Әсәргә бик зур бәя биреп, Ватан сугышын чагылдырган сәхнә әсәренең иҗат ителүен, «Ташкыннар»га тиңдәш әсәр тууын әйттеләр. Ләкин, көннәр үтү белән, әкренләп фикерләр үзгәрә башлады. Әсәрдә нииндидер кимчелекләр күрмәгә керештеләр. Төрле җирләрдә яңадан укулар оештырылды. Җаваплы урында эшләүче бер иптәш хәтта шушындый «акыллы» сүз әйтте: «Шахтерлар тормышы турында Шәриф Камалның «Козгыннар оясында» драмасы бар, шулай булгач, «Изге әманәт» әсәрен сәхнәгә куюның кирәге бар микән?» —диде...

Шуннан инде башланды... Берсенә ул җитми, икенчесенә бу ошамый. Акыл саталар, үзләренчә киңәшләр бирәләр. Шулай да әсәр төрле җирләрдә укылып йөргәннән соң, аны куярга булалар...

«Тәнкыйть яратмыйсың икән» дип уйлый күрмәгез, мин тәнкыйть белән үстем, хаклы рәвештә ясалган файдалы тәнкыйтьләргә колак салып, әсәрләремне һаман төзәтә барам, һәрберсен кабат-кабат яңадан язам. Мәсәлән, «Бишбүләк» әсәренең унбишләп варианты бар. «Наемщик», «Чаткылар» драмаларын әйткән дә юк. Хаклы булган тәнкыйтьне мин һәрвакытта кабул итәм. Әгәр дә инде югарыда әйтеп киткән кебек «тәнкыйтьләрне» кабул итмим икән, бик дөрес эшлим.

Минем дөньяга, әдәбият, сәнгатькә булган карашым бар. Бу карашым мине халкым интересларына бервакытта да каршы куймады һәм моннан соң да куймас дип ышанам».

**«Чын мәхәббәт»**

«1947 елны язылды... Әсәр тамашачылар тарафыннан тирән мәхәббәт белән каршы алынды. Куелган спектакльләр күтәренке рухта барды. Көннән-көн тамашачыларны үзенә җәлеп итте...

«Чын мәхәббәт» Казанда гына түгел, Свердловск, Чиләбе, Магнитогорск, Уфа, Куйбышев, Ташкент шәһәрләрендә дә уңыш белән бара. Газеталарда зур мактаулы рецензияләр ала. Ике ел эчендә 92 мәртәбә уйналып, театрга иң күп доход китерүче әсәр булып исәпләнә. Куйсалар, хәзер дә ул тамашачыны тартыр иде».

**«Алсу таң» («Мин-минлек корбаны»)**

«Алсу таң» әсәре 1949 елның башында Татарстан республикасының XXX еллык бәйрәменә багышлап язылган иде. Һәм шул көннәргә багышлап постановка итеп тә әзерләнгән иде...

Әсәр сәхнәгә куелмады. Шуннан мин әсәрне «Совет әдәбияты» журналына басарга тәкъдим иттем. 1952 елның беренче санында ул басылып чыга»...

## ЭЧТӘЛЕК

Ялкын (Фәрхиназ) ...........

Кыю кызлар .............

Башмагым ..............

Таймасовлар (Патриотлар) ......

Изге әманәт .............
Чын мәхәббәт ............
Алсу таң (Мин-минлек корбаны) ...
Автордан .............

Литературно-художественное издание

*Тази* ***Гиззат***
*(Гиззатов Тази Калимович)*

ПЬЕСЫ

Казань. Татарское книжное издательство, 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

*Таҗи* ***Гыйззәт***
*(Гыйззәтов Таҗи Кәлимович)*

ПЬЕСАЛАР

Мөхәррире *В.Р.Шәрипова*
Рәссамы *И.Р.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.06.2006. Форматы $84\times108^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Times» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 20,16. Шартлы буяу-оттиск 20,58.
Нәшер-хисап табагы 20,90. Тиражы 2000 д. Заказ З-495.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.